ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

3.2002



# «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ




ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты Секретариатының 1930 елның 20 июнендә булган киңәшмәсе кабул иткән карарда мондый юллар бар: «... «Безнең юл» журналын Наркомпрос органы буларак сакларга, анда культура-политик һәм гыйльми мәсьәләләрне киңрәк яктыртырга, шулай ук бу журналда татар совет язучыларын тагын да киңрәк төстә катнашырга җәлеп итәргә. Бу журнал өчен тарихи-революцион исем буларак, «Яңалиф» исемен сакларга...»

Июль аенда Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасының айлык әдәбият, сәясәт, сәнгать һәм тәнкыйть журналы «Яңалиф»нең (редакторы Фатих Сәйфи-Казанлы) беренче саны дөнья күрә.

Журналның үз йөзе, төзелеше, рубрикалар системасы булырга кирәк. «Яңалиф» түбәндәге сәхифәләрдән тора: сәясәт, матур әдәбият, әдәбиятны өйрәнү, сәнгать, культура-көнкүреш, библиография, тәнкыйть һәм хроника.

Айга бер мәртәбә чыга торган калын журнал буларак, «Яңалиф» күләмлерәк чәчмә әсәрләргә, шигърияткә һәм сәяси мәкаләләргә урын бирә. Анда М. Галәү, Ф. Хөсни, Ф. Сәйфи-Казанлы, И. Туктар, Ш. Камал, А. Алиш, М. Әмир, И. Гази хикәяләре; Һ. Такташ, Ф. Кәрим, Х. Туфаннарның поэмалары; С. Хәким, Ә. Исхак, Х. Мөҗәйнең һәм башкаларның шигырьләре, күренекле чит ил һәм рус язучылары әсәрләреннән тәрҗемәләр дөнья күрә. Әдәби хәрәкәтне күзәтү, бәяләү журналда даими һәм житди төстә алып барыла.

«Яңалиф» латин имласында, 2000—2200 тираж белән 1932 елның ахырына кадәр чыккан.

# Казан утлары
# Qazan utları

*2002*

**3**

**(953)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*


ШИГЪРИ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

ЗӨЛФӘТ. Сүзләрнен бар шундый кәрваны... *Шигырьләр* .......... 5
Суфиян ПОВАРИСОВ. Оҗмахка бер адым. *Роман* .......... 10
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Каюм коесы. *Поэма* .......... 58
Илсөяр ИКСАНОВА. Кышларның суыгын җылытып. *Шигырьләр* .......... 105
Камил СӘГАДӘТ. Кайтып киләм. *Шигырьләр* .......... 108

«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Юл башында нурлы яктылык ул... .......... 88
Әхсән ФӘТХЕТДИНОВ. Кадерле яктылыклар .......... 122
Әхмәт ГАЛИЕВ. Милләтебез горурлыгы .......... 157

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Гомәр ГАЛИ. Харис Саттаров. *Хикәя* .......... 110

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Рәдиф ГАТАШ. Йолдызларны танып, сөенә белик... .......... 118

ТАРИХ

Солтан ШӘМСИ. Низаглы йортта .......... 68
Раиф МӘРДАНОВ. Тарих битләрен актарганда .......... 125
Лена ГАЙНАНОВА. Рәшит Рәхмәти Арат һәм Гаяз Исхакый .......... 162

Коръән татар телендә .......... 138

СӘНГАТЬ

Наис ГАМБӘР. Беренчеләр *(Композитор М. Мозаффаровның тууына 100 ел)* . 153

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Ләйлә МИНҺАҖЕВА. Халык иҗатыннан көч алып .......... 156

КИТАП КҮЗӘТҮ

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Безнең дә әниләр бар иде... .......... 171

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Фәнис ЯРУЛЛИН. Бәхетле пар .......... 176

КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ

Ләлә ГЫЙМАДИЕВА. Капка. *Хикәя (Ф. Латыйфиның кереш сүзе белән)* .......... 181

ХӘТЕР

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Үзбәк абый үз иде. .......... 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .......... 189

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман С. ПОВАРИСОВА «Один шаг к раю» *(окончание)*; поэма Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ «Колодец» и стихи ЗУЛЬФАТА, И. ИКСАНОВОЙ, К. САГАДАТА.
«Из сокровищницы татарской литературы»: рассказ Г. ГАЛИ «Харис Саттаров».
«К 80-летию журнала»: «Казан утлары в моей жизни»—воспоминания А. ГИЛЯЗОВА, А. ФАТХУТДИНОВА, А. ГАЛИЕВА.
«История»: С. ШАМСИ «В скандальном доме» *(страницы истории Золотой Орды)*, статьи Р. МАРДАНОВА «Страницы истории» и Л. ГАЙНАНОВОЙ «Рашид Рахмати Арат и Гаяз Исхаки».
«Литературная критика»: Р. ГАТАШ. «Есть звезды на небосклоне поэзии».
Коран на татарском языке.
«Искусство»: Н. ГАМБАР. «Они были первыми» *(к 100-летию композитора М. Музаффарова)*.
«К истории литературы»: Л. МИНГАЗОВА. «Корнями в народном творчестве».
«Книжное обозрение»: Р. ШАРАФИЕВ рецензирует новую книгу Ш. Маннапова.
«Юмор и сатира»: рассказ Ф. ЯРУЛЛИНА «Счастливая пара».
«Писатели—современники»: Л. ГИМАДИЕВА. Рассказ «Ворота»
«Память»: Р. ФАЙЗУЛЛИН. «Он наш—Узбек абый»
На наших обложках: «Под лунным светом»—картина художника А. Фатхутдинова; поэтесса Н. Сафина.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": S. POVARISOV'S novel «One step to paradiset» (finishing); I. SHARIFULLINA'S poem «The well» and verses of ZULFAT, I. IHSANOVA, K. SAGADAT.
"From theasury of tatar literature": G. GALI'S story «Haris Sattarov».
"Commemorating of 80th anniversary of journal": «Kazan utrary in my life» - memoris of F. GILYZOV. A. FATHUTDINOV, A. GALIEV.
"History": S. SHAMSI "In scandalous house" (the history pages of Gold Orda), R. MARDANOV'S article "Page of history", L. GAINANOVA "Rashit Rahmati Arat and Gayaz Ishaki".
"Literary criticism": R. GATASH "Exist sctars on horizon of poetry".
"Koran in Tatar language".
"Art": N. GAMBAR "They was former" (commemorating of 100th anniversary of composer of M. Muzzafarova).
"History of literature": L. MINGAZOVA "The rootes in national creative".
"Book review": R. SHARAFIEV reviewaring od new book of Sh. Mannapov.
"Humor and satira": F. YARULLIN'S story "Happy pair".
"Writers - contemporary": story's L. GIMADIEVA "Gate".
"Memory": R. FAIZULLIN "He our - Uzbek abzy".
The diary of social and cultural life.
In our covers: "Under moon light" - picture of artist A. Fathutdinov, poet N. Safina.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 26.02.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8765 Заказ Б—100
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.



## Зөлфәт

### СҮЗЛӘРНЕҢ БАР ШУНДЫЙ КӘРВАНЫ...

#### Күзгә-күз

Күпме яшәп була, адәми зат,
Һаман набат сугып, чаң кагып?—
Бераз гына туктап уйлан әле
Сызылып аткан таңга таң калып!

И талкыйбыз сыман бу дөньяны!
Ду киләбез... хәйран тамаша!—
Тамашадан айнып бер карасаң,
Дөнья безне талкый лабаса!..

Кул селтә дә дөнья шау-шуына,
Алсу таңга ишек ач! Керсен...
Уйларыңа тылсым фәрештәсе
Канатының очын тидерсен!

Менә шунда, уйларың сүз булып
Очар... гүя кошлар кәрваны...
Ә сүзләрнең шундый кәрван булып
Биекләрдә очып барганын

Шигырь диеп ышанып гел яши
Шагыйрь дигән сәер бер нәсел!
...Сызылган таң белән алар һаман
Гел күзгә-күз кала, күрәсең...

ЗӨЛФӘТ *(1947)—шагыйрь, «Язмышлар ярында», «Утлы бозлар», «Йөрәгемне былбыл чакты» һ. б. китаплар авторы. Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2000). Казанда яши.*

## Зарыгу

Була шундый дуслар... Акыл аңлый—
Юлларында инде бу җирнең
Очрашулар, күрешүләр булмас...
Ул аръягына китте гомернең!

Каршы очрап, ихлас сәламләшеп,
Бер сүз алмашырдай кемнәр бар?
Җан дус белән гәпләшәсе килгән,
Киңәшәсе килгән көннәр бар...

Юл узышлый гына эндәшсә дә
Бөтенәер,
Бүтәнәер иде дөньялар:
—Йә, картаеп буламы соң анда?
Ниләр кыйратасың? Ниләр бар?

Дуслар исән-сауда—юллар тауга!
Юл һич бетмәс сыман барасың.
Вакыт үзе мәллә шигырь әйтә—
Гади сүзләрне дә шигырәйтә...
Мәңгелекнең тойгач карашын!

Шигырь—гомер... Чын дусларга дәшеп
Тәмамласам икән мин аны:
—Йә, ниләр бар? Нихәлләрдә, дустым?
Җир җимертеп яшәп буламы?

...Даһи акыл һәм хис иясе
Әйткән бөек сүзләр барында,
Болай гына әйтелгәндәй сыман
Сүзләрне ник күңел зарыга?

Болай гына, дидем... Юк, түгел лә!—
Ул сүзләр бит, уйлап карасаң,
Мөмкиннән һәм мөмкин түгелдән
Бик тирәннән ташып түгелгән!
Күңелләргә ташкан күңелдән—
Мөмкиннән һәм мөмкин түгелдән...

## Бөек сер

Кеше күңеле миңгә төрләнсә дә
Мәхәббәтле караш бер булыр—
Мәхәббәт ул бөек ачыш булмас,
Ачылмаслык бөек сер булыр.

Күпме яшәсәң дә аңламаслык
Күңел ашкындыргыч шул серең.
Һәр яшәгән көнгә әфсен өрер,
Тылсымы шул булыр гомернең...

Һәммәсен дә аңламакчы кеше!
Акылы белән, әйе, бөектер...
Аңлашылмас ләкин чын мәхәббәт—
Мәңгелектән килгән бөек сер,
Мәңгелеккә калган бөек сер...

Аңлашылса беркөн сөю сере,
Кешелеккә килер зур афәт—
Җиһан үзе юкка чыккан сыман
Юкка чыгар Бөек Мәхәббәт!

Ярый әле, язмыш, насыйп иттең
Сөю дигән чоңгыл-үткелне,
Юкса, узып китәр, бетәр идем
Сердән мәхрүм дөнья шикелле...

## Яфрак ярдың, и сүзем!..

Борынгыдан килгән язмаларга
Гомер багышлаган чын галим
Бер сөйләгән иде—
язмаларның
Ничек кара җиргә чумганын.

Күмелгәннәр күпме кулъязмалар
Кеше белән бергә—
кабергә!
Бу—
язылган сүз өчен һәлакәт тә
Һәм... җан тетрәткеч олы кадер дә...

Элеккедән яшәп килгән йола—
Һәр язганны туфрак итәргә!
Туфрак һәм Күк!—шушы икәү аша
Тәңрегә үк барып җитәргә...

Ышанганнар: сүз—җан...
Язылган сүз—
Җанның тапшырганы кәгазьгә.
Кәгазьләрдә—бөек дастаннар да,
Мөнәҗәт тә, дога-вәгазь дә...

Җан барлыкка дәлил түгелме бу?
Һәр җан—дога... ул—тән җылысы...
Әллә каян серләр эзлисе юк—
Хикмәт шунда, асыл сер шушы!

Җан хакында сөйләү җан сорый, дип,
Җан дияргә хәтта куркабыз.
Яктыртсын җан тома караңгыны,
Кара төндә, кардәш, ут кабыз!

Бөек фәлсәфәләр кора-кора,
Кешем, һаман читкә талпынма!
Кан, дан хакында без күп сөйләштек...
Сөйләшикче бер җан хакында...

Яралткыч көч алсу офыкларда
Ярсу-саксыз җанны кабызды.
Җан ул—без үзебез!—Туфрак һәм Күк!
Туфрак һәм Күк—Бөек Ялгызлык!

...Кульъязмалар күмелгәннәр элек
Кеше белән бергә кабергә...
Язылган сүз өчен кабер дә бу,
Язылган сүз өчен кадер дә бу,
Җан белән сүз гел бер... гел бергә!

Тентү арты тентү керә торган
Караңгы һәм шомлы дәвердә,
Табылмас, дип, кабер тентүчеләр,
Яшергәннәр һаман кабергә
Изге сүзләр язган кульъязманы,
Яшергәннәр сүзнең газизен...
Асыллары сүзнең туфрак булган...
Җанда яфрак ярдың, и сүзем!

Тере бул син... Һаман җанда бул син—
Һаман янда, һаман ерак бул!
...Минем белән бергә күктән иңдең,
Минем белән бергә туфрак бул!..

## Тансык

Акыл сату җиңел... Әмма, никтер,
Сатып алып булмый акылны—
Сәфәрчеләр шуңа гел юл сапты,
Гел бушлыкка уклар атылды.

Гел акыллы гына яшәүчеләр
Бар бит җирдә, бар бит, җитәрлек.
Алардагы акыл
диңгезләрне
Чыланмыйча җәяү үтәрлек.

Алардагы акыл җитеп ашкан,
Акыл сата алар нәкъ шуңа—
Юнәлтмәкче булып бәндәләрне
Гел әйбәткә, һаман яхшыга.

Мактый-мактый сата алар һаман,
Йә, җәмгысы күпме сатылды?
Никтер, алучылар күренми шул
Менә дигән сатлык акылны!

Хәер, мөмкиндер бит рәхәт яшәү
Акыл шундый тансык вакытта,
Акыл базарында ду китереп
Юк акылны хәтта сатып та?!
Юк акыл да—акыл...
тансыкта!

## Һуш

Инде Әмирхан ага да
Бик ипле генә
Күз салды җан ышыгына—
Мәңгелегенә...

Саф дәрья суларын таба,
Агымын таба

Синдәй саф уйлаган уйлар,
Әмирхан ага!

Затлы гомереӊ укыйм да
Тетрәнеп китәм:
—Әйтәсен әйтте...
Күбесен
Ул алып киткән!

Шул соңгы сагы да киткәч
Әдәби һушның,
Ходам, безгә тагын ниләр
Кылырга куштың?

Белмим, тагын ни кылырбыз
Мондыйлар юкта?
Бусы—соңгысы.
Бүтән юк!
Мәңгелек нокта...

...Менә шулай безнең тарих
Тын, иплe генә
Китеп бара бугай инде
Мәңгелегенә...

## Төнге гөлләр

Гөлләр җылысыннан мантый дөнья
Йолдызлары салкын төн килсә...
Җылытырга түгел, җылынырга
Диеп шыткан гөлләр югыйсә!

Җылынырга түгел, җылытырга
Моңнар тулып күңел яралган—
Шул күңелдә шигырь—сулык-сулык!
Ул канымa инде таралган...

Сыенадыр шигырь төнге гөлгә...
Шигъри сүздән дөнья җылынсын!—
Күшеккәндә, яшәр җылы эзләп,
Шигъри сүзгә еллар сыенсын!

Гомерлеккә җитәр итеп сеңдер
Гөл җылысын, гөлләр яктысын,
И күңелем! Сиңа сыенсын да
Җылынсын бу дөнья, яктырсын!

...Чиксезлеккә эндәшәм бит инде
Тын гөлләргә дәшкән шикелле...
Гөл җылысы бераз җылытмасмы
Йолдызлары салкын бу төнне?—

Шуңа күрә, япа-ялгыз чакта,
Йолдызлары салкын төннәрдә,
Өшәнгән бу җаным җылынсын дип,
Сыенам мин төнге гөлләргә...

*2000-2001*

# Суфиян Поварисов

## ОҖМАХКА БЕР АДЫМ

РОМАН

### Дүртенче бүлек

Казан каласы кайгылардан исәңгерәп калган кебек.

Тышта жил исә.

Зәһәр жил йөзъяшәр карт агачлар белән көрәшеп, аларның ботакларын сындырып бетерә, аннан Сөембикә манарасына килеп ябырыла, янә өлкә комитеты йортларының түбәләрен зыңгылдатып үтә, шуннан Пелатән төрмәсенә китә: монда аның ачуы мең өлеш кабарачыдый алмыйча, йә карт бүре булып улый, йә яралы аю шикелле үкерә.

Пелатән төрмәсендәге фаҗига Татарстан җөмһүрияте фаҗигасе. Татар халкы афәте. Чөнки, ни дисән дә, монда күбрәк Татарстанның үз кешеләрен китереп тутыралар.

Сәламәт тоткыннарны артык нык җәзалыйлар. Кулларын каерып, аякларын сындырып бетерәләр. Кул тырнаклары астына энә кадыйлар. Тәүлекләр буе йокысыз басып торырга мәҗбүр итәләр. Һуштан язганчы тукмау, су сибеп янә изәргә керешү... Түзә адәм баласы. Чыдый. Сабырлык күрсәтә. Чөнки үзен гаепсез сизә ул. Дөрес, үләр чиккә җиткәненен төрле уйдырма язуларга кул куйганнары да бар. Мондый очракта алар: барыбер атылам, бу вәхшәттән котылып булмас»,—дип уйлый. Болары, чыннан да, йә атыла, йә мәңгелек сөргенгә, каторгага җибәрелә.

Чирлеләр аерым яши. Алар арасында да үзгәрешләр булып тора.

Нифаков акылыннан язды. Аны психбольницага күчерделәр. Озакламый үлүе турында хәбәр килде.

... Каюм Йосыповны тукмалган, изелгән, беткән килеш кертеп ыргыттылар. Тешләрен коеп бетергәннәр. Бер күзе чыккан. Аның ахыргача көрәшүе күренеп тора.

Галимҗан Ибраһимов өчен бик авыр иде бу хәл. Чөнки Каюм Йосыповның дөрес кеше икәнлеген яхшы белә. Севастопольдән Казанга Пелатән төрмәсенә товар вагонында алып кайтканда да күрсәтте ул олы йөрәклелекне. Вакытсыз үлемнән саклап алып калды аны. Ә менә үзенә яшәү бүләк итеп булырмы? Галимҗан Ибраһимовның үз хәле соңгы көннәрдә берникадәр яхшырып китте. Бу—табибә Фатыйма ханымның

---

Ахыры. Башы 2 санда.

җылы күз карашы, йөрәген ярып бирергә әзер торуы аркасында да иде. Ул, билгеле, андый миһырбанлылыкны башкаларга да еләшә. Галимҗанга ул әледән-әле тәмле-татлы ризыклар да алып керә.

—Кирәкми, акыллым, мин сезгә беркем дә түгел бит, гаилән, балаларың бардыр, белсәләр, минем өчен үзегезне харап итәргә мөмкиннәр,—дип тә карый Ибраһимов.

—Ике яшьлек кызым, биш яшьлек улым бар, Галимҗан абый, ирем яхшы урында эшли—прокурор, бик акыллы, унган кеше,—диде табибә бер сөйләшкәндә.—Ул сезне яхшы белә, әсәрләрегез буенча. Сезне коткару чарасын эзли.

—Менә монысы кирәкми, акыллым, кабатлап әйтәм: минем аркада авырлык күрә күрмәгез.

—Минем ирем куркак түгел, Галимҗан абый, үзем дә яратмыйм түбән җанлыларны.

—Рәхмәт, акыллым...

—Ирем сезнең хакта сорашып кына тора, Галимҗан абый! Сезне коткарачаклар, менә күрерсез. Шундый әсәрләр язган кеше нишләп «халык дошманы» булсын инде, бу бер аңлашылмаучылык кына. Тик... Шул урында сүзе киселде Фатыйма ханымның.

Ибраһимов сорарга мәҗбүр булды:

—Нәрсә: «тик?»

—Ирем әйтә: допрос вакытында үзен бик дорфа тотмасын, аларны җинеп булмый барыбер, ди.

—Намусым кушканча кыланам, балакаем, табигатем шулай.

—Сезнең хакта бөтен шәһәр халкы сөйли. Кем-кем, әмма Галимҗан Ибраһимов «халык дошманы» булмас, диләр.

—Төрлесе бардыр инде, балакаем!

—Андыйлар күп түгел.

Каюм Йосыповның хәле көннән-көн авырая баруы нык борчый Ибраһимовны. Галимҗан ана Фатыйма алып килгән ашамлыкларны да тәкъдим итә. Ләкин алмый аны Каюм Йосыпов. Ибраһимов аңлый моның сәбәбен: Галимҗан абыйсының үз җанын сакларга кирәк, янәсе. Тик монда башка хикмәт бар икән: комиссар Йосыпов яман шеш яки рак белән авырый башлаган. Юньләп ашамаганына бер айга якын булган инде. Ләкин чирен берәүгә дә әйтмәгән. Ә «дәҗҗал»[1]га көн дә диярлек чакырганнар. Газаплыйлар, алдан әзерләнгән язуга кул куярга үгетлиләр. «Мин халык дошманы», «Мин фашизм ялчысы», «Мин совет властена каршы» кебек сүзләр, башка гаепләүләр дә бар анда. Әлбәттә, сорау алучылар белгән аның ашказанында рак икәнлекне. Табиблар куйган шундый диагнозны. Ә инде язуга кул куйдырырга тырышучылар, әгәр алар теләгән үтәсә, «алтын сарай» вәгъдә иткән: дәвалау өчен авырулар бүлмәсенә чыгарачаклар, гомерен саклап калачаклар, тегесе-монысы.

Каюм Йосыпов шул ерткычларча кыйналудан соң озак яшәмәде. Көннәрдән бер көнне аны «үлем бүлмәсе»нә чыгардылар. Икенче көнне инде «үлем бүлмәсе»ндә ул булмаган. Димәк, иртәнгә чаклы өзелгән гомере. Кая алып киткәннәр? Кайда күмгәннәр? Беркем дә белми. Чөнки «халык дошманы»ның кабере юк. Бер төнне әллә ничә тоткын хушлаша фани дөнья белән. Шәһәр читендә «халык дошманнары»ның «үләт базы» бар, имеш. Шунда илтеп аударалар икән аларны.

Каюм Йосыповның үлеме ноябрь башындагы салкын иртәгә туры килде. Ачы җилләр котырынды. Көчле буран купты. Кышкы гарасат шашынып җенләнде. Шул «халык дошманнары»ның «үләт базы» өстендә мең дию пәрие улаган тавышлар чыгарып шыңшыды. Аннан бөтен Казан каласын дер селкетеп чыелдады.

---

[1]Тоткыннар «допрос»ны үзләренчә «дәҗҗал» дип атадылар, чөнки сорау алу вакыт-вакыт шул дәрәҗәгә барып җитә.

Шул көнне Галимҗан Ибраһимовны янә «дәҗҗал»га чакырдылар. Тикшерүчеләр җәза төрләрен алыштырып кына торалар. Берсеннән-берсе газаплырак булганнарын уйлап табалар. Җәзага күпләр түзә алмый. «Дәҗҗал»дан чыгу белән егыла. Бәгъзе берсе еландай бөгәрләнеп ята. Икенчесе үгездәй үкереп еларга керешә. Өченчесе сүзсез генә әрни.

Бүген тикшерүче башка кеше иде. Кырык яшьләр чамалы, аксыл йөзле, килешле гәүдәле, чибәр генә кеше утыра иде өстәл артында. Галимҗан Ибраһимовны ул ачык йөз белән каршы алып, алдындагы утыргычка утырырга кушты. Аннан алар бер-берсенә озак кына карашып тордылар. Тикшерүченең нигә алмашынганын аңлады Галимҗан Ибраһимов. Тегесе белән борчаклары пешмәде. Ул артык тупас телле иде. Надан иде. Сорауны да рәтләп бирә белми иде хәтта. Һәр сүзеннән сәяси мәсьәләләрдә аксаганлыгы сизелеп торды. Монысы аңа охшамаган. Аның шулай икәнлеге сүз башлавыннан ук күренде. Каршысында «халык дошманы» түгел, бөтен төрки телле халыклар өчен уртак язучы булып даншөһрәт казанган, академик, Хезмәт Герое, тарихчы, тәнкыйтьче, тел галиме, педагог, методист, революционер Галимҗан Ибраһимов утыруын яхшы белә иде ул.

Тикшерүче сүзне бик йомшак башлады:

—Галимҗан Гирфанович! Сезнең эшне миңа тапшырдылар,—диде ул.—Моңа чаклы булган тикшерү кәгазьләре буенча фикер йөртсәк, миңа аларның барысы да таныш, шуңа күрә сораулар күп бирүне артык, мәгънәсез, урынсыз эш дип исәплим. Минем ихлас күңелдән, чын ирләрчә сөйләшәсем килә. Мин, билгеле, юрист кеше, канункар буенча эш итүче, тик шулай да законнардан өстен торган нәрсәләр дә бар бит бу дөньяда. Ул да булса кеше язмышы. Ләкин кемдер әйткәнчә: «Закон тәртә белән бер, кая борсаң, шунда бара»,—дип тә булмый. Бу әхлаксызлык булыр иде. Хәер, сез зур мәгълүматлы кеше. Боларның барысын да безгә караганда күбрәк аңлыйсыз. Кыскасы, мине сезнең язмышыгыз борчый. Без сезне коткару ягында. Бөтен Казан халкы кызыксына сезнең язмыш белән. Алар сезнең котылуны тели. Чөнки сез—татар халкының горурлыгы булу дәрәҗәсенә күтәрелгән бөек шәхес. Мин бит сезнең «Безнең көннәр», «Яшь йөрәкләр», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар» кебек татар классик әдәбиятының алтын фонды булырлык романнарыгызны укып, тәрбияләнгән кеше. «Татар хатыны ниләр күрми», «Кызыл чәчәкләр», «Алмачуар» кебек әсәрләрегез генә ни тора! Образлы, матур тел белән язылган «Яз башы», «Сөю—сәгадәт», «Табигать балалары», «Диңгездә» хикәяләрен сездән башка берәү дә бу кадәр классик дәрәҗәдә иҗат итә алмый. Минем әтием белән сез «Галия» мәдрәсәсендә бергә укыгансыз. Ул сезнең үзегезгә дә, зур әдәбиятыгызга да мөкиббән гашыйк иде. Мин дә хыялландым язучы булырга. Моңа сез гаепле. Сезнең әсәрләрегез сихерләде мине. Язарга каләм алуым шуңа бәйләнгән. Юридик институтта укыганда каләм тибрәтүчеләр әдәбият түгәрәге оештырган идек. Мин аның җитәкчесе булдым. Сезнең әсәрләрне укып бәхәсләшкән, фикер алышкан чаклар сагынып искә алырга гына калды. Ышансагыз—ышаныгыз, ышан-масагыз—юк: «Яшь йөрәкләр» исемле романыгызны әллә ун мәртәбә укып чыкканмындыр. Беркайчан да туйдырмаган тәмле аш кебек бит ул!

Бик күңелле иде бу сүзләрне ишетү Галимҗан Ибраһимов өчен. Кайсы гына язучы яратмый мактаганны? Барысы да ярата.

Тикшерүченең фикер йөртү офыклары шактый киң кебек тоела. Аның хакыйкатенә ышанырга ярыймы соң? Мондыйларны беренче мәртәбә очратуы түгел бит Ибраһимовның. Шул фикерләрен раслау өчен сорауны үзе бирергә мәҗбүр булды ул:

—Бу фикерләрегез бүгенге хакыйкатькә туры киләме?

Тикшерүче уйланып калды.

—Фикерләремнең бүгенге хакыйкатькә туры килмәве дә мөмкин, Галимҗан Гирфанович, бу бәхәскә кермим, сезнең белән сөйләшүнең

авыр булачагын да анлыйм, ләкин сүзне бер фикер тирәсендәрәк йөртсәк иде.

—Тынлыйм.

—Сезнең барлык әдәби әсәрләрегезне, тел, әдәбият, тарих, фәлсәфә, педагогика, методика буенча язган хезмәтләрегезне бөтен җирдән җыеп алдылар. Ләкин кайберәүләрнеке кебек яндырылмаган әле. Алар тиешле урыннарда саклана.

—Минем бөтен борчылуым да шул әсәрләрем, фәнни хезмәтләрем өчен. Ә инде гомер өмет итмим.

—Сез әле яшәргә тиеш, Галимҗан Гирфанович, халык өчен, ил өчен! Без моны булдыра алабыз. Сезне шәһәрнең иң абруйлы больницасына күчерү турында сүз бара. Муеныгызга кидерелгән «халык дошманы» камытын да алып ташлаячакбыз.

—«Быз» дисез. Кемнәр соң алар?

—Югарыдагылар һәм мин.

—Анлыйм: кул куярга кирәк.

—Теге үткәндәге сораулар, «фашист ялчысы» дип әйтүләр алып ташлана. Сез андый кеше түгел. Менә хәзер кул куюның бернинди авырлыгы да юк. Кабатлап әйтәм: бүгенге имзагыз сезнең үзегезне үлемнән коткарып калып, әсәрләрегезгә яшәү мөмкинлеге бирәчәк.

—Рәхмәт! Мин Киев төрмәсендә дә утырган кеше. Оренбургта 1905 елгы революция демонстрациясенә катнашып, аннан Вәли мулла мәдрәсәсеннән, соңрак Уфадагы «Галия» мәдрәсәсеннән сөрелеп, озак еллар полиция күзәтүе астында яшәгән ышанычсыз гына түгел, хәтта патша хөкүмәте өчен куркыныч кеше идем...

—Димәк, анлаштык! Менә бу кәгазьдә, моңа чаклыларыннан аермалы буларак, сезнең намусыгызга энә очы зурлыгы да кара тап төшерелмәгән нәрсәләр язылган. Укыгыз да, имзагызны куегыз.

«Мөртәтлек» шактый озын язылган. Ун бит чамасы. Дикъкать белән укыды аны Галимҗан Ибраһимов. Бүген дә, башка вакыттагы кебек, үзен тыныч тотарга, йөрәккә кылчыктай кадалырлык нахак-мәгънәсез, адәм ышанмаслык сүзләре булса да, игътибар итмәскә тырышты. Шулай да укыган саен йөзе үзгәрә, ачуы кабара, күнеле тетрәнә башлады. Дөрес, тикшерүче әйткәнчә, Галимҗан Ибраһимовның үз намусына бернинди дә кара ягылмый анда. Киресенчә, анын зур язучы, ышанычлы, намуслы шәхес булуы турында әйтелгән. Анда алты язучы турында сүз бара. Һәрберсенең әсәреннән менә бүгеннән үк «халык дошманы» итәрлек мисаллар табылган. Анын ачуы йөзенә чыкты. Күп яшь көчләрне үстерде ул. Дөрес, каты булды, көчле булды, таләпчән булды. Тәнкыйть итүдән дә курыкмады. Унай һәм кире якларны аерып күрсәтә белде. Шушы яшьләрнең әсәрләреннән «халык дошманы» ясарлык «хаталар» тапканнар. Бу юл белән китсәң, барлык язучыны утыртып бетерергә мөмкин. Әсәрдәге гәүһәрләрне күрмиләр, шул гәүһәрләр асылына сыенган көферлекне эзләп маташалар. Шунысы көн кебек ачык: ул «кырлык»ны НКВД кешеләре таба белми. Алар бу әсәрләрне ниндидер бер язучыга биргәннәр. Түләү зур—бу болганчык заманда «газиз» җанкаен саклап кала ич.

—Боларның барысы да талантлы, зур язучылар, аларның әсәрләрен кем тикшергәндер, бу каләресе мина караңгы; янә шуны әйтә алам: ул күрсәтелгәннәрнең берсе дә хата түгел. Аларда язучының тормышка, чынбарлыкка, кешеләргә биргән житди, объектив бәясе; мин моңа кул куймыйм,—диде дә кәгазьне тикшерүченең үзенә кире кайтарды Ибраһимов.

Тикшерүче йөзен үзгәртмәскә тырышты. Бу анын өчен табигый хәл иде. Шулай да йөзе акрынлап кара коелды.

Галимҗан Ибраһимов, утырган урыныннан көч-хәл белән торып, чыгып китәргә җыенды. Анын бу кыланышы ошамады тикшерүчегә:

—Әле китәргә рөхсәт бирмәдем. Соравым бар.

—Тынлыйм.

—Сез анда врач Фатыйма Харисовна белән мөнәсәбәткә кергәнсез икән?

—Бу сорауның мәгънәсен анламыйм мин.

—Анламаслык катлаулы бернәрсә дә юк монда.

—Фатыйма Харисовна безнең, ягъни авыру тоткыннарның табибәсе. Авыру белән табибә арасында нинди мөнәсәбәт булырга тиеш тагын?

—Анысы сезнең үзегезгә мәгълүм, Галимҗан Гирфанович.

—Бу—алтын базыннан чүп эзләү дигән сүз.

—«Халык дошманнары» чүпле ил намусын.

—Ә мин сезгә алай уйларга кинәш итмәс идем.

—Димәк, бу язмага кул куймыйсыз?

—Мин ике сөйләшергә яратмыйм.

—Тагын бер мәртәбә сорыйм.

—Сез минем кем икәнлегемне белмисез.

—Беләбез. Әйттем бит инде.

—Андый төче сүзләрнең сәяси бәһасен анлыйбыз. Без инде, әйткәндәй, карт чыпчык. Шомарган таш.

—Алары да мәгълүм.

Галимҗан Ибраһимов бу юлы тикшерүчегә атардай итеп батырып карап торды. Тәндә, гәүдәдә, вөҗүдтә чәүкә куркытырлык көч-гайрәт булмаса да, аның каты, усал карашында биек таулар, таш кыялар җимерерлек көч бар иде сыман. Әмма көчле ачудан үзе тетрәнә, бизгәк тоткан кеше шикелле калтырана башлады. Егылып китмәс өчен уң кулы белән урындыкка тотынды.

—Мин сатлык җан түгел. Дусларымны да, каләмдәшләремне дә, халкымны да, ватанымны да беркайчан да сатмаячакмын!—дип кычкырды ул.

Тикшерүче сакчыларны чакырды. Галимҗан Ибраһимовны алып чыгып киттеләр.

* * *

Галимҗан Ибраһимов салам түшәгенә менеп ятты. Ике кулын баш астына куйды да хатирәләр дөньясына чумды. Шулай яткан чаклары күп булды аның. Солтанморатта—үзләренең бакчасында. Өй янына карават куелган. Укып, язып аргач ике кулын баш астына куеп, күккә карап сузылып ята. Җәйге көннәрдә анда бик рәхәт. Җил чәчләреннән сыйпап иркәли. Җиләк-җимеш исләре аңкып тора. Сирень, сәрби чәчәкләреннән таралган хуш исләр белән аралашып китә алар. Җәйге кыр эшләреннән арып туктагач, зәңгәр күккә карап ятуның ләззәтен башка бернинди рәхәтлекләр белән дә алыштырып булмыйдыр. Казакъ далаларында да шулай зәңгәр күккә карап сузылып ятканы бар. Кавказда нугай балаларын укытканда да. Киевта да. Зәңгәрлекләр дә төрлечә икән. Солтанморат күге—куе зәңгәр. Казакъныкы—ачык зәңгәр. Кавказныкы—көрән-зәңгәр. Киевныкы—сыек зәңгәр.

Зәңгәр күзләр дә бик күп. Алар да төрлечә зәңгәр. Һич аерып бетерер хәл юк. Беренче очрашуда аны Гөлсемнең уйнаклап торган зур зәңгәр күзләре сихерләде шикелле. Нинди зәңгәр иде ул? Тәгаен генә әйтеп булмый. Әстерхан күге зәңгәрлегедер ул, бәлки? Чөнки кыз Әстерхан каласыннан иде. Бәлки, әлеге санап киткән зәңгәрлекләр җыелмасыдыр. Матурлыгы белән шул зәңгәрлекләрнең барыннан да өстен торган туган авылы Солтанмораттагы Зәңгәр күзле чишмә зәңгәрлегедер ул.

Мәхәббәт ана шул зәңгәрлекләр аша килдеме? «Өйләнмим» дигән иманын шул зәңгәрлекләр җимердеме? Ул бит—пролетариат революциясе солдаты! Гаилә кору—аның өчен вак нәрсә. Тик мәхәббәт революцияләр, давыллар, утлар, гарасатлар белән исәпләшми икән. Аның үз кануны. Тулпардай ярсып, яшьнәп, күкрәп килә икән ул. Килде. Кочагына алды. Кысты. Үзеннән уналты яшькә кече булган зәңгәр күзле Әстерхан кызына

гашыйк булды. Медицина институтының беренче курсында гына укый икән әле—унтугыз яшьтә генә. Күзләре генә сихерләмәгәндер. Бөтен җире килешле. Өзелеп торган нечкә бил. Калку гына күкрәк. Бөдрә чәч. Йөз чибәрлегенә дә күз тимәсен. Бик тере мәгәр.

Өйләнүне ашыктырды Галимҗан. Очрашып өч-дүрт көн үттеме-юкмы, тәкъдим дә ясады. Колчак тылында йөргәндәге разведчик кыюлыгын күрсәтте. Озак уйланырга вакыт та бирмәде. Хәзергә юньле фатиры да юк. Өс-башы да бик шәптән түгел. Болары вак нәрсә. Кызның беренче курста гына булуы да борчымады аны. Өйләнде дә куйды.

Шулай да икеләнү, шөбһәләр бөтенләй үк булмады түгел. Мәхәббәт җиле беренче мәртәбә генә какмый ич аны. Алмабикә белән булган мәхәббәт романы да шактый хәтәр.

Анысы аның 1906 елда ук башланды.

... Шәкертләрнең миен черетердәй әллә нинди аңлаешсыз иске сабаклар ятлатып, дөньяви фәннәрне укытуга теше-тырнагы белән каршы торган хәлфә мөдәррисләргә каршы чыкканы өчен Ырымбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсеннән куылган иде ул. Бәхете—шул ук елда Уфада «Галия» мәдрәсәсе ачылды. Әтисе Гыйрфан мулла зур тимер арбага Алмачуарын җигеп, китерде дә ташлады «тәртипсез» улын шушы яңа мәдрәсәгә. Тик исеме бар, җисеме юк, дигәндәй, «Галия» мәдрәсәсенең бинасы да төзелмәгән икән әле. Шәкертләр өчен хәзергә дәресханә дә, ятак та юк. Вакытлыча Зариф мулла мәчетендә укытып тормакчылар. Галимҗанның әтисе Гыйрфанның дуслары күп. Шуларның берсе—Уфа каласындагы Габдрахман хаҗи. Гыйрфан мулланың үзе кебек үк, күркәм сыйфатлы кеше. Ике катлы йорты бар. Биш бүлмә. Бакчасында алма, чия, карлыган ... тагы да әллә ниләр үсә. Биш баласының иң зурысы Каһирәдәге Әл-Әзһар дәрелфөнүнендә укый. Тагын өч малае үсеп килә.

«Галия» мәдрәсәсен төзегәч, шәкертләргә ятак булачак, билгеле. Озакка сузылмас кебек. Чөнки мәдрәсә башында Каһирәдә укып кайткан, шөһрәтле Зыяэтдин әл Камали галиҗәнабләре. Ул инде кылны кырыкка яра белүче шәхес. «Галия» эшләре аякка басканчы Галимҗан шул биш бүлмәнең берсендә яшәп торачак. Бәхет бу! Иллә мәгәр бәхетнең монда аннан да зуррагы—тау кадәресе бар икән әле. Монысы—Габдрахман хаҗиның Алмабикә исемле алмадай чибәр кызы. Гимназистка. Күңел дәрьясы киң. Әдәбият, сәнгать ярата. Галимҗан Ырынбурда чакта үзлегеннән күп укыды. Рус классиклары Толстой, Тургенев, Пушкин, Лермонтов әсәрләре, Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа әдәбияты белән танышты. Әтисе калдырып киткән акчасының күп өлешен китап сатып алуга тота иде ул. Егет белән сүзгә керешкәч, кыз башта ни турыда сөйләшергә белми аптырап калды. Галимҗан исә, шактый шомарган егет кебек. Алмабикә әдәбият дөньясына алып кереп китте. Алмабикә башта үзен аннан өстен куебрак сөйләшергә тырышты. Ни дисәң дә, ул—Уфа гимназисткасы. Галимҗан—Ырынбурдагы тирә-якка яманаты чыккан Вәли мулланың кадим мәдрәсәсеннән куылган бичара бер шәкерт. Ә инде фикер алыша башлагач, егетнең белеме тирән, ә кызныкы сай икәнлек ачыкланды.

—Сез, Галимҗан абый, Ырынбурның иң алама мәдрәсәсендә укыган шәкерт, нишләп шулай бик күп беләсез?—дип сорады Алмабикә.

Галимҗанның шаярта торган гадәте бар. Алмабикәнең соравына:

—Фәрештәләр колагыма әйтеп тора,—диде.

—Миңа да шулай бер фәрештә табып бирә алмассызмы, Галимҗан абый?

—Фәрештә синнән ерак түгел лә ул...

—Кайда ул?

—Әле Алмабикә исемле чибәр кыз белән сөйләшеп утыра.

—Димәк, сез минем фәрештәм булмакчы?

Алмабикә дә нык чибәр иде. Уртача буй. Аксыл күләч йөз. Уймак авыз. Энҗе тешләр. Киенүе дә матур. Чытлыкланып та ала үзе. Елмайганда

бит очларында сизелер-сизелмәс кенә чокырчыклар хасил була. Бу да аның чибәрлегенә ямь өсти. Ләкин аның елмаюында вакыт-вакыт берникадәр эрелек чаткылары да сирпелеп кала. Әтисенә, әнисенә килешсезрәк сүз әйткән чагы да була. Алмабикә—дүрт ир бала арасында бердәнбер кыз. Кыскасы, бик тә иркә кыз ул Алмабикә.

Адәм баласы фәрештә түгел, билгеле. Аның ак һәм кара яклары була. Алмабикәнең ак ягын күбрәк күрергә тырышты Галимҗан. Башта алар бер-берсенә күз сирпеп карашырга да кыенсынып йөрделәр. Чөнки Галимҗан үзен нибары фатирчы итеп тойды. Алмабикә беренче курста гына укый әле. Болан баласы кебек кенә. Ана нәфесенне сузу гөнаһ булыр иде. Әтисе, әнисе алдында да оят.

Тора-бара бер-берсеннән тартынулар һаман кими барды.

Шәкерт чапанына төренгәнче, Галимҗан үз зәвыгы теләгәнчә киенеп йөрде. Кара чалбар. Әнисе тегеп биргән кызгылт күлмәк. Аның изүе һәрвакыт эләктерелмәгән. Сул як якасы өчпочмак ясап ачылган. Билен ул әнисе ясап биргән бармак юанлыгы ефәк билбау белән буа. Билбауның очларына әллә ничә төрле ефәк жепләрдән ясалган чачаклар тагылган. Билбау сул як кабырга тирәсеннән бәйләнә. Ә чачаклар асылынып тора. Бу инде шәкерт хөлләсе түгел. Бу аның ирекле шәхес икәнлеген раслап тора. Буе уртачадан озынрак. Чем-кара чәчләрен ул артка таба төшереп, матур, шома итеп тарап куючан. Төс ягына килгәндә, Галимҗан кара чибәрләр рәтенә керә. Очкын чәчеп торган кара, чая күзләр. Кыскасы, «егетләр солтаны» дип әйтергә мөмкин аны. Бу кыяфәт нык ошый Алмабикәгә. Барыннан да бигрәк, Галимҗанның акрын, салмак, уйлап, жай гына сөйләшүе, өйгә калын китаплар ташуы, шулар хакында әңгәмәләшү, фикер алышу сихерләде Алмабикәнең ялкынлы күңелен. Тора-бара ул, ишек шакып, Галимҗан янына ялт килеп керүне табигый бер хәлгә исәпли башлады. Сөйләшеп утырулар Алмабикә өчен иң ләззәтле халәт иде. Хәзер инде Галимҗанны сәгать саен, минут саен күрәсе килеп кенә тора. Күрмәсә, йөрәгенә нидер житми, юксына, борчыла, үзен-үзе өзгәли. Әллә Галимҗанга гашыйк булды инде? Шулайдыр. Шулай булмаса, ул юкта, тәтиен югалткан баладай, сөмсере коелып йөремәс иде.

Галимҗанны төшләрендә күрә башлады ул хәтта. Төшен мәгәр беркемгә дә сөйләми. Ул тәмле төшләр йөрәк төпкелендә мәхәббәт гәүһәре булып сакланалар. Бу хакта әллә үзенә әйтергәме Галимҗан абыйның? Юк. Ярамый. Аллам сакласын!

Галимҗан, зирәк егет буларак, аңлый Алмабикәнең йөрәк кичерешен. Кызның карашында хәзер очкын, жылы агым гына түгел, кайнар ялкын бар. Бу ялкын Галимҗанның үз йөрәгенә дә күчте. Күчте дә ут кабызды. Аннан янарга мәжбүр итте. Ләкин әлегә нык тота үзен Галимҗан.

Аларның артык якынаеп китүенә, Алмабикәнең әти-әнисе кыбыржый, шөбһә белдерә башладылар.

—Бу балаларны әйтәм, атасы, гөрләшеп тик утыралар, бер-бер хикмәт булмасын берүк, Алла үзе сакласын инде, —диде беркөн абыстай.

Габдрахман хажи жавапны шаяртыбрак бирде:

—Анысы аның, остабикә, шул инде: матур чиләккә —матур капкач.

Абыстай ачулангандай булды:

—Авызыннан жил алсын бу сүзләрне!

Егет белән кызның дуслашып китүләренә, Габдрахман хажи да, абыстай да каршы төшмәделәр тагын. Чөнки Галимҗан азып-тузып йөрми. Һаман китап укый. Аларны Алмабикәгә дә биреп тора. Габдрахман хажи үзе мәгълүматлы кеше. Балаларын югары белемле, мәгълүматлы, зыялы итмәкче. Баш баласын Каһирәдә укыту—шуның бер ачык мисалы. Чиратта Алмабикә тора. Анысын—кыз баланы—чит илгә жибәрмәсләр, билгеле. Кыз пианинода да матур уйный. Бу вакытта Галимҗан мон дәрьясына чума. Гимназиядә бертөрле сабак алса, Галимҗан Алмабикәгә әллә күпме әдәбият, сәнгать буенча «дәрес» бирә.

Бу йорт чын мәгънәсендә оҗмах иде Галимҗан өчен. Ә Алмабикә— шул җәннәтнең былбылы. Зур бәхет бу! Ләкин көтмәгәндә бәхет бакчасына корт төште. Каһәр суккан ютәле. Шул ютәле, кан косуы сәбәпле Ырынбурда «Хөсәения» мәдрәсәсенә дә үтә алмады бит. Шул чир аркасында менә хәзер шушы җир җәннәтеннән мәхрүм калырга тиешме ул?

Алмадай чибәр кыз алдында, җитмеш яшьлек карт шикелле, бума ютәленне тыя алмыйча, ахмактай кыланып утыр, имеш. Гарьлеге ни тора моның. Алмабикә белән икәү генә булганда бер хәл әле. Бервакыт аш табынында тотты ютәле. Галимҗан, авызын уң кулы белән каплап, чыгып китәргә мәҗбүр булды.

Шундый күңелсезлекләрдән соң Алмабикәнең җылы карашы көнесәгате белән салкына башлады. Дөрес, кыз аны сиздермәскә тырыша. Галимҗан алдында, элеккечә, һаман өзгәләнеп тора. Тик ул ясалма иде инде хәзер. Элекке кебек ихлас зәвык белән сөйләшүләр торган саен кими барды. Габдрахман хаҗи белән аның хәләл җәфете абыстайның элекке миһырбанлы, мөкиббән, җылы карашына да салкын кырау төште. Кешедәге холык-сыйфатлар әнә ничек бик тиз үзгәрә икән, дип борчылды Галимҗан. Җитмәсә, бер көн абыстайның: «Бу балада чихут корты бар бугай, Алмабикәгә йокса нишләрбез»,—дигән сүзләрен ишетеп калды ул. «Чихут» сүзе очлы хәнҗәр булып кадалды аның йөрәгенә. Озак тормый, бер әбинең өстәл, урындык, карават кына куярлык ташландык бүлмәсен тазартты да күчте дә килде шунда. Яхшы фатирлар да күп, әлбәттә. Ләкин ана түләргә кесә бик сай.

Алмабикә дә, әтисе, әнисе дә аны җибәрмәскә тырышты.

—Әтиең Гыйрфан мулла белән мәдрәсәдә бергә укыдык, искиткеч гадел, кешелекле, ярдәмчел иде бит ул. Мина күрсәткән изгелекләрен гомер онытачагым юк. Әле менә шул яхшылыкларны кайтармакта идем, кай җиребез ошамады сиңа, нигә китәсең бездән?—дип үрсәләнде Габдрахман хаҗи.

—Мин дә шуны әйтәм: нигә яратмадың соң әле, Галимҗан балам, син безне? Нигә болай илтифатсызлык күрсәтәсең?—дип өзгәләнгән булды абыстай.

Бу сүзләрнең өстән генә, күңел өчен генә әйтелгәнлеген аңлады Галимҗан. Алмабикә сүзгә катнашмаска тырышты. Шулай да:

—Ул бит бала түгел, үзе беләдер,—дип кенә куйды.

* * *

Галимҗан барда өй эчендә ниндидер җанлылык була иде. Галимҗан киткәч, ялкынны кинәт боз каплаган кебек, барысы да сүнде дә куйды. Галимҗанны ихлас яратуын менә хәзер генә ныклап аңлады кыз. Ул аның олы мәхәббәте иде. Мәхәббәт өчен көрәшергә кушалар. Ә ничек? Ике-өч ай үткәч, эзләп табарга булды Алмабикә. «Галия» мәдрәсәсенә барып, адресын алды да торган урынына китте ул аның. Барып керсә, артына егылып китә язды Алмабикә. Шактый дөнья күргән бәләкәй генә өстәл. Аның өстендә китаплар өеме. Артсыз ике алама урындык. Иске агач караватта Галимҗан йоклап ята. Аягындагы, өстендәге киемен дә салмаган. Озак кына карап торгач, чыгып китәргә дә ниятләде ул. Шулай да, ни өчендер, бу адымга җөрьәт итмәде.

Берара буылып-буылып ютәлләргә кереште Галимҗан. Шулай да чыгып китмәде Алмабикә. Аның уянуын, торып утыруын көтте. Көтәкөтә түземлеге беткәч, карават читенә барып утырды. Мамыктай йомшак куллары белән Галимҗанның чәчләреннән, йөзеннән сөеп иркәләргә кереште. Галимҗан, ниһаять, уянды да Алмабикәнең кулын эләктереп алды. Кем кулы бу? Учына йомылган мамык кулны җибәрмичә торып утырды.

Алмабикәне күргәч, күзләре шардай ачылды. Кызның беленнән алып кочаклады да аны үзенә тартты. Алмабикә, хискә бирелеп,

Галимҗанның муенныннан кочаклап алды да:

—Мин сезне сагынып килдем, Галимҗан абый!—дип пышылдады.

—Ә мин сине сагынып көттем, Алмабикә!

—Сагынсаң, безгә бер килеп чыгар иден әле.

—Әллә нигә уңайсыз бит.

—Һи, тапкан сүз! Әти белән әни дә сагына сезне.

—Әгәр бу чын йөрәктән булса?..

—Менә тагы: әйтте бер сүз...

Алмабикә бик матур киенгән иде. Өстә—затлы пальто. Башта—мамык шәл. Бит очлары пешкән алмадай кызарып тора. Галимҗан кызның сылулыгына сокланып карап торды да аны күтәреп үк алды. Егетнең куенына иркә песидәй йомарланып йомылды кыз. Аны кулыннан төшергәч, Галимҗан карават читенә барып утырды, Алмабикәгә әлеге артсыз ике урындыкның берсен тәкъдим итте:

—Ләкин иплап утыр, Алмабикә җаным, бу тарихи урындык таралып төшә күрмәсен.

—Тарала башласа, торып, куеныңа сыенырмын, Галимҗан абый!

Шактый озак сөйләшеп утырды алар. Телгә ни килә, шул хакта гәп куерттылар.

—Сез һаман да ютәл чире белән иза чигәсез кебек, Галимҗан абый?—диде кыз. Шунда кызның йөзендә шикләнү чаткылары сирпелеп алды.

Галимҗан кашларын җыерды.

—Мин авырмыйм, акыллым, курыкмагыз...

Бу очрашудан соң да килгәләп торды Алмабикә. Һәр күрешүдә, сүзнең очы шул сәламәтлеккә барып бәйләнә. Кызның яратканлыгын аңлады Галимҗан. Монысына аның иманы камил. Шулай да, Галимҗан фикерләвенчә, чын мәхәббәт түгел иде бу. Мәхәббәт ул—бөек, саф, садә тойгы! Ул вак-төяк икеләнүләргә, курку, шикләнүләргә мохтаҗ түгел. Бер килгәндә Алмабикә яратуын ихлас күнелдән әйтте.

—Мин дә сине яратам, Алмабикә!—диде егет.

Әмма бу әйтүдә дә мәхәббәт кайнарлыгы юк иде. Кыз аны да сизде. Һәм... башка очрашуга килмәде.

... Галимҗанны язмыш җилләре әле тегендә, әле монда олактырып йөртте дә йөртте. «Галия» мәдрәсәсеннән куылу, казакъ далалары, Миасс җиз эретү заводы, Казан, Киев... Анда ташкапчыкка эләгү. Яңадан Уфада. «Галия» мәдрәсәсендә укыту. 1915-1917 еллар. Галимҗан утыз яшьне түгәрәкләгән иде инде. Алмабикә янә Галимҗанны эзләп тапты ул чакта.

Үзе сөйләгәннәрнең бары да чын булса, Алмабикәнең матурлыгы фаҗигагә әйләнеп бара икән. Ул Гутман заводында эшләүче бер мастер егет белән дуслашкан. Ләкин әтисе, әнисе аңа барырга фатиха бирмәгән. Аннан соң тотканнар да хатыны үлеп ике баласы белән калган бер муллага «сыларга» тырышканнар. Риза булмаган Алмабикә. Шулай итеп, атналар, айлар, еллар үтә, яшьлек ялкыннары акрынлап сүнә-сүрелә бара.

... Аларның очрашуы шактый ешаеп китте. Бер мәртәбә Алмабикә ашка чакырырга килде аны. Әтисе, әнисе кушуы буенча. Әтисе Габдрахман хаҗи әйткән: Галимҗанны табып алып кил әле, кызым, менә бу гарәпчәне татарчага аударырга кирәк иде, минем баш җитми, Галимҗан аны «ә» дигәнче эшләп бирәчәк, дигән.

Барды Галимҗан. Әллә нәрсәләр турында сөйләштеләр. Аш, чәй мәҗлесе дә бик күнелле үтте. Шуннан соң Алмабикәнең чакыруы торган саен ешая барды. Берсеннән дә баш тартмаска тырышты Галимҗан. Икәүдән-икәү генә калган чаклары да була. Мондый вакытта икесенә бер караваты, бер мендәр дә җитә. «Яратам» дигән сүзне борчак урынына сипте Алмабикә. Әмма Галимҗан аңа саран иде.

—Яратасыңмы?—дип Алмабикә сораса:

—Алманы яратмаган кеше юк ул,—диебрәк җавап бирә килде.

Бервакыт, әтисе-әнисе энеләрен алып кунакка киткәч, Галимҗанны

янә чакырды ул. Шул ук сый. Җыр. Пианинода уйнау. Моң. Ике кешегә бер мендәр. Иртән Алмабикә дулкынландыргыч хәбәр әйтте:

—Минем сина зур бүләгем бар, Галимҗан абый!

—Син үзең зур бүләк, Алмабикә!

—Ул әйтелә торган сүз. Ә минеке—башка.

—Тыңлап карыйк.

—Мин синнән бала көтәм!

Бүлмәне авыр тынлык басты. Алар бер-берсенә карашып каттылар.

* * *

Патша төшерелгән көнне Галимҗан Туган авылы Солтанморатта иде. Икенче көнне үк ярсый-ярсый, җилкенә-җилкенә килде ул Уфага. Аннан төрле урыннарда кайнашу, митингларда кайнар чыгышлар ясау, газеталар редакторы булу һәм, ниһаять, учредительное собраниегә сайлану. Ленин, Сталин янында эшләү. Боларның барысын да ишетеп, белеп йөрде Алмабикә. Ә менә Галимҗан белән Колчак тылында очрашу каләресе ике ятып бер төшенә дә кермәгән иде.

Уфа большевиклар кулына күчкәч, эре байларны йортларыннан куып чыгару дулкыны башланды. Бу дулкынга Алмабикәләр дә эләкте. Алмабикә, бер байга ияреп, Колчак кояшына карап китте. Җылы каршылады аны Колчак кояшы. Бер карт офицерның сөяркәсенә әйләнде. Ашау мул. Эчү. Типтерү. Берсе дә калмый.

Хәер, карт офицерларга сөлектәй сыланып йөрүче сөяркәләр Алмабикә генә түгел монда. Алар шактый күп. Алмабикәнең сөяркәсе полковник Арысланов. Исеме—Гайнетдин. Аны Геннадий Иванович дип йөртәләр. Мишәр. Урыс сүзләре белән мишәр сүзләрен катнаштырып сөйләшә:

—Алмабикә йөрәгем, сугыш бетмәгә көп калмады, халеңне аңлыйм, өзең сүләмәсәң дә, понимаешь, терпи, мин сине эрмәгән йиргә дә ытыртмам, вот так...—диде бер сөйләшкәндә.

—Кайчан бетә соң ул сугыш, полковник әфәнде?

—Бир нимә дә мәңгелек төгәл, Аккушом!

—Без аннан соң кайда яшәрбез соң?

—Америкага китәрбез мужыт.

—Анда эре байлар гына китә. Алтыны күп булганнар.

—Алтун ул биздә бир йүк, так что...

Америка сүзен ишеткәч, Алмабикәнең түбәсе күккә күтәрелә. Күк кабагы ачыла. Ләкин ул озакка бармый. Күккә күтәрелгән түбә бик тиз җиргә төшә. Ачылган күк кабагы ябыла да куя. Ни өчен китәргә Америкага? Димәк Колчакның җинеп чыгуына беркем дә ышанмый.

Монысы бер хәл. Беркөн, сугышның иң кызган чагында, Галимҗан белән очрашты Алмабикә. Моны аңлатып бирү дә бик кыен.

... Галимҗан дошман тылында озак йөрде. Авыл картлары сүзенә дә колак салып йөри. Алар аклар кайда, кызыллар кайда икәнлекне белеп торалар. Бер көнне ул партизаннардан Карма авылына урнашкан кызылларга акларның ябырылачагы турында ишетте. Атын шул якка борды Галимҗан. Чаптырып барып җитте, хәбәрне кызыл командирга җиткерде. Үзенең кем икәнлеген белдерү өчен 5 нче армия тарафыннан бирелгән документын күрсәтте.

Тик хәбәр соңлап килеп җитте. Күп тә үтмәде, аклар кавалериясенең ябырылып килүе күренде. Кызыллар каршылык күрсәтәсе урынга, дәррәү күтәрелеп, авылдан чыгып, урман эченә кереп югалдылар.

Галимҗан үзе генә ачыклый алмады кызылларның ни өчен шулай тиз, сугышмый гына качуларын.

Кызыллар китте. Аклар авылга килеп тулды. Галимҗан бер якка да юл тотмаска, аклар арасында калырга булды. Кем уйлар Галимҗанны шундый куркыныч, авыр, четерекле эш белән йөри дип. Биленә төшкән

кара сакал. Тула оек. Иске чабата. Кырык ямаулы бишмәт. Киндер ыштан. Җитмәсә, килештереп, аксаклап та йөри. Торганы житмеш яшьлек авыл карты. Арбасында бер-ике шешә зәмзәм суы да йөртә ул. Кырык тартмачыда ни булмас. Ә эчеп алгач инде теле ачыла ак офицерның. Галимҗан көткән барлык кирәкле хәбәрләр борчак урынына чәчелә башлый. Аларны күңел сәхифәләренә яза бара ул. Шуннан аны кызылларга җиткерә. Бервакыт Оренбургтагы Вәли мулла мәдрәсәсендә бергә укыган Низам атлы шәкерт белән күзгә-күз очрашты. Низам акгвардеец булып алган. Офицер. Ләкин танымады ул Галимҗанны. Ни гаҗәп, Мөбәрәк тә шунда иде. Исерек. Ибраһимовны, элекке остазын, якасыннан алып җилтерәтте. Аннан тибеп очырды. Әллә кая барып төште Галимҗан.

Бу юлы ни булыр. Анысын бер Ходай үзе белә. Кызыл командир торган йорттан китмәде ул. Аты аның урам якта. Капка баганасына бәйләп куелган. Анысын-алай, монысын-болай итеп, үзенчә бер зур эш корган кешегә охшап, арбасында чокчынуын белде.

Аклар йортларга таралды. Сакчылар куеп йөргән яшь офицер Галимҗанга бәйләнде. Кем ул? Нигә монда тора? Тегесе-монысы... Галимҗан кырык тартмачы булу өчен алган хокук кәгазен күрсәткәч, ул китеп барды.

Бу авылда иң зур, матур, күркәм йорт иде бу. Ике сакчы калдыргач, анда иң зур командир килергә тиештер инде.

Шулай булып чыкты да. Озакламый яшь офицер янә әйләнеп килде. Галимҗанга моннан китәргә кушты ул. Ризалашты Ибраһимов. Биш-алты капка үткәч, иң иске йорт янында тукталып калды ул. Бу өй менә-менә җимерелеп төшәр кебек. Калын итеп ябылган салам йортның билен тәмам бөкрәйткән. Капка баганалары да, исерек кеше шикелле, бер якка кыйгаеп төшкән. Ишегалдында сиксән яшьләр чамасындагы карт яньчелгән комган тотып тора. Юынырга чыккан, күрәсең.

—Әссәламәгәләйкем!—диде Галимҗан.

Карт сул кулын сул колагы артына куйды:

—Ә-ә-ү... Ни кирәк?..

—Атымны куеп торырга буламы?

—Ә-ә-ә... «ат» дисеңме? Аталар шул. Атышалар.

Галимҗан аның колакка каты карт икәнлеген аңлап алды. Шуңа күрә бәләкәй капкадан эчкә үтеп, картның янына барды да мәсьәләне аңлатып бирде. Атны ишегалдына куеп торырга рөхсәт сорады.

Капканы көчкә-illалла ачып, атны ишегалдына кертте дә, тугарып, бабайга озакламый әйләнеп кайтачагын әйтеп, урамга чыкты Галимҗан. Яшь офицер һаман чабулап йөри иде әле. Ул Галимҗанны үз янына чакырды.

—Син кырык тартмачымы, бабай?

—Кырык тартмачы.

—Безгә кирәк нәрсә юкмы синдә?

—Кырык тартмачыда кырыктан да ким әйбер булмас. Ни кирәк соң сезгә?

—Аракы. Күрмисеңмени эт урынына чабып эзлим. Берәүдә дә юк.

—Кемгә кирәк соң ул?

—Полковникка.

—Ул кайда?

—Әнә теге йортта.

—Аракы бар, хәзер үзем илтәм полковник галиҗәнабләренә,—диде Галимҗан.

Офицер аның белән килешмәде:

—Юк, юк, аның янына керергә ярамый,—диде.—Акча кирәк булса, менә...

—Миңа акча кирәкми, бүләк итеп бирәм, олылап...

—Ну, ладно...

Галимҗанның арбасында дүрт шешә аракы бар иде. Арыш капчыгына

төреп салынган. Шуның берсен алып килгәндә, офицер капка төбендә көтеп тора иде. Ул һаман үзенекен тугылады:

—Сина ярамый анда керергә.

—Бүләктән патша да баш тартмый,—диде дә Галимҗан, офицер каршы төшкәнче, ян капкадан кереп тә китте. Офицер Галимҗан белән бергә керде. Уң кулын чигәсенә куеп, тантаналы рәвештә дулкынланып әйтте:

—Полковник галиҗәнабләре, бөтен авыл халкы без килгәнгә зур шатлык кичерә. Менә бу бабай авыл халкы исеменнән аз гына күчтәнәч алып килде. Мин аны монда кертмәскә дә уйлаган идем. Ләкин аның бүләкне сезгә үз куллары белән тапшырасы килде.

Галимҗан, рөхсәт-фәлән сорап тормыйча, төргәген ачты да, аннан бер шешә чыгарып, аны өстәл уртасына куйды.

Полковник, күзләрен чекерәйтеп, әле Галимҗанга, әле шешәгә карап, яшь офицерга бер бармагын күрсәтте. Бик аз бит, берәү генә, дигәнне аңлата иде бу. Галимҗан сизде моны:

—Тагын бар, алып килермен, полковник галиҗәнабләре!

Полковник елмаеп куйды. Шул секундта Галимҗан сул якта басып торган яшь ханымга игътибар итте. Бу—Алмабикә иде. Аларның карашлары очрашты. Күпме генә могҗиза, фаҗига, авырлык күрмәсен, йөрәгенең бу кадәр дертләгәне булмагандыр Галимҗанның. Иң сәере шул—аны Алмабикә дә танып алды. Нишләп йөри ул монда? Менә сиңа зур язучы! Менә сиңа күренекле галим! Менә сиңа Ленин, Сталин янында эшләгән бөек фигура!

Галимҗан, эчке кичерешләр давылында бәргәләнсә дә, үзен нык тотты, коелып төшмәде, төсен дә үзгәртмәскә тырышты. Ә инде зур офицерлар белән беренче очрашуы түгел аның. Әлбәттә, ашарына-эчәренә күп булса, офицер сиңа борылып та карамый. Арт ягына тибеп чыгарып җибәрергә дә күп сорамый ул. Күп вакыт, бүгенге кебек, аракы ярдәм итә. Кырык тартмачы икәнлеккә бирелгән кәгазен күрсәткәч, аңа тимиләр. Бу очракта ул аклар яклы булып сөйләшә. Эчкән офицер, сөйли-сөйли, Галимҗанга кирәкле серләрне дә әйтеп ташлый. Бүген дә шундый максатны күз уңында тотып кергән иде ул. Ләкин Алмабикә алдында кылану куркыныч. Тизрәк таярга кирәк моннан.

—Рөхсәт итегез китәргә, полковник галиҗәнабләре!

Полковник бер бармагын күрсәтте. Тагын берәү кирәк, дигәнне аңлата иде ул.

Галимҗан шуна ризалашып чыгып китте.

Ул кайтканда, бабай казан астына ягып маташа иде. Казан чәе әзерлидер, дип уйлады Галимҗан. Өй эчендә җилләр уйнап тора. Такталары кайшалып беткән шыгырдык сәке. Ул пычрак. Шалкан чәчәрлек. Сәкенең сул як почмагында йодрык зурлык кына бер мендәр. Ертык җиреннән салам күренеп тора. Димәк, эченә салам тутырган мендәр бу. Уң як почмактарак бер ярык агач табак белән ярык чәркә. Җир идән. Карындыктан ясалган бердәнбер тәрәзә тышкы яктагы яктылыкны эчкә бик аз үткәрә.

Халыкны менә шушындый караңгы баздан чыгару өчен көрәшеп йөрү бит инде, дип уйлады Галимҗан. Аннан картны үз янына чакырды да утырырга һәм тәрҗемәи хәле турында сөйләргә кушты. Бабайның саңгырау икәнлеген аңлап, сөйләгәндә аңа кат-кат сорау бирмәде Галимҗан. Тыңлап кына утырды.

Бабайның карчыгы моннан ун ел элек гүр иясе булган. Үзе Порт-Артур сугышында катнашкан икән. Империалистик сугышта өч малае үлеп, хәзер берүзе генә яшәп ятмакта. Менә бүген өендә чыпчыкка салырлык та ризыгы юк икән. Шул карт башы белән урманнан балтырган җыеп кайткан да, әле менә шуннан аш пешерү белән мәшгуль. «Казан чәе» дип ялгышкан Галимҗан. Казан кайнап, өйгә үлән исе чыккач, барын да аңлады ул.

Галимжан тиз генә ишек алдына чыгып, арба төбендәге ашъяулыкка төрелгән бер бөтен икмәк, бер әчмуха чәй алды да өйгә кереп китте. Ашъяулыгын сәкегә җәеп, икмәкне тураклап ташлады, әчмуха чәйне бабайның кулына тоттырды. Чәйгә карап, катты да калды бабай. Моны күрмәгәненә биш былтыр бит инде. Ул хәзер аның төшенә дә керми башлады хәтта. Аның уч төбендә әчмуха чәй түгел, гүя, алтын тау балкып тора. Бабайның куллары гына түгел, бөтен тәне дер селкенә башлады.

* * *

Кояш баеп килә иде инде. Атына солы салып йөргәндә, теге яшь офицер янә килеп җитте.

—Бабай, полковникка аз булды, тагын да юкмы?—диде дә кесәсеннән акча чыгарды.

—Табылыр, бар, кайта тор, илтермен, полковникка әйтәсе рәхмәтем бар.

—Акчаны алыгыз.

—Юк. Кирәкми. Сез—җиңүчеләр. Бушка сыйлыйм. Әйт шулай дип полковникка.

Офицер киткәч, Галимҗан уйланып калды. Барып чыгармы планы? Ябып куймасלармы? Алмабикә ни уйлый икән? Сатмасмы аны?

Бераз уйланып торгач, йомшап киткәне өчен, үзен-үзе эчтән генә сүгеп ташлады ул. Нинди генә куркыныч хәл-вакыйгаларга юлыкмады? Кемнәр белән генә күзгә-күз килешмәде? Тоттырмады мәгәр. Судан коры чыга белде.

Китте Галимҗан полковник янына. Өстәлдә төрле-төрле нигъмәтләр. Уртада буш шешә кукраеп тора. Яшь офицер белән Алмабикә юк иде. Полковникның борын очы кызарган. Күзләре мелт-мелт итә. Әмма шул сизелә: ана әле җитмәгән. Төргәгеннән бер яртыны чыгаргач, ул Галимҗанны килеп кочаклады хәтта.

—Айда, айда, кырык тартмачы бабай, отыр янıма, син арыган, халь ал, понимаешь, ну и безобразие, көн чап, төн чап, акча үчүн бит, ужас...—дип, бер мишәрчә, бер урысча такылдый-такылдый, өстәл артына—үз янына утыртты Галимҗанны. Аракыны ике рюмкага сала-сала сүзен дәвам итте:—Акча бирделәрме сезгә?

—Акча кирәкми. Бу бүләгем сезнең җиңү шәрәфегезне котлап, полковник галиҗәнабләре!

—Җиңү? Ха-ха-ха! .. Ә акча?.. Мына... ни дип җырлыйлар әле? «Акча бездә бир букча, җифәк дисәң, мунчала», вот әйткәннәр...

Кесәсеннән бер төргәк акча алып, Галимҗанга аны санамый-нитми төртте дә, рюмкадагы аракысын түнкәреп тә куйды. Аннан Галимҗанны кыстарга кереште:

—Ич, ич, пей, кырыкма, атаманом будешь, ха-ха...

—Мина ярамый, полковник галиҗәнабләре, кырык тартмачы изге җан иясе була.

—Син кем яклы?

—Мин дөреслек ягында.

—Ә дурүслек кем ягында?

—Ватан ягында.

—Синеке былгатып сөләй.

— Мин дөреслек яратам!

—Вот это хорошо. Дөреслек аклар акылында. Поэтому сине безне яраткан. Так что ли?

Галимҗан эндәшмәде. Эндәшмәүне «ризалашу билгесе» дип уйлады шикелле полковник. Салды эчте, салды эчте, аннан теленә ни килсә, шул хакта лыгырдарга кереште. Карт хатыны, бер улы, бер кызының Екатеринбургта яшәве турында әйтте. Балалар инде үскән, балигъ булганнар. Ә усал, ачы телле хатынын гомер буе яратмаган. Сугыш

беткәч, отставкага чыгып, яшь хатыны Алмабикә белән гомер итәчәк. Кайда? Алмабикә, имеш, аны чит илгә китәргә котырта.

«Алмабикә» сүзен ишеткәч, Галимҗанның аркасыннан бер көтү кырмыска йөгереп үткәндәй булды. Дөрес, кичерешен полковникка сиздермәскә тырышты. Хәер, ана инде хәзер дингез тубыктан. Һаман сала да эчә, сала да эчә. Вакыт-вакыт алмашынып та китә. Янында кем утырганын да оныта. Ә инде теле тегермән ташы урынына әйләнүеннән туктамый.

Бервакыт Алмабикә белән яшь лейтенант килеп керде. Хатын исерек иде. Ул өзгәләнә. Чәчләре тузган, уймак авызы бүртенгән, йөзе шешенгән. Исерек акылдан ни чыкмас? Хәерлегә түгел иде бу. Нәкъ ул уйлаганча килеп чыкты да. Алмабикә, ямьсез тавышлар чыгарып, бармагы белән яный-яный, кычкырырга кереште:

—Полковник әфәнде! Син кем белән эчеп утырганыңны беләсеңме? Бу бит... бу бит... Язучы Га-лим-җан... Ибраһимов. Кызылларга сатылган таракан.

Полковник айнып киткәндәй булды. Күзләрен чекерәйтеп, Галимҗанга карап катты. Яшь лейтенантның да чибәр, ак йөзенә кинәт кара коелды. Алмабикә, күз карашы белән тотылдыңмы төлке дигәнне аңлатып, янә ахмакларча шаркылдап көлеп җибәрде.

Полковник башта нинди карарга килергә дә белмичә аптырап торды. Аннан соң катгый боерык бирде:

—Утыртырга!

Әфисәр кавурыннан револьверын чыгарып Галимҗанга төзәде.

Галимҗанны кулларын бәйләп, өстеннән йозак белән бикләп куйдылар.

Келәтнең тәрәзәсе-фәләне юк иде. Башта, күз тышта калганлыктан, караңгы булды. Бервакыт күзгә төртсәләр дә күренмәс дәрәҗәгә җитте.

Арыган-алҗыган иде ул. Ләкин йокы алмады.

Алмабикә турында да һаман әрни-әрни уйланды Галимҗан. Каян очрашты алар. Их...

Беренче әтәч кычкырды. Димәк, ярты төн авышкан инде.

Әтәчләр тынгач, кемнеңдер йозакны ачып эчкә кергәнлеге ишетелде. Бу—Алмабикә иде.

—Галимҗан абый! Галимҗан абый! Син кайда?—дип, кармаланып килде дә, тапкач, аны кочаклап алды.

Нишләргә дә белмәде Галимҗан. Тибеп очырасы килде хатынны. Ләкин тыелды. Алмабикәдән аракы исе аңкып тора.

—Кит моннан, себерке!

Алмабикә чигенмәде. Үзенекен аңлатырга кереште:

Минем болай булуыма син гаепле.

—Гаепне үзеңнән эзлә!

—Эзлим. Мин сине яраттым. Кайнар мәхәббәтем белән. Ә син миңа карата боздан да салкынрак булдың.

—Полковник җылытыр. Тапкансың бит.

—Минем сиңа әйтәсе сүзләрем бар.

—Җилгә сөйлә.

—Җилнең жаны юк. Ул аңламый.

—Бар ул җилнең җаны.

—Тыңла әле, Галимҗан абый, курыкма, монда берәү дә килмәс, без икәү генә, полковник чучка урынына эчеп егылды. Аны хәзер дию пәрие дә торгыза алмый. Беләм гадәтен. Офицерны да аягыннан егылганчы эчердем.

—Минем боларны тыңлыйсым да килми.

—Тыңла.

—Бар, кит моннан.

—Иртәгә сине атачаклар.

—Мин аннан курыкмыйм.

—Әнә шул батырлыгың өчен дә яратамдыр әле. Хәтерендәдер: «Мин синнән бала көтәм»,—дигән идем. Ә синең йөзеңдә тамчы да курку әсәре күрмәдем. Мин алдадым сине ул вакытта. Үземә беркетер өчен әйткәнмендер. Бүген үзенә пистолет төзәгәч тә шүрләмәден. Елмаеп куйдың хәтта. Син—җинмешәк кеше. Ләкин җинелдең. Кабатлап әйтәм: иртәгә сине атачаклар...

Галимҗан эндәшмәде. Хатынны читкә этәрде.

—Син бит үзең дә мулла малае. Ник кызыллар ягында йөрисең, ә? Хәер синең эш. Мин хәзер кулынны чишәм, ә син тизрәк кенә тай моннан. Сакчыларны да көйләдем. Атынны җик тә, тай урманга. Мин авылны чыкканчы озата барам.

* * *

Галимҗан ат җигеп бетерүгә, Алмабикә килеп тә җитте.

Алмабикә, Галимҗанның әйтүен көтеп тормыйча, арбага менде дә утырды. Аның киеме дә әллә ничек бит әле. Өстендә—җилән. Яулыгын корткаларча, алга төшереп бәйләгән. Кулында—төенчек. Юлчы әбигә охшап тора.

Авыл халкының изрәп йоклый торган чагы бу. Урамнарны ай яктырта.

Зур гына авыл иде бу. Анда-санда этләр өреп ала.

Авылны чыккач, Галимҗан атын туктатты:

—Йә, Алмабикә, төш инде. Минем үз юлым, синең үз юлың...

Алмабикә сүзсез генә утыра бирде: ни—«а», ни—«б».

«Әллә йоклап киткәнме соң бу ак шайтан?»—дип борчылды Галимҗан. Йокламый иде Алмабикә. Ниндидер бер җенлелек кыяфәте алып кырт борылды да, Галимҗанның кочагына капланып, үксеп еларга кереште. Мәгәр үзе бер сүз дә әйтми.

Ни генә булмасын, монда бер генә минутка да калырга ярамый ич ана. Алмабикәне эзли чыгарлар, килеп тотсалар, бетте баш. Ул шымчы, хисләргә бирелү һич ярамый иде.

Галимҗан, җан ачуы белән Алмабикәне үзеннән куптарып, арбадан сикереп төште.

Алмабикә, ниһаять, телгә килде:

—Галимҗан абый, ни кылануыгыз бу? Бер кая да китмим. Сез кайда—мин шунда. Безне эзләп килергә мөмкиннәр. Ку атыңны! Юк булыйк моннан...

Галимҗан аптырап, арбага сикереп менде дә дилбегәне бик нык тартты ат сыртында каеш чыбыркы уйнатып алды.

Алар шактый бардылар да бардылар. Тәмам курку үткәч, Алмабикә сорамый булдыра алмады:

—Кая барабыз соң болай, Галимҗан абый?

Галимҗан ачулы иде. Шуңа күрә җавабы шактый дорфа чыкты:

--Бәлеш төбе ашарга!

Бара торгач, алар аклан сымаграк бер урынга килеп чыкты. Анда—атлар, арбалар, әллә нинди иске-москы киемнәр киенгән кешеләр. Бер урында учак яна. Чиләк асып аш пешерәләр.

Галимҗан атны туктаткач, озын гына буйлы, мәһабәт гәүдәле, башкаларга караганда арурак киенгән кеше болар янына килә башлады. Галимҗан, арбадан сикереп төшеп, ана таба атлады. Бераз сөйләшеп торгач, мәһабәт гәүдә Галимҗанның аркасыннан сөеп куйды. Алмабикә шулай уйлады: монда кайнашкан чуар киемле кешеләр—партизаннар. Ә Галимҗан белән сөйләшеп торганы—партизаннарның командирыдыр.

Бераздан командир Алмабикә янына килде.

—Безнең сафка өстәмә көч—пополнение алып килдеңме, Галимҗан абый?—дип сорады.

Галимҗан теләр-теләмәс җавап бирде:

—Шулайрак.

—Молодец!

—Нинди файдасы булыр инде...

—Синең шаярта торган гадәтең бар. Вакыты ул түгел. Монда бер ул гына түгел хатын-кыз заты, әйдә, шулар янына алып барыйк.

Алмабикәне, ботакларын тирә-якка нык җәеп үскән бер карама төбендә бәрәңге әрчеп утырган ике ханым янына китереп куйды командир. Аларның берсе яшь кыз чамасында, иске күлмәк өстеннән ямаулы бишмәт кигән. Мәгәр чибәр генә үзе. Кара күзләре уттай уйнап тора. Кыйгач кара кашларын да сикертеп ала хәтта. Бик дәртлегә, мут кызга охшаган. икенчесе—өлкәнрәк. Монысыннан шәһәр исе килә. Яланбаш. Арттан кистерелгән кыска чәчле. Өстендә—зәңгәрсу кофта. Кара итәк. Аякта—итек.

Командир:

—Менә сезгә «өстәмә көч»,—дигәч, йөзләре ачылгандай булды. Әлеге авылча киенгәне сорау бирде:

—Алма тазарткы пеләме[1]?

Алмабикә эндәшмәгәч:

—Тымырсык гуй, үргемес, пезнең күк шыгыртык төгәл[2].

Икенчесе сүзсез генә утырды. Ул гына да түгел, сорау бирүчегә: «Юлдан арып килгән кешене җәфалама»,—дигән караш ташлады.

Командир аларның сүзенә игътибар итмәде.

—Эшләтегез дә, ашатыгыз да, ял да иттерегез,—диде дә китеп барды.

## XIII

Командирның исеме—Мөхәммәткадыйр, фамилиясе—Әхмәтсолтанов.

Мөхәммәткадыйр да, Галимҗан Ибраһимов кебек, мулла малае. Алар күптән таныш. Ырынбурның Әәли мулла мәдрәсәсендә бергә укыдылар. Уфадагы «Галия»дә дә. Киев төрмәсендә дә бергә утырып чыктылар. Аннан язмыш җилләре аларны төрле якка чәчте. Империалистик сугыш башлангыч, патша хезмәтенә алына Мөхәммәткадыйр. Революция чорында кызыллар ягына чыга. Бервакыт әлеге Мәхмүт Шәһиәхмәтов төзегән татар-башкорт батальонына килеп эләгә. Галимҗан Колчак тылына чыгаручыларның берсе иде Мөхәммәткадыйр. Язмыш давыллары бервакыт аның үзен Колчак тылына китереп ташлый. Ул батальон камандиры иде. Каты бер алышта батальон чолганышта кала. Партизаннарга килеп кушыла, командирына әйләнә. Мәгәр батальоннар оештыручы Мәхмүт Шәһиәхмәтов белән элемтәне өзми. Арада разведчиклар йөреп тора. Ходай Тәгалә аны Галимҗан Ибраһимов белән янә очраштырды. Ләкин озакка түгел. Чөнки Шәһиәхмәтов Мөхәммәткадыйр Әхмәтсолтановка Галимҗан Ибраһимовны Колчак тылыннан чыгарып, кызыллар ягына кайтарырга кушып хат җибәргән. Бу фәрман, ә армияда фәрманга буйсынмый чара юк.

... Алмабикәдән бәрәңге әрчетмәделәр. Чөнки аның нык алҗыганы йөзенә бәреп чыккан иде.

Куышка кереп яту белән тирән йокыга талды Алмабикә. Уянып чыкканда кояш төшлеккә якынлашып килә иде инде. Аны Галимҗан каршы алды. Галимҗан абыйсы ана елмаеп карап торды да, кулыннан җитәкләп чуар киемле кешеләр төркеме янына алып китте.

Халык күп иде.

Галимҗан Алмабикәне командир янына алып килде.

---

[1]Алма тазарткы пеләме?—Бәрәңге әрчи беләме?

[2]Тымырсык гуй, үргемәс, пезнең күк шыгыртык төгәл—Азсүзле, сүлпән икән, безнең кебек шаян түгел. *(Себер татарлары теленнән.)*

... Мөхәммәткадыйрга бүген үк китәсен белдерде Ибраһимов. Алмабикә белән булган романын бәйнә-бәйнә, түкми-чәчми, нәкъ булганча, чынлыкка бер генә дә ялган салам кыстырмый сөйләп биргән иде инде ул. Теге вакытта үзен фронт сызыгы аша ничек озатканнар, бишенче армия штабына нәкъ шул сыйфатта кайтып керәчәге турында әйтте. Алмабикә монда калачак.

—Алмабикәнең язмышы синең карамакка тапшырыла, Мөхәммәткадыйр туган!—диде Галимҗан.

Командир җилкәсен кашып куйды:

—Ярый. Килештек.

Галимҗанның китәчәген белгәч, Алмабикә елап җибәрде.

—Мине дә алып кит, Галимҗан абый! Калдырма.

—Бу мөмкин түгел.

—Курыкма, Галимҗан абый. Сиңа авырлык китермәм.

Галимҗан өзеп кенә җавап бирмәгәч, Алмабикә янә сөйләп китте:

—Минем әйтәсе сүзләрем күп, Галимҗан абый! Ләкин килештереп әйтәлмәм кебек. Синең алда мин зур гаепле. Теге вакыттан бирле. Яратуым көчле. Син мине бер шакшы, бозык хатын дип уйлыйсыңдыр. Уйла. Каршылыгым юк. Теләсә нинди авыр сүзләр әйтсәң дә ризамын. Үз мәхәббәтемә үзем пычрак яктым. Син көчле кеше. Кичер мине, зинһар. Калдырма мине монда. Алып кит! Мәхәббәт—мәңгелек ул... Шуны менә хәзер генә аңладым...

—Алмабикә! Бу мөмкин түгел. Бик теләсәң, сине коткару чарасын үзем күрәчәкмен. Сине теге якка чыгарып куярлар. Аннары үзем эзләп табачакмын сине. Ышан миңа!..

## Бишенче бүлек

Галимҗанның Колчак тылында йөрүе турындагы уйлары йокыдан бүленүгә җитди сәбәп булды. «Колчак» романы аның тарафыннан күптән язылып куелган иде инде. Сорау алу вакытында әлеге яшь, чибәр тикшерүче аның сәхифәләрен янә ачты. «Колчак вакыйгасы»—бер романлык. «Себер татарлары тормышы»—икенче романлык. Галимҗан Ибраһимовта, чыннан да, Колчак белән очрашу теләге бик зур иде. Дошман тылында йөргәндә очрашу өчен җай эзләп йөрде ул. Ләкин максаты, кем әйтмешли, аксак тай кебегрәк булып калды. Колчакның Иркутскида атылганы ачыкланды. Җыйган алтын-көмеше җир куенына Колчакның үзе белән бергә китәчәк. Шушы төшне—Колчак белән очрашуны—Галимҗан Ибраһимов юл дәфтәренә язып куйган иде—булачак роман өчен бер эпизод. Әлеге Ялтада аны кулга алганда тикшерүчеләр аның шушы язмаларын да салганнар арыш капчыгына. Ул хәзер—Казан тикшерүчеләре өчен ифрат кыйммәтле кәгазь. Галимҗан Ибраһимовның чыннан да «халык дошманы», «илен сатучы» икәнлеген раслау өчен шушы язма гына да җитәрлек. Сүзне бүген тикшерүче шуннан башлады:

—Галимҗан Гыйрфанович! Сез Колчак белән очрашырга теләгәнсез. Чынмы бу?

—Чын.

—Ни өчен?

—Аның «Бөек хакимдар» булу, Бөек Русия белән җитәкчелек итү турындагы хыял-фикерләрен үз телennән ишетәсем килде.

—Нигә кирәк булды соң ул сезгә?

—Әсәр өчен. Мин бит язучы.

—Очраша алдыгызмы соң?

—Кызганычка каршы—юк.

—Ә язмагыз башканы сөйли. Очрашкансыз бит.

—Очрашсам, әйтер идем. Аның ни гаебе бар?

—Без беренче көнне үк алдашмаска, бер-беребезгә карата эчкерсез булырга, аңлашып эш итәргә сүз куешкан идек. Хәтерегездәдер?

—Сезнеңчә, мин алдакчы кеше булып чыгам?

—Тикшерү фактлар дөреслеген ярата.

—Галимҗан Гыйрфанович! Беренче очрашуда ук әтиемнең сезне яратуы, үземнең дә әсәрләрегезгә гашыйк булуым, сезнең язмыш өчен халыкның нык борчылуы турында әйткән идем. Мин бит, үзегезгә мәгълүм, болар хакында фәлсәфә сатып утырырга тиеш түгел. Зур талантыгыз, милләт күзгесе булуыгыз сезгә кешеләрчә карарга мәҗбүр итә мине. Ә сез ашка таш атасыз. Мине бала-чага дип исәплисез.

—Һич юк. Каян аласыздыр боларны. Юридик законнарга теләсә кем,—сез дә, мин дә, хәтта патша үзе дә,—буйсынырга тиеш.

—Моны аңлау гына житми. Аны гамәлгә ашырырга кирәк.

—Сезнең шуның өчен тырышканлыкны аңлыйм. Әмма закон белән минем арада нинди капма-каршылыклар булуны сез аңлап бетермисез. Гадел була алырсызмы миңа карата—бөтен хикмәт шунда. Аларны аңламагач, мин ничек гадел була алам соң?

—Киевта мин утырып чыктым. Ләкин закон ялгышлыгы белән. Әле «халык дошманы» буларак утырам. Сез бит эчке дөньягыз белән моңа ышанмыйсыз. Шулаймы? Бер сөйләшкәндә моны үзегез үк әйткән идегез. Гәрчә тиешле булмаса да. Ярый, бу ике арада кала торган нәрсә. Әмма мин «халык дошманы» түгел. Шулай булгач, закон белән минем арадагы капма-каршылык түгелмени бу?

—Мин моны аңлыйм, Галимҗан Гыйрфанович!

—Аңлагач, ышанырга да кирәк!

—Ә нәрсәгә ышанырга бу очракта?

—Минем Колчак белән очрашырга тырышуым аклар ягына чыгу өчен түгеллеккә.

—Кабатлап сорыйм: очраштыгызмы соң?

—Юк.

—Алайса, менә бу язманы карагыз. Сезнекеме ул? Укыгыз. Кул куегыз.

Язуны укып чыккач, Галимҗан Ибраһимов аны тикшерүченең үзенә кире кайтарып бирде:

—Минеке.

—Шулай булгач, кул куегыз.

—Бу бит әсәр өчен. Төштә күргәнне язам, имеш. Чынлыкта мин Колчак янында булмадым.

—Ә төш икәнлеге әйтелми бит монда.

—Димәк, ул өлешен алып ташлаганнар. Шуңа күрә мин аңа кул куя алмыйм.

—Авыр сезнең белән эш итүе, Галимҗан Гыйрфанович!

—Чынбарлыкны сезгә аңлату миңа да бик җиңел түгел.

Шуның белән аларның сүзләре киселде. Галимҗан Ибраһимовны сакчылар урынына кире илтеп куйды. Монда ике хакыйкатьнең очын чыгару бик кыен, әлбәттә. Галимҗан Ибраһимов хакыйкате—нахакка утырганлыгын ачыклау. Башта моңа ышанып бара иде әле ул. Ләкин өскә һаман өелә килгән нахак бәлаләр һич тә ерып чыгарлык түгел. Сәламәтлеге булса, көрәшер иде, бәлки. Авыру торган саен көчәя. Тикшерүченең уңышы—«халык дошманы»н утырту. Шуңа көче житмәсә, аны йә эштән алып ыргыталар, йә бәдәненә әллә нинди ялган койрыклар тагып, үзен утыртып куялар. Мондагы гаделлек шул.

* * *

... Төн. Төрмә.

«Халык дошманы»ның кайберсе үлеп йоклый. Түбә сайгагын күтәрердәй гырылдаулары колакларны тондырырлык. Ана авыруларның

сызлану өннәре килеп кушыла. Сүгенүләр авазы да ишетелә.

Галимҗанның үз уе. Үз дөньясы. Үз хыялы. 1923 ел. Сентябрь. Казан. Ул университетка лекция укырга чакырылды.

Хәзинәдә барынча дигәндәй, матур киенергә тырышты ул. Кара костюм. Ак күлмәк. Зәңгәрсу галстук. Аякта штиблет. Дөрес, аларның барысы да яп-яңа түгел. Берникадәр дөнья күреп, үзләренә аң гына тормыш сөремен, кешеләрнең күз карашын сеңдергән киемнәр. Ничек кенә булмасын, алар утыз алты яшьлек буйдак ир-егетнең тәненә матур гына, иплe генә сыланып, аны ыспай гына зыялы зат итеп күрсәтәләр.

Менә Галимҗан Ибраһимов килеп керә. Кулында берни дә юк. Кайберәүләр кебек, карап укыр өчен, букчасыннан кафедра өстенә өем-өем кәгазьләр алып куймый. Башта ул, гәүдәсен тәртипле солдаттай төп-төз тотып, баскан урынында студентларга карап ката... Шактый зур аудитория. Кызлар, егетләр аралашып та утырган, өлкән яшьтәгеләр дә күзгә чалына: алары укытучы, галимнәр булса кирәк. Яңа лекторның акыл кылын тартып карарга килгәннәрдер.

Зал тын иде. Йөзләгән күзләр төбәлде лекторга. Матур киенгән. Карашы кырыс та, ягымлы да, идеаль йөз. Яшь кызларны гашыйк итәрлек. Мәүзүг кызыклы. Һәркемне борчый торган. Лектор ерактанрак башлады. Төрки халыклар башта рун тамгалары белән эш иткән. Иң кирәкле нәрсәләрне, ул вакытта әле кәгазь булмаганлыктан, тактага, тирегә, каен тузына яза торган булганнар. Ләкин алар чери, янгынга эләгә, төрле сәбәпләр белән юк була бара. Ә инде унынчы йөздә ислам дине кабул ителгәч, гарәп тамгаларына яки коллиграфиясенә күчелә. Бу әле һаман дәвам итә. Безнең өчен иң кулае—латин хәрефенә күчү. Моның өчен зур әзерлек бара. Әмма ул да бәхәсле. Егерменче гасырның башыннан бирле килгән бу бәхәс төене әле һаман чишелмәгән.

Галимҗан Ибраһимов һәр аваз—хәрефне, сүзне, җөмләне, күңелгә ятышлы итеп сөйләде. Һәрберсенең ихлас күңелдән тыңлавын, язып баруын күргәч, акрынрак сөйләүгә күчте ул. Әйдә, язсыннар. Димәк, кирәкле нәрсәне аңлыйлар.

Тәнәфес ясап тормады әдип. Чөнки студентларның бу мәүзуг чылбырына нык мөкиббәнлек белән бирелүен шәйләде ул. Ике сәгать вакыт сизелми үтте дә китте. Галимҗан лекциясен әле язма әдәби тел барлыкка килгәнче үк телнең зурлыгы, киңлеге, матурлыгы турында халык үзе иҗат иткән мәкаль белән тәгәлләде:

Тел дигән дәрья бар,
Төбендә энҗе-мәрҗән бар;
Теләгәннәр чумып алыр,
Теләмәгән коры калыр.

Бер урында да тотлыкмады Ибраһимов. Сүзләре бер-берсенә эчке мәгънәләре белән бәйләнеп агылдылар. Һәр сүзне уйлап, матур, аһәнле әйтеп, сәнгатьле теле белән сихерләде ул студентларны. Алар күңеленә эстетик зәвык салды. Ике сәгать буе урыныннан кузгалмады диярлек. Лекция беткәч, шаулатып кул чаптылар.

* * *

Лекциядән соң Галимҗан Ибраһимов иң әүвәл үзе чыгып китмәкче иде. Студентлар аның белән хушлашырга ашыкмады. Әле берсе, әле икенчесе, әле өченчесе, юк сорауны бар итеп дигәндәй, килеп кенә тордылар аның янына. Бу хәл нык шатландырды аны. Тел, халык, милләт язмышы һәркемне кызыксындыра. Халык үз язмышын ил, ватан язмышы белән бәйли. Аның күңеле чал тарихка йөгерә, хәзерге хәл-вакыйгаларны айкый, алдагы якты, матур көннәргә омтыла.

Барысы да чыгып беткәч, аның янында егерме яшьләр чамалы бер кыз гына калды. Зур, зәңгәр күзләренә күз салгач, Галимҗан тетрәнеп

куйды хәтта, фән дингезеннән капыл мәхәббәт дөньясына күчкәнлеген үзе дә сизми калды. Каһәр суккыры! Утыз алты яшьлек тун карт йөрәкне кымырҗытучы, ул йөрәктәге салкын бозны эретеп җибәрүче, ул йөрәккә тиз генә кереп оялаучы мәхәббәт уты бар микәнни соң әле? Белми микәнни бу җил кыз йөрәгендә һаман әле фәкать «Пролетариат революциясе солдаты» каны кайнаганны?

Кыз Галимҗанга шактый калын бер китап сузды. Ибраһимов бер китапка, бер кызга карап, ни әйтергә белмичә, аптырап торды. Бу аның 1919 елны Казанның «Сабах» ширкәтендә басылган «Безнең көннәр» романы иде. Галимҗан сүзне сорау белән башлады:

—Сез моны кайдан алдыгыз, сеңлем?

—Әти бирде.

—Ә нигә мина бирәсез? Ошамадымы әллә?

—Ошады. Имзагызны куйсагыз иде!

—Автограф була инде?

—Әйе.

Кафедрадан ике-өч адым ераклыкта өстәл бар иде. Янында ике урындык. Шуларның берсен—өстәлнең бер, икенчесен—өстәлнең икенче ягына куйды да кызга утырырга тәкъдим итте. Алар капма-каршы утырыштылар. Кыз, букчасыннан алып, Галимҗанга каләм бирде.

Башта кызның исемен, фамилиясен, кайдан килүен, кайсы факультетта укуын сорады.

Исеме—Гөлсем, фамилиясе Мөхәммәдова икән. Әстерхан шәһәреннән. Әтисенең исеме—Давыт. Галимҗан «Әстерхан» сүзен ишеткәч, нишләптер, кызның тормышы, әтисенең хәл-әхвәле турында кызыксынып китеп, сорау артыннан сорау бирә башлады. Кыз барын да сөйләп бирде. Әтисе балыкчы көймәләрен ремонтлау белән шөгыльләнә икән.

Әтисе Давыт, гәрчә гади эшче генә булса да, әдәбият-сәнгатьне, яхшы белә икән. Шуңадыр, күрәсең, Казаннан килгән язучы, журналист, галим ишеләр аның әтисе белән очрашып яшәгән. Аларда Тукай, Сәгыйть Рәмиев булган хәтта. 1911 елда Петербург консерваториясендә укыган җырчы Мәрьям Искәндәрованың алар өендә булуын дулкынланып сөйләде кыз. Бу вакытта Гөлсем сигез яшьтә генә була әле. Соңга таба Тукай шигырьләрен галибанә мөкиббәнлек белән укый башлагач, аның күңеле «моңлы», «дәртле» Казанга тартыла.

—Без тагы да очраша алабызмы, Галимҗан абый?

—Бик мөмкин!

—Кайда?

—Кайда телисез бит.

—Сезнең төп эшләгән урыныгыз?

—Алар бик күп, сеңлем!

—Ә нигә ул кадәр?..

— Ахмак булганга.

Алар аерылыштылар. Мәңгелеккә түгел. Фәкать берничә көнгә.

* * *

Галимҗанның күңеле дингездәй уйный башлады. Күңеленнән теге зәңгәр күзле кыз китми генә бит. «Әстерхан сандугачы»н эзләп, әллә ничә мәртәбә барды ул тулай торакларына. Юк, табалмый. Кайда очып йөридер. Шайтан белән эзләп тә табарлык түгел. Бер барды. Ике. Өч. Дүрт. Биш. Алтынчысында гына тапты.

Табу—бер нәрсә. Мәхәббәт дигәннәре—икенче нәрсә шул. Кыскасы, хәзер аңа утыз алты яшьлек корычтай ир-егет булып, күкрәк киереп, борынны югары күтәреп йөрү кирәкми. Аңа хәзер, уналты яшьне алып ыргытып, егерме яшьләр чамалы яшь егет сыйфатына керү кирәк. Киногa алып бар син аны. Театрга! Циркка, музейга! Кабан күлендә көймәдә йөзәргә... Үзеңне шат тот. Кикриге шиңгән әтәчтәй йөремә. Шаяр.

Көлдер. Үзең дә көл. Әмма чаманы бел. Ахмакларча кыланма. Ярлы тәкәббер булма. Ир-егетлек сыйфатыңны югалтма. Кичке бакчаны да күрсәт. Форсаты тисә, зәңгәр күккә дә каратып ал. Йолдызларны макта. Нәфесеңне уч төбенә йомарлый бел.

Иялешер өчен шактый вакыт кирәк. Сабыр тотты үзен. Кыз әдәбият, сәнгать ярата икән. Рус классикларын укыган. Чит ил әдәбияты белән дә ару гына таныш. Очрашкан саен мәхәббәт учагы ныграк дөрли. Фикерләр уртаклыгы, дөньяга караш берлеге белән яшәү әлеге тормышны тагын да ямьләндереп җибәрде. Шулай да баштук алтын сарай вәгъдә итәргә ярамый. Ничек бар аның тормышы, ул аны шулай кабул итсен. Фатирына шул ният белән алып килде ул аны. Күрсен аның тавык кетәгеннән аз гына зуррак булган бер тәрәзәле бүлмәсен. Тегендә дә, монда да таудай өелгән китапларын күрсен.

Алып килде. Күрсәтте. Кавказ халкының: «Кем иренен нык кыса, шуның йөрәге тарая»,—дигән бер мәкален ишеткән иде Галимҗан. Ә менә бу «Әстерхан сандугачы»ның, алама бүлмә күреп, ирене аз гына да кысылмады. Димәк, йөрәге аның тараймады, зур килеш калды. Йөзе үзгәреп, чырае да сытылмады. Ни дисәң дә, эшче-рабочий кәүсәсеннән үсеп чыккан ботак шул, дип уйлады Галимҗан. Ә менә Алмабикәнең кәгазь кебек юка иренен кыса торган гадәте бар иде. Ирендә дә хикмәт бар икән шул, валлаһи!

Кара-каршы утырып чәйләр дә эчкәч, кара һәм зәңгәр күзләрдән чыккан җылы нур агымнары бер-берсенең йөрәгенә керешеп кәрәзләнде. Әмма, никадәр генә кыю булмасын, мәхәббәт алдында юаш иде Галимҗан. Өйләнү мәсьәләсен теле белән әйтә алмады, язып бирде. Өч сүз белән генә:

--Миңа тормышка чыгасызмы?

Тынлык шактый озакка сузылды. Менә бервакыт, кыз зур зәңгәр күзләрен әйләндереп, бер карап алды да аңа:

—Сез мине аңламыйсыз икән, Галимҗан абый!—диде.

—Бәлки.

—Мин иптәшләрчә... абыем кебек күреп...

—Ә мин сезне ул хисегездән беркайчан да мәхрүм итмәм.

—Минем әле укыйсым бар. Шул хыялларымны сез тапарга җыенасыз.

—Киресенчә. Ул хыялларыгызны мин ныгытачакмын гына.

Бераз дәшми торгач, кырыс тавыш белән:

—Уйларга өч көн вакыт бирәм, Сандугач!—диде.

* * *

Өченче көнне Галимҗан Гөлсем янына, тулай торакка китте—ул юк. Барды дүртенче көнне—ул юк. Бишенче көнне барды—ул юк. Һәм вәссәләм. Бүлмәдәш кызыннан сораса—әйтми. Нидер яшергәнлеге йөзеннән үк сизелеп тора. Димәк, кача. Очрашасы килми. Нишләргә?

Йөри торгач очратты ул кызны. Тагын алып килде үз бүлмәсенә. Китаплар караштырып утырырга кушты да, бер букча алып, йөрештереп кайтачагын әйтеп чыгып китте.

Галимҗанның басылган әсәрләре бер урындарак. Шуларны караштырырга уйлады ул. Дөрес, аларның күбесе Әстерханда чакта ук кат-кат укылган иде инде. Менә «Сөю-сәгадәт». Менә егет яраткан кызы турында ничек уйлый: Минемчә, ул—илаһи; ул—табигатьнең аерым бер сәнгате; ул—хозур язның бөтен күрсен, бөтен ләтафәтен җыйнаган берданбер асыл чәчәк». Яки: «Мин аның белән танышкан көнемнән алып, үземне бөтенләй яна бер халәттә хис кыйла башладым. Хәятым әллә ничә дәрәҗәдә матурайды, баеды, язмыш тагы рәхимләнде». Яки: «рухым үзенә яңа бер куәт, яңа бер дәрт алып, һәммә нәрсәнең төсе матурга таба үзгәрде; кулларым да, бөтен тормышым да җиңеләеп, эшкә гайрәтем тәмам башкаланды». Янә: «Ул миңа бөтен шатлыкның чишмәсе, хәятым-

ның мәркәзе булды. Шул дәрәҗәдә ки, дөньяны туфан басып та, ул сәламәт калса, мин һичбер кайгы күрмәячәкмен. Аны бер күрү, нурлы йөзенә тагы бер аерым күрек арттырып, сак кына бер елмаюы, матур бер сүзе, хәтта икенче бүлмәдән торып аның миңа ишетелгән тавышы, хәтта ерактан күренгәндер бер киеме, йөреш вә кузгалышы—кыскасы, һәрбер нәрсәсе илаһи бер ямь ала. Була шундый вакытлар: ул үзенең гаҗәеп тавышы белән шыңгырдатып, кем беләндер көлә-көлә сөйләшә башлый. Мин бөтен рухым белән аның тавышына йотылып, һәрбер авазын йөрәгемнең төбенә, күңелемнең иң эченә алып, бонан башка бер хәлдә дә булмаган шаһи бер сәгадәт хис кыйлам. Шуннан тамырларымача бер хозур йөгерә, тәнемә аерым бер ләтафәт китә. Сизәм ки, мин бу туташны сөям».

Сөюнең бәхет, сәгадәт, илаһият иконлеген әнә ничек тасвирлый. Ул—табигатьнең аерым бер сәнгате. Язның бөтен күркен, ләтафәтен җыйган бердәнбер асыл чәчәк! Мәхәббәт табигать сәнгате булу дәрәҗәсенә күтәрелә. Кыз йөрәге белән табигать йөрәге олы бер сәнгатькә әверелә. Мәхәббәт турында Галимҗан Ибраһимов кына шулай олы итеп әйтә аладыр.

* * *

Тышта аяк тавышы ишетелде. «Кайтты» дип уйларга да өлгермәде, ишек шакыдылар. «Рәхим итегез» дию̧гә, ишек шактый киң ачылып, егерме яшьләр чамалы бер егет килеп керде. Бик җитез кыяфәтле үзе. Тере. Бер басасы урынга биш басып тора торган. Гади генә күк күлмәк кигән. Изүе ачык. Пиджак төймәләрен дә эләктермәгән. Аягында штиблет. Озын чәчләре ике якка аерылып төшеп тора. Киң маңгай. Зур зәңгәр күзләр. Ул күзләрдән ниндидер ялкын бөркелә.

Егет, тышкы яктан шактый кыю күренсә дә, нишләптер, кыюсызланып кына сүз башлады:

—Миңа Галимҗан ага кирәк иде.

—Хәзер кайтып җитәр инде.

—Ярый, гафу итегез, башка вакытта килермен әле...

—Сез кем буласыз соң? Галимҗан абый кайткач, кем килде, дим?

—Мин... Мин... Һади Такташ булам.

—Һади Такташ?! Шагыйрь?!

—Әйе. Без ни... Галимҗан агага тынгылык бирмибез инде. Бер нәрсә язсак, тизрәк аңа укып күрсәтергә йөгерәбез. Ишеген типкәләп ачып кергән чак та була. Төн уртасында килсәң дә кабул итә ул. Ачуланмый. Тангача утырган вакытлар да була. Без, язучылар, бигрәк әрсез халык шул. Ишектән куып чыгарсалар, тәрәзәдән керә торган.

—Һәр язган әсәрне аңа күрсәтү мәҗбүримени соң?

—Ул әсәрнең ак һәм кара якларын тиз аерып күрсәтә белә. Проза, драма, поэзия... Барын да тирән аңлый ул. Редакциягә без күп очракта Галимҗан ага фатихасы белән барабыз.

—Әле нәрсә укыячаксыгыз соң аңа?

—«Зәңгәр күзләр» дигән озын гына шигыремнең яңа вариантын.

—Ул язылып беткәнме инде?

—Басылган иде инде ул. Быел «Безнең юл»да. Галимҗан ага, укыгач, бик ошатып бетермәде. Мин аны үзгәртергә булдым. Шактый озын шигырь. Поэма кебегрәк.

—«Укып күрсәтергә килдем» дисез, ә үзегезнең кулда берни дә юк.

—Мин барлык әсәрләремне яттан беләм.

—Сез бик зиһенле икән.

—Башта йөрәктә языла. Аннан күңел сәхифәләренә күчә. Мин шуннан карап укыйм.

—«Зәңгәр күзләр»не укып күрсәтсәгез, мин бик шат булыр идем.

—Хәзер... бер өзек...

Зәңгәр күзле егет кунак итеп
Сезне чакыра,
Әй, сез!
Ишетәмсез?!
Зәңгәр күзле егет ял итәргә
Сезне чакыра,
Әй, сез!
Килешәмсез?!

Без бу җирдә сирень гөлләреннән
Матур итеп таҗлар үрербез,
Кайгы-хәсрәтләрне онытып, без
Балалардай уйнап йөрербез.
Кызык булыр,
Биредә безгә карап
Көлүчеләр дә юк, кем дә юк.
Акыллылар да юк, Алла да юк,
Патша да юк монда, җен дә юк.
Килегез сез!
Мин дә, зурлап сезне,
«Зәңгәр күзләр» көен көйләрмен.
Күкрәгемдә бик күп еллар яшереп йөргән
Бер серемне сезгә сөйләрмен.

Сөйләп биргәч, йә, ничек ошыймы, хис-тойгыларына кагыла алдыммы азрак», дигәндәй, Такташ кызга карап катты. Кыздан бәһаләү көткән иде ул. Ләкин сүз әйтергә ашыкмады Гөлсем. Ә инде Такташ ошау-ошамау мәсьәләсендә ныклап, кат-кат сорагач, эчкә салынган шигъри гәүһәр хакында әйтми калуны килештермәде кыз.

—Мин сезнен әсәрләрне кат-кат, дөньямны онытып, җаным-тәнем белән, әллә нинди тирән хис илаһилыгына бирелеп укыйм, Такташ абый, алардан әллә нинди менә, үзем дә аңлап бетермәгән, йөрәкләрне җилкендереп җибәрә торган лирик тәм алам. Тукайлар, Сәгыйть Рәмиевлар, Дәрдмәндләр, Такташлар татар поэзиясен Күк тәхетенә күтәрәчәкләр әле. Тик менә...

—Нәрсә: «тик»?

—Ярый, әйткәч әйтим инде. Үпкәләмәсәгез?..

—Минем андый гадәт юк, акыллым!

—Галимҗан ага чәчмә әсәрдә яки прозада, сез, Такташ абый, шигырьдә яки поэзиядә лирик җылылык белән эш итәсез. Шуның белән отасыз да. Чөнки әдәби әсәр, ничек әйтим, тәмле аш кебек ул. Сезнен әсәрләрне лирика тәмли. Җир белән күк илаһилыгын кушып язуыгыз да отышлы. Тик, Такташ абый, сез кайбер очракта лирика аклыгына кара тап төшерәсез. Күрәм: сез мина үпкәлисез. Йөзегез үзгәрде.

—Юк, юк, акыллым, әйтегез, сезне тыңлау күнелле. Минем ул кара тапнын ни икәнлеген беләсем килә.

—Кара тапны анлатып бирә алмам кебек. Шулай да, бер сүз чыккач инде, әйтми калырга ярамастыр. Сез, Такташ абый, яныгызга кешеләр чакырасыз. Анда сездән көлүчеләр дә юк, беркем дә юк, акыллылар да юк, Алла да юк, патша да юк, җен дә юк. Ә нигә сез аларнын барысыннан да куркасыз? Шулар юк җирдә аулак кормак буласыз? Аларсыз мөмкин түгел бит. Алла һәр эшенә катнаша. Җен дә. Һәркемне ике фәрештә сагалап йөри. Берсе яхшылыгынны, икенчесе яманлыгынны яза бара. Алардан качып котыла алмыйсыз, Такташ абый! «Алла да юк» дип әйтүегез бөтенләй чеп-чи ялган. Бар ул Алла! Бар! Димәк, сезне яманлыкка җенегез, шайтаныгыз өнди. «Алла юк» дип әйтүегезгә алар шатлана. Алар җингәч, сезне Алла орачак. Шагыйрь эше Алла сүгү түгел. Сак булыгыз!

Зур зәңгәр күзләрен чекерәйтеп, артык гаҗиз булып, хәтта тын да

алмый тынлап торды да, кызнын сүзе беткәч, кычкырып көлеп җибәрде Такташ.

Нәкъ шул вакытта Галимҗан кайтып керде. Анын кулында төенчекләр иде. Такташны күргәч, аптырабрак калды ул. Төенчекләрен бер урынга куеп, Такташ белән килеп күреште аннан. Аны үз итеп, якын күреп, «Һадиулла» дип эндәшергә ярата ул. Бу юлы да шулай итте:

—Һо, Һадиулла хәзрәтләре килгән, болай булгач, эш майлы табада шуган коймак сымаграк китәчәк, яна шигырь беләнме?

—Искесен сипләгән идем дә ул, Галимҗан ага, менә бу сенелкәшкә сөйләп күрсәткән идем, тәнкыйть чукмары, ай-һай, каты икән: телгә дә, башка да китереп бәргән иде, дивана кеше кебек бәлтерәдем дә калдым. Кем була сон бу усал кыз, Галимҗан ага, бер-бер туганыгызмы, дигәндәй?..

—Бумы? Әстерхан сандугачы бу. Гөлсем. Табибәлеккә укый. Беренче курста гына әле. «Тәнкыйть чукмары» шәп дисен инде? Булачак җингән шул яктан да танытып өлгердеме үзен? Тукай әйтмешли, тәнкыйть кирәкле шәйдер. Сина да, мина да, барыбызга да.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Галимҗан пинҗәк кесәсеннән бер кашлы йөзек алды да аны Гөлсемнен урта бармагына кидерде. Йөзек тап-таман иде.

—Туй бүләге!—дип, Галимҗан зур шатлык белдереп куйды хәтта.

Галимҗан үзен тыныч тотты. Гөлсемнен исә эче давыллы иде. Ничек бу? Шундый катлаулы мәсьәлә шулай бик җинел хәл ителәме? Ләкин нindидер карышулык күрсәтү дә әллә ничек хәзер, логатькә сыймас кебек тоела.

Такташ, каккан казык кебек, урыныннан аз гына да селкенмичә, аптырап карап тик торды. Ни сон бу? Чынмы? Түгелме? Хәер, Галимҗан абыйсының шактый катлаулы мәсьәләләрне әнә шулай капыл-кинәт җинел генә чишеп ташлый торган гадәте барлыкны белә Такташ. Бусы шуларның чираттагы берседер. Анын өйләнүен бөтен дуслары, җәмәгатьчелек, язучылар, галимнәр, журналистлар...—тагы да әллә кемнәр тели иде бит инде. Менә шатланырлар инде!

* * *

... Алар һаман әле шул тар бүлмәдә яшәп ятмакта иделәр. Галимҗан иртәннән алып кичкә дүрткә кадәр Гыйльми үзәктә була. Аннан башка эшләр башлана. Шул тар бүлмәгә кичен язучылар, галимнәр, төрле һөнәр әһелләре җыела. Кыскасы, көндез очланмый калган эш кибәннәре очлана бирелә. Вакыт-вакыт ул төнге сәгать икеләргәчә сузыла. Галимҗанның бу кадәр гадилегенә аптырый Гөлсем ханым. Ләкин каршы бер сүз дә әйтми. Шулай кирәктер, күрәсен, дип уйлый. Инде ул зур кеше ич—Гыйльми Үзәк рәисе. Академик. Нишләп ана юньлерәк бер фатир бирмиләр икән? Бу хакта уйланмый түгел Гөлсем ханым. Уйлана. Шулай да фикерен әйтми иренә. Галимҗан исә моны яхшылыкка юрый. Кайбер кәттәкән-түрәләр хатыны кебек яхшы фатир, затлы киемнәр таләп итеп, беркайчан да анын якасыннан алмый. Бу яктан караганда, минекенә җиткән хатын бөтен җир йөзендә юк, дип уйлый ул.

«Сабыр иткән—морадына җиткән» кебек булды боларның. Бервакыт Татарстан Мәгариф министры Шәһит Әхмәдиев килде дә:

—Син начар бүлмәдә яшәгән өчен мине сүгәләр; еламаган балага имчәк бирмиләр ич, бу мәсьәләне үзен әллә кайчан күтәреп чыгарга тиеш иден инде, күрмисенмени: әллә кемнәр әллә нинди сарайларда яшәп яталар,—диде.

Галимҗанга Новокомиссариатская[1] урамыннан биш бүлмәле фатир бирделәр. Аста өч бүлмәле подвалы да бар.

Инде хәзер нәсел-нәсәп мәсьәләсендә дә уйлар вакыт җиткәндер.

[1]Хәзерге Мөштәри урамы.

Галимҗан төрле яклап әтисенә охшап туды: төсе, бите, йөзе, чырае, зур башы, киң маңгае, әрекмән колагы—һәммәсе Гыйрфан мулланыкы.

Ибраһимовларның нәсел агачы янә бер җимеш бирде. 1926 елның 5 ноябрендә Гөлсем ханым бер ир малай бүләк итте Галимҗанга. Теге вакытта Галимҗанның әтисе Гыйрфан муллага бер тамчы су кебек ошавы турында сокланып әйтсәләр, шул ук сүзләрне хәзер дә кабатларга туры килә. Малайга Рөстәм дип исем куштылар. Рөстәм суйган да каплаган әтисе. Ибраһимовлар нәселен дан-шөһрәткә күмүдә әтисе Галимҗанны мең өлеш арттырып җибәрер, бәлки. Шуны өмет итеп куанды Галимҗан. Үз улының гына түгел, инкыйлабый түнкәрелеш елларыннан соң туган балаларның аңлы, зиһенле, көрәшчән булуларына, алар яулаган яңалык байрагын югары тотачакларына, ил, халык бәхете өчен яшәячәкләренә ихлас, мөкиббән, биниһая ышана иде ул. Рөстәм бәхете белән туды. Йөгереп-чабулап уйнар өчен биш бүлмәле фатир бар. Мәзәк сүзләр сөйләп көлдерә торган шаян, чибәр әтисен бик яратыр Рөстәм. Бер басасы урынга биш басып торган житез, хәрәкәтчән, сүзгә оста әнисен ул дөньядагы иң бөек, иң гүзәл, иң чибәр ана дип исәпләр.

Инде кырыкны кырлап килгән Галимҗан өчен бала бигрәк тә тансык иде. Бишеккә бара да озак-озак карап тора аңа.

—Ата кешенең күзе каты була, имеш, Галимҗан бабакай, күзең тия күрмәсен берүк,—дип кисәтә кайчак Гөлсем.

—Анысын да ишеткәнем бар, балакай, карамый һич түзә алмыйм шул. Ләкин мин күзнең катылыгын йомшартыр өчен аны исле сабын белән ныклап юып килэм,—дип шаярта Галимҗан.

—Мин үзем дә аннан күземне алалмыйм инде, бабакай, бу кадәр дә мәхәббәтле бала булыр икән!

—Синең үзеңдәге мәхәббәт зур булганга шулай ул, зәңгәр күзләреннән аңа төшкән сөю ялкыны кире үзенә мәхәббәт уты булып кайта.

—Мин аны ашар чиккә җитеп яратам. Үбә башласам, тыела алмыйм хәтта. Икегезнең мәхәббәте бергә укмашты, күрәсең.

—Ә менә тагын берне тапкач, мәхәббәтең ана күчәчәк.

—Күңеленне киң тот, бабакай, безнең нәсел бик үрчемле.

—Ә безнеке соң: картатайның унике баласы була—сигез ул, дүрт кыз. Шуларның берсе—минем әткәй. Әни дә җиде бала тапкан...

—Мин бала яратам. Күпмегә тырышсам да, тыймассың, бабакай, ярыймы?

—Алла белән киңәшләшеп карыйсы бар, балакай!

—Һи, синең әле «Партия белән киңәшләшеп карыйсы бар» дип тә әйтүең мөмкин.

Икесе дә көлеп җибәрделәр.

Тукайның зур бәхет турында әйткән сүзләрен янә бер искә алды Галимҗан:

Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә;
Аһ, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.

Дөрес, зур эшләрне шәхси бәхет өчен башкармый Галимҗан. Ул хакта уйламый да хәтта. Һәрхәлдә үзен бәхетле сизә Галимҗан. Күпме авырлыклар аша килде бу илаһи зур бәхет! Рөстәм вакыт-вакыт янгыратып елап җибәрә. Аһ, анын елавы! Тавышынын моңлылыгы! Сандугач сайрыймыни! Җырчы булыр, Аллаһы боерса! Әнисе дә бик матур җырлый бит. Әстерхан татарлары җырын суза башласа, мең сандугачның бер якта торсын. Галимҗан җыр, моң ярата. Дөньяларын онытып тыңлый әйбәт җырны. Үзенең тавышы моңлы гына кебек.

* * *

Галимҗан кинәт аяктан егылды. Шифаханәдә Гөлсем ханым көнтөн анын янында. Чөнки Галимҗанга бик авыр. Ул—яшәү белән үлем арасында. Җитмәсә, шифаханәгә Рөстәмнең тәрбиячесе Феня елап килеп

керде. Рөстәм бик каты авырып киткән. Ут эчендә ята. Температурасы— 39 градус. Шулай итеп, ике ут арасында калды Гөлсем ханым. Галимжан сөйләшә дә алмый. Тамагына берни капмый. Аны Казанның иң абруйлы табиблары саклап тора. Ә инде Гөлсем ханым аңа рухи ныклык биреп торучы.

Бала хәбәрен Галимжанга әйтмәскә булган иде Гөлсем ханым. Ләкин андый эшне яшерергә мөмкинмени?

—Кайгырма, Галимжан, бала авырмый тормый, салкын-фәлән тигәндер, аны уйлап борчыла күрмә берүк, мин кайтып килим тиз генә,—диде Гөлсем.

—Дөрес эшлисең, балакай, ул ялгызы бит, монда мине әллә күпме табиб карый, бар, Рөстәм янына ашык,—диде Галимжан.

Гөлсем ханым әле Рөстәм янына йөгереп кайтты, әле Галимжан янына кабат йөгереп килде. Ике арада киләп-сарып йөрергә туры килде ана. Ул икесенең дә бик тиз аякка басуына ышанды. Ләкин алданды. Казан табиблары Галимжанны үлем тырнагыннан йолкып алып калачакка ышаныч белдермәделәр. 1927 елның апреле иде бу. Яз—авырулар өчен куркынычлы мәл. Ул әллә кемнәрне алып китә теге дөньяга. Галимжанда чихут чире көчәйде. Галимжан зур милләтнең алтын баганасы булу дәрәжәсенә җиткән иде. Бу багана ауса, ниндидер зур афәт килер кебек милләткә. Казан һавасы муенына агулы елан булып сарылды. Казаннан чыгып китмәсәләр, ул елан аны буып үтерәчәк. Бу елан әле Ялтага барып җитмичә аның муенын җибәрмәячәк. Ялтага барып җиткәч кенә иркен тын алачак Галимжан.

Юл шактый озын, куркыныч, газаплы, әлбәттә. Симферопольгә хәтле өч тәүлек чамасы поездда барасы. Аннан соң машина белән янә өч-дүрт сәгатьлек юл. Ялтага чаклы аны бер Казан табибы озатырга тиеш. Тегендә каршы алачаклар. Әлбәттә, аның белән бергә хәләл җефете Гөлсем ханым да барырга тиеш. Бу вакытта Рөстәм дә сәламәтләнеп бетмәгән иде әле. Гөлсем ханым өстенә өелгән авыр тауны алып ташларга беркемнең дә көче җитмәстер хәзер. Моның өчен инде фәкать Алла кодрәте генә кирәк!

* * *

Кырым һавасы коткарды Галимжанны вакытсыз гүр-иясе булудан. Муенын буган әлеге үлем еланы Ялта һавасында тончыкты. Ләкин моны болай әйтүе генә җиңел. Чир ул потлап килә, мыскаллап китә. Юлда нык йончыган иде ул. Ун ай буе түшәктә беркеп ятты Галимжан. Аяклар эшләми. Тән дә, куллар да каткан. Гөлсем ханым аны кош баласын ашаткан мисалда туендыра. Вакыт-вакыт сөйләргә теле дә әйләнми.

Бу кадәресен көтмәгән иде Галимжан. Ул инде яшәүдән өметен өзде. Хәер, мондый тормышның кирәге дә юк. Еллар буе файдасыз кисмән урынына караватка беркеп ят, имеш. Берни язма. Эшләмә. Ә җиләктәй хатының синең өчен кипсен, корысын, чәчәктәй гомерен заяга үткәрсен.

Шулай да ун айлап яткач, кашыкны үз кулына тотып ашый башлады ул. Мондагы табибларның һәркөн килеп торуы, янадан-яна дарулар бирүе, рухи яктан ярдәм итүләре, кешелеклелек сыйфатлары...—барысы, һәммәсе баш күтәрергә ярдәм иттеләр.

—Рәхмәт инде сезгә, үлем тырнагына бирмәдегез, Газраилне якын китермәдегез, тәки алып калдыгыз бит,—ди Галимжан шатланып.

—Үзегезгә рәхмәт, Галимжан Гыйрфанович, сез безгә көчле рухыгыз белән ярдәм иттегез, бергәләп җиңдек бу чирне,—диләр табиблар.

Гөлсемгә аның рәхмәте тау кадәрле иде:

—Синең мөнәсәбәтең табибларның барлык даруларыннан, шифалы мәрхәмәтлекләреннән дә өстен булды, балакаем, син бөтен назыңны шифа итеп яптың миңа,—ди ул.

—Бу минем төп вазифам, бабакай. Синдә эчке ныклык көчле, шул сәламәтләндерде дә үзеңне!

Галимҗан, акрынлап, торып утыра башлады. Кулына каләм алды. Аңа 1924-25 елларда ук яза башлаган «Тугры сүз» («Тирән тамырлар») романын төгәлләргә кирәк иде. Дөрес, куллар әле һаман карыша. Языйм дисә, ак кәгазьгә аваз энҗеләре түгел, әллә нинди кәкре-бөкре тамгалар—хәрефләр төшә. Ә шулай да язарга кирәк.

Шулай да артык җәфаламаска тырышты аны тормыш юлдашы Гөлсем.

—Син әйтеп тор, мин язып торыйм, Галимҗан бабакай,—диде көннәрдән бер көнне ул.

Галимҗан җавапны борчылып кайтарды:

—Күпме җигәргә була инде сине, балакаем!..

Өстәп куйды.

—Авыр инде сиңа, балакай, авыр!..

Татарда аның җыры да бар: «Уфа таралары белән кемнәр чәчен тараган; Бу дөньяны авыр диләр, кем күтәреп караган». Авырлыкка сылтанып яшәү—ялкаулар эше. Авырлыкларны җиңү өчен яңа көрәш башланды. «Тугры сүз» дәвам ителде. Галимҗан торып утыру гына түгел, акрынлап карават тимерләренә ябыша-ябыша, аякка да баса башлады. Бу аның яңа җиңүе иде!

* * *

Казан җәмәгатьчелеге 1928 елда Галимҗан Ибраһимов иҗатының 20 еллыгын бәйрәм итүне көн тәртибенә куйды. Бу мәсьәлә 1927 елда ук кузгатылган иде инде. Ләкин әдип үзе моңа житди каршы чыкты. Беренчедән, язучыны каты кара чир канаты ныклап каплап алган иде инде. Ул каты кара канатны аның күңеленә бернинди дә бәйрәм төсе сындырып үтәрлек түгел иде. Анда җан кайгысы көчле иде. Икенчедән, хәтта сәламәт булса да, Галимҗан Ибраһимов барыбер үткәрмәс иде аны. Илдә бөек төзелешләр бара. Халыкның тормышы һаман мантымый.

Гомумән, үзе өчен генә түгел, андый юбилейларга каршы иде Галимҗан Ибраһимов. Гайбәткә кереп китсә, арыслан артыннан чапкан ташбака кебек, кем әйтмешли, кәҗә тезеннән торырлык хезмәте өчен дә бәйрәм тантанасы йөткерергә тырышып йөрүчеләр яңгырдан соң үрчегән гөмбә кебек кубәячәк. Шуларны уйлап, бу өлкәдә һич тә кире өлге күрсәтәсе килмәде аның. Кылган хезмәте күп, билгеле. Ләкин алар белән һич тә канәгать түгел ул. Менә аякка басты. Бөтен көчен әдәби әсәрләр язуга сарыф итәчәк. «Безнең көннәр»не трилогия итеп эшлисе, «Яшь йөрәкләр»не яңадан язып чыгасы, янә күңелен борчып торган әллә күпме яңа әсәрләрне ак кәгазьгә төшерәсе бар. Тыныч кына һичьюгында янә ун ел чамасы язганда, әллә күпме яңа томнар барлыкка киләчәк. Бик телиләр икән, әнә шул чакта үткәрерләр аның иҗат тантанасын.

Юбилейның кирәклеге турында аңа иң якын дуслары, каләмдәшләре, житди житәкчеләр, шактый абруйлы кешеләр кат-кат ныклап әйтте. Ләкин ул берсен дә тыңламады. Казанда юбилейны Галимҗан Ибраһимовсыз гына үткәрергә булдылар.

Бу вакытта Галимҗан Ибраһимов Ялтада бер бүлмәдә тора иде. Иртәннән алып кичкә чаклы элемтә бүлегеннән телеграмма ташыдылар аңа. Почта хезмәткәрләре арып бетте хәтта. Үзебезнең илне әйтәсе дә юк: Казан, Уфа, Мәскәү, Чиләбе, Троицк, Әстерхан, Оренбург, Алма-Ата, Ташкент, Сахалин, Мурмонск, Архангельск, Төркия, Германия...—тагы да әллә кайлардан килде котлаулар.

Ничек кенә каршы килмәсен, Галимҗан Ибраһимовның үзе өчен дә бик күңелле булды бу юбилей. Аның күңеле күтәрелеп, йөзе ачылып, хәле аруланып китте. Фәннәр академиясенә член итеп сайланды. Хезмәт Герое исеме бирелде.

—Бу кадәр кирәкмәс иде, нигә бу тиклем шапырыналар, кая күтәрәләр мине,—дип кыенсынды ул.

Гөлсем ханым бу хакта тирәнрәк уйлаучы булып чыкты:

—Сине генә күтәрмиләр, бабакаем, татар милләтен күтәрәләр,—диде ул горуланып.—Бу синең шәхси батырлыгың гына түгел, милләт Батырлыгы!

* * *

«Тирән тамырлар» («Тугры сүз») язылып беткәч, «Безнең көннәр» трилогиясенә керешә Галимҗан Ибраһимов. Иң әүвәл аның беренче томын югары сәнгать таләпләренә җавап бирерлек итеп, яңадан язып чыгарга кирәк иде әле. Бер үк вакытта «Әдәбият кануннары»н да яңабаштан эшләп чыгарга йөрәксенде ул.

Галимҗан Ибраһимовны Кырымга алты айга дип җибәргәннәр иде. Бер ел да, ике ел да аккан судай, искән җилдәй үтеп китте.

Бу көннәрдә иҗат аның өчен зур хәят, аның хәләл җефете Гөлсем—шул хәятның рухы, Рөстәм шул рухлар канатланучы бөркет булып тоелды.

Рөстәмгә тәрбия бирү, аны аңлатып бирә алмаслык илаһи бер бөек ләззәт белән сөю, мәхәббәт ялкынын ана биреп бетерү чигенә җитеп ярату ягыннан алар арасында аерма булмады шикелле. Галимҗанны кырысрак табигатьле дип уйлый иде Гөлсем ханым. Усаллык бар, билгеле, Галимҗанда. Әмма бала янында үзе дә балага әйләнә дә куя ул. Бишек янына килеп, бала тәтигә кызыгып карагандай карап тора Рөстәмгә. Бу вакытта аның күзләре очкынлана, эчкә баткан яңаклары алсулана, калын иреннәре зур шатлык кичереп дерелди. Шуннан, Гөлсемне чакырып, бер үк сүзләрне кабатлый:

—Балакай! Кара инде бу бөркетне, тач мин бит бу! Ә башының зурлыгы!

Гөлсемнең Галимҗанга бик кыйммәтле, җылы, матур сүзләр әйтәсе килә. Алар вакытында йә телгә килми, йә артык төче булып яңгырар кебек. «Баллы сүз баш әйләндерә»,—дигәне дә бар бит әле аның. Җавапны барлык аналарга хас булган уртак сүзләр белән бирергә тырыша Гөлсем ханым:

—Тигез карарга насыйп булсын инде, әтисе, бәхетле булсын бала!

Өч яшендә соклангыч бала булып үсте Рөстәм. Акыллы кешеләр белән зурларчарак сөйләшүе генә ни тора. Һәркемнең аның белән сөйләшәсе килә. бер үк вакытта һәркемнең аны тотып сөясе килә. Казанда әтисе белән бер үк вакытта аяктан егылганнар иде. Икесе дә кабат аякка бастылар.

* * *

Тора-бара бу зур бәхет әле бер, әле икенче як читеннән башта азлап-азлап, аннан күпләп-күпләп кителә башлады, бервакыт бөтенләй челпәрәмә килде.

Галимҗанга җандай кадерле күргән, сөеп кенә түгел, карап та туя алмаган, яраткан улын кулга алырга, аның белән бергә утырып ашарга, алсу бит очларын, зур зәңгәр күзләрен үбәргә, аның белән гомерендә бер генә мәртәбә булса да кочаклашып йокларга рөхсәт ителми башлады. Чөнки бала Галимҗаннан туберкулез авыруы йоктырыр дип курка иде Гөлсем.

—Әти! Әти!—дип йөгереп килсә, Галимҗан, төрле сәбәпләр табып, аннан качарга, ераклашырга тырышты.

Ата белән бала арасында Аллаһы Тәгалә үзе биргән җәннәт җылылыгы бар иде. Ә хәзер инде ике арага, гүя, боз тавы үсеп чыкты. Рөстәм, авызын турсайтып, әнисе янына килә дә:

—Әти мине яратмый,—дип үпкәли.

Гөлсем ханым аны төрлечә юата:

—Алай түгел, акыллым минем, әтиең сине нык ярата, ул әле чирле, шуңа күрә аның янына барырга ярамый.

—Чирле ата янына барырга нигә ярамый?

—Менә ул озакламый савыгыр, аннан рәхәтләнеп уйнарсыгыз.

—Кайчан терелә соң ул?

—Озакламый. Син дә бит авырган идең. Әнә хәзер алма кебек булдың.

—Әтинең кай төше авырта?

—Куй. Сорама. Аны врачлар гына белә.

—Ә мин врач килгәч сораячакмын.

—Ярамый, улым! Врачлар сораганны яратмый.

Бервакыт тәлинкәләр дә, кашыклар да бүлеп куелды: әтинеке, әнинеке, Рөстәмнеке.

Бу хакта да күп сораулар бирде бала. Моның серен дә анага алдаша-алдаша аңлатып бирергә туры килде.

Хәер, озакламый Рөстәм бу яшерен мәсьәләләрне үзе үк белде. Урамда бер әрем телле хатынның озын телле малае әйткән аңа:

—Әтиең чихут белән чирли, ул йогышлы, әнием синең белән уйнамаска кушты, яныма килмә минем,—дигән.

Бу хакта да әнисенә кайтып әйтте Рөстәм. Бу юлы да Гөлсем ханымга төрлечә аңлатырга туры килде. Шулай да саксызлык та җибәрде Гөлсем ханым:

—Йокмый ул, балам, йокмый, якын килмәсәң, бергә утырып ашамасаң, берни дә булмый.

Моны Рөстәм атасына җиткерә:

—Син чихут белән чирлисең, ул башка кешеләргә дә йога, шуңа күрә мин синең белән бергә ашамыйм да, йокларга да ятмыйм,—ди.

Галимҗан дөресен әйтә:

—Син дә нык авырган идең бит. Сәламәтләндең. Минем дә чирем озакка бармаячак. Менә күрерсең. Аннан соң без бергә утырып та ашарбыз, бергә ятып та йокларбыз, урамда житәкләшеп тә йөрербез.

—Ә минем йә сеңлем, йә энем булырмы соң?

—Булыр, улым, булыр, булмый калмас.

—Кайчан?

—Ашыкма, улым, сабыр ит...

Бергә утырып ашау ярамагач, Рөстәмне балалар бакчасына бирделәр. Ләкин анда да әлеге әрем телле хатынның озын телле малае Рөстәм әтисенең йогышлы чир белән авыруы турында әйткән. Шуннан балалар Рөстәм белән уйнамый башлаганнар.

Галимҗан исә Рөстәмне күз нурлары, йөрәк ялкыны, балага булган кайнар хис-тойгылары белән генә сөеп йөрде. Гел болай булмас әле. Табиблар яхшы монда. Көн дә диярлек килеп торалар. Ашау-эчү начар түгел. Кеше гомерен кисә торган «чихут» дигән каһәр төшкән чирнең көче житмәячәк аңа. Җиңәчәк ул аны. Барыбер җиңәчәк!

Рөстәм җәннәткә ашыкмаса, ул шулай да булыр иде, бәлки. 1931 елның 21 мартында, дүрт яшь ярымлык вакытында, гүр иясе булды Рөстәм. Йөрәк параличы алып китте аны.

Бу көтелмәгән дәһшәт иде. Гөлсем ханым, һушы китеп, караватына ауды. Табиб чакыртып, укол казагач кына килде ул аңына. Кешеләр җыелган. Иң беренче Рөстәм караваты янында улына карап каткан Галимҗанны күрде ул. Йөзе аның көл төсле булган. Сулыш та алмый хәтта. Хәрәкәт тә ясамый. Әйтерсең, үлгән кешене бастырып куйганнар.

Шуннан алар бер-берсе өчен кайгырыша башладылар.

—Гөлсем, балакай! Кулга алырга тырыш инде үзенне, сабыр ит!—дип юатырга тырышты Галимҗан хәләл җефетен.

Гөлсем ханым йөрәктә каткан кайгыны күз яше белән түгеп ташлау юлына басты. Әле тегендә барып, әле монда килеп, кеше күргәндә дә, күрмәгәндә дә елап ала. Шуннан ул берникадәр бушанып кала. Эчтә

укмашкан кара төер таркала, тышка чыга, тын алырга ирек бирә. Тик Галимҗан гына елый алмый. Йөрәгенә укмашкан кара төер таркалмый, изелми, тын алырга ирек бирми. Ана: «Ела, җинелрәк булыр»,—дип әйтеп тә булмый бит. Ул менә—яки күз яшьләре түгәргә—күнекмәгән. Алар шулай тәрбияләнгән. Авыр еллар шулай иткән аларны. Каты бәгырьлегә әверелдергән.

* * *

Гөлсем ханым Галимҗан Ибраһимовны ташлап киткәч, гаилә бәхете бөтенләйгә челпәрәмә килде. Тормыш, югыйсә, җай гына аккан су шикелле бертөрлелектә, әллә ни тирән үзгәрешләр көтелмичә, ярсу-давылланулар да булмыйча, яшәүнең әллә ни тәмен татымыйча, һәммәсенә күнгән ярлы кешенең талгын гомер сөрүен хәтерләтеп, акрын гына үз җае белән бара иде әле. Рөстәмне югалту кайгысын икесе дә авыр кичерде. Гөлсемнең болай да бәләкәй гәүдәсе тагын да кечерәеп калды. Нык ябыкты ул. Яңаклары эчкә батты. Зур зәңгәр күзләреннән коелган кайнар яшьләрен җыйсаң, арттырып әйтсәк, үзенчә бер күл булыр иде. Аның бөтен эчен бала сагышы уты биләп алды. Инде бергәлектә ун ел гомер кичерделәр. Нинди генә авырлыклар үтмәде баштан? Ләкин Гөлсем бервакытта да зарланмады, эш күптән сыкранмады. Бернинди авырлык та чылатмады аның күз төбен яшь белән. Менә шунда гына ныклап белде Галимҗан бала югалтуның ана йөрәге өчен иң авыр кайгы икәнлеген.

—Балакаем! Үлгән артыннан үлеп булмый, үзеңне кулга алыр вакыт җиткәндер бит инде, гомер буе болай яши алмассың, бер басылырга кирәк,—кебек сүзләр дә әйтеп карый. Алар, киресенчә, ярсытып кына җибәрә Гөлсемне:

—Нишлим соң, нишлим, Ходайдан сабырлык та сорап карыйм, берни ярдәм итми, дип күз яшьләрен коя.

Бервакыт зәңгәр күзләргә яшь килми башлады. Алар эчтә корып беттеләр шикелле. Йөрәктәге кайгы утында корыдылар бугай. Гөлсем эшкә керде. Техникумда рус теле, әдәбияты буенча дәресләр бирә башлады ул. Дәресләре күп иде аның. Икенче бер яна хезмәткә чуму, көннәрен техникумда халык арасында үткәрү, кичләрен дәрескә әзерләнү, дәфтәрләр тикшерү, җәмәгать эшләренә бирелеп китү...—шуларга охшаш башка шөгыльләр аның авыр кайгысын берникадәр җиңеләйтә башладылар.

Галимҗан да кичерде шундый ук авыр кайгы газапларын. Еламаска тырышса да, нык уйланган чакларда күзе төбенә барыбер килеп чыга иде кайнар яшь. Аны сөртеп ала. Мәгәр Гөлсемгә күрсәтмәскә тырыша. Баланы бирде-бирүен Ходай, тик ул аны кысып-кысып бер сөяргә дә рөхсәт итмәде, дип әрни.

Иҗат дәвам итте, билгеле. «Безнең көннәр» романын яңадан эшләп чыкты. Чир белән көрәшеп яшәде ул.

Ходайга шөкер, таякка таянып булса да, җәй көне бакчага чыгып йөри башлады. Бу, билгеле, яшь баланың тәпи басарга өйрәнү чоры кебек кенә иде әле. Ләкин бит яшь бала, егыла-егыла булса да, шуннан акрынлап йөреп китә. Ул да шулай булыр. Аягы ныгыр. Бәдәненә хәл керер. Хәзер инде, яшь чактагыча, муенга кырык төрле хезмәт камыты киясе юк. Хәер, ул әле дә карт түгел. Яңа гына кырыктан үткән ир кеше карт була димени? Аның яшендә әдәбият мәйданында дан-шөһрәт казанучылар бик сирәк. Димәк, алга! Яңа җиңүләргә! Яңа иҗат биеклекләренә!

Бакчага чыгып утыргач, вакыт-вакыт аны сырып алалар. Танышлары күп монда. Һәркем аның хәлен сораша. Аның озак яшәвен тели. Бу да аның күңеленә яңа рухи көч өсти. Кешеләрнең бер тәмле сүзе бәгъзе бервакыт синең рухыңны күкнең җиденче катына күтәрә. Ә тәмсез сүз тернәкләнеп килгән рухны телгәләп ташлый.

Беркөн шулай булды да. Көн нык матур иде. Диңгез яктан талгын гына җылы җил исә. Зәңгәр күк йөзендә болытның әсәре дә юк. Кыскасы,

Кырымнын авыруларга шифа өләшеп йөри торган хозур бер көне иде бу. Анын алдына илле яшьләр чамалы бер хатын килеп басты. Өс-башы бик начар иде анын. Ямаулы итәк, иске пинжәк кигән. Баш очлары тишелгән туфлиләре дә анын ифрат ярлы яшәве турында сөйләп торалар. Чәче-башы тузган. Соры күзләре ач мәченекедәй ямьсез карый. Үзеннән аракы исе анкып тора. Бәйләнде бит ул Галимжанга. Әллә ниләр такылдый. Тик сүзләрен һич аңлап булмый. Әллә кырым татарлары телендә, әллә гагауз телендә, әллә караим телендә сөйли. Рус сүзләрен дә ара-тирә кыстырып җибәрә.

—Әленне бир маа, сизә бер сөз гәпрәм[1],—ди бу.

Анын куллары да шакшы, пычрак иде. Галимжан, саруымны кайнатып йөрмә әле дигән төс чыгарып, башын икенче якка борды. Ләкин хатын китеп бармады. Русчага күчте. Анысын да вата-җимерә сөйли:

—Рука дай мнуга ыскажу... пыравды ыскажу...

Ачуы килде Галимжаннын. Аңа акча кирәк. Шуны бирмәсәң, барыбер китмәячәк, кат-кат килеп җанына тиячәк әле ул. Кесәсеннән бер көмеш чыгарып бирде дә, китәргә кушты ана Галимжан. Әмма хатын китмәде.

—Менә... рәхмәт... сия, чичас пыравду ыскажу... синеке катын бер хәрби кеше мән гулять итә...

Бер агарды, бер күгәрде Галимжан.

—Китегез моннан!—дип кычкырганын үзе дә сизми калды.

Хатын, шаркылдап көлеп, китеп барды.

Бераз киткәч, янә борылып карап, тагын бер мәртәбә алама итеп кычкырып көлде ул. Монысында мыскыллау тагын да ныграк янгырады.

Хәбәрнен яхшысы да, яманы да тиз тарала. Аны алама авыздан да, матур авызлардан да ишетәсен. Галимжаннын монда танышлары күп иде инде. Гөлсем ханымнын намусына тагылган әлеге хәрби кеше турында күпләрдән ишетте ул. Киләләр дә сөйлиләр. Киләләр дә сөйлиләр. Мәгәр Галимжаннын һич тынлыйсы килми андый гайбәтләрне.

—Кем белән кем йөрмәс...

—Дөнья иркен ич...

—Мин көнләшә белмим...

—Юкны сөйләмәгез...—кебек сүзләр әйтә дә куя.

Хәрби кешенен майор булуы турында әйтәләр. Мәгәр бик чибәр, озын гына буйлы, ачык йөзле, матур гәүдәле, күнелле кеше, имеш. Бик якыннарыннан ишеткәч, Галимжан көннәрдән бер көнне сорарга мәҗбүр булды:

—Ниндидер хәрби кеше белән дуслашып алгансын икән, хәерлегә булсын, кем ул?

Гөлсем сорауга каршы сорау белән җавап бирде:

—Кемнән ишеттен аны?

—Телләргә кергән күнелләргә күчә.

—Димәк, гайбәт җыясын?

—Аллам сакласын!

Сорау бирүенә үкенде Галимжан. Кирәкмәс иде. Хәрби кеше, бәлки, элекке, әллә кайчангы танышыдыр. Мәктәп елларындагы дустыдыр.

Шундый уйлар кичерде ул башыннан. Ә инде Гөлсем ханымнын «гайбәт җыясын» дип әйтүе хәтерен нык калдырды анын. Нинди гайбәт? Ни пычагыма ул? Әйтерсен, анын шуннан башка эше юк.

Юк, гайбәт түгел иде бу. Анын шулай икәнлеге элекке кайнар Гөлсемнен акрынлап салкын бозга әйләнә баруында да сизелә. Авырган чакта бала урынына тәрбияләде ләбаса ул ярын. Кашыклап ашатты. Каткан тәннәрен акрынлап массаж ясап йомшатты. Иҗади эшкә икәүләп керештеләр. Ул әйтеп тора. Гөлсем яза. Ин авыр вакытта да ике арадагы җылы мөнәсәбәт җиле өзелмәде. Ә хәзер ике арада кырыс җилләр исә.

[1]Кулыгызны бирегез мина, сезгә бер сүз әйтәм.

Әйткән сүзенә юньле җавап та бирми Гөлсем. Элек сүзләре тәмле була иде. Хәзер ире белән сөйләшәсе дә килми.

Аның холкы-табигате дә үзгәрә башлады. Уйланып тора-тора да, елап җибәрә. Мәгәр бу Рөстәм өчен елау түгел иде инде. Ике арада сүз бетте.

Ялта күге җәйләрен гел аяз була диярлек. Сентябрь, октябрь айларында да әле күк җәйге төсен ул кадәр нык үзгәртми.

Күңелләрдәге болытлар нык куерды. Алар хәзер мәңге таркалмас кебек.

Моны якыннары да сизде. Галимҗан янына күп килә иде. Табиблар. Кырым өлкә комитеты кешеләре. Кырым язучылары. Зур җитәкчеләр. Гади кешеләр белән аралашырга да яратты Галимҗан. Бакча каравылчысы Кырымбай белән нык дуслашты ул. Кырымбай—уртача гына буйлы, юка гына гәүдәле, кара-туткыл йөзле, илле яшьләр чамалы хәрәкәтчән кеше. Бакчада сөйләшеп утыра торган булып китте алар. Май бәйрәме көнне Кырымбай Галимҗаннарга хәләл җефете Нәфисә белән килеп тә киттеләр. Бәйрәм белән котларга. Күп итеп йөзем җимеше алып килгәннәр. Ул кырым җирендә генә үсә, имеш. Бик файдалы. Җитмеш төрле дәвасы бар. Әле татарчалап, әле русчалап сорады беркөн Кырымбай:

—Сизиң үй ичидә цир тетрәмәче икән ку, Галимҗан мүәллим?[1]

Галимҗан эндәшмәде. Елмаеп кына куйды. Чөнки җавап бирү кыен инде аңа. Кырымбай аңлады Галимҗанның кичерешен. Башкача төпченмәде.

Гөлсем шикле сүзләргә үзе нокта куярга булды. Хатын керләрен юып, үтүкләп, үзенекен ике чемоданга тутырып куйды. Галимҗанның да юды киемнәрен. Алар да үтүкләнгән. Үз урыннарында. Боларның барын да күреп, Гөлсем ханымның китәргә әзерләнүен сизеп торды Галимҗан.

Гөлсем ханым әллә ничә мәртәбә тукталды әйтергә. Ләкин булдыра алмый. Әйтергә авызын ачса, күзенә яшь килеп тыгыла. Елый-елый аерылышырга теләми ул. Тавыш-гаугага да кирәкми. Барысы да урынсыз. Барысын да кешеләрчә эшләргә кирәк. Соңыннан бер-берең турында яман уйларлык булмасын. Әлбәттә, ул күп әйтмәячәк.

—Мин китәргә булдым, бабакай, гафу ит! Шулай кирәк. Башкача безгә бергә торырга ярамый. Соңыннан моны үзең дә аңларсың,—диячәк.

Галимҗан, гадәтенчә, караватында ятып тора иде.

—Бабакай! Мин китәм! Гафу ит!—диде.

Шуннан аның йодрыгы төйнәлде. Ирене кысылды. Уртлары чәйнәлде. Елап җибәрмәс өчен иде бу.

Галимҗан авыр сулап куйды. Сүз әйтергә ашыкмады. Алама сүзләре юк иде аның Гөлсем ханым өчен. Хәер, булса да әйтмәс иде. Бу бит ир белән хатынның аерылышуы гына түгел. Болар намуска, кешелеклелеккә, хәтта бөек идеалларга бәйләнгән нәрсәләр. Аны язмышка бәйләп аңлаталар. Ул, бәлки, шулайдыр. Ләкин аның белән генә чикләргә ярамыйдыр аны. Кешеләрнең йөрәк төпкелендә, күңел тирәнлекләрендә әллә ниләр бар бит ул.

Өч кенә сүз әйтте Галимҗан:

—Бәхетле бул, балакай!

Гөлсем, елап, Галимҗанның күкрәгенә ауды:

—Алай димә! Бәхет теләмә миңа! Сүк син мине! Чәчләремнән йолык! Җиңелрәк булыр кебек!..

* * *

... Тышта көчле гарасат купты. Көн кинәт караңгыланып китте. Дөньяны җимерердәй итеп, күк күкрәде. Юк, күк күкрәү генә түгел иде

---

[1] Сезнен өйдә җир тетрәмәкче икән. Ялтада еш кына җир тетрәүчән. Кырым татарлары өй эчендәге ызгышны шуңа чагыштыручан. «Мүәллим»—аларның зур кешегә хөрмәтләп эндәшүе.

бу. Шуңа кушылып, бизгәк тоткан кешедәй, бөтен җир тетрәнә-селкенә башлады. Җир тетрәү! Бу юлы артык кылана шикелле. Йорт, әйтерсең, хәлсез кешедәй, менә-менә авып китәчәк. Җимерелеп төшәчәк. Өстәл, китап шкафы, хәтта Галимҗан яткан карават ыргый, сикерә, бии башлады. Йә, Хода! Ахырзаман, кыямәт көне шушымы әллә? Бу дөнья бетеп, бөтен җан-рух ияләренең икенче бер урынга җыела торган чагы килеп җиттеме?

Гөлсем ханым, Галимҗан кочагыннан аерылып, тышка чыгып йөгерде. Ә Галимҗан ята бирде караватында. Җир һаман тетри. Караватсикереп-сикереп куя. Галимҗанны ул туп урынына чөя. Рөстәм исән чакта да булган иде шундый көчле җир тетрәү. Бу юлы бигрәк каты кылана бу җир. Әйтерсең, кемгәдер үче бар.

Галимҗан, бөтен көчен җыеп, торып утырды. Караваттан төшеп, тәгәри-тәгәри булса да, тышка чыгуда иде аның исәбе. Әмма коточкыч янә бер тетрәү аны идәнгә сузып салды. Шунда һушын югалтты ул. Аның өчен хәзер җирнең асты өскә килә.

Тетрәү дәвам итте. Кайбер йортлар җимерелеп төшә башлады хәтта. Галимҗанны җимерек йорт астында изелеп калудан Кырымбай белән Нәфисә ханым килеп коткарды.

## Алтынчы бүлек

**... 1937 ел**. 31 декабрь.

Халык яңа елны каршылау мәшәкате белән йөри. Салкын бит очларыңны чеметеп ала.

Мәгәр кешеләрнең табигатьтә әллә ни гаме юк. Аларның үз шөгыле баштан ашкан. Кичкә матур табын әзерләп өлгерергә кирәк. Яңа елны ярлы өстәл белән каршы алырга ярамый.

Илдә бөтен дөньяга өлге итеп куярлык социализм төзеде.

Яңа җәмгыять өчен яңа төр кешеләр кирәк икән. Лаеклы булмаганнар өчен Гулак кебек үлем йортлары төзелә. Алар һаман ишәя бара. Социализм—оҗмахның ишегалды гына. Чын оҗмах—коммунизм. Аңа күп калмаган. Бер адым гына. Кешеләрне хәзер җиз иләктән үткәреләр. Үтеп чыга алганнар коммунизм гөлбакчасында яшәячәк. Үтмәгәне—иләк өстендә калган кибәге—җилгә очырылачак.

Пелөтән төрмәсенә «халык дошманнары»—коммунизм-оҗмахта яшәргә тиеш булмаганнар—юк ителергә хөкем көтеп яталар.

Авырулар бүлмәсендәгеләрнең хәле тагын да мөшкелрәк. Үлем хәленә җиткәннәрне монда алып килеп ябалар. «Халык дошманы» булыр рәте бармы аларның? Үз җанын сакларлык та чамасы юк бит.

Галимҗан Ибраһимов та үлем хәлендә килеп кергән иде. Өч көн дә яши алмас кебек иде. Өч ай үтеп киткән икән ләбаса инде. Өч ай! Өч ел сымак тоелды ул. Газаплы көннәр. Каһәрле минутлар. Йокысыз төннәр. Берөзлексез үлем белән көрәшү. Җан чатырман арасында диләр, дөрес икән.

Бүген «дәҗҗал»га яки сорау алуга чакырмадылар. Яңа ел килү шаукымы, күрәсең, һәркем күңеленә ниндидер шәфкатьлелек нуры өсти. Авырулар арасында да чагыштырмача тынычлык хөкем сөрә. Ә инде соңгы көннәрдә, яңа ел якынлашуын сизеп булса кирәк, имеш-мимешләр куерып китте. Имеш, 1938 елның башында суд ясаулар күбәячәк. Менә шунда алар һич тә «халык дошманы» булмаулары, совет властена каршы түгел икәнлекләре турында чатнатып әйтеп бирәчәкләр. Совет суды гадел хөкем чыгарырга тиеш. Аңлы, белемле, кешелекле судьялар язмышыңны уңай якка хәл итәргә тырышачаклар. Ил, халык алдында аларның тузан бөртеге кадәр дә гаепләре юк икәнлекне болай да тикшереп белгәннәрдер инде. Чыгарырлар моннан. Башкача тотмаслар.

Болар өчен шундый изге хәбәр дә йөри. Янәсе дә, гаепсезгә

утырганнарны яңа елда болай гына—судсыз гына коткарачаклар. Утын агачы кадәр дә файдагыз юк бу җәмгыятькә, бушка ашап ятасыз сасып, сезне асраганчы эт асрарсың, алдыннан артың яхшы, ди, арт ягына берне чәпеп куачаклар, ди, моннан.

Галимҗан Ибраһимов сүзләргә катнашмаска тырышты. Чөнки бу сүзләргә ышанмый инде аның акылы. Утын итеп яксалар-ягарлар аларны, иллә мәгәр чыгарып җибәрмәячәкләр. Шулай да моны аларга әйтергә ярамый. Өмет, кеше өчен бик кирәк ул. Ә үзенең кәефе начар түгел иде бүген. Яңа елга бәйле өметле уйлардан күтәрелгән күңел түгел бу. Сәбәбе Фатыймада.

Галимҗан Ибраһимов Фатыймага үз янына бөтенләй килмәскә, аның белән сөйләшмәскә, фикер алышмаска кушты. Бик авыр кичерде аның бу кыланышын табибә. Алсу бит очлары кинәт күгәреп киткәндәй тоелды. Җылы күз карашлары салкынайды. Сүз әйтә алмас хәл кичерде хәтта. Шулай да сорарга мәҗбүр булды:

—Галимҗан абый! Нигә алай?

—Шулай кирәк.

—Хәтерегезне калдырдыммы әллә?

—«Халык дошманы»ның хәтерен сакламыйлар.

—Ник алай дисез? Сез «халык дошманы» түгел. Әйттем бит инде: сезне коткарачаклар. Бөтен җәмәгатьчелек шөгыльләнә моның белән. Әтием—шуларның башында.

—Кирәкми, акыллым! Соңгы сүземне әйтәм. Мина беркемнән дә, бернинди дә яклау кирәкми. Зинһар, килмәгез яныма!

—Әгәр шулай кирәк икән...

—Шулай кирәк.

Бу хәлне икенче көнне әтисенә сөйли Фатыйма ханым.

—Галимҗан Ибраһимов зур, акыллы, мәгълүматлы кеше, кызым, көчле сәясәтче, аның сиңа әйткән сүзләрендә нindiдер серлелек, үзенчә бер тирән мәгънә бардыр; аңа карап, аны ташлама, кызым,—диде.

—Нинди серлелек икән соң ул, әти?

—Син кешенең чирен генә карама, кызым, аның эчке дөньясына да үтеп керергә тырыш, врач кеше шулай булырга тиеш бит.

—Галимҗан Ибраһимов кебек бөек шәхеснең эчке дөньясына үтеп керерлек сизгерлек бардыр шул миндә...

—Ул синең үз язмышың өчен борчыладыр.

—Ничек инде алай?

—Галимҗан Ибраһимовка якынлыгыңны сизсәләр, үзеңне харап итәргә мөмкиннәр.

—Мин аннан курыкмыйм, әти!

Ата күңеле дөрес фараз иткән иде Галимҗан Ибраһимовның нечкә сәясәте хакында. Бер сорау алу вакытында тикшерүче Фатыйма ханым белән ни өчен якын мөнәсәбәткә керүен сораган иде бит. Димәк, шымчылар авыру «халык дошманнары» арасында да бар. Хәер, кайда гына юк ул чебен җанын саклап калу өчен намусын, вөҗданын сатучы әшәке җаннар? Галимҗан Ибраһимов, чыннан да, Фатыйма язмышы өчен борчылып кискән иде ике арадагы җылы мөнәсәбәт җебен.

Әмма Фатыйма тиз чигенә торган холыклы түгел икән шул. Кергән саен, арага бернинди күләгә төшмәгәндәй, кояштай балкып килә дә Галимҗан абыйсы янына, әйтәсе килгәнен чатнатып әйтеп, әлеге балкышыннан нур түгеп калдырып китеп бара. Галимҗан теге вакытта салкын сүз әйткәне өчен үкенеп тә куя. Бүген, яңа ел алдыннан, бу шәфкать туташ фәрештәсе җылы хәбәр белән шатландырды аны. Ул аңа Хәдичә белән очрашуын сөйләп бирде.

—Хәдичә?!

—Әйе, Хәдичә апа!

—Тукта! Тукта! Минем Хәдичәме?!

—Сезнең Хәдичә!
—Бу бит... бу бит... Әллә ничек...
—Әйе, Галимҗан абый, әллә ничек шул. Бик катлаулы.
—Ә син гадиләштереп кенә сөйләп бир инде, сеңлем!

* * *

... Теге вакытта, Симферопольдән Казанга килеп төшкәч, аны-моны һич уйлап тормыйча, Галимҗан Ибраһимовка ташланган иде Хәдичә. Утыртып куйганчы, иренә бер генә сүз булса да әйтеп калуда иде аның теләге. Ләкин Мөбарәк-Колга күреп калды да Хәдичә ханымны, ире яныннан тартып алып, аны бер милиционер кулына тоттырып җибәрде. Бер ай җәзалыйлар Хәдичәне төрмәдә. Көн дә диярлек сорау алына. Хәдичә, барын да булганча сөйләп бирә. Декабристлар хатыннарының ирләре артыннан Себергә барулары турында да әйтә. Нигә, гаепмени? Чын хатын шулай булырга тиеш.

Ирекккә чыккач, йөри, сораша, Галимҗанның Пеләтән төрмәсендә утыруын белә Хәдичә. Монда тоткыннар белән очраштыру гадәте юк икән. Якын да китермиләр. Шунысы бар: үзенең дә хәле шәптән түгел, бер тиен акчасы юк. Үзе дә ач йөри. Кунар урыны да юк. Төннәрен вокзалда үткәрә. Ашханәләр тирәсендә йөри. Чүп савытына бәрәнге кабыклары, кәбестә яфраклары чыгарып түгәләр. Кайчакта икмәк кисәге дә эләгә. Кыскасы, аның тормышы ташландык эт язмышыныкына әйләнә...

Үзләрендә кунакта булган күп кенә татар язучыларын белә Хәдичә ханым. Әллә шуларны эзләп табаргамы? Ялтада аларда көн дә кеше була иде бит. Галимҗан аларны кочаклап ала иде. Әллә аңа да эзләп табаргамы фатирларын? Барып керергәме? Юк шул, булмый. Заманы ул түгел хәзер. Кешеләр керпе урынына йомарланды. Галимҗан Ибраһимовның исемен әйтергә дә куркучылар күбәя бара. Аларны мазасызлап йөрү һич килешмәс. Ни дисәң дә, Галимҗан Ибраһимов хатыны бит әле ул!

Казаннан китү ярамый иде аңа иреннән башка. Эш эзләде дә, эш эзләде. Бервакыт, үзе дә ни өчен икәнлекне уйлап тормыйча, китап кибетенә керде ул. Китаплар шактый күп. Алучылар да юк түгел. Шунда ике кешегә игътибар итте. Язучылар затыннан булырга тиешләр. Алар янына барды да:

—Сез Галимҗан абыегызны беләсезме, яшьләр?—дип сорады.

Берсе сораугa сорау белән җавап бирде:

—Казанда Галимҗаннар буа буарлык ул, апа, сезгә кайсысы кирәк соң аларның?

—Галимҗан Ибраһимов, дигәне.

—Димәк, сез «халык дошманы»н эзлисез? Кеме буласыз аның?

—Галимҗан Ибраһимовның «халык дошманы» булуы мөмкин түгел. Аның турында шундый алама фикер йөртүчеләрнең үзләрен «халык дошманы» дип әйтер идем мин.

—Авызыңны шәйләп ач, апа, утыртып куюлары бар.

—Ә мин аннан курыкмыйм.

Бу ике кеше чыгып киткәч, яшь кенә сатучы кыз янына барды ул:

—Миңа Галимҗан Ибраһимовның берәр әсәре кирәк иде, сеңлем.

—Соң, апа, белмисезмени: «Галимҗан Ибраһимов» дигән сүзне әйтергә дә куркалар Казанда. Ул бит «халык дошманы» булып чыкты. Китапларын әллә кайчан җыеп алдылар бит. Яндырып та бетергәннәрдер инде.

Хәдичә, башын түбән иеп, йөрәге уттай янган хәлдә, чыгып китте китап кибетеннән. Тышта буран иде. Аның эчендә ут иде.

Өч тәүлек инде авызына юньле ризык капканы юк. Су белән генә тора. Аның хәле бетте. Башына әллә нинди уйлар килә. Ул хәзер психбольницага бармак була. Аһ, куй! Ни өчен? Әллә хыялланамы? Бетте, бары да бетте. Дырылдап җир әйләнергә тотынды. Әйләнде, әйләнде дә нindидер упкын барлыкка килде.

Бөтен көчен туплап, йөгереп китмәкче булды ул. Ләкин булдыра

алмады. Исерек кешедәй чайкалып шул китап кибетенең баскычына барып утырды да ике кулы белән башын тотты.

... Һушына килгәндә, бәләкәй тәрәзәле тар бер бүлмәдә агач караватта ята иде ул. Озак кына түшәмгә карап ятты. Кайда ул? Ни булды? Нишләттеләр аны? Менә шактый дөнья күргән бәләкәй генә бер каты уч төбе анын йөзен сыйпап алды. Шуннан анын карлыккан, алжыган, зәгыйфь тавышы ишетелде:

—Үтте, балам, бары да үтте, Аллага шөкер, инде үлем шайтаннары тырнагыннан тартып алынды, Ходай Тәгалә моннан арысын хәерле кылсын инде! Иншаллаһ! Болай булгач—яшәрсең!

Караваты янына терәп үк куелган агач урындыкта утырган бер карчыкның күзләре белән очрашты анын карашы. Күзләре анын бәләкәй генә. Эчкә баткан. Шуңа күрә аларнын нинди төстә икәнлеген дә белеп алу шактый кыен. Соры төсендәрәк булса кирәк. Битләр кырык картадай җыерчыкланып беткән.

—Китап кибете күтәрмәсеннән егылып төшкәнсең бит, гөлкәем, кем соң син? Йөрәк өянәгең бармы әллә, күгәрченкәем, әгәр шулай икән, нишләп ялгыз йөрисең бу суыкта? Өстең дә бик юка лабаса, ярый әле изге күңелле кеше кулына эләккәнсең, туңып үләр идең бит...—дип сөйләде дә сөйләде әби.

—Кем кулына эләккәнмен соң мин, әбекәй?

—Нурмөхәммәт исемле ул. Тушы[1] бүлмәнең хуҗасы була. Китап кибете күтәрмәсе янында тәгәрәп ятканыңны күргән дә, күтәреп алып та кайткан фатирына. Шуннан синең янына мине чакырды. Шәфкатьбикә әби, ди бу, син тушы хатын янында утырып тор, ди; мин, ди, ашамлыклар алып кайтам, аннан соң өчәүләп чәй эчәрбез, ди. Ут инде, ут, балакаем, терекөмеш тә шулай булмас, кеше өчен үлеп тора мәгәр; получка алган саен чәйгә чакыра. Шәфкатьбикә әби, Коръән укы, сабак укы, ди, пәри кызлары иялəшмәсен, алар минем ише ялгыз ирне чамалап кына йөриләр,—дип көлдерә. Җәмәгате дә би-и-к уңган иде мәгәр, күршекәем, Шәфкатьбикә әбекәем, дип, үлепләр торыр иде, авыр туфрагы җинел булсын инде... Вафатына ике ел инде менә.

Бүлмәгә күз йөртеп чыкты Хәдичә. Ишекне кергәч тә, сул якта табак-савыт куя торган урын, аннан берничә агач урындык. Бүлмә уртасында дүрт почмаклы кечкенә өстәл. Уң як стена буенда ике кеше ятарлык агач карават. Өстәл өстендә яткан берничә китап хуҗанын укырга яратуын аңлатып тора.

—Шәфкатьбикә әби, сезгә бик зур рәхмәт инде. Мине саклаган өчен, Ходай бәхетле картлык, озын гомер, сәламәтлек бирсен үзегезгә!—дип, ишеккә таба киенергә бармакчы булды Хәдичә ханым. Ләкин, башы әйләнеп, кире карават читенә утырды.

—Син китмәк буласынмы, балакаем, Нурмөхәммәт җибәрмәскә кушты бит, ни диде, чәй куя тор, диде, очып кына базарга барып кайтыйм әле, диде. Чәй куелган, кәридурда, примуста, кайнагандыр инде...

Ул арада, тышта аяк тавышы ишетелеп, җинелчә генә ишек шакылды, шунда ук ул ачылып та китте, бер ир-ат килеп керде. Кереш-керешкә тәтелдәргә дә керешге:

—Вәт минем күршем Шәфкатьбикә әбекәччәем, чәен дә өлгерткән, дога укып, бу чибәркәйнең чирен дә куган, хәзер рәхәтләнеп чәйләп алабыз, хи-хи-хи...

Кулында анын берничә төенчек иде.

—Бусы, Шәфкатьбикә әбекәччәем, сарык итен таныш татардан алдым; хәзер үк аш салып җибәр әле.

---

[1] Тушы—Казан арты сөйләшендә шчт чиратлашуы картлар телендә һаман да бар.

* * *

Чәй табынында сүз әллә ни куермады.

Хәдичә ханымга бик кыен иде. Чәйне кыстатып эчте.

Бу ике миһырбанлы кеше янында бик рәхәт ана. Нурмөхәммәтнең буе—уртачадан югарырак. Күкрәге—киң. Уйнаклап торган конгырт күз. Килешле генә борын. Чибәрлеге уртачарак. Мәгәр сөйкемле кеше.

Хәдичә нишләргә белми иде. Чыгып та китә алмый. Чит кеше фатирында калу да килешми.

Тәрәзә төбендә берничә китап ята иде. Хәдичәнең китапларга карап торуын күреп, берсен алып бирде Нурмөхәммәт:

—Менә бу китапны ун мәртәбә укып чыкканмындыр.

Бу Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы иде, Хәдичә аны күкрәгенә кысты. Китап тәненә сеңеп, йөрәгенә үтеп кергәндәй булды. Ул тынсыз калды. Күз яше сыгылып чыкты.

Хәдичә ханымның бу аңлаешсыз халәте аптырашта калдырды Нурмөхәммәтне:

—Сезгә ни булды, сеңлем? Төсегез үзгәрде?

—Мин—Галимҗан Ибраһимовның тормыш иптәше Хәдичә Фәтхуллина булам!

—Галимҗан Ибраһимовның хатыны?!

—Әйе...

Беразга тын тордылар. Авыр иде бу тынлык. Нурмөхәммәт озакка сузмый, үзенең Пеләтән төрмәсендә сакчы булып эшләве, Галимҗан Ибраһимовны күрүе, аны коткарачаклары турында җылы сүзләр ишеткәләве, әдипкә Фатыйма исемле изге күңелле табибәнең ярдәм итүе турында сөйләп бирде.

—Шулай да Галимҗан ага Ибраһимов бәхетле икән!—диде ир елмаеп.

—Нишләп кинәт кенә андый фикергә килдегез әле?

—Аны бөтен кеше ярата. Кешеләр тарафыннан яратылу зур бәхет ул! Бу—бер. Икенчедән, аның сезнең кебек олы йөрәкле хатыны бар.

—Шулай иде дә бит.

—Шулай булып калачак та! Галимҗан Ибраһимовны коткарачаклар!

—Ул әле яшәячәк! Тагы да шулай матур-матур әсәрләр язачак! Галимҗан, сәламәтлеге яхшырса, үзен-үзе акларлык көч табачак!—диде Хәдичә.

Галимҗан Ибраһимов белән Хәдичәне очраштырырга сүз бирде Нурмөхәммәт. Хәдичә бер кисәтү дә ясады:

—Галимҗан Ибраһимов китабын саклавыгыз өчен рәхмәт! Ләкин хәзер аны теләсә кемгә күрсәтмәскә кирәк.

—Ә мин курыкмыйм, Хәдичә сеңлем! Шул китап белән бергә үземне утыртсалар да курыкмыйм!

—Сез көчле, каһарман кеше!

—Мин үз иманыма табынам.

—Сез нишләп эш урыны итеп төрмәне сайладыгыз?

—Мин анда кирәкле кеше!

—Кайсы яктан?

—Тоткыннарны эт урынына да күрмиләр. Типкәләп йөртәләр. Ә мин алай итмим. Шуңа күрә мине яраталар. Мин анда бик кирәк. Фатыйма сеңлекәшне алыйк. Ул бит теләсә нинди якты, зур, нур балкып торган шифаханәләрдә эшләрлек. Юк. Китми. Авыру тоткыннарны дәвалый. Үзен нык яраталар. Палатага бер кереп чыктымы, авырулар төрмә тышындагы матур тормышны күз алдына китерәләр. Теләсәгез, мин сезне Фатыйма белән дә очраштыра алам.

—Мин бик шат булыр идем, Нурмөхәммәт абый!

* * *

Көннәрдән бер көнне Нурмөхәммәт тоткыннарны эшкә алып килде. Үзе кебек янә бер конвой-сакчы белән. Тимер юлдагы вагоннан цемент бушатырга. Рәттән акча эшләргә дип килүче чуар кешеләр дә йөк бушаталар.

Әлеге «чуар» кешеләр арасында Хәдичәне күреп калды Нурмөхәммәт. Кырык ямаулы телогрейка, сырма чалбар кигән. Башындагы бүреге шулкадәр иске—нинди чүплектән тапкандыр инде аны. Ирләр аның хатын кеше икәнлеген белми шикелле. Аркасындагы мендәргә[1] капчыкны салып җибәреп кенә торалар. Кайдан ала ул бу кадәр көчне? Таш ташып чыныкканмы? Үзен харап итә ләбаса бу. Менә исәр хатын! Аның аркасына авыр капчык салганда, Нурмөхәммәтнең эчәк-бавырлары өзелеп төшкәндәй тоелды.

Нишләргә? Бер капчыгын илтеп куеп, янә башкасын алырга барганда, аның юлына аркылы төште Нурмөхәммәт.

Сукмакта торырга ярамый иде. Читкәрәк алып китте аны Нурмөхәммәт:

—Хәзер үк кайтып китегез, Хәдичә сеңлем!

—Эшнең ни гаебе бар, Нурмөхәммәт абый?

—Ул хакта кич сөйләшербез.

—Күп калмады бит инде. Тагы бер сәгать чамасы эшләсәк...

—Бу капчыкларның авырлыгын мин үзем дә күп татыдым. Аркам әле дә чымырдап тора.

—Мин бәләкәйдән үк авыр күтәрергә өйрәнгән...

—Андый михнәт нормагыз аркылып үтәлгән бит инде... Нигә үзегезне-үзегез кыйныйсыз?

* * *

Сөйләшү кич дәвам итте. Документ юк. Бер җирдә дә эшкә алмыйлар. Ә яшәргә кирәк. Шул хакта әйтеп бирде Хәдичә ханым. 1938 ел башларында Галимҗанны чыгарачаклар. Аны тәрбияләргә дә кирәк булачак бит әле. Шул кадәресен дә мәгълүм кылды Хәдичә ханым. Ул янә бер хатын белән танышкан икән. Әлеге «мендәр», кырык ямаулы телогрейка, җылы чалбар, бүрекне ул табып биргән. Иртән Нурмөхәммәт фатирыннан чыгып китә дә, теге хатынга барып, әлеге алама киемнәрне киеп ала, эштән кайткач, юынып, кеше рәтендә өйгә кайта икән.

—Менә нәрсә, Хәдичә сеңлем, Галимҗан Ибраһимовны тиздән коткарачаклар, акча мәсьәләсендә борчылма; мин ялгызым гына түгел, без бик күпләр, ул чыгуга якты бүлмәләр дә, тәмле ашамлыклар да, дус-ишләренең хөрмәте дә күп булачак, ә сез сәламәтлегегезне аның өчен сакларга тиеш. Озакламый мин сезне Галимҗан ага белән очраштырачакмын! Менә шул! Хәзергә бер үзеңә бер бүлмә җитәдер бит?

Бу мәсьәләне алар беренче көнне үк хәл иткән иде инде. Шәфкатьбикә әби үз янына алырга булды Хәдичә ханымны. Мәгәр аның бу уе белән килешмәде Нурмөхәммәт:

—Караватың бик тар, Шәфкатьбикә әби. Минекендә йокласын, әнә.

—Ә үзең?

—Шәйхелисламның да ялгыз икәнлеген беләсең, мин хәзергә шунда...

Шул хәлләрне Фатыймага җиткерде Нурмөхәммәт. Фатыйма нык шатланды моңа.

—Мине Хәдичә белән очраштырыгыз әле, Нурмөхәммәт абый!—диде ул.

Җавапны шаяртыбрак бирде Нурмөхәммәт:

—Кирәк икән, Сезнең өчен күктәге фәрештәне алып төшәм.

—Ышанам сезнең көчкә, Нурмөхәммәт абый! Тик мине баштa җирдәге фәрештә белән кавыштырыгыз әле!

Очрашты алар. Хәдичә ханым Галимҗан Ибраһимовны белгән вакыттан башлап, бүгенге көнгә кадәр булган барлык тормыш мажараларын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Шуларны җиткерде Фатыйма Галимҗан Ибраһимовка. Хәдичә ханым белән тиздән очраштырачагы турында әйтте.

---

[1]Аны төрлечә атыйлар: мендәр, подушка, козел, ишәк...

* * *

Һәр кеше үзе бер дөнья! Туа. Үсә. Хезмәт итә. Җитди хыяллар белән яши. Бәләкәй чакта ук һәр күргәнен күнел сәхифәләренә яза башлый ул. Башта—азлап. Үз тирәсендәге әйберләр турында. Аннан күз карашы ерак офыкларны капшый. Күнел кошы әллә кайларга очып китә дә галәм серләрен өйрәнеп йөри. Бу кошның томшыгы каләмгә әверелә. Каләм күреп кайтканнарын хуҗасының күнел сәхифәләренә яза. Димәк, һәркемнең күнелендә калын-калын китаплар бар. Шуна күрә һәркем үзе бер дөнья ул. Аның йөрәгендә кояш ялкыны, котып бозы, акыл барып җитмәслек галәм сере, ак һәм кара төсләр, оҗмах, тәмуг...—тагы да әллә ниләр, әллә нәрсәләр бар.

Хәдичә белән 1915 елның көзендә танышты Галимҗан. Бу вакытта ул усал тәнкыйтьче булып танылган иде инде.

Аны үзен «Галия»дән кугач Зыя Камали укытырга чакырды. Хәдичә дә шунда укый иде.

Ул вакытта кызга 16-17 яшьләр чамасы иде.

Ашханәдә кызлар эшли. Хәдичә дә шунда мәш килә. Галимҗан килгәч, Зыя Камали әфәнде кушуы буенча, чәй һәм вак бәлеш алып керде Хәдичә. Хәдичә белән дә кызыксынды егет. Хәдичәне монда казакъ егете шәкерт Бәембәт Майлин алып килгән икән.

* * *

... Ике ел эшләде Галимҗан Ибраһимов «Галия»дә. Ике ел буе Хәдичәне дә өйрәтте укырга-язарга. Бу еллар Хәдичәнең аязлы көннәре иде. Ике елдан соң китеп барды Галимҗан. Хәдичә өчен болытлы көннәр башланды. Галимҗанга бөтен йөрәге белән гашыйк булганлыгын аңлады ул. Барысын да,—сөю-мәхәббәт, бәхет-сәгадәт, өмет-рухият,—үзе белән алып китте Галимҗан Ибраһимов. Кояштай балкып китте. Хәдичә өчен кояш нурлары үтмәстәй кара болытлар калдырды.

Уфада яшәү мөмкин түгел иде. Ул туып-үскән якларына—казакъ далаларына кайтып китте.

... 1933 ел. Галимҗанны Гөлсем ташлап китте. Бернинди караучысыз калды ул. Кырымбай агай белән Нәфисә түтинең килми калган көне бик сирәк сирәгән дә...

Монысы кем? Чемоданын күтәреп килеп керде.

Хәдичә ич бу!

Галимҗан ятып тора иде. Аны күргәч, торып ук утырды. Бу көннәрдә аның хәле ул кадәр начар түгел иде. Ул сикереп диярлек аягына басты хәтта. Ишек төбендә басып торган кызга таба атлады:

—Хәдичә! Бу синме?! Әллә ялгыш күрәмме? Нинди язмышлар белән?

Хәдичә, чемоданын куеп, аның куенына йомылды:

—Әйе. Бу мин, Галимҗан абый! Хәдичә. Таныдыгыз.

—Сон, нишләп мин сине танымаска тиеш әле?

—Күп еллар үтте бит.

—Ничек сон бу? Ялга-фәләнгә килденме?

—Ялга түгел, Галимҗан абый!

—Сон? Берәр эш беләнме?

—Мин сезнен янга килдем. Бөтенләйгә. Рөхсәтме?

—Бәхет бит бу!

—Әйе, минем өчен бәхет! Сезнен өчен ничектер?

—Уртак бәхет!

—Рәхмәт!

—Төшме бу, өнме?

—Өн бу, Галимҗан абый! Тормышта шундый көтелмәгән хәлләр була икән шул.

—Көтсән дә болай килеп чыкмас, валлаһи!

—Гафу итегез инде!

—Ни сөйлисең? Нинди гафу?

... Хәдичәнең өстендә җәйге юка пальто иде. Аны салып чөйгә элгәч, костюмнан гына калды. Күксел-зәңгәр костюмы аның көзге айларда була торган казакъ далаларының күксел-зәңгәр күк төсен хәтерләтә. Ә инде дулкынланып торган чем-кара чәчләре казакъ далаларының көзге төндәге шигъри каралыгы төсле. «Галия»дә аны «кара чибәр» дип йөртәләр иде. Сөрмәле кара кашлар, гөл чугыдай озын керфекләр, көлеп торган кара күзләр, чиядәй кызыл иреннәр аны бик гүзәл итеп күрсәтә. Әйтерсең, казакъ далаларын матурлау өчен генә үскән гүзәл бер чибәр бу! Шул гүзәллекне тулы килеш, бөртеген дә югалтмый алып килгән монда. Бу чибәрлек Ялта кызларын да көнләштерерлек ләбаса! Утыз биш яшьтә үзе әле егерме яшьлекләргә биргесез. Икесе өчен дә бик кадерле минутлар иде бу. Көтелмәгән очрашу икесен дә хәлсезләндереп җибәргәндәй итте. Шулай да ул артык озакка бармады. Чемоданын ачып, өстәлгә казакъ бавырсагы, татар чәкчәге, тагы да әллә нинди ашамлык-күчтәнәчләр куйгач:

—Хәзер чәй әзерлим,—дип, үз өендәге сыман, житез хәрәкәтләр белән табын хәстәрләргә керешә Хәдичә.

* * *

—Син мине бәхетле иттең, Галимҗан әкә!

—Киресенчә, Хәдичә-Йолдыз!

—Ничек алай?

—Теге вакытта мин моны аңламаганмын.

—Ә мин аңладым: «Пролетариат революциясе солдаты» өчен мәхәббәт кирәкмәгәнлеккә төшендем.

—Уналты ел янып яшәдеңме?

—Еpактагы Кояш нурында кызынып.

—Син егетләрне бер каруда гашыйк иттерерлек, Хәдичә!

—Мәхәббәт бер генә була, Галимҗан әкә!

—Яхшылыгыңны бәяләрлек сүз таба алмыйм, Хәдичә! Арыслан кыз син!

—Арыслан—ерткыч җанвар. Тешләрем бар, Галимҗан әкә! Миндә усаллык та юк түгел.

—Шул энҗе тешләрең белән бит очларымны умырып алсаң да бер сүз әйтмәс идем.

—Синең бит очларың болай да чокырлы, Галимҗан әкә, аның кай җирен умырасың?

Шулай сөйләшә торгач, алар янә көлешеп ала.

Ул янакларның эчкә батуы, чибәр йөзнең көл төсенә керүе өчен Галимҗанның үзен гаепли Хәдичә.

Уфадан киткәч, уналты ел буе, Ялтага килеп янадан очрашканчы, Галимҗанның тормышы, иҗаты, бөтен эшләре белән кызыксынып яшәде.

Ә инде өйләнгәнен ишеткәч, нишләргә дә белмәде ул. Йөрәге беркөн шатлыктан шашса, икенче көн кайгыдан котырынды. «Пролетариат революциясе солдаты»ның боз җанына яшәүнең бөек мәгънәсен бирә торган сөю кайнарлыгы кергән, ниһаять! Эретсен ул кайнарлык аның бозын! Бәхетле итсен аны. Аллаһдан бернәрсә дә яшереп булмаган кебек, бөек затларның да кылган эшен сер капчыгында саклап тору һич мөмкин түгел. Аның үзеннән уналты яшькә кече кызга өйләнүе дә мәгълүм булгач, «аһ» итте Хәдичә. «Пролетариат революциясе солдаты»ның боз йөрәгендә чын мәхәббәт уты кабыза алырмы ул? Әллә бозны яшьлек тилелегенең кара япмасы белән төрерме?

Гөлсем малай тапкач, шатланган иде Хәдичә. Чөнки Галимҗанга нәсел-нәсеп тамырын дәвам иттерүче варис кирәк. Ә инде уллары озак яшәмәгәч, күңеле белән янә Гөлсемне битәрләде ул. «Җебегән нәстәкәй: ирен аяктан екты, улын кабергә тыкты»,—дип гасабиланды. Бер хәрби кеше белән танышып, Галимҗан Ибраһимовны иң авыр вакытта ташлап

китүен ишеткәч, жене бөтенләй котырды Хәдичәнең. Ирне ир иткән дә хатын, чир иткән дә хатын шушы түгелме? Оятын эт ялаган бу юньсезнең, дип, тупас уйларга да бирелгән чагы булды. Шул юньсезлекне эшләр идеме Хәдичә? Астан эшләмәс иде. Кирәк икән, көче житсә, күтәреп йөртер иде. Һм!.. Галимжан Ибраһимов бит ул!

Боларны түкми-чәчми ихлас күңелдән сөйләп бирә ул Галимжан әкәсенә.

Галимжан Ибраһимов аны болан баласыдай юаш бер кыз дип исәпли иде. Теге вакыттагы әдәпле, басынкы, артык ипле чакларын уйлап. Куркак куян баласын да хәтерләтә иде әле ул.

Болары шулай булсын, ди. Ә менә атылган йолдыз урынына килеп керүе һич акылга сыймый. Чыннан да, ул аны шулай нык яратканмы? Шуңа күрә, үзе әйткәнчә, башкага тормышка чыкмаганмы? Кызлык гыйффәтлелеген аның өчен саклаганмы? Бу бит искиткеч зур мәхәббәт! Таһирның Зөһрәсе, Йосыфның Зөләйхасы, Мәжнүннең Ләйләсе, Отеллоның Дездемонасы, Хәлилнең Галиябануы ише бит бу! Кайбер йомшак авызлар: «Элеккеге мәхәббәт юк ул хәзер»,—дип, кара сафсата саталар. Бар икән бит! Гөлсемнең мәхәббәте ялган булган. Аңлау кыен моны. Серле йомгак икән мәхәббәт. Аның хакында күп акыллы башлар бик гыйбрәтле сүзләр әйткән. Әмма һәркем үзенчә фәлсәфә сата беркем дә төгәл генә аңлатып бетерә алмый.

Сөю тойгысы көчле булган Хәдичәдә. Өйләнергә теләүчеләр аның ачуын китереп бетергән хәтта. Берсен дә яратмаган. Берәүгә дә баш бирмәгән.

Шуларны сөйләгәч, шаяртып, яратып, Галимжан:

—Усал син, Хәдичә,—дип кеткелдәде.

—Усал. Аргамакның ялын тота алмадым барыбер.

—Тоттың инде, тоттың, тик мин аргамак түгелмен шул инде хәзер.

—Йөрәгең аргамак булсын, Галимжан әкә!

—Йөрәктәге аргамак бии лә ул, аны йөгәнләп кенә булмый.

—Йөгәнләмә, Галимжан әкә...

—Рәхәт синең белән!

... Барысын да сөйли Хәдичә. Берсен дә яшерми.

Зур кешеләрнең хатлары да үзенчә бер мәгънәле әсәр икән. Аларда—йөрәк сере, күңел дөньясы, аң-акыл, дуслык-туганлык хисләре, кешеләр арасындагы яхшы мөнәсәбәт, кыйммәтле тойгылар. Галимжан Ибраһимовның бай китапханәсе бар. Китап дөньясына чума Хәдичә ханым. Укыган саен фикерең ярлы, башың надан, караңгы икәнлекне аңлыйсың. Китап наданлыгыңны кысрыклап, аңга белем энжеләре сала, караңгы башыңны һаман яктырта бара. Өем-өем хатларны да ихлас укый Хәдичә. Галимжан әкәсе язмышына бәйле булганнарына тирән анализ ясарга ярата. Әлеге Шәһит Әхмәдиевка язган хаты кат-кат әйләнеп кайта. Беркөн аерым юллары турында озак баш ватып утырды ул. Бер урында болай диелгән: «Адәм гомере шулай инде: дөньяга килсәң, планның бер өлешен үтисең, тәмамлауны башкаларга тапшырып китәсең. Шулай да, Шәһит, акрынлык белән булса да, бер егерме ел гомер кирәк әле. Саклансак, мона да ирешербез».

Егерме елны ул түшәмгә төкереп яту өчен теләми. Ана язарга кирәк. Язарга!

—Галимжан әкә! Гомерне чикләп әйтмиләр, ул бит фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килергә мөмкин,—диде Хәдичә ханым.

—Бу хакта әнидән дә ишеткәнем бар иде, усал биям! Синең фикер аныкына гел туры килә дә тора. Тик мин аны рәнжеттем.

—Нишләп?

—Жирләргә кайта алмадым.

—Аңладым: «Пролетариат революциясе солдаты...»

—Ул гына түгел. Вакыт булмады...

—Шул инде ул. Солдатлык галәмәте...

—Ата-ананы рәнжеткән бала рәхәт күрми, имеш.

—Шуны әле яна гына белдеңме?

—Әти, әнидән ишеткән бар иде лә ул. Аларны күп рәнҗеттем бугай.
—Ничек?
—Кире якларым күп иде.
—Аларча яшәргә теләмәгәнсеңдер?
—Бу мөмкин түгел иде!
—Рәнҗемәгәннәрдер. Синең кебек бөек кешегә бәддога кылмый атана. Горурлана гына...
—Шулай дисеңме?
—Шулай димен!
—Син минем акылыма алтын саласың.
—Әгәр мине тыңласаң, озак-озак яшәтермен, Галимҗан әкә!
—Врачлар әйтә...
—Мина алар сүзе кирәкми, Галимҗан әкә, үзем врачмын. Чирне дәвалау юлларын күп беләм.
—Берәрсен әйт әле хәзер үк.
—Чирне иркәләргә ярамый. Иркәләсәң, ул очына, и хуҗам әйбәт, дип, йокыга моң песидәй, ята бирә эчендә. Сүгенсәң, авырткан җиренне йодрыкласаң, бик начар, дивана кешегә эләктем, моның белән борчак пешереп булмас, ди дә китә дә бара икән.

Галимҗан кычкырып көлеп җибәрде дә алдына утыртты Хәдичәне. Аның чәчләреннән әллә нинди тәмле ис килә. Чәч тәме! Мәхәббәт тәме дә шундадыр, бәлки. Галимҗан шул тәм эченә чумды.

Сөю хисе белән янган кайнар иреннәрен үзе үк Галимҗанның иреннәренә китереп терәде. Иреннәр бер-берсенә керешеп, көчле, утлы, ярсулы үбешү булып алды. Алар бер-берсенә берегеп, бер мәхәббәт йомарлыгы булып әверелделәр. Рәхәт тә, ләззәтле дә, шул ук вакытта куркыныч та иде бу минутлар. Иң әүвәл Галимҗан һушына килде:

—Ярамый болай!..
—Нигә ярамый? Мин хәзер—синең хатының.
—Күп нәрсәне аңлап бетермисең шул әле.
—Нәрсәне аңларга кирәк соң әле безгә тагын да?
—Миндә туберкулез. Сиңа йогуы бар.
—Мин аннан курыкмыйм, Галимҗан әкә! Ир белән хатын бер йөрәк ул, алар бер бөтен, бер-берсеннән шикләнмәскә тиеш, мин монда туберкулездан куркып түгел, мәхәббәтемне эзләп килдем.

Хәдичә уттай янган иреннәрен Галимҗанның иреннәренә батырды. Бу ут иреннәр тирәсендә генә калмады, йөрәк төпкеленә үтеп керде Галимҗанның. Бу ут чын мәхәббәтнең ялкыны булды. Ул утны океан сулары белән дә сүндерерлек түгел иде инде.

—Мин сине яратам, нык яратам, Галимҗан әкә!—дип пышылдады Хәдичә.—Син дә мине яратасыңмы, тик дөресен әйт, мин ялганны яратмыйм, икебез бер иман белән яшик!..
—И, усалым, беренче мәртәбә мондый сөю ләззәтен синнән күрәм, син—мәхәббәт фәрештәсе!
—Юк, Галимҗан әкә, мин фәрештә түгел, була да алмам, андый кызыл сүзләр кирәкми, дөресен генә өзеп әйт!
—Дөресе шул, мин сине бик нык яратам! Бик нык!

* * *

Хәдичә килгәч Галимҗан Ибраһимов күп эшләде. «Безнең көннәр» романының икенче кисәге язылып бетте, өченчесен башларга иде исәбе. «Яшь йөрәкләр» романын яңабаштан үзгәртеп чыкты. «Казакъ кызы» романының икенче кисәгенә тотынырга дәртләнде.

Галимҗанның эш ысулы кызыксындыра иде Хәдичә ханымны. Өстәл алдыннан ул, нигәдер, кара чалбарын, ак күлмәген кия, галстук буа. Үзен матурлый, җыйнаклый, билгеле бер тәртип-халәткә кертә. Бу кыланышы аның кыз алырга барырга әзерләнгән фырт егетне хәтерләтә. Шулай үзен

билгеле калып эченә керткәч тә, әле тиз генә барып утырмый. Уйлана. Йөрештереп ала. Нидер кичерә. Бу вакытта Хәдичә ханым аны кызлар белән ат чабышына әзерләнгән казакъ егетенә охшата. Шул минутларны сагынып искә ала. Менә хәзер Галимҗан белән икебез ике атка атланып чабышасы иде, дип кызыга. Әлбәттә, ул еллар үткән инде. Җил булып искән.

Бу вакытта аңа аз гына да комачауламый Хәдичә ханым. Эше булса, аяк очына гына басып йөри. Үзе дә җитди бер эш таба да берәр урынга барып сенә. Аңа килгән, ул кемгәдер язган (кайберләренең күчермәсен калдыра) хатларны кызыксынып укый. Менә ничек язган ул Фатих Хөснигә:»... Сезнең анда, беренче биттә үк, менә мондый сүзләр бар: «Гыйнвар кешеләрнең мыекларына кар ябыштырып йөри». Шунда ук тагын: «Ә җил чабып килә дә вагоннар астына кереп ышыклана»,—дигән җөмләләр бар. Мин аңламыйм, Фатих туган, ничек ябыштыра соң ул гыйнвар дигәнең кешеләрнең мыекларына карны? Бөтен кешеләргә берьюлы ябыштырамы? Әллә, берсен оформить иткәннән соң, икенчесенә китәме? Аннары тагын, Сезнең логика белән йөрсәк, болай килеп чыга: гыйнвар үзе тудырган җил, шул гыйнварның үзеннән качып, вагон asларына кереп ышыклана булып чыга. Мин үзем, сүздән әйтик, табигатьнең мондый четерекле күренешен аңлап җитмим. Ник дисәгез, сәбәбе ачык: чөнки мыекка кар ябыштырып йөрүче гыйнварны, образлап әйткәндә, бәлки, күз алдына китереп тә буладыр. Әмма, гыйнвардан куркып, вагон астында качып утырган җилне күргәнем юк... Болар барысы да, Фатих туган, ничек тә булса шәп итеп, шаккаттыргыч итеп язарга тырышудан килә. Ә нигә кирәк безгә кешеләрне шаккаттыру? Болай да эш җитәрлек ләбаса. Кыскасы, гадилек һәм кешеләрчәрәк язарга өйрәнәсегез бар».

Шундый хатларны укып чыккач, тирән уй кичерә Хәдичә ханым. Язучы хезмәтенең тауда таш кисүдән, шахтада күмер ватудан, цехта чуен кайнатудан авыр икәнлеген ишеткәне бар иде аның. Валлаһи, дөрестер бу.

Галимҗан Ибраһимовны аңламаучылар да күп булды. Кемнәрнедер дусларча, кемнәрнедер аяусыз тәнкыйть итү уты бервакыт аның үзенә әйләнеп кайтты, үзен көйдерә башлады. «Алмачуар» хикәясе басылып чыккач, «алашалар әдибе» дип атадылар аны хәтта. Хәнәф Наум дигән «тәнкыйтьче» кара канатын аеруча нык җәеп җибәрде. Галимҗан Ибраһимов иң авыр чирләр кичергәндә, аның турында әллә күпме лөгатькә сыймастай сүзләр белән мәкаләләр язарга, өстенә чиләкләп-чиләкләп пычрак атарга тотынды. Галимҗан Ибраһимовны әдәбият тарихыннан сызып ташларга кирәклек турында пычрак сафсата сатты, лаф орды. Акылның аң белән яхшы булуын аңламауның күнелсез бер күренеше иде бу. Шундый кара уйлылар юлына ак җәймә җәюче мөхәррирләр дә гаепле, билгеле. Камчы тәнне яралый, ә нахак сүз сөяк сындыра. Болай да коры сөяккә калган Галимҗанның җаны нык әрнеде ул вакытта. Утны май белән сүндереп булмый. Җәмәгатьчелек Ибраһимовның утлы һөҗүмен көтте. Әмма сабыр итте зур әдип. Ут та чәчмәде. Су да сипмәде. Корым да сөртмәде. Эндәшмәве белән җинде Галимҗан. Шуның белән ул үзенең көчле ихтыярлы икәнлеген янә бер мәртәбә исбат итте. Шул инде: мең эт җыйнаулашып өрсә дә, айның чите кителеп төшми.

Үткәннәр. Хатирәләр. Киләчәк. Янә бер авыр чирне җинде Галимҗан Ибраһимов. Ялта табиблары аның ике кабыргасын кисеп ташлады. Шулай да аякка басты. Нык баскан иде шикелле. Хәдичә ханым һаман шулай йөрәгенә, күңеленә, шифа булып керә белде. Казакъ халкының: «Картлар йөрәген гашыйк яшәртә»,—дигән әйтемен искә алып тәрбияләде аны. Ире белән бер йөрәк булып яшәргә тырышты.

... Ул көнне алар дингез буенда да йөрделәр.

Сентябрь азагы. «Бәрхет мизгеле» дип атала бу чор Кырымда. Һава саф. Сулышны кысмый. Галимҗан Ибраһимовның күнеле күтәренке иде.

—Син миңа янә ун ел гомер бир, Хәдичә! Язасыларым күп бит!

—Вакытны чикләп сорамыйлар, Галимҗан әкә!

—Әйе. Бу хакта әйткән идең инде.

Аның хәяты явыз көчләр белән чикләнде. Иртәнге саба җиле аңа шифа булып исте, кичке сәҗдә җиле гомерен кисте.

* * *

... Төрмә... 1938 ел. Беренче гыйнвар. Төн буе керфек какмады Галимҗан Ибраһимов. Уйланып ятты. Башкаларның да хәләте шулайрак иде. Яңа ел! Тоткыннар яңалык өмет итә. Өсләренә өелгән пычрак-чачракны алып ташларга тели.

Кичен әллә күпме бәхәсләр, юраулар, хыял итүләр булып алды. Төн урталары үткәч, берәүләр авыр ярадан сызлана, икенчеләр сүгенә, өченчеләр гырлап йоклап китә...

Шулай да тоткыннар өчен рәхимлерәк булды беренче гыйнвар. Аларны бүген «дәҗҗалга» яки сорау алырга чакырмадылар. Тикшерүчеләр бәйрәм иткәндер, бәлки.

Төн буе Хәдичә ханым турында уйланып ятты ул. Нык борчылды аның язмышы өчен. Кайларда йөри икән? Нинди язмышлар көтә аны алда? Ә менә төштән соң язмыш очраштырды да куйды аларны. Моны изге күңелле Фатыйма ханым белән әлеге миһырбанлы сакчы Нурмөхәммәт оештырган.

Хәдичә Казанда яшәячәген, эшкә урынлашканлыгын әйтте. Бер арада әлеге яратып әйтә торган «әкә» сүзен кыстырырга да онытмады:

—Сине коткарырга йөрүчеләр күп, Галимҗан әкә, мин шуларның берсе.

Галимҗан мона каршы төште:

—Юк, юк, кирәкми, Хәдичә, үзеңне утыртып куюлары бар.

Хәдичә үпкә белдерде:

—Минем курыкмаганлыкны беләсең бит инде, Галимҗан әкә!

Ибраһимов аның күңелен күтәрергә тырышты:

—Беләм, беләм, усалым, син әнә күзеңнән үгез үткәрәсең. Сак кылан. Минем аркада болай да күпне күрдең.

—Безнең язмышлар уртак.

Алар кавышу өмете белән аерылыштылар.

* * *

Берничә көннән бәхетсезлек килде. Фатыйма белән Нурмөхәммәтне утыртып куйдылар. Моны Галимҗан бик авыр кичерде. Нурмөхәммәткә аның язмышы өчен борчылып йөрмәскә кушкан иде. Фатыйма ханымны янына килүдән дә тыйды. Катырак әйтәсе калган аларга. Ит яхшылык, көт явызлык кебегрәк килеп чыкты бу. Аңа изгелек эшләү үз башларына кара кайгы алу булып чыкты. Моның өчен Ибраһимов соңгы сулышынача кайгырачак.

Тоткыннар арасында да шымчылар бар икән шул.

Сталинга хат язарга кушалар Ибраһимовка. Бергә эшләгәннәр, янәсе. Онытмагандыр. Аңа язучылар күптер инде хәзер. Мең-миллиондыр. Сталин хәзер коммунизм шәүләсе белән фашизм шәүләсе арасында кысылып калды. Бу ике шәүлә кыршау урынына кыса аны. Көнбатыш Европада сугыш уты кабына. Аның ялкыннары Бөек Русияне ялмый. Асу. Ату. Үтереш. Илнең алтын баганасына торырлык ватан каһарманнары харап була. Күпләрнең башы төрмәләрдә чери. Кайчанга чаклы дәвам итәр бу? Хәят кояшы кара болыт белән каплана. Ул болытларны куарлык берәр пәйгамбәр табылырмы?

* * *

Сасы төрмәдә үлем белән һаман Прометейча көрәшеп яткан Галимҗан Ибраһимов үз иҗат офыкларының кайсы тирәдәрәк тибрәлүен яхшы белә. Ләкин әнә шулай язып чыгачакларына ышанып бетми инде хәзер. Чөнки

ул—«халык дошманы». Бу кандала дөньясына килеп эләгүне бер аңлашылмаучылык дип исәпли. Совет власте бар. Коммунистлар партиясе бар. Ленин идеяләре яши. Дәүләт түрендә корыч характерлы Сталин утыра. Тиздән аны бу кандала оясыннан коткарачаклар. Шуна ышана ул.

Үлем шайтаны күз алдында бии. Газраил йодрыгын борын астына китереп куя. Мәңгелеккә чакыра.

Мәңгелек!

Җан бирер вакыт җиткәндә адәм баласы шул хакта баш ватып хафалана икән. Җир һәм Күк берлеген барлый. Ул оҗмах өмет итә. Бер уйласаң, Җир үзе дә җәннәт бит. Матурлык белән зиннәтләндерелгән ул. Көмеш сулы елгалар. Зәңгәр сулы океаннар. Калын урманнар. Чәчәкле хәтфә болыннар. Җимеш тулы бакчалар. Иген кырлары. Тагы да санап беткесез мең-миллион төрле бизәкләр. Димәк, оҗмах икәү: берсе—Җирдә, икенчесе—Күктә. Күк оҗмахына эләкмәде Галимҗан. Бер адым калгач, Сират күпере кылы өзелде. Бу төш иде. Ләкин тавык төшенә ярма керү түгел ул. Җир һәм Күк кендеге берлеге турында уйлану төше. Тавык беркайчан да андый төш күрми. Тавык мие эчкәннәр дә күрми андый төшне.

Җир оҗмахы турында да уйлана Галимҗан. Язганнары чама белән егерме том булыр кебек. Шуларны уйлап, якты дөньяга чыгарырлар, бәлки. Шайтан гына өметсез була. Яшәүгә өмет бар әле.

* * *

1938 ел. 20 гыйнвар. Галимҗан Ибраһимов «дәҗҗал» бүлмәсендә. Өстәл артында яна тикшерүче утыра иде. Илле яшьләр чамалы бер «мужик». Чыннан да ул «мужик» кыяфәтле иде. Каткан костюмнан. Күлмәк, пинҗәк изүләре ачык. Чуалган чәчле. Күзләре, менә сине чәйнәп ташлыйм дигәндәй, ерткыч бүренекедәй елтырап тора. Бит очларындагы кан бүлтәймәсе—тавык күкәе зурлык. Чиртсәң, кан чишмәсе бәреп чыгарлык. Аның салмыш икәнлеген ахмак та аңларлык. Алаптай авызын колакларынача ерып, көрәктәй зур кул аркасы белән каткан калын иреннәрен сыпырып куйды да:

—Бу соңгы сорау, понимаешь ли, или смерть, или жизнь, решай сам, яшисең килсә, кулынны куй,—диде ул, тупас кына, татар, урыс сүзләрен боламык урынына болгатып.

Анда ни язылганны белә Галимҗан. «Мужик» укый башлагач:

—Кирәкми, укыма,—диде.

—Значит, кул куясың?—дип турсайды «мужик».

Галимҗан эндәшмәде. Син бүре булсаң, мин бүре алдында каушап кала торган сарык түгелмен, дигәндәй, «мужик» усал гына карап торды. Аның янында янә ике кеше бар иде. Берсе—озын буйлы. Икенчесе—мичкәдәй юан кыска гәүдәле. Галимҗан башта аларга игътибар итмәгән иде әле. Бәй, бакса, икесе дә таныш кешеләр икән ләбаса. Озын буйлысы—элекке шәкерте Мөбәрәк. Мичкә юанлыгы карсакның исемен белми Галимҗан. Ялтада тентү үткәреп, аны Казандагы шушы Пеләтән төрмәсенә китереп ыргытучылар бит болар. Икесе дә, теге вакыттагыча, НКВД киемендә. Икесе дә үзләрен тыныч тота. Йөзләрендә берникадәр горурлык та бар кебек. Менә тагын да очраштык, «остазым», безнең капкын шулай инде ул, бер эләксәң, аннан ычкынып китүе бик кыен, дигәндәй карый. Карсакның да йөзе шуны аңлата.

Тикшеренү арасында төрлесе булды. Берсе юха елан урынына кылана. Икенчесе төлкеләнергә ярата. Өченчесе ач бүредәй тота үзен. Әмма берсенә дә баш бирмәде Ибраһимов. Үзен һәрвакыт алардан өстен тотты. Шуны аңлап, ерткыч «мужик»ны җибәрүләрен сизде Галимҗан. Ләкин аның алдында да калтыранып калмады Ибраһимов. «Мужик», чыннан да, котырынган бүре урынына кыланды. Әле утырды, әле каты-кат басып йөреп алды, өстәлне йодрыгы белән төя-төя, әллә нинди кабахәт сүзләр әйтте дә:

—Мин җиңмәгән, подпись куйдырмаган «халык дошманы» юк,—дип женләнде.

Һаман чигенмәде Ибраһимов. Үзен кешеләрчә горур тотарга тырышты:

—Иманым бөек минем. Аны вакларга тырышуыгыз ташны сыгып су чыгарырга маташуыгыз шикелле генә. Җәфа чикмәгез. Бер дә юкка түкмәгез нервларыгызны. Бу хаталарның вакытлы икәнлеген анларсыз бервакыт. Озакламас...

«Мужик» анын сүзен бүлде:

—Мораль укыма, «халык дошманы»! :Кул куй!

—Бу шакшы кәгазь нәкъ менә пычракта аунаган дунгыз баласы шикелле инде, мина калса...

—Димәк, кул куймыйсыз?

—Юк!

«Мужик» ручкасын йөз мәртәбә кулына алып, аны йөз мәртәбә кире куйгандыр инде. Тагын бер тапкыр алды да Галимҗанга сузды аны:

—Мә!

Галимҗан үрелмәде ручкага. Шуннан «мужик», нәрсәгәдер эшләргә кушып, тегеләргә бармагы белән ниндидер билге күрсәтте. Алар икесе ике яктан Ибраһимовның ике беләгеннән килеп тотулары булды, «мужик» ручка очы белән бер-бер артлы Галимҗанның ике күзенә җибәрде. Күзләрдән кан чәчрәп чыкты. «Халык дошманы» егылмаган иде әле. Күзләрдән кан ага. Ә кулын тотып, әлеге кәгазьгә имзасын салдырдылар да яткырып типкәләргә тотындылар аны. Җан биргәнче изеләр дә үлем бүлмәсенә чыгарып ыргыттылар. Шулай җан бирде Ибраһимов.

* * *

Эш беткәч, «уф» дип куйды «мужик», тегеләргә горурлык белән карады: менә шулай кирәк, янәсе; моңа чаклы тикшерүчеләр камыр батырдай кыланган, ә ул берүзе бер кала алырлык каһарманлык күрсәтте.

Аннан кыска гына протокол төзелде. Өчесе дә ана кул куйдылар. Анда Галимҗан Ибраһимовның «халык дошманы» икәнлеген тануы хакында язылган иде.

Бу зур «җиңүне» алар аракы эчеп тантана итте.

* * *

Ул көнне якты дөнья белән хушлашучы бер Галимҗан Ибраһимов кына түгел иде. Авырулар арасыннан алар бишкә җитте. Аларның барысын да башта «үлем бүлмәсе»нә кертеп куйдылар. Аннан, караңгы канат җәйгән мәлдә, ихата уртасына чыгарып куйдылар.

Кыш уртасы булуга карамастан, артык салкын түгел иде. Чөнки мамыктай йомшак карлар ява. Башта ул сирәк-мирәк кенә төште. Аннан куера башлады. Куерып, укмашып, куе караңгылык карынынннан бияләй зурлык карлар ишелде җиргә. Бервакыт мәетләр калын кар юрганы астында калды.

... Таң алдыннан Галимҗан һушына килде. Әлеге газраил белән «дуслыгы ярдәм иттеме? Ил, халык, киләчәк матур хәят өчен анын кирәкле каһарман булуын анлыймы? Аннан мәңге үлмәс Прометей ясамак буламы? Җир йөзендә куерган артык фаҗигый хәлләр аның ачуын кайнатамы? Кешелексезлек атомының Җир шартлатачагына борчыламы? Газраилнен дә вөҗданы бармы? Алып йөрәкле ир-солтаннарны кырырга ашыкмаска Аллаһы Тәгалә үзе кушканмы әллә ана? Шуна алмаганмы Галимҗанның җанын? Хәзер аны, кар астыннан йолкып чыгарып, Прометей урынына берәр диварга сөяп куймакчы буламы? Күк оҗмахына керергә калган бер адымны башта Җир оҗмахында атлатып карарга телиме? Анламассың. Серле бу. Сихерле. Коточкыч. Әкияттәге кебек.

Галимҗан, мәетләрне тезеп яткызган чакта, бер як читкә туры килгән иде. Чыгып бетмәгән җанына йомшак кар һавасы яшәү сулышы өрдеме? Әллә Ходай, фани дөнья өчен һаман кирәклеген анлап, үләннәрне кабат терелтә торган шифалы кар яудырдымы аның өстенә? Ходайның кодрәте зур бит ул! «Бүлмәгә керү белән җанын эри, ничектер табигый матурлык, зәвык, тәмиз хис кыласың»,—дип язган иде Галимҗан бервакыт. Ходай

бүген аның өстенә йомшак кар яудырган. Ул хәзер рәхәт хис кылып ята. Ул—ожмахта! Ожмахта! Рәхәт ана. Уй да юк. Кайгы да. Хәсрәт тә.

Изге күңелле кеше үләр алдыннан шундый рәхәт мизгел кичерә. Аңа Ходай Тәгалә ожмахтагы хозурлыкны күрсәтә.

Тән авыртуын сизми. Күзләре юклыкны да белми. Ә йомшак кар астында изелеп ятканлыгын чамалый. Күтәрелергә уйлый. Мәгәр гәүдә кузгалмый. Аның өстендә, әйтерсең, йомшак кар түгел, албасты сузылып ята. Шуннан ул үзенең күп албастыларны җиңеп яшәгәнлеген хәтеренә төшерде. Бу албастыны да тибеп очырырга кирәк. Аякларын күтәрергә тырышты. Күтәрү түгел, кыймылдатып та булмый. Кулларына өметләнде. Алары да албасты урынына киреләнәләр. Шулай да, үтенеп хәл сорагач, Ходай ярдәм итте. Куллар, акрынлап, хәрәкәткә килде.

Йомшак карны авызына алырлык та көч тапты ул. Салкын кар башта теш төбендә торды. Аннан, эреп, эчкә китте. Аңа рәхәт иде хәзер.

Кычкырырга уйлады. Әмма тавыш чыкмый. Ниндидер гырылдык кына килә тамак төбенә. Үлмәгәнен белгәч, кемнеңдер коткаруына өметләнә ул.

Чү! Тавыш. Кемнәрдер килә. Ул мәрхәмәтлелек көтте. Оһ, «мәрхәмәтле» берәү ни беләндер аның башына тондырды.

1938 ел. 21 гыйнвар.

Аларны төяп алып киттеләр. Кайда каберләре? Аны бер Ходай үзе генә белә. Корыч ихтыярлы, Прометей йөрәкле Галимҗан Ибраһимов һаман үлмәгән булгандыр, бәлки. Тереләй күмелгәндер...

* * *

Кичкә таба буран купты. Көчле, давыллы җил котыра-шаша, дөньяның астын-өскә китермәк була. Казан каласында Нух заманындагыдай шашкан гарасат. Буран җылый, чиный, үкерә. Хәдичә ханым, кар-буран пәрдәсен ертa-ерта, Пелетән төрмәсенә таба атлый...

## Соңгы сүз урынына

Кеше һәм йолдыз! Аларны чагыштырып карау җиңел түгел. Авырлыгы да юк кебек. Чөнки кеше—йолдызның дусты. Караңгы төннәрдә ул адашканнарга юл күрсәтә. Аның атамасы да шуңа бәйләнгән бит. Юл төз дип йөрткәннәр. Димәк, йолдыз төз юл күрсәтүче. Кыскача болай була: юл төз (юлдөз) йолдыз. Һәркемнең үз йолдызы бар, дип сөйләшәбез. Соңгы вакытта моңа аеруча игътибар итела башлады. Сүнүче йолдызлар бар. Әмма нурлары галәмнең башка җисемнәренә, шул исәптән Җиргә, килеп торалар.

Җиргә куркыныч янаганнары да юк түгел. Соңгы вакытта Эта Киль йолдызы котырына. Аның авырлыгы Кояшныкыннан 100 тапкырга артыграк. Ә инде балкышы Кояшныкыннан 4 миллион тапкырга артып киткән. Йолдызның гамма-нурланышы озон катламын ертса, Җиргә зыян килә.

Романда төрле шәүләләр бәрелешенең егерменче гасыр кешеләренә зыян китерүе турында сүз йөртелгән иде. Эта Кильнең шашынган гамма-нурланышы шул шәүләләр белән аралашып китмәсме?

Һәркем, күчерелмә мәгънәдә яки шагыйрьләр теле белән әйтсәк, үзе бер йолдыз. Тик аларның яктылыгы бертигез түгел: берәүнеке—мул, икенченеке—уртача, өченченеке—сүренке, дүртенченеке... Хәер, санап беткесез.

Күк җисемнәренең серен ачыклау бик кыен. Шуның кебек, мул нурлы шәхес-йолдыз Галимҗан Ибраһимов ишеләрнең дә эчке илаһи дөньясы зур дикъкатьлелек сорый. Галимҗан Ибраһимов—катлаулы шәхес. Корыч ихтыярлы кеше. Вакыт-вакыт ул муенына берьюлы унар төрле эш камыты киде. Унлап эш арбасы тартты. Әйбәт тартты. Тырышып. Чын ирләрчә. Сыкранмый. Октябрь инкыйлабыннан соң Ленин, Сталин белән эшләү, Колчак тылында йөрү, Академик үзәк рәисе булу, һәр фәннең дилбегәсен оста тота белү, ун ел буе Кырымда яшәү, Киев төрмәсендә, Казанның Пелетән төрмәсендә утыру.

...Һәр вакыйга аерым-аерым роман язарлык. Аларның һәммәсен бер чылбыр яки сюжет тирәсенә туплау—ифрат авыр хәл. Бу хакта мин трилогиянең икенче томында («Күкнең җиденче катында») әйткән идем. Шуны янә кабатлыйм. «Нигә менә шул хакта да язмаган» диючеләр булыр. Әйберләрне артык дыңгычлап салсаң, капчык ертыла. Галимҗан Ибраһимов кичергән вакыйгаларның барысын да көчләп тутырсаң, әсәр, тупас булса да әйтик, күп ашаган кешенең корсагыдай бүлтәеп торачак.

Галимҗан Ибраһимов турында трилогия язуымны белгәч, бигрәк тә беренче, икенче томнар басылып чыккач, төрле тарафлардан миңа хатлар ташкыны агылды. Әдипнең туган авылы Солтанморатта яшәүче элекке укытучы Фәүзия ханым Рәхмәтуллина ун дәфтәр язып җибәргән. Рәхмәт аңа! Ходай, бөтен кайгы-хәсрәттән аралап, бәхетле һәм рәхәт яшәтсен!

Бер үк вакыйга турында төрле кеше төрлечә яза. Кайсын сайларга? Кайсысы дөрес? Автор баш вата, борчыла, чынбарлыкны эзләргә керешә, үзенә кирәген таба. Бу очракта да: «Алай түгел, болай ул»,—диючеләр булмый калмас. Ризасызлык белдерүчеләр гафу итсен мине!

Кыскасы, минем трилогия язу бөтен җәмәгатьчелек эшенә әверелде шикелле. Аның шулай булуы табигый хәл. Теләсә кем түгел бит ул. Галимҗан Ибраһимов! Җәмәгатьчелекнең рухи ярдәмен нык тоеп яздым мин. Зур яшьтә бу авыр эшне җиңеп чыгарга шул да ярдәм иткәндер, бәлки.

Рәхмәт әйтәсе кешеләрем бихисап. Аларны санап чыгу мөмкин түгел. Бик күпләр. Шулай да кайберләрен искә алмый булмый.

Сүзне Татарстан фәннәр академиясе президенты академик Мансур Хәсәновтан башлыйсы килә. Галимҗан Ибраһимов 1955 елда аклана. Монда Гомәр Бәширов белән Әмирхан Еники зур эшчәнлек күрсәтә. «1955 елның 29 октябрендә Еники иптәшкә Мәскәүдән түбәндәге документ килә:

| | |
|---|---|
| *Совет социалистик* | *29 октябрь, 1955* |
| *республикалар союзы* | *N13 ОК—8122-55* |
| *Прокуратурасы* | *Казан шәһ. Достоевский урамы, 05-85, кв. 1.* |
| *Москва, центр, 15-а* | *Ә. Еникеевка.* |

Сезнең Г. Ибраһимовны гаепләү буенча эшне яңадан тикшерү турында КПСС Үзәк Комитетына адресланган гаризагыз тикшерелде. РСФСР УПКның 4 нче статьясының 5 нче пункты буенча, ягъни Ибраһимовның эшләрендә җинаять составы булмау сәбәпле, 1955 ел 24 сентябрендә эш туктатылды.

Махсус эшләр бүлегенең прокуроры, юстиция Советнигы И. Земцов».

Мансур Хәсәнов Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты турында докторлык диссертациясе язып яклады. Шундый ук фәнни дәрәҗә трилогия-эпопея авторына Галимҗан Ибраһимовның тел-өслүб үзенчәлекләрен тикшергән һәм күп хезмәтләр бастырган өчен бирелде. Галимҗан Ибраһимовның сигез томлыгы басылып чыкты. Кыскасы, зур йолдызлар үлми. Зур йолдызлар сүнми. Сүнсә дә, аларның яктылыгы, нуры галәмнең башка җисемнәренә барып тора. Тукай—егерменче гасыр поэзиясе пәйгамбәре. Г. Ибраһимов—егерменче гасыр прозасының пәйгамбәре. Пәйгамбәрләр үлми. Алар—мәңгелек!

Инде рәхмәт әйтү мәсьәләсе. Алар бик күп, мөбарәк тәсбих төймәләре генә җитәрлек түгел. Санап чыгу бик кыен. Иң зур рәхмәтем трилогия чыгаруны, исәп-хисап эшләрендә яки акча мәсьәләсен үз кулына алган Галимҗан Ибраһимов туганы Марат Сәетовка—«МИГ-С җәмгыяте» директоры Мәҗит улына һәм аның әнисе укытучы Мәүсилә ханымга, башка туган-тумача, кардәш-ыруларына чиксез рәхмәтлемен. Кыскасы, трилогия язган матур, эзлекле, уйландыргыч киңәшләре белән ярдәм иткән бөтен Солтанморат халкына, башкаларга, бик күпләргә ихлас рәхмәтемне белдерәм!

АВТОР



## Эльмира Шәрифуллина

# Каюм коесы

ПОЭМА

I

*«... Шөкер, туган нигезендә бүгенге көнгә кадәр Каюм Насыйриның коесы сакланган...*

Якташы, мөгаллимә Гөлсинә Гайфуллина.

*«Моннан соңгылар, әлбәттә, ... файдаланырлар.»*

Каюм Насыйри.

1

Гасырларны кичеп исән калган,
Исән калган Каюм коесы.
Күпме чишмә—юлын югалтканда,
Адашканда—иң мул сулысы,
Насыйрилар нәсел агачының
Бер тылсымы булып, ядкаре,
Нуры булып изге гамәлләрнең,
Бер әдәбе булып, әхлагы—
Исән калган кое. Һәм бүген дә
Тибеп тора көчле чишмәсе.
Ничә килеп, күпме мәртәбәләр
Сындырганнар булыр сиртмәсен...

Кискән саен үсеп чыккан кебек,
Тылсым көче белән кабаттан,
Изгелеккә тугры якташлары

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА—*шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Яңгыр җиле», «Гөлләр елы», «Таң чыгы» һ.б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Сиртмә-чыгырларын яңарткан.
Яңарткан да сипләп, ипләп кенә
Су алырга йөргән коедан.
Терек суы,
Гүя гыйлем суы
Агып чыга Шырдан буеннан.

2

Белем алу—кое казу, диләр,
Инә белән казу—коены...
Гыйлем сөйгән Каюм бабабызның
Таза булган нәсел-буыны.

Ничә гасыр яшәр гомер биреп,
Казыган ул үзенең коесын:
Якташлары, авыл кешеләре
Шифалы су белән туенсын!

Коены да казый белеп казу,
Урынын табып казу кирәктер.
Гыйлем коесына корал—инә,
Су коесы өчен—көрәктер.

Урынын белеп, әйе, казу кирәк,
Кадере булсын дисәң коеның.
Сүз сөйләсәң, белеп сөйләү кирәк,
Дөреслеген тоеп уеңның.

Ләгънәт укып искә алмасыннар
Коесының суы тәмсез, дип.
Иҗатында, әйткән фикерендә
Сүзе—тозсыз, уе гамьсез, дип.

Рухи кое һәм гамәли кое!
Зиһене дә җиткән, көче дә.
Шуңа күрә Шырдан төбәгенең
Якты булгандыр, дим, киче дә!

II

*«Татарларга урыс телен белү кырык беренче фарыз.»*

Габдерәхим Утыз Имәни.

*«Балалар укыта башлап, капка өстенә вывеска куйгач, частька барып әйткәннәр... Хәтта бәгъзе адәмнәр Казан шәһәреннән кудырырга йөрделәр.»*

Каюм Насыйри.

1

Әкияттә әйтелмәгән сүзләр
Аның йөрәгенә тупланганды\u0440.
Шуның өчен дә ул кое казу
Ниятенә, бәлки, тукталгандыр.

Килер көнгә тоташтырыр өчен
Бүгенгесен,
Үткән заманнарны.

Яхшылыкны өстен итү өчен,
Фаш кылырга теләп яманнарны
Язган Каюм. Каршы чыгар аңа
Бәндәләрнең фәкать абынганы...
Балаларны тәрәккыйга илтү—
Йөрәгендә дөрләп кабынганы.

Әмма шушы изге башлангычның
Тәмамланган ахыры шактый моңсу.
Мөгаллимлек эшен ташлатканнар,
Татарга, дип, урыс теле ничу...

Укытырга урын таба алмый
Бәргәләнеп йөргәч Казанында,
«Куарга», дип, бәгъзе адәмнәрне
Хөкем чыгаргачтын азагында,
Тулысынча фәнгә кереп чумган,
Язучылык булган бер шөгыле.
Татарымны аңлы, тәрбияле
Итү һаман барлык уй-фигыле.

Зарурлыгын телләр өйрәнүнең
Аңлатмакчы булып, кылып ният—
Әкиятләр хәтта әйтмәгәнне
Сүз башлаган—әйтергә дип, теләп.

2

Коега төкермәгез!
Ризыктан олы калып,
Туенып сикермәгез.

Туенып сикермәгез.
Ширбәт сораган чагында
Ачуташ эчермәгез.
Ачуташ эчермәгез:
Уеннан уймак чыгарып,
Кайгылар китермәгез.

Кайгылар китермәгез.
Һәр милләтнең үз тамыры—
Телемне үтермәгез!

Телемне үтермәгез.
Минутлык хискә алданып,
Шатлыктан исермәгез...

Шатлыктан исермәгез.
Соңыннан суын эчәрсез—
Коега төкермәгез!

III

*«... Гарәптән татарга әйләнүдә—Насыйри бездә беренче кискен революционер булды.»*

Галимҗан Ибраһимов.

*«... Без—татарлар. Телебез—татар теле!...»*

Каюм Насыйри.

1

«Без татарлар, телебез—татар теле,
Бүтән телдән бер дә ким түгел!»—
Кискен булган галим.—Кайчак, юкса
Күзледә дә сукыр ул күңел.

«Яратмыйлар мине, милләтемне—
Татар милләте, дип атасам...»
(Мыскыл итеп, сүгеп җибәргәннәр
Бер-бер җирдә чыгыш ясаса.)

«Урам теле, имеш, ломовойлар—
Әдәбият, фәнгә сәләтсез...»—
Шундыйларга каршы чыккан өчен
Насыйрига ярлык—«әдәпсез».

Әдәп саклап, ай-һай, күп яшәдек,
Телдән чак-чак колак какмадык.
Беркемнән дә гаеп эзләмәдек,
Беркемгә дә яла якмадык.

Хәтер калдырудан курыктыкмы,
Куштанлану булды микән соң?
Миңгерәтер өчен татар башын
Акыл саттылармы төштән соң?..

Ни булса да булган, телгә каршы
Әшәке бер көрәш барганда
Исән калган телем—Каюм кебек
Фидаилар сөрән салганга.
Исән калган.
«Телебез—татар теле,
Мөстәкыйль һәм төзек, камил тел!»
И без, татар, үзебез утырганга,
Утырткanga балта чаптык гел...

2

... Туган тел бер генә була,
Ул минем бөек телем!
Үзем белән бергә шыткан
Иң асыл, шиңмәс гөлем.

Минем өчен шиңдермичә
Саклаган Каюмнары.
Махсус кое казыгандыр
Сугарырга ул аны!..

IV

*«Берәүнең дә.. бу хәтле күп җырлар һәм мәкальләр тапшырганы юк иде. Насыйров әфәнде тарафыннан тапшырылган бу материаллар аның халкының искиткеч акыллы икәнен исбат итәләр...»*

Николай Катанов.

*«Татар теленә хезмәтче булыйм дип, утыз биш ел уздырдым... Никадәр тырышсам, шул кадәр җәфа чиктем...»*

Каюм Насыйри.

1

Тамырлары—Болгар дәверендә,
Укымышлы ата баласы...
Габделкаюм Әл Болгари, диеп,
Санап киткән җиде бабасын.

Нәселен дә,
Тарихын да белгән,
Мирас җыйган эзләп, бөртекләп.
Туган ягы Зөя өязенең
Шәҗәрәсен сызган җентекләп.

Гореф-гадәт, йола-кануннарның
Туган төбәктәге төрләрен
Теркәп куйган, туар яшь буыннар
Төшенерлек итеп серләрен.

«Кырык вәзир», «Әбугалисина»—
Зур кыйммәткә ия эшләрне
Тәрҗемәләп милләтенә биргән,
Шәрехләгән кирәк төшләрен.

Иҗатының нинди тармагы юк:
Җәгърәфия дисәң... тәрбия.[1]
Татарның ул—Ломоносовы, дип,
Чит милләтләр хәтта баш ия!

Матбугаты, һич хәбәре булмый
Яшәгән һәм торган заманда,
Чирек гасыр өстәл календаре
Чыгаручы—Каюм һаман да!

Туган телем—«Татар телебезнең
Аңлатмалы сүзлек» китабын,
Иң беренче булып кем төзегән?—
Таудай хезмәт ләса ул тагын

... Санап кына бетерерлек түгел
Каюм бабабызның хезмәте.
Без белгәне—диңгездән бер тамчы,
Бер тамчының меңдер хикмәте!

2

Әй, минем газиз халкым син,
Әй, минем моңлы илем!
Сине зурлыйм, олылыйм, дип,
Яшәлде һәрбер көнем.

Әй, минем газиз милләтем,
Әй, минем шанлы җирем.
Батырлыгыңны сөйлим дип,
Шул җиргә тамды тирем.

Әй, минем газиз якларым,
Сыйлы сагышлы түрем.
Даһилыгыңны дауладым,
Мәһәргә—ләхет-гүрем.

Әй, минем газиз кавемем—
Югары Шырдан буе.
Һәйкәл булсын эшләремә,—
Калдырам сезгә кое!

---

[1] «Китап әт-тәрбия» күздә тотыла. *Автор.*

## V

*«... Аллаһы Тәгалә бик күп кешеләрне пәйгамбәр кылмышдыр. Ул пәйгамбәрләр һәркаюсы адәмнәрдер... ул пәйгамбәрләр... кешеләрне Хак дингә вә изге гамәлләргә өндәмешләрдер».*

Гыйбадәт Исламия.

*«Ят хәбәр юк. Ләкин халык бик ябык. Зарланмаган кеше юк.»*

Каюм Насыйри.

### 1

**Сабыйларны сөендермәк эштән**
**Сәгадәтле, садә, жанына**
**Ләззәт илә ял, ямь алгандыр ул,**
**Дәрман йөгергәндер канына.**

**Авылына кайтып, сабан туе**
**Ясаган бит бала-чагага.**
**Көч сынаткан, аркан тартыштырган,**
**Алып чыгып иркен далага.**

**Тезеп бастырган да яшь буенча**
**Аннан йөгерергә боерган.**
**Юмарт бабалары тирәсенә**
**Бала-чага ел да җыелган.**

**Алдан килгәннәргә бүләк биргән,**
**Арттагы да нәүмиз калмаган.**
**Кызыл билле тәмле прәникне**
**Бала калмагандыр алмаган.**

**Бәгъзеләргә, сәер тоелгандыр,**
**Көлке тоелгандыр кылганы.**
**Сабан туе ясап, балаларга,**
**Өләшкән ич бөтен булганын.**

**Кубыз чирткән, курай уйнаган ул,**
**Еллар ябык диеп тормаган.**
**Сабыйларның күңел кылларына**
**Йомгак-йомгак гыйлем чорнаган.**

**Балаларның шат авазы сеңгән**
**Шырдан буендагы аланга.**
**Тирбәткән ул барча кыз-угылны**
**«Әт-тәрбия» дигән таганда.**

### 2

**Һөнәрле бул, углан,**
**Һөнәр үзе—**
**Чикләнмәгән дәүләт, дигәндер.**
**Нәфесеңне тыю, сабыр итү,**
**Шөкер кылу кыйммәт, дигәндер.**

**Тән пакьлеге, җан сафлыгы өчен**
**Хәрәкәт һәм гакыл кирәктер.**
**Башы—уйсыз, җаны—сыйсыз бәндә**
**Кеше түгел, шәүлә, өрәктер...**

Олылардан узып, күкрәк сугып,
Бәхәсләшмә җиңмәк дәрт белән.
Кунак җыйсаң—ашлы табак китер,
Туйдырма сүз, коры гәп белән.

Үкенә бел ялгышларың өчен,
Усал белән тапма, бүлешмә.
Дус-туганны бик еш борчыма да,
Онытырлык сирәк күрешмә.

... Әй угланым,
Күп нәсыйхәт бирдем,
Әйткәнемне сеңдер буеңа.
Сәламәт уй, дөрес гамәл кылыр
Кеше булып өлгер туеңа!

3

Балаларның балалыгы йогып,
Сабыйлыгы йогып, сафлыгы—
Үз сыеңда, үз көчеңдә үткән
Юмарт бабабызның картлыгы.

Телдән телгә йөргән хатирәләр
Халык күңелендә саклана.
Милләтеңә ихлас хезмәт итү—
Гасырларны үтеп хаклана.

Хәер-фатихалы сүзкәйләрнең
Ел тузаны җуймый егәрен.
Дәверләрне кире кайтардык та
Үзебезгә алдык кирәген.

Ерагайган саен якыная
Насыйриның олуг кыйммәте.
Булгандыр ул, бәлки, бер варисы,
Соңгы пәйгамбәрнең өммәте.

Мәгърифәтче Каюм коесыннан
Тустаганлап алам уй-фикер.
Иманлы сүз кайтты тәрбиягә,
«Әт тәрбия» кайтты, мең шөкер!

VI

*«Әллә ниләр күрер иде халык*
*Чорлар шундый кара чагында.*
*Кулларыннан алып яктылыкка*
*Сөйрәмәсә «сукыр» Каюмнар.»*

Зөлфәт.

*«Урыс укучысын татар хикәяләре,*
*– шуларга бәйләнештә туган ырымнары,*
*– гореф-гадәтләре белән таныштырырга*
*телим...»*

Каюм Насыйри.

1

Кое, кое,
Серле, сихри кое,
Чишмәсенә бер күз салыгыз.
Кое төпләренә җиткәч, Каюм
Хәбәр биргән: «Тартып алыгыз!»

Сиртмә бавын төшерегез, әйдә,
Байлыгымны сезгә озатам.
Якты дөнья күрсен хезмәтләрем—
Кылган эшем белән мин кайтам...

... Ишетмәгән гүя адәми зат
Кое эченнән килгән аһәңне.

Сиртмә бавын кисеп ыргытканнар—
Күтәрмичә тор, дип, бәһаңне...

Киссәләр дә, какса-типсәләр дә
Чигенмәгән Каюм, нык торган.
Туган телем яшәп калсын өчен
Яратылган гали зат булган!

2

Тормыш серле... Галим—гали затлар
Күз нурларын түгә, тир түгә.
Зыялыга күп чак зиндан тия,
Талантлыга бик тиз көн сүнә.

Чын талантлар, никтер, сәер була,
Артык нечкә була күңеле.
Гайбәт өчен һәрчак җирлек туа.
Эше, сүзе кала күмелеп.

Бүген белән бетми әмма тормыш,
Җир әйләнә, дөнья—куласа.
Күп нәрсәне аңлый алмас идек,
Көчле җаннар җиргә тумаса.

Нәкъ шундыйлар милләт дәрәҗәсен,
Милләт данын өскә күтәргән.
Татар халкы эшчән, мәгърифәтле,
Зур халык дип фикер үткәргән.

Талантлар күп татар милләтендә,
Данга төреп өскә чөярлек.
Тик бер нәрсә юлны яба безнең:
Җитми, кайчак дуслык, бердәмлек...

Кара еллар аркылыга сөргән,
Буйга ярган халык хәтерен.
Югалтканнар,
Махсус югалтканнар
Бөекләрнең эзен... каберен.

Югалтканнар: шулай кирәк булган,
Кулай булган шулай кемгәдер.
Татардагы газап—тоташ сыктау,
Милләт «базары»нда кимгәдер...

Түбәнсетер өчен «гаеп»ләр күп:
Сукыр әнә Насыйр Каюмы.
Нинди гыйлем, имеш, бирә алсын,
Безнең кебек туны каюлы...

Каян килеп даһи шәхес бирсен
Кеп-кечкенә Шырдан авылы?..
Һәрчак шулай каз кадәрле булып,
Күренә тик күрше тавыгы.

3

Пәйгамбәрлек йөген тартыр шәхесләре
Туа торган татар халкының.

Кадер күрми яшәп үлә торган—
«Төштән соң» ич татар акылы...

Үтертелгән Әҗәл-киллер белән,
Үз милләте башын ашаган...
Бушбугазга дөнья иркенәйгән,
Талантсызга урын бушаган.

Шулай булган элек, хәзер шулай,
Тагын нинди газап татырмын?..
Тик, кабаттан гомер бирсә Ходай,
Татар булып Җиргә кайтырмын!

## VII

*«К. Насыйриның тормыш авырлыгын гәүдәләндергән, акыл һәм әхлак темасына багышланган кайбер хикәяләре генә укучыга тәкъдим ителде әле. Бу исә, диңгездән бер тамчы...»*

Якташы, галимә Резеда Ганиева.

*«Ни өчен башка йорт халкына ялынабыз? Ни өчен башка йорттан килгән даруларга мохтаҗ булабыз? Кайчан ки, үз җиребездә дәвага яраклы үсемлекләрнең һәммәсе бардыр.»*

Каюм Насыйри.

### 1

Әллә инде Рәсәй кичерәйгән,
Әллә биегәйгән Ширдан тавы?
Колакларда изге дастан кебек,
Кое чишмәсенең сулкылдавы.

Кайтавазлар сеңгән тирәнлекнең
Саф суына серләр манчылган күк.
Чирткән Каюм кое ниргәсенә—
Хакыйкатькә юллар ачылган күк.

Әкиятләр хәтта әйтмәгәнне
Әйткән галим туар баласына.
Кое төпләреннән күтәрелеп
Чыгып баскан белем даласына.

Җиде юл чатында җитмеш һөнәр—
Әле уңга, әле сулга илтер.
Каюм бабабызның салган эзе
Мәгърифәткә—фәкать нурга илтер,

Иң якты юл гыйлем тарафына—
Су эчкәндәй белем эчәрсең, ди.
Мәгънәсен тойсаң хак фикернең
Тәрбияле булып үсәрсең, ди.

Бер юл китәр урман арасына:
Балта тотсаң, оста итәрмен, ди.
Кубыз-курай ясау серләренә
Өйрәтмәккә сине көтәрмен, ди.

Бер юл китәр тугай-болыннарга
Үләннәрнең серен чишәрмен, ди.
Мине җыеп, белеп куллансагыз,
Шифа булып сезгә күчәрмен, ди.

Тик йөрмәгез кеше тупсасында,
Хәер эстәү—матур шөгыль түгел.
Туган Җирен сөеп сихәтләнсен,
Һәм хушлану алсын һәрбер күңел!

2

Алдап булмый икән Табигатьне,
Үзенекен итә Җир-Җиһан.
Без генә ул, ялган белән бизәп,
Кызыл сүздән көттек җыр-илһам.

Ә Табигать гадел! Юк кодасы,
Кодагые, килен-кияве...
Даһиларны үзе сайлап ала,
Һәм бәяли биреп тиярен.
Гыйбрәт алсын, гыйбадәтен кылсын,
Шифалы су белән туенсын,—
Диеп гүя, ике гасыр буе
Яшәтә ул Каюм коесын.

Яшәтә ул, җыры үлмәсен дип,
Җире иңмәсен, дип, татарның.
Исбатлый күк Каюмнары белән
Бөеклеген илнең, Ватанның!

Ураү юллар, гасырга тиң еллар
Кайтавазлар булып эндәшә.
Инә белән казылса тик, кое—
Каюм коесына тиңләшә.

... Су бирегез, кирәк бер йотым су...
Кайчагында җитә бер тамчы.
И Туган җир! Каюм коесында
Шул бер тамчы саф су булсамчы!

*1997*

Солтан Шәмси

# НИЗАГЛЫ ЙОРТТА

АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕНЕҢ
ТАРКАЛУ ЧОРЫННАН СӘХИФӘЛӘР

## Заман кемнең заманы?

### Мамай мирза үлеме

Куликово сугышыннан соң Туктамыш ханның Иделнең унъяк ярына чыгуы, анда сугыш хәрәкәтләре башлап җибәрүе аркасында Мамай мирза Мәскәүгә икенче кат яу белән бара алмый кала. Ә Туктамыш хан Алтын Урдада үз хакимиятен ныгытырга, таркау яткан олысларны бер байрак астына тупларга керешә. Хаҗитарханны, Төньяк Кавказны үз кулына төшерә. Татар мәмләкәтенә тәмам хуҗа булыр өчен аңа үзәк хөкүмәткә каршы торучы Мамай мирзаны гына буйсындырасы кала.

Кайбер тарихчылар Туктамыш хан белән Мамай мирза арасындагы хәлиткеч бәрелеш, тарих фәнендә кабул ителгәнчә, Калка елгасында түгел, ә Бурсыклы (соңрак урыслар аны Ворскла дип йөртә башлыйлар) суы кушылдыгы Колмак (Кальченка) янында булган дигән фикер әйтәләр. Бәлки шулайдыр да, тик моның укучы өчен әллә ни әһәмияте юк. Аның өчен вакыйгалар чылбырының өзелмичә дәвам итүе, аның эчке логикасы-психологиясе саклануы мөһимрәктер дип уйлыйм.

Бу сугышта Мамай мирза җиңелергә дучар була. Урыс елъязмасында, мәсәлән, Мамай мирзадан Туктамыш хан ягына күчә-авыша башлаган мирзаларның болайрак фикер йөртүе теркәлеп калган: «Мамай хөкемендә яшәүдән безгә файда юк,—диләр алар,—кая барсак та дошманнарыбыз тарафыннан кыйналабыз. Әйдәгез, Туктамыш ягына чыгыйк, анда тагын күз күрер...» Шулай байтак мирзалар, көчленеке замана дигәнне истә тотып, Туктамыш хан хозурына килеп баш оралар. Билгеле, иелгән башны кылыч кисми. Җитмәсә, Туктамыш ханның да әле ныгып җитәсе бар. Шуңа күрә ул моңа сөенә генә.

Шулай итеп, Кыпчак даласын күпме заман үз кулында тоткан гайрәтле Мамай мирза бик авыр хәлгә төшә. Әлбәттә, янында иң тугры кешеләре генә кала. Ә тугрылар алар һәр заманда санаулы.

Туктамыш хан исә үзенең хәтәр дошманын тизрәк юк итү өчен барысын да эшли, чөнки исән калган очракта гайярь мирзаның кабат тарафдарлар табуы, баш калкытуы, бихисап мәшәкатьләр китереп чыгаруы бар. Шуңа күрә һаман ишәя, көч туплый барган хан гаскәре Мамай

---

Дәвамы. Башы 1, 2 саннарда.

мирзаны эзәрлекләүдән туктамый. Ахыр чиктә, Мамай мирза Кырымга качарга мәҗбүр була, андагы яр буе шәһәрләренә—дингез сәүдәсе белән көн күрүче итальян-җәнүизләргә килеп сыена. Ул дингез буендагы Кәфә (Феодосия) каласына килеп урнаша.

Әмма башта якты чырай күрсәткән сыман кыланган җәнүизләргә тәхеткә чыккан Туктамыш ханнан качып йөрүче гыйсьянчы Мамай мирзаның бөтенләй кирәге булмый. Беренчедән, бу хәл аларның хан белән арасын гына бозачак, сәүдә эшләренә китереп сугачак, икенчедән, алар форсаттан файдаланып, Мамай мирзага карата саклап килгән үчләрен дә исләренә төшерәләр: моннан унбиш еллар элек алар зур файда күреп яткан унсигез авылны кулларыннан тартып алучы шушы Мамай мирза түгел идеме соң? Өченчедән, Мамай мирза бит Кәфә каласына буш кул белән әйләнеп кайтмый—гомер буе җыйган мал-мөлкәте, хәзинәсе үзе белән. Мирза Кыпчак даласында кылыч айкаса да, Кырым бит аңа гомер буе ныклы тыл булып хезмәт итте.

Мамай мирзаның кем кулыннан һәлак булуы турында тарихчылар арасында төрле фикер яши. Берәүләр, байлыгына кызыгып, аны җәнүизләр үтергән дип язса, икенчеләре—Туктамыш ханга ярарга тырышып, җәнүизләр аны хан кулына үзләре тапшырган дигән фикер әйтәләр. Безнең өчен шунысы ачык: җәнүизләр аны үзләре үтерсә дә, ханга тотып бирсә дә—отышлы хәлдә калалар, хан алдында ышаныч яулыйлар. Ә монысы алар өчен иң мөһиме, чөнки яр буендагы калаларга таянып сәүдә итәселәре бар.

Шушы вакыйгадан соң Туктамыш хан да җәнүизләргә бурычлы булып калмый—алардан элек тартып алынган унсигез авылны кире кайтара. Җәнүизләр исә ханның дошманнарын да, киләчәктә аннан качып китүчеләрне дә кабул итмәскә, ханга тугрылык сакларга сүз бирәләр. Мамай мирза юк ителгәннән соң тормыш элекке эзенә төшә: хан Кәфә каласында салымнар җыючы, аның исеменнән хөкемнәр чыгаручы калгаен утырта да китеп бара.

## Туктамыш хан олысларны туплый

Хәтәр көндәше Мамай мирзаны тарих мәйданыннан алып ташлагач, Туктамыш хан алдына «бөек болгак» елларында мөстәкыйль яшәргә күнегеп өлгергән олысларны бер йодрыкка туплау зарурияты килеп баса. Сарай олысын, Хаҗитарханны, Төньяк Кавказ белән Кырымны буйсындырганнан соң ул урыс кенәзлекләреннән Рязань белән Нижний Новгородны да үз биләмәләренә китереп куша, чөнки Куликово сугышы алдыннан берләшкән кенәзлекләр бу вакытта инде кабат таралган була. Әлбәттә, тәхеткә чыккан хан Болгар олысын да читтә калдырмый, ул да Туктамыш хан кул астына керә. Аннан чират Мәскәү кенәзлегенә житә.

Тәкәбберләнеп киткән Мәскәүне тез чүктермичә торып Алтын Урдада тулы хуҗа була алмаячагын, Дмитрий Донскойның тагын көчәеп китәчәген, үз тирәсенә башка кенәзлекләрне туплый башлаячагын Туктамыш хан бик әйбәт аңлаган булса кирәк.

1381 елда Туктамыш хан Мәскәүнең олуг кенәзенә илчеләр җибәрә дә аның, элекке гадәт буенча, Сарайга килеп баш оруын, кабат үз кул астына керүен таләп итә. Әлбәттә, Куликово сугышы «каһарманы» моңа риза булмый, зур тәкәбберлек күрсәтеп, ханның таләбен кире кага.

Яңа гына Сарай тәхетенә чыккан Туктамыш хан моңа ничек җавап бирергә тиеш? Сүзен сүз итмәгәч, ул нинди хан булсын. Үз әмирләре, бәкләре, гаскәр башлыклары ни уйлар? Алар каршында үзенең йомшаклыгын күрсәтергә аның хакы бармы? Әллә Мәскәү кенәзе Дмитрий үзен аның белән, тамырларында Чыңгыз каны уйнаган хөкемдар белән тиң куярга уйлаганмы? Мамайны куып җибәрдем дип, ул әллә Бату, Үзбәкләрдән калган биек тәхеттән йөз чөермәкчеме? Әллә ясак түләмичә үзбашка яшәргә җыенамы?

Бездә гомер-гомергә шәхесләрнең тарихи вакыйгаларда тоткан роленә тиешле бәя бирелмичә килде. **Вакыйгалар күп очракта сәяси һәм икътисади факторлар белән аңлатылды. Ә бит тарихны беренче чиратта шәхесләр ясый.**

Аларның тормышка карашы, симпатиясе-антипатиясе, холкы-фигыле, шәхси сыйфатлары конкрет вакыйганы теге яки бу юнәлешкә бора да җибәрә.

Без яна гына тәхеткә чыккан, зур хыяллар белән Алтын Урданың олысларын үз байрагы астына тупларга керешкән Туктамыш ханны аңларга тырышып карыйк. Сарай ханы буларак, ул бит үзен Чыңгызлардан башланган, аның вафатыннан соң узган гасыр ярым вакыт эчендә зур дәүләтчелек традицияләре туплаган, даны-шөһрәте бөтен дөньяга таралган зур мәмләкәтнең законлы ханы итеп тоя. Шул сәбәпле үзе турында да, идарә иткән дәүләте турында да бик югары фикердә тора. Икенче төрле итеп әйткәндә, бу вакытта Туктамыш хан үзен ана мирас итеп калдырылган бөек татар империясенең законлы ханы буларак хис итә. Шулай була торып, мәмләкәтнең бер олысында кенәз булып утырган Дмитрий атлы колының аңа каршы дәшәргә маташуын ул ничек кичерә алсын да, моны ничек күрмәмешкә салынсын ди!

Шулай итеп, Мәскәү кенәзе үз хәлен үзе белмичә өстенә татар явы китерә. Юкса бит элеккечә ясак түләп тору һәм яуны булдырмыйча калу да мөмкин иде. Юк шул, кайчакта адәмне минминлек белән тәкәбберлек харап итә дә куя.

Туктамыш хан Мәскәү явын Болгар олысына бераз гаскәр җибәрүдән башлый. Ул иң элек анда сату иткән урыс сәүдәгәрләрен җыеп алырга, тоткарларга боера, чөнки тегеләрнең ни ишетсәләр шуны Мәскәүгә ташып торуларын, шымчылык белән шөгыльләнүләрен яхшы белә. Кенәз Дмитрий татар явы килүне соңрак белсә—һәр яктан да отышлы булачак.

Сәүдә әһелләрен кулга төшергәч, хан үзе дә Иделне кичә, зур гаскәр белән Мәскәүгә юнәлә. Әмма күпме генә сер сакларга тырышмасыннар, хәбәр тиз арада кенәз Дмитрийга барып ирешә. Юлда татарларга Суздаль кенәзе Дмитрий Константиновичның ике улы—Василий белән Семен да килеп кушыла. Әлбәттә инде, үз полклары белән. Шулай Дмитрий Константинович, улларын Туктамыш ханга ярдәмгә җибәреп, Нижний Новгород кенәзлеген таланудан саклап кала. Рязань кенәзе Олег та бу яуда хан ягында була. Гомумән, урыс елъязмаларында кенәз Олегка карата әйтелгән нәфрәт сүзләре еш очрый. Бер урында, мәсәлән: «Рязань кенәзе Олег, Туктамыш хан аның биләмәләренә килеп җитмәс борын ук, ханны каршысына барып сәламләде, баш иеп, үзенең Русьне яулауда аңа ярдәм күрсәтәчәген белдерде, Русь җирен, Мәскәүне ничек басып алырга, ничек җиңү яуларга һәм кенәз Дмитрий Ивановичны ничек кулга төшерү турында күп киңәшләр бирде»,—диелә *(ПСРЛ, Т.—VI. С.—98)*. Кыскасы, Мәскәүне камарга татар явы белән байтак урыс полклары да бара.

Чыннан да, Рязань кенәзе Олег Ока елгасындагы кичү урыннарын татарларга күрсәткәч, Туктамыш хан зур тизлек белән урыс җирләренә килеп керә. Юл уңаеннан Серпухов каласын ала, Мәскәүгә якынлаша.

Бу хәбәрне ишетеп алган олуг кенәз Дмитрий, казнасын төяп, гаскәр туплау сылтавы белән Костромага чыгып кача. Ул юкка чыгу белән Мәскәүдә төрле бәхәсләр, чуалышлар, бәрелешләр башлана. Эш шунда ки, халыкның бер өлеше татарлар килеп җиткәнче шәһәрдән чыгып качу ягында булса, икенчеләре, киресенчә, Кремль эченә кереп бикләнергә, каршылык күрсәтергә чакыра, качып китүчеләрне тоткарларга омтыла. Шулай сугышкыйнаш, талаулар, кибет басулар, әчүчелек башланып китә. Хәтта митрополит Киприан белән олуг кенәзнең хатыны Евдокияне, олы боярларны да башта каладан чыгармыйлар. Һәр капка төбендә ялангач кылычлы сакчылар тора. Тик үгетли торгач кына митрополит белән Евдокияне чыгарырга булалар.

Шунысы игътибарны җәлеп итә: бу көннәрдә урыслар арасында татар явына каршы көрәш оештыручы бер генә атаклы адәм дә табылмый. Бу соң дәрәҗәдә сәер хәл, әлбәттә. Юкса бит әле ике ел элек кенә, урыс тарихчылары язганча, Куликово кырыннан «җиңүче» булып кайттылар, олуг кенәзләрен күкләргә чөеп мактап, ана «Донской» исемен бирделәр. Шул ике елда халыкнын рухы тәмам сынганмы? Булган рух алай тиз юкка чыгар идеме? Бу факт та Куликово сугышынын әһәмияте империячел тарихчылар тарафыннан соңгы гасырларда гына махсус һәм ясалма рәвештә күпертелүен

күрсәтеп тора. Көрәшне житәкләүче табылмагач, ахыр чиктә, Литва кенәзе Ольгердның оныгы Остей дилбегәне үз кулына алырга мәжбүр була. Ул килеп төшү белән талашлар шунда ук бетә, аның житәкчелегендә кала диварлары ныгытыла, халык Кремль эченә кереп бикләнә дә татарларның һөҗүмен көтә.

## Татарларның Мәскәүне алуы

**1382** елның 23 август көнендә татарларның алгы отрядлары Мәскәүгә килеп житә. Алар Кремль диварларына якынлашу белән: «Олуг кенәз Дмитрий каладамы?»—дип сорыйлар. «Юк»,—дигән жавап ишеткәч, татарлар иң элек Кремльне әйләнеп тикшереп чыгалар, аннан камап алалар. Шулай кала өчен көрәш башланып китә.

Табигый, кенәз Остей житәкләгән Мәскәү халкы башкаланы саклап калырга тырыша. Ике көн буе бәрелешләр бара. Татарлар тарафыннан атылган уклар мәскәүлеләр өстенә янгыр булып ява, махсус жайланмалар ярдәмендә татар гаскәре Кремль диварларын жимерергә жыена, аларга менәр өчен озын баскычлар әзерли.

Әмма урыс халкының бер сәер үзенчәлеге бар—ул хәмер эчми тора алмый. Хәтта үтә жаваплы чакта да. Бу юлы да халыкның бер өлеше, дошманга каршы жан-фәрман сугышаса урынга, ачылган базлардан исерткеч эчемлекләр табып алып, лаякыл булганчы эчә-исерә. Ә исереккә, кем әйтмешли, диңгез тубыктан: Кремль диварларыннан атышу да, капка төбендә торган көчле Урда гаскәре дә аларга бер уен эш кенә булып тоела башлый. Шулай булмыйни, Мамай мирзаны куган халык ич алар. Ә мактанчыклар өй борынча йөреп сөйләнә: «Һәй, шул татардан куркып торырга! Калабыз нык, диварлары таштан, капкалары тимердән. Татар барыбер монда озак тора алмаячак. Ник дигәндә, аларга ике яктан куркыныч яный—каладан без атсак, арттан гаскәр белән олуг кенәз үзе килеп чыгачак—барыбер далага качып китәчәкләр». Кайберәүләр артык батыраеп китеп, хәтта диварлардан татарларны мыскыл итү, мәсхәрәләүгә үк барып житә *(С. М. Соловьев,—кн. 2.—С.—280)*.

Бәрелеш вакытында Кремль капкаларының берсенә менеп кунаклаган Адам исемле сукночы-сәүдәгәр (чит ил кешесе булса кирәк) Туктамыш ханның бик якын бер бәген уктан атып үтерә. Хан моны бик авыр кичерә. Әлбәттә, урыслар ягында да югалтулар аз булмагандыр, чөнки камауның өченче көнендә Туктамыш хан ягында сугышкан Нижний Новгород кенәзләре, олуг кенәзнең каенишләре, Василий белән Семен, юкка кан коймыйк дип, Мәскәү халкына тәкъдим белән мөрәҗәгать итәләр. Алар камалыштагы Мәскәү халкына: «Хан сезгә, үз олысы халкына ачу тотмый, чөнки сезнең бер гаебегез дә юк. Ул монда сезгә жәбер-золым салырга килмәде, кенәз Дмитрийның тәртибен төзәтер өчен генә килде. Ул бары бер нәрсәне—кенәз Остей белән бергәләшеп, аны хөрмәт белән каршылавыгызны, бераз бүләкләр бирүегезне генә таләп итә. Ханның калага кереп аны тамаша кылып йөрисе килә, ә сезгә ул тимәячәк»,—диләр. Халыкка зыян салу булмаячагын ышандырып, хан исеменнән ант итәләр.

Бераз киңәшкәннән соң мәскәүлеләр капканы ачарга риза булуларын белдерәләр һәм, чыннан да, капканы ачалар. Гаскәриләр һәм дин әһелләре Туктамыш ханны төре тоткан килеш иппи-тоз белән каршылыйлар.

Моннан соң булган хәлләрне урыс тарихчылары, татарларны бик нык сүгеп һәм үтә дә нәфрәтләнеп тасвирларга яраталар. Аларның сүзенчә, Туктамыш хан иң элек мәскәүлеләрнең көрәшен житәкләгән литвалы кенәз Остейны үзенә чакыртып алып үтерткән. Аннан соң ачык капка төбендә басып торган дин әһелләрен турарга боерган, имеш. Бу хәл 1382 елның 26 августында була.

Әмма без урысларның тарихны гел үз файдаларына бозып язу гадәтен дә беләбез. Татарның олуг тарихчысы Ризаэддин Фәхреддин дә урыс тарихчыларының һәр сүзен саф алтын дип кабул итмәскә, фикер йөрткәндә

бик сак булырга чакыра. Бу очракта да ул үз мөнәсәбәтен бик ачык белдереп уза: «Тик бу хәбәргә тулысынча ышанырга ярамый,—дип кисәтә ул.—Татар ханнарында бу рәвешле золым итү зур гаеп санала, аның өстенә шәригать тарафыннан тыела иде. Туктамыш кебек каһарман, галиҗәнаб бер ислам падишаһының болай алдап, түбәнлеккә төшүе мөмкин түгел. Биредә төп гаеп, үгет-нәсыйхәткә карамыйча, үҗәтлек күрсәткән һәм каршы торырга маташкан шәһәр халкының үзендә булырга тиеш. Болай булганда үтерү һәм талау булачагы табигыйдер»,—ди ул.

Чыннан да, моннан соң ясак түләп торачак үз олысы халкын алай кыру-имгәтү Туктамыш ханга нигә кирәк булды икән. Нинди генә холыклы булмасын, һәр хөкемдарның халык алдында «гадел хан» дигән абруй казанасы килә. Туктамыш хан исә капкаларны ачканчы халыкка тимәскә сүз биргән иде. Үзен хөрмәт иткән хан сүзен беркайчан да бозмый. Аның Сарай тәхетенә әле генә чыгуын искә алсак, бу бигрәк тә шулай. Сүзендә тормаса, ул бит моны башкалардан да таләп итә алмаячак, димәк, кул астындагы бәкләр-әмирләре алдында абруе бик нык төшәчәк. Ә абруйны саклау, аны ныгыту—бу вакытта ана бик кирәк булган, чөнки әле генә Дәшти Кыпчак олысларын туплап, үзәк хөкүмәтнен хакимиятен ныгытты.

Әйе, өч көн камап торганнан соң татарлар Мәскәү каласын кулга төшерә, анда зур сугыш була, халык күп кырыла. Ни сәбәпле? Бу очракта без урыс тарихчылары сүзенә сукырларча ышанырга тиеш түгелбездер дип беләм. Бәлки татарлар калага килеп кергәннән соң берәр провокация-мазар булгандыр, әйтик, берәр исерекбаш көтмәгәндә аткандыр. Киеренке чакта юк кына нәрсә дә җитә кала бит. Бәлки кала эчендә сугыш шул сәбәпле кабынып киткәндер. Кем белә...

## Туктамыш хан заманы...

Мәскәү вакыйгасыннан соң Урда гаскәре төркем-төркем булып төрле якка таралыша да урыс калаларын йөреп чыга. Шулай Владимир, Переяславль, Юрьев, Звенигород, Можайск, Боровск, Руза, Дмитров кебек калалар һәм бихисап авыллар кабат Сарай хөкүмәте кулына күчә. Бу вакытта «Куликово кыры каһарманы» олуг кенәз Дмитрий гаиләсе белән Костромада качып ята. Шунысы кызык, Туктамыш ханның урыс җирләрен кабат Сарайга беркетеп йөрүен читтән генә күзәтеп торган Тверь кенәзе Михаил, С. М. Соловьев язганча, ана зур бүләкләр белән үз киличиен җибәрә. Хан аның кешесен зур хөрмәт белән кабул итә һәм кенәзлек итү өчен ярлык яздырып бирә. Бу хәбәрдәге **«киличей»** сүзе игътибарны җәлеп итә. Әлбәттә, бу татардан кергән «килүче» сүзе. Урыс кенәзләренең документлар төзегәндә, Алтын Урдада кабул ителгән терминнар белән эш итүе билгеле нәрсә. Ләкин «килүче»—«илче» түгел, гәрчә мәгънә ягыннан алар якын торсалар да. Илчене мөстәкыйль дәүләт кенә җибәрә алган. Ә Тверь кенәзлеге Сарай биләмәсе саналган, шуна күрә кенәз Михаил ханга килүчесен генә җибәргән.

Тверь белән эшне җайга салгач, хан кире юлга борыла. Кайтып барышлый Коломнаны ала, аннан Рязань җирләре аша Сарайга әйләнеп кайта.

Татарлар киткәч, олуг кенәз Дмитрий, берни булмагандай, качып яткан җиреннән Мәскәүгә әйләнеп кайта. Туздырылган, таланган башкаланы күреп, аның эче «жу» итә. Ә бит акыл белән эш иткән булса, башкалага беркем тими иде.

Ул арада Тверь кенәзе Михаил, форсаттан файдаланып, олуг кенәзлекне үзенә эләктерер өчен астыртын эш йөртә башлый. Бу хәбәр Мәскәү кенәзенә дә килеп җитә. Ул олуг кенәзлекне үз кулында калдырыр өчен улы Василийны һәм берничә боярны Туктамыш хан хозурына Сарайга озата. Алар Сарайга 1383 елның язында, җирләр кипкәч кенә чыгып китәләр. Җәй урталарында Мәскәүгә Туктамыш ханнан илче килә һәм, рәсми мәрасим[1] оештырып, кенәз Дмитрий

[1]Мәрасим—церемония.

өстенә элекке вазыйфаларын кабат сала. Шушы көннән Мәскәү кенәзлеге Сарайга элеккечә ясак түләргә керешә. Ә олуг кенәз Дмитрий сүздән чыкмасын өчен, Сарайда яткан улы Василий әманәт сыйфатында Туктамыш хан хозурында яшәргә тиеш була.

Бу вакыйгалар Куликово сугышындагы җинүнең чамадан ашкан бер уйдырма икәнлеген тагын бер кат исбатлыйлар. Бу сугышның «дөньякүләм тарихи әһәмияте» менә шуңа кайтып кала. Урыс олысы кабат Алтын Урданың гадәти бер олысына әйләнә.

Мәскәү кенәзлеген кабат Сарайга китереп кушуы белән Туктамыш хан «бөек болгак» елларында таркала язып калган Алтын Урда олысларын бер кулга туплавын тәмамлый. Шулай ул гомеренең ин биек баскычына күтәрелә, көчле мәмләкәтнең гайрәтле идарәчесе-ханы булуга ирешә. Бу дәүләтнең тарихын белмәгән кешенең моннан соң инде Туктамыш хан сәүдә эшләренә, икътисадка зур әһәмият бирер, Бату, Үзбәк ханнардан мирас булып калган асыл дәүләтне тагын да ныгытыр, аның калалары кабат нур чәчеп торучы мәгърифәт учакларына әверелер, шулай бөек мәмләкәт икенче яшьлеген кичерер дип уйлавы да бар. Туктамыш хан һәр эштә башлап йөрүче булыр, армый-талмый дәүләт язмышын кайгыртыр дип өмет итәргә дә мөмкин. Әмма юк, галиҗәнаб тарих, көчле ташулардан соң үзәкләрен үзгәрткән елгалар сыман, бөтенләй көтелмәгән якка борылып кереп китә.

Алтын Урда тарихында шундый аяныч хәл була. Инде барысына да ирештем дигәндә генә Туктамыш хан каршысында ифрат көчле гайярь көндәше— Идегәй мирза фигурасы калкып чыга. Һәм шушы ике шәхес арасындагы каршылыклар ике дистә ел дәвамында татар мәмләкәтен тетрәнүләргә дучар итә. Тарихта күп тапкырлар сыналганча, бу юлы да татарга каршы көрәшүче татар табыла.

## Гайрәт күрсәтү

Әлбәттә, Туктамыш хан үзе дә, аның белән Идел-Йортка ияреп килеп, ханның төп көндәше Мамай мирзаны юк итүдә катнашкан, Мәскәүне кулга төшереп, олуг кенәз Дмитрий Ивановичны тез чүктергән, Тверь кенәзлеген яңабаштан Сарай канаты астына алган бәкләр-әмирләр дә,—Алтын Урда олысларын берләштерү эшенең Сәмәрканд әмире Аксак Тимер фатихасы белән башкарылганын яхшы аңлаганнар булса кирәк. Шуңа күрә ханның якын киңәшчеләреннән саналган өлкән әмир Галибәк, Өрлек-Тимер, Акбуга кебек дәүләтнең сул канатыннан чыккан әмирләр җай чыккан саен Туктамышны Мәвараэннәһер хакименә карата әдәп сакларга, аның кылган изгелекләрен онытмаска чакыруны кирәк табалар. «Моны син беркайчан да исеңнән чыгарырга тиеш түгелсең,—диләр алар.—Аның өстенлеген тануда бер генә вак нәрсәне дә игътибарсыз калдырма, чөнки изгелеккә игелек белән җавап бирү сина күтәрелергә ярдәм итәр һәм дәүләтенне генә киңәйтер».

Билгеле, яшьлеге зур калалардан, мәдәният үзәкләреннән читтә, Җучи олысының бер ерак провинциясе саналган Мангышлак, Арал буйларында узган, соңрак фәкать Сәмәрканд әмире булышлыгы белән башта Күк Урда, аннан Сарай тәхетенә ук чыккан Туктамыш хан, ягъни юньле тәрбия ала алмый калган, язмышның бер уены аркасында сәнәктән көрәк булган Туктамыш мондый акыл өйрәтүне, Тимер бәкне үзеннән өстен куеп сөйләшүне өнәп бетермәгәндер. Шулай да баштагы чорда ул бу мәсьәләдә ризасызлык күрсәтми, киңәшчеләренең сүзеннән чыкмыйча яши. Ләкин хакимият ул шундый нәрсә, аның тирәсенә, балга чебен җыелгандай, халык тиз сырыша, анда урын алу өчен гел көрәш бара.

Бу очракта да шундыйрак хәл килеп чыга. Тора-бара Туктамыш хан тирәсендә Күк Урдадан чыккан әмирләр, киңәшчеләрнең саны кими башлый, Өрлек-Тимер, Акбугалар гүр иясе була, аларны Идел буенда туып үскән башка затлар алыштыра һәм... акрынлап ханга бүтән киңәшләр дә бирелә башлый. Ни өчен дигәндә, болар үзгә шартларда үскән-калыплашкан, бүтән караштагы кешеләр.

Болар Идел буенын киң далаларында күпме кирәк мал асрап, Хаҗитархан, Төньяк Кавказ, Маҗар, Азак, Кырым калаларының чуар халкын күреп, сәүдә итеп, иркенлектә, муллыкта, кысылмыйча яшәргә күнеккән затлар. Аннан соң алар өчен Сәмәрканд әмире дә әллә кем түгел. Алар аны күрмәгән, аның белән яу йөрмәгән. Дөрес, Тимер мирзаның күп яулары, туплаган байлыклары турында ишеткәннәре бар. Шулай булгач, нигә әле җыелып барып аның җирләрен бер айкап кайтмаска да, мал-мөлкәтен тартып алмаска?!

Хакимияте ныгый барган Туктамыш ханның да остазы Тимер бәк кул астыннан тизрәк чыгасы, үзен мөстәкыйль идарәче—зур мәмләкәтнең беркем белән дә хисаплашмыйча хөкем сөрүче бөек ханы итеп күрәсе килгәндер. Өстәвенә үзенең Сәмәрканд әмиренә бурычлы булуын, бу дәрәҗәгә фәкать аның ярдәме белән ирешүен, гидай-мескен чакларын тизрәк онытырга, бәкләр, әмирләргә дә үзенең кем икәнлеген исбат итәргә теләгәндер. Ул да адәм баласы ләбаса.

Тарихчы М. Г. Сәфәргалиев тә бу мәсьәләгә нык игътибар итә, ул бу вакытта Туктамыш хан тирәсендә тупланган кешеләр арасында әмир Казанчыны, Идегәй мирзаны, аның абыйсы Иса бәкне күрсәтә. Алар барысы да мангыт ыруыннан чыккан халык, димәк, Туктамыш ханның якташлары сыйфатында, аның иң якын кешеләре булганнардыр дип уйларга нигез бар. Өстәвенә хәйләкәр Идегәй мирза, Туктамышның кызына өйләнеп, хан кияве дә булып китә, шул сәбәпле кинәт зур дәрәҗәгә ирешә—гаскәрнең сул кулы белән идарә итә. Бу инде хан тәхетен тотып торучы төп баганаларның берсенә әверелү дигән сүз.

Менә шушы кешеләр, хезмәт юлларын Туктамыш белән бергә башлаган, аның белән яуларга йөргән, ханның холкын-фигылен, йомшак якларын бик әйбәт белгән шушы адәмнәр тәэсирендә дәүләтнең сәясәте үзгәрә башлый, ягъни ул акрынлап Алтын Урда ханнары тоткан элекке эзгә төшә. Элекке эзгә төшү исә—яу йөрүләрне башлап җибәрү дигәнне аңлата. Тәхетнең төп баганалары «яу» дип торганда Сәмәрканд әмиренә карата булган кешелек бурычыңны аркылы атлап чыгарга да мөмкин ич. Аннан соң хан үзе дә шуны ук тели түгелме?

Шул рәвешле Сарай тәхетенә утырганнан соң берничә ел үтүгә Тимер бәк өмет иткән, өлешчә инде басып та ала башлаган җирләргә яу чабу нияте Туктамышта тәмам ныгып өлгерә.

Л. Н. Гумилев язганча, 1383 елдан Хәрәзем олысында Туктамыш хан исеменнән акчалар сугыла башлый. Бу инде бирелә аның хакимияте урнашуны күрсәтә. Дөрес, моңа хәтле, Алтын Урдада «бөек болгак» барган елларда Тимер мирза бу төбәккә берничә тапкыр яу белән килә, ләкин Суфилар династиясе аңа бик нык каршылык күрсәтә. Соңрак тагын бер яу оештырып, Үргәнеч каласын җир белән тигезли (1388), аның урынына тары чәчтерә. Шул вакыйгалардан соң Бөек Ефәк юлында гөрләп яшәп яткан бу төбәктә тормыш тәмам сүрелә, Сәмәрканд әмиренең дә аңа игътибары кими. Ләкин ул барыбер бу төбәкне үзенеке санаган булса кирәк.

1383 елда Туктамышның монда үз хакимиятен урнаштыруына ул ни өчендер игътибар итми. Бәлки моның сәбәбе Үргәнечнең гомер-гомергә Җучи олысына керүендәдер. Әле генә тәхеткә чыккан үз лачыны Туктамышның бу эшенә ул бер шаяру дип кенә карагандыр. Әмма тагын ике елдан (1385) Туктамыш хан Әзәрбайҗан белән Иранга зур яу җибәрергә карар кыла. Моңа хәтле аның Мисыр солтанына илчеләр җибәрүе дә билгеле. Тарихчылар фикеренчә, илчелекнең төп вазыйфасы, ике ил арасында мөнәсәбәтләр урнаштырудан тыш, хаҗәте чыга калса, Тимер бәккә каршы хәрәкәт итү өчен килешү төзеп куюдан гыйбарәт булган. Бу вакытта Тимер мирза Исфахан белән Ширазны яулау белән шөгыльләнә, ягъни Иранның үзәк өлкәләрендә сугыш хәрәкәтләре алып бара. Шуннан файдаланып, Туктамыш ханның Бикбулат ханзадә, әмирләрдән Иса бәк белән Янгидайлар җитәкләгән ун меңгә якын гаскәре Әзәрбайҗанга бәреп керә, аннан Иранның төньягында урнашкан Тәбриз шәһәрен камап ала. Фарсы тарихчысы Зәйнетдин Казвини (Хамдуллаһ Казвининың улы) бу вакыйганы менә ничек тасвирлый: «Тәбризлеләр урам вә мәхәлләләрне агач-богач белән ныгыттылар. Туктамыш гаскәре шәһәр халкының каршы торырга әзер икәнен

күрде. Гаскәриләр Шамб-и Газанда тукталдылар. Сигез көн буе шәһәр тирәсендә әйләнсәләр дә аңа һөҗүм итәргә җай таба алмадылар. Аннан соң әмир Вәлине чакырып чыгарып солых тәкъдим иттеләр. Әмир Вәли солыхка шундый шарт белән генә риза булды: Туктамышка гаскәрнең ат дагалары хакын түләгәннән соң тегеләр кайтып китәргә тиешләр. Шәһәрнең хәлле кешеләрен җыеп сөйләшкәннән соң шундый карар кабул ителде: җомга көн иртән һәрберсе бер түмән алтын китереп тапшырырга тиеш. Җомга көн иртән әмир Вәлинең нөгәрләре килде, Туктамышның хәзинәдәрләрен чакырып китерделәр дә җыелган акчаларны санарга керештеләр. Җомга көн булганга һәм солых төзелгәнгә, халык коралын өйдә калдырган иде. Туктамыш гаскәре моны белеп алды да шәһәргә һөҗүм итте, халыкны үтерә-талый башлады. Шәһәр халкы моңа каршы тора алмады. Сигез көн буе йөз меңгә якын рәхимсез кяферләр шәһәрне taладылар, беркемне кызганмыйча халыкны суйдылар...» *(Зайн ад-дин ибн Хамдаллаһ Казвини. Зайл-и тарих-и гузида.—Баку.—1990.—С. 131).*

Әмма яу моның белән тәмамланмый, Алтын Урда гаскәре Әзәрбайҗанның башка калаларын—Марага, Маранд, Нахичеванны да талый һәм үзе белән ике йөз мең әсирне куып алып кайтып китә.

Чәчең үрә торырлык бу өзектә аңлашылмаган бер урын бар: «Туктамышка гаскәренең ат дагалары хакын түләгәннән соң тегеләр кайтып китәргә тиешләр» диелә. Монда борыннан килгән бер йола чагылыш тапкан. Берәр хан яисә атаклы әмир гаскәре белән үзенә буйсынган идарәче җире аша узганда, теге аңа «ат дагасы хакы» дигән булып, шактый зур сумма акча яки кыйммәтле бүләкләр бирергә тиеш булган. Үзенә күрә бер ришвәт! Димәк, Тәбриз әмире Вәли эшне шушы борынгы йоланы үтәү белән тәмамларга уйлаган. Тик зур фаҗига килеп чыккан.

Бу яуга каршы Тимер бәк ни белән җавап биргән соң? Вакыйгаларга күчкәнче шунысын да әйтеп үтәргә кирәк. Әлбәттә, бу вакытта әле Туктамыш яу йөргән җирләр Тимер бәк биләмәләренә кермәгән. Ләкин бу әле Иранның төньяк өлкәләренә ул битараф булган дигән сүз түгел. Эш шунда ки, моннан зур табыш китерә торган сәүдә юллары узган. Аларны кулга төшерү Алтын Урда ханы өчен дә, Сәмәрканд әмире өчен дә зур әһәмияткә ия булган. Шуңа күрә бу елларда әлеге җирләрне һәркайсы үзенеке итәргә тырышкан.

Шик юк, Тимер мирза Туктамышның анда бәреп керүен зур оятсызлык, аның өлешенә керү дип санаган. Ләкин зирәк сәясәтче буларак, ул моны әлегә йөзенә чыгармый. Башка җирләрдә яулар алып барганга, Туктамышка ачыктан-ачык каршы чыкмый, вазгыятьне белеп тору өчен гаскәр җибәргәндә дә әмирләренә сугышка кермәскә, көч күрсәтү белән чикләнергә боера. «Туктамыш белән безнең арада килешү бар, без аны сакларга тиешбез», ди. Тагын бер елдан улы Мираншаһ җитәкләгән гаскәр бер бәрелештә Алтын Урда сугышчыларын әсир төшерә, арада берничә аксөяк тә була. Тимер мирза аларга зур хөрмәт күрсәтә һәм болай ди: «Безнең арада *(Тимер мирза белән Туктамыш арасында—С. Ш.)* ата-угыл хакы торыр. Берничә тинтәк аркасында халыкны харап итәргәме? Безгә киләчәктә дә килешү шартларын төгәл үтәү һәм йокыга талган фетнәне уятмау лязем. Әгәр дә кем дә кем моны бозса, ике як та ул адәмне акылга утыртырга, башкаларга сабак булсын өчен җәзага тартырга тиеш» *(В. Г. Тизенгаузен. Сборник документов...—т. II.—С. 110).* Тимер бәк әмирләрне җылы кабул итү белән генә чикләнмичә, аларга хәтта акчалар, халатлар, башка киемнәр дә бүләк итә. Аннан соң аларны, гади әсирләрдән аерып, махсус сак белән Сарай шәһәренә озата.

Бу яулар шактый табыш китерсә дә, Туктамыш ханга Әзәрбайҗанда ныгып калырга туры килми.

## «Буйсыну камытыннан башын чыгарды...»

**1385** елда Алтын Урда гаскәренең Әзәрбайҗанга бәреп кереп, анда берничә каланы талавына Тимер бәк җавап явы җибәрми дигән идек. Әйе, бу вакытта Иранда җитди яулар алып баруы аркасында, Тимер бәк ике тарафта

сугышуны кирәк тапмаган, күрәсең. Шулай да Туктамыш гаскәре ул тирәдә тагын да узынып йөрмәсен өчен, ул 1386 елда Грузиягә яу озата, әллә ни көч түкмичә генә аны басып ала һәм Алан капкасы дип йөртелгән Дарьял тарлавыгына, бүтән әһәмиятле урыннарга үз гарнизоннарын урнаштыра. Шушы чаралары белән Туктамышның Әзәрбайҗанга юлын бикләп куя. Ләкин Тимер бәкнең, һөҗүм итмичә, бары тик саклык чаралары гына күрүен Туктамыш хан үзе дә, аның тирәсендәге бәкләр-әмирләр дә дөрес аңламаган, күрәсең.

Бу вакытта хан тирәсенә тупланган кешеләргә Л. Н. Гумилев шундый сыйфатнамә бирә: «Ике йөз ел эчендә «озын ихтыярлы затлар»дан ханга тугры калган батыр нойоннарның варислары инде бәкләр, угланнар булып ирештеләр, ягъни алар хисләрен тыеп тормаучы, үз сүзен сүз итәргә яратучы, сәяси яктан тар карашлы провинциалларга әверелделәр,—ди галим һәм мәсьәләне тәмам ачыклау өчен өстәп куя:—Ханның көрәштәшләре батыр, көчле, чыдам, хәтта тугры да кешеләр булалар, тик вакыйгаларны алдан күрү сәләтен инде югалталар... Кыскасы, XIY гасыр ахыры күчмәләре этнопсихологик яктан гармониягә ирешәләр һәм, Аксак Тимер нинди генә гаскәр тупламасын, аларның бунчуклары, байраклары һәрвакыт җиңү ореолы эчендә торып калачак дигән ышанычта яшиләр. Үз-үзенә булган андый беркатлы һәм чамадан тыш ышаныч һәр мәдәниятнең түбән катламына хас күренеш» *(Древняя Русь и Великая Степь.—М., 1989,—С.—642—643).*

Чыннан да, Тимер бәкнең җавап явы белән килмәвен алар көчсезлек дип кабул иткән булса кирәк. Рас шулай икән, нигә әле аның биләмәләренә кабат яу чапмаска да, аннан асыл ганимәт маллары төяп кайтмаска.

Шулай итеп, Туктамыш хан остазы һәм химаячысы Тимер бәккә каршы зур яу оештыру эшенә керешә. Андый чакта ышанычлы аркадашларың-союзникларың да булса, үз-үзенә тагын да ышаныбрак хәрәкәт итәсең. Шул сәбәпле Туктамыш хан Магулистан хакиме әмир Камаретдингә мөрәҗәгать итә.

Магулистан—Шәркый Төркестан, Җиде-су, Көньяк Себерне дә үз эченә алган зур дәүләт булып, XIY йөз урталарында Чыңгыз хан улы Чагатай тарафыннан төзелә һәм мөстәкыйль яши башлый. Әлбәттә, инде күп илләрне үз кулына алырга өлгергән Сәмәркандь әмире Тимер бәкнең бу җирләргә дә күзе кыза, ул аларны кире Чагатай олысына китереп кушарга, биләмәләрен тагын да киңәйтергә омтыла. Тик әлегә, гөнаһ шомлыгына күрә, Магулистан белән шөгыльләнергә һаман вакыты җитми. Шулай да булдыра алганча әмир Камаретдинне гел борчып, бимазалап тора. Тик анда озаткалаган гаскәре кечкенә булганлыктан әллә ни уңышка ирешә алмый. Бу инде үзенә күрә, көтмәгәндә килеп чыгып, далада хәвефле хәл тудырып, мине онытып бетермәгез әле дип, Магулистан күчмәләренә үзенең барлыгын белдереп тору кебегрәк бер нәрсә була. Шуңа күрә Магулистан әмире белән Сәмәркандь әмире арасында киеренке мөнәсәбәтләр урнаша.

Туктамыш хан әмир Камаретдингә мөрәҗәгать иткәндә шушы киеренке мөнәсәбәтне күздә тоткан булса кирәк. Чыннан да, алар бер-берсен тиз аңлыйлар, килешү төзиләр һәм яуда бергәләп хәрәкәт итәргә сүз куешалар. Аларның планы буенча, Тимер бәк биләмәләренә Туктамыш хан төньяктан, әмир Камаретдин көнчыгыштан һөҗүм итәргә тиеш була. Бу яуда шулай ук Хәрәземнең Мәхмүт солтан да катнашырга ризалык бирә. Ни өчен дигәндә, аның да Тимер бәккә үче бар, Чыңгыз хан васыяте буенча Җучи Олысына бүлеп бирелгән Хәрәземне үзенеке итәргә тырышып, Сәмәркандь әмире ничә тапкыр яу белән килде, яндырып-талап, җимереп китте. Мәхмүт солтан үз чиратында көнбатыштан һөҗүм итәргә атлыгып тора.

Кыскасы, Туктамыш хан барлык олыслардан зур гаскәр туплый, анда Урда татарларыннан тыш, нигездә, кыпчаклар, болгар, мукшы, чирмеш, алан, Кырымнан җыйган катнаш халык, хәтта урыслар да була. Эш шунда ки, бу вакытта Суздаль-Новгород кенәзе Борис Константинович бер туганының уллары Нижний Новгородтан куып җибәрә һәм аларга Туктамыш хан каршысына килеп егылырга кала. Хан аларны хөрмәт белән кабул итә, гаскәре сафында урын бирә.

Яу 1387 елның көзендә башлана. Туктамыш хан, килешенгәнчә,

Мәвараэннәһер калаларына төньяктан һөҗүм итә. Калган ике яктан дошманны әмир Камаретдин белән Мәхмүт солтан кыса. Сәуран каласы камап алына, әмма гарнизоны нык торганга шәһәр эченә керә алмыйлар, тирә-юнь, әлбәттә, рәхимсез талана. Уңышлы яуны дәвам иттереп, берләшкән көчләр Ташкентка ук барып житә, Бохараны камый, хәтта Аму-Дәрья буенда урнашкан Термез каласына кадәр барып житәләр. Тик каланың нык диварлары дошманга бирешми. Тимер бәкнең Каршы каласында урнашкан Зәнгәр сарай дип аталган резиденциясе, яндырылып, көлгә әйләндерелә. Хәтта Мәвараэннәһернең башкаласы Сәмәрканд та куркыныч астында кала. Тимер бәкнең улы дошманны Мәвараэннәһердән ничек кенә кысрыклап чыгарырга тырышмасын, барыбер көче житми. Ул, чигенеп, кире Сәмәркандка кереп бикләнергә мәҗбүр була. Шулай итеп, Аксак Тимер жиһангирның ике дистә ел буе зур тырышлыклар куеп туплаган төп йорты Мәвараэннәһер аз гына һәлак булмый кала.

Әлбәттә, хәвефле хәбәрләр ана тиз килеп житә, ул Ирандагы сугыш хәрәкәтләрен кисәк туктатып, 1388 елның февраль аенда 30000 гаскәр белән Сәмәркандны саклаучы улы Гомәр-шәехкә ярдәмгә ашыга.

Аның яуларда чыныккан гаскәр белән туган иленә кайтып төшүен ишетүгә, төрле якка таралышып, кала-авылларны талап йөргән Алтын Урда гаскәре зур хәвефкә төшә. Тупланып, жиһангирны оешкан төстә каршыларга инде вакыт калмый. Шуңа күрә яу өчен берләшкән аркадаш гаскәрләрнең һәркайсы үз жаен үзе карарга, тизрәк үз олысына кайтып китәргә ашыга. Берәүләре Хәрәземгә, икенчеләре Магулистанга юл ала. Тукгамыш ханның нинди юлдан чигенүе турында төрле фикер бар. Л. Н. Гумилев, мәсәлән, Аксак Тимер аны Сыр-Дәрья буенда урнашкан Ходжент каласына таба барганда куып житкән, шунда сугышка керергә мәҗбүр иткән, дип яза. М. Г. Сәфәргалиев исә Алтын Урда гаскәре туган иленә Хәрәзем аша әйләнеп кайта, ди. Бу очракта мәсьәлә татар явының Арал дингезен сулданмы яисә уңнанмы әйләнеп узуына кайтып кала. Л. Н. Гумилев версиясе буенча кайту юлы шактый озыная төшә. Бәлки гаскәр икегә бүленгәндер, Тукгамыш хан Күк Урда аша—далалар аша уңга китеп, ә Хәрәзем солтаны Мәхмүт турыдан гына үз иленә әйләнеп кайткандыр. Ничек кенә булмасын, Тимер бәк гаскәре Урда татарларын юлда байтак вакыт эзәрлекләп бара һәм аларга күп зыян сала. Шулай Тукгамыш ханның 1388 елның кыш айларында үткәргән бу явы хурлыклы куылу белән тәмамлана. Тимер бәкнең Һиндстан явы вакытында яу көндәлеге алып барган Гыясетдин Али бер урында шундый сүз өстәп куя: «Тукгамыш үзенең оятсызлыгы аркасында үзенә карата эшләнгән изгелекләрне онытты һәм башын буйсыну камытыннан, ә муенын галиҗәнабыбыз Тимер әмир муенчагыннан чыгарырга жөрьәт итте».

Чыннан да, Тукгамыш ханның бу явы аны кеше иткән остазы Тимер бәк тарафыннан галәттән тыш оятсызлык дип кабул ителә. Башкача булса, тарих сәхифәләренә әлеге сүзләр теркәлеп калмас иде.

## Көрәш кыза...

Китереп сугучыга жавапсыз калса, ул Аксак Тимер буламыни? Чыннан да, ул биләмәләренә бәреп кергән Алтын Урда гаскәрен 1388 елның кышында куып жибәрү белән генә чикләнми, яз житеп, далалар яшәрү белән Хәрәземгә жавап явы оештыра. Тимер бәкнең гаскәре монда әллә ни каршылыкка очрамый. Тукгамыш ханның биредә калдырган калгайлары Илуглымыш углан белән Сөләйман Суфилар, олысны дошманга калдырып, тизрәк табан ялтырату ягын карыйлар—Тукгамыш хан канат астына кереп сыеналар. Шунысы кызык, чыганакларда инде Хәрәзем солтаны Мәхмүтнең исеме күренми. Бәлки Тукгамыш хан аны, Мәвараэннәһердән куылганнан соң алыштырган булгандыр, аның урынына башка бер затны утырткандыр. Шулай ук яуда Мәхмүт солтанның үлеп калуы да мөмкин.

Тимер бәкнең Хәрәземгә бишенче тапкыр яу йөрүе була бу. Олыс бик нык талана, калалар жимертелә, Үргәнеч исә, гомумән, кара күмергә әверелә.

Алай гынамы сон, рәхимсез җиһангир олысның исән калган халкын Сәмәркандка күчерергә, ә каланың үзен җир белән тигезләргә, анда арпа чәчәргә боера. Әмма ничек кенә тырышма, кала хәтле каланы барыбер бөтенләй үк җимереп бетерү мөмкин түгел. Тарихчылар язганча, бу әмер барыбер ахырына кадәр үтәлеп җитмәгән. Әмма «хакан галиҗәнабларынын» боерыгы формаль яктан булса да җиренә җиткерелгәндер дип уйларга кирәк. Кемнен башы белән түләсе килсен!

Шушы фаҗиганың шаһиты булган шагыйрь Әхмәд Үргәнче туган каласының җимерелүе турында мондый юллар язып калдырган, алар Аксак Тимергә мөрәҗәгать итеп язылган. Укучыга аңлашылсын өчен аның бүгенге татар теленә тәрҗемә ителгән вариантын китерәбез:

И залим вә кан эчүче, вә тәмуг утына ягасы башсыз;
Кайчангача агар Аму-Дәрья белән Сыр-Дәрья тулы күз яше?!
Үрләде күккә аһ-зар, илгә килде каза;
Бел шуны, килми калмас илдән сиңа җәза.
Куйга дип килгән бүре очрар чабан таягына;
Кем күтәрсә авыр таш, төшәр үзенең аягына.
Үргәнечкә чәчтерден арпа, шытып иген чыгар,—
Һәр башакның бөртегеннән сиңа үлем чыгар.
Зәһәр салучы ашыбызга ахыр үзе эчәр;
Кара туфрак өстендә үзенә кәфен кисәр.
Әхмәд аһын тыңлап, Аллаһ сине тәмугка салыр;
Дөньяда безгә дуслык, гаделлек шаһы калыр,—

дип шагыйрь үзенең тетрәндергеч һәм гүзәл шигырен тәмамлый. Аның тирән кайгы белән сугарылган сүзләре Бөек Ефәк юлында яткан борынгы каланың кара сөремле көннәрен күз алдына китереп бастыра.

Күзәтә башласаң, ил-дәүләтләрнең сәясәтендә кеше холкы-фигыленә охшаш күп төсмерләр, үзенчәлекләр табарга була. Ни өчен дигәндә, илләр белән аерым шәхесләр идарә итә, карарлар кабул иткәндә еш кына акыл бизмәне түгел, ә хисләр—нәфрәт, минминлек, үз-үзенә кирәгеннән артык ышану яисә якын-үз итү, авырга килсә дә, ярдәм кулы сузарга тырышу кебек гамәлләр чагылыш таба.

Бу очракта без Туктамыш ханның бернигә карамыйча Сәмәрканд әмиреннән үч кайтарырга омтылуын күрәбез. Хан тагын барлык олыслардан зур гаскәр җыя, шулай итеп, Шәрекъ тарихчылары язганча, «агач яфраклары белән яңгыр тамчыларыннан да күбрәк, исәбенә чыгып булмаслык гаскәр туплана».

Яу шул ук 1388 елның көзендә башлана. Туктамыш хан гаскәре Сыр-Дәрьяне кичеп чыгып, моннан өч гасыр элек Төркестан күгендә якты йолдыз булып кабынган суфи шагыйрь Әхмәд Ясәвинең туган каласы Ясәне, аның тирә-юнен бик нык талый. Әмма барыбер яуны уңышлы дәвам иттерә алмый. Беренчедән, кар явып, суыклар башлана. Кызык килеп чыга бит, әй, ярты гомерен шушы төбәктә үткәргән, остазы Тимер бәк ярдәмендә шушында хан булып күтәрелгән Туктамыш көзен яуга кузгалганда мондагы һава шартларын, бураннар башланасын белмәгәнме? Көздән соң суык кыш киләсен уйламаганмы? Бу факт үзе үк ханның Хәрәзем өчен Тимер бәктән үч алырга ашкынуын, карарларны акыл белән түгел, хис-эмоциягә бирелеп кабул итүен күрсәтә шикелле.

Икенчедән, Тимер бәк тә кул кушырып утырмый. Дөрес, бу вакытта аның янында гаскәр зур булмый, чөнки, гадәттәгечә, аның гаскәре кайда да булса сугыш алып бара. Һәм җиһангир, әлегә актив хәрәкәтләр башламыйча, аларның килеп җитүен көтә—башкаласы Сәмәркандны дошманнан саклый. Әмирләре дә шуны киңәш итәләр.

Тик үз биләмәләрен дошман атлары таптаганда Тимер бәкнең йөрәге түзеп торамы соң? Бу хәлгә тизрәк чик куярга теләп, ул Туктамыш белән ныклап торып бәрелешергә була. Шулай барлык көчләрен бер йодрыкка туплап, Туктамыш хан өстенә ташлана һәм... бик тиз уңышка ирешә. М. Г. Сәфәргалиев күрсәткәнчә, шушы сугышта Тимер бәк ягында мәрхүм Ырыс хан улы Күнче

углан белән Тимермәлик хан улы Тимер Котлык та катнаша, дошманның артына төшеп, Туктамышның бер төркем гаскәрен юк итә. Шунысына да игътибар итик: Тимер бәк аларны яуның беренче сафларына—мангайга куйган була. Эштә сынап карар өчендер, күрәсең. Ләкин укучыда сорау туарга мөмкин: Тимер Котлык Идегәй мирзаның бертуган апасының улы, урысча әйтсәк, племянникгы түгелме соң? Һәм ул, мантыйк буенча, абзасы Идегәй мирза белән Алтын Урда гаскәрендә булырга, Туктамыш хан ягында сугышырга тиеш иде кебек. Тиешен тиеш иде дә, тик менә көтмәгәндә Тимер бәк ягында сугышкан булып чыкты. Бу нәрсәне аңлата соң? Моны ничек аңларга? Тагын шунысы да аңлашылып житми: Тимермәлик хан үтерелгәннән соң Идегәй мирза тәрбиясендә һәм яклавында калган яшь Тимер Котлыкны ничек итеп Идегәй мирза үзеннән еракка, Аксак Тимер янына жибәрде икән? Моның өчен бик житди сәбәпләр булырга тиеш. Нигә яшь егетне анда озаткан да, үзе Туктамыш хан хезмәтендә калган? Бу серне без алдагы бүлекләрнең берсендә чишәрбез. Ә хәзергә кабат яу хәрәкәтләренә әйләнеп кайтыйк.

Шулай итеп, Туктамыш ханның төп көчләре Сыр-Дәрьянең сул як ярына кысрыклап чыгарыла. Димәк, Тимер бәккә бераз хәл алырга, дошманның кинәт һөжүм итүеннән шикләнмичә, төп көчләрнең килеп житүен көтәргә җай кала. Чыннан да, бераздан ярдәм килеп житә—Хорасаннан, Бәлхтән, Бадакшаннан, Хисардан һәм башка төбәкләрдән.

1389 елның кышында актив хәрәкәтләр, каты бәрелешләр булмаганга охшый. Бары тик февраль ахырлары—март башларында гына Тимер бәк гаскәренең бер өлеше Сыр-Дәрьяне кичеп чыга, Туктамышка һөжүм итә. Аннан соң эзәрлекләргә тотына. Әлбәттә, тыштан күрсәтмәсә дә, эчтән затсыз Туктамышка жирәнеп караган, аңа ярдәм иткәне өчен үзен кичерә алмаган Тимер бәк бу яуны тегенең тар-мар ителүе белән тәмамларга теләгәндер, шуңа ирешү өчен барысын да эшләгәндер. Әмма кайчакта вакыйгалар агышы жиһангирлар ихтыярыннан да көчле булып чыга.

Тимер бәк үзенең һәр очракта да мул кан агызып эш итүче гаскәрен Туктамыш хан өстенә ташлау өчен үзенә чакыртып алу белән яуланган жирләрдә жирле халык баш күтәрә башлый. Дөресрәге, андагы әмирләр, бәкләр хакимиятне үз кулларына алырга омтылалар. Хорасан белән Магулистан Тимер бәк кул астыннан чыгарга омтылыш ясый. Эшләр болайга киткәч, Сәмәрканд әмиренә икенең берен сайларга туры килә: йә Туктамышны эзәрлекләүне дәвам иттерергә, йә баш калкыткан өлкәләрне бастыру белән шөгыльләнергә. Ул дала буйлап Алтын Урда гаскәрен куып йөрү урынына, үз йорты булган Мәвараэннәһергә якын өлкәләрдә тынычлык урнаштыруны тиеш таба.

Туктамыш ханга килгәндә, бу яуларда ул бернәрсәгә дә ирешми дип әйтү хакыйкатьнең яртысын гына белдерү булыр иде. Төптән уйламыйча кылыч тартулары аркасында ул хәтта булганын да югалта—Хәрәзем харап ителә, шулай ук аның биләмәләренә кергән Сыгнак (Күк Урдада) каласын да югалта.

Әлбәттә, ханның яудан хурлыклы рәвештә жинелеп кайтуы, куып жибәрелүе тәхет тирәсендәге бәк-әмирләрдә аңа карата булган ышанычны бик нык киметә. Бу яу Туктамыш ханның сәләтсез, үзсүзле, төптән уйлап эш итә белмәүче буш куык адәм икәнлеген бик ачык күрсәтә.

Һәм тәхет тирәсендә аның сәясәтеннән, эш-гамәлләреннән риза булмаган бер төркем аксөякләр хәрәкәткә килә.

## «Мангыттан азган Идегәй...»

Кайчакта сакланып калган кечкенә генә факт-хәбәр дә вакыйгалар агышын дөрес аңларга, зур нәтиҗәләр ясарга ярдәм итә.

Алдагы бүлектә без Тимер Котлыкның 1388 елдагы яу вакытында Туктамыш хан гаскәрендә булмыйча, аның дошманы Тимер бәк (Аксак Тимер) ягында сугышуын әйтеп үткән идек. Бу фактны истә тоткан хәлдә, тагын бер хәбәргә игътибар итик. Анысы урыс елъязмаларында теркәлеп калган. Анда

Идегәй мирзаның да, Туктамыш ханга хыянәт итеп, Аксак Тимергә качып китүе һәм шушы хәлдән соң ханның алты бала табып биргән хатыны Тәүлинбикә ханишәне үтерүе хакында әйтелә.

Безнең алда бер-берсенә бөтенләй бәйле булмаган ике факт тора кебек. Чыннан да, яшь-җилкенчәк Тимер Котлыкның Тимер бәккә хезмәткә күчүе белән Туктамыш ханның хатыны Тәүлинбикәне үтерүе арасында нинди бәйләнеш бар? Соңгысы, гомумән, Туктамыш ханның шәхси тормышына гына кагыла кебек. Ләкин ашыкмыйк, иң элек ятим калган Тимер Котлыкның соңгы елларда гел абзасы Идегәй мирза канат астында яшәвен тагын бер хәтердә яңартыйк. Шулай итеп, Тимер Котлык Аксак Тимергә күчкәннән соң бераздан Идегәй мирза үзе дә Сәмәркандка качып китә һәм, чыганаклар күрсәткәнчә, шуннан соң Тәүлинбикә ханишә үтерелә.

Алтын Урда гаскәренең сул кулы (корпус) белән идарә итүче гаскәр башлыгы Идегәй мирзаның Туктамыш хан кияве булуын да искә төшерик. Шундый зур дәрәҗәгә ирешкән зат, ханны ташлап, аның дошманына качып киткән икән, димәк, Туктамыш хан гаиләсендә дә, тәхет тирәсендә дә бик күп вакыйгалар булып узган дигән сүз. Идегәй мирза ханның гаилә әгъзасы, аның кияве бит. Әле күптән түгел генә ул аның ышанычлы гаскәр башы, тәхетнең төп баганаларыннан берсе иде. Шундый зат дошманына качып китсен әле! Димәк, үтерелгән Тәүлинбикә ханишә дә бу вакыйгаларда ниндидер роль уйнаган. Шуның өчен хан аннан үч алган булса кирәк. Бу очракта без Идегәй мирза фәкать Тәүлинбикә кызына өйләнгән булган дип фараз кыла алабыз. Алай гына да түгел, Тәүлинбикә хәтта гомеренә куркыныч янаган киявен кисәтеп, аңа качып китәргә, шул сәбәпле башын саклап калырга да ярдәм итмәде микән дигән сорау да куя алабыз. Аның хан тарафыннан юк ителүе шул хакта сөйли кебек.

Кызганыч, бу вакыйгаларны яктыртучы хәбәрләр аз сакланган, аларны аерым фактларны җентекләп тикшерү, гомумиләштерү юлы белән ачыкларга туры килә.

Тәхет тирәсендәге ыгы-зыгы Туктамыш ханның Күк Урдага йөргән уңышсыз явы тәмамлангач та башланган булса кирәк. Бу аның Тимер бәк биләмәләренә икенче йөрүе. Әлбәттә, ике тапкыр рәттән җиңелеп кайтуы кул астындагы бәкләр-мирзаларда ханга карата ышанычны нык какшатып кына калмыйча, кайберәүләрдә аны алыштыру уе да кузгаткан булса кирәк. Тәхеткә лаеклы затлар бер Туктамыш кына түгел! Урыс чыганакларында ханның нәкъ шушы вакытта ниндидер «Ози баба» исемле ханзадәне үтерүе, башларын саклап калу өчен берничә бәкнең Мәскәүгә качып китүе һәм олуг кенәзгә хезмәткә ялллануы хакында хәбәр бар. Качып китүчеләрдән Бәхетхуҗа, Кадерхуҗа, Мәмәтхуҗа исемле аксөякләрнең (бертуганнар булса кирәк), кире Сарайга әйләнеп кайтудан өмет өзеп, хәтта православие диненә күчүләре дә хәбәр ителә. Юкса, алар елъязмага кереп тә калмаган булыр иде!

Икенче бер чыганакта, мәсәлән, Туктамыш ханга каршы фетнә оештырылуы, анда Бикбулат белән Хуҗаметдин угланнар, Бакшы, Тордычык, Даут бәкләрнең катнашуы ачыктан-ачык әйтелә.

Шулай да бу астыртын эшләр башында Идегәй мирза үзе торганга охшый. Гомеренең соңгы көннәренә хәтле Туктамыш ханга (димәк, үзәк хөкүмәткә!) каршы көрәшкәне өчен дастан каһарманына кем әверелгән? Идегәй мирза! Алтын Урда дәүләтенең ярты өлешен күпме заман үз кулында кем тоткан? Идегәй мирза! Ханга каршы үсеп чыккан оппозицияне җитәкләрлек иң абруйлы, иң көчле шәхес кем? Шул ук Идегәй мирза!

Туктамыш хан үзенең Ягайлога җибәргән ярлыгында да шул фактны телгә ала (1393 елда): фетнәчеләр (Аксак) Тимер белән бәйләнешкә кереп, Идегәйне аның хозурына озаттылар, аны миңа каршы котырттылар, ди. Ни өчен Идегәй мирзаны? Чөнки ул Сәмәрканд әмирен яхшы белә, аның белән ничек сөйләшергә кирәген чамалый, карьерасы башланган вакытта Туктамыш белән икәүләшеп аңа хезмәт иткән кеше.

Аннан соң Идегәй мирзаның бары үзе генә белә торган яшерен планы да була. Һәм бу план үз улы кебек якын кешесе—Тимер Котлык углан белән бәйле. Аның Тимер Котлыкны якын итүен, аңа зур өметләр баглавын соңрак

булачак вакыйгалар тулысынча ачып сала. Хәзергә бу әле ният-хыял рәвешендә Идегәйнең уенда гына яши.

Без инде ни өчен Тимер Котлык кинәт Сәмәрканд әмире ягында пәйда булды, аның гаскәрендә Туктамыш ханга каршы сугышты?—дигән сорау куйган идек. Инде менә ана жавап бирергә вакыт житте. Искә төшерик: Тимер Котлыкның атасын Тимермәлик ханны кем үтерде? Туктамыш хан! Ә Идегәй мирзаның атасы кем кулыннан һәлак булды? Шул ук Туктамыш хан кулыннан! Бу нәрсә турында сөйли—яшь Тимер Котлыкның да, Идегәй мирзаның да Туктамыш ханны күрә алмаска, күңелләренең иң тирән җирендә аңа карата дошманлык һәм нәфрәт сакларга хаклары бар. Һәм бу шулай булган да! Дөрес, Туктамыш хан Алтын Урданың ике канатын да берләштергән, гаять көчәеп киткән елларда алар бастырылып яткан хисләренә ирек бирмәскә, аларны сиздермичә яшәргә мәжбүрләр иде. Тик уңышсыз яулардан соң ханның абруе төшә башлагач, тәхет тирәсендәге аксөякләрдә Туктамыш хан алып барган сәясәттән ризасызлык барлыкка килгәч, баш калкыткач, яшеренеп яткан хисләр кабат уянган булса кирәк. Шунысын да онытмыйк: яшь Тимер Котлык—хан углы, чыңгызый, аның да, Туктамыш хан кебек, тәхеткә чыгарга хакы бар, һәм ул анда утыра калса, берәү дә авыз күтәреп каршы сүз әйтергә җөрьәт итмәячәк. Шулай булгач, ни өчен әле сәләтсез, дуамал, алдан күреп эш итә белмәүче Туктамышны яшь һәм тыңлаучан Тимер Котлык углан белән алыштырмаска?! Бу барысы өчен да уңай булыр иде. Идегәй мирза өчен бигрәк тә!

Тарихчы Әбелгази хезмәтендәге бер хәбәр моны тулысынча раслый кебек: «Тимер Котлыкның йөрәге падишаһ булу ихтималын уйлап сызланды, шуңа күрә ул Туктамыш ханга каршы фетнә оештырды. Туктамыш аны тотып алып үтермәкче иде, тик Тимер Котлык качып өлгерде һәм Тимер бәк хозурына китте»,—диелә анда. Әлбәттә, әле унсигезе дә тулмаган Тимер Котлыкның Туктамыш ханга каршы фетнә оештыра алуына ышануы кыен. Шик юк, аның артында Идегәй мирза оештырган оппозиция торган. Алар, астыртын эш йөртеп, Туктамыш ханны тәхеттән төшерү юлларын да уйлый башлаган булырга тиешләр. Ләкин мондый җаваплы эшкә керешкәнче Идегәй мирза, хакимият тирәсендә зур тәҗрибә туплаган, кételмәгән борылышларны күп күргән зат буларак, Тимер Котлыкны җил-давыл тимәслек җиргә озатуны кирәк таба. Ә андый бердәнбер җир—Тимер бәк янында, Мәвараэннәһердә. Димәк, ул киләчәктә тәхет иясе булырга тиешле егетне, апасының улы Тимер Котлыкны шунда озаткан булса кирәк. Менә ни өчен 1388 елдагы яуда Тимер Котлык Алтын Урда ягында түгел, ә Тимер бәк гаскәрендә була, хәтта батырлык та күрсәтеп өлгерә. Абзасы тарафыннан ни өчен монда озатылуын ул белгәндер. Барысы да алдан сөйләшеп эшләнгәнгә охшый, юкса, тарихчы Әбелгази: «Тимер Котлыкның йөрәге падишаһ булу ихтималын уйлап сызланды...»—дип язар идемени. Ул бит бу сүзләрне үзе уйлап чыгармаган, конкрет вакыйгаларга таянып язсә берәр чыганактан файдаланып теркәп калдырган.

Димәк, Идегәй мирза бу эшкә мәсьәләнең алдын-артын уйлап керешкән, вакыйгалар икенче юнәлеш алган очракта Тимер Котлыкка хәвеф янамасын өчен барысын да алдан кайгырткан. Ул бит Тимер Котлыкны туганы булганы өчен генә сакламый, егетнең исән-имин калуы Идегәй мирзаның үзе өчен дә үтә мөһим мәсьәләгә әверелә. Тимер Котлык углан хан тәхетенә утырса, хан янында үзенең кем буласын ул бик әйбәт белә. Хәлләр ул уйлаганча барса, Тимер Котлык аның үз бәхете, үз киләчәге дә түгелмени?! Шуңа күрә Идегәй мирза Тимер Котлыкны күз карасыдай саклый.

Әмма аларның ханга каршы фетнә оештырулары көтмәгәндә ачылып китә һәм... Идегәй мирзага ашыгыч рәвештә Сәмәрканд тарафына качып китәргә туры килә. Монысы инде чыганаклар белән расланган тарихи факт. Туктамыш ханның хатыны Тәүлинбикәнең Идегәй мирза качып киткәч үтерелүе дә бик аңлашыла. Күрәсең, ул ханның аны юк итәргә җыенуын кияве Идегәй мирзага әйтеп өлгергән. Тарихи фактларны җентекләп тикшергәндә, кайчак менә шундый катлаулы төеннәр дә ачылып китә.

Әйе, татар тарихының кызыклы дәвере булган Алтын Урда тарихында Идегәй мирзаның роле ифрат зур. Мәгълүм бер чорда вакыйгалар агышы аерым шәхесләрнең үзара мөнәсәбәтенә бәйле рәвештә бара. Мисал өчен, шул ук

Туктамыш хан белән Идегәй мирза тарихына күз салыйк.

Идегәй мирза 1352 елда мангыт (ак мангыт) ыруының Балтычка би («Идегәй» дастанында аның исеме ни өчендер Котлыкыя би дип бирелә) гаиләсендә дөньяга килә. Ә мангыт ыруы, тарихта билгеле булганча, Мангышлак белән Арал дингезе, Җаек арасындагы җирләрдә яшәгән. Ә Туктамышның атасы Туйхуҗа би шушы төбәкнең идарәчесе булган. Моннан нәрсә килеп чыга? Шундый каршылыкларга кергән бу ике шәхес якташлар икән бит. Алар яшьтән үк бер-берсен белеп, аралашып үсәләр, бергә буын ныгыталар, киң далага да бер үк вакытта чыгалар. Күк Урдада барган сугышлар вакытында икесе дә Тимер бәк ягына күчә, Туктамыш соңрак хан булып күтәрелгәч, Идегәй дә өлешсез калмый, аңа да тәхет тирәсендә лаеклы урын табыла. Ә инде Туктамышның кызына да өйләнеп алгач, гомумән, абруе үсеп, хәзергечә әйтсәк, социаль статусы ныгып китә.

Әмма бу ике шәхес арасында, олы юлга аяк баскан чакта ук, зур каршылык үсеп чыга. Без аны алдарак инде телгә алып узган да идек, инде җентекләбрәк тикшереп карыйк.

1378 елда Күк Урдада барган көрәшләр вакытында Тимермәлик хан Туктамыш тарафыннан үтерелә. Ханның өлкән әмире Балтычка да Туктамыш кулына төшә. Иделдән көнчыгышта яткан җирләрнең хуҗасына әверелгән Туктамыш хан Балтычка бинең зур акыл иясе, дәүләт эшләрендә үтә дә тәҗрибәле, идарә эшләрендә файдалы зат булуын белә һәм аны үз ягына аударырга омтыла. Ул аңа мондый тәкъдим ясый: «Әгәр дә, мине үзеңнең ханың дип танып, бигать бирсәң, гомереңне саклап калу гына түгел, чал башыңнан бер чәч бөртеге дә төшмәс. Бу очракта мин сине, үземнең якын кешем итеп, идарә эшләренә билгеләрмен»,—ди хан.

Моңа каршы Балтычка би: «Ханым Тимермәлик исән чакта мин абруйлы әмир булып яшәдем. Хәзер кулларым бәйле булмаса, сине ханым тәхетендә күргән бу күзләремне чокып чыгарыр идем. Әгәр дә миңа изгелек кыласың килсә, башымны чабып өзәргә боер, башымны ханым башына, гәүдәмне аның гәүдәсенә каплап куярга куш. Аның асыл гәүдәсе болай кадерсез ятарга тиеш түгел»,—дип җавап бирә. Ягъни туры йөрәкле Балтычка би хыянәт юлына басмаячагын ханның йөзенә бәреп әйтә.

Әлбәттә, бу—Балтычка бинең соңгы сүзләре була. Ул шунда ук үтерелә. Шик юк, үлем сәгатен каһарманнарча каршылый белгән ата улы Идегәй өчен гомерлек үрнәк—бөек үрнәк булып калгандыр.

Бу вакытта Идегәйгә егерме җиде яшь. Шушы елдан аның өчен гомер буена сузылган шәхси фаҗига башланып китә. Аның эзе Идегәй язмышында гына түгел, бөтен Алтын Урда дәүләте тарихында да ап-ачык ярылып ята.

Алтын Урда калаларына сәяхәт кылган тарихчы Ибне Гарәпшаһ Идегәй мирзаның иң дәрәҗәле вакытта, дәүләтнең бер канатын үз кулында тоткан чагындагы портретын менә нинди сүзләр белән тасвирлый:

«Идегәй,—дип яза ул,—урта буйлы, каратут йөзле, тыгыз тәнле, батыр йөрәкле, куркыныч карашлы, әмма бик матур һәм мөлаем итеп елмая да белүче, искиткеч сизгер, зирәк һәм тапкыр телле кеше. Укымышлы һәм дәрәҗәле адәмнәрне бик якын итә. Төрле дәрвишләр, фәкыйрьләр, дин әһелләре белән аралашырга ярата, алар белән үзен бик гади тота, уен-көлкеле сүзләр әйтеп сөйләшә. Шуның өстенә ул ислам кануннарына бик зур ихтирам белән карый, уразаны бер дә калдырмый, төннәрен дә намазга тора. Коръән вә хәдисләрне үзенең Аллаһы Тәгаләгә булган мөнәсәбәтендә төп корал итеп саный».

Бу өзектә Идегәйнең тәмам житлеккән, дан-шөһрәтнең иң югары ноктасына житкән чагында алган бәясе китерелә. Шуннан чыгып фикер йөртсәк, безгә аның атасы Балтычка би үтерелгән вакыттагы халәтен күз алдына китерү дә артык кыен булмас шикелле.

Әлбәттә, ул яшьтән булдыклы, зирәк, теләсә нинди эшне җиренә житкереп тиз арада башкара белүче егет булып үскән. Моңа аның гади гаиләдән чыкмыйча, би улы булуы да ярдәм иткәндер. Идегәйнең тиз арада күтәрелүе аның, чыннан да, батыр йөрәкле, зирәк акыллы, алдын-артын уйлап эш итә белүче нык холыклы һәм, иң мөһиме, оста оештыручы-лидер булып үсүе хакында сөйли. Шуңа күрә ул тиз арада үзенә игътибарны җәлеп итә,

сәләтләре, актив эшчәнлеге белән күпләрдән аерылып тора. Шушы сыйфатлары ана Тимер бәк хозурына баргач та үз урынын табарга ярдәм иткәндер.

Шулай да, атасының гомере Туктамыш хан кулыннан өзелүе аның язмышына күләгә төшерми калмый. Шул күләгәдән чыгу, хан белән араны җайлау, чын-чынлап аның ышанычын яулау, якын кешесенә әйләнү өчен зирәк һәм хәйләкәр Идегәй мирза нинди дә булса көтелмәгән адым ясарга тиеш иде. Һәм ул аны ясый да—ул Туктамыш ханның кызына өйләнә, аның киявенә әверелә. Бу никахта мәхәббәт хисләренә караганда, исәп-хисап зуррак булмады микән? Шушы адымы аның үсү-күтәрелүен дә тәэмин итә. Дөрес, моның өчен аның үзенә дә нык тырышырга, алны-ялны белмичә хан йомышында йөрергә туры килгәндер. Әмма ни генә булмасын, Идегәй мирза бераздан ханның ин абруйлы, иң җаваплы боерыкларын башкаручы төп әмирләрнең берсенә әверелә, Алтын Урда гаскәренең сул кулы белән идарә итә башлый.

Ләкин болар бит тормышның кеше күз алдында үтә торган тышкы ягы, шәхеснең җәмгыятьтә тоткан урыны гына. Әле күңел дөньясы бар. Идегәйнең үз-үзенә биргән бәясе, хыяллары-идеаллары бар. Шик юк, бу бәя бик югары булган. Бу хакта ике төрле фикер була алмый, чөнки Идегәй мирзаның тормыш юлы, мәмләкәт тарихында калдырган тирән эзе шул хакта сөйли.

Әлбәттә, ул үзен күпләрдән өстен тойган, үзенең кем икәнлеген белеп яшәгән. Көчле, горур шәхес буларак, башкаларга булган мөнәсәбәтен артык яшереп тә тормагандыр дип әйтә алабыз. Гадәттә, андый кешене яратмыйлар, аннан көнләшәләр һәм куркалар. Җае чыккан саен астыртын гайбәт тә тараталар, яла ягалар, төрлечә зыян салырга тырышалар. Андый шәхеснең түрәләр белән дә мөнәсәбәте катлаулы була. Бу очракта Идегәй мирзадан югары торучы бердәнбер зат—Туктамыш хан үзе. Аларның мөнәсәбәте артык җылы булгандыр дип күз алдына китерүе кыен. Дөресрәге, бер-берсенә кирәкле кешеләр буларак, алар билгеле бер чикне чыкмыйча, якынаймыйча һәм ерагаймыйча дәүләт эшләрен бергәләп тарткан булырга тиешләр. Бу хәл «Идегәй» дастанында да чагылыш таба. Атасын үтергән кешегә, ул хан булса да, аның йөрәге ничек эреп китсен. Ләкин нишләмәк кирәк күктә Ходай, җирдә хан дигәндәй, беркая да китеп булмый—әлегә замана Туктамышныкы. Телисеңме, юкмы—дөнья көтәргә кирәк.

Бер караганда, Идегәй мирзаның бер дә язмышка үпкәләр җире юк. Ул хан кияве, андый бәхет бик сирәк кешегә тәти. Шуна күрә билгеле бер чиккә кадәр Идегәй мирза язмышы белән килешеп, ана риза булып яшәгәнгә охшый. Ә Туктамыш хан аны гаҗәеп эшлекле һәм булдыклы булганы өчен югары бәяләгән, дәүләт эшләрендә файдаланган. Әлбәттә, хан Идегәй мирзаның үзеннән сәләтлерәк тә, зирәгрәк тә икәнен белеп яшәгән. Һәм... шул сәбәпле мирзадан бераз шүрләп тә куя торган булгандыр. Ә бу очракта араны бозу өчен бер гайбәт җибәрү, яла ягу да җитә. Һәм хан тирәсендәге вак халык, көнчеләр ахыр чиктә Туктамыш хан белән Идегәй мирзаның арасын тәмам бозуга ирешәләр. Шулай гаскәр арасында абруйлы, нык холыклы, зирәк һәм астыртын-хәйләкәр Идегәй мирза хан өчен куркыныч бер фигурага әверелә. Моны Туктамыш хан бик тиз аңлап ала, аны дәүләт эшләреннән читләштерү планына керешә. Димәк, берәр ыгы-зыгы килеп чыкканда һәр нәрсәгә үз фикере булган Идегәй мирзаның көтелмәгән адым ясау мөмкинлеген Туктамыш хан дөрес чамалаган. Рас шулай икән, бәладан башаяк дигәндәй, хәтәр кияүдән тизрәк арыну хәерлерәк, дип фикер йөрткән булса кирәк Туктамыш хан.

Әлбәттә инде, андый нәрсәләргә үтә дә сизгер Идегәй мирза да кул кушырып утырмый—ханга каршы астыртын эш алып бара. Тик, әйтелгәнчә, бу фетнә көтелмәгәндә ачылып китә һәм кияү кеше тәвәккәл адым ясарга мәҗбүр була. Шулай ул Туктамыш ханнан качып китә (1389). Билгеле, ул әлеге адымны чарасызлыктан ясалган вакытлы бер чигенү дип кенә карый. Башкача була да алмый. Аның бит ныклап уйланган генераль планы бар, Тимер Котлык бар. Ул аны әле Сарай тәхетенә утыртачак. Моның өчен барысын да эшләячәк.

Чыганаклардан күренгәнчә, Туктамыш ханга каршы баш калкыткан оппозициядә Идегәй мирзадан башка Бикеш, Тордычык-Бирде, Даут мирза һәм Идегәйнең абыйсы Иса бәк кебек затлар да булган. Астыртын эшләр беленгәч, кайберләренең юк ителгән булуы да бик ихтимал.

# Аксак Тимер: тәхеткә чыгу сәнгате

## Чагатай олысында

Аксак Тимер 1335 елда барлас (монгол) ыруының Тарагай атлы әмир гаиләсендә туа. Кайбер риваятьләрдә туган чакта ук анын чәче чал булган, ә йомарланган уч төбендә оешкан кан төере күргәннәр диелә. Моның соңрак уйлап чыгарылган тарихи риваять булуы да бик ихтимал. Чыңгыз хан турында да шундый ук риваять саклануын искә төшерик. Аксак Тимернең ифрат күп кан коюлар белән бәйле бихисап яулары, кешелек хәтеренә кереп калган мәшһүр эшләре, ярты дөньяга таралган даны-шөһрәте, аләмнәр башына сыймаслык рәхимсезлекләр кылуы моның сәбәпчеседер, шәт. Аләми затның бит мондый гамәлләрне ничек тә аңлыйсы килә. Ә туганда ук чал чәчле, учы канлы нарасыйның язмышында ниндидер яшерен көчләрнең роль уйнавы—барлык сорауларны да берьюлы хәл итә сыман. Бу очракта адәм баласына бары тик күзләрен күккә текәргә дә аптыраганнан кулларын җәяргә генә кала.

Ә бит мәсьәлә гаять җитди—андый шәхесләрнең көтмәгәндә тарих мәйданына килеп чыгуында, чыннан да, кеше аңлап житкерә алмаслык ниндидер сер бар кебек. Бу очраклы хәл, язмыш шуклыгы гына булмаска тиеш. (Хәер, урыс язучысы Даниил Андреевның «Роза Мира» дип аталган эзотерик хезмәтендә мондый сорауларга да җаваплар табарга мөмкин. Без укучыларны шул гаҗәеп тирән мәгънәле хезмәт белән танышырга чакырабыз.)

Аксак Тимер, ягъни Тимер мирза барлас ыруыннан чыккан, дидек. Бу монгол ыруы Мәвараэннәһергә ничек килеп урнашкан соң? Моның кызыклы гына тарихы бар. Һәм аны ачыклап китү безгә җиһангирның нинди традицияләрне дәвам иттерүче булуын аңларга ярдәм итәр.

Чыңгыз хан үзе исән чакта ук яулап алынган һәм яулап алыначак җирләрне өч улы—Тули, Чагатай һәм Җучиларга мирас итеп калдыра. Ә дүртенче улы Үгедәй төп тәхеттә Монголиядә кала. Шул җирләрдән Төркестан, Мәвараэннәһер һәм Хәрәзем Чагатайга тия. Шул рәвешле гаять зур Чагатай олысы барлыкка килә. Бу олысның көнчыгышындагы далаларда күчмәләр яшәсә, Аму-Дәрья белән Сыр-Дәрья елгалары арасында урнашкан Мәвараэннәрһердә борын-борыннан халыклар утрак тормыш алып барганнар. Анда бай шәһәрләр күп, сәүдә, һөнәрчелек, мәдәният чәчәк ата. Бөек Ефәк юлы шушы төбәктән уза, транзит сәүдәсе калаларга зур табыш китерә.

1251 елда Монгол империясенең башкаласы Каракорымда булып узган корылтайда Алтын Урда ханы Бату булышлыгы белән Чыңгыз хан оныгы Мөнке бөтен империянең төп ханы—каган итеп сайлана һәм тәхеткә чыга. Бераздан Үгедәй белән Чагатай варислары Мөнке каганга каршылык күрсәтә башлыйлар. Көрәш кабынып китә. Үгедәй белән Чагатай варисларыннан байтак кеше юк ителә. Шул сәбәпле Чагатай олысының бер өлеше булган Мәвараэннәһер—Алтын Урда ханы Батуга, ул үлгәч, Бәркә хан кулына күчә.

Мөнке каган заманында (1251—1259) аның туганы Хулагу хан Иранны яулый, Багдад шәһәрен басып ала (1258), Габбасыйлар нәселен юк итә. Тәбриз каласын үз дәүләтенең башкаласы итеп сайлый. Шулай Алтын Урда күршесендә аңа дошманлык саклаган Хулагу хан дәүләте барлыкка килә.

Сәяси вәзгыять үзгәрүдән файдаланып, Чагатай варисларыннан Алгуй хан Мәвараэннәрһерне Алтын Урда ханнары кулыннан кире тартып алуга ирешә. Шулай итеп, мәдәниятле Мәвараэннәрһер калалары кабат күчмә монголлар кулына күчә. Ләкин аларны утрак тормыш, анда ныклап тамыр җәйгән ислам дине бөтенләй кызыксындырмый—бары тик калалардан, эшкәртелгән җирләрдән тиешле салымнар гына вакытында җыелып, аларга тапшырылып торсын. Алар Мәвараэннәрһерне Масудбәк атлы бер әмиргә идарә итәргә тапшырып, үзләре аның эшләренә кысылмаска тырышалар.

Әмма вакыт үз дигәнен эшли тора бит ул. Тора-бара Чагатай варисларыннан булган кайбер ханнар шәһәрләр йогынтысына бирелә, мөселман

мәдәниятенә, ислам диненә тартыла башлый. Тарихчылар билгеләп үткәнчә, шундыйларның берсе булган Мөбәрәкне хан итеп күтәрү тантанасы, мәсәлән, гадәттәгечә Җидесу төбәгендәге Или елгасы үзәнендә үткәрелмичә, утрак тормыш чәчәк аткан Мәвараэннәһердәге Ангрен суы буенда уздырыла. Тарихта булмаган хәл, йоланы бозу. Бу инде Чагатай йортыннан чыккан кайбер ханнарның күчмә тормышка караганда бай калаларны якынрак күрүен, үз итүен күрсәтүче ап-ачык билге була.

Инде кабат Тимер мирза тарихына әйләнеп кайтыйк. Аның туган барлас ыруы Мәвараэннәһергә нәкъ менә шушы чорда Мөбәрәк хан белән күчеп килә. Һәм Кашка-Дәрья үзәнендә урнашып кала. Шушы ук елларда бирегә җалаир ыруы да күчеп утыра. Алар яшәү урыны итеп Ангрен елгасы буйларын сайлыйлар. Шунысын да әйтергә кирәк, күчеп утырган монгол ырулары, әле Җидесуда яшәгән чакта ук, шактый төркиләшеп өлгергән булалар. Яна җирдә исә бу процесс тагын да тизрәк бара һәм берничә буын алмашуга алар инде монгол телен бөтенләй онызталар. Тимер мирза, мәсәлән, монгол телен инде бөтенләй белми, аның каравы төркичә һәм таҗикча бик оста сөйләшә.

Күреп торабыз, бай шәһәрләр йогынтысы Чагатай йортын эчтән таркатырга тотына, анда ике фирка-партия барлыкка килә. Берәүләре борыннан килгән дала йоласын сакларга, ана тугры калырга, ата-бабадан килгән гадәт буенча, бозыклык оясы булган калалардан ерак яшәргә чакырса, икенчеләре исә кала тормышының унайлыкларын татып өлгергән, транзит сәүдәсе аша кулга агылып кергән байлыкның нәрсә икәнен күргән, унайлы һәм матур итеп җиһазландырылган сарайларга, мунчаларга, чылтыр-чылтыр килеп арыклар агып торган җимеш бакчаларына күнеккән, искиткеч назлы җария кызлар, музыкантлар, шагыйрьләр, мөселман илләреннән килгән зыялылар белән аралашуны кырыс дала тормышына алыштыру акылсызлык дигән фикерне үзләштергән була. Шулай итеп, Чагатай йортында тормышка ике төрле карашта булган халык барлыкка килә. Җидесу монголлары иркә тормышка ияләшкән Мәвараэннәһер халкын өнәмәсә, утрак тормыштагы Мәвараэннәһер халкы дала батырларының тупаслыгыннан, гыйбадлыгыннан көлә торган булып китә. Бу хәл табигый рәвештә Чагатай олысының киләчәктә ике мөстәкыйль өлешкә бүленүенә китерә. Әлбәттә, бу процесс акрынлап, үз җае белән бара. Һәм Тимер мирза тарих мәйданына чыккан чакта Магулистан белән Мәвараэннәһер, чыннан да, ике мөстәкыйль ил-төбәк рәвешендә яши. Өстәвенә, бу вакытта Мәвараэннәһерне бер йодрыкка туплап торырлык көчле шәхес тә булмый, эреле-ваклы идарәчеләр бер-берсе белән дошманлашып, үзара тарткалашып, берәүгә дә баш бирмәскә тырышып, иркле сәясәт алып барырга омтылыр. Шулай XIY йөз уртасында, үзара тарткалашуларга чик куеп, бөтен Мәвараэннәһерне берләштерүче шәхескә тарихи ихтыяҗ туа. Мәйданга Тимер мирза фигурасы калкып чыгу язмышның барлыкка килгән әлеге ихтыяҗны канәгатьләндерүе булгандыр, дип уйларга кирәктер.

## Юлбасар мирза

Игътибар итик: соңрак чорда Тимер мирза хозурында яшәп, аның тормыш юлын, әмерләрен, яуларын көндәлеген язып барган рәсми тарихчыларның хезмәтләрендә җиһангирның яшь чагы турында без мәгълүматлар таба алмыйбыз. Аның тормыш юлын тасвирлау 1360 елдан гына башлана. Ә бу вакытта Тимергә инде 25 яшь була. Нәкъ шушы елда аның тормышында кискен борылыш була. Эш шунда ки, 1360 елда Магулистан ханы Туглук Тимер таркау яткан (димәк, көчсез!) Мәвараэннәһерне элеккечә Чагатай олысына китереп кушу өчен бирегә яу белән килә. Тик ул вакыйгаларга күчкәнче җиһангирның яшьлеген бераз яктыртып китү дөрес булыр дип уйлыйм.

Билгеле булганча, Тимер мирзаның вафатына бер ел калганда, ягъни 1404 елда, Кастилия короле Герих III тарафыннан Сәмәркандка Рюи

Гонзалес де Клавихо житәкчелегендә илчелек килә. Тимер мирза илчелекне бик жылы кабул итә. Клавихо Тимер мирза белән берничә тапкыр күрешә, әңгәмәләр кора, аның турында һәр ишеткән-белгәнен теркәп бара, башка калаларда да була, күп кеше белән сөйләшә. Кыскасы, 1404 елда илче тулысынча диярлек Тимер мирза хозурында яши, күп мәгълүмат җыя. Һәм, тарихчылар фикеренчә, бу гаять күзәтүчән һәм зыялы кешенең язганнары дөрескә туры килә икән.

Тимер мирзаның ялагай тарихчылары язмаганны шушы испан илчесе теркәп калдырган. Бу очракта безне җиһангирның яшь чагы кызыксындыра. Тимер мирза яшьтән үк ишләре арасында башлык-лидер сыйфатлары белән аерылып торган, кыю һәм тәвәккәл булганы өчен барлас ыруы яшьләре аңа тартылганнар. Шулай бер төркемгә тупланып алгач, яшьләр төрлечә «шаяра» башлаганнар. «Ул үзенең дүрт-биш нөгәре белән күршеләреннән бер көнне сарык, икенче көнне сыер чәлдерә башлаган»,—дип яза Клавихо. Ә инде аның төркеме үсә төшкәч, яшь Тимер углан күршеләренә барынтыга да йөри, үткән-сүткән кәрваннарны да талаштыра. Ләкин ул беркайчан да саранлык-кысмырлык күрсәтмәгән, тапкан малын нөгәрләре белән тигез бүлешкән. Бер яктан, бу аның абруен күтәрсә, икенче яктан, яңа кешеләрне дә аңа тарткан. Шулай аның төркеме (аны банда дип тә атап булыр иде!) 300 кешегә хәтле үсә. «Шул кадәр җайдак җыелгач, ул (Тимер) төрле җиргә барып, нәрсә туры килсә шуны урлау, талау белән шөгыльләнә, юлга чыгып, сәүдәгәрләрнең дә малларын тартып ала торган булып китә»,—дип өсти Клавихо.

Мәсьәләнең бу ягын белгәннән соң, аның рәсми тарихчыларының авызларына су капкандай, ни өчен җиһангирның яшьлеге хакында берни язмавын аңлый башлыйсың. Соң, Тимер мирза яшьлегендә юлбасар булган икән ләбаса! Бу хакта язу өчен ничек кулга каләм алмак кирәк...

Клавихо үзенең язмаларында Тимер мирзаның аксаклыгын да телгә алып уза һәм шундый хикәя китерә. Бер төнне Тимер мирза аркадашлары белән бер көтү сарыкны урлап алып кайтмакчы була. Бу вакыт мал хуҗалары килеп чыга да бәрелеш башлана. Тимер мирзаның байтак егетләре үтерелә, үзен дә атыннан сөйрәп төшерәләр, уң аягын, ике бармагын яралыйлар. Шул вакыйгадан соң ул гомергә аксак булып кала. Шунысы кызык: бу вакыйгаларны күренекле тарихчы Ибне Гарәпшаһ та үзенең Тимер мирза турындагы хезмәтендә китерә. Ул 1388 елда Димәшкъ шәһәрендә туып, 12 яшьлек малай чагында Җиһангирга әсирлеккә төшә, Сәмәркандка алып кителә. Үз гомерендә аңа күп җирләрдә, шул исәптән Хәрәземдә, Алтын Урда калаларыннан Сарайчыкта, Хаҗитарханда, Сарайда, Кырымда булырга туры килә. Узгынчы адәмнең гайбәте дип, без Клавихо хикәясен әле игътибарсыз да калдыра алган булыр идек, ләкин аксаклыкның сәбәбе турындагы шул ук сүзләрне гомерен Мәвараэннәһердә уздырган, андагы хәлләрне яхшы белгән Ибне Гарәпшаһ та кабатлагач, ышанмаска хакыбыз юк. Димәк, дөресе шул!

## Хан хезмәтендә

Тарихта эз калдырган шәхесләрнең тормыш юлын күздән кичергәндә, без даими кабатланып торучы бер күренешкә тап булабыз: аларның һәркайсына гомернең ниндидер бер дәверендә зур каршылыкларны җиңеп чыгарга, моның өчен гаять күп көч-куәт сарыф итәргә, тырышлык, түземлек, ихтыяр көче күрсәтергә туры килә. Тимер мирза тормышында исә андый чор 1360 елда башлана. Әйтелгәнчә, шушы елда Магулистан ханы Туглук Тимер таркау яткан Мәвараэннәһергә бәреп керә. Монда аңа каршылык күрсәтерлек бер әмир да табылмый. Ул шулай Кашка-Дәрья үзәненә үк килеп җитә, мондагы җирле идарәче Хаҗи Барлас та аңа каршы тора алмый.

Белгәнебезчә, Кашка-Дәрья үзәне Тимер мирзаның туган җире, аның ата-бабалары биредә моннан бер гасыр элек Җидесудан күчеп утырган.

Беренче яуда каршылыкка очрамаган Туглук Тимер хан бер елдан Мәвараэннәһергә яуны кабатларга була. Нигә әлеге бай төбәкне бөтенләй үзеннеке итмәскә? Табигый, бу юлы да аңа зур каршылык күрсәтүче табылмый. Ә Хажи Барлас, гомумән, Харасанга качып китүне кулайрак күрә.

Аксак Тимернең үзе исән чакта язылган биографиясендә бу хәлләр менә ничек яктыртылган: «Миңа 31 яшь тулды—диелә анда.—Чыңгыз хан оныгы Туглук Тимер Чете (Магулистан) өлкәсендә хан иде. Көннәрдән бер көнне ул Мәвараэннәһерне яулап алырга теләде, шулай Сыр-Дәрья буена Ходженттан ерак булмаган, Хак дип йөртелгән бер җиргә килеп урнашты да анда зур гаскәр туплады. Туглук Тимер миңа, Хажи Барласка һәм әмир Баязидка ярлыклар юллады. Бу ярлыкта, әйтергә кирәк, каршы килү мөмкинлеге калдырылмаган тон белән шундый әмер язылган иде: «Мин Туглук Тимер хакан, хакан углы, сиңа шуны боерам—тиз арада халкың белән миңа килеп кушыл».

Кыскасы, боерык алып, Хажи Барлас куркуга төште һәм киңәш сорап миңа мөрәҗәгать итте. Мин аңа бөек хакан белән араны бозмаска, буйсынып, аның карамагына барырга, шулай хаканның күнелен яулап алырга киңәш иттем. Хажи Барлас киңәшемне тотмады, халкы һәм бөтен мал-мөлкәте белән дәрья аша кичеп, Харасанга китеп барды. Әмир Баязид исә халкын ияртеп, зур бүләкләр белән Туглук Тимер хозурына юнәлде. Мин үзем дә Туглук Тимер хакан өчен бүләкләр әзерләргә керештем, тик бу вакыт атам әмир Тарагай бик нык авыртып китте, шул сәбәпле миңа атам янында калырга, вафатына кадәр аны багарга туры килде. Аннан соң атамны бер изге кабере тирәсенә зурлап җирләдем. Шул көннәрдә Туглук Тимердән миңа тагын бер ярлык килеп төште. Ул мине кабат үзенә чакыра иде. Әмма ыруым Туглук Тимергә буйсынырга теләмәде, синең кул астыңда илдә тынычлык урнашты, кирәк булса без кулга корал тотып бәйсезлегебезне саклап калырга әзербез, дип белдерде. Мин аларга: «Безгә Туглук Тимер белән бозылышырга һәм аңа каршы баш күтәрергә кирәк түгел, аңа буйсынудан башка чара юк»,—дип җавап бирдем.

Шулвакыт миңа Хажи Мәхмүд Шаһ идарәсендәге Туглук Тимер гаскәре бирегә таба хәрәкәт итә дигән хәбәр житкерделәр. Мин тиз арада халкымны туплалым да бүләкләр белән Туглук Тимерне каршы алырга, аңа үземнең буйсынуымны белдерергә ашыктым...»

Аксак Тимер үзенең хан белән очрашуын болай тасвирлый: «Мин Туглук Тимер өчен әзерләгән бүләкләремне аңа Ходжент тирәсендәге далада тапшырдым һәм ул минем буйсынуымнан бик канәгать калды. Бер көнне аңа алда барган гаскәр башлыкларының Мәвараэннәһер халкыннан байтак мал-мөлкәт тартып алуын килеп әйттеләр. Туглук Тимер тартып алынган әйберләрне ияләренә кире кайтарырга боерды. Ханның мондый әмерен гарьлек дип кабул иткән Магулистан әмирләре аңа каршы баш күтәрделәр. Бу хакта ишеткән Туглук Тимер, авыр хәлдән ничек чыгарга дип, миннән киңәш сорады. Мин аңа кире Чете (Магулистан) өлкәсенә китәргә киңәш иттем. Киңәшне ул хуплады һәм, мине Мәвараэннәһердә идарәче итеп калдырып, шул хакта ярлык та биреп, үзе Чете өлкәсенә кайтып китте. Шул көннән минем көчем-куәтем арта башлады, мин Мәвараэннәһернең барлык калаларын кулга төшердем һәм Шәһрисябзга юнәлдем».

Бу өзектә Тимер мирза тормышындагы кискен борылыш вакыты тасвирланганга без аны тулысынча китердек. Шулай итеп, ул зирәк сәясәтче булуы аркасында кинәт зур дәрәҗәгә ирешә. Ләкин монда кайбер төгәлсезлекләр дә бар шикелле. Текстта Тимер мирза исеменнән: «Миңа 31 яшь тулды» дип әйтелсә дә (алай булганда вакыйга 1367 елга карар иде), шәркыятьче-тарихчылар В. Бартольд белән А. Якубовский әлеге вакыйга 1361 елда булган дип саныйлар. Ә бу вакытта Тимергә 25 яшь кенә. Автобиография Тимер мирза хакимиятенең соңгы елларында язылып, вакыйгаларның төгәл елы аның хәтерендә буталган булуы да мөмкин.

Аннан соң бу елда Туглук Тимер хан аңа бөтен Мәвараэннәһерне калдырмыйча, бары тик качып киткән Хажи Барлас биләмәсен—Кашка-Дәрья

вилаятен генә идарә итәргә тапшыра. Автобиографиядә әйткәнчә, шушында ныклап тамыр җибәрү, ныгу аңа соңрак бөтен Мәвараэннәһер калаларын кулга төшерергә ярдәм итә. Кыскасы, Туглук Тимер хан ягына чыгу Тимер мирзага киләчәктә канат җәеп очар өчен бер трамплин ролен уйный.

Ул шушы чорда үзенә югарырак күтәрелергә ярдәм иткән әмир Хөсәен белән дә таныша. Хөсәен—Казаган бәкнең оныгы була. Чыңгызый булуына карамастан, аның бабасы Казаган бәк үзен беркайчан да хан итеп күтәрттерми. Алтын Урданың Мамай һәм Идегәй мирзалар кебек, тәхеткә күндәм ханнарны куеп, Мәвараэннәһердә алар исеменнән идарә итә (1346—1358). Аның вафатыннан соң бу төбәктә көчле хаким калмый. Шулай Тимер мирза абруйлы чыңгызый әмир Хөсәен белән якыная, хәтта аның сеңлесе Улҗай Теркен-агага өйләнеп, аның белән туганлашып та китә. Чыңгыз нәселе белән туганлашу аның абруен үстереп җибәрә. Әмир Хөсәен исә Бәлх каласы һәм шул исемне йөрткән вилаятьнең бер өлешен кулында тота. Шулай Мәвараэннәһердә ике гайрәтле әмир барлыкка килә. Дөрес, булачак вакыйгаларга күз ташласак, бу берләшүнең нигезендә ниндидер зур эшләр башкару нияте ятмавын күрәбез. Хөсәен белән Тимер мирзаны болганчык һәм хәтәр заманда бер-беренә терәк булу ихтыяҗы гына берләштергән, ахрысы.

Кашка-Дәрья вилаятен кулдан ычкындырган Хаҗи Барлас үз биләмәләренә хуҗа булган Тимер мирзаны куып җибәрү өчен төрле чаралар күрә башлый. Автобиографиядә бу хәлләр менә ничек тасвирлана: «Миңа билгеле булганча, әмирләр Хаҗи Барлас белән Баязид (җалаир ыруыннан), үзара илчеләр алмашып, көч берләшү һәм мине үтерү өчен килешү төзегәннәр. Ә бит әмир Хаҗи Барлас миңа туган тиешле кеше!

Мин аңа хат язып җибәрдем, анда үзебезнең туганнар булуыбызны һәм дә аңа күрсәткән хезмәтләремне исенә төшердем. Ләкин әмир Хаҗи Барлас минем хатка илтифат итмәде. Шуннан соң мин гаскәремне әмир Хөсәен белән кушылу өчен алып киттем, ләкин Хаҗи Барлас минем юлымны кисте. Аккаба Чагатай дигән

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ
## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Аяз Гыйләҗев,**

*Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты.*

## ЮЛ БАШЫНДА НУРЛЫ ЯКТЫЛЫК УЛ...



*Зиһен ачыклыгы бетте. Әле ярый үткәнемне хәтергә төшерерлек хатирәләрем-хатларым сакланган. Мин шулар белән сөйләшеп бәхетле, уйлы, фикерле елларымны, мизгелләремне күз алдыма китерәм.*

*Бишенче ел таңында уянган ан егерменче гасыр буенча туктаусыз дәвам иткән кырылышлардан татарны саклап калган. Татарны бөек милләт итеп раслаган бишенче ел әле бүген дә безгә көч-гайрәт өстәп тора. «Казан утлары»ның чыга башлау тарихы асылда шуңа барып тоташа да...*

*Татар—зур милләт: бар аның тоқымы мәгърур кыпчаклардан килә торган ишле мишәре, дөнья тарихында нугай дип аталып сенеп калган икенче бер тармагы бар, әлегәчә тарихы әдәбиятта тиешле бәя таба алмаган данлы Күчем хан дәвамчылары—Себер татарлары бар. Әле без белмәгән, язмышлары урыс казаклары станына барып ялганган «татар казаклары» да булган. Мәшһүр режиссерыбыз, бүген нигәдер күзебездән китеп торган, картлыгында да егетлеген саклаган, яшьләргә күп акыл биргән тынгысыз Габдулла ага Йосыпов үзенең «татар казагы» булуы белән чиксез горурлана иде. Һәм шушы без белмәгән, күрмәгән*

жирдә безнең арада сугыш булды. Мин гаскәрне 7 өлешкә бүлдем дә һәр көнне аның жиделән берен сугышка кертә башладым. Әмир Хызыр белән аның баһадирларын уң кулга урнаштырдым, әмир Жагуй Барлас исә сул кулга басты. Үзем белән Шәһрисябздан килгән гаскәрне дүрт өлешкә бүлдем. Идарәне үз кулыма алып, көн саен гаскәрнен дүрттән берен орышка кертә тордым. Өч көн шулай орышкач, дүртенче көндә, голәмәләр белән сәедләрнең хәерфатихасын алып, Аллаһны ярдәмгә чакырдым һәм төн карасында, дошман йокыга талган чакта гаскәремне аның өстенә ташладым. Орыш төне буе дәвам итте, көн туганда жиңү минем якта иде. Дошман гаскәре таралып бетте, әмир Хажи Барлас исә Сәмәркандка качып китте дә әмир Баязид-жалаир канат астына барып сыенды».

Моннан соң әле тагын бер бәрелеш була, анысында да Тимер мирза жинеп чыга: «Шушы хәлләрдән соң әмирләр Баязид һәм Хажи Барлас үзара хатлар алышалар да хәйләле тозак корып мине үтерергә булалар. Әмир Хызыр *(Тимер мирзаның дошман ягына чыккан әмире—С. Ш.)* белән бәрелешкәннән соң берничә көн үткәч, әмир Баязид Сәмәркандтан гаскәр белән чыга да, далага житеп, Шаш (Ташкент) янында туктала. Әмир Хажи Барлас, әмир Баязид белән бер сүздә булып, мина шундый эчтәлекле хат жибәрде: «Без, бөек әмир дусларының дуслары һәм дә аның дошманнарының дошманнары, Ходжент каласын кулга төшерергә карар кылдык. Әгәр дә син безнең дуслыкка, тугрылыкка ышансаң, безгә кушыл. Бу барыбыз өчен дә файдалы булачак».

Аларның нияте мине алдап кулга төшерү һәм юк итү булган. Мин, мөэмин-мөселман буларак, сүзләренә ышандым, гаскәремне алар белән кушылырга алып киттем. Алар туктал-ган жиргә килеп житәрәк мин шуна игътибар иттем: тирмәләр куелган урда уртасында бик зур чатыр корылган иде. «Бу мине каршылар өчен корыл-ган инде»,—дип уйлап алдым. Мине зур хөрмәт белән каршы алдылар һәм чатыр эченә чакырдылар. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән мин шунда дошманнарымның ниятен сизеп алдым: чатыр эченә керү белән анда әмир

*татар кабиләсе Ибраһим Салахов тарафыннан татар әдәбиятына, татар дөньясына «Казан утлары» аша «Иманнар тамыр жәйгәндә» романы булып килеп керде. Ибраһим Салахов үзе Балтач ягы тумасы, язмыш аны Күкчәтау далаларына илтеп ташлый һәм ул шул якнын атаклы улына әверелә. Ул татар казакларынын тормышын, көн-күрешен, гореф-гадәтләрен, гаскәргә озату йолаларын, Сабан туйларын, сөю-сөешүләрен, татулыгын, сугышчанлыгын ышандырырлык вакыйгалар аша ачып бирде.*

*«Иманнар тамыр жәйгәндә»—октябрь алды чорын бәян иткән бу роман исеменен сере бик гади, фажигасе чамасыз авыр... Бу роман—сабыйларча өмет баглаган большевизмнын казакларны һәлакәткә илткән авыр юл турында булып чыга. Ленин-Сталин корган дәүләт бераүне дә, шул жөмләдән, иманнар булып совет властена иннәрен куйган гади большевикларны да аямый. Заман Ибраһим Салаховнын үзен дә ялмап йота...*

(Ибраһим Салахов язган хатлардан).

*«... февраль 1985 ел. Сөенечләр бар! Миркасыйм Усманов романынны («Иманнар тамыр жәйгәндә») бик ошаткан. Бик әйбәт рецензия язды. Сонра, мин кульязманы карап бетергәч сина жибәрмен. Журналда Рашат Низамиев укып чыкты. «Роман-повестьлар алдымда богыл булып өелеп ята, арада моннан да шәбе юк!» диде. Редактор белән дә, урынбасары белән дә сөйләштем, журналнын өч санында 350 бит чамасы басарга булдылар. Миркасыйм бик жентекләп укыган, байтак тәкъдимнәре, фикерләре бар. Бүгеннән шуна утырам, Тел ягын карап, иплэп-сиплэп ашыгыч рәвештә журналга да тапшырачакмын. Эш шактый. Тик авырыксынмыйм, яратып эшләдем, роман иптәшләргә дә ошагач күнел күтәрелеп китте, сезгә ихтирамым артты!*

*Журналда 350 бит яулап алу—бу зур жинү, Ибраһим ага!..»*

*Роман 85 нче елнын 11. 12 саннарында басылып чыкканнан сон, Гариф Ахунов идарә утырышында ялкынланып: «Журналда Ибраһим Салаховнын романы басыла башлады, беренче өлеше гениально шэп, дип чыккан. Бу да бит хәзерге көн өчен тарих сахифәсе булып калып килә.*

*Еллар елга кебек ага тора. Шәхесләр алмаша, журнал яши...*

Баязидны, сулда әмир Хаҗи Барласны күреп алып, мәҗлестән соң болар мине үтерергә җыеналар, ахрысы, дип уйлап алдым. Үземә янаган хәвефтән бик нык шомланган хәлдә күңелдән Аллаһы Тәгаләнең мине үлемнән коткаруын сорадым. Шул вакыт нилектәндер борынымнан кан китте, һәм мин, шуны сәбәп итеп, чатырдан тизрәк чыгарга ашыктым. Чыгу белән көтеп торган нөгәрләремә миңа куркыныч янавын белдердем, тиз генә атка сикереп мендем. Мине туктатырга берәү дә җөрьәт итмәде. Шулай Аллаһы Тәгалә мине үлемнән йолып калды».

Хакимият атын иярләп өлгергәнче Тимер мирзага мондый хәтәр хәлләр аша күп тапкырлар чыгарга туры килә. Автобиографиясендә Тимер мирза Мәвараэннәһердә тынычлык булмавын, әмирләрнең, эреле-ваклы хакимнәрнең үзара гел сугышып торуын һәм шул сәбәпле халыкның күп зыян күрүен еш телгә ала. Бу хәлләрдән туйган халык аңа: «Бөек әмир идарә итә белүе һәм дә батырлыгы белән илнең тулы хокуклы хакиме булсын иде»,- дип мөрәҗәгать иткән, имеш, һәм шуннан соң гына Тимер мирза Чыңгыз хан оныгы Туглук Тимергә хат юллаган, анда Мәвараэннәһердәге хәлләрне тасвирлап биргәннән соң ханның яу белән килүен, илдә тәртип урнаштыруын үтенеп сораган. Чыннан да, бу хәлнең булуы мөмкин, чөнки Тимер мирзаның Туглык Тимер ханның ышанычын яулавын, Кашка-Дәрьяда хаким итеп билгеләнүен без инде күрдек. Моннан бер нәрсә ап-ачык күренеп тора— Тимер мирза, монголларны чакырып китереп, алар кулы белән башка әмирләрне буйсындырырга, үзе биредә хуҗа булып калырга омтылганга охшый.

Чыннан да, Тимер мирзаның мөрәҗәгате эзсез калмый. Туглук Тимер хан тиз генә гаскәр җыя да яу белән Ходжент каласы тирәсенә килеп урнаша, Тимер мирзаны үз хозурына чакыра.

Сәмәркәнд әмире Баязид, каланың капкаларын бикләтеп, үзе Туглук Тимер хан карамагына юнәлә. Килеп җиткәч тә хан аннан Сәмәркандның ачкычларын тапшыруын таләп итә, тик әмир Баязид шул вакыт бер хата җибәрә—ачкычларны бирергәме-юкмы дигәндәй, уйга кала, сорагач та

*«25 ноябрь 1987 ел. ... Истәлекләрен («Тайгак кичү») 4, 5, 6 саннарга керә дип торабыз. Беренче өлешен Тәүфикъ Әйди редакцияләп китергән. Иншалла, һәммәсе жай гына барса кирәк. Башлангыч өлешен мина да укытып карадылар. Искиткеч нәрсә булачак! Татар укучысының күзен татарча басылган житди әсәрләр дә ачарга тиеш! Халкыбызның язмышын үзебез язып, әдәбиятта беркетеп калдырмасак, бүгеннән дөнья тәртәсе арасына жигелергә торган киләчәк буын, телебезне ярым-йорты гына белүче буын, безнең татарча кайгырганны, татарча көенгәнне аңлый алырмы соң? Бәби тапканда хатыннар әнкәләре телендә ыңгырашсалар, читен чакта ирләр үз телләрендә дога укыйлар диләр ич...»*

*1965 елның декабрендә Фатих Хөсни, Шәүкәт Галиев һәм мин Себер якларына барып чыктык. Максатыбызның ин зурысы: журналның эшчәнлеге белән таныштыру булса, икенчесе—аннан да зуррагы минем өчен ул вакытта—ныклап Себер тарихын өйрәнергә керешү иде. Түбән өлкәсенен Тубыл районы Хужайлан авылында очрашуларда катнашканнан сон, шул төбәкнең күренекле педагогы, күнеле белән гомере буе язучылыкка талпынган сөйкемле зат Якуб Зәнкиев белән ныклап таныштык. Аның белән шул очрашудан башланган элемтәбез бүгенге көндә дә дәвам итә. Үзем шул танышлыкны ныгыту өчен 1966 елның август аенда Себер якларына бардым. Якуб Зәнкиевнең язучы булып китәсе килә, ә минем Себер татарлары турында күбрәк беләсем килә...*

*Якуб Зәнкиев Күчем хан нәселе булган Себер татарларына бәйләнешле вакыйгаларны «Иртеш таннары» романында яктыртып, безне—Казан татарларын да ул өлкә белән тоташтырды. Бу тоташтыручы жеп сапламының башы Якуб ага кулында булган булса, аны элмәкләп бәйләүчесе «Казан утлары» булды. Язучылыкка талпынган чагында Зәнкиев «Иртеш таннары»н ижат иткән булса, тагын да дәртләнеп китеп инде чын язучы исемен алгач, «Өтелгән мәхәббәт»не «Казан утлары»нда бастырып, безне сөендерде.*

*Инде килеп фактларга мөрәжәгать итсәк...*

*«... 9 январь, 1966 ел... Якуб ага, быел бик шатлыклы хәл, татарча газета-журналларның тиражы бик нык артты. 20*

чыгарып бирми. Моны күреп торган хан аның башын кистерә дә Сәмәркад халкына озата. Шулай Тимер мирза хан кулы белән бер көчле дошманыннан арына.

Бу хәлләрне ишетеп алган Хажи Барлас куркуга төшә, ашыгычлык белән Аму-Дәрьяны кичеп, качып китә. Хан аның артыннан эзәрлекләр өчен отряд җибәрә. Качучылар байтак кешеләрен югалта-югалта, ниһаять, хан гаскәреннән аерылалар. Харши-Жучи дип аталган кечкенә генә бер калада урнашалар. Әмма бераздан мондагы халык белән Хажи Барлас кешеләре арасында низаглар килеп чыга, аннан бәрелешләр дә башлана, бер сугышта Хажи Барлас үзе һәм берничә туганы үтерелә. «Исән калган килмешәкләр шушы калада торып калдылар, тора-бара җирле халык белән кушылып беттеләр. Соңрак, Харасанны кулга төшергәч, мин Харши-Жучи каласын Хажи Барлас варисларына мирас итеп бирдем»,—диелә Автобиографиядә. Хажи Барлас Тимер мирзаның туганы икәнне дә онытмыйк. Шулай итеп, Тимер мирза икенче көндәшеннән дә котыла.

Бу вакыйгалар барганда Тимер мирза әле Туглук Тимер хан хозурында булмый, ул һаман вакытны суза. Менә ханнан аны үзенә чакырткан икенче хат килеп төшә. Бу юлы инде ул хан хозурына бармый кала алмый. Тик юлга чыгып киткәнче бер хәйләле эш башкара, тирә-юньдәге ыруларга хатлар юллап, Туглук Тимер яу белән килергә җыена, мине үзенә таләп итә. Әгәр дә малларыгыз исән калсын дисәгез, аңа тапшыру өчен миңа бүләкләр китерегез, дип хәбәр тарата. Күп тә үтми ырулардан күп бүләкләр китерәләр. Тимер мирза җыелган байлык белән юлга чыга. Ходжент каласында ул бүләкләрне ханга тапшыра, аның якын кешесенә әверелә. Шик юк, бүләкләрнең күпчелек өлеше башка ырулардан җыелуын ул ханга әйтеп тормагандыр. «Берәр хәл килеп чыкканда, хан гел миннән киңәш сорый иде. Мин аңа Мәвәраэннәһердәге изге ниятле адәмнәргә ярдәм кулы сузарга киңәш иттем, ә явызлар гамәлләре белән үз-үзләрен болай да кыен хәлгә куячаклар, ни чәчсәләр, шуны урачаклар, дидем»,—диелә Автобиографиядә. Бу сүзләрнең ни өчен әйтелгәнен укучы чамалый

*мен белән чыгып килгән «Казан утлары» быел 34 меңнән артыграк тарала. 25 меңле «Ялкын» журналы 40 меңгә җитте. «Азат хатын» журналының тиражы 200 мең чамасы. Бик сөенечле хәбәрләр!*

*Халкыбызның рухи ихтыяжы арта, милләтебезнең киләчәге зур! Без, язучылар, моңа куанмый булдыра алмыйбыз...*

*Минем Төмәнгә барасымны белеп, иптәшләр ярдәм итәргә торалар, киңәшләр, эшләр йөклиләр. Әле карт журналистыбыз Исмәгыйль Рәми Янбай авылындагы элек яшәгән бер меценат турында кызыклы гына мәгълүматлар язып бирергә булды. Кыскасы, мин август аенда сезгә барам дип кызып йөрим... Юри генә белешегез әле: сезнең авылда татар журналлары ничә данә тарала икән?..»*

*Көндәлектән...*

*«Себер Хуҗайлан. Август, 1966 ел. Кичәге көн бик күп җанлы әңгәмәләр белән узды. Бик карт бер бабай белән сөйләшеп утырдык. Хуҗайланның үзендә өч төрле халык яши икән: йомышлылар, ясаклылар һәм ярлы Бохар сартлары. Якуб агай да үзенең тумасы белән нәкъ шул ярлы, җирсез Бохар сарты икән. Без сөйләшкән бабай да нәкъ шул нәселдән булып, үзенең элекке елларда никадәр нужа чигүен, ясаклыларга, йомышлыларга ничек хезмәт күрсәтүен, Омскига, башка шәһәрләргә олау-олау балык ташып, аннан кәҗә тиресе төяп кайтуларын сөйләп утырды...»*

*«... 5 сентябрь 1980 ел. Якуб ага!.. Еллар куа. Сәгатьләр куа. «Татар халкы алай, татар халкы болай», дип кулны шомарган чалбар кесәсенә тыгып, махра тартып, матбугат йорты коридорында эре генә йөреп тору җинел ул! Сүздә түгел, эштә ярышырга кирәк. «Литературная газета» да соңгы еллардагы татар прозасы турында профессор Ибраһим Нуруллин мәкаләсе чыкты. Журналыбызның тиражын 80 мең дип күрсәткән. Мин аннан «нигә шулай ындырт меңгә киметтең?» дип сораган идем, «хәзергә кадәр уңайсызланам, карамаганмын, сиксән мең дип күңелгә кереп калган, хәзергесен карамаганмын» диде. Бик гыйбрәтле сүзләр! «Күңеленә кереп калган, хәзергесен карамаган!» Журналның тиражын гына түгел, татар прозасының бүгенге торышын да чөнки «кайчандыр, кайдадыр!» аның күңеленә «нидер» кереп калган! Ә проза үсә! Карагыз инде, М. Мәһдиев повестьларын!*

торгандыр. «Туглук Тимер хан Мәвараэннәһерне, Шәһрисябз, Шибирганат һәм Бәлх вилаятенә кадәр сузылган башка җирләрне минем карамакка тапшырды»,—дип тә өстәлә шул ук Автобиографиядә. Шулай итеп, Тимер мирза Туглук Тимер ханның биредәге ышанычлы ярдәмче-хакименә әверелә.

Шул көннәрдә ханга бер сәер хәбәр килеп җитә: имеш, әмир Хөсәен зур гаскәр белән Вахш суы буенда тукталган да Туглук Тимергә һөҗүм итәргә җыена икән. Моны ишетеп, хан бик нык гаҗәпләнә: ничек инде ниндидер бер әмир Магулистан ханына каршы яу белән килергә җөрьәт итсен?! Бу хәлдән дә Тимер мирза үзенә файда таба. Ул ханга мондый киңәш бирә: әмир Хөсәеннең гаскәр башы Кайхисрау Җиләни исемле адәмгә хат язып җибәрергә дә, әгәр әмир Хөсәенне ташлап китсәң, ныгытмалардан Шадман белән Хутланны сиңа бирермен, дип ышандырырга кирәк. Бәлки безнең якка чыгар, ди Тимер мирза ханга.

Хан киңәшне кабул итә, хат җибәрелә. Ике гаскәр яу кырында очрашкач, Кайхисрау идарәсендәге мангай кул (авангард) кинәт Туглук Тимер хан ягына чыга. Бу хәлне күргән әмир Хөсәен сугышчылары куркып кала, аннан тәртипсез рәвештә качарга тотына. Хан гаскәре аларны таратып бетергәнче эзәрлекләп бара. Шулай итеп, Тимер мирза каенагасы әмир Хөсәенгә дә астыртын зыян сала. Икенче төрле итеп әйткәндә, Тимер мирза юлында торган һәр кешене төрле ысуллар белән алып ташлау сәясәтен эзлекле рәвештә үткәреп килә.

Әмир Хөсәен белән эшне төгәлләгәч, Туглук Тимер хан Сәмәркандка килә, анда шәһәр әмире Баян Салдурның башын кистерә, аннан соң Мәвараэннәһернең башка шәһәрләрендә дә тәртип урнаштыра. Әлбәттә, бу вакытта Тимер мирза гел хан янында була, аның төрле әмерләрен башкарып йөри, сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Бу эшләр тәмамлангач, ханны ничек тә Мәвараэннәһердән ераккарак озату нияте белән ул аңа күршедәге Харасан өлкәсен яуларга киңәш итә. Бу күп көч таләп итмәячәк, бары Аму-Дәрьяны гына кичәсе, ди. Туглук Тимер бу киңәшне кабул итеп, тормышка

*Күрегез Миргазиян Юныс әсәрләрен! Мин күптән түгел генә Миргазиян Юнысның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» исемле яңа повестын укыдым. Бөек әсәр! Имгәнмичә генә басылып чыкса кана!.. Ә А. Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...»е. Сез әсәрне ашыгып укыгансыз. Юл арасына бер дә күз салмагансыз. Әсәр алай тиз аңлашыла торган түгел. Гади әсәр түгел ул! Әгәр шулай әйтергә ярәса, мин аны «Өч аршын җир» белән тиң куям һәм бүгенге көнгә татар прозасының иң югары казанышларыннан берсе дип исәплим. «Ай да Пушкин, ай да молодец!» Никадәрле кыссалар да, изсәләр дә мин үз сукмагымнан барам һәм ул юлдан тайпылырга җыенмыйм да!..»*

*Шәхсән үземә килгәндә, «Казан утлары» минем өчен иҗатымның юл башында торган нурлы яктылык ул!*

*1963 нче елның 5, 6 саннарында «Өч аршын җир» повестым басылды. Шуннан соң 19 ел үткәч кенә яңадан китапка кертелү хокукы алуга ирешкән әсәрне басарга җөрьәт иткән журналга мин рәхмәтләремнең иң зурысын әйтергә бурычлымын.*

*Якуб Зәнкиевкә бу хакта да хәбәр иткәнмен. «Февраль, 1982 ел. «Өч аршын җир», ниһаять, китап булып басылып чыкты. Бүген шул китапны сезгә салам. Ниһаять, дим, егерме ел тинтерәттеләр шул повестьның башын! Егерме ел! Әгәр шул чакны, эш башында мине чалып екмаган булсалар, бәлки мин бераз кыюрак, нәтиҗәлерәк язган булыр идем!..» Шулай уйлаганмын. Хәзер дә шулай уйлыйм. Татар халкына аң-белем, зыялылык өстәрлек, дөньяга киң колачлы фикере белән балкый алырлык әсәрләр язсыннар иде язучыларыбыз! Бергә булыйк, татарлар, берләшегез!*

ашырырга гына торганда хан урдасына күтелмәгән хәбәр килеп төшә. Магулистандагы әмирләр ханга каршы баш күтәргәннәр, тәхеткә Тамлики ханны утырткannар. Әлбәттә, Туглук Тимер ханга ашыгычлык белән Җидесуга кайтып китәргә, анда үз тәхетен кайтару эшләре белән шөгыльләнергә кирәк була. Ул, махсус ярлык яздырып, улы Ильяс Хуҗаны Мәвараэннәһердә хаким итеп билгели, ә Тимер мирзаны аның беренче ярдәмчесе итеп күтәрә. «Туглук Тимер миңа тимер такта күрсәтте,—диелә Автобиографиядә,—анда бабаларыбыз Качули баһадир белән Кабил ханнарның килешенге бер шарты язылган иде. Ул шарт буенча, Качули баһадир варислары һәрвакыт гаскәр башы итеп билгеләнергә, ә Кабил хан варислары атадан угылга хан дәрәҗәсен тапшырырга тиешләр иде».

Табигый, монарчы гел атасы күләгәсендә йөргән Ильяс Хуҗаның идарә эшләрендә тәҗрибәсе җитешми, шуңа Туглук Тимер хан китеп барганнан соң аның кул астындагы кешеләр бик нык иркенлеккә чыгалар, җирле халыкны җәберли башлыйлар. Көннәрдән бер көнне Сәмәркандтан 400 кызны җыеп алып китәләр, ислам динен сөймәгән Магулистан магуллары (Тимер мирза аларны «үзбәкләр» дип атый) мулла-мунтагайга, дин әһелләренә дә көн күрсәтмәгән, ахрысы, чөнки Автобиографиядә Тимер мирза исеменнән «иң элек мин үзбәкләр кулыннан 70 сәедне азат иттем», диелә. Кыскасы, Тимер мирза, җирле халыкны яклап, Ильяс Хуҗа белән каршылыкка керә.

## Сынау артыннан сынау...

Аның дошманнары, шуны гына көткәндәй, Туглук Тимер ханга шикаять язып җибәрәләр: янәсе, Тимер мирза хан галиҗәнапларына каршы баш күтәрде, Ильяс Хуҗаны үтерергә җыена. Хәер, моның дөрес булуы да бик мөмкин, чөнки Тимер мирзаның, хан улыннан арынып, дилбегәне үз кулына алырга омтылуы бик табигый хәл. Тәҗрибәсез һәм акыл ягыннан үзеннән күпкә түбән ханзадә кул астында йөрү аңа җиңел булмагандыр. Кыскасы, хәлләр гаять куерып китеп, Туглук Тимер хан Тимер мирзаны тотып үтерергә боера. Тик бу фәрман «очраклы» рәвештә Тимер мирзаның үз кулына килеп эләгә. Шулай ул серне белеп ала, саклану чараларын күрә. Бераздан үтерүне таләп итеп ханнан бер-бер артлы тагын ике фәрман килә. Ләкин Тимер мирзаны үтерергә дошманнарына һаман җай чыкмый. Ахыр чиктә Тимер мирза Сәмәрканд ягына качып китәргә мәҗбүр була, бераз вакыт анда таулар арасында яши. Шул вакыт рухани остазы аңа Хәрәзем тирәсенә китәргә, эз югалтырга киңәш итә. Тимер мирза тиз арада китеп югала.

Шул көннәрдә ул каенагасы әмир Хөсәен белән кабат очраша. Ул да гаскәре тар-мар ителгәннән соң качып йөри икән. Алар үзара килешү төзергә, көчләрне бергә тупларга булалар. Хәрәземгә юнәләләр, анда өлкә әмиренең ныгытмасын тартып алырга ниятлиләр. Тик юлда аларны Ильяс Хуҗа тарафыннан җибәрелгән 1 мең кешелек отряд куып җитә. Болар исә кешеләрен санап карасалар, көчләре бары тик 60 кеше генә икәнне ачыклыйлар. Аяусыз бәрелеш була. Тимер мирза сүзләренчә, аларда 60 кешелән 7, ә дошманның 1000 кешесеннән бары 50 кешесе генә исән кала. Шушы 50 кешелек отряд аларны эзәрлекли башлый, болар исә җаядан ата-ата дошманнан аерылырга тырышалар. Хәрәзем җирләренә җиткәч, ниһаять, дошман артта кала. Бу вакыйгада бер деталь игътибарны җәлеп итә: «Хөсәеннең аты үлде, аңа хатыны Дильшат-ага атыннан файдаланырга туры килде, ә аны мин үз хатыным, Хөсәеннең сеңлесе атына утырттым»,—диелә Автобиографиядә. Димәк, бу бәрелешләр вакытында гаиләләре дә алар белән булган.

Менә куа килгән дошманнан аерылгач, алар бер кое янында туктыйлар. Бер көтүчедән ике сарык сатып алып, тамакларын туйдыралар, шушында ике көн ял итәләр. Тик бер килмәсә килми бит ул—монда да аларны бер аяныч хәл көтә. Юлда аларга ияргән өч кеше төнлә белән өч атны урлап кача. Шуның аркасында Тимер мирзаның хатыны белән сеңлесенә юлны җәяү дәвам иттерергә туры килә.

Шушы хәлләрдән соң Тимер мирзаның болай да мажараларга бай тормышы тагын да катлауланып китә, хәтта, әйтергә мөмкин, аның тормышы кыл өстендә кала. Эш шунда ки, бара торгач, алар төркмәннәр яшәгән бик тә аулак бер жиргә килеп чыгалар. Тегеләр юлчыларны угрылыкта йөрүчеләр дип уйлап, кинәт һөҗүм итәләр, болар исә, хатын-кызларны уртага алып, жан-фәрман сугыша башлыйлар. Шул вакыт төркмәннәрдән берәү Тимер мирзаны танып ала, бәрелешне туктата. Бу элек Тимер мирзада хезмәт иткән Сәет Мөхәммәд Хажи исемле адәм булып чыга. Тимер мирзаның Мәвараэннәһер әмире булуын аңлаткач, төркмәннәр түбәнчелек белән гафу үтенәләр, өч көн буе боларны кунак итәләр. Киткәндә күп итеп азык-төлек бирәләр, ун кешелек отряд боларны бераз озата да бара.

Ләкин мажаралар әле моның белән генә бетми. Өч көннән юлчылар Мәхмүди дип аталган жиргә килеп житәләр, монда берничә көн туктталырга булалар. Бәлки, аларны бәрелешләр вакытында артта калган кешеләре куып житәр?

Бу вакыт төркмәннәр арасында шундый хәбәр тарала: имеш, Тимер мирза гаскәре белән Мәхмүди дигән жиргә килеп туктаган. Бу хәбәр төркмәнбашы әмир Алибәк Жаны-Курбанига да килеп ирешә. Ул төнне боларга һөҗүм итәргә куша. Чыннан да, йоклаган чакта мосафирларны әсир итәләр, бәйләп, әмир хозурына китерәләр. Ләкин тегесе сорау алып та тормыйча тоткыннарны зинданга яптыра. Ә зиндан дигәннәре хәшәрәтләр белән тулы тирән чокыр була. Автобиографиядә: «Мин үзем һәм хатыным, Хөсәеннең сеңлесе, шушы зинданда газаплы һәм озын илле көн утырдык»,— дип язылса да, тарихчылар ачыклаганча, ул анда 62 көн утырган.

Шунысы кызык: бу сынау Тимер мирзада гомерлек эз калдыра, аны күп уйланырга мәҗбүр итә. Бу очракта аның үз сүзләрен китерү ышанычлырак булыр: «Төрмәдә утырган чакта мин Аллаһы Тәгаләгә, бөтенесен ачыклап бетермичә, беркемне дә төрмәгә утыртмам дип ныклы сүз бирдем. Бу фажига вакытында мин шундый фикергә килдем: миңа берәр көтелмәгән, гадәттән тыш адым ясап, ничек тә булса төрмәдән чыгарга да сугышырга кирәк. Максатка ирешсәм, шуның белән теләгем тормышка ашар, әгәр инде иреккә чыга алмасам, мине үтерерләр һәм жирләр өчен мине моннан алып чыгарлар, шулай мин барыбер якты дөньяга чыгармын. Димәк, ничек кенә булмасын, якты дөньяны күрер өчен барыбер тәвәккәлләп карарга кирәк».

Шулай Тимер мирза ниятен тормышка ашыру эшенә керешә. Качарга ярдәм итсәләр зур бүләкләр бирергә ышандырып, ул берничә төрмә хезмәткәрен үз ягына аудара, алардан кылыч алуга ирешә. Һәм, жаен туры китереп, сакчыларга һөҗүм итә. Күрәсен, иреккә чыгу теләге анда шундый көчле булган, ярсып өсләренә ташланган тоткынны туктатырга берәүнең дә хәленнән килмәгән. Тирә-юньдә «качты, качты» дип кычкыра башлыйлар. «Мина бу эшем өчен оят булып китте. Мин туп-туры Алибәк Жаны-Курбани янына киттем. Иреккә чыгу өчен миңа нинди киртәләр узарга туры килгәнен белеп, анарда батырлыкка хөрмәт уянды һәм ул уңайсызланып калды»,—диелә Автобиографиядә. Әлбәттә, бу вакыйга нәкъ шулай булгадыр дип әйтүе кыен. Сонрак, Автобиография язылганда, аның шомартып-матурлап тасвирлануы да бик ихтимал. Әмма Тимер мирзаның тоткынлыктан иреккә чыгуы тарихчылар тарафыннан расланган факт.

Ләкин Тимер мирзаның мажаралары моның белән генә тәгалләнми. Иреккә чыккач, ул Хәрәзем даласына юнәлә. Монда кабат төркмәннәр белән очраша—арада тагын Тимер мирзаны таныган кеше табыла, шулай кан коелмый кала. Алай гына да түгел, Әхмәд исемле төркмән, ырудашларын үгетләп, Тимер мирзага 50 жайдак бирергә күндерә. Шул вакыт, күк капусы ачылгандай, ана төрле яктан отрядлар килеп кушыла башлый. Бу факт шулай ук Тимер мирзаның халык арасында абруе зур булуын күрсәтә, чөнки ул кулга төшкән табышны гадел итеп бүлә белгән, беркайчан да малга-акчага кызыкмаган. Моны сугышчылар да яхшы белгән.

Әлбәттә, болай кангырып йөрү озак дәвам итә алмый, үзен хөрмәт иткән идарәче мона тизрәк чик куярга тырыша. Әйтергә кирәк, бу вакыт

Тимер мирза тирәсенә йогынтылы әмирләр, баһадирлар туплана—барысы да килмешәк Ильяс Хужага оппозициядә торучылар. «Мин Мәвараэннәһерне кулга төшерергә өметләндем, шул сәбәпле Кеш каласына 200 жайдак жибәрдем, ә үзем ыруыма барып, гаскәр тупларга ниятләдем.—диелә Автобиографиядә.—Ил гизүче дәрвиш-каляндар киеме киеп, ыруыма юнәлдем».

Шулай итеп, Тимер мирза үз ыруы барласларга килеп, 1 мең кешелек отряд туплый, аннан Сәмәрканд каласына керә. Монда аның апасы Улжай Теркен-ага яши, Тимер мирза шунда туктала. Биредә ул 48 көн тора, яшерен рәвештә корал, азык-төлек туплый. Магулистан килмешәге Ильяс Хужаны Мәвараэннәһердән куып жибәрер өчен әзерлек эшләре алып бара. Тик бу эшләрне белеп алалар. Хәлләр катлаулана, инде Сәмәркандта калу мөмкин булмый, Тимер мирза Кеш каласына юнәлә, тарафдарлары белән шул тирәдә урнаша. Тик монда да озакка туктала хәвефле була, шуңа Тимер мирза 50 кешесе белән кабат Хәрәземгә юнәлә. Алар ай буе Аму-Дәрья тирәсендә яшиләр, ау белән тамак туйдыралар.

Монда аңа күп әмирләр килеп кушыла, барысы да Жидесу үзбәкләреннән (магуллардан) котылырга телиләр. Тимер мирза илне дошманнан азат итү дулкынының сыртында торып кала. Ул, төрле дипломатик ысуллар кулланып, төрле кала, ныгытма хужаларын үз ягына аударырга тырыша, кыйммәтле бүләкләрне кызганмый. Кыскасы, бөтен осталыгын, хәйләкәрлеген, зирәклеген эшкә жигеп, күбрәк гаскәр тупларга омтыла. Тырышлыгы заяга китми, хәтта кайбер дошманнары да аның ягына чыга. «Бергә жыела алуыбыздан без бик канәгать калдык. Уртак фикергә килеп, Чета (Магулистан) гаскәренә һөжүм итәргә ният кылдык... Тиздән без торган урыныбызны калдырдык та башка жиргә күчтек. Кондыз һәм Бадакшан идарәчеләре Али белән Мәхмүтша Кабулилар да зур отрядлары белән безгә килеп кушылдылар».

Тамук-баһадир отряды хәбәргәр (разведка) сыйфатында магулларны күзәтеп торырга озатыла, тик алар Термед елгасын кичкәндә дошманның 6 меңлек отрядына килеп юлыгалар һәм барысы да һәлак булалар. Бары Тамук-баһадир үзе генә әйләнеп кайта.

Тимер мирза байрагы астына торган саен күбрәк халык жыела. Ул Аму-Дәрья ярында туктала. Бу вакыт әмирләрдән Сөләйман, Муса, Жәләлетдин, Хинду һәм ырудашы Жагуй Барластан аңа ярлыклар килеп төшә. Анда аларның магуллардан канәгать булмавы, үз отрядлары белән Тимер мирзага кушылырга теләве белдерелә.

Шул вакыт каршы як та хәрәкәткә килә. Туглук Тимер хан фәрманы белән Ильяс Хужаның 6 меңлек гаскәре Тимер мирза өстенә килә. Алар Термед белән Бәлхне алалар, андагы халык, Аму-Дәрьяны кичеп, Тимер мирза канаты астына ашыга. Дошман көтмәгәндә елганы кичә, сафларга тезелеп, һөжүмгә әзерләнә. «Мин гаскәремә борылып карадым. Дөресен әйтим, сан ягыннан без кимрәк икән шул. Әмма минем сугышчыларымның күбесе атаклы баһадирлардан торганга, мин шикләнмәдем»,- ди Тимер мирза. Ләкин һөжүм булмый, шулай кич житә. Кичен Тимер мирза баһадирларын кинәшкә жыя, төнлә көтмәгәндә һөжүм итәргә булалар.

Төн урталарында читтә ниндидер хәрәкәт сизеп алалар, өч отрядның аларга якынлашуы ачыклана. Болар да чарасын күрәләр. Шунда куанычлы хәбәр алына—әмирләр Сөләйман, Жагуй Барлас, Мусаларның (алар ярлык жибәргәннәр иде) Тимер мирзага кушылырга килүе икән. Шулай аларга тагын мең ярым сугышчы килеп өстәлә.

Күп тә үтми дошман ягындагы Миңле Буга, әмир Сәет һәм Андхай идарәчесе Хәйдәр боларны кысрыклый башлый, бу вакытта Тимер мирза кулында 3 мең сугышчы була. Ул аларны алты өлешкә бүлә. Гаскәрен сафларга тезеп, иң алга укчыларны куя, алар артына сөңге һәм кылыч йөртүчеләрне. Кояш чыгу белән орыш башлана, көне буе сугышсалар да, уңышка ирешә алмыйлар—соң дәрәжәгә житеп арыйлар. Ул көнне Тимер мирза башка кулларны-бүлекчәләрне сугышка кертми. Гаскәрнең өчтән ике өлеше ял иткән килеш көтеп тора. Төн житә. Шул вакыт Тимер мирза көне буе сугышып арган-алжыган дошман өстенә калган сугышчыларын ташлый.

Өч һөҗүм әллә ни уңыш китерми, аннан «Аллаяр!» дип сөрән салып, быргылар кычкыртып, барабаннар кагып тагын бер талпынып карыйлар да дошманны качарга мәҗбүр итәләр. Олаулар, бөтен сугыш кирәк-ярагы болар кулына төшә.

Бу хәбәр Ильяс Хуҗага барып житкәч, ул Тимер мирза өстенә яңа көчләр җибәрә. Тимер мирза тагын авыр хәлдә кала, шуңа ул тиз-тиз яу урынын оештыра башлый. Аму-Дәрьяны кичеп, мул үләнле бер җирдә урнаша. Кызганычка, һөҗүм көтмәгән каравыл төнен йокыга тала, дошман урда читендәге чатырларга килеп җитәрәк кенә сөрән салына. Каты сугыш башланып китә. Ничек кенә кыен булмасын, дошманны урда эченә үткәрмиләр. Елга аръягында дошман булмаганны күреп, Тимер мирза тиз генә теге якка чыгарга боера. Сугышчыларның бер өлеше чатырларны, кирәк-яракларны ташырга керешә. Аннан Тимер мирза үзе дә көймәдә Аму-Дәрьяны кичә. Шунда лагерь коралар, ай буе торалар.

Дошман елганы кичәргә батырчылык итми. Ике яу елганың капма-каршы ярында ай буе торганнан соң бер көнне Ильяс Хуҗа магуллары юкка чыга. Шуннан соң Тимер мирза Бәлх каласына юнәлә. Анда аны тантаналы шартларда каенагасы әмир Хөсәен каршы ала. Мәҗлесләр, күнел ачулар ун көн дәвам итә. Шул көннәрдә «миндә Четенең (Магулистан) Турандагы барлык калаларын яулап алу фикере туды», диелә Автобиографиядә.

## Хәлиткеч бәрелешләр

Бу вакыйгаларда күп әмирләр, баһадирлар катнашып, җиңүләр уртак көч белән бергәләшеп яуланса да, алардан иң зур сәяси файда алучы Тимер мирза була. Әлбәттә, бу хәл кайберәүләрнең эчен пошыра башлый. Моны бигрәк тә әмир Хөсәен авыр кичерә. Казаган оныгы, чыңгызый, житмәсә әле Тимер мирзага сәясәттә беренче адымнарын ясарга да ярдәм иткән Хөсәен язмыштан күбрәкне өмет иткәндер, күрәсең. Ә монда эшләр бөтенләй икенче юнәлеш ала. Кияү кеше аны култык астына кыстырырга, дөньяны басып китәргә жыена түгелме соң? Аны туктатырга вакыт житмәде микән? Шулай әмир Хөсәен, ачыктан-ачык каршы чыгарга кыймыйча, астыртын эшләр башлап җибәрә. Ул Тимер мирзаның көрәштәше Пулад Бугаир белән ызгыша, шул сәбәпле тегесе Тимер мирза лагерын ташлап китә. Һәр сугышчы санаулы чакта! Нәкъ шул көннәрдә Магулистан гаскәреннән Кечек бәк, Тимурин Туклан, Сарык баһадир, Сангум баһадир, Туглук Хужа һәм Көч Тимерләр 20 мең гаскәр белән Тимер мирзага каршы хәрәкәт башлыйлар. Аларга элек Тимер мирзада хезмәт иткән Туглук Салдур белән Кай Хусрау да килеп кушыла. Дошман гаскәренең саны 30 меңгә житә. Тимер мирзаның исә бу вакытта бары 6 мең сугышчысы була. Бу санга ул әмир Хөсәен сугышчыларын кертми, чөнки аларга ышанып бетми. Кыскасы, Тимер мирза хәл эчендә кала.

Бәрелешләр башлана. Тимер мирза сугышка үз отрядын кертми, Җилән ягына чигенә. Дошман аны, качты дип уйлап, хәтта эзәрлекләп тә тормый, бернинди саклык чаралары да күрми. Тимер мирза исә, 32 чакрым жир житеп, кире әйләнеп кайта да дошманның тәмам тугарылып ял итеп ятканын күрә. Шунда Кай Хусрау белән Туглук Салдур аның ягына чыга (һөҗүмгә күчкәнче үк, ул аларны үз ягына аударган булса кирәк). Магулларга бергәләшеп һөҗүм итәләр, уңышка ирешәләр. «Яхшы атлардагылар гына качып китәргә өлгерделәр, Ильяс Хужага килеп кушылдылар,»—диелә Автобиографиядә. Дошман кабат болар өстенә килергә җөрьәт итми.

Галәттә, озакка сузылган сугышларда бер-ике төп бәрелеш була, шуннан соң гына кемнең җинүче, кемнең җиңелүче икәне төсмерләнә башлый. Магулистан явына каршы алып барылган көрәш тәҗрибәсеннән чыгып, Тимер мирза шундый нәтиҗәгә килә: «Чете иле (Магулистан) гаскәрен ачык сугышта җинеп чыгу кыен эш, орышканда башта чигенергә кирәк, гүя ки син аларның ишле явыннан куркып калгансың. Шулай

дошманны үзеннен көчсез булуына ышандыргач һәм аның уяулыгын бик нык киметкәч кенә кинәт һөҗүм оештырырга мөмкин». Сугышның соңгы, хәлиткеч бәрелешендә Тимер мирза бу фикерне бик оста тормышка ашыра. Ул өч әмирен дошман каршысына куя да үз гаскәре белән тау өстенә менә, анда чатырлар корып, күзәтергә тотына. Сугышчылар тирә-юньдәге үрләр өстендә бик күп учаклар тергезеп җибәрәләр. Тик шунда көтелмәгән хәл була—иртәнге намаздан соң Ильяс Хуҗа идарәсендәге Магулистан гаскәре барабаннар кагып китеп бара. Кайбер әмирләр ана таудан төшәргә, дошманны эзәрлекләргә киңәш итә, тик Тимер мирза риза булмый: «Алар мине тау өстеннән төшереп, үзәндә орыштырмакчы булалар»,—дип җавап бирә ул. Чыннан да, дошман гаскәре бераз көтеп торганнан соң кире әйләнеп кайта, унайсыз шартларда, тау итәгендә сугышырга мәҗбүр була. Ә Тимер мирза сугышчылары өстән ташлар атып та дошманга күпме зыян салалар.

Төнлә Тимер мирза хәрбиләрне киңәшмәгә җыя. Анда һаман тау өстендә торып булмас, тау итәгенә төшеп, ныклап торып сугышка керергә кирәк дигән фикергә киленә. Әгәр эш уңышлы барса, максатка ирешербез, уңышлы бармаса, башка тарафка китеп барырбыз, маневр ясарга мөмкинлек калыр, диләр.

Планны шул ук төнне сынап карарга булалар. Тыгыз сафларга тезелгән гаскәр тавыш чыгармый гына тау итәгенә төшә, дүрт яктан Ильяс Хуҗага һөҗүм итә. Бик каты бәрелеш була. Эш кул сугышына, үзара бугазлашуга кадәр барып җитә. Орышның иң кызган чагында Тимер мирза Ильяс Хуҗа белән хәтта йөзгә-йөз очраша. Ахыр чиктә дошман чигенә, үз урдасына кереп бикләнергә мәҗбүр була. Соңыннан ачыкланганча, Ильяс Хуҗа әмирләре, җиңелүдән бик нык хурланып, Тимер мирзаның башына җиткәнче, соңгы кешегә хәтле сугышырга ант итәләр. Иртәгесен һөҗүм башларга булалар.

Бу вакыт Тимер мирзага әмир Хөсәен килеп кушыла (бәрелеш вакытында кайда йөргән?). Шулай көчләр арта төшә. Ләкин иртәгесен бәрелеш булмый кала. Магулистаннан көтелмәгән хәбәр алына—Туглук Тимер хан вафат булган, тәхет бушап калган. Инде Ильяс Хуҗага ашыгыч рәвештә иленә кайтырга, тәхеткә чыгарга туры килә. Ханзадә кул астындагы әмирләргә үзе әйләнеп кайтканчы бирешмәскә, кальга-ныгытма эчләренә бикләнеп, каршы торырга боера да китәргә хәзерләнә.

Шушы көннән Тимер мирза Ильяс Хуҗаны ничек тә Мәвараэннәһердә калдырырга, тотып алып, юк итәргә омтыла. Иленә кайтып, хан тәхетенә чыкса, ул тагын көчәеп китәчәк, үч явы белән кабат монда киләчәк. Моны Тимер мирза яхшы аңлый. Кыскасы, әмир Хөсәен белән көч берләшү аның мөмкинлекләрен арттырачак кына. Нәкъ шул көннәрдә Ильяс Хуҗаның Кеш каласына гаскәр җибәрүе, анда үз әмирен утыртырга җыенуы билгеле була. Моны ишетү белән Тимер мирза да берничә әмирен шунда озата, чөнки Кешне саклап калырга тели. Дошманны алдау, психологик яктан басым ясау өчен Тимер мирза атларның койрыгына агач ботаклары бәйләргә куша. Аның Кешка якынлашып килгән гаскәре юлда болыттай тузан күтәрә һәм, чыннан да, каланы саклаучылар, бик зур көч килә дип уйлап, качарга тотына. Шулай кала җиңел генә Тимер мирза кулына төшә. Бу вакытта дошман лагерында Тимер мирзага файдалы кайбер хәрәкәтләр күзәтелә—Ильяс Хуҗаның Магулистанга китәргә җыенуын исәпкә алган әмирләр бер-бер артлы аны ташлап китә башлыйлар, Тимер мирза ягына чыгалар.

Табигый, Ильяс Хуҗа да тик ятмый, кабат гаскәр җыя, ирешкәнен кулдан ычкындырмаска тырыша. Ә Тимер мирза дошманга каршы көрәшне каенагасы әмир Хөсәен, башкалар белән дәвам иттерә. Канлы бәрелешләр ешая, берсендә магулларның гаскәрбашы Кечек бәк хәтта әсирлеккә дә төшә, шаһзадә үзе дә көчкә качып котыла. Җиңү тантанасы Автобиографиядә менә нинди сүзләр белән тасвирлана: «Без Ильяс Хуҗа артыннан куып киттек. Минем гаскәремдә буш кул белән баручы сугышчыны табу кыен иде—без шул кадәр күп әсирләр, атлар, корал һәм мал кулга төшердек. Мин әсирләрнең барысын да китерергә куштым, чөнки һәркайсының дәрәҗәсен исәпкә алып сөйләшеп чыгасым килде. Мин гаскәремә җиңүне әйбәтләп

билгеләп үтәргә, мәжлесләр корырга һәм күңел ачарга рөхсәт иттем...»

Тимер мирзаның әсир төшкән гаскәр башы, мең башы, йөз башы һәм башкалар белән сөйләшеп чыгуы игътибарны җәлеп итә. Магулистан гаскәре белән идарә итүче Кечек бәкне ул үз ягына чыгарга үгетләп карый, тик теге риза булмый. Аннан соң ул әсирләрдән:

—Мин сезгә нинди җәза бирергә тиеш?,—дип сорый.—Алар: «Без җәза алырга лаеклы», дип җавап бирделәр,—диелә Автобиографиядә.—Ләкин бу очракта Чете (Магулистан) илендә үз туганнары өчен үч кайтарырга әзер торган кешеләр күп табылачак. Әгәр дә мин әсирләрне азат итсәм, минем кин күңеллелегем күпләрнең күңелен яулап алачак һәм аларның күбесе минем байрагым астына басачак.

«Үч алыргамы, гафу итәргәме—син үзең яхшырак беләсең»,—диделәр миңа әсирләр.

Мин кабат, төрле нәрсәләр ышандырып, аларны үз ягыма чыгарга үгетләп карадым, тик алар минем якка аумадылар. Шунда гына мин аларның үз хакимнәренә тугры булуына тәмам ышандым. Ахыр чиктә мин аларны азат иттем. Мул итеп бүләкләп, барысын да Ильяс Хуҗа янына кайтарып җибәрдем».

Шушы хәлләрдән соң Тимер мирза Ильяс Хуҗаның Ходжент каласы тирәсендә Сыр-Дәрьяны кичүе хакында хәбәр ала. Ул тиз генә шул тарафка юнәлә, ләкин дошманны очрата алмый. Бу эш барып чыкмагач, әмирләрдән Сәйфетдин белән Җаганы Сәмәрканд каласын кулга төшерергә дип озата, ә үзе бераз ял итү нияте белән ауга йөри. Шулай ауда йөри-йөри Сәмәркандка якынлаша. Шәһәр халкы аны бик зурлап каршы ала. Тимер мирза кышны шушында уздыра. Киләчәктә бу каланың Җиһангир төзегән дәүләтнең башкаласы булачагын да искә төшерик. Гомумән, Тимер мирза Сәмәркандны гомер буе игътибар үзәгендә тота, бизи, монда яңа сарайлар салдыра, бакчалар утырттыра.

## «Пычрак орыш»

Бу вакыт Тимер мирза белән әмир Хөсәен арасындагы болай да гаять четерекле мөнәсәбәтләр тагын да катлауланып китә. Автобиографиядәге: «... әмир Хөсәен, миңа каршы астыртын эш йөртеп, Тумны ыруының башы белән сүз берләшкән, хан итеп мине түгел, ә Каражуй Чагатайны күтәртергә кирәк дип сөйләгән»,—дигән сүзләр шул хакта сөйли кебек. Ләкин хәлләрнең кабат куера башлавы, Магулистан ягыннан куркыныч янавы аларны тагын якынаерга мәҗбүр итә: «Яз җиткәч, шундый хәбәр таралды: имеш, баш күтәргән Чете гаскәре зур көч туплап Мәвараэннәһергә һөҗүм итәргә җыена икән. Әмир Хөсәенне бу хәбәр зур куркуга салды, ул ашыгычлык белән үзенә тугры гаскәр башларын киңәшкә җыйды. Алар анда Чете гаскәренә каршы көрәш минем катнашымнан башка мөмкин түгел, дигән карар чыгарганнар». Шуннан соң ике арада сөйләшүләр башланып китә һәм дошман белән бергәләшеп көрәшергә дигән килешү төзелә.

Биредә сүз тарих сәхифәләренә «Пычрак орыш» дигән исем белән кереп калган сугыш турында бара. 1365 елның язында Ильяс Хуҗа зур яу белән кабат Мәвараэннәһергә килә. Аның төп дошманнарыннан булган Тимер мирза белән әмир Хөсәен Ильяс Хуҗаны Сыр-Дәрья буенда каршылыйлар. Бәрелеш Ташкент белән Чиназ арасында була. Бу вакыйгалар Автобиографиядә болай тасвирлана: «Мин зур гаскәр тупладым да әмир Хөсәенгә Четегә яу белән барам дип хәбәр иттем, аннан Дәрья аша кичү урынын сакларга юнәлдем. Тупланган җиде мең гаскәрне җиде өлешкә бүлдем. Әмир Хөсәенгә чапкын җибәрдем, ул миңа килеп кушылды һәм урдам тирәсендә урнашты. Шымчыларым Ильяс Хуҗаның хәле турында хәбәр китерделәр... Мин үз чиратымда түбәндәге затларны рекогносцировкага җибәрдем: Аложай-ту, Шир-Баһрам, Тулат-Буга, әмир Пархат белән Мәлик баһадир, ә аларның баш идарәчесе Кутлуш Саланчи Арлат иде. Флангларга мин Саз Буга белән Тимер Хуҗаны куйдым, калган баһадирларны үз янымда калдырдым.

Әмир Хөсәен Сыр-Дәрьяне кичте. Мин Ильяс Хуҗага икебез ике яктан һөҗүм итсәк яхшы булыр, дигән фикер әйттем, ләкин әмир Хөсәен риза булмады—ул көчләрне икегә бүлмәү ягында иде. Аны күндереп булмавымны күргәч, аның фикеренә кушылдым. Тиздән безнең алда Ильяс Хуҗа явы пәйда булды. Яуның зурлыгыннан мин хәтта каушап калдым...»

Бу очракта укучыны кисәтеп кую дөрес булыр, чөнки сугыш ахыр чиктә, Тимер мирза белән әмир Хөсәеннең тар-мар ителүе белән тәмамлана. Автобиографиядә исә Тимер мирза җиңелүнең гаебен аркадашы әмир Хөсәен өстенә сала шикелле. Һәрхәлдә, вакыйгалар монда объектив яктыртыла дип әйтүе кыен. «Дошман көчләреннән Хаҗи бәк, Саланчи баһадирны сытып, әмир Хөсәен отрядына ташланды һәм беренче һөҗүмдә үк аларны качарга мәҗбүр итте. Мин Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, гаскәремнең калган бүлекчә башларына һәм сугышчыларга ныклык иңдерүен сорадым. Шул вакыт әмир Шәмсетдин отряды да әмир Хөсәен өстенә бара башлады. Мин кул астымдагы сугышчылар белән әмир Шәмсетдин өстенә ябырылдым, аны кысрыклап, Ильяс Хуҗага таба качып китәргә мәҗбүр иттем. Һөҗүм шундый көчле булды—Ильяс Хуҗа гаскәрендә паника башланды.

Дошман бик нык каушады, тизрәк һөҗүм оештырырга кирәк дип, мин әмир Хөсәенгә, миңа килеп кушылуын таләп итеп, боерыклар җибәрдем. Дошманның мондый хәлдә калуыннан файдаланып калырга кирәк иде. Әмир Хөсәен исә, аңа 10 тапкыр чапкын җибәреп карасам да, бер сәбәпсез боерыгыма илтифат итмәде, килеп кушылмады. Мин аның хыянәт юлына басуын аңладым. Шуны күреп, чигендем һәм тукталыш ясадым. Дошман гаскәре дә бик нык арган иде, алар да чигенде. Бу төндә мин ат өстеннән бөтенләй диярлек төшмәдем. Орыш тукталганнан соң әмир Хөсәен, җаен табып, миңа килеп кушылды. Без дүрт тарафка каравыллар куйдык та төннең калган өлешен тыныч уздырдык».

Сугышның хәлиткеч өлеше икенче көнгә туры килә. Коеп яңгыр ява башлый, ул торган саен көчәя, чиләкләп дигәндәй орырга тотына. Аяк астында җир бик нык җеби, атлар таеп егыла, аларны идарә итү авырлаша. Шул сәбәпле магуллар белән җирле Мәвараэннәһер гаскәре арасындагы бу бәрелеш «Пычрак орыш» дип тарихка кереп калган. Ильяс Хуҗа орышта өстен чыга. Әлеге бәрелеш Автобиографиядә болай тасвирлана: «Дошман явындагы «ядачы» әфсен-төфсен кылганнан соң коеп яңгыр ява башлады һәм ул безгә зур кыенлык тудырды, хәрәкәтне туктатты. Шуңа да карамастан, мин баһадирларым белән быргылар кычкырттырып орышка кердем. «Бераздан без яңгыр чакырган теге «ядачыны» тотып алдык һәм үтереп ташладык, яңгыр да шундук явудан туктады. Мин яугирләрем белән дошман өстенә ташландым, аны шундый каты китереп кыстым, Ильяс Хуҗа гаскәре һөҗүмгә чыдый алмыйча, тир-якка таралып бетте. Гаскәрем аларны эзәрлекләп китте, ә мин ике мең сугышчы белән торып калдым, хәрби музыка уйнатырга куштым.

Шул вакыт һич көтмәгәндә безнең өскә дошманның гаскәр башы әмир Шәмсетдин ябырылды. Мин аңа каршы бер мең гаскәр куйдым. Ул көнне орыш караңгы төшкәнче барды. Минем мең кешелек төркемем тулысынча кырылып бетте, чөнки дошман бик ишле иде. Болай сугышны дәвам иттереп булмаячагын күреп, гаскәрем белән Кеш каласына таба чигендем. Дошманга икебез ике яктан һөҗүм итик дигән киңәшемне әмир Хөсәеннең кире кагуы миңа нинди хәлгә китерде. Бу сугыш мине хәрби өлкәдә идарәнең ике кулда булуы сугыш барышына зур зыян китерә һәм моны һич тә булдырырга ярамый дигән фикергә китерде. Шулай ике тәкә башы бер казанга сыймый дигән мәкаль тагын бер кат расланды».

Бу өзектә сугыш хәрәкәтләреннән тыш игътибарны яңгыр чакыручы ниндидер «ядачы» да җәлеп итә. Чыннан да, төркиләр тарихы белән танышканда «ядачы», «яда ташы» дигән төшенчәләргә килеп юлыгасың. Урта гасырларда әфсен-төфсен, сихер белән шөгыльләнүче шундый махсус затлар булган. Бүгенге терминологиягә күчерсәк, аларны магия белән шөгыльләнүчеләр дип атап булыр иде. Аларның кирәк чакта күккә ташлар атып (бәлки махсус

кристаллардыр?) янгыр чакыртып китерүе хакында хәбәрләр бар. Әмма вакыйгаларга әйләнеп кайтыйк.

Тимер мирза белән әмир Хөсәен, орышта оттыргач, Бәлх тарафына юнәләләр. Аму-Дәрья буенда аларга тагын берничә төркем килеп кушыла. Шул вакыт аларга Магулистан гаскәренең берничә каланы кулга төшерүе турында хәбәр килеп житә. Дошманның һөҗүменнән шикләнеп, алар елганың икенче ярына чыгалар—Сәмәркандны ташлап китәргә туры килә. Әлбәттә, ныклы диварлары да булмаган каланы дошманга ташлап киту, халкын якламау әмирләрне бизәми бизәвен дә, тик тегеләр үзләрен кайгырту белән чикләнәләр.

«Мин кышны анда уткәрү нияте белән Карши каласына күчтем,— диелә Автобиографиядә.—Мин сугышчыларны өйләренә тараттым да кабат яз көне, Нәүрүз бәйрәменә генә жыелырга куштым».

Бу вакытта Сәмәрканд шәһәрендә шактый киеренке хәлләр булып ала. Үзләренең яклаучысыз калуын белеп алган халык якынлашып килүче дошманга каршы көрәшкә күтәрелә. Башлап йөрүче дә табыла. Иң элек хәрби хезмәткә яраклы кешеләрнең исемлеген төзиләр, үзара эш бүлешеп алып, каланы төрле яктан ныгыта башлыйлар. Киң үзәк урам буш калдырыла, ә вак-төяк урамнарда һәм тыкрыкларда баррикадалар ясала. Иң унайлы урыннарга укчылар куела. Әлбәттә, дошман бу хакта берни белми.

Менә берни абайламаган Ильяс Хужа отрядлары калага керә. Алдагылары бер тоткарлыксыз үзәккә үтә, алар артыннан башкалар да уза. Шәһәр тып-тын, урамда кеше-фәлән күренми, дошман халык куркудан яшеренеп беткән дип уйлый.

Кинәт магуллар өстенә ук янгыры ява башлый, аннан ташлар очарга тотына. Теләсә нәрсә белән коралланган халык урамнарга атылып чыга, дошман өстенә ташлана. Бу шул кадәр көтелмәгәндә була, магуллар ике меңгә якын сугышчысын югалткан хәлдә каланы ташлап чыгалар. Өстәвенә, азатлык өчен күтәрелгән халыкка табигать үзе ярдәмгә килә—магул армиясендә үләт авыруы башлана, дошманның атлары кырыла башлый, һәр дүрт атның берсе генә исән кала. Дошман тиз арада Сәмәрканд тирәсеннән китәргә мәжбүр була. Ә бераздан алар сугыш хәрәкәтләрен гомумән туктаталар да Мәвараэннәһерне ташлап китәләр. Сәмәрканд халкы үзен жинүче саный.

Яз житеп, далалар яшәрү белән Тимер мирза, әмир Хөсәен кабат берләшәләр дә Сәмәркандка юнәләләр. Кала читендәге бер бистәдә тукталып, каланы саклаганда башлап йөрүчеләрнең тырышлыгын «хуплауларын» белдерәләр, аларны үзләренә чакырып алалар. Ләкин икенче көнне аларның барысы да жәзага тартыла. Житәкчеләрдән бары тик Мәүлана Задә исемле адәм генә исән калдырыла. Тарихчылар язганча, Тимер мирза аны әмир Хөсәен кулыннан йолып калган, имеш.

## Соңгы көндәш

Шушы көннәрдә Тимер мирза белән әмир Хөсәен арасыннан тагын кара мәче йөгереп уза. Болай да киеренке мөнәсәбәтләр соңгы чиккә житә. Эш шунда ки, әмир Хөсәен Тимер мирза әмирләреннән ана булган бурычларын түләп бетерүен таләп итә. Ә бурыч исә «Пычрак орыш» аркасында барлыкка килә. Әмирләр ул сугышта бик күп матди зыян күрәләр, атларын, сугыш кирәк-ярагын югалталар, үз отрядларын кабат коралландыру, комплектлау өчен әмир Хөсәеннән бурычка акча алып торалар. Иң унайсыз чакта әмир Хөсәен бурычны кайтаруны кабыргасы белән куя.

Автобиографиядә бу хакта болай диелә: «Әмир Хөсәен минем әмирләремнән исәп-хисап таләп итте, гәрчә алар бөтен алган нәрсәләрен сугышка тотсалар да Хөсәеннең бу эше минем шул кадәр ачуымны чыгарды, мин аны үтерергә теләдем. Әмма шул вакыт Коръән сүзе исемә төште, анда болай диелгән: «Жәннәт ачуын баса белүче һәм кешене гафу итүчеләргә әзерләнгән. Аллаһы Тәгалә изгелек кылучыларны якын күрә». Шуннан мин бу уемнан кире кайттым. Мин әмир Хөсәенгә хат юлладым (...) ана бик күп атлар, дөяләр жибәрдем. Әмир Хөсәеннең сеңлесе, Улжай Теркен-ага *(Тимер мирзаның*

*хатыны—С. Ш.)* үз агасына шулай ук бик күп терлек, мал һәм кыйммәтле ташлар җибәрде. Әмир Хөсәен барысын да комсызланып кабул итте. Мин аңа күп акчалар җибәрдем, ул аларны да ала торды, ләкин нәфесен тыя белмичә, һаман канәгать булмады. Шундый комсызлыгы һәм саранлыгы өчен минем әмирләрем аны күрәлмәс булдылар».

Тимер мирза үз әмирләрен, баһадирларын авыр хәлдә калдырырга теләмичә, бар булган байлыгын әмир Хөсәенгә бирә, хәтта хатынының колак алкаларын да кызганып тормый. Әмир Хөсәен кыйммәтле әйберләр арасында сеңлесенең алкаларын таныса да, кире кайтарып бирми, нәфесен тыя алмый. Бу хәлләр күпләрне Тимер мирза ягына аудара, аның тарафдарлары арта бара, ул зур абруй казана. Әмирләр бер-бер артлы Тимер мирза ягына чыга башлый. Табигый, бу хәл араларның тагын да бозылуына китерә. Әмир Хөсәен үзеннән аерылучыларга үтерү белән яный.

Беренче карашка, шәхси мөнәсәбәтләргә, симпатия-антипатиягә, хакимияткә омтылуга гына корылган бу вакыйгаларда объектив сәбәпләр дә бар сыман. Ни өчен дигәндә, илдә барган туктаусыз бәрелешләр, әмирләрнен кем көчле шуның ягына чыгып, әле бер, әле икенче лагерьда орышып йөрүләре, илдә тынычлык булмау—барысын да туйдыргандыр, күрәсен. Шуна күрә җирле идарәчеләрнең акрынлап көчле һәм гадел шәхес Тимер мирза тирәсенә туплануы, аның абруе елдан-ел үсә баруы очраклы хәл түгел. Мавараэннәһернең, дошманнан арынып, бер ныклы кул астына керүе дә күпләрнең уртак теләген чагылдыргандыр, дип уйларга нигез бар. Әлбәттә, монда Тимер мирзаның шәхси сыйфатлары да зур роль уйнаган. «Илдә барган феодаль анархия болай озак дәвам итә алмый иде. Феодаль сепаратистлар белән беррәттән ул дәвердәге җәмгыятьтә феодаль берләшүгә йөз тоткан, көчле дәүләт булдырырга омтылган көчләр дә туплана башлый,—дип яза В. Якубовский үзенең «Тимер» дип аталган китабында.—Сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, мөселман дин әһелләре, шулай ук җир эшкәртеп көн күрүче халык берләшүне тели... Тимер исә замана таләпләрен Хөсәенгә караганда яхшырак аңлый, дин әһелләре белән шәһәр халкы арасында үзенә теләктәш төркемнәрне армый-талмый әзерли».

Нәкъ шушы вакытта Тимер мирза шәхси югалту да кичерә—аның хатыны Улҗай Теркен-ага вафат була. «Хатынымның вафатыннан соң Хөсәен белән булган туганлык мөнәсәбәтләре төкәнде: безнең арада дошманлык белән нәфрәттән башка бернәрсә дә калмады. Әмирләрем белән киңәшеп, мин Хөсәен өстенә барыр өчен яу туплый башладым»,—диелә Автобиографиядә.

Чыннан да, монарчы туганнарча итәгать саклап килгән Тимер мирза өчен, хатыны үлгәч, аны Хөсәен белән бәйләп торган соңгы җеп өзелә. Ул каенагасы белән ачыктан-ачык көрәшә башлый. Хәлнең кискенләшә баруын сизгән әмир Хөсәен ашыгычлык белән үз каласы Бәлхне ныгытырга керешә.Ул булган бар байлыгын, сугыш кирәк-яракларын, коралларын каланың кальгасы-хиндуванга китереп тутыра. Бу әзерлекләрне каенагасының ни өчен алып баруын Тимер мирза күреп тора, инде уртак тел табу, дус-тату яшәп булырына берсе дә ышанмый. 1366—1370 еллар арасында алар бик катлаулы мөнәсәбәтләрдә яши, ике арада күп бәрелешләр була. Һәръяк әмирләрне үзенә тартырга, көчәеп китәргә омтыла. Ара-тирә бәрелешләр тукталып, килешү кебек нәрсә дә төзиләр, тик бераздан барысы да чуала тора. Бу вакытта күп әмирләр ике арада йөри, әле Тимер мирзага, әле әмир Хөсәенгә ярдәм итә.

Ниһаять, 1670 елда Тимер мирза әмир Хөсәеннең Бәлх каласын алырга һәм аны кулга төшерергә кирәк дигән ныклы карарга килә. Ул зур гаскәр туплый, каланы камап ала. Шәһәр өчен сугыш башланып китә. Күп тырышлыклар куйган, зур югалтуларга дучар булган гаскәр, ахыр чиктә, Бәлх диварларының бер җирендә эчкә үтеп булырлык тишек уя. Кала алына. Әмир Хөсәен үзе ныгытылган кальга-хиндуванга кереп бикләнә. Хәленең бөтенләй өметсез икәнен аңлап, ул сөйләшүләр башлап җибәрә, хиндуванны сугышсыз тапшырган очракта Тимер мирза нинди гарантияләр бирә, дип сорый. Тимер мирза: «Исән калдырудан башка нәрсә вәгъдә итә алмыйм»,—дип җавап бирә.

Кичкә энгер-меңгердә әмир Хөсәен атка атланган килеш берничә

нөгәре белән кальга капкасыннан чыга. Ләкин Тимер мирза урдасына килеп житәм дигәндә генә кинәт куркып кала да, атын кирегә борып, күздән югала. Аны очраклы рәвештә бер манара эченнән табып алалар. Аның язмышы үзеннән-үзе хәл ителә. Эш шунда ки, 1360 елда әмир Хөсәен Кайхусрау исемле әмирнең якын туганы Кайкубадны җәзага тарткан була. Магулистан ханы Туглук Тимер белән көрәш барган чакта исән калган Кайхусрау хан ягына чыга, хәтта аның ерак кыз туганына өйләнеп, «хан кияве» дә булып ала. Сонрак, магуллар илдән куылгач, Кайхусрау Ташкентка кайтып урнаша, Тимер мирза белән бергә әмир Хөсәенгә каршы көрәшә. Алар хәтта кодалар да булып китәләр—Тимер мирзаның улы Җиһангир Кайхусрауның кызы Төмән Котлыкка өйләнә. 1370 елда, Бәлхне алганнан соң кулга төшкән әмир Хөсәенне Тимер мирза кодасы Кайхусрау хөкеменә тапшыра. Ни өчен дигәндә, шәригать буенча рөхсәт ителгән кан үче (кисас) канунына нигезләнеп, әмир Кайхусрауның Хөсәенне үтерергә хакы була һәм ул бу хокуктан бик теләп файдалана. Ул туганы өчен әмир Хөсәеннән үч ала. Шулай Тимер мирза кеше кулы белән әмир Хөсәенне юк итеп, Мәвараэннәһер тәхетенә дәгъва итүче төп көндәшеннән котыла. Хәзер инде ана каршы торырлык зур шәхес-фигура калмый—шулай хакимияткә туры юл ачыла. Шулвакыт Тимер мирза Суюргатмыш атлы бер чыңгызыйны үзенең «кесә ханы» итеп күтәртә, ә инде Бәлх каласы егылгач үткәрелгән корылтайда аны Мәвараэннәһернең бердәнбер идарәчесе итеп таныйлар. Шушы вакыйгадан соң аның янына мөселман дөньясы үзәгеннән Бәрәкә исемле бер сәед килә һәм хакимият билгесе булган байрак белән барабан тапшыра, тәхетнең озын гомерле, бәхетле булыр, дип юрый. Шушы көннән Сәед Бәрәкә аның гомерлек остазы, киңәшчесенә әверелә.

## Җиһангир башкаласы

Бәлх вилаятендә әмир Хөсәеннең эшен бетергәч, Тимер мирза күңеленә якын Сәмәрканд шәһәрен үзенең башкаласы итеп сайлый, анда нык диварлар, кальга-цитадель төзетә. Киләчәктә ышанычлы тыл булып хезмәт итәчәк каланы ул төрле яктан ныгыта. Гомумән, Мәвараэннәһер әмирләренең (чагатайларның) калаларда урнашуы, акрынлап утрак тормышка күчүе жинел генә бармаган. Бу процесс башта зур каршылыкларга очраган, төрле бәхәсләр, низаглар китереп чыгарган. Чагатай олысының көнчыгышында күчмә тормыш алып баручы магуллар (Магулистан) утрак тормышка гел каршы була. Әле Чагатай үзе исән чакта ук Мәвараэннәһергә карата мөнәсәбәттә бәхәсләр килеп чыга, чөнки анда ислам дине һәм мәдәният хөкем сөрә. Әлбәттә, дала йоласында тәрбияләнгән Чагатай һәм аның нойоннары исламны кабул итә алмый. Ләкин кайбер чагатай ханнары—Мөбәрәк шаһ белән Борак хан ислам диненә күчәләр. Мөбәрәк шаһны чагатай тәхетенә күтәрү дә Жилесудагы Алмалык шәһәре тирәсендә булмыйча, Мәвараэннәһердә уздырыла. Бу инде ханнарның калаларны, анда яшәүче мөселманнарны якын итә башлавын күрсәтә.

Мондый күренешләр дала канунын-түрәсен, Чыңгыз хан кануннарын бар нәрсәдән дә өстен куярга өйрәнгән магулларда шундый көчле каршылык уята ки, эш хәтта корылтай жыюга кадәр барып житә. Тимер мирзаның башкала итеп Сәмәркандны сайлавына кадәр әле бер гасыр элек, ягъни 1269 елда чагатай ханы Кайду Талас үзәнендә магул ханзадәләре белән нойоннарны корылтайга жыя. Табигый, корылтайда Мәвараэннәһергә йөз тоткан партия жинелә, шундый карар кабул ителә: моннан соң таулар белән далаларда гына яшәргә; калалардан ерак торырга; ашлык чәчелгән басу-кырларга терлек кертмәскә; игенчеләрдән тиешеннән артык салымнар таләп итмәскә.

Ләкин тормышның үзендә башланган процессны корылтай карары белән генә туктатып буламы соң?.. Чыңгыз хан улы Чагатайдан мирас булып калган зур өлкә (олыс) икегә бүленә башлый. Утрак тормыш хөкем сөргән Мәвараэннәһердә чагатайлар, далага йөз тоткан Магулистанда магуллар үзләренчә

тормыш алып баралар. Ә Тимер мирза заманында әлеге бүленеш инде тәгәлләнгән була һәм, әмир Хөсәеннән котылганнан соң, башкала итеп Сәмәрканд сайлануы бик табигый кабул ителә.

Шулай да, ни өчен Тимер мирза үзенең булачак империясе башкаласы итеп Сәмәркандны сайлаган? Моңа төрлечә җавап бирүчеләр бар. Берәүләр каланы сайлаганда, аның зурлыгы хәлиткеч роль уйнаган, икенчеләре монда һава шартлары бик әйбәт булган, кала шул ягы белән Тимер мирзага ошаган, диләр. Кайберәүләр Сәмәрканд Тимер мирза кулга төшергән беренче кала, шуңа күрә ул аның күңелендә аерым урын алган дигән фикер дә әйтәләр. Ни генә булмасын, 1370 елдан борынгы Сәмәрканд язмышында өр-яңа дәвер башлана. Тимер мирза яуларда кулга төшергән бар байлыкны, колларны, галимнәрне, шагыйрьләрне, мимарчы-архитекторларны, төрле һөнәр ияләрен шушы калага алып кайта, алар ярдәмендә башкаланың даның күтәрә, йөзен үзгәртә, гомере буе аны кайгыртып яши. Әлбәттә, зиннәтле биналар, зур-зур бакчалар, яңа арыклар, сугару системалары—барысы да талап җыелган байлык, кан коеп табылган хәзинәләр хисабына эшләнә. Шәһәрнең гүзәл архитектура истәлекләре хакында сүз барганда, аларның нинди нигездә үсеп чыгуын да онытмаска иде.

Күренекле шәркыятьче-галим В. Бартольд Тимер мирза гаскәре хакында кызыклы мәгълүмат китерә: «Чагатайлар Тимер заманында үзләрен мөселман гаскәре дип санаганнар, әмма тышкы кыяфәтләре һәм хәрби төзелешләре ягыннан алар Чыңгыз хан традицияләренә тугрылык саклап килгәннәр (...) Чыңгыз хан түрәсен шәригать кануннарыннан өстен күргән өчен Тимер белән чагатайларга хәтта гаеп тә ташлый торган булганнар (...) Тимер һәм аның сугышчыларын башка мөселманнардан монгол гадәте буенча толымга үрелгән чәчләре бик нык аерып торган, бу шулай ук Урта Азиядә сакланып калган рәсемле кульязма китаплар белән дә раслана. Тимер гаскәре Димәшкъне камап алгач (1400—1401), аның оныгы Солтан-Хөсәен, бабасына хыянәт итеп, камалучылар ягына чыга. Анда беренче эш итеп егетнең толымын кисәләр һәм киемен алыштырырга мәҗбүр итәләр» *(В. Бартольд. Сайланма хезмәтләр.—Т. V.—171 б.).*

Тимер мирза төзегән дәүләттә чагатайлар (төркиләшкән монголлар) төп урынны алып торган дип ышанып әйтергә мөмкин. Алар арасында дүрт ыру: арлат, җалаир, каучин, барлас ырулары иң затлылардан саналган. Әйтелгәнчә, Тимер мирза үзе барлас ыруыннан була. Арада «каучин» дигәне башта ыру булмыйча, Тимер мирзаның 1000 кешелек шәхси гвардиясен тәшкил иткән. Соңрак әлеге хәрби берәмлеккә кергән сугышчыларның нәселе аерым ыру булып санала башлаган. Әлбәттә, Тимер мирза хакимият өчен көрәшкәндә иң элек үз ыруы барласларга таянган. Шулай да, данлы калалар иле Мәвараэннәһердә хөкем сөргән Тимер мирза, зирәк дәүләт эшлеклесе һәм сәясәтче буларак, төркиләшкән чагатайлар белән җирле таҗикларны һәрвакыт бертигез күргән. Төрки һәм фарсы телләрен камил белгән, берсен дә өстен куймаган, шуның аркасында ике як та аны үз иткән.

## Нәтиҗә

Тимер мирзаның тормыш юлын барлый башласаң, анда бер-берсеннән аерылып торган өч дәвергә игътибар итәсең. Беренчесен без инде шактый тәфсилләп тасвирладык: 1360—1370 еллар. Тимер мирза сәясәт мәйданына 25 яшьтә чыга, атасы әмир Тарагай үлгәч аның варисы булып кала. Шулай эреле-ваклы бәрелешләргә, феодаль таркаулык еллары стихиясенә кереп чума. Әлеге көрәшнең башында ук ул, көтелмәгән адым ясап, Магулистан ханы Туглук Тимергә хезмәткә керә, Кашка-Дәрья вилаятенә хуҗа була. Аның алдында зуррак мөмкинлекләр ачыла. Канатын тагын да киңрәк җәю өчен, ул Бәлх вилаяте әмире Хөсәен белән якыная, аның сеңлесенә өйләнеп, әмир белән туганлаша, аның көрәштәшенә, уң кулына әверелә.

Мәвараэннәһер әмирләренең магулларга каршы көрәшендә бу ике зат башта бер-берсенә нык терәк булалар, ләкин соңрак аралары бозыла, чөнки

ике тәкә башы бер казанга сыймый башлый. Һәркайсының Мәвараэннәһердә хуҗа буласы, хакимиятне үз кулына аласы, тәхеткә чыгасы килә. Шуннан астыртын эшләр башлана. Әмма Тимер мирза зирәгрәк булып чыга. Көчәеп китү өчен ул кабат Магулистан ханы Туглук Тимергә килеп сыена, аның ышанычын казана. Ханның улы Ильяс Хуҗа Мәвараэннәһер хакиме итеп куелгач, Тимер мирза аның иң якын түрәсе-урынбасары итеп билгеләнә. Зирәк сәясәт, һәр адымын уйлап атлау ана кабат көчәеп китәргә ярдәм итә. Шулай җирле әмирләр арасында аның абруе үскәннән-үсә, тарафдарлары арта.

Магулларны Мәвараэннәһердән куып җибәрү өчен күтәрелгән патриотик көрәш вакытында Тимер мирза ханзадә Ильяс Хуҗага каршы чыга, шул сәбәпле үлемнән чак котылып кала. Бу вакытта әмир Хөсәен белән алар кабат якынаялар, дошманга каршы көрәшне бергәләшеп алып баралар. Ләкин ике көндәшнең һәркайсы моның вакытлы нәрсә икәнен яхшы аңлый—арада инде элекке дуслык, ышаныч юк. Тимер мирзаның хатыны үлеп киткәч, әмир Хөсәен белән аралары бөтенләй өзелә, беренчелек өчен аяусыз көрәш башлана. Һәм бу көрәшкә Тимер мирзаның Бәлх каласын алуы белән нокта куела. Хакимияткә ирешү юлында торган соңгы киртә—әмир Хөсәен дә алып ташлана (1370)—Тимер мирза тормышындагы өч дәвернең беренчесе шуның белән тәгәлләнә. Бу дәвер ун ел вакытны ала. Бу елларда ул бик күп сынаулар аша уза, хәрби яктан да, сәяси һәм социаль яктан да зур тәҗрибә туплый. Үзен Мәвараэннәһердә иң зур шәхес итеп таныта.

Икенче дәверне 1370—1386 еллар белән билгеләргә мөмкин. Бу чорда ул илне берләштерү, җирле идарәчеләрнең үзара талашып яшәвен туктату өчен күп көч түгә, аларны үзенә буйсындыру, Мәвараэннәһерне бер йодрыкка туплау белән шөгыльләнә. 1372 елдан Тимер мирза Хәрәземне үз биләмәләренә кертү өчен яулар башлап җибәрә. 1373—1374 елларда Көньяк Хәрәземне кабат яулап ала. Бу яшь җиһангирның беренче уңышы була. Моннан соң ул Хәрәземгә тагын өч тапкыр яу йөри. Соңгысы 1388 елда Үргәнеч каласын җимертү, аның урынына, сукалатып, арпа чәчтерү белән тәмамлана. Шулай Тимер мирза бу өлкәне бүтән баш күтәрә алмаслык хәлгә төшереп, үз дәүләтенә кушуга ирешә. Бу эш гаять кансыз ысуллар белән башкарыла.

Шушы вакытта аның игътибарын Күк Урдада көчәеп киткән Ырыс хан җәлеп итә. Алтын Урдадан качып, үз канат астына килеп сыенган чыңгызый Туктамыш угланнан ул бик оста файдалана, аңа зур ярдәмнәр күрсәтә, шулай тырыша торгач, аны башта Күк Урда тәхетенә, аннан Алтын Урда тәхетенә хан итеп утырта. Бер үк вакытта Харасан өлкәсен, Көнчыгыш Иранны яуларга керешә. 1381 елда Һират алына, ике елдан Сеистан да Тимер мирза биләмәләренә керә, тагын ике елдан Көньяк Әзәрбайҗандагы Тәбриз шәһәре аның кул астына керә.

Өченче дәвердә Тимер мирза гомерен нигездә талау яулары оештыруга багышлый, чөнки бу вакытта инде аның алдында дәүләтне киңәйтү, ныгыту ихтыяҗы тормый. Шулай ул «өч еллык», «биш еллык», «җиде еллык» яулар нәтиҗәсендә Иранны, Гыйракны үз дәүләтенә китереп куша. Шушы ук елларда Әрмәнстан белән Грузияне, аннан Әзәрбайҗанны басып ала.

Тимер мирза тарихка Идел буен кара күмергә әйләндергән, аның калаларын хәрабә хәленә төшергән җиһангир буларак та кереп калды (1389—1391, 1394—1395 еллардагы яулар). Бу гаять катлаулы һәм татар өчен фаҗигале тема, ул аерым тикшеренүне таләп итә, бу хакта сүз соңрак булыр.

1398—1399 елларда Тимер мирза Һиндстанга яу йөри, Дәһли солтанатын яулап ала. 1400 елда төрек солтаны Баязид Йылдырым һәм Мисыр солтаны Фараҗга каршы сугышлар алып бара, ә 1402 елда Анкара янындагы сугышта солтан Баязидны хәтта әсирлеккә төшерә. Гомерен яуларда уздырган Тимер мирза хәтта ерак Кытайны да яулап алмакчы була. Тик ул теләгенә ирешә алмый, 1405 елда, инде Кытайны яулар өчен юлга чыккач, Отрар каласы янында язмыш ана «җитәр сина!» дигән карарын чыгара. Ул юлда, үпкәсенә суык тидереп, 70 яшендә теге дөньяга күчә.

*Дәвамы киләсе санда*



## Илсөяр Иксанова

### КЫШЛАРНЫҢ СУЫГЫН ЖЫЛЫТЫП...

#### Итек

*Сталинның итекләрен*
*Иртәгә кем кияр?*
Зөлфәт.

Сталинның итегеме,
Әлләме ул башка?
Һаман да шул кара итек
Баса безнең башка.

Әз генә турайса муен,
Куя хәзер бөгеп.
Өндәү билгесен сораугa
Әйләндергән кебек.

Без!—дип кенә әйтеп кара.
Шундук сорау: кем сез?
Без! була ала димени
Безсез—мәскәүләрсез?!

Сезнең читекләр-итекләр
Бездә инде күптән.
Татар гынамы, братлар,
Ул итекне үпкән?

Бигрәк хикмәтле итек бу
Туамый торган бер дә.
Салдырдың исә берсеннән
Икенчесе кия.

Илсөяр ИКСАНОВА—*шагыйрә, «Кышкы канәферләр» китабы авторы. Казанда яши.*

Да-а, көннән-көн «канат җәя
Демократия»...

## Гасырлар чигендә

Артта—синле гасыр.
Алда—
Синсез гасыр.
Булырмы ул җаһил,
Булырмы ул асыл,—
Ул минеке түгел.
(Кичер, Яңа гасыр!)
Калды минем күңел
Синле гасырымда,
Хисем асылында...

## Язмыш

Китмә, дип,
китмә, дип ялвардым—
Син киттең бернигә карамый.
Мин беләм: Син—минем язмышым,
Язмышка рәнҗергә ярамый.

Китмә, дип,
китмә, дип инәлдем
Гомерең кыл өсте торганда.
Нишлисең, бу безнең язмыштыр—
Мин монда каласы,
Син—анда.

Китмә, дип,
китмә, дип, өзелдем
Син күчкәч күкләрнең катына.
Аңладым:
бу—язган язмышлар,
Мин түзәм шул Язмыш хакына.

Китмә, дип,
китмә, дип, өзелеп
Кулыма сарылыр балам бар.
Кышларның суыгын җылытып,
Кызара ап-ачы баланнар.

## Таулар

Үпкәләсәм—үпкәләргә хаклы
Хакым бардыр хәтта каргарга.
Алар сине алдап ашкындырды,
Син мөкиббән идең тауларга.

Алар сине миннән аерып алды,
Алар мине синсез калдырды.
Үпкәләсәм—үпкәләргә хаклы:
Күккә ашырдылар җаныңны.

Һәм минем дә ярты җаным китте.
Синең белән бергә... күкләргә.
Бу халәтем үземә дә сәер,
Аңлашылмый булыр күпләргә.

Тик мин аңлап калдым
Син киткәндә...
Туктаталмый...
Тау, дип, җан аттың.
Сине өзелеп сөйгән йөрәгемне
Кыяларга бәреп канаттым.

Үпкәләсәм—үпкәләргә хаклы,
Хакым бардыр хәтта каргарга.
Ничек каргыйм?
Мин үзем дә гашыйк
Син яраткан серле тауларга.

*

Синсез яши алмам кебек...
куркам.
Китмә, китмә, китмә син озакка.
Киткән саен шулай
Йөрәгемнең
Утлы кылын өзеп озатам.

Теткәләнә бара, өзелә йөрәк.
Боз булмаммы әверелеп уттан?!
Берни тоймый башлармын күк
бер көн.
Синсез яши алуымнан куркам.

*

Әйләнә дә килә синсез кышлар.
Синең эзләр төшмәс карлар ява.
Соклandыргыч аклык!
... сокландырмый.
Кышлар аклыгы да миңа—яра.

Әйләнә дә үтә синсез еллар,
Гомрем сыза синсез.
Җаным яна.
Бер шатлыксыз түгел юкса гомер.
Шатлыгы да аның миңа—яра.



# Камил Сәгадәт

КАЙТЫП КИЛӘМ

## Болгарым бар

Идел белән диңгез кавышкан ил,
Ак кораблар йөзеп үткәли.
Тарих ташлап киткән изге җирләр
Кемгә рәнҗи, кемгә үпкәли?

Идел белән хыял тоташкан ил!
Ничек карыйм синең күзеңә?
Чиркәү нигезендә ташлар елый,
Җаннар иңри, йөрәк өзелә.

Чал тарихның күптер ятимнәре,
Үксезе дә бардыр, толы да.
Олыласа халык үз үткәнен,
Тарихы да мең кат олылар.

Идел белән тарих тоташкан ил,
Диңгез белән хыял кавышкан.
Башын янә күккә чөйсен халкым
«Болгарың бар!»—дигән тавыштан.
«Болгарым бар!»—дигән тавыштан!

## Сайлау туйда

Сайлау туе булды, сабан туе.
Мәйданнарда бәйге гөрләде.
Нинди генә ярыш төрләрендә
Сынашмады илнең ирләре.

Сабан туйда төрле хәлләр була.
Күңелле дә, кайчак хәтәр дә.
Минем менә соңгы сабан туйның
Бер мизгеле чыкмый хәтердән:

Бил алышты егет. Ак сөлгедә
Маңгай тире калды. Дан булып.
Көрәш дәрте янган яшь батырга
Олы агай чыкты. Сан булып.

Өстән казый бармак янап торгач
Егет бераз каушап сыгылды.
Шуны гына көткән олы агай
Аяк чалды. Егет егылды.

Шау-гөр килде халык. Сайлау туйда
Каян килә шундый адәмнәр?
Бер ходаем, сакла егылудан,
Бер ходаем, сакла хәрамнән!

---

Камил СӘГАДӘТ *(1952)— журналист-шагыйрь, көндәлек матбугатта басылган шигырьләр һәм җыр текстлары авторы. Казанда яши.*

## Сезнең якта

Сезнең якта алсу шәфәкъ күрсәм,
Әллә ниләр уйлап сискәнәм.
Яна, яна, яна, яна төсле,
Минем йөрәк кебек бар галәм.

Сезнең якта күксел томан булса,
Моңланасың, димәк, сизенәм.
Сызлый, сыкрый, өзгәләнә күңел:
Онытып булмый икән тиз генә!

Сезнең якта давыл, кара болыт,
Яшен кисә, кисә йөрәкне,
Аһ, мәхәббәт! Ай-һай, ялгыз яну
Өзеп карый икән үзәкне,
Биреп карый икән кирәкне!

Сезнең якта алсу шәфәкъ күрсәм,
Әллә ниләр уйлап сискәнәм.
Яна, яна, яна, яна төсле
Минем йөрәк кебек бар галәм...

## Син Сөю бугай

Карашларың бигрәк серле,
Син үзең Сөю бугай!
Синнән көнләшәдер хәтта
Күк йөзендә тулган Ай.

Табигать тә сине көткән,
Каеннар Сине дәшә!

Яз белән янәшә шул Син,
Сөю белән янәшә.

Сине сагынып җырлый бугай
Болында дәртле тургай.
Карашларың бигрәк серле,
Син үзең Сөю бугай...

## Яңа өйгә күчкәч

Догасыздыр бу йорт.
Гөлләр корый!
Күзгә күренеп шиңә
Яңасы.
Тозлы учта
Тыпырчына кебек
Ташлап киткән өйнең
Ярасы.
Монда да бит
Тәрәзәмә сарыла
Манарадан Коръән сүзләре.
Нигә шиңә гөлләр?
Иске өйнең
Ябылгандай моңсу күзләре.
Күп катлы өй.
Гөлләр үсми хәтта.
Күңелләр дә авыр берегә.
Җитми инде
Үзең төзегән йортта
Тату гына гомер сөрүгә.

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

## Гомәр Гали

# ХАРИС САТТАРОВ

КӨЛКЕ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕ ХИКӘЯ

Минем бер уңмаган энем бар. Менә шул энем, һәрбер уңмаган укучы кебек, мәктәптән мәктәпкә күчеп теңкәмне корытты бит. Башта мин аны, ничек житте шулай, авыл хужалыгы техникумына урнаштырган идем. Һавасы яхшы, фәлән-төгән дип үзенең дә күнеле шунда тартты. Ләкин анда бераз гына укыган иде, энекәшем бөтенләй икенче нәрсә сөйли башлады: мин, ди, напрасно бирегә кердем. Моны бетергәч, ди, какой-нибудь несчастный агроном булып калыр хәлем юк, ди. Шуңа күрә миңа рабфакка керәсе калган. Аннан берәр вузга китәр идем, вузны бетергәч, бер профессорга ассистент булыр идем, аннары доцент булыр идем, аннары инде, үзең беләсең, профессор булыр идем, ди.

Ярый, мин әйтәм, аганның дус-ишләре булуы сиңа да ярдәм итсен, дидем, сыйнфый чыгышыбыз да зарарсыз, мин әйттем, тоттым да кыш уртасында рабфакка күчердем. Сыйнфый чыгышыбыз чыннан да адәм көлдерерлек түгел, мин дә, энем Гаптерәшит тә—икебез дә крестьян малайлары. Дөресен әйткәндә инде, миңа биш, Гаптерәшиткә өч яшь булган чакта гына әтиебез мулла булган. Житмәсә ул, безнең бәхеткә каршы, бик тиз үлгән дә. Без чеп-чи крестьян кызы булган Хөббениса кулында үскәнбез.

Энемне рабфакка урнаштыргач, «менә шәп булды» гына дип тора идем, икенче елны бит энекәшем: «Миңа инде, Заһир, ди (ул үзе, каһәр, миңа абый дими), бу ел рабфакка керергә туры килмәс, мин үземдә педагогический способность сизәм, шуның өчен дә Шәрекъ педагогия институтына керергә кирәк булыр», ди. Билгеле, аның анда керерлек белеме юк. Шуннан соң икәү киңәшеп, килешеп, ул педтехникумга керергә булды. Анда чынлап тырышып йөрде. Көндез дә, кич тә киенә дә китә, киенә дә китә. Кичләрен бигрәк тырышып йөрде: киенә, ясана, яканың акларын алмаштыра, галстукны бик пөхтә иттереп бәйли, кайчагында минем костюмны да эләктергәли. Шулай тәмам «франтка» әйләнгәч, «мин химический кабинетка вечерний, практический... лабораторный занятиегә киттем», дип, ишектән югала. Бөтен игътибар авиохимга юнәлдерелгән бер заманда эненнен—иптәшеннең практик химиягә шулкадәр бирелүенә, әлбәттә, шатланып карыйсың. Мин дә шулай карадым. Тик байтак вакытлар үткәч кенә башкача карарга туры килде. Ләкин сонга калган идем инде—бу вакытта минем энем Габдерәшитне академия ягыннан аксавы, укучылар арасындагы эшкә катнашмавы, тагын шунда нинди тоташлар белән булган әллә нинди хәлләр өчен педтехникумнан чыгарганнар иде. Ул юньсезнен бөтен лабораторный занятиеләре кызлар белән кинодан кинога, театрдан театрга йөрүдән гыйбарәт булган икән.

Костюм бит никадәр яхшы булса да, кайткач, мине киеп театрга бардылар, дип сөйләми.

Шуннан соң инде энем укудан бөтенләй кул селтәп:

—Мина нинди дә булса эш табып бир,—ди башлады.

Менә шул уңмаган егеткә эш эзләгәндә инде мин Харис иптәш Саттаров белән таныштым.

Без Чернышевский урамында почта алдында сөйләшеп тора идек.

—Ул,—диде мина бер иптәшем,—Кремльдә фәлән учреждениедә, фәлән урында тора; мина ул таныш кеше,—диде,—ялкаулыкта, эшсезлектә ул синен энеңнән калышмый, ләкин аның урыны—әлегә яхшы урын. Ул, һичшиксез, берәр урын табып бирер,—диде.

Нәкъ менә шул минутта Америка кинофильмнарында була торган бер вакыйга сабит булды. Анда бит һәммә нәрсә алдан хәзерләп куелган кебек әзер тора. Әллә нинди сахралар, тау-таш аралары, дингезнең текә ярлары булсын, ерткыч хайваннар белән тулы урман булсын,—ләкин анда кешесе дә, автомобиле дә, иярләп куйган аты да, тиешле кешеләрне коткарырга көймәсе дә, биек шәлаләгә таба агып барган кешене судан коткарып алырга бавы да—һәммәсе дә әзер була. Менә монда да шуның шикелле булды. Нәкъ без сөйләшеп торган вакытта Наркомпрос почмагыннан Харис Саттаров үзе күренде.

—Әнә үзе дә килә,—диде мина иптәшем.

Без басып калдык. Харис иптәш Саттаров һәм аның янында нindидер бер урта яшьләрендәге чандыр йөзле, зәңгәр күзлекле кеше үлек озатканда катафалк артыннан баручылар адымы кебек әкрен, ялкау адым белән узып киттеләр. Зәңгәр күзлекле кешенең портфеленең артык зурлыгын, тулылыгын исәпкә алганда, аны читтән килеп тә Казанда әле фатир таба алмыйча йөргән берәр ответработникка яки берничә айлык эшне портфель эчендә йөрткән суд башкаручысына охшатып була иде.

Минем беренче тапкыр Харис Саттаров иптәш белән исәнләшүем, ана нык кына иттереп баш июем шунда булды. Әлбәттә, ул мине танымый иде. Ләкин минем артык бер самими йөз белән баш июем аның кәефенә киткән булса кирәк, ул үзе дә минем кебек баш ию белән җавап кайтарды. Аннан соң иптәшенә борылып нәрсәдер сөйләп китте.

Йөрәгем сизде: ул, мөгаен, иптәшенә ни дә булса алдагандыр; бу кеше наркомнарыбыздан, яки профессорларыбыздан, яки, һич булмаса, атаклы язучыларыбыздан фәлән фәләнов, минем бик якын танышым, дигәндер. Аннан соң минем аңа никадәр ихтирам белән караганлыгымны сөйләп, мактангандыр. Ә иптәше, зәңгәр пыялалы пенснэсен төзәтә-төзәтә, монын сүзенең ялган икәнен белә торып, бик ышанган, гаҗәпләнгән һәм үзенең минем белән таныш булмавына үкенгән кыяфәт белән тынлап баргандыр.

Шуннан соң инде мин Харис иптәш Саттаров белән ешрак очраштым һәм очрашкан саен, мөмкин кадәр, иске танышлар кебек исәнләшә башладым. Шулай да ныклап очрашу һәм ныклап танышу башка җирдә булды.

Казанда цирк программаларында Анатолий Анатольевич Дуров гастрольләре һәм нindидер бер заграничный хатынның ат өстендә мәтәлчек атачагы язылган көннәрнең берсе иде. Циркка бардым. Чиратта кешенең күплегенә хәйран калырсың. Нишләргә? Әлбәттә, шундый вакытларда кассиршаның таныш булуы белән файдаланырга тырышасың. Мин дә шул уй белән чиратсыз-нисез кассага юнәлдем. Ләкин тиз туктарга туры килде—артымнан берсе җиңемнән тарта:

—Син кая киттең, чиратсыз!—ди.

Борылып карасам, үзенең өч-дүрт яшьлек кызын тоткан Зәкия ханым басып тора. Таныйм: ул шомырт күзле кечкенә кыз—Зәкия ханым ата-аналарга, парлап тору «мещанлыкларына» каршы көрәш алып барган вакытларында туган кыз ул. Аның атасының кем икәнен Зәкия ханым үзе дә белми, ди.

Зәкиягә борылып кулны сузган идем, ул кулын бирмәде:

—Не культурно!—ди.

Колакка ирекле-ирексез бер тавыш ишетелде. Чиратта торучы берәүнең, нәкъ Зәкия туташның кызы яшьләрендә булыр улы:

—Әти, әти, кайчан атларны күрергә керәбез инде, бүген дә теге зур, ак ат булырмы икән? Нигә аны ашатмыйлар икән, ә безнең Акбай нинди таза,—ди.

Үзе әтисенә ышырыла. Шундый әйбәт әтисе булганга шатланган күзләр белән югары карый—әтисенең күзләрен очратасы килә. Минем башта тагын фикер туа һәм күзләрем Зәкия ханым кулындагы атасыз туган балага юнәләләр.

—Минә бу кызчык кемгә шулай «әти, әни» дигән сүзләрне әйтер. Нигәдер ул кечкенә кызчык кызганыч тоела.

Зәкия ханымга билет алырга дип акча алганда, минем янымда инде икенче иптәш тә басып тора иде. Карасам, Харис иптәш Саттаров икән.

—Син миңа да алты гына билет ал инде,—ди.

—Нигә ул чаклы күп?—дигән идем, ул чиратның койрыгына борылып карады.

Сиздем: анда ике нарком (тәшкәннәреме, хәзергеләреме, булачакларымы—анысы бик үк әһәмиятле түгел) цирк билеты алырга чиратта торалар иде. Беләм мин аларны, театр кассасы тирәсендә күргәнем юк үзләрен, ләкин кинода Гарри Пильне карарга билет алып биргәнем бар үзләренә.

Барлыгы миңа тугыз билет алырга туры килде. Кассирша алдында чиратсыз шул чаклы билет алуым өчен гаять түбәнләндем. Ләкин башкалар алдында, бигрәк тә Харис Саттаров алдында күтәрелүемнең чиге юк иде. Ул дүрт билетны чиксез зур «услуга» күрсәткән фасон белән нарком иптәшләргә илтеп бирде дә киредән минем яныма килде. Ул миңа шунда беренче мәртәбә:

—Карагыз әле, без үзебез якын танышлар, ләкин мин сезнең фамилиягезне онытгым бит,—диде.

Аллады, хәерсез, белгән нәрсәне генә онытып була бит. Ә аның минем фамилиямне гомерендә дә белгәне, ишеткәне юк.

—Заһир Әүхәдиев,—дидем.

Без Саттаров белән партерның уң ягына киттек. Нарком иптәшләр дә, хурлык баганасы яныннан ычкынган кешеләр кебек, ашыгыч рәвештә чираттан чыгып, партерның сул ягына кереп утырдылар.

Минә минем Харис иптәш Саттаров белән ныклап танышуым шунда булды. Шунда инде мин аның кем икәнлеген белдем, ул да минем кем икәнлегемне белде.

Ул бер заман бөтенебезне ачлыкка туйдырып торган мәшһүр «КАПО»да—Казан потребитель җәмгыятендә дә эшләгән икән. Аннан Татсоюзга күчкән, аннан соң, Коммунхозда эшләгән, аннары инде минә миңа кирәкле учреждениегә килеп урнашкан икән. Ул иренеп кенә үзенең егерме беренче елгы чистка вакытында ай ярымлап тиф белән авыру сәбәпле партиядән механический төшеп калуы турысында да сөйләде. Восстановить итәргә йөргән идем, әле минә конкретный җавап алганым юк, ди.

—Нервларым да бозылып бетте инде, иптәш Әүхәдиев,—ди.

Ә мин аның өреп тутырган кебек тулы, кызыл битләреннән ботинка башына кан таммаса ярар иде, дип аякларымны үземә табарак җыештырам.

—Әйе, гомумән, гасабиланып, кибеп бетәбез, йөзләребездә кан әсәре калмый,—дим.

Ул да озын гына сулап куя да:

—Әйе,—ди.

Озакламыйча мин Харис иптәш Саттаровның хатыны Наилә ханым белән дә таныштым. Минем уемча, Наилә ханым—чибәр генә холыклы

ханымнарның берсе. Дөрес, ул бераз артыграк басынкырак. Шулай да мин аны ошаттым. Ул—сабыр, ашка-суга юмарт бер хатын. Тик анарда ничек тә тормышыннанниндидер ризасызлык сыман нәрсә сизелә. Ул еш кына әллә нинди уйларга бата. Була шундый вакытлар: син ана нәрсәдер сөйлисең, ул синең алдыңда аңлаган кеше кебек басып яки утырып тора. Соныннан инде син үз сүзләреңә җавап көткәндә, ул гаҗәпләнгән һәм аптырап калган кыяфәт белән күзләрен тутырып ача да, мишәрчәрәк итеп:

—Янадан сүләгез әле, мин ишетмичә калдым, нәрсәдер мечтать итәдер идем,—ди.

Әйе, ул шулай мечтать итәргә ярата. Ул моннан бер-ике ел элек Яна бистәдә татар мәктәпләренең берсендә укытучы да булган. Анда сыйныфта дәрес барганда да мечтать иткәләгән, хәтта күп мечтать иткән. Кайвакытта «Уян инде, Наилә апа» дип аның кабыргасына да төрткәләгәннәр. Ул әкрен генә борылган да тагын шул сүзне кабатлаган:

—Нәрсә турындадыр мечтать итәдер идем әле...

Шулай да ул үзенең мәктәптән чыгарылуының сәбәбен монардан күрми. Мине укучылар яраталар иде, тик мәктәп мөдире белән Наркомпрос инструкторы Сәйфуллин мина каршы булдылар, ди. «Мечтать» иткәләгән өчен дә, дәрестән калгалаган өчен дә артык нәрсә булмаган, тик аны бер кечкенә генә вакыйга харап иткән. Вакыйга менә болай булган: алар берничә укытучы беренче дәрестән соң тәнәфес вакытында коридорның бер башына тәрәзә төбенә җыелганнар да үзара фикер алышырга тотынганнар. Наилә ханым үзенең ачыкканлыгын, иртә белән тик бер кечкенә генә кисәк алма пирогы гына ашаганлыгын сөйләгән. Ана каршы икенче бер укытучы Хәлимә ханым үзенең бик һәйбәт иттереп кәбестә пирогы пешерергә өйрәнгәнлеген һәм аның алма пирогыннан туклыклырак икәнлеген әйткән. Шуннан инде төрле пирогларны бер-берсенә бәйләп комплекс методы буенча тикшерү башланган. Тикшерү озак дәвам иткән, кыңгырау да булган. Укучылар да сыйныфка кереп тулганнар. Ләкин тәрәзә төбе укытучы ханымнар белән һаман тулы булган... Менә шул нәрсә мәктәп мөдире Гыйниятулла Хисаметдинов иптәшкә, аннары Сәйфуллинга ирешкән. Моннан элек тә Наилә ханым кул астында шундый бер тикшерү эшләнгән булган; улысында алар алган чагында алсу төстә булган тар тирәле фетр эшләпәне кия-кия ничә төрле төскә буярга мөмкинлек турында сөйләшкән булганнар.

—Мин ул скандалларга чыдамадым, тоттым да мәктәпне үзем ташлап чыктым,—ди Наилә ханым.

Шуннан соң ул, бер җирдә дә эшләмичә, өй хуҗасы булып калуны артык күргән. Харис иптәш тә мона каршы килмәгән. Тота белсәң, мин тапкан да җитәр, дигән. Берәр эшче хатын яки коммунистка-комсомолка булса, «мин акча табар өчен генә эшләмим бит... фәлән...» дип фәлсәфә сатар иде. Ләкин Наилә ханым алай җаваплашып маташмаган.

Наилә ханым үзе—чыннан да яхшы өй хуҗасы. Аның өе тын була, җыйган була, нинди вакытта булса да ашарга берәр төрле азыгы була. Ул вак кына нәрсәне дә зур җитдият белән эшли. Вак кына нәрсә турында да җитди пафос белән сөйли. Ул мине кайчан телефон аркылы пәрәмәч ашарга чакыра, шундый җитди иттереп чакыра ки, Совнарком утырышына чакыралар дип белерсең. Тегендә телефон станциясендәге бичара телефонистка Наилә ханымның пәрәмәч турында шулчаклы җитди сөйләвен тыңлап торса, көлә-көлә эче катар иде. Кайчакта мин дә көләргә тотынам. Ә ул:

—Йә, сина көлке, минем анда пәрәмәчләрем кирәгеннән артык кызаралардыр,—дип телефон трубкасын калдырып кухнясына китә.

Трубканы Харис иптәш үзе ала.

—Ну, нихәл, шәп тордыңмы, беркөн башың авыртмадымы, мин икенче көнне көн буе мингерәп йөрдем. Катнаш нәрсә шулай була ул,—ди.

Кайсы көннәрдә гадәттән тыш ачу килә. Синең тирә-юненне эш белән килгән кешеләр чолгап алган булалар, сәгать унбер була, ә Харис иптәш һаман өйдән телефон шалтырата.

—Нихәл, син кичә өйдә идеңме?—ди һәм үзенең кайда да булса төн буе лото, карта, пиво янында утырганлыгын сөйли.

Мин аның пошымсызлыгына, ялкаулыгына, ашыкмаслыгына гаҗәпләнәм, шуңар карап эчем поша:

—Син, иптәш Саттаров, татар Обломовы булмакчы буласыңмы әллә?—дидем.

Ул үзенең симез иреннәрен кузгатырга иренеп борын аркылы көлә.

—Син Гончаров була алсаң, мин Обломов булырга риза,—ди.—Юк, түгел, мин Обломовка бер генә тамчы да охшамаган. Ул бит гомер буе караватта ятып уйлап үткәргән. Ә мин бөтенләй киресенчә—мин Наилә уйлаганда да эчем поша,—ди.

Соныннан мин үзем дә үз сүземнең ялгыш икәнлегенә тиз төшендем. Юаштан юан чыга, дигәндәй, бердән, аның мина «Син Гончаров була алсаң» дигән сүзе агулы тоела, икенчедән, шул ук вакытта Обломов белән Саттаров арасындагы аермалар күз алдына баса. Обломов бит ул русның әдәбиятын, шигырен, музыкасын аңлаган; ул заманына күрә «кешелек» дигән нәрсәне дә үзенчә бик нечкә рәвештә аңлаган. Ә бу—«сыер бит бу», дип уйлап куям, Тукайча. Обломов бит, чиновник булып торганда, Астраханьга җибәрергә тиешле бер рәсми кәгазьне үзенең ялгыш Архангельскига җибәрүен зур җинаять санап отставкага чыккан. Ә Саттаров инде меңнәрчә шундый кәгазьләр җибәргәндер, меңнәрчә ялгыш кәгазь җибәреп, меңнәрчә кешенең башын әйләндергәндер, ләкин алай да отставкага чыгарга җыенмый, хәтта, юл булса, югарырак үрләргә дә исәбе юк түгел.

Мин хәзергә чаклы Саттаров иптәшнең дөньяга карашын, тормышны ничек аңлавын, киләчәккә нинди планнар коруын белә алмадым. Бу турыда ул бөтенләй сөйләми иде. Кайчагында гына ул үзенең партиядән механически чыгуы белән бәйләп:

—Әйе, партия белән минем мөнәсәбәт мәсьәләсендә әнә шундый аңлашылмау булды,—ди торган иде.

Ләкин ничек аңларга? Ул, бәлки, башкача аңлагандыр. Ләкин мин, Саттаров иптәш белән ныклап танышкач, аның бу сүзләрен һәрвакыт бертөрле аңладым:

—Әйе, аңлашылмау булган: синең егерме беренче елга чаклы партиядә тору мәсьәләң аңлашылмау булган...

Үзенә мин мондый фикерне туры әйтә алмадым. Тик кайбер сүз уңае белән генә:

—Син, иптәш Саттаров, хәзер обывательләрчә бөтен нәрсәгә пассив карыйсың. Совет эшенә булган бөтен мөнәсәбәтең биш-алты сәгать учреждениедә утыру белән бетә. Сина бит «татар чиновнигы, аппарат балласты» дип караулары мөмкин,—ди торган идем. Ул:

—Ярый, ярый, артык активлашып киттең, эч әле, эч әле, эч. Кыярның «үрнәк» магазиннан алганын кап. Мин ул турыда үзем дә берәр вакыт ныклап уйланырга йөрим әле. Тик менә бушап кына булмый!—дия торган иде.

Мине гаҗәпләндергән нәрсәләрнең берсе—Харис иптәш Саттаровның үз вакытында учреждениегә эшкә йөри алуы иде. Ләкин ул кичен төн буе кайда да булса утыра . Ә иртә белән узышлый янына кергәндә инде ул учреждениедә очрый. Кайвакытта мин аның үзен күрәм, кайвакытта ул портфелен өстәл өстендә калдырып каядыр киткән була. Гаҗәп кеше ул, портфелен калдыра да үзе каядыр югала... Тик сәгать унберләрдә генә үзенең каядыр мөһим бер җыелышта булганлыгын яки хосусый эш белән киткәнлеген әйтеп, сөйләнә-сөйләнә кайтып килә.

Беркөнне мин Харис иптәш Саттаров янына занятиедән кайтышлый кергән идем, гаять бәхетсез бер вакытка туры килдем. Учреждениедә

киемнәр элә торган җиргә бөтен учреждение халкы диярлек җыелган. Алар алдына шунда ун елдан бирле эшләп килгән сторож карт баскан. Аның бөтен кыяфәте нәрсәдәндер чиксез курыкканлыгын күрсәтеп тора. Башы түбән иелгән, чырае киткән. Аңа каршы учреждениенең эш башкаручысы Иван Сергеевич Лапин басып тора. Ул өстенә кигән, ә башы яланбаш.

—Ни булган?—дидем.

Бөтен халык, тәртипсез тезелгән солдатларга кинәт команда бирелгән кебек, миңа карады.

Харис иптәш бик мөһим нәрсә сөйләгән кебек мәсьәләне аңлатты:

—Менә Иван Сергеевичның каракүл бүреген алып киткәннәр. Әле өченчекөн генә җиде сум биреп төзәттергән булган,—диде.

Үзе, минем бүрегем башымдамы икән, дигәндәй, башын тотып куйды, ул гына түгел, башкалар да кулларын башларына суздылар.

Хикәядә актык вакыйгага иттереп сөйләргә теләгән нәрсә—менә шушы бүрек югалтканның нәкъ иртәгесе көнне булды.

Наилә ханымның кулыннан зур эш күтәргә мөмкин булмавы сезгә билгеле инде. Соң, азмыни шундый кулыннан эш килмәслек хатыннар. Аларның барысын да сөйләп тә бетереп булмас. Кайсылары турында, иренә ярагач, безгә нәрсә, дип тә карап куясың. Әнә Наилә ханым инде Саттаров иптәшкә чынлап та ярый иде. Байтак вакыт мин алар белән таныш булып тордым. Соңгы вакытларда Саттаров иптәш әлеге учреждениедән чыгып—чыгарылып, тәмам Казаннан күчеп киткәнчегә хәтле аларның хәлләрен белеп тордым. Хәтта аны Тәтештә дә тоз баржасына заведующий итеп билгеләгәннән соң да күргәләдем. Ләкин шул озак вакытта мин Саттаров иптәш белән Наилә ханым арасында һич гаилә кычкырышы очратмадым. Хәтта вакыт-вакыт пар күгәрченнәр кебек сайрашып торалар иде. Мондый вакытта Саттаров иптәш:

—Наиләчек,—дип тә җибәрә иде.

Ләкин мондый неп-нечкә сүз Саттаров иптәшнең яртышар кадаклы ирене белән чолганып алынган туп-тупас авызыннан әллә ничек килешсез чыга торган иде.

Наилә ханым белән аның ире арасында әнә шундый мөнәсәбәт иде. Гомумән, Наилә ханым йомшак табигатьле, һичбер кешегә зарар итү ихтималы булмаган бер хатын иде. Кулдан зур эш килмәүне җинаять иттереп аңлап булмый инде аны. Тик шулай да мин әнә шул бүрек вакыйгасының иртәгесе көнне Наилә ханымны җинаятьчеләргә генә хас хәлдә очраттым: аны мин конвой белән бара торган арестантка хәлендә күрдем.

Милиционерның бер кулында портфель, икенче кулын ул наган кабурасына тергән: нәкъ арестовать ителгән кеше янынннан барганча бара. Ни булган? Наилә ханым нинди җинаять эшләгән? Һичбер җавап бирә алмадым. Бездә элекке елларда Гайнетдин урынына Котбетдинне өч-дүрт көн генә яткырып, аннан соң, ялгышлык булган, гафу итегез, дип чыгарып җибәрүләр булгалый иде. Әллә хәзер дә шул хәлме? Кайсы көннәрдә төнлә төрле җинаятьләр белән тотылган ханым һәм «туташ»ларны иртә белән җинаятьләрне эзләү бүлегенә алып киләләр иде. Әллә Наилә ханым да нииндидер явыз язмыш, хәтта бөтенләйгә үтерелгән тәкъдир аркасында шулар арасына эләккәнме? Ул әллә шулар арасыннан качканда тотылганмы? Тфү... Нинди саф бер ханым турында нинди әшәке уйлар!

Бу очрашу нәкъ Кремль капкасы төбендә булды. Мин эчкә керә идем, ә Наилә ханым белән милиционер чыгып баралар иде. Наилә ханым мине күрдеме, юкмы, мин аны уңайсыз хәлдә калдырмау өчен аңа күренмәскә тырышып бер почмакка борылдым. Күзләрем Кремльнең ишелгәннән соң төзәткән, ләкин буярга өлгермәгән ала-кола стеналары буйлап Казан монастыренең симез һәм ялтыравыклы куполына юнәлделәр, күнелем Наилә ханым кайгысы белән тулды. Бераздан мин борылып караганда, алар Ивановский монастырь буйлап тар тыкрыктан Сорочий

базарына таба төшеп баралар иде. Нишләргә? Артларыннан китсәң, тегендә эш кетә, китмәсәң, күнел борчыла. Артларыннан киттем. Алар уртача гына адым белән Сорочий базарының вак-вак кибетләре арасыннан борылып-борылып беренче район милициясенә таба киттеләр. Ничек бу болай? Алар анда туктамадылар. Мин дә туктамадым. Тик Проломный буенча барып, «Тум» магазины тыкрыгыннан борылып, Саттаровның квартир ишегенә житкәч кенә барыбыз да туктадык. Ишегалдында мин аларны куалап життем. Күзләрем Наилә ханымга юнәлделәр: аның күзендә яшь бөртекләре күренә, йөзе дә хурлану билгеләре белән тулган иде. Каршыбызга Саттаров үзе чыкты. Аның шешенгән кабаклары, кызарган күзләре «кичә без эчтек» дип туп-туры кычкырып торалар иде.

Наилә ханым һич тә аңарда булуы көтелмәгән бер гайрәт белән еларга, ярсырга тотынды:

—Адәм көлкесе бит, адәм көлкесе! Син мине бөтен Казан алдында хур иттең! Бөтен Проломный буенча жир тишегенә керерлек булып бардым... Имеш, аның башы авырта, имеш, ул бераздан үзе барачак. Өстәл өстендә портфель булгач, шуның белән эш бетә, имеш. Бетте менә, хәтта бөтенләйгә бетәр... Иртәгә үк бөтен Кремль синең гайбәтең белән тулачак бит...

Вакыйганың серенә көчкә төшендем. Харис Саттаров моннан элек тә байтак вакыт портфелен алдан жибәреп үзе соңыннан баргалаган. Ләкин бүген, Наилә ханым бәхетсезлегенә каршы, эш башкача барып чыккан. Наилә ханым Харис утыра торган бүлмәгә портфель күтәреп кергәндә, анда инде эш вакытыннан алда килеп, берничә кеше эшкә тотынган булганнар. Ят бер ханым килеп керү белән алар аңа караганнар. Наилә ханым да аларга караган. Шуннан инде нишләргә белмичә, портфельне күтәреп кире чыкканда, көтелмәгән зур скандалга очраган. Кичәге бүрек вакыйгасыннан соң тәмам аптырап, кемгә бәйләнергә белмәгән, бүрек урлаучыны тапса, Әбүҗәһел хатыны хәзрәте Хәмзәне өзгәләгән кебек тешләре белән өзгәләргә житешкән карт сторож, ниндидер бер чит хатынның, кеше күрмәсә ярар иде, дип чыгып баруын күрү белән:

—Син кем, занятие башланмас борын биредә нишләп йөрисең?—дигән.

Иремнең портфелен өстәл өстендә калдырырга килдем, дияр хәл юк бит.

Наилә ханым да алай димәгән; башка жавап та таба алмаган—«ык-мык» иткән дә чыкмакчы булган. Шуннан соң инде сторож да, үзенең карт гәүдәсен ашыгыч рәвештә Наилә ханым янына ташлап, Наилә ханымның куркынган күзләренә карап, мәсьәләне бөтенләй кабыргасы белән куйган:

—А...а... попалась, шлюха, скажи, где шапка, вчера шапка, сегодня порт-фель...—дигән.

Шул арада Саттаров иптәш бүлмәсендә эшләүче машинистка да, занятиегә килеп, портфель урлаучы хатынга боргаланып-сыргаланып караган да:

—Хулиганка, как не стыдно!..—дип эчкә кереп киткән.

Шулай, Наилә ханым чыдаган, милиционер алып килгәч тә чыдаган, квартирга житкәнче чыдаган. Тик анда кайткач кына ул чыдамады. Сүгүенең соңгы сүзе итеп:

—Оятсыз син!—диде дә үзе алдында эчке күлмәктән торган Саттаровның ачык изүендә күренеп торган йонлач күкрәгенә төкерде.—Тфү,—диде.

Наилә ханымның шундый урында булса да ире өстенә гайрәтләнә белүенә шатландым.

Ә бу вакытта минем теге энем, Саттаров рекомендациясе белән урнашып, госмагазиннарның берсендә сату итеп судка эләгергә дә өлгергән иде инде.

ИСКӘРМӘ

Кайчакта, элекке буыннар әдипләребез әсәрләрен укыгач яки мәгълүматлы кешеләрнең сүзен тыңлагач, наданлыгыңа исең китә дә:

—Нәрсә генә беләм соң мин...—дип балаларча беркатлылык белән, ихластан әйтеп куясың.

«Казан утлары» журналының «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» бүлегенә әсәрләр әзерләгәндә, миңа әлеге сүзләрне еш, хәтта моңарчы һәр очракта диярлек әйтергә туры килә. Мәҗбүрмен! Гомәр Галинең хикәяләре, очерклары, әдәбият гыйлеме мәкаләләре белән җентекләбрәк танышкач, югарыдагы мәгълүм гыйбарәне тагын кабатладым. Г. Галинең кыска күләмле әдәби әсәрләре, күп санлы тәнкыйть мәкаләләре узган гасырның егерменче һәм утызынчы елларында аның татар әдәбияты казанышларын ишәйтү өчен таланты көчен кызганмыйча иҗат итүен исбатлыйлар.

Гомәр Гали (Гомәр Билал улы Галиев) 1900 елда Буа районының Иске Тинчәле авылында туган. Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, ул Донбасс шахталарында эшли, Кызыл Армиядә үзе теләп хезмәт итә, гражданнар сугышында катнаша. Татар коммунистик университетында тырышып белемен баета, аны тәмамлаган елда ук—егерме биш яшендә «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакторы була, аннары ун ел дәвамында Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият секторын җитәкли, Татарстан Язучылар берлеген оештыруга күп көчен сала.

Аның ишле үк булмаган хикәяләре университетта укыган елларында языла. Аннары ул, нигездә, әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнә. Г. Гали хикәяләрендә дә, башка күп кенә әдипләрнең шул чордагы әсәрләрендәге кебек, иске белән яңа арасындагы көрәш чагыла, тормыштагы тискәре күренешләрнең сәбәбен ачарга тырышу сизелә. Журнал укучылар игътибарына тәкъдим ителгән югарыдагы хикәядә дә эшлексезләр, эш кешесе җилкәсендә утыручылар фаш ителә. «Харис Саттаров» исемле бу хикәянең язылу елы күрсәтелмәгән, ул язучының «Г. Гали хикәяләре» (1931 ел) дигән китабына кертелгән. Журналда бастыруга әдипнең «Сайланма әсәрләр»еннән (Татарстан китап нәшрияты, 1958 ел) алынды.

Әдәбиятта үз урынын тапкан Гомәр Гали репрессиягә эләгә. Ватан сугышыннан соң ирекккә дә чыгарыла. Һәм иҗат эшенә ныклап бирелә. Тик аны тагын кулга алалар, ул 1954 елда вафат була.

... Гомәр абый Галине, аның ирекккә чыгарылган вакытында, миңа күреп калырга насыйп булды. Матбугат йортының өченче катында, Язучылар берлеге бүлмәсе каршында, тәрәзә төбенә сул терсәге белән таянып, ялгызы басып тора иде ул. Аны миңа, хәтерем ялгышмаса, Зыя Мансур күрсәткән иде. Әмма без Гомәр абый янына барырга базмадык. Күрәсең, Зыя Мансур да аның белән таныш булмагандыр. Шәриктәшем Зыя абый белән мин университетның беренче курсында гына укый идек әле... Шулай да бер нәрсә күңелдә уелып калган.

Матбугат йортының бу тар, әмма урамга караган якты коридорында, ялгызы басып торучы Гомәр Галинең узган-киткәнгә игътибар итмәгән кыяфәтендә, горурлыгы җәелгән-бөркелгән киң йөзендә, үткен һәм тирән уйчан карашында болай дип язылган кебек иде:

—Нәрсә беләсез соң сез...

Аның шушы халәте һич тә онытылмый.

*Әсәрне журнал өчен*
**Мәгъсум ХУҖИН** *әзерләде.*

# ЙОЛДЫЗЛАРНЫ ТАНЫП, СӨЕНӘ БЕЛИК...

## ШИГЫРЬЛӘРЕБЕЗ ТУРЫНДА БЕР УЙ

*Баш очымда инде ничә йолдыз!*
*...Ә йолдызлар күп бит, күңел... Сөен!*

Йолдызларга сокланып, димәк ки, биеклеккә, шигырьгә табынып узган яшьлектән калган бу юллар(ым) инде якты күзләремә дә туры килмәсме? Әйе, инде аксакаллар яшенә җиткән, шактый күп яшәлгән—янып көйгән, язган, укыган, сокланган, инкарь иткән, тагын сөенеп кабынган—димәк ки шигырь белән узган гомеремә, диюем?! Инде шигырь дә, шагыйрьләр турында да язылмады түгел (кем әйтмешли, «инде мин дә яшәмәдем дисәм!»), ә язасы, фикер уртаклашасы, кычкырып уйланасы, нәрсәдер әйтәсе килә—ахрысы, бу—олыгая барган кешеләрдә күңел бушатасы килү халәтедер. Гәрчә бик беләм: шигырь, «Әнкәбез-Шигърият», үз каләмдәшләрең—шагыйрьләр турында язу—ул шигырьнең үзен язу-тудыруга караганда катлаулырак, четреклерәк эш бугай. Кырык елга якын язучыларның төрле җыелышларында, корылтайларында, секция утырышларында катнашкан, ниһаять, үзем дә шагыйрьләр секциясе җитәкчесе, журналда поэзия бүлеге мөдире сыйфатында озак вакыт «шагыйрьләр белән эшләгән» кеше буларак та әйтәм: шигырь турында фикер-сүз әйтү, докладлар, күзәтүләр, мәкаләләр һәрчак диярлек авыр кабул ителә, тәнкыйтькә очрый, сөйләүчене бүлдерәләр, хәтта мөнбәрдән үк куып төшерәләр... Шундый эмоциональ халык инде без!

«Демократия чоры» моны тагын да «камилләштерде», гадәткә әйләндерде. Төрле-төрле фикерләргә дә урын-мәйдан мул ачылды, үз сүзен әйтергә теләүчеләр дә, сәләтлеләр дә шактый күп булып чыкты—кыскасы, элек авторитетлы, компетентлы дигән тәнкыйтьчеләребез йә аксакалларыбыз сүзенә колак салгандай моң гына яшәгән әһле каләм инде үз хокукын яклый, даулый алу көчен дә күрсәтте. Әйе, шигырь, ахрысы, яратылышында ук субъектив, индивидуаль—ягъни хис, акыл җимеше булуы табигый. Ә тәнкыйтьне, нинди генә объектив булмасын, шундый дип кабул итәбезме соң без? Кайсыбыз «ярата» аны? Үзебезне «мактаган әйбәт язмаларны» искә алмаганда... Шуңа да, тәнкыйть үсми, шигырь тәнкыйте юк, дип сөйләүләр һаман дәвам итәчәк. Һәркем үзен, язганын дөрес аңлауны көтә, өмет итә, һәм бу, табигый, һаман да ерак бер хыял килеш. Укучы эзләү, әзерлекле, хуш күңеллелек белән, М. Цветаева язганча, шигырьгә «соучастник» булган, ягъни иҗатташ, фикердәш, теләктәш укучы турындагы уй кебек... «Бөек укучы булганда гына бөек шагыйрьләр була», дияргә дә яратабыз бит без. Бу сүзебездә бөек булырга потенциаль теләк, дәгъва, мөмкинлеккә дә «яшерен» генә ишарә ята түгелме? Хәер, кайсы чын шагыйрь үзенә шундый ышанычтан башка гына язсын икән?! Ул бит элек-электән пәйгамбәрләр белән ярышып иҗат иткән. Пәйгамбәребез Мөхәммәткә дә үз вакытында «оппозициядә»

торган шагыйрьләр күп булган... Коръәндәге «Шагыйрьләр» сүрәсе дә юктан гына тумаган—Ходайдан вәхи алган пәйгамбәребез аларны шул ук шигырь теле белән «тәртипкә сала».

Хәзер дә шулай бит: һәр яңалык, яңа вәзгыятьләр чорында әүвәл шагыйрь мәйданга чыга, көрәшә, кирәктә үлә дә белә. Әллә инде бу яшәү дигәнебез дә шигырьдән аерылгысыз микән? Борынгыдан ук шагыйрьләр казаны, милли өметләр, шигъри дау вә шау-шулар ватаны булган шәһре Казаныбызда хәзер дә шагыйрьләр бихисап: «үрчедек», Нажар Нәҗми әйтмешли. Күп язабыз, сөйлибез, газета-журналларда тулып басылабыз, китап чыгарабыз, җыр булып радиодан яңгырыйбыз, мәйданнарга чыгабыз—һәм бу матди яктан иң авыр бер вакытта! Кайда монда мантыйк? Нигә хәзер бик күпләр, хәтта башка жанрда язучылар шигырьне якын итә, шигырь китаплары чыгара? Депутатларыбыз җанында да—шигырь җене, шигырь теле... Туфан Миңнуллинга ни җитмәгән, даны аз идеме? Ә ул менә дигән робагыйлар диваны бастырып чыгарды (үземнең дә шул көннәрдә робагыйлар китабым дөнья күргәнгә, чагыштыру, нәтиҗәләр ясау өчен җай булды. Тәнкыйть мәкаләләре дә булды). Гариф ага Ахунов—мәрхүм дустыбыз да шигырь-җырдан аерылмыйча яшәде ләбаса. Җырчы Г. Ибушев—менә дигән шагыйрь. Хәмит Латыйпов атлы милләттәшебез әнә шундый шагыйрь-рәссам. Һәр яңа талантлы әсәр йә китапны күргәч, җаны түзми ташый торган Айдар Хәлим аның шигырь китабы турында мәкалә дә язып чыгарды. (Ирекле шигырь һәм Кави Латыйп эволюциясе турында да язды ул, Рифкать Закиров иҗаты турында да, яшьләрдән Луиза Янсуар китабы хакында да җитди эссе чыгарды. Һәм күптән түгел—инде барыбызга да сабак өчен булса кирәк, «Милли шигырьләр» исеме белән, үзенең сайланмасын да мәйданга куйды. Башка жанрларда үзенчәлекле, вакыйга булырдай китаплары басылып та, татарча шигырь сайланмасы юк иде әле Айдарның. Мәрхәбә!—диик моңа. Бу—сүз җаеннан гына. Югыйсә, соңгы өч ел эчендә шактый шигырь китаплары басылды—алга таба телгә алырбыз аларны.) Ләкин бер нәрсә нәкъ элеккечә калды: басылып чыккан китапларны күрү, уку, алар турында язу, яңалыгын билгеләү юк дәрәҗәсендә, һаман шул: бер-береңне уку, игътибар, ихтирам юк. Туфанлы, Хәкимле чор сагындыра хәзер—«пир» саналырдай аксакаллар юк. Булган байлыкны, чын шагыйрьләребезне пропагандалау да аз. Кыскасы, үз йолдызларыбызны үзебез үк танымыйбыз кебек. Тәнкыйтьтә «егерменче гасыр ахырында Тукайлар чорындагы кебек якты исемнәр булмады» дигән фикерләр дә күренде. Янәсе, гасыр ахырындагы талантлы шагыйрьләр—яңа гасыр башы йолдызлары өчен җирлек, зәмин генә булды. Монсы да әйбәт! Ә Тукай бит: «Яктырак йолдыз янадыр төн кара булган саен...» дип язган. Бүгенге заман нәкъ шундый, бәлки? «Тукайдан—Зөлфәткәчә чор» дип атадым үзем дә егерменче гасыр татар шигырен. Ә күпме исемнәр, зур шагыйрьләр яшәде бу чорда!.. 2000 елда Тукай премиясе Зөлфәткә бирелсә, 2001 дә әнә Роберт Әхмәтҗан лаек булды. Димәк, узган гасыр арсеналы әле тулысынча яңасына күчә. Анда—халык шагыйрьләребез дә, Тукай премиясе лауреатлары да шактый. Шуларныңмы аерым җылы сүзгә «хакгы юк»? Ай-һай! Дистәдән артык бит якты йолдызларыбыз, яна алар, яна!

Бу титуллар, әлбәттә, Франция академиясе «үлемсез»ләре—аның 40 әгъзасы кебек үк, мәңгелеккә дәгъва итмиләр дә (Ә бит бу бәхетлеләр арасына Бальзак та, Дюма да «сыймаган»!), шулай да җанр өчен горурлык зур: йолдызларыбыз бар, алар яна, яначак! Әле танылмаганнары да, яңалары, яшьләре дә бардыр... Әйе, язганнарыбыз басыла тора. «Казан утлары»нда, «Идел»дә, «Мәдәни җомга»да, башка газеталарда. Китаплар да, аллага шөкер, дөнья күрә. Бу җәһәттән яңа «Рухият» нәшрияты эше бәрәкәтле булды: соңгы 2-3 ел эчендә бик затлы, шәп басмада шагыйрьләребезгә юл ачты ул. Мәрхүм зур шагыйрьләребез С. Сөләйманова, Рәш. Әхмәтҗан томнары өчен сөенеп өлгермәдек, мәйданга исәннәр—Г. Афзал, Ф. Яруллин кебек халык шагыйрьләребезнең тансык китаплары, К. Булатова, Зөлфәт, Ф. Гыйззәтуллина, Н. Әхмәдиев... соңгы арада гына М. Әгъләм, Роб. Әхмәтҗаннарның саллы томнары килде. Рәхмәт бу нәшрият хуҗаларына, редакторларына—ихластан тәбрик булсын аларга! Дәвам итсен бу эш, сүрелмәсен...

Кайбер «җан атып, борчылып, сөеп язучылар» әйтүенчә, янәсе, соңгы

чорда «60 елларда ирешелгән зур уңышларыннан ерагая барган» безнең буын шагыйрьләренең дә яңа китаплары басылмады түгел: Р. Фәйзуллинның чираттагы 4, 5 томнары чыкты; Ренат Харисның бер-бер артлы яңа җыентыклары дөнья күрде. Үземнең дә юбилеем уңае белән «Гамь шәрабе» исемле лирика китабым, «Газәлләр» диваным чыгу шатлыгы белән уртаклашсам, гаеп булмастыр. Гәрәй Рәхимнең дә шигырь китабы—«Замандашларына хат»ы басылды, томнары әзерләнә. Бу китапларга да бәяне бирми калмаслар дип ышанам. Әле юбилейлары мөнәсәбәте белән дә матбугатта яшьтәшләрем хакында шактый күп, әтрафлы мәкаләләр булды. Н. Измайлова, Ф. Зыятдинова, Акъегет, Ш. Җиһангировалар иҗаты турында да язмалар чыкты. Матбугатта еш басылган шагыйрьләребез иҗаты да сөендерә килде (яңа китаплары чыкмаганнардан): Ш. Галиев, И. Юзеев, Ә. Баян, Ш. Маннап, Ә. Рәшит, Р. Миннуллин, Х. Әюп, З. Мансуров, Л. Шагыйрьҗан, Р. Закиров, К. Латыйп, Р. Низами, Б. Рәхимова, Н. Сафина, Р. Рахман, Л. Янсуар һ. б.ның публикацияләре еш һәм хәтердә калырлык булды. Яна исемнәр дә күренә тора...

Соңгы елларда Г. Морат «Түбә»се өчен түбәбез күккә тиеп шатландык. Бик матур бәйләмнәре белән шатландыра килгән Н. Гамбәр дә яңа китабы белән үзенә лаек күркәм урын яулады дия алабыз: уйлы, оригинал сурәт-фикерле, житди шагыйрь булуын күрсәтте ул. Әдәби мохиттә—Казаннан читтә яшәүчеләргә игътибар артты, үзләре дә активлашты бугай: Г. Мөхәммәтшин, И. Гыйләжев, Ә. Исхаков, М. Мирза һәм В. Фатыйховлар турында әйтүем. Язганнары саллы, ышанычлы янгырый, үзләре дә ихтирамга лаек затлар. Шагыйрьлек белән «ялтырап», богемачылыкта Ходай биргән талантны исраф итүчеләр чоры түгел хәзер. Андый «бунтарьлык»—җимешле дә түгел. Ерак иләрдән шигырь өчен жан атып яшәргә Казанга кайткан С. Мулла Гали якынрак безгә алардан, билләһи! Читтә дигәннән, Уфа—Башкортстандагы Р. Идиятуллин, Х. Мөдәррисовалар иҗаты да кадерле безгә. Кырымда яшәүче Ә. Синугыл да яначa ачылып, төрки дөнья рухына якын жанрларда яза башлады...

Шагыйрәләребезгә аерым бер игътибар, мәхәббәт белән тукталсам кирәк. Соңгы елларда күзгә күренеп үзгәрде, үсте алар. Клара Булатова беренче чиратта шундыйлардан саналырга лаектыр: әлеге «Рухият» чыгарган «Шушы җирдән, шушы туфрактан без» исемле китабы һичшиксез уңышлы басма. Сабыр, тыенкы бер холык белән хатын-кызның тирән яшерелгән хис һәм дәрт-көчен чагылдыра ул. Инде күпне күргән, кичергән, үз фәлсәфәсе, образлар дөньясы белән тормышчанлык һәм мәңгелек Наз сөйли кебек анда. Безнең заман хатын-кызы язмышының көзгесе дип тә әйтергә буладыр... Ф. Гыйззәтуллина, Б. Рәхимова, Ф. Зыятдинова, И. Иксанова, Ф. Мөслимоваларнын китаплары да шулай кабул ителде—алар турында шактый әтрафлы күзәтүләр, мәкаләләр булды. Хатын-кызларның шигырьдә шулай жанлы, матур эшләве яшьләр өчен дә үрнәк, мөгаен: соңгы елларда мәйданга чыккан Л. Янсуар, Г. Вәлиева кебек яшь шагыйрәләрдә С. Сөләйманова һ. б. мәктәбен тоеп була. Әлбәттә, дөнья шигърияten дә, шәрекъ бөекләрен дә, тоташ агым—мең еллык төрки-татар шигырен дә, Г. Сәмитованы да, Ахматова, Цветаеваларны да өйрәнә бүгенге яшьләр...

Шигырь тәнкыйтьчеләре бик хаклы әйткәнчә, бүгенге язганнарыбызда стиль-алымнарда бертөрлелек, бигрәк тә гомум сәясилек, ялангач публицистика, прозаизм, хәтта примитизм көчәйде. Бу нидән? Мөгаен, шигырь теле, стиле, индивидуаль алымнарның бертөслелеге, ярлылыгы күренешедер. Тенденция рәвешен алды шикелле бу хәл: йә, танылган йәки атаклы бер шагыйрь почеркын башлап язучыныкыннан аерыла дип әйтеп буламы? Шул ук коры информатика, прозаик «быт», һәркемгә таныш-гомум акыл-фикерләр «интернет»ы түгелме? Артык дөрес милли чынлык, мангайга бәреп әйткән, берләнбер дип уйланган хакыйкать, шигырьнең үз үсешеннән, эчке сер-көрәш логикасыннан килеп чыкмаган нәтиҗәләр... Бер шагыйрьне икенчесеннән ничек аерырга хәзер? Хәтта жанрларда да, үлчәү, формада да игезәктәй охшашлык китте түгелме? Менә шундый чакта хәтта төрле эпатажлары, үзенчәлекле эзләнүләре, стиль атрибутлары белән ялтырап алсын икән берәрсе! Яна шагыйрь килде дип, һәркем таныр, күрер иде аны... Шагыйрьнең барыннан да бигрәк

«нәфасәт багында сакчы» булырга тиешлеген дә онытабыз... Ә бу кинәшне, Дәрдмәнд уйлаганча, бик үк «тотмаган» Тукаебызның да бөеклеге—публицистиканы якын иткән шигырендә генә түгел, ә бәлки, тинсез тел-сурәт остасы булып, төрки бөекләрнең рухын дәвам итеп, гадилектән илаһи югарылыкка күтәрелә алуындадыр... Бу—бик сирәкләргә генә бирелгән халыкчанлык. Бүген без юкка гына Г. Афзал, Ф. Яруллин, М. Әгъләм кебек шагыйрьләрнең көчен танымыйбыз бит: алар—нәкъ менә элгәрләрнең юлын дәвам итә бу бабта.

Роберт Миннуллин да халыкчанлыгы белән яраттыра... Зөлфәтнең «Былбыл сулышы»нда да шушы югарылыкны, шагыйрь үзе язганча, «Ходай сулышы» кебек иркенлекне, киңлекне тоеп, тетрәнәсең. Рөстәм Мингалимнең даулы, көрәшле тормышчан бәйләмнәре дә җанга якын. Гәрәйнеке дә...

Равил Фәйзуллинның шигъри үзенчәлеге—бөтенләй башка, мөгаен. Безнең күзәтүебезчә, бу—шагыйрьнең үз шәхесе, дөньяга карашы, кешеләр белән мөнәсәбәте, мәхәббәте, нәфрәтенең нык калку бирелешендә. Әйе, дөнья, Җир Кояш тирәли йә Ходай ирке белән түгел, гүяки шагыйрь тирәли, аның көче-ихтыяры белән әйләнә, яши, аңа буйсына кебек. Шагыйрь—барыннан да бигрәк хөкемдар, хакимлек итүче... Бу лирик герой, «мин» характеры белән бәхәсләшергә, хәтта кабул итмәскә мөмкин, әмма аның көчен танымыйча булмый. Шагыйрь «Сайланма әсәрләр»енең әлеге 4, 5 нче томнарында инде аксакалларча—ил гаме, халык язмышы турында уйланулар, борчылулар тулы сәхифәләрдә әдәби-мәдәни дөнья уртасында янып яшәүче шагыйрь күзаллана.

Поэма жанрында иң актив эшләүчеләр, әлбәттә, И. Юзеев, Р. Харис, Ә. Рәшит, Ф. Гыйззәтуллиналар... Сүз дә юк, һәммәсенең инде берничә дистә поэма язу тәҗрибәсе бар, жанрны яхшы белеп эш итәләр—укыла, бәхәсләр, төрле фикерләр уята алар. Бу көндә озын поэмаларга ихтыяҗ бармы, резонансы, перспективасы нинди—бусы икенче мәсьәлә. Шагыйрьләребез һаман яза; шәхси тәҗрибәләрме бу, милли, рухи нәтиҗәләрме? Вакыт хәл итәр...

Марс Шабаевның «Ярты төн бәхете» поэмасы. Сугыш чорында ирсез калган кызлар... бүген дә исән толлар язмышы, саф сөю турында ул. Бу әсәр хәтта дәүләт, җәмәгать эшлеклеләренә дә ирешеп, хатын-кызларыбыз тормышын матурлау-яхшырту уйларына да этәрде, диделәр... Амин!—диик.

Шигырьдә һаман да яшь булып кала алган, профессионал югарылыкта иҗат итүче тагын бер җитди шагыйребез—әлбәттә, Әхсән Баян. Заман белән, дөнья белән иркен сөйләшә ул: кайчак элегия теле белән, моңсурак, ә кайчакта—усал, кискен сурәтләрдә... Дөнья әдәбиятында иркен йөзә, шуның сулышы бар. Мондый киңлек белән татар шигъри дөньясын, сурәтләр байлыгын яңарту Зиннур Мансуровка да хас. Ул да үзенә—югары накаллы, уйлы-фикерле, милли рухлы шигырьгә тугры. Ә Айдар Хәлим, Газинур Моратларда бу тагын да кискенрәк, көн үзгәрешләренә карата катгый бәя, нәтиҗәләр белән ныгытылып, заманга, кешеләргә, хәтта халык-илгә шагыйрь карары төсен ала.

Соңгы 2-3 елда минем күзгә ташланып, хәтердә калганнардан бер күзәтү-сәхифәмдер бу. Ул һич тә тулылыкка, яки объективлыкка да дәгъва итми, юк, һич андый уем юк. Шагыйрьләребез күп, публикацияләр, хәтта китаплар да санап бетергесез... Яңа журналлар, газеталар да чыга, үз тирәсенә туплый. Әйтик, «Мәйдан»да әллә нинди яңа шагыйрьләр килеп чыгар, бәлки... Чаллы шигърияте генә булмас ул, зур әдәбиятка коячак саф чишмәләр булыр, иншалла! Ә яңа исемнәр, яңа талантлар килүен—һәммәбез дә көтә. Туган телебезнең, олуг мирасның дәвамы булачак бит алар, яңа йолдызлар.

Ә инде яңа XXI гасырга килгән—зур мирас һәм шигъри мәктәпләр белән сыналган, төрле стильләрдә үскән һәм якты йолдызларын күктә балкыткан татар шигыренең бүгенгесе дә зарланырлык түгел. Булганны яратырга өйрәнсәк иде. Әйе, йолдызлар бар, алар яңа—күрә, сөенә белик дип әйтәсем килә минем. Мәңгегә шигърият гашыйклары, тугры рыцарьләре булып калыйк әле!

**Рәдиф ГАТАШ**

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ
## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Әхсән Фәтхетдинов,**

*Татарстанның халык рәссамы,*
*Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты*

# КАДЕРЛЕ ЯКТЫЛЫКЛАР



*Бу табигыйдер, кеше олыгайган саен үткәннәрне искә төшерә, сагына, шулардан ниләрдер эзли. Кайчак таба, кайчак, күпме генә җәфаланса да, онытылганнарның очына чыга алмый. Алар формасы, иseme билгесез, ите-чиге күренми торган йә яктылык, йә караңгылык булып кына тоелалар. Шул яктылык һәм караңгылыклар синең эчеңдә гомер буе яшиләр, томанлы шатлык-кайгылар, уйланулар тудыралар. Бәлки, шул яктылыклар, сиздермичә генә, кеше юлына нур сибәләрдер, иҗатына, яшәү рәвешенә мәгънә-максат бирәләрдер. Кадерле, бик тә кадерле ул яктылыклар! Акыл белән ачыклаганда аларның кайсылары әтиәнидән, туганнардандыр, кайсылары авыл янындагы урман-кырлардан, балачак атларыннандыр, укылган китаплардан, нинди сокланулардандыр дип уйлыйсың. Әле хәзер дә, кайдан гына килмәсен, кешеләрдәнме, куктәнме, табигатьтәнме, яктылыкларны хөрмәтлим, бәясен беләм.*

*Сәяхәткә чыгыйм әле шул яктылыкларның берсенә. Мәктәпкә кергәнче үк, кайда нинди язу күрсәм, шуны укый идем, ә соңрак авылдагы бөтен китапларны укып бетергәнмендер. Шулар арасында «Совет әдәбияты» журналын уку истә калган. Нинди әсәрләр, авторларны укыганмындыр, хәтерләмим, әле ул чакта язылганнарга зиһенем дә җитмәгәндер. Шигырь-поэмалар ошагандыр миңа, ә нигәдер тәнкыйть бүлеген дә яратып укый идем. Элэктергәндер үзенә ул журналлар, йоклап яткан күзәнәкләремне уяткандыр, менә шуның өчен дә балачагымның сүнмәс яктылыгы булып калганнардыр алар.*

*Журнал белән бәйләнгән бер мизгел бөтен детальләре белән истә калган. Нindидер бер китапны укып, эчтән генә, андагы ошап бетмәгән җырләрен билгеләп үткән идем. Җәйнең бер көнендә авылыбызның яраткан укытучысы Ләлә апаларга Кләүле станциясеннән кунакка килгән, миннән бер яшькә олы Марс белән чикләвек җыеп йөргәндә, аңа китап турында сөйләп, җитешсезлекләрен дә әйттем. Берничә көннән соң нәкъ шул китапны анализлаган «Совет әдәбияты» кулыма элэкте. Автор башка җитешсезлекләре арасында, миңа ошамаган җырләренә дә тукталып, кайбер фикерләремне раслаган булып чыкты. Йөгердем Марска, мәкаләне яньип-кызып әйткәннәремә туры килгән урыннарын кабат-кабат укыдым. Әтәчләнгәнмендер, мактанганмындыр да әле. Хәзер дә шаккатам, каян килгән ул, бала башың белән, Корьән дип саналган китапны тәнкыйтьләү.*

*Үз иҗатымның иң мөһим чыганакларының берсе итеп үзанализны саныйм. Мин—аның баласы. Әллә ни сәнгать мәктәбен үтмичә, үз-үземә каты таләпчәнлек куеп, тырышып-тырмашып, үз иҗатым белән башкаларныкын да анализлап, нәрсәгәдер ирешелде. Бәлки, менә шул «Совет әдәбияты» белән очрашу мизгелләрендә, андагы тәнкыйть мәкаләләрен укудан тугандыр да ул үз-үзеңне анализлау, ә соңрак бу дөньяның ак та, кара да, акыллы да, акылсыз да икәнен аңлау.*

*Ул журналларның елларын, саннарын да белмим инде. Бары тик төштән соңгы кояшлы җәйге көн, кесәдәге чикләвекләремнең, агач башыннан егылып төшкәч, түгелүләре, аларны озак кына җыюым һәм балачак дустым Марс кына истә калганнар. Иҗатлы һәм иҗатсыз елларымда, кайнар бәхәсләр эчендә, күпме генә «чикләвекләрем» түгелмәгәндер, кочләрем әрәмгә китмәгәндер, ә хәзер инде, аңыма килгәндәй, эссе кояш, кар-яңгыр астындамы, көндез-төнләме «түгелгән чикләвекләремне» җыям, югалганнарын да барлыйм төсле. Менә шулай булды хәзерге «Казан утлары»ның элгәреге «Совет әдәбияты» белән балачакта очрашуның сагышлы бер мизгеле һәм аның күңелемдә тамгалануы.*

*Язмыш мине озак елларга (уналты еллар чамасы) «Совет әдәбияты»ннан аерды. Әйе, шулай булды, шулай туры килде, кызганычка каршы. Ул чорларда рус телен белү бик кирәк иде. Камышлы педучилищесына кергәч, берәү бәлки, яхшылык теләптер, татарча китапларны укымаска кушты. Бернәрсә аңламасам да, русчаны укырга тотындым. Махсус рәвештә сүзләрдә басымнары күрсәтелгән китапларның берсе Фадеевның «Разгромы» булды. Өч мәртәбә кычкырып укып чыктым, аңламадым, хәзер дә аның эчтәлеген белмим. Яхшы әсәр дисәләр дә аны яңадан укыйсым килми, чөнки, ул мине ана телемнән аеруның бер тамгасы булып калды. Әйе, моңарга ул китап түгел, ә дәүләт үзе гаепле иде. Соңыннан рус, украин, казакъ балаларын русча укытып, армиядә хезмәт итеп, Түбән Тагил пединститутын бетереп, шунда ук өч ел дәресләр биреп, русчага да өйрәндем. Ләкин, ана телем зәгыйфьләнгән, сүз байлыгы саеккан, нечкәлекләре, матур сүзләре онытылган иде инде.*

*1969 елны Татарстанга, Түбән Камага кайткач, ана теленең рухың өчен кирәклеген, аны сагынганлыгымны аңладым. Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Фәридә Кудашеваларны тыңлагач, «Гөлҗамал»ны, «Кара урман»ны, «Ай, былбылым»ны, «Каз канаты»н, «Киек казлар»ны» ишеткәч, яңадан туган кебек булдым. Яңа ел башыннан «Казан утлары»на язылдым, алда әйтелгән яктылыгым белән кабат очраштым, исәнләштем һәм хәзерге көнгә кадәр аерылмадым. Альбом-китап чыгару мәшәкатьләре аркасында ике ел языла алмасам да, киосклардан, редакциядән алып барыбер укыдым. Беренче вакытларда абынгаласам да, хәзер инде йөгертеп укыйм, йотам. «Казан утлары» икенче мәртәбә ана теленә кайтуда укытучым булды, шул елларда журнал мине күпме роман-хикәяләр, поэма-шигырьләр, тарихи материаллар, үзем яраткан тәнкыйть мәкаләләре, кеше язмышлары аша үткәрде.*

*Хатын-кыз торышы, тәртибе белән баланы эчендә чагында ук тәрбияли башлый икән, ә тугач аны имезә, киендерә, сөйләргә өйрәтә. Ул шуны берөзлексез эшли, тыныч кына кешелекне дәвам иттерә, аның өчен орден-медальләр дә сорамый. Бу—табигый. «Казан утлары» да шуңа охшаган: кешеләрне ана теле белән имезә, халкыбызның талантлы балаларының иҗатлары, уй-фикерләре белән таныштыра, тарихына чыгып, аны саклый, үстерә. Ул да моны шаушусыз тыныч кына эшли, бүләкләр дә сорамый, бары тик, укысыннар гына. Бу да—нәкъ табигатьтән.*

*«Казан утлары»н укучы рәссам булarак, тагын бер очрашуга тукталам. Әле яңа гына Мәскәүдән укып кайткан татар фамилияле берәү киңәш сораган иде, янәсе милли рәссам буласы килә. Аның татар тарихын сай белгәнен үзем сизгәч, җырларын тыңларга, соңгы вакытта чыккан күп санлы яңа материалларны, «Казан утлары»н укырга кирәклеген һәм берничә еллардан соң милли рәссам булу мөмкинлеген әйткәч, ул үзенең ашыкканын, бүген үк нәтиҗәләргә ирешү теләген белдерде. Соңыннан татар түбәтәеннән уза алмады шикелле. Тышкы яктан шулай ул, башка түбәтәй киелә, ләкин бит милләтнең серле эче, моңы була, аны инде тоярга кирәк. Рәсем ясый алу гына мәсьәләне чишә алмый шул.*

*Мин кайчак Мәскәү һәм Петербург сәнгать мәктәпләрен милли рәссамнарны үстермәүдә, адаштыруда гаеплим (кайберәүләргә кагылмаса да), чөнки алар татар рухи дөньясын оныттыралар. Техник яктан көчле булсалар да (ул да бик кирәк), кайбер матур фикергә чыксалар да алар татар менталитетыннан ерагаялар. Мин анда укучы татар балаларына, башка чаралар арасында, «Казан утлары»н мәҗбүри укуны программага кертергә тәкъдим итәр идем, ләкин бу хыял гына шул. Кайберәүләрдә сорау да туарга мөмкин—кирәкме соң ул милли сәнгать һәм әдәбият? Дөнья—төрлелеге белән матур ул. Милли сәнгать һәм әдәбият бөтендөнья сәнгате һәм әдәбиятының бер төре, бер кирпече, үзенә генә хас булган бер бизәге һәм бик кирәклесе. Төрлелек-яшәешнең бик мөһим бер этәргече. Бөтендөнья сәнгате һәм әдәбияты—нәкъ менә шул төрлелекләрнең суммасы була да инде, ул әллә кайда, еракта түгел, ә үзебезнең эчебездә һәм*

*якын янибызда яши. Әллә «Казан утлары»нда чыккан әсәрләр арасында бөтендөнья өчен кирәклеләре юктырмы? Аларны күрә һәм таба белергә генә кирәк. Димәк, татарлык—тарлык түгел ул, ә бары тик үз эчендә генә калырга түгел, ә тирә-якны, еракгагыларын да, бөтен дөньяны белергә кирәк. Шулчакта гына үз-үзеңне, халкыңны, моңыңны ихтирам итә аласың. Менә шулайдыр ул Зур Иҗатның туувы, милли сәнгать һәм әдәбиятның да чәчәк атуы.*

*Бер генә мисал. Мең еллардан артык сакланган татар Сабантуе тарлык эчендә калмыйча, татарга гына хас булган элемент-бизәкләре, эчтәлекләре белән кереп, башка халыкларның да бәйрәменә әйләнә. Без барыбыз да—бүгенге көннәрдә шуның тере шаһитлары. Мәҗүсилек чорыннан бирле үзен саклый алган Шүрәленең дә язмышы шул айрак. Димәк, татар сәнгате һәм әдәбияты да шулай була ала!*

*Хәзерге көннәрдә татарны бүлгәләргә теләгән, теленә, алфавитына бәйләнгән, аның башын катырган чорда, «Казан утлары»ның роле тагын да артырга тиеш—моны табигать үзе, дөньяның матурлыгы булган төрлелек тә, яшәргә хакы булган татарлык та таләп итә. Бу урында журналның киләчәк язмышы турында тагын бер мәртәбә уйлап, язучышагыйрьләрнең язмышына чыгам. Хәреф, сүз, җөмләләрне, хикәя-романнарны, нинди генә мәгънәле, эчтәлекле, фикерле булсалар да, базарларда сатып булмый. Ул рухи байлыкның урыннары балалар бакчасында, мәктәпләрдә, уку йортларында, гаилә һәм китапханә киштәләрендә булырга тиеш. Азмы-күпме материаль яктан ярдәм итәрлек акчалы кешеләр, җитәкчеләр арасында сәнгать һәм әдәбиятны төпле һәм тирән аңлаучылар бик аз шул. Бу инде начар гына түгел, ә ничектер куркыныч та. ...Татарлыкны бетерү Мәскәүдән килә дибез, бу шулайдыр, әллә милләт эчендәге байтак кына, күпмедер дәрәҗәдә татар язмышын чишә алырлык кешеләрнең, чын сәнгать һәм әдәбияттан, рухи, әхлакый дөньядан ерагаюы аларның интеллектуаль дәрәҗәсенең сай булуы, баеп-череп ятулары, үзебезне-үзебез ашап бетерүгә китермәс микән? Тарихны чүпрәкләп бетермәсәм дә уйлыйм кайчак, татар дәүләтенең бетүенә күп еллар элек, шушылар ук сәбәп булмады микән? Дөрес, аерым шәхесләр аркасында, соңгы елларда татар менталитеты интеллектуаль көченең зурлыгын күрсәтте, әмма бит аның әле уйланырлык киләчәге дә бар... Табигатькә генә ышаныч кала, ир-ат белән хатынкызны чамасы белән бер үк санда яраткан кебек, талантларны да ул тудырачак, ләкин алар реаль тормышка чыгып югалмаслармы, чәчәк атарлармы, бөртекләнерләрме, башка акчалы шөгыльләргә күчмәсләрме. Киләчәктә, әле бүгенге көндә дә, «Казан утлары»нда энҗе-мәрҗәннәрнең булуы алардан тора бит.*

*Тагын бер нәрсә мине борчый. Үзем яши торган, халкы 200 меңнән артык (яртысы татарлар) Түбән Камада журналны берничә кеше генә ала. Моның сәбәбен аңлату үзе бер зур язма булыр иде, ләкин бу юлы аңарга тукталмыйм, ә бары тик күңелсез фактны әйтеп кенә үтәм.*

*1999 елның 6 нчы санында минем турында Равил Фәйзуллинның «Нарасый Хәким» дигән күләмле мәкаләсе, тышлыгында «Сугыш елларының атлары», тагын бер тышлыкта «Тыкрык иясе» дигән әсәрләрем басылган иде—болар барысы да минем шатлыгым һәм горурлыгым. Моның өчен журналга бик рәхмәтлемен.*

*Юбилей көннәрендә журналның баш мөхәррире, иҗатларыбыз тоташкан шагыйрь Равил Фәйзуллин турында да әйтәсем килә. Ул йөкне тарта белүче, эшне ахырына кадәр җиткерүче, журналның реаль хәлен тирән аңлаучы дип әйтер идем. Шулай ук барлык мөхәррирләрне, гамәли хезмәткәрләрне дә юбилей белән котлыйм, эшләрендә уңышлар телим.*

*Рәссам буларак, язучы-шагыйрьләрдән ак көнләшәм дә, чөнки аларның иҗатлары «Казан утлары»нда тикшерелә, өйрәнелә, тәнкыйтьләнә, һәрчак игътибар эчендә яши, ә инде безнең үз журналыбыз булмагач, тирән анализлар бик әләкми шул.*

*Миңа калса, рәссам буларак, күп еллар укылган журналлар, барлык материаллары белән бергә кушылып айлы-кояшлы, күпйолдызлы галәм—татар дөньясы булып күренә һәм бер зур калын «Казан утлары» дигән китапка әверелә. Галәмдәге йолдызларга карыйсың да, кайсылары кайчандыр укылган матур бер җөмлә, шигъри юллар булып күренә, автор—әсәрләрне искә төшерә дә, серле генә сискәндереп куя. Җир өстендә шундый зур татар дөньясының барлыгын тоеп, якты өмет эчендә каласың. Аны тою, аерым итеп рәсемләп, бөтендөньяны аңлауга да киртә булып тора алмый бит. Әлегә «Казан утлары» укыйм. Барысы белән дә ул—минем журналым. Хәзерге көндә киштә, өстәлләремдә өелеп ятканнарыныкы белән балачактагы яктылыклар бергә тоташалар, татар моңы булып яңгырыйлар эчемдә. Алар серле дә, изге дә, иҗатым өчен файдалы да.*

# ТАРИХ БИТЛӘРЕН АКТАРГАНДА...

Моннан ун ел элек, 1992 елның гыйнвар аенда Татарстан Милли китапханәсендә яна бүлек—«Кульязмалар һәм сирәк китаплар» бүлеге оештырылган иде. Әлбәттә, ул буш урында пәйда булмады, анарчы китапханәдә эшләп килгән «Сирәк китаплар» секторы нигезендә үстерелде. Яңа бүлекнең оешуына китапханәгә борынгы төрки-татар һәм Шәрекъ телләрендәге кульязма истәлекләрнең туплана башлавы этәргеч булды. Шулай ук әлеге бүлекнең хезмәт даирәсе дә киңәйде. Академик Әбрар ага Кәримуллин җитәкчелегендә, 1917 елга кадәр нәшер ителгән татар басма китабының тулы каталогын төзү буенча фундаменталь хезмәт тә «Кульязмалар һәм сирәк китаплар» бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан планлы рәвештә монда башланып китте.

Хәзерге вакытта бүлек ике мөстәкыйль сектордан—«Татар һәм Шәрекъ әдәбияты», «Рус һәм Көнбатыш әдәбияты» секторларыннан гыйбарәт. Бу мәкаләдә бүлекнең ун ел дәвамындагы киң эшчәнлеген яктыртуны максат итеп куймыйча, бары тик аның аерым бер тармагы—кульязмачылык өлкәсенә гомуми күзәтү ясарга омтылдык.

Китапханәдә оештырылган яна бүлекнең исемендә үк «Кульязмалар...» төшенчәсе бар. Бу гыйбарә, һичшиксез, җисемнең исемгә туры килүен таләп итә торган зур җаваплылык йөкли. Әле бүлек оешып кына килгән бер мәлдә төрле гыйльми даирәләрдә Татарстан Милли китапханәсенә кульязма истәлекләр туплау эшенә карата икеләнүчән һәм шикчел, сагаюлы фикерләр йөргәләсә дә, китапханә җитәкчелеге—ул вакыттагы директоры Разил Исмәгыйль улы Вәлиев—тәвәккәллек күрсәтте.

Әлеге тәвәккәллек үзен акладымы? Акласа, ни дәрәҗәдә? Республикабызның үзәк китапханәсендәге яңа бүлек тернәкләнеп киттеме? Аз булса да эш күрсәтә алдымы? Язмабызда әлеге сорауларга киңрәк җавап бирергә тырышырбыз.

1990-1991 елларда китапханәгә берничә дистә борынгы кульязма алынган иде һәм аларның саны көннән-көн ишәя барды. Ә 1992 елдан, яңа бүлек оештырылу белән, халкыбызның кульязма мирасын туплау һәм өйрәнү эше Татарстан Милли китапханәсендә төп максатларның берсе итеп куелды. Академик Миркасыйм ага Госманов бу мәсьәләдә бүлекнең гыйльми консультанты итеп билгеләнде. Кульязма истәлекләрне туплау өчен китапханә идарәсе матди җәһәтне, ә бүлек хезмәткәрләре көчләрен кызганмадылар.

Кульязма истәлекләрне туплау максатында 1992 елның җәеннән Казан дәүләт университеты белән берләштерелгән археографик экспедицияләр (җитәкчесе—Казан университеты доценты Җәүдәт Миннуллин) оештырыла башлады. Экспедиция ел саен дәвам итеп, узган җәйдә унынчы эш нәүбәтен башкарып кайтты. Ун ел эчендә экспедиция Түбән Новгород, Пенза, Самара, Оренбург, Пермь өлкәләрендә һәм Башкортстанның милләттәшләребез яши торган төбәкләрендә эшләде. Моннан тыш, бүлек тарафыннан һәр елда 2-3 мәртәбә республикабыз районнарына, шулай ук күрше республика һәм өлкәләргә дә берәр атналык археографик сәфәрләр оештырыла. Шул рәвешчә, күп кенә кала һәм авылларда сакланып калган кульязма истәлекләр Татарстан Милли китапханәсенә алып кайтылды. Казан шәһәренең үзендә дә археографик

эзләнүләр уңышлы алып барыла. Башкалабыздагы күп кенә мәчет идарәләре, мөрәҗәгатьләребезгә җавап итеп, үзләрендә тупланган, фәнни әһәмияткә ия борынгы язмаларны Милли китапханәгә тапшырдылар. Казандагы «Ноталар» китап кибетенең букинист бүлегеннән дә гарәп язуындагы борынгы китаплар даими төстә китапханәгә алына. Матбугат, радио һәм телевидение чаралары аша халыкка мөрәҗәгать итүләр дә нәтиҗәсез калмады. Күп кенә милләттәшләребез почта аша да һәм үзләре китереп тә кызыклы гына материаллар тапшырдылар һәм бу хәзер дә дәвам итә килә.

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләренең ун еллык археографик эзләнүләре, кулъязма истәлекләрне сатып һәм бүләк буларак алу, алмашу кебек чаралар нәтиҗәсендә Татарстан Милли китапханәсе фондларына хәзерге вакытка барлыгы 3070 берәмлек кулъязма тупланды. Елларга бүленештә караганда, 1992 елда—251, 1993 елда—366, 1994 елда—98, 1995 елда—326, 1996 елда—973, 1998 елда—194, 1999 елда—195, 2000 елда—191 һәм 2001 елда—268 берәмлек кулъязма истәлек тупланган. Шулардан 1116 төрки-татар кулъязмалары, гарәп телендәге 315, фарсы телендәге 62 (барысы 1493) берәмлек кулъязма эшкәртелеп, махсус теркәлде. Ә калган 1577 кулъязма истәлек әлегә эшкәртү һәм өйрәнү, теркәү халәтендә. Ун ел эчендә башкарылган бу хезмәт аз түгел дип беләбез.

Сан ягы шулай, ә җыелган кулъязма байлыкның сыйфат ягы нинди соң? Мәсьәләнең ул ягы ничегрәк тора?

Гомумән, һәр кулъязма китап һәм дәфтәр үзенчәлекле, кызыклы һәм кабатланмас хасиятләргә ия.

Әйтик, Кол Гали иҗат иткән мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасының кулъязма нөсхәләре археограф галимнәр тарафыннан әледән-әле табылып тора. Татарстан Милли китапханәсендә милли әдәбиятыбызның чишмә башы исәпләнгән «Кыйссаи Йосыф» әсәренең хәзерге вакытта егерме сигез нөсхә кулъязма күчермәсе бар. Бу, әлбәттә, аз сан түгел. Шулардан өчесендә әсәрнең текстлары тулаем сакланган, алтысының берничә битләре генә җуелган, бишесе 10-30 кәгазьдән, калганнары берничә яки берәр битле фрагментлардан гыйбарәт. Ике фрагментар кулъязма XVII йөз ахырына, берсе исә XVIII гасыр башына, өчесе XVIII йөзнең икенче яртысына, калганнары XIX гасырның башы яисә беренче яртысына нисбәтләләр.

XVII йөз ахырында күчерелгәннәре башкаларыннан палеографик үзенчәлекләре белән аерылып торалар. Алар 1993 елда Казан шәһәренең «Болгар» мәчетеннән алынган иделәр.

Китапханәбездә саклана торган «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең табылу географиясе дә шактый киң. Шулардан тугызы Казан шәһәрендә, янә тугызы археографик экспедицияләр вакытында Пенза, Пермь өлкәләреннән һәм Башкортстаннан; Татарстанның Апас районыннан—бер, Арча районыннан—ике, Әгерҗе районыннан—ике, Теләче районыннан—бер, Ютазы районыннан—бер, Самара өлкәсенең Динис авылыннан—бер, Уфадан—бер, Тобольск каласыннан—бер кулъязма табылган.

Милләттәшләребездән шагыйрь Мөхәммәт Садри «Кыйссаи Йосыф» әсәренең XIX йөз башы, шагыйрә һәм җәмәгать эшлеклесе Заһидә Бурнашеваның туганнары 1841 елгы күчермәләрен китапханәгә бүләк иткәннәр иде. Шулай ук поэманың 1852 елгы басмасының җуелган битләрен XIX йөз татар шагыйре Гали Чокрый үз кулы белән язып тулыландырган нөсхә дә бар.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы халык арасында шул дәрәҗәдә популярлашкан булган ки, төрле чорларда бу әсәрнең шигъри калыбы һәм үлчәмендә күп санлы бәетләр һәм җырлар да иҗат ителгән. Андыйларның кайберләре безнең китапханәдә дә саклана. Ни хикмәттер, безнең күзәтүләр буенча, аларның күпчелеге пародия, сатира өслүбендә язылганнар. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф» сюжетына пародия рәвешендә иҗат ителгән бер әсәрнең XIX йөз башы кулъязма фрагментында мондый юллар бар:

Йосыф әйтер: «Ходавәндә, ходавәндә,
Сәнең хөкемең кәлтерде бәне монда.
Зөләйха әйтер: «Не куручи, будет пулна!
За шту кручить напрасна?»—диер имди.

Шул ук әсәр үлчәмендәге, XIX гасыр уртасына караган янә бер шигъри әсәр «Миһман килсә, куенны багламагыл...» дип башлана.

XIX йөз уртасында күчерелгән тагын бер кульязма да мәшһүр әсәр калыбында язылган. Анда дала ягында көн күргән төрки кардәшләребез арасында мөселманлыкның зәгыйфьлеге, яшәү-көнкүрешләрендәге Ислам кануннарына хилаф гамәлләр тәнкыйть ителгән.

XIX йөзнең соңгы чирегендә, Габделҗәббар Кандалый шигырьләре белән бергә күчерелгән бер дәфтәрдә «Кыйссаи Йосыф» әсәре үлчәмендәге шигъри юллар белән җилбәзәк яшь кызлар тасвирлана.

Шундый ук шигъри юлларның җинел холыклы һәм азгын яшь кызларны гаять усал рәвештә тәнкыйтьләгән варианты да бар. Ул да—XIX йөз ахыры кульязмасы.

«Кыйссаи Авык» әсәренең дә шигъри калыбы «Кыйссаи Йосыф»ныкыча. Габделҗәббар Кандалыйның да бу шигъри калыпта еш кына үз шигырьләрен иҗат иткәнлеге мәгълүм. Китапханәдә андыйлар да бар. Соңрак чорда Шакир Мөхәммәдев, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай һ.б. бөек әсәрнең шигъри үлчәменә ияреп иҗат иткәннәр.

XIX йөз ахыры һәм XX йөз башында «Кыйссаи Йосыф» үлчәмендә иҗат ителгән төрле бәетләр дә еш очрый. Андый шигырь-бәетләр безгә тупланган язмалар арасында дистәдән артык төрдә. Бәетләрдән «Күркә-әтәч бәете», «Ташаяк ярминкәсе бәете», «Ранный[1] солдат бәете» һ.б. «Йосыф кыйссасы» калыбында язылганнар. Болар бар да бөек әсәрнең халык арасындагы шөһрәтен күрсәтүче дәлилләрдән.

Болгар дәвере галиме Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәреннән күчерелеп, аерым өзекләр теркәлгән XVIII йөз ахыры (Казаннан табылды) һәм XIX йөз башы (Теләче районының Иске Җөри авылыннан табылды) кульязмалары да кызыклы. Соңгысында «остазым Габдессәлам бине Уразайдан ишеткән сүзләрем» дип язылган юллар да бар. Монда XVIII гасырда яшәп иҗат иткән татар шагыйре Габдессәлам күздә тотыла.

Татарстан Милли китапханәсендә төрки-татар әдәбияты тарихында мәгълүм башка шигъри кыйссаларның кульязма нөсхәләре дә саклана. Мәсәлән, Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» поэмасының XIX йөз урталарына нисбәтле төрле күләмдәге өч күчермәсе шундыйлардан. «Авык кыйссасы»ның XVIII йөз ахыры һәм XIX йөзгә караган сигез кульязмасы бар. Шулай ук «Кисекбаш» китабы, «Кыйссаи Салсал», «Кыйссаи Әхтәм», «Таһир-Зөһрә кыйссасы» һ.б. кыйссаларның нөсхәләре тупланган.

Үзенең иҗат ителү вакыты белән XIII-XV йөзләргә нисбәт ителгән «Түләк-Сусылу» дастанының моңарчы фәндә берничә кульязмасы мәгълүм иде. Ягъни, 1) Нәкый Исәнбәт архивындагы нөсхә, иҗат ителү вакыты билгесез; 2) Миркасыйм Госманов тарафыннан 1969 елда Кама Тамагы районының Олы Кариле авылында табылган (XIX йөзнең икенче яртысында күчерелгән) нөсхә; 3) 1985 елда Казанда Марсель Әхмәтҗанов тапкан, 1877 елда күчерелгән нөсхә һәм 4) 1994 елда Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында шул ук М.Әхмәтҗанов тапкан, XVIII йөзнең икенче яртысына караган фрагмент. Икесенең (2 һәм 3 саннар белән күрсәтелгәннәренең) текстлары басылып чыкты *(кара: Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Тулыландырылган икенче басма.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.—Б.225–300; Әхмәтҗанов М. Түләк белән Сусылу //Әдәби мирас (Дүртенче китап).—Казан: Татар.кит.нәшр., 1977.—Б.14-33).*

1996 елның апрель аенда Самара өлкәсенең Камышлы районы Иске Ярмәк авылының яшь имамы Габдулла хәзрәт Кәрим чакыруы буенча ул төбәккә археографик сәфәр оештырган идек. Табылган 160 берәмлек кызыклы кульязма истәлекләр арасында әһәмиятле фәнни хәзинә—Камышлы авылы мәчетеннән алынган «Түләк-Сусылу» дастанының яңа күчермәсе булды. Бу хакта Самара өлкәсендә нәшер ителә торган «Бердәмлек» газетасында үз вакытында хәбәр ителгән иде *(Мәрдан Р. Якутлар табыладыр вакыт белән... // Бердәмлек.—1996.—2–8 июль).* Дастан XIX йөзнең беренче яртысында күчерелгән

[1]Ранный—яралы

жыентыкның 4-14 нче кәгазьләренә теркәлгән. Җыентыкта шулай ук «Түләк-Сусылу» дастаныннан тыш төрки телдәге шигъри бер әсәрнең ахыргы өлеше, Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» әсәре, төрле догалар һәм дини эчтәлекле язмалар урын алган. Кулъязманың кайбер битләре дефектлы. Бер биттәге язмадан бу җыентыкны Сибгатулла бине Фәхретдин исемле кеше күчергәнлеге аңлашыла. Кулъязма кәгазендә су билгесе белән 1832 ел билгеләнгән. Димәк, дастанның язма тексты монарчы матбугатта басылган вариантлардан әүвәлгерәк.

Яңа табылган дастан текстына килгәндә, аның язуы тәртипсезрәк, хаталы, кайбер сүзләрне ялгыш язулар, кирәксезгә кабатлаулар чагыла. Әсәрнең башындагы бер бит чамасы өлеше юк. Ике-өч биттән соң тагын бер кәгазе төшеп югалган. Ахырдарак 5-6 җөмлә күчерелмичә, буш урын калдырылган. Әсәрнең ахыры кыскартылган, гадиләштерелгән вариантта.

Яңа текст монарчы билгелеләре белән нигездә тәңгәл килә, зур аермалар юк. Ләкин шигъри строфаларда, сирәк булса да, үзгәлекләр күренә. Әлеге кулъязмада төшеп калган строфалар булган кебек, яңалары да бар. Шулай ук, яңа кулъязмадагы кушагъларның (җыр, такмак) ахыргы строфалары икешәр мәртәбә кабатлана һәм әсәрнең поэтик аһәңен көчәйтә вә бизи. Мәсәлән:

Атың әйтче, Сусылу,
Атың нәдер, Сусылу!?.

«Түләк-Сусылу» дастанының яңа табылган Камышлы нөсхәсен текстологик тикшереп, тирәнтен өйрәнү, әлбәттә, киләчәктәге бурычлардан.

Әдәби мирасыбызның энҗе бөртегенә тиң кыйммәтле хәзинәләреннән—Казан ханлыгы дәвере әдибе, шагыйрь Мөхәммәдъярның «Нуры содур» поэмасының бер күчермәсе дә бар китапханәбездә. Ул Кукмара районының Уразай авылында Ибраһимов Имаметдин агаларда сакланган. 1999 елда аны китапханәгә студент кыз Гөлназ Гарипова тапшырды. Кулъязма шактый ук дефектлы, күп кенә битләренең аскы итәкләре тетелгән һәм җуелган. Күп урыннарда язу карасы кәгазьне бозып, тишкәләгән. Кәгазенең су билгеләре аның 1701-1710 елларда Һолландиядә эшләнгәнлеген күрсәтә. Димәк, поэма XVIII йөздә күчерелгән. Кулъязмада «Нуры содур» поэмасының баш өлеше сакланмаган, төп өлеше һәм ахыры бар. Текст кулъязма җыентыкның 12-28 кәгазьләрендә урнашкан һәм бер биттә 16 юл булып язылган. «Нуры содур» поэмасының монарчы фәнгә җиде күчермәсе билгеле иде. Татарстан Милли китапханәсендәге яңа табыш сигезенчесе булды.

Борынгылык җәһәтенә килгәндә, китапханәдәге иң әүвәлге кулъязма XIV йөзгә карый. Җыентыкта ислам дине кануннары, фикъһ, астрономия буенча һ.б. язмалар белән беррәттән, гарәп тарихчысы Табаринның хезмәтеннән дә өзек бар. Кулъязманы күчерүченең исеме дә сакланган, ул—Дауд бине Мөхәммәд бине Хирыс (?) бине Мөхәммәд бине Җәгъфәр. Бу кулъязма истәлек китапханәбез өчен үзенең борынгы булуы белән һәм эчтәлеге ягыннан да әһәмиятле.

Төркия җирлегендә XVII йөз ахыры—XVIII йөз башында күчерелгән тел гыйлеме, дини эчтәлекле язмалар һәм 1558 елда Мәхмүд бине Мостафа әл-Хәнәфи кулы белән күчереп язылган гарәп телендәге шигъри әсәр бергә тегелгәннәр.

Борынгы булуы белән дә, оригинальлеге белән дә әһәмиятле кулъязма истәлекләрнең берсе—төрек әдибе Зәгыйфи әсәрләре. Зәгыйфинең тулы исеме—Пир Мөхәммәд бине Әүрәнус бине Нуретдин бине Фарис. «Көллияте Зәгыйфи» исеме белән аталган кулъязма җыентыкта әдипнең биш әсәре туплап бирелгән. Беренчесе—«Китабе сәргезәшт» *(15-32 кәгазьләр)*, әдипнең үз тәрҗемәи хәле һәм тормышын тасвирлаган төрки телдәге шигъри әсәр. Икенчесе—«Китабе сабрел-мәсаиб» *(33-37 кәгазьләр)*, төрки телдәге чәчмә әсәр. Өченчесе—«Китабе рисаләи җәүһәрия»—кыйммәтле ташлар: алмаз, йакут, энҗе, фирүзә, мәрҗан һ.б. турындагы «Җәүһәрнамә» исемле әсәрнең төрки телгә сайланма рәвештәге тәрҗемәсе; шунда ук авторның солтанга һәм башка шәхесләр исеменә язган хатларының текстлары теркәлгән. Дүртенчесе—

«Китабе рисаләи имтихания» *(58-68 кәгазьләр)* исемле гарәп телендәге әсәр. Бишенчесе—«Диване Зәгыйфи» *(69-123 кәгазьләр)* исемле төрки телдәге шигъри әсәрләр тупламы.



*«Диване Зәгыйфи» китабының бер бите. 1557 ел*

Кулъязма жыентыкның аеруча әһәмиятле ягы шунда ки, аның текстлары тулаем авторның үз кулы белән каллиграфик нәфис итеп язылганнар. Һәр әсәрнең ахырында автор үз исемен күрсәтеп, бу кулъязманың үз кулы белән язылуын белдергән. Жыентыкның соңгы сәхифәләре һижри 964 елның 7 рабигыль-әүвәлендә (милади 1557 елның 8 гыйнварына туры килә) Константиния (Истанбул) шәһәрендә күчерелеп тәмамлануы белдерелгән. Кәгазьдәге су билгеләре дә бу датаны раслый, чөнки текст язылган кәгазьләр 1545-1554 елларда Европада эшләнгәннәр.

XVI йөздә Константиния шәһәрендә язылган әлеге автографик жыентык төрле кешеләр кулыннан күчеп (моны тышлыгындагы күпсанлы язмалар дәлилли), безнең якларга килеп житкән. Хужаларының соңгы язмаларына караганда, Зәгыйфи жыентыгы 1970 елда Кушлавыч авылы имамы Касыйм Мөхәммәдгали улы китапханәсеннән Казанда яшәүче Габдулла Фәйзрахман улына алынуы беленә.

Васфи Маһир Кужатүркнең «Төрек әдәбияты тарихы» (Анкара, 1970) китабында язылганнар буенча Зәгыйфи ләкабле ике төрек әдибе мәгълүм. Аларның берсе XV йөзнең икенче яртысында яшәгән, «Солтан Морад хан» исемле бер әсәр язган. Икенчесенең 1552 елда вафат булуы билгеле, әсәрләре турында әйтелмәгән. Бу ике Зәгыйфи дә яшәгән дәверләре буенча безнең кулдагы «Көллияте Зәгыйфи» авторы булырга охшамаганнар. Шул ук Кужатүрк хезмәтендә XVI йөздә яшәгән Пир Мөхәммәд исемле (ләкабе күрсәтелмәгән) әдип турында языла, басылмаган әсәрләре бар диелә. Арадан Солтан Сөләйман Кануни дәверендә ижат иткән «Шәфәгатьнамә» («Әрвахнамә») әсәренең исеме әйтелә. Яшәү һәм ижат итү дәверенә караганда, соңгысы «Көллияте Зәгыйфи» китабының авторы белән бер үк кеше булуы ихтимал. Ләкин моны тәгаен тәфсыйлләп тикшерү таләп ителә.

Борынгы кулъязмалардан бездә шулай ук 1553, 1660, 1690, 1707, 1717, 1719 һ.б. елларга караган, күчерелү даталары тәгаен күрсәтелгән кулъязмалар бар. XVIII йөз һәм аннан соңгылары шактый. Кулъязма истәлекләр арасында күренекле шәхесләр һәм әдипләрдән Габдеррәхим Утыз Имәни, Шиһабетдин Мәржани, Хөсәен Фәезханов, Мирза Казембек, Ризаэддин Фәхреддин, Гали Чокрый, Шәһид Әхмәдиев, Гариф Атаманов, Галел Кутуй һ.б. үз куллары белән язылган хезмәтләре һәм әсәрләре дә булу—китапханәнең горурлыгы. Шулай ук укымышлы затлардан Ш. Мәржани, Габдулла Апанай, Р.Фәхреддин, Таиб һәм Гыйльман Яхиннар, Үзбәк Байчура, сәүдәгәрләрдән Үтәмешевләр, Госмановлар кебек танылган миллəттәшләребезнең шәхси китапханәләрендә булган кулъязма китаплар фондларыбызда урын алды.

Борынгы әдәби тәржемә ядкярләреннән «Кәлилә вә Димнә» исеме белән танылган хикәяләр тупламының китапханәбездә өч кулъязмасы бар. Икесе—1660-1670 еллар, ә берсе—XVIII йөз башы күчермәсе.

Халкыбызның әдәби мирасы хәзинәлегендә Һәмдәми исемле авторның фарсы шагыйре Фәридеддин Гаттар поэмасына нәзыйрә сыйфатында ижат ителгән «Нәсыйхәтнамә» исемле әсәре билгеле. Дөрес, бу әсәр әлегә аз өйрәнелгән. Әдәбият галиме Фәрит Яхин хәбәр итүенчә, әлеге әсәрнең

моңарчы ике кульязмасы фәнгә мәгълүм иде. Татарстан Милли китапханәсе хезмәткәрләре тарафыннан Һәмдәми поэмасының тагын ике күчермәсе табылды. Берсе—Тәтеш районының Келәш авылында сакланган. Баштагы һәм ахырындагы битләре җуелган бу күчермә безнең көннәргәчә 18 кәгазьдә килеп ирешкән. Су билгеләренә караганда, текст 1659—1660 елларда Европада эшләнгән кәгазьгә язылган. Икенчесе 1844 елда Эстәрлетамакта Мөхәммәдшәриф Хәлил улы кулы белән күчерелгән. Тексты 15 кәгазьдә, башлангыч өлеше юк, ахыры бар.

Ф. Яхин «Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология» дигән хезмәтендә *(Казан: ТДГИ нәшр., 2000.—Б.224—239)* «Нәсыйхәтнамә» әсәренең авторын һәм иҗат ителү вакытын билгеләгән. Фәрит Яхин бу әсәрнең авторын Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» хезмәтендә телгә алынган Хуҗамшөкер бине Гаваз-байга нисбәт итеп, поэманың язылу елы 1703 ел дип билгеләгән. Ләкин «Нәсыйхәтнамә»нең Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган XVII йөз күчермәсе бу версиянең хаклыгын шик астына ала. Чөнки 1703 елда иҗат ителгән әсәрнең 1659-1660 еллардагы кәгазьгә язылу ихтималы бик шикле.

Милли китапханәдәге археографик табышлар арасында чын ачыш буларак бәяләнгәннәре дә бар. Мәсәлән, XVII йөз татар әдибе Мәүла Колыйның моңарчы әдәбият тарихында бөтенләй билгеле булмаган ике әсәре—«Берекәннәр сыйфаты» һәм «Хәләл нәфкъә эстәгәннәр сыйфаты» («Хәләл ризык теләүчеләр сыйфаты») поэмалары фондта саклана. 1754 елда күчерелгән бу яңа табыш турында элегрәк язылган иде *(«Казан утлары».—1996.—№ 10.—Б.159-171)*. Шунда ук поэмаларның текстлары да дөнья күрде. Поэма текстларының табылу мөһимлеге шунда ки, моңарчы аерым хикмәт-шигырьләр авторы буларак билгеле булган Мәүла Колыйның поэма жанрында да иҗат иткәнлеге ачыкланды.

Күренекле татар шагыйре һәм фикер иясе Габдеррәхим Утыз Имәни әсәрләренең күчермәләре дә китапханәбездә шактый тупланган. Арада иң кыйммәтлесе—1804 елгы кульязма китапның баштагы һәм ахыргы битләренә Габдеррәхим Утыз Имәнинең үз кулы белән язылган әсәрләре. Берсе—әдипнең «Гаварифез-заман» поэмасының «Фасл дәр табакате голяма» бүлеге. Текстның ахырында «тәммә галә йадил-мүәллиф мулла Габдеррәхим бине Госман әл-Болгари» дип язып, шигъри юлларның автор кулы белән теркәлгәнлеге билгеләнгән. Икенчесе—«Нәзмы Габдеррәхим әл-Болгари» исеме астында «Анчә бидгать лязем...» дип башлана торган фарсыча дүрт юллы шигырь һәм аның татарчага сигезьюллык тәрҗемәсе («Ул нә бидгать лязем улды...»). Монысы да автор кулы белән язылган. Г.Утыз Имәнинең «Горбәтнамә» поэмасы моңа кадәр XIX йөзгә караган 5 күчермәдә мәгълүм иде. Бездә исә аның шактый элгәреге, 1786 елга караган нөсхәсе бар.

Г. Утыз Имәнинең «Мөһимматез-заман» поэмасының моңарчы биш кульязмасы һәм басылып чыккан нөсхәсе дә билгеле иде. Милли китапханәдә аның тагын өч күчермәсе бар. Берсе—XIX йөз уртасында, икенчесе—1859 елда, өченчесе—XIX йөзнең ахырында күчерелгәннәр. Моңарчы өч кульязмасы билгеле булган «Мәрсияи Хәмидә зәүҗәте Габдеррәхим Болгари» һәм бер кульязмасы билгеле булган «Мәрсияи Габденнасыйр вәләде Габдеррәхим» шигырьләренең безнең китапханәдә XIX йөз башына караган берәр күчермәләре саклана. Ике мәрсия дә бер кульязмада теркәлгәннәр. Фәндә бер кульязмасы мәгълүм «Нәзмы чәй вә каймак» шигыренең XIX йөз уртасына нисбәтле бездәге яңа бер кульязмасы шулай ук шагыйрь мирасын баета.

Габдеррәхим Утыз Имәнинең «Мөнәҗәт» («Иляһи, эстәрем синнән...») шигыренең XIX йөзнең беренче яртысыннан алып, 1905 елга кадәр төрле еллардагы 11 күчермәсе фондларыбызда урын алды. Г.Утыз Имәнинең соңгы җыентыгын басмага әзерләгән әдәбият галиме Әнвәр Шәрипов хәбәренчә, моңарчы бу шигырьнең фәнгә өч күчермәсе билгеле булган. Татарстан Милли китапханәсендә Г.Утыз Имәнинең шәригать буенча татар телендә язылган бер хезмәтенең XIX гасыр уртасында күчерелгән нөсхәсе дә саклана.

Татар иҗтимагый фикерендә тирән эз калдырган мәшһүр мөселман фикер иясе Габденнасыйр Курсавиның (1776-1812) дини-фәлсәфи хезмәтләре

фәнгә мәгълүм. Әмма аның шигъри әсәрләр иҗат иткәнлеге билгесез иде. Истанбулда авыруга дучар булган Габденнасыйр Курсави тарафыннан иҗат ителгән дип күрсәтелгән шигъри юллар теркәлгән кулъязма да бар китапханәбездә. XIX йөзнең беренче яртысына карый торган бу кулъязма китапханәбезгә Яшел Үзән шәһәрендә яшәгән галим-педагог Шәриф ага Сайкиннан 1994 елда алынган иде. Әлеге шигъри юллар, кулъязмада күрсәтелгәнчә, чынлап та Габденнасыйр Курсавиның үз каләменнән чыккан, яисә башка берәү тарафыннан язылып, Курсавига нисбәт ителгән булырга да бик мөмкин. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, китапханәдә Габденнасыйр Курсавиның гарәп телендәге «Шәрхе гакаиден-Нәсәфи» әсәренең күчермәләре дә бар.

Кулъязмалар арасында Русиядә патша хөкүмәте дәверендәге рәхимсез тәртипләргә кискен ризасызлык белдергән эчтәлектәге шигъри әсәр дә бар. Ул Саба районындагы Ак Бигәнәй авылыннан 1996 елда табып алынган иде. Бу кулъязма XVIII йөз ахырына караган кечкенә форматтагы дәфтәрдән гыйбарәт. Дәфтәрнең күп битләре җуелган һәм язуы да начар танылa. Дәфтәрнең сакланган өлешеннән күренгәнчә, бу шигъри әсәрнең күләмле булганлыгы күренә. Авторы мәгълүм түгел.

XIX йөзнең күренекле татар шагыйре Габделҗәббар Кандалый әсәрләре дә кулъязмалар туплаганда очрап тора. Китапханәдә әдипнең «Мәгъшукнамә» поэмасының ике күчермәсе (берсе тулы диярлек, икенчесе аерым өзек), «Сахибҗамал» поэмасының 1841 елгы язма фрагменты, «Рисаләи-л-иршад» поэмасының аерым өлешләреннән күчермәләр, шулай ук төрле шигырьләре теркәлгән дәфтәрләр бар.

Китапханәбездә язма мирас җәүһәрләреннән әдәби, бигрәк тә шигъри әсәрләр күп тупланган. Гомумән, Шәрекъ әдәбияты классиклары, төрки шигърияте җәүһәрләре һәм татар әдипләреннән Хафиз, Зөһәйер, Сәгъди, Руми, Мирза Бедил, Җами, Фирдәүси, Нәсими, Нәваи, Фөзули, Мәшрәб, Яссәви, Гаттар, Аллаһыяр Суфый, Бакырганый, Кол Гали, Кол Гобәйди, Кол Шәриф, Өмми Кәмал, Һәмдәми, Мәүла Колый, Габдеррәхим Утыз Имәни, Рәхимкол Әбүбәкер угылы, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Каргалый, Габделҗәббар Кандалый, Акмулла, Гали Чокрый һ.б. аерым шигъри җыентыклары яисә әсәрләре теркәлгән кулъязмалар әнә шундыйлардан.

Тарихка бәйле кулъязмалардан Пугачев хәрәкәте турында мәгълүмат теркәлгән XVIII йөз ахыры язмасы да әһәмияткә ия. Бу хакта «Гасырлар авазы» журналында *(1998.—№ 3/4 —Б.220-224)* хәбәр басылган иде инде.

Тарихи әсәрләрдән Хисамеддин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» кулъязмасының алты күчермәсе Татарстан Милли китапханәсендә саклануы да куанычлы күренеш. Арада 1853 ел күчермәсе тулы текстны тәшкил итә. Шулай ук Таҗеддин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» («Тәварихы Болгария») хезмәтенең дә XVIII-XIX йөзләргә нисбәтле өч күчермәсе бар. Бу ике авторның тарихны тасвирлаудагы примитив алымнары һәм күпсанлы ялгыш-хаталары соңгырак дәвер татар тарихчылары тарафыннан тәнкыйтьләнсәләр дә, үз чорына күрә Мөслими һәм Ялчыгол китапларының халык арасында таралыш табуы—татар халкында тарихка карата кызыксыну булганлыгын күрсәтүче бер дәлил икәнлеген инкяр итә алмыйбыз.

«Дәфтәри Чыңгызнамә» исеме белән мәгълүм дастаннар җыентыгыннан китапханәбездә «Аксак Тимер дастаны»ның ике кулъязмасы, «Гайсә угылы Амәт» дастанының бер битле күчермәсе, «Дастани фит-тарих»ның дүрт кулъязмасы саклануы да мәгълүм булсын. Алар барысы да XVIII йөз ахыры-XIX йөз башында күчерелгәннәр.

Фәндә татар сәяхәтнамәләре жанрындагы мәгълүм язма истәлекләрдән «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе» белән «Мөхәммәтәмин сәяхәтнамәсе»—иң мәшһүрләрдән. Беренчесенең XIX йөзгә нисбәтле бер, ә икенчесенең ике кулъязмасы фондларыбызда урын алды. Шулай ук игътибарга лаеклы башка сәяхәтнамәләр дә бар. Мәсәлән, хәрби хезмәттәге татар кешесе тарафыннан 1756 елда теркәлгән кулъязма шулар рәтеннән. Язмада хәрби поход, мишәр гаскәре, казаклар, Дон казаклары һ.б. турында тарихи мәгълүмат бирелү белән бергә, авторның башкача кызыклы шәхси күзәтүләре дә сәяхәтнамә жанрына хас стильдә чагылган. Соңгырак дәвер сәяхәтнамәләреннән Кукмара


районы Төркәш авылының Гобәйдулла Рәхмәтулла улының 1938 елда Кырымга сәяхәте игътибарга лаек. 70 яшьлек автор сәяхәтнамә жанрындагыча, тәгаллек белән күргән-белгәннәрен, анда яшәгән кырым татарлары, караимнәр, немецлар, болгарлар, греклар, яһүдләр һ.б. турында язып калдырган. Ул чордагы кырымтатар авыллары турындагы мәгълүматлар кызыклы. Кырымтатар халкының ачы язмышы һәммәбезгә мәгълүм. Сәяхәтнамәдә телгә алынган Солтансарай, Булгак, Азамат, Салтыбай, Орчык, Мәүлет, Тайган, Кортлык, Жимерек, Сәй һ.б. авылларның хәзерге вакытта күпчелегенен урыннары гына түгел, исемнәре дә жир йөзеннән юкка чыккандыр.

Мәшһүр татар тарихчысы һәм дини эшлекле Шиһабеддин Мәржани шәхси китапханәсенең язмышы шактый катлаулы һәм буталчык. Галимнең вафатыннан соң бу бай китапханәнең бер өлеше юкка чыккан, варислары кулында сакланган өлешенең беркадәресе гыйльми оешмаларга—Казан университетының фәнни китапханәсенә, Татарстан Фәннәр академиясенең Мирасханәсенә саклanышка тапшырылган. Тик шулай да Мәржаниләр нәселен дәвам итүче варисларында Шиһабеддин хәзрәт китапханәсендә булган кыйммәтле язмалар әле дә сакланып килә.

Шиһабеддин Мәржанинең улы Борһанеддиннең оныгы Даниял абый Әмирханов (Казанда яши) 1998 елда Татарстан Милли китапханәсенә үзләренең гаилә архивларында сакланган кыйммәтле кульъязмалар тапшырды. Моңарчы фән даирәсенә билгесез булган язма материаллар арасында Шиһабеддин Мәржанинең үз кульъязмалары, аңа адресланган хатлар һ.б. бар. Арада аеруча игътибарга лаеклысы—Мәржани китапханәсенең китаплар исемлеге теркәлгән дәфтәр. Анда китапханәдә булган 430 нөсхә кульъязма һәм басма китап теркәлгән. Әлбәттә, бу бай китапханәнең бер өлеше генә. Бу табышлар турында безнең тарафтан «Гасырлар авазы» журналының 2000 елгы 3/4 санында хәбәр бирелгән иде. Ләкин анда Д.Әмирхановлар тапшырган янә бер дәфтәр турында әйтелмәгән иде.

Ул дәфтәр исә, чын-чынлап, милли тарихыбыз өчен гаҗәеп мөһим табыш һәм ачыш дип бәяләнергә хаклы.

1866 елда яшьли дөнья белән хушлашкан шәкерте Хөсәеннең гыйльми язмаларын Ш.Мәржани соратып алдырганлыгы фәндә мәгълүм. Фәезхановның гыйльми мирасыннан ике кульъязманы «Рисалә» һәм «Ислахе мәдарис» хезмәтләрен Мәржани оныкларыннан Нажия ханым Ильясова һәм Даниял әфәнде Әмирханов 1986 елда тарихчы-галим Миркасыйм Госмановка тапшыралар. Соңгы еллардагы эзләнүләр нәтиҗәсендә, шул ук Д. Әмирхановлардан Х. Фәезхановның тагын бер автографик кульъязмасы табылды.



*Хөсәен Фәезхановның «Касимский ханлыгы» хезмәтеннән бер сәхифә*

Утыз кәгазьдән торган (60 битле), 18x22 см зурлыгындагы гадәти генә дәфтәргә Хөсәен Фәезханов кулы белән «Касимский ханлыгы» *(1а-8б кәгазьләрдә)*, «Казан ханлыгы» *(9а-20а кәгазьләрдә)* хезмәтләре һәм Болгар дәвере кабер ташлары текстларын тасвирлаган язмалар *(21а—30а кәгазьләрдә)* теркәлгән. Төзәтмәләр һәм өстәмәләр, текстларның бөтен булмавы ишарә итүенчә, бу язмалар галим тарафыннан ниятләнгән зур һәм гаять житди хезмәтләрнең караламалары булуы аңлашыла. Бер урында исә Фәезханов Болгар дәүләте турында да хезмәт язганлыгын белдереп үтә. Хезмәтләрнең теле Ш. Мәржани китаплары белән чагыштырганда күпкә жинел. Әлеге тарихи хезмәтләрендә галим тарихи чыганакларның төрләренә һәм әһәмиятләренә киң тукталган. Аерым

алганда, Казан тарихы буенча язма чыганаклар унаеннан Х.Фәезханов «...Фаразан, андый тарих бер вакыт язылган булса да, ул заманда басма санагате булмаганнан, нөсхәләре таралмый калып, Казан мәмләкәтенең башына килгән бәлаләр вә бүлеклекләр арасында югалган булса кирәк... Русиялеләр үз тарихларын язганда Казан әхвален вә әхбарен дә язгалаганнар. Әмма ...бусы да бар: рус халкы ул заманда җаһил булганнар вә язган хәбәрләрен инсаф белән вә гыйльме тарих өчен язмаганнар, вә тәфтиш вә тәхкыйк итмәй (*тикшермичә—Р.М.*), гавам авызыннан ишеткәнчә вә үз политикаларына килешкәнчә язганнар... Бу сәбәптән рус тарихларына һәм тәмам ышанып житеп булмайдыр. Шулай булса, ата-бабаларының әхвален вә Казан ханнарының тарихын белергә сусаган ватандашларымыз вә газиз мөселман карендәшләремезне кандырырдай бер дә чишмә юкмы вә бу хосуста өмид өзеп, карап тораекмы?»— дип, бу мәсьәләне мөселман һәм рус чыганаклары нигезендә өйрәнүгә керешүен белдерә.

Галим үз хезмәтендә Казан атамасы, Казан шәһәренең нигезләнүе, ханлыкның оешуы, халкы һәм сәясәте, әдәбияты, ташъязма истәлекләре һ.б. турында бәян итә. Шулай ук Хисамеддин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» хезмәте яртысыннан күп өлеше хаталар белән тулы булуын белдерә. Казан арты һәм Тау ягы авылларының атамалары турындагы фикерләре белән уртаклаша. Тау ягы авылларында Иван Грозный тарафыннан бирелгән грамоталар саклануын да искәртә. Бу хакта аның үз вакытында Ш.Мәрҗанигә дә хәбәр биргәнлеге билгеле. Болгар дәверендә мөселман булып, руслар кулына төшкәч чуашлыкларына (мәҗүсилеккә) кайткан һәм сонрак христианга әверелгән чуашлар һ.б. турында да яза.

Хезмәтләренең эпиграфикага багышланган өлешендә Тау ягындагы Әтрәч, Аксу, Байтирәк, Олы Яльчик авылларындагы Болгар чоры кабер ташлары текстлары тәфсыйлләп тасвирланган. Фәезханов мондый ташларның ел саен бетә баруларын искәртә. Ул Әтрәч авылы янындагы зиратта сакланган 21 борынгы ташның текстларын күчереп алган. Шунда ук Әтрәч зиратындагы башка 20-30 ташның соңгы дәвердә генә алып кителеп, чиркәү нигезенә түшәлүләрен әрнеп язган. Хөсәен Фәезхановның эпиграфика буенча язмасы, тәгаен күрсәтелмәсә дә, 1862 елда теркәлгәнлеге аңлашыла.

Хөсәен Фәезханов гыйльми мирасының саллы бер өлешен тәшкил иткән бу табышларны галимнең башка хезмәтләре белән бергә туплап нәшер итү—нәүбәттәге бурычларыбызның берсе.

Даниял Әмирхановлардан Фәезханов дәфтәрләре белән бергә алынган тагын бер кызыклы дәфтәр турында әйтергә кирәк. Монысы Фәезханов кулы белән язылмаган. Үзендә авторы да күрсәтелмәгән. Язу-почеркы Каюм Насыйриның бертуган энесе Габделганинең кулына бик тә охшаш, шулай ук К.Насыйриның бертуган агасы Габделәхәт кулына да охшаган. Әлбәттә, киләчәктә бу ачыкланыр. Ләкин Каюм Насыйриның агасы да, энесе дә мондый яки моңа охшаш эчтәлектәге хезмәт язганлыклары мәгълүм түгел. Алар кемнеңдер хезмәтен күчереп алган булулары бик мөмкин. Эчтәлеге исә кыскача татар тарихын бәян итә. Хезмәтнең башында автор «ата-бабаларымның йорты—Казан мәмләкәтенең» үткән хәлләре турында кыскача булса да бер тарих китабы булмаганлыктан «үртәлеп, Казан татарлары телендә тәварих язмага тәвәккәл кылдым» дип белдергән. Уртача зурлыктагы дәфтәрнең 14 кәгазендә якынча 1860 елларда теркәлгән бу «тәварих»та, нигездә, рус чыганакларына таянып, Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханнары дәверендәге тарихи вакыйгалар турында кыскача мәгълүмат бирелә. Ахыргы битләре сакланмаганлыктан бу тарихи кульязма Хәлил хан дәверен (1462-1467 елларны) хикәя иткән урынында өзелеп калган.

Фондларыбызга тарихи-документаль, хроникаль язмалардан төрле мәсьәләләргә караган хосусый актлар, сату-алу кәгазьләре, метрикәләр кебек материаллар да тупланып килә. Андыйлардан сәүдә эшләре буенча 1765-1767 елларда теркәлгән хосусый актлар, Ижевск шәһәре мәчетендә язып барылган метрикә дәфтәрләре һ.б. бар.

Төбәк һәм авыл тарихлары, шәҗәрәләре, аерым нәсел шәҗәрәләре дә китапханәгә уңышлы гына җыйнала. Аерым алганда, Саба районының

Мамалай, Арча районының Оры (Ясаклы Оры), Кукмара районының Төркәш һәм Әсән-Елга, Чирмешән районының Югары Чагадай һәм Туймәт, Ютазы районының Бәйрәкә, Киров өлкәсенең Таң авылы, Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Камышлы, Иске Ярмәк, Иске Госман, Похвистнево районының Гали авылы тарихлары буенча материаллар һәм шәҗәрәләр бар. Болардан тыш, тарихыбызда мәгълүм шәхесләрдән Шиһабеддин Мәрҗани, Казаковлар һ.б. мәшһүр нәселләрнең шәҗәрәләре саклана. Аерым кулъязма җыентыкларны күчерүчеләр үзләренең унар буынга кадәр ата-бабаларының исемнәрен дә күрсәтеп язганнар. Болар да шәҗәрәләр исәбенә керергә лаеклы.

Шәҗәрә рәвешендәге силсилә-династияләр теркәлгән кулъязма истәлекләрнең кайберләре Адәм галәйһиссәламнән башланып, мөселман дөньясындагы суфилар һәм татар ишаннарын санап, 1950 еллардагы безнең җирлеккә килеп тоташа. Берсендә исә борынгы чордан алып гарәп һәм госманлы хөкемдарлары, солтаннарының династиясе сызылган, шәхесләргә карата тарихи хронологик искәрмәләр дә бирелгән.

Мәшһүр төрки-татар тарихчысы, дин галиме, җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм әдип Ризаэддин Фәхреддингә бәйле берничә кулъязма да бар фондларыбызда. Аның берсе—Ризаэддин Фәхреддин Шәлчәле (Чыршылы) мәдрәсәсендә шәкерт вакытында күчереп язган кулъязма җыентык. Җыентыкта 1874-1880 елларда аның кулы белән язылган «ишаннар силсиләсе», тәҗвид дәресләре, хәдисләр, гарәп телендәге шигъри әсәрләр. Бу кыйммәтле кулъязма Самара өлкәсенең Камышлы районы Иске Ярмәк авылында 1996 елның язында табып алынды. Икенчесен—шул ук Чыршылы мәдрәсәсендә 1887-1888 елларда язылган кулъязманы—китапханәгә Әбрар ага Кәримуллин 1995 елда тапшырган иде. Ана исә китапны Иске Шөгер авылы укытучысы Сәгыйть Хәбиров биргән булган.

Мөхәммәдсадыйк Иманколый (1870-1932)—XX йөз башы татар иҗтимагый тормышында мәгълүм исемнәрдән. Дөрес, аның тормыш юлы һәм әдәби иҗаты әлегәчә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Бу шәхескә махсус мәкалә багышлаган әдәбият галиме Мәсгуть ага Гайнетдинов та моны искәрткән иде *(Юл чатында асылташ //Мәдәни җомга.—2000.—22 сентябрь).* Мөхәммәдсадыйк хәзрәт—XIX йөз ахырында Бохарада белем алып, Казанга кайтып имам булган, дини һәм шигъри әсәрләр дә иҗат иткән каләм әһеле. Китапханәбездә М. Иманколыйның Бохарада белем алган вакытында үз кулы белән язган шигъри мәҗмугасе саклана. Бу җыентык 1891-1892 елларда язылган. Кулъязмасына һәм үзе ясаган бизәк-нәкышьләргә караганда, М.Иманколый гаҗәеп матур язучы оста каллиграф-хаттат һәм рәссам да булган. Җыентыкта аның тарафыннан ясалган Мәккә, Мәдинә күренешләре, Нух пәйгамбәр көймәсе, планеталар хәрәкәтен тасвирлаган (астрономия буенча) рәсемнәр, үз кулы белән сызылган һәм төсле буяулар белән буялган Азия кыйтгасының картасы һ. б. бар.

Җыентыкның эчтәлегенә килгәндә, ул нигездә фарсы, гарәп һәм төрки телләрдәге Мирза Бедил, Җами, Сәгъди, Хафиз, Нәваи, Фирдәүси, Фөзули һ.б. Шәрекъ әдәбияты классикларының шигъри әсәрләре, робагыйлары белән тулы. Сүз һәм каләм осталарының бөек шигърият мирасы тәэсирендә иҗат иткән Мөхәммәдсадыйк Иманколыйның үз шигъри әсәрләре дә шул ук җыентыкта теркәлгән. Иҗатына өстән генә күз ташлаганда да, М. Иманколыйның шигъри мирасы борынгы классик Шәрекъ мәктәбен дәвам итүе белән әһәмиятле. Гомумән, бу җыентык әдипнең мирасын өйрәнү өчен менә дигән материал булып тора.

Игътибарга лаеклы кулъязмалардан билгесез автор тарафыннан 1845 елда иҗат ителгән, фәлсәфи трактат характерындагы «Мәгарифе кальбият» исемле күләмле шигъри әсәр күчермәсе дә бар. Моңа хәтле бу әсәрнең Петербургта саклана торган бердәнбер кулъязмасы билгеле иде. 1856-1960 еллар тирәсендә күчерелгән нөсхәсен Милли китапханәгә 1994 елда Казан университеты доценты Җәүдәт әфәнде Сөләйманов тапшырган иде.

Кулъязма хәзинәләр арасында борынгы җыр текстлары теркәлгәннәре дә бар. Мәсәлән, XVII йөзнең икенче яртысында язылган бер җыентыкта кызыклы гына бер җыр тексты сакланган. Аерым алганда анда мондый юллар бар:

...Ханнарның ханы, җаннарның җаны,
Галим йегетләр солтаны, бакча-сарайлар;
...Ушалдыр[1] хәлем, корбандыр җаным,
Мәмләкәт-малым бакча-сарайда;
...Барырым кырга, шонкарым кулда,
Чөярем кызга бакча-сарайда.

Сөләйман Бакырганый хикмәтләре, «Кәлилә вә Димнә» хикәятләре һ.б. язылган бу кызыклы кульязма 1996 елда Балтач районының Түнтәр авылында табылган иде.

Борынгы җырлардан «Хан кызы» җырының да берничә күчермәсе барлыгын әйтеп китәргә кирәк.

Кульязмаларда фольклор әсәрләре күп очрый. Борынгы дәвергә нисбәтле, әле өйрәнәсе-тикшерәсе кызыклы әкият текстлары да бар.

Китапханәбездә төрле төбәкләрдән (бигрәк тә Татарстанның Тау ягы һәм Казан арты төбәкләреннән) тупланган шәкерт дәфтәрләрендәге бәетләрнең репертуары үзенең киңлеге белән таң калдырырлык. Ул дәфтәрләрдә язылган бәетләрнең исәбе-саны юк. Аерым дәфтәрләрдә теркәлгән бәетләрнең саны кайвакытта 20-25 тән артып китә, хәтта 34 төрле бәет теркәлгән дәфтәр дә бар. «Сак-Сок», «Нәүрүз», «Шәһри Болгар», «Сөембикә манарасы», сугыш бәетләре (төрек, япон, герман), «Солдат», «Шамил», «Перепись», «Шәкерт», «Ташаяк ярминкәсе», «Урыска сатып кияүгә бирелгән кыз», «Фәлше акча сугучылар», «Башмак», «Самавыр», «Тавык» бәетләре, шәхси фаҗига бәетләре һ.б., һ.б. 1917-1919 еллардагы милли рух күтәрелеше дәверендә иҗат ителгән шигырьләр һәм җырлар, милли гаскәр маршлары теркәлгән дәфтәрләр дә күп кенә.

Кульязма истәлекләр арасында хатлар да күп очрый. Тарихи шәхесләргә бәйле хатлар да бар. Мәсәлән, Шиһабеддин Мәрҗанигә Сәлимгәрәй мөфтидән, энесе Садреддиннән, башка шәхесләрдән юлланган хатлар игътибарга лаеклы. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтендә телгә алынган Хәсән бине Хәмид исеменә язылган дистәләгән хатлар, татар хаҗилары һәм сәүдәгәрләре, күп санлы имамнар, шәкертләр һ.б. хатлары гаять кызыклы. Казакъ балаларын укытучы шәкерт улына әтисенең үгет-нәсихәт биреп язган 1877 ел хаты кебек хатлар да бар.

Дини әчтәлекле хезмәтләр һәм әсәрләр китапханәдә тупланган кульязма мирасның зур бер өлешен тәшкил итә. Андыйлар арасында традицион китаплар булу белән беррәттән сирәк хезмәтләр дә очрый. Мәсәлән, ислам-христиан, җәдитчелек мәсьәләләренә багышланганнардан «Миссионер Саблуковның Манзарател-җаваб исемендә Коръәнгә игътиразына рәддия», «Инҗил» һәм Гайсә өйрәтмәләре турындагы Мөхәммәд Габдәһ карашларын бәян иткән кульязмалар, Иж-Бубый мәдрәсәсе шәкертенең төрле дәресләрне язып барган конспектлары һ.б.

Дәвачылык һәм халык медицинасына караган кызыклы кульязмалар әледән-әле табылып тора. Китапханәдә дистәдән артык тыйбби әчтәлекле кульязмалар бар. Алар арасында Әбугалисинаның «Канун фит-тыйбб» хезмәтеннән күчермәләр һәм «Гайййәтил-бәйан фи тәдбири бәдәнил-инсан» исемле (1758 елда күчерелгән) китаплар да бар.

Табышларга юлыгуда да гаҗәп кызыклы мисаллар булгалый. Мәсәлән, 1999 елгы археографик экспедиция вакытында Оренбург өлкәсендә табылган кульязманың төшеп җуелган битләре 2000 елгы экспедициядә Пермь өлкәсендә табылды. Бу—ышанмаслык кебек тоелса да, факт! Әлеге кульязма—нәфис нәкышьле, XIX йөздә фарсы һәм гарәп телләрендә каллиграфик язылган Иран миниатюрасы. Аны хаҗга баручы милләттәшләребез татар җирлегенә алып кайткан булса кирәк. Ә бер кульязманың икегә аерылып, ике төбәктә табылуына килгәндә, бу гайре табигый хәл түгел. Китаплар да, халкыбыз кебек үк, элек-электән хәрәкәттә булган, кулдан-кулга күчеп йөргәннәр. М.Госмановның «Каурый каләм эзеннән» исемле хезмәтендә андый сәяхәтче

[1]Ушал—шушы, шулай.

китапларга махсус бүлек багышланган. Кульязма миниатюралар дигәннән, XX йөз башында Казанда «Исмәгыйль доктор» дип танылган күренекле табибның кызы Зөлфә ханым Госманова 1995 елда китапханәбезгә гаҗәеп бер кульязма Коръән бүләк иткән иде. Зурлыгы нибары 7х9 см булган 428 кәгазьле миниатюр Коръән китабы нәфис итеп язылган, сүрә исемнәре һәм һәр битендәге рамкалар алтын кара белән эшләнгән. Һәр битендә текст 3х5 мәйданда урнашкан бу хикмәтле китап XVII йөздә Шәрекъ илләренең берсендә язылган.

1964 нче елда ук Казан университеты китапханәсенә «Мәрҗани» мәчетеннән алынган кульязма истәлекләр арасында белорус татарлары тарафыннан язылган дини эчтәлекле китап булуы мәгълүм. Университет китапханәсендә аңарчы да гарәп язулы белорус телендәге ике кульязма сакланган. Галим А.К.Антоновичның белорус телендә гарәп язулы истәлекләрне өйрәнүгә багышланган махсус хезмәте бар *(Антонович А.К. Белорусские тексты, написанные арабским письмом, и их графико-орфографическая система.—Вильнюс, 1968).*

1996 елның мартында «Мәрҗани» мәчетеннән Татарстан Милли китапханәсенә алдырылган борынгы язмалар арасында гарәп хәрефләре белән татарча һәм, нигездә, белорусча XIX йөз урталарында язылган китапның бер өлеше *(43 кәгазьдә)* табылды. Эчтәлеге буенча анда намаз тәртипләре һәм төрле догалар күчерелгән. Баштарак 1964 елда университет китапханәсенә алынган белорус телендәге кульязманың бер өлеше түгелме дигән шигебез булса да, тикшереп карагач, мөстәкыйль кульязма икәнлеге ачыкланды.

Рус теленең йогынтысы татар кульязмаларында да ара-тирә чагылыш тапкан. Алдарак «Кыйссаи Йосыф» поэмасына пародия рәвешендә язылган бер әсәрнең өзеге китерелгән иде. XIX йөз башына караган ул кульязмада Зөләйха, ни гаҗәп, «не куручи...» дип русча сөйләшә. Рус сүзләрен, бигрәк тә, татарча документларда, төрле хосусый актларда һәм фольклор әсәрләрендә күп кулланганнар. Татар телендәге гарәп язулы кульязмалар өчен ятрак булган рус сүзләре беренче карашка аптырашта да калдыра. Чөнки рус сүзләре шактый ук үзгәреш кичереп, татарча яңгыраш алганнар. Әйтик, XIX йөз урталарына караган бер дәфтәрдә «Иртәсен дә, кичен дә Зәйнәп ашый бәлинҗә...» диелгән такмактагы «бәлинҗә» сүзе «варенье»ны белдерә. Ә инде XIX йөзнең ахыры һәм XX йөз башындагы татар шәкерт дәфтәрләрендә гарәп хәрефләре белән теркәлгән русча шигырьләр һәм җырлар күбрәк очрый. Ул чорда рус телен өйрәнгән татар шәкертләре язып куйган «Петушок», «Коровушка», «Зайчик» һ.б. шигырьләр инде алай ук сәер тоелмый.

Бүлеккә татар әдипләренең һәм галимнәренең шәхси архивлары да туплана. Хәзерге вакытта Шиһабеддин Мәрҗани, Гаяз Исхакый, Вафа Бәхтияров, Үзбәк Байчура, Шиһаб Рамазанов, Гыйбад Алпаров, Хәсән Туфан, Бәян Гыйззәт, Шәриф Сайкин, Рашат Гайнанов, Альберт Фәтхи, Әбрар Кәримуллин архив материалларының аерым өлешләре монда саклана. Фотоматериаллар коллекциясе дә яхшы гына тупланып килә. Фондта Габдулла Тукай, Фатыйх Әмирхан, Гаяз Исхакый, Камил Мотыйгый, Заһидә Бурнашева, Хәсән Туфан һ.б. күренекле затларның төп нөсхә фоторәсемнәре бар.

Совет дәвере золымнарын, 1920 һәм 1930 елларның кара сәхифәләрен чагылдырган мемуар һәм шигъри әсәрләр, документаль материаллар да аз түгел. 1921 елда сәнәкчеләр күтәрелешендә катнашуда гаепләнеп кулга алынган һәм большевиклар лагеренда җәфа чиккән Мөхәммәдгали Шәриповның башыннан кичкәннәрен теркәп барган көндәлеге «Мирас» журналында 1996 елда дөнья күргән иде. Шулай ук 1931 елда кулак дип гаиләсе белән Магнитогорскига сөрелгән Сабирҗан Шаһимәрдановның бәет-мөнәҗәтенең текстын да матбугатка әзерләп бастырган идек *(Әдәби мирас. Икенче китап.—Казан: Татар.кит.нәшр., 1992.—Б.69-74).*

Мөһаҗирлектәге милли тарихыбызның бер истәлеге—1934-1936 елларда Шанхай төрки-татар җәмгыяте идарәсе җыелышларының язмалары теркәлгән дәфтәр дә китапханәбездәге кадерле истәлекләрдән. Аны 1993 елда китапханәгә АКШның Калифорния штаты Татар җәмгыяте президенты Равил Салиәхмәт тапшырган иде.

Китапханәнең «Кульязмалар һәм сирәк китаплар» бүлеге татар китабы

мирасын пропагандалау эшен дә алып бара. Мәсәлән, беренче татар басма китабының 270 еллыгы унаеннан Казанда 1992 елның 21—22 декабрендә Татарстан Милли китапханәсе тарафыннан «Татар китабының үткәне һәм бүгенгесе» исемле халыкара фәнни-гамәли конференция оештырылды. Шулай ук, 1995 елның декабрендә Татарстан Милли китапханәсенә 130 ел тулуга багышланган «Кулъязма һәм борынгы басма китапларны туплау, саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре» дип аталган фәнни-гамәли конференция уздырылды. Бу ике зур конференцияне һәм махсус бай күргәзмәләрне оештыруның төп үзәге китапханәнең «Кулъязмалар һәм сирәк китаплар» бүлеге булды. Әлеге күргәзмәләрдә Казан университеты Фәнни китапханәсе, Татарстан Дәүләт музее, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты «Мирасханәсе» хәзинәләре дә күрсәтелде. Болардан тыш, китапханәдә кулъязма истәлекләрдән төзелгән тематик күргәзмәләр дә әзерләнеп һәм оештырылып килә. Мисалга, күптән түгел, 2001 елның август-сентябрь айларында, Россия Милли китапханәсе (С.-Петербург) белән бергә оештырылган, Милли китапханәдә куелган «Татар халкының әдәби мирасы» исемле күргәзмә җәмәгатьчелектә зур кызыксыну тудырды.

Матбугат чараларында даими рәвештә экспедицияләр һәм археографик сәфәр табышлары турында мәгълүмат биреп барыла. Конференцияләрдә дә, матбугаттагы чыгышларда да кулъязма истәлекләрне барлау, саклау һәм өйрәнү буенча китапханә чикләрендәге һәм гомуми масштабтагы хәл ителәсе мәсьәләләр, проблемалар да искәртелә килә. Бигрәк тә борчыганы—кулъязма чыганаклар һәм архив материаллары белән тиешле дәрәҗәдә эшләрлек әзерлекле белгечләрнең җитешмәве. Югыйсә, кулъязмалар туплауны актив рәвештә дәвам итәргә дә, аларны эшкәртеп өйрәнергә дә, яхшы сакланышларын тәэмин итәргә дә, гыйльми тасвирламаларын хәзерләргә дә кирәк. Тупланган кыйммәтле материалларның сакланышы һәм аларны консервацияләү-реставрацияләү мәсьәләсенә мәкаләбездә кинәеп тукталмадык. Бу бик җитди һәм комплекслы чаралар таләп итә. Аларның да уңай хәл ителәчәгенә шигебез юк. Чөнки Татарстан Милли китапханәсенең Химаячеләр шурасы рәисе Р. И. Вәлиев һәм китапханә директоры Н. Ә. Камбеев борынгы мирасыбызны туплау һәм саклау юнәлешендә монарчы алып барылган актив эшчәнлекнең дәвамын тәэмин итәчәкләрен белдерәләр.

Мәкаләбез башында берничә сорау куелган иде. Татарстан Милли китапханәсе «Кулъязмалар һәм сирәк китаплар» бүлегенең ун еллык эшчәнлегенә күзәтү рәвешендәге бу мәкаләдә ул сорауларга җавап бирергә тырыштык. Әйе, 1992 елда Татарстан Милли китапханәсендә бу яңа бүлекне оештыру үзен, һичшиксез, аклады һәм бүлек берникадәр эш күрсәтүгә ирешә дип бәяләү хакыйкатькә хилаф булмас. Киләчәктә исә тагын күбрәк һәм зуррак эшләр, ә алар белән бергә уңышлар көтә дип өметләнәбез.

Китапханәбездәге «Кулъязмалар һәм сирәк китаплар» бүлегендә кулъязма мирасны туплау һәм өйрәнү өлкәсендә монарчы актив катнашкан яшь белгечләребезнең исемнәрен дә әйтеп китәргә кирәк. Ирек Һадиев (хәзер китапханәнең директор урынбасары), Айрат Заһидуллин (хәзер Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире), Ильяс Мөстәкыймев, Рафаэль Яруллин һәм Алсу Нәҗипова халкыбызның кулъязма мирасын саклап калуда үзләренең лаеклы өлешләрен керттеләр. Алар белән берлектә язма мирасыбызның энҗе бөртекләрен эзләп йөзләгән авыллар йөрелде, шәһәрләрдә эш алып барылды, меңләгән капка-ишекләр ачылып, күпме милләттәшләребез белән танышып, әңгәмәләр корылды. Сүзебез ахырында тарихыбыз өчен гыйльми әһәмияткә ия булган тиңдәшсез кыйммәтле кулъязма истәлекләрне саклап, Татарстан Милли китапханәсенә тапшырган барлык милләттәшләребезгә дә ихлас рәхмәтләребезне юллыйбыз.

**Раиф МӘРДАНОВ,**
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең «Кулъязмалар һәм сирәк китаплар» бүлеге фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты.*



## 22–ХАҖ (ХАҖ) СҮРӘСЕ

**Хаҗ сүрәсе 78 аятьтән тора. Мәдинәдә, Мәккәдә иңгән.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әй, сез, кешеләр! Раббыгыз *(каршында гөнаһ кылу)*дан куркыгыз. Чөнки ул Сәгатьтә *(Кыямәт көнендә)*ге тетрәү бик тә дәһшәтле булыр.

*(«Төп нөсхәдә» әл-сәгать» сүзе Кыямәт көне мәгънәсендә кулланыла. Сәгатебез суккач, ягъни Кыямәт җиткәч, галәмдәге тәртип бозыла. Кояш Көнбатыштан чыгачак, җир тетрәүләр, коточкыч гарасат башланачак».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән).

**2.** Ул Көнне күргәч, сабыен имезеп утыручы хатын сабыен онытыр, йөкле хатынның *(куркудан)* баласы төшәр. Кешеләр аек булсалар да, исерек шикелле анкы-минке кебек күренер. Аллаһның җәзасы шулай каты булачак.

**3.** Инсаннар арасында надан килеш Аллаһ хакында бәхәсләшергә һәвәс кешеләр бар. Алар—азгын шайтанга ияргән кешеләр. **(4)** Шайтан хакында болай язып куелган: аны юлдаш иткән кеше белеп торсын, *(шайтан)* аны юлдан яздырачак вә ялкынлы утка *(җәһәннәмгә)* алып керәчәк.

**5.** Әй, халыклар! Янадан терелүгә шикләнсәгез, шуны белеп торыгыз: сезне туфрактан, соңра шәһвәттән, аннан соң галяктан *(кан күзәнәгеннән)*, аннан соң күзәнәкләре беленер-беленмәс җанлы ит кисәгеннән *(яралгы итеп)* яралттык. Кодрәтебезне сезгә белдерер өчен. Һәм мәгълүм бер вакыткача *(яралгының кем булачагын билгеләгән хәлдә)* ана карынында тотабыз. Соңыннан сезне бер бәбәй рәвешендә дөньяга чыгарабыз. Аннан соң акылга, көчкә ия булсын, дип үстерәбез. Кайсыларыгыз *(яшьли)* вафат була, кайберләрегез картаеп, хәлдән тайганчыга чаклы яши, никадәр генә гыйлемле булса да, картлык көнендә барысын да онытып бетерә. Син коп-коры *(үле-җансыз)* Җир йөзенә карап торасың, әмма Без өстенә янгыр яудыргач, ул терелә, бүртә башлый һәм төрле *(токымнан булган)* үсемлекләр үстерә.

*(«Аналыкта яралган яралгының үсеш дәверен күрсәткән бу аятьтәге сүзләрне төрлечә тәрҗемә итәләр. **Х. Чантайда:** токымын кеше суыннан, соңра оешкан каннан, аннан соң (составы) күзәнәкләре беленер-беленмәс бер ит кисәгеннән яралттык. **Х. Караманда:** туфрактан, соңра шәһвәттән, соңра күзәнәкләре беленер-беленмәс җанлы ит кисәгеннән яралттык. **Ш. Ногманида:** балчыктан халык кылдык, соңра нәселегезне үрчетер өчен бер тамчы мәни суыннан, соңра ул суны оешкан кан кылдык, соңра канлы ит кисәге кылдык, кирәк—ул сурәтләнгән булсын, кирәк—сурәтләнмәгән булсын, аның кем булачагын билгелибез... **М. Чагрыҗыда:** «Галяка» сүзенең төрле мәгънәләре бар: бәйләнеш, аралашу, элемтә, мөнәсәбәт бәйләнешләре, оешкан кан. Оеган кан түгел, оешкан кан. Составта оешкан, катлаулы составы булган кан. Кешенең яралуында катнаша торган матдәләр менә болай аңлатыла: хатынның һәм ирнең күкәйлекләре эшләп чыгарган ике орлык кушылып, аралашып, катнашып аналыкка кереп урнашкан яралгы да «галяка» дип атала. Шушы катлаулы эшне башкара алган Аллаһка үләләрне терелтү кебек эш һич тә авыр түгел».)*

**6.** Чөнки Аллаһ ул—Хакыйкатьнең үзе. Аллаһ үлене терелтер. Аллаһ бар нәрсәне дә булдыра ала торган кодрәт иясе.

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

**7.** Хактыр ки, ул Сәгать *(Кыямәт)* сугар. Аллаһ каберләрдәге барча кешеләрне терелтеп кубарыр.

**8.** Кешеләрнең кайберләре, белемсез көе, тугры юл күрсәтүчесе, зиһеннәрен яктыртучы китабы булмаса да, Аллаһ турында фәлсәфә куерта. **(9)** Тәкәббер рәвештә *(күкрәк киереп)* кешеләрне Аллаһ юлыннан яздырырга телиләр. Алар өчен фани дөньяда хурлык әзерләнгән. Кыямәт көнендә исә аларга яндырып-көйдерүче газаплар булыр.

**10.** *(Гөнаһлыларга әйтелер):*

—Бу—үзең *(кулларың илә кылган гөнаһларыңа күрә)* әзерләгән газапларыңдыр. Шик юк ки, Аллаһ бәндәләренә гаделсез булмас.

**11.** Бар шундый кешеләр, кайсыларыдыр ки, Аллаһка ышаныр-ышанмас кына *(денсезлек белән иман эргәсендә)* гыйбадәт кылалар; эшләрендә уңыш килсә, бик нык шатланалар; кыенлыклар килсә, чырайлары үзгәрә *(бу диннән ваз кичеп, Аллаһтан)* йөз чөерәләр. Андыйлар дөньялыгын да, Ахирәттәгеләрен дә югалталар. Менә шушы булыр ап-ачык мәхрүм калу.

**12.** Аллаһны инкарь итеп, үзләренә файда да, зыян да эшләргә көчләреннән килмәгән нәрсәләрне ярдәмгә чакыручылар *(аларның исеме белән гыйбадәт кылучылар)* бар. Бу—кире чыкмаслык бер адашу-саташу. **(13)** Файдасына караганда зарары күбрәк булган ул нәмәрсәләргә табыналар. Ул *(потлар, ташлар)*—шикле ярдәмче, ышанычсыз дуслар.

**14.** Хактыр ки, Аллаһ иман китергән һәм игелек кылган кешеләрне арыкларыннан чишмәләр агып торучы җәннәтләргә кабул итәр. Шик юктыр ки, Аллаһ ихтыяр иткәнен гамәлгә ашыра торган чиксез кодрәт иясе.

**15.** —Бу дөньяда да, Ахирәттә дә Аллаһ *(Пәйгамбәренә)* ярдәм итмәсен иде,—дип уйлаган кеше Күк гөмбәзенә бау таксын да, *(аякларын)* җирдән аерсын *(шул бау буйлый әскә менсен)*. *(Аллаһның Мөхәммәд Пәйгамбәргә)* ярдәм җибәрә торган вәхий юлын киссен. Аның бу хәйләсе ачуын китергәнне *(Аллаһның ярдәмен)* юкка чыгарырмы икән? *(Кяфер кешесениләр генә кыланса да, Аллаһның Мөхәммәдкә булган ярдәмен кисә алмас!)*

**16.** Менә шулай итеп, Без аны *(Корьәнне)* ачык аятьләр хәлендә иңдердек. Хактыр ки, Аллаһ ихтыяр иткән һәр кешесен тугры юлга күндерә ала.

**17.** Мөселманнар, яһүдләр, сабийләр, христианнар, мәҗүсиләр вә мөшрикләр: Аллаһтан башка тәңреләр дә бар, дип табынучыларга килгәндә, хактыр ки, Кыямәт көнендә Аллаһ боларның һәрберсен аерым-аерым хөкем итәр. Аллаһ барысын да белеп торучы.

**18.** Күрмисеземени, Күктәгеләр дә, Җирдәгеләр дә, Кояш та, Ай да, йолдызлар, таулар, агачлар, хайваннар вә инсаннарның күбесе Аллаһка сәҗдә итә; җәзага тарганнары да байтак. Аллаһ кемне дә булса хурлыкка төшерә икән, аны коткарырлык башка берәү дә юк. Андыйга Аллаһ янында хөрмәт вә абруй булмас. Хактыр ки, Аллаһ теләгәнен җиренә житкезә.

**19.** Раббы турында низаглашкан ике төркем бар. *(Мөселманнар белән кяферләр).* Инкарь итүчеләргә уттан тегелгән күлмәк булыр. Аларның башына шау кайнар су түгеләчәк. **(20)** Шулай итеп, аларның бөтен әгъзалары, тиреләре янып-пешәчәк. **(21)** Алар өчен анда тимер чыбыктан үрелгән камчылар булыр. **(22)** Бу әрнүләрдән котылырга теләрләр. Аларны кире утка атачаклар. Һәм:

—Бу үзәк өзгеч ут газапларын татыгыз,—дип әйтелер.

**23.** Хактыр ки, иман китереп, игелек кылганнары арыкларыннан чишмәләр агып ятучы җәннәтләргә кабул итәр. Алар анда алтын беләзекләр киеп, энҗеләр тагарлар. Киемнәре исә ефәктән тегелгән булыр. **(24)** Алар иң татлы-гүзәл сүзгә ирешер, мактауга лаек Аллаһның юлына күндерелгәннәр шулар булыр.

**25.** Хактыр ки, кяферләр инсаннарны Аллаһ юлыннан, Мәсжед-и Харамга керүдән тыялар, Без аны гыйбадәт кылыр өчен кордырдык, анда торучыга *(җирле халыкка)* да, читтән килгән юлчыларга да тигез хокуклар бирдек. Берәрсе ул мәчеттә нәҗеслек кылса, Без аны әрнетүле газап белән җәзалаячакбыз.

**26.** Бервакыт Без Ибраһимга Бәйтулла *(Кәгъбәтулла)* булачак урынны күрсәттек һәм әйттек:

—Һичбер кемне, һичбер нәрсәне миңа тиңдәш кылма, таваф итүчеләр *(изге йортны әйләнеп йөрүчеләр)*, аягөсте гыйбадәт кылучылар, рөкүгъ вә сәҗдәгә киткәннәр өчен йортымны пакь тот,—дидек.

**27.** Кешеләр арасында Хажга баруның кирәклеге турында хәбәр тарат; алар җәяүләп тә, озын юл йөреп арыган дөяләргә атланып та килер. **(28)** *(Алар Хаҗ сәфәрендә кешеләр белән аралашып, мәгълүмат җыеп, пакьләнеп, Хаҗның файдасын күрсеннәр)*, махсус билгеләнгән көннәрдә үзләренә ризык өчен бирелгән корбанлык хайваннар чалып, Аллаһны зикер итсеннәр *(шуның өчен Хаҗга килсеннәр)*. Шул корбан итләрен һәм үзегез ашагыз, һәм дә юксылларга, фәкыйрьләргә дә ашатыгыз.

**29.** Аннан соң керләрдән *(сакал-мыек, чәчле-төкле урыннарын, тырнакларын китәрсеннәр)* арынсыннар. Нәзерләрен үтәсеннәр вә Борынгы Изге Йортымны *(Кәгъбәтулланы)* таваф итсеннәр.

**30.** Менә *(Хаҗ сәфәрендә)* шундый хәлләр. Аллаһның әмерен хөрмәт белән үтәп, тыелганнарны кылмаган һәркемгә Раббы катында бик тә хәерле эш булыр. Харам дип игълан ителгән хайваннардан тыш *(хайваннар)* сезгә хәләл ителде. Шуңа күрә, нәҗестән, *(Аллаһка тиң күрелгән)* потларга табынудан сакланыгыз. Ялган сөйләүдән куркыгыз.

**31.** Аллаһтан башканы илаһ итмәенчә, аның хәнифләре *(ягъни, Аллаһның берлеген танучы мөэминнәр)* булыгыз. Аллаһ янына тагын бер илаһ китереп кушкан кеше Күктән егылып төшкән, *(үләксә козгыннары тарафыннан)* ботарланган *(мәет)* кебек булыр яки давыл өермәсе әллә кайларга илтеп ташлаган үләксәгә тиң булыр. **(32)** Эшләр менә шулай тора. Шөбһә юктыр, Аллаһның хөкемнәрен хөрмәт иткән кешенең күңеле тәкъвалыктадыр.

**33.** Аларда *(корбанлык хайваннарда яки Хаҗ гамәлләрендә)* сезнең өчен, мәгълүм бер вакытка кадәр, файдалар бардыр. Аннан соң аларның барачак җире Борынгы Йорт *(Кәгъбәтулла)* булыр.

**34.** Без һәр өммәт өчен корбан чалуны тәртип иттек. Үзләренә ризык булырга тиешле, дүрт аяклы малларны *(чалганда)* Аллаһ исемен телгә алсыннар, дип. Менә, сезнең Тәңрегез—Ул бердәнбер—Аллаһ. Шулай булгач, Аңа тәслим итегез. *(Ий, Мөхәммәд)* син ихлас күңеллеләрне һәм тыйнак итагатьчеләрне сөендер.

**35.** Аллаһ исемен ишетүгә үк аларның йөрәкләре хөрмәт илә тетрәр. Башларына төшкән авыр сынауларны алар сабырлык белән уздыра. Алар намазны дөрес укый. Үзләренә бирелгән ризыклардан *(Аллаһ юлында)* башкаларга да өлеш чыгаралар.

**36.** Без дөяләрне дә сезнең өчен Аллаһның *(дини)* ишарәләреннән *(корбанлык)* кылдык. Аларда сезнең өчен файда бар. Алар аяклары өстендә торганда да, Аллаһның исемен әйтегез. Янбашларына төшкәндә *(чалганнан соң җан биргәндә дә Аллаһның исемен әйтегез)*. Аларның итен үзегез дә ашагыз һәм дә сораган мохтаҗларга да өлеш чыгарыгыз. Менә шул хайваннарны Без, шөкранә кылырсыз, дип сезнең файдага бирдек. **(37)** Аларның *(корбанга чалынган хайваннарның)* ни ите, ни каны Аллаһка түгел, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына барып ирешә. Сезне тугры юлга бастыручы Аллаһның бөеклеген таныр сыз, *(Аңа тәкбир әйтегез)* дип бу хайваннарны шулай итеп сезнең файдагызга бирдек. *(Ий, Мөхәммәд)* игелек кылганнарны сөендер.

**38.** Аллаһ иманлыларны саклар. Шунысы да хактыр ки, Аллаһ хаин вә

кяфер һәр кешене мәхәббәтеннән мәхрүм итәр. **(39)** Үзләренә гаделсез һөҗүм иткән очракта, җәберләнгән мөселманнарга сугышырга рөхсәт ителде. Шуна күрә, аларга ярдәм итү—Аллаһның кодрәтеннән килә торган эш.

**40.** Алар бары тик:

—Раббыбыз—бер Аллаһ,—дигәннәре өчен генә гаделсезлек илә өйләреннән куылган кавем. Аллаһ бер төрле кешеләрнең яманлыгын икенчеләренең көче илә бастырмаган булса, ул чагында, һичшиксез, эчләрендә Аллаһның исеме еш-еш искә алынган чиркәүләр, синагогалар *(яһүдләрнең гыйбадәт йорты)*, монастырьлар вә мәчетләр җимерелгән булыр иде. Аллаһ *(үз диненә)* ярдәм иткәннәргә, әлбәттә, ярдәм итә. Һич шөбһәсез, Аллаһ көчле һәм җиңүче.

**41.** Җир йөзендә тормыш итәр өчен бер урын бирсәк, алар *(мөэминнәр)* намаз укыр, зәкят бирер, игелек кылыр вә яманлыклардан баш тартыр. Соңыннан аларның эшләре Аллаһ хозурында булыр.

**42.** *(Ий, Мөхәммәд)* сине ялганчы дисәләр *(аптырап калма)*, моңа чаклы да Нух кавеме, Гад белән Сәмуд кавемнәре дә *(үз пәйгамбәрләрен)* ялганчыга чыгарды, аллакчы дип хурладылар. **(43)** Ибраһимны да, Лутны да, **(44)** Мәдьян халкы *(Шөгаебне дә)*, Мусаны да үз кавеме ялганчы дип атады. Мин аларга форсат бирдем *(бәлки тәүбә итәрләр дип)*, соңыннан *(тәүбә итмәгәч)* аларны якалап, җәзага тарттым. Ризасызлыгыма күрә, ай, хәтәр дә җәза бирдем мин аларга. *(Нигъмәтләрен кистем, тормышларын пыран-заран китердем, үзләрен һәлак иттем, йортларын җимереп бетердем.)* **(45)** Гаделсез кыланган бик күп шәһәрләрнең халыкларын Без һәлак иттек. Хәзерендә ул җирләрдәге шәһәр диварлары җимерек килеш саклана. Сусыз калган коелар вә күпме ташландык кальгалар тырпаеп тора.

**46.** Әллә соң алар Җир йөзе буйлап сәяхәт итеп йөрмиләрме? Йөргән булсалар, башларына уй төшкән булыр иде. Колаклары ишеткән булыр иде. Хактыр ки, аларның *(маңгай)* күзләре сукыр түгел, фәкать күңел күзләре сукыр.

**47.** *(Ий, Мөхәммәд)* алар хәзер үк җәза килгәнен күрергә тели. Ләкин Аллаһ вәгъдәсен бозмас. Хактыр ки, Раббы янындагы бер көн сезнең *(вакыт илә)* мең елга торыр.

**48.** Гаделсез хөкем иткән никадәр залим халыкларга Мин *(бәлки, тәүбә итәрләр, дип)* форсат бирдем. Соңыннан Мин аларны җәзага тоттым. Кайтарылыш бары тик Аллаһка гынадыр.

**49.** Әйт:

—Әй, кешеләр, мин бары тик сезне *(Аллаһның җәзасы белән)* кисәтүче, куркытучы гына,—диген. **(50)** Иман китереп, игелек кылганнарга ярлыкау вә мул ризык булыр. **(51)** Бер-берсен уздыра-уздыра, аятьләребезне зәгыйфьләтмәк өчен ярышканнар җәһәннәмнеке булыр.

**52.** Без синнән алда килгән бер генә илчене дә, бер генә пәйгамбәрне дә *(җенси ләззәткә, дәрәҗәгә, абруйга омтылу)* теләкләреннән азат итеп җибәрмәдек. Шайтан исә ул теләкләргә котырту кертә иде. Ләкин Аллаһ шайтанның ул коткыларын юкка чыгара килде. Аллаһ аятьләрен пакь килеш саклый. Аллаһ белеп хөкем итүче чиксез кодрәт иясе.

**53.** Эчләрендә хасталык булганнарга, *(усаллык һәм денсезлектән)* күңелләре катканнарга шайтан вәсвәсәсе сынау булсын. Залимнәр, һич шөбһәсез, үгет кермәс рәхимсезлекләре белән гадел кешеләрдән бик нык аерылып тора. **(54)** Гыйлемле кешеләр аның *(Корьәннең)*, чыннан да, Раббы тарафыннан иңдерелгәнен белсеннәр һәм шуңа инансыннар, аларның күңеле ышанычка ирешсен өчен. Шик юк ки, Аллаһ иманлыларны тугры юлга юнәлтер.

**55.** Аллаһка ышанмаганнар кинәт килеп, Сәгать сукканчыга кадәр яки *(Кыямәт)* көненең газабы килгәнчегә чаклы *(Корьәнгә)* шик белән богачаклар. **(56)** Ул Көнне бар нәрсәгә Аллаһ кына хуҗа. Ул гына кешеләр арасында хөкем йөртер. Иман китереп, игелек кылганнар Нәгыйм җәннәтләре эчендә

булыр. **(57)** Инкарь итеп, аятьләребезне ялганга чыгарырга маташканнар өчен әрнетүле җәзалар булыр.

**58.** Аллаһ юлында һиҗрәт итеп, үтерелгәннәре, үлгәннәре, һичшиксез, Аллаһ татлы ризыклар белән сыйлар. Шик юк ки, Аллаһ ризык биргәннәрнең иң юмарты. **(59)** Аллаһ аларны канәгать калачак бер урынга *(җәннәткә)* куячак. Аллаһ барысын да белә. Ул—миһербанлы хикмәт иясе.

**60.** Менә шулай булыр эшләр. *(Нахак)* зыян күргән кеше зыян күргәне кадәр зыян китергәннән үч алса һәм янә дә зыян күрсә, һичшиксез, Аллаһ аңа ярдәм итәр. Аллаһ ярлыкаучы, мәрхәмәтле гафу итүче. **(61)** Бусы да шулай булыр. Аллаһ—төнне көнгә, көнне төнгә алыштыручы. Аллаһ һәр нәрсәнең асылын ишетә, асылын күрә. **(62)** Нәкъ шулай. Аллаһ—Хакыйкатьнең үзе. Аннан башка илаһ дип табына торган нәрсәләр ялганның үзе. Хакыйкать—Аллаһ. Әлбәттә, Ул—бөек.

**63.** Күрмисезмени, Аллаһ Күктән янгыр яудыра. Җир өсте яшеллек белән каплана. Чыннан да, Аллаһ мәрхәмәтле. Ул бөтен нәрсәдән хәбәрдар. **(64)** Күкләрдәге, Җирдәге бөтен нәрсә дә Аныкы. Хакыйкатән, Аллаһ бер ялгызы. Ул *(һичкемгә, һичнәрсәгә мохтаҗ түгел)* гаять бай, мактауга лаек.

**65.** Күрмисезмени, Аллаһ Җирдәге нәрсәләрне вә әмере буенча дингездә йөзүче көймәләрне сезнең файдага яралтты. Күкне дә Җиргә иңүдән Ул тотып тора. Аның рөхсәтеннән башка Күк Җиргә иңмәс. Аллаһ кешеләргә бик тә шәфкатьле вә миһербанлы.

**66.** Сезгә тормыш *(җан)* биргән, соңра сезне җансыз итүче, аннан соң тагын терелтүче Ул. Дөресе шул, адәми зат бик тә шөкерсез холыклы бит. **(67)** Без һәр өммәткә үзләренә кулай булганча гыйбадәт тәртипләдек. Шулай булгач, алар *(Китап әһелләре)* бу мәсьәләдә синең белән чәкәләшмәсеннәр. Син аларны Раббың тарафына чакыр. Чөнки син, чыннан да, тугры юлдагы кеше. **(68)** Синең белән тарткалашып торсалар, әйт:

—Сезнең ни кылганыгызны Аллаһ яхшы белеп тора,—диген. **(69)** Арагыздагы гаугалар сәбәпчесе булган нәрсәләрне Аллаһ Кыямәт көнендә ачыклап бирер. **(70)**—Шуны да белмисезмени, Аллаһ Җирдә, Күктә ни булса—барысын да белеп тора. Боларның барысы да Китапка *(Ләухел Мәхфүзгә)* язып куелган. Боларны белү Аллаһка бик тә ансат.

**71.** Алар Аллаһны инкарь итеп, тәңрелеккә һичбер дәлил китерә алмаган, үзләре белмәгән нәрсәләргә ябышып-табынып яталар. Гаделсез залимнәрнең һичбер ярдәмчесе булмас.

**72.** Ап-ачык итеп аятьләребезне укыганда тыңлап утыручы кяферләрнең чырайларына бак, ризасызлык күрерсең. Алар аять укучыларны ботарлап ташлардай булып утыра. Әйт син:

—Моннан да хәтәррәге турында сезгә ирештеримме? Җәһәннәм! Аллаһ аны *(сезнең кебек)* кяферләргә вәгъдә итте. Коточкыч бер урын ул—җәһәннәм,—диген.

**73.** Әй, инсаннар, бер мисал бирелде. Хәзер шуны тыңлагыз. Аллаһны инкарь итеп, табына торганнарыгыз бергә җыелышып тырышса да, хәтта бер чебен дә яралта алмаган булырлар иде. Әгәр дә чебен аларның берәр нәрсәсен чәлдерсә, алар аны кире кайтарып ала алмаслар иде. *(Шундый мәгънәсез нәрсәләргә)* табынганнар да бичара, шул табынган нәрсәләре дә бичара. **(74)** Алар Аллаһның кодрәтен белеп бетермиләр. Һич шөбһәсез, Аллаһ чиксез кодрәтле, барысыннан да өстен.

**75.** Аллаһ фәрештәләрне дә, кешеләрне дә илче итеп җибәрә. Шик юк ки, Аллаһ барысын да ишетеп, күреп тора. **(76)** Аларның алда ни күрәчәген дә, узганда ни күргәннәрен дә Аллаһ белеп тора. Барча гамәлләр дә Аллаһка кайтарылачак.

**77.** Әй, иман китергән кешеләр, рөкүгъка китегез, сәҗдәгә егылыгыз, Раббыга гыйбадәт кылыгыз, игелек кылсагыз—котылырсыз. **(78)** Аллаһ юлында Ул канәгать калырлык Җиһад кылыгыз. Ул сезне сайлады, дин юлында сезнең

өскә Ул бернинди дә авырлык йөкләмәде. Атагыз Ибраһим тоткан диндә дә шулай иде. Пәйгамбәрләр сезнең эшләргә шаһит булсын, сез дә кешеләргә шаһит булырсыз дип, алда иңдерелгән китапларда да, монысында *(Коръәндә дә)* сезгә мөселман исеме бирелде. Шулай булгач, намаз укыгыз, зәкят бирегез, Аллаһка сыеныгыз. Ул сезнең Раббыгыздыр. Нинди яхшы Раббы, нинди игелекле ярдәмче ул—Аллаһ Тәгалә!

# 23–МӨЭМИНУН (МӨЭМИННӘР) СҮРӘСЕ

**Мөэминнәр сүрәсе 118 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Һичшиксез, мөэминнәр Сәгадәткә ирешәчәк. **(2)** Чөнки алар намаз-гыйбадәтләрендә итагать илә сәҗдә итә. **(3)** Алар файдасыз, буш сүз сөйләми. **(4)** Зәкят бирүчеләр. **(5)** Сафлыкларын саклыйлар *(җенси азгынлыктан тыйлыгалар)*. **(6)** Хатыннары вә җарияләре *(белән булган назик эшләр)* бу хисапка керми. Һәм болар *(хатыннары, җарияләр белән булган гамәлләре)* өчен җәза бирелмәс.

**7.** *(Шушы ике төрле хатыннардан)* башкаларын *(җенси ләззәт өчен кулланырга)* теләгән кеше, һичшиксез, хәттин ашкан *(азгын)* булыр.

**8.** Алар *(мөэминнәр)* әманәтләрне саклаучылар һәм антка тугры калучылар.

**9.** Алар—намазларын калдырмыйча, үз вакытында укып баручылар. **(10)** Алар, һичшиксез, *(оҗмах)* варислар(ы) булачак. **(11)** Шулар гына Фирдәвес җәннәтенең варислары булыр. Алар анда мәңгегә яшәп калачак.

**12.** Хактыр ки, Без инсанны *(Адәм галәйһиссәләмне)* сафландырылган балчыктан ясадык.

*(**Ш. Ногманида:** саф балчыктан яралттык. **Х.Караманда:** сөзелеп чыгарылган балчыкның үзлесеннән яралттык. Крачковскийда: создали человека из эссенции глины. Т. **Кочигиттә:** балчыкның сафыннан яралттык. Йомгаклап шуны әйтергә була: җирдә, туфракта, дымлы, үзле балчыкта кеше бәдәне өчен кирәкле бөтен элементлар да бар. Шул рәвешчә, бөек галим—Аллаһ Тәгалә махсус әзерләнгән химик-биологик матдәләр белән беренче адәми затны барлыкка китерә. Аннан соң шул адәми зат үз организмыннан үрчи башлый. **М. Алидә:** сотворение человека выводится здесь из земли, ибо «малая жизненная капля, то есть сперма, происходит из пищи, которая так или иначе берется из земли.)*

**13.** Соңыннан аны ышанычлы бер урынга тамчы итеп урнаштырдык. *(Адәм (галәйһиссәләм)нең нәсел орлыгын хатынының аналыгына урнаштырдык).*

*(**Х. Чантайда:** соңыннан аны (Адәмнең токымын, кеше яралгысын) катлаулы һәм чыдам, ышаучан итеп, тамчы (шәһвәт, мәни) рәвешендә (ышанычлы) ояга (ана карынына) урнаштырдык. **Ш. Ногманида:** соңра Адәмнең нәселен ана карынында мәни кылдык. **Х. Караманда:** соңра аны ышанычлы бер урынга шәһвәт хәленә китердек.*

**14.** Аннан соң шул шәһвәт тамчысын кузәнәк оешкан кан *(яралгы)* хәленә китердек; канны җепсел-җепсел ит иттек; аны сөяккә *(сөлдәгә, скелетка)* әверелдердек, шул сөякләрне ит белән каплаттык. Соңра аны башка рәвешкә *(кеше сурәтенә)* китереп, хасил иттек *(җан өрдек)*. Иҗат белән шөгыльләнүчеләрнең иң бөеге, иң данлысы—Аллаһ Тәгаләдер.

**15.** Соңыннан, һичшиксез, барыгыз да үләчәксез. **(16)** Ахырда сез Кыямәт көнендә, әлбәттә, терелтеләчәксез. **(17)** Хактыр ки, Без сезнең өстегездә җиде юл яралттык. Яралтканнарыбызны без һәрвакыт күзәтеп торабыз, аларга Без битараф түгел.

*(«**Җиде юл**—җиде кат Күк, фәрештәләр йөри торган юллар, дип аңлаталар, ләкин бәгъзе тәфсирчеләр ул җиде юлны кешенең җиде сәләте, дип аңлыйлар: күрү, ишетү, тәм тату, ис сизү, тире белән тоеп сизү, акыл сәләте, вәхийны сиземләү—күңел сизгерлеге, инстинкт, диләр».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.

*«Здесь говорится о семи путях, под которыми несомненно имеются в виду орбиты семи планет Солнечной системы, не считая Земли—это явствует из слов «над вами». Мөхәммәд Али тәфсиреннән.)*

**18.** Җитәрлек микъдарда Без Күктән яңгырлар яудырабыз, Җирне су белән туендырабыз. Хактыр ки, Без аны корыта да алабыз. **(19)** Шулай итеп, *(Җиргә сеңгән дым аркасында)* хөрмә бакчалары һәм йөзем баглары үстерәбез. Аларда сезнең өчен мул җимешләр бар, сез аларны *(рәхәтләнеп, шөкер итә-итә)* ашагыз. **(20)** Синай тавында *(сезнең өчен)* бер *(зәйтүн)* агач(ы) үстердем. Бу агач май да бирә, башка ризыкка катыштырып ашый торганы *(җимеше дә)* бар. **(21)** Хайваннарда да сезнең өчен файдалы гыйбрәтләр бар. Аларның эчендә яралтылганнары *(сөтне)* сезгә эчертәбез. Алардан сез бик күп файдалар күрәсез. Итен дә ашыйсыз. **(22)** Аларга атланып йөрисез һәм көймәләрдә дә йөзәсез.

**23.** Хактыр ки, Нухны кавеменә күндердек, ул:

—Әй, халкым, Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Сезнең өчен Аннан башка һичбер тәңре юктыр. *(Башка ясалма илаһларга табынасыз, гөнаһлы булудан)* Аллаһның җәзасыннан курыкмыйсызмыни соң?—диде.

**24.** Кавеменең инкарьчы житәкчеләре *(халыкка)* әйтте:

—Бу бары тик сезнең кебек бер бәндә генә. Ул сездән өстен хаким булырга тели. Аллаһ безгә пәйгамбәр күндерергә теләсә, һичшиксез, фәрештәләрен җибәргән булыр иде. Бездән элек яшәп киткән ата-бабаларыбыздан бу турыда һичбер нәрсә ишетмәдек,—диделәр. **(25)**—Бу бары тик акылыннан язган бәндә булырга тиеш. Шулай булгач, аның тилелек шаукымы узып киткәнен сабыр итеп көтик.

**26.** Нух әйтте:

—Йа, Раббым, мине ялганчыга чыгарганнарга каршы *(көрәшергә)* ярдәм ит, зинһар,—диде.

**27.** Шуннан соң Без аңа вәхий юлладык:

—Күзәтүебез астында, кушканыбызча көймә яса. Әмеребез килеп, кайнап, сулар арта башлагач, һәр женестән берәр пар җанлылар ал; үзләренә хөкем чыгарылганнардан тыш, гаиләңне ал. Көфер итүчеләр өчен Миңа ялварма. Аларның барысы да батып үләчәк.

*(Күп кенә тәфсирләрдә ниндидер мичнең кайнавы, суларның арта башлавы турында языла. Ләкин кайбер язучылар мич турында һичбер сүз әйтми. Бары тик суларның ташуы турында гына язалар.* ***Т. Кочигиттә:*** *әмеребез килеп, сулар кайный башлагач, диелгән.* ***Х. Карамандa:*** *әмеребез килеп, сулар артып ташый башлагач, диелгән.* ***И. Крачковскийда:*** *придет Наше повеление и закипит печь.* ***Х. Чантайда:*** *әмеребез килеп тә мич кайный башлагач, диелгән.* ***Ш. Ногманида:*** *мичтә су кайнаса, диелгән.)*

**28.** Якыннарың белән көймәгә яхшылап урнашканнан соң әйтерсең:

—Аллага шөкер, безне залимнәрдән коткарган Аллаһ Тәгаләгә мактаулар булсын!—диярсең. **(29)** Аннан соң тагын әйт:

—Раббым, мине *(көймәдән)* бәрәкәтле бер җиргә төшерсәнә. Син урнаштыручыларның иң хәерлесе,—диген.

**30.** Шик юктыр ки, монда *(Нух вакыйгасында)* беркадәр гыйбрәтләр бар. Хакыйкатән, Без шулай сынап бaгабыз. **(31)** Соңыннан алар урынына башка бер кавемне *(Гад белән Сәмуд халыкларын)* китердек. **(32)** Аларның үз араларыннан сайланган берәүне *(Һудны)* пәйгамбәр итеп күндердек; ул *(үз халкына):*

—Аллаһка буйсынып, гыйбадәт кылыгыз. Сезнең Аннан башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәңре булырдай һичберкемегез юк. Әле һаман Аллаһтан *(җәзасыннан)* курыкмыйсызмы?—диде.—Нигә сакланмыйсыз?

**33.** Аның халкы арасындагы кяферләрнең түрәләре дөнья тормышында мул нигъмәт эчендә яшәсәләр дә, Ахирәтне инкарь итүчеләр иде. Алар әйтте:

—Бу безнең кебек үк бер бәндәдер. Без ашаганны ашый, без эчкәннәрне эчә,—диделәр. **(34)**—Әгәр дә сез үзегез кебек үк гап-гади кешегә иярсәгез, бәхетсез булачаксыз. **(35)** Ул сезгә үлеп, туфрак булганыгыздан соң, черек сөяк өеменә әверелеп беткәчтән дә, һичшиксез, терелеп *(кабердән)* кубарылачагыгызны

вәгъдә итә. **(36)** Ул вәгъдә итә торган нәрсәләр бик ерак әле *(булырдай эш түгел ул).* **(37)** Тормышта яшәү бары тик шушы дөньяда гына. Яшибез дә үләчәкбез. Берәү дә янадан терелмәячәк, **(38)** Алласы турында ул шыр ялган гына сөйләп йөри торган бәндә. Без ана ышанмыйбыз.

**39.** Пәйгамбәр:

—Раббым,—диде.—Мине ялганчыга чыгарганнарга каршы *(көрәшергә)* ярдәм ит, зинһар. **(40)** Аллаһ әмер итте:

—Озакламый алар пошаманга төшәчәк,—диде.

**41.** Чынлап та, куркыныч, әмма гадел бер аваз аларны качып котыла алмаслык каты итеп тотты. Һәм Без аларны, коры чүп үләне кебек, өермә белән алып киттек. Залимнәрнең җаннары җәһәннәмгә олаксын. **(42)** Соныннан алар урынына башка кавемнәрне бар иттек. **(43)** Һичбер өммәт *(үзенә Аллаһ тарафыннан билгеләнгән)* вакытын *(әҗәлен)* ашыктыра алмаган кеби, аны кичектерә дә алмас. **(44)** Без бер-бер артлы пәйгамбәрләр күндердек. Пәйгамбәрләр килгән саен, алар *(мөшрикләр, кяферләр)* пәйгамбәрләрне ялганчыга чыгара бардылар. Без дә аларны *(инкарьчыларны)* берсе артыннан икенчесен юк итә бардык. Һәм, *(башкаларга)* гыйбрәт булсын дип, аларны хикәятләребезгә керттек. Иман китермәгәннәрнең жаны—җәһәннәмдә.

**45.** Аннан соң аятьләребез вә ап-ачык фәрманнарыбыз илә Муса һәм аның кардәше Һарунны Фиргәвенгә вә аның яраннарына күндердек. **(46)** Ләкин алар *(Фиргәвен кавеме)* тәкәббер һәм масайган халык булып чыкты. **(47)** Алар әйтте:

—Безгә буйсынган халык арасыннан чыккан, безнең кебек үк шушы ике бәндәгә иярергә тиешме без?

**48.** Шулай итеп, аларны ялганчыга чыгардылар. Һәм шунын аркасында һәлак булдылар да. **(49)** Дөресе шул, бәлки, алар игә килер дип, Мусага Китап бирдек.

**50.** Мәрьямнең улы *(Гайсәне)*, аның анасын *(кодрәтебез илә)* аятьтә үрнәк кылдык. Аларны уңайлы урынга, чишмәле калкулыкка урнаштырдык.

**51.** Әй, пәйгамбәрләрем! Пакь-хәләл ризыклар гына ашагыз. Игелек кылыгыз. Сез кылганнарның барысын да Мин дөресе белән белеп торамын.

**52.** Шик юктыр ки, сезнең динегез—бердәнбер хак дин. Мин сезнең Раббыгыз буламын. Бәс, Минем җәзамнан куркыгыз. **(53)** Аяныч ки, кешеләр үзара бозылышып, *(дин)* эшләрен аерым-аерым фиркаларга бүлгәләп бетерделәр. Һәр фирка үз *(дин)*ен мактап, аны гына хак *(дин)*, дип лаф ора. **(54)** Хәзер инде син мәгълүм бер вакытка чаклы аларны адашкан хәлдә, үз юлларында калдырып кит. **(55, 56)** Үзләренә муллык һәм күп угыллар биргәч, алар: *(Аллаһ)* безгә яхшылык эшләргә ашкынып тора икән, дип уйлыйлар, ахрысы. Юк шул! Алар *(эшнең асылын)* аңлап бетерми. *(Бу нигъмәтләр һәм угыллар аларны сынар өчен генә бирелә).*

**57.** Хактыр ки, Раббыны бөек күреп, *(гөнаһ кылудан)* куркып, гыйбадәт кылучылар менә кемнәр: **(58)** Раббының аятьләренә ныклы иман китергәннәр, **(59)** Раббыга тиң, дип башка затларга табынмаганнар, **(60)** Раббы янына кайтарылачакларын белеп, куркып, бирәчәкләрен *(бурыч-әҗәт, хәер, садәка, зәкятне)* ихлас күңелдән кайтарганнар, **(61)** ярыша-ярыша *(бер-берсен уздырырга тырышып)* игелек кылучылар. *(Әҗер-савап алганда)* алар иң алгы сафта булыр.

**62.** Без һичбер кемгә көче җитмәслек эш йөкләмибез. Яныбызда дөреслекне бәян кылучы бер китап *(Ләүхел Мәхфүз)* бар. Алар хаксызга рәнҗетелмәс. **(63)** Хәер, алар *(инкарьчылар, наданлыклары аркасында)* болар турында хәбәрдар түгел. Һәм моннан башка да алар кылган гөнаһлар байтак. Әле кыласылары күпме!

**64.** Байлык-муллык эчендә яшәүчеләрен җәзага тотсак, алар шундук ярдәм сорап кычкыра башлый. **(65)** Аларга:

—Зарланмагыз, сезнең аһ-зарыгыз файда бирмәс!—дип әйтербез. **(66, 67)**—Каршыгызда аятьләребезне укыган чакта, сез борыныгызны чөеп, арка куеп китә идегез. Җыелышып, кичләр буе *(Коръәнне)* мыскыл итеп лаф ора

идегез. **(68)** Хак сүз *(Коръән)* турында яхшылап уйлап бакмадылар. Әллә соң аларның ата-бабаларына килмәгән берәр нәрсә *(китап, яки пәйгамбәр, яки Аллаһның газабыннан котылу)* ингәнме? **(69)** Яки үз пәйгамбәрләрен башта ук *(яхшы кеше, гүзәл әхлаклы, бер тапкыр да ялган сөйләмәгәнен)* белмиләр идемени? *(Беләләр иде.)* Шулай да аны *(Аллаһның илчесе икәнен)* инкарь иттеләр. **(70)** Алар Рәсүлемне: гәрчә ул Хакыйкатьне *(Коръәнне)* китерсә дә: ул җенләнгән, диделәр. Ләкин ул Хакыйкать күбесенең күңеленә хуш килмәде. **(71)** Әгәр дә *(Аллаһ тарафыннан күндерелгән)* Хакыйкать аларның күңеленә хуш килә торган булса, күкләрдә, Җирдә *(булган төзеклек бозылыр)*, һичшиксез, гарасат башланган булыр иде. Без аларга *(Коръән сыйфатында)* бары тик шан-шәрәфләр китердек, ләкин алар шуннан ваз кичте.

**72.** *(Ий, Мөхәммәд)* әллә син алардан берәр бүләк өмет итәсеңме? Раббың бирәчәк бүләк аннан да хәерлерәк булачак. Раббың бүләкләүчеләрнен иң юмарты. **(73)** Хактыр ки, син аларны тугры юлга чакырасың. **(74)** Ахирәт көненең киләчәгенә инанмаганнар тугры юлдан язганнар булыр.

**75.** Аларны кызганып, өсләренә килгән бәлаләрне алсак, алар күзләре күрмәс дәрәҗәгә җитеп, барыбер элеккеге азгынлыкларын дәвам иткән булырлар иде. **(76)** Хактыр ки, Без аларны *(ачлык белән)* җәзаладык, шуннан соң да алар Раббыга буйсынмады, *(ярлыкау сорап)* Аңа ялвармадылар. **(77)** Җәзалар белән тулы һәм дәһшәтле бер капканы ачканнан соң, аларның ничек шашып, өметсезлеккә төшкәннәрен күрсәң иде.

**78.** Аллаһ сезгә колаклар, күзләр, күңел тойгылары бирде. Ләкин, ни өчендер, сез аз шөкер итәсез.

**79.** Сезне яралткан да, Җир өстенә тараткан да—Аллаһ. Сонра Аның хозурында тупланачаксыз. **(80)** Җан биргән дә—Ул, җан алган да—Ул. Төн белән көнне алмаштыру эше дә Аның хөкемендә. Шуны аңлар өчен *(аңлагач, иман китерер өчен әле һаман)* акылыгызны җикмисезмени? **(81)** Шуңа да карамастан, алар борынгылар сөйләгәнне кабатлый. **(82)** Алар:

—Үлеп, туфрак булгач, сөяк өеменә әверелгәч, чыннан да, без янадан терелербезме? *(Без моңа ышанмыйбыз)*,—диләр. **(83)** Чыннан да, безгә борынгы ата-бабаларыбызга да шуны *(үлгәннән соң терелүне)* вәгъдә иткәннәр иде инде. Ләкин *(берсенең дә терелгәне юк)* бу *(вәгъдәләр)* искедән калган әкиятләр генә. Башка түгел.

**84.**—Күп белсәгез, әйтегез: бу дөньяга һәм андагы барча нәрсәгә кем хуҗа?—дип сора син алардан. (85) Алар, һичшиксез:

—Аллаһ!—дип әйтәчәк.

—Шулай булгач, нигә уйлап карамыйсыз *(нигә иман китермисез)*?—диген. **(86)**—Җиде кат күкләрнең һәм бөек Гарешнең Раббысы кем?—дип сора син алардан. **(87)**

—Аллаһ!—дип әйтерләр.

—Шулай булгач, сез Аллаһның җәзасыннан нигә курыкмыйсыз? *(гөнаһлардан сакланмыйсыз!)*—диген. **(88)**—Алай бик күп белсәгез, әйтегез: барлык мөлкәтне кем үз ихтыярында тота? Һәр нәрсәне саклап-коткаручы, әмма Үзе моңа мохтаҗ булмаган ул кем?—дип сора син алардан. **(89)**

—Аллаһ!—дип әйтерләр.

—Алайса, нишләп сез *(хисләрегезне тыймыйча, нәфесегезне авызлыкламыйча)* вәсвәсәгә биреләсез?—диген.

**90.** Без аларга Хакыйкать иңдердек, алар аны ялганга чыгарды. **91.** Аллаһ бернинди дә баланың атасы булмады. Аңа тиң башка бер илаһ та юк. Әгәр булса, һәр илаһ үзе яралткан малны һәм идарәне үз кулына алырга тырышыр иде һәм, мотлак, алар бер-берсен җинәргә тырышып, сугышырлар иде. Аллаһ алар *(мөшрикләр)* табынганнардан өстен. **92.** Аллаһ яшерелгәнне дә, ачыгын да белүче. Ул мөшрикләр уйлап чыгарганнардан *(ясалма илаһлардан)* бөек. **93.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син:

—Йа, Раббым, аларга вәгъдә иткән газапларыңны миңа да күрсәтсәң иде. **(94)** Раббым, зинһар, мине залимнәр арасына куйма,—диген. **95.** Әлбәттә, Без

аларга вәгъдә иткәннәребезне сиңа да күрсәтә алабыз. **(96)** Син *(алар кылган)* яманлыклардан яхшы гамәлләрең белән саклан. Без аларның *(сиңа)* ни сылтаганнарын бик яхшы белеп торабыз. **(97)** Әйт син:

—Раббым, шайтаннарның вәсвәсәсеннән Сиңа сыенамын,—диген.—**(98)** Алар яныма килә башласа да, Сиңа сыенамын,—диген. **(99)** Ниһаять, аларның берәрсен әҗәл тотса, әйтер:

—Раббым, мине дөньяга кире кайтар; **(100)** эшли алмый калган игелекләрне башкарачакмын,—дип кабат-кабат ялварыр. Юк! Бу аның авызыннан чыккан буш сүз генә. Кыяматкә чаклы аларны терелтмичә тота торган бәрзах *(комачау)* бар.

**101.** Сур быргысына өрелгәч *(Кыямәт килеп җиткәч)*, алар арасында туганлык җепләре калмас, *(ярдәм итәр өчен)* сораштыра-сораштыра бер-берсен эзләмәсләр. **(102)** *(Саваn)* бизмәне авыр тарткан кеше Сәгадәткә ирешкән булыр. **(103)** *(Гөнаһ)* бизмәне авыр баскан кеше үзенә котчыккыч зыян эшләгән кеше булыр, алар мәңгегә җәһәннәмдә калачак. **(104)** Аларның чырайларын ялкын чорнар, аларның йөзе имәнгеч *(тешләре ыржайган, авызлары чалшайган)* булыр. **105.** Аятьләребезне укыганда, сез аларны ялганга чыгармадыгызмы?

**106.** Әйтерләр:

—Раббыгыз, *(нәфесебезне тыя алмыйча)* бәдбәхетлегебез өскә чыкты, без юлдан язганнар өеренә әвереләдек,—диярләр.

**107.**—Раббыбыз, безне моннан чыгар. Әгәр без тагын *(кылган әшәкелекләребезне)* дәвам итсәк, менә шунда инде без, чыннан да, залимнәр булырбыз.

**108.** Аларга әйтелер ки:

—Рисвай килеш шунда кала бирегез. Минем белән сөйләшергә җөрьәт итмәгез.

**109.** Бәндәләрем арасында шундыйлары да бар иде:

—Раббыбыз, без иман китердек; шулай булгач, Син безне гафу ит; безне кызган. Син мәрхәмәтлеләрнең дә мәрхәмәтлесе,—диделәр.

**110.**—Менә сез аларны мәсхәрә иттегез; *(шул мәсхәрәләүләрегез белән артык мавыгып, сез)* Мине оныттыгыз, сез аларны мыскыллап көлә идегез. **(111)** Бүген Мин аларны *(шул мыскылларга түзеп торган)* сабырлыкларына күрә, бүләклим дә. Шик юк ки, алар—морадларына ирешкән бәхетле кешеләрдер.

**112.** *(Аллаһ инкарьчылардан)*:

—Җирдә сез ничә ел тордыгыз?—дип сорар.

**113.** Алар:

—Бер көн яки көннең берничә сәгатен тордык. Санап барганнардан *(фәрештәләрдән)* сора,—дип әйтер.

**114.** *(Аллаһ аларга)* әйтер:

—Бик аз тордыгыз. *(Җәһәннәмдә мәңгегә калачагыгызны)* белсә идегез!

**115.**—Болай гына, эше булмаганнан эш булсын, дип кенә безне яралтты һәм, чынлап та, ул безне үз хозурына кайтармас,—дип өметләнәсезме?

**116.** Мотлак хаким булган Хак Тәгалә—бөек. Аннан башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәңре булырдай һичберкем юк. Ул—бөек Гарешнең хуҗасы.

**117.** Кем дә кем, һичбер исбаты булмаган көенчә, Аллаһка тиң башка берәр *(уйдырма)* илаһка табынса, аның хисабы *(җәзасы)* бары тик Аллаһ ихтыярындадыр. Хакыйкать шулдыр ки, кяферләр Сәгадәткә ирешә алмас *(курыкканнарыннан котылмаслар, өмет иткәннәренә ирешмәсләр)*.

**118.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйткел:

—Йа, Раббым, *(мөселманнарны)* ярлыка, аларга мәрхәмәтле бул. Миһербанлыларның иң хәерлесе—Син,—диген.

# 24—НУР (НУР) СҮРӘСЕ

**Нур сүрәсе 64 аятьтән тора. Мәдинә-и Мөнәүвәрәдә иңгән. 35 нче аятьтә күкләрне, Җир йөзен яктыртучы Аллаһның нуры турында сөйләнгәнгә күрә, сүрәнең исеме дә Нур дип атала.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** *(Бу сүрәне)* иңдердек һәм фарыз иттек—бу шундый сүрә. Анда ап-ачык аятьләрне иңдердек. Бәлки, уйлый торгач, гыйбрәт алырсыз!

**2.** Зина кылган хатын белән иргә йөзәр таяк сугыгыз. Әгәр Аллаһка вә Ахирәт көненә инанган булсагыз, *(Аллаһның дине кушканнарны үтәүче булсагыз)* аларны кызганмагыз. Аларны җәзалаганда *(берничә)* мөэминнең шаһит булып торуы шарт.

*(«Ибне Габбас (разый Аллаһу ганһу)гә күрә, бу шаһитләр дүрт кешедән алып, кырыкка чаклы булырга мөмкин. Зина—хәттин ашу, Аллаһ тарафыннан куелган чикләрне (хәтне) бозу иң зур гөнаһлардан санала. Аятьтәге җәза никахлы булмаган, өйләнмәгән егет белән кызга бирелә. Әгәр дә никахлы булып та, башкалар белән зина кылганнарга рәҗем җәзасы бирелә. Ягъни, таш белән атып үтерү».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**3.** Зиначы ир зиначы хатынга яки мөшрик булган хатынга гына өйләнергә хаклы. Зиначы хатын да зиначы яки мөшрик ирдән башкага кияүгә бармас. Мөэминнәрнең зиначылар белән *(өйләнүе, җенси)* мөнәсәбәтләргә керүе харам саналыр. **(4)** Намуслы һәм хөр хатыннарга *(зина кылды дип)* нахак сүз әйткән кешеләр дүрт шаһит китерә алмаса, һәрберсе сиксән тапкыр таяк белән сугылыр. Алга таба алардан беркайчан да шаһитлек соралмас. Алар фасикъларның да фасигы—бозык адәмнәрдер. **(5)** Мәгәр соңыннан *(гайбәт сөйләгәннәренә үкенеп)* тәүбә итсәләр, төзәлсәләр: Аллаһ—ярлыкаучы һәм бик тә миһербанлы. **(6)** Кем дә кем үз хатынына нахак яла яга икән, үзеннән башка шаһитләре булмаса, сөйләгән сүзләренең дөрес икәнлегенә Аллаһ исеме белән дүрт тапкыр ант итсә, шаһитлеге кабул ителер. **(7)** Бишенче тапкыр ант иткәндә ул:

—Әгәр дә мин ялганласам, валлаһи, Аллаһ мине рәхимсез җәзалар,—дип үзенә ләгънәт чакырыр. **(8)** Әгәр дә хатын дүрт тапкыр Аллаһ исеме белән:

—Валлаһи, ирем ялганлый,—дип ант итсә, җәзадан котылыр. (9) Бишенче тапкырында ул:

—Ирем хак сөйләсә, мине Аллаһның ләгънәте суксын,—дип үзенә ләгънәт чакырыр.

**10.** Әгәр дә Аллаһның рәхмәте киң булмаса, үкенүләрне, тәүбәләрне кабул итүче бердәнбер хөкемче һәм хикмәтләр иясе Аллаһ булмаса... *(халкайләрегез бик тә мөшкел булыр иде).* **(11)** Ул уйдырма хәбәрне *(нахак сүзне)* сөйләгәннәр арагыздан бер төркем кеше иде. Аны *(ялган сүзне)* сез күңелегезгә якын алмагыз. Киресенчә, ул сезнең өчен файдага гына булыр. Аларның һәрберсенә кирәгенчә *(гөнаһына күрә җәза)* бар. Аларның иң гөнаһлысы иң хәтәр җәза алыр.

*(«Бер яу сәфәрендә Хәзрәти Мөхәммәднең хатыны хәзрәти Гайшә дә катнаша. Сугыштан кире кайтканда хәзрәти Гайшә ыстанда булмый. Ул мәшгуль булган бер җирдә кыйммәтле муенсасын төшереп калдыра, ул шуны эзләп киткән була. Ләкин сугыштан кайтучылар хәзрәти Гайшәне дөя өстенә корылган, өсте каплаулы ханәкә эчендә утырадыр, дип кузгалып китәләр. Гаскәр артыннан күзәтүче вазифасы булган берәү ялгыз калган Гайшәне алып, гаскәрне куып җитә. Гаскәрдәге Габдулла бине Убәй исемле бер монафикъның сүзләренә ышанып, берничә кеше Гайшә турында ялган хәбәр тарата; имештер, ул хатын иренә хыянәт итәр өчен аерылып калган».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.)

**12.** Бу яланы ишеткәннән соң сез, *(Аллаһка)* инанган ирләр, мөслимә хатын-кызлар, ни өчен күңелегездә яхшы уй асрамадыгыз һәм ни өчен сез:

—Юк, бу ап-ачык бер нахак яла,—дип кычкырмадыгыз? **(13)** Нишләп алардан сез дүрт шаһит китерүләрен таләп итмәдегез? Шаһит китерә алмасалар,

алар Аллаһ каршысында ялганчыга калган булыр иде. **(14)** Әгәр дә дөньяда һәм Ахирәттә Аллаһның сезгә карата мәрхәмәте киң булмаса иде, гайбәт сазлыгына кереп батып, һичшиксез, хәтәр газаплар эчендә калган булыр идегез. **(15)** Чөнки сез бу гайбәтне телдән төшермичә, бер-берегезгә сөйлисез. *(Үз күзегез белән күрмәгән)* белмәгән нәрсәләрне *(өзлексез)* кабатлыйсыз һәм бу эшне шулай кирәк *(гадәти бер хәл, аның гөнаһысы юк)* дип уйлыйсыз. Гәрчә, Аллаһ катында ул бик зур гөнаһ санала. **(16)** Нигә сон аны *(гайбәтне)* ишеткәч тә сез:

—Болай *(нахак сүз)* сөйләү килешә торган эш түгел. Әстәгъфирулла! Житте! Бу бик әшәке гайбәт бит,—дип әйтмисез! **(17)** Әгәр дә сез иман китергән кешеләр икәнсез, беркайчан да моның кебек эшләрне кабатламасыннар дип, Аллаһ сезне кисәтә *(нахак сүз сөйләүне харам эш итә)*. **(18)** Аллаһ аятьләрен шулай ачык итеп аңлата. Аллаһ—*(барысын да)* белүче, хөкем вә хикмәт иясе. **(19)** Иманлы кешеләр арасында чирканыч гайбәт таратудан ләззәт ала торганнар дөньяда да, Ахирәттә дә хәтәр җәзага мәхкүм булачак. Аллаһ белгәннәрне сез белмисез.

**20.** Аллаһ сезгә рәхимле вә мәрхәмәтле булмаса, Аллаһ сезгә бик тә рәхмәтле вә ярлыкаучы булмаса... *(сезнең хәлкәйләрегез бик тә мөшкел булыр иде)*.

**21.** Әй, иман китергән кешеләр, шайтанга иярмәгез. Шайтан үзенә ияргән кешегә, һичшиксез, ярамаган гамәлләр һәм яманлык эшләргә котырта. Аллаһ сезгә рәхимле вә мәрхәмәтле булмаса, сезнең берегез дә мәңге дә пакьлеккә ирешә алмаган булыр иде. Бары тик Аллаһ кына Үзе ихтыяр иткән кешесен пакьлеккә чыгарыр. Аллаһ барысын да ишетеп, белеп торучы.

22. Муллыкта яшәүче, саф мөселман кешесе туганнарына, юксылларга, Аллаһ юлында һиҗрәт иткәннәргә ярдәмен киметмәсен, *(хаталарын)* гафу итсен, кичерсен *(моннан түбән мин аңа ярдәм итмим дип)* ант итмәсен. Үзегез дә Аллаһ ярлыкавын бик телисез бит. Чыннан да, Аллаһ—ярлыкаучы һәм бик тә мәрхәмәтле.

*(«Хәзрәти Гайшә зина кылды, дип гайбәт таратучылар арасында хәзрәти Әбү Бәкернең тәрбиясендәге Мыстах исемле бер кеше дә бар иде. Хәзрәти Әбү Бәкер аның гайбәтче икәнен ишеткәч, Мыстахка моннан ары аңа ярдәм итмәячәкмен, дип ант итте. Аять шуңа юнәлтелгән»*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.)

**23.** Зина кебек эшләрдән пакь, әшәкелектән хәбәре булмаган, намуслы мөэминәләргә *(гайбәт)* нахак яла ягучылар дөньяда да, Ахирәттә дә ләгънәтләнер. Аларга бик тә хәтәр газаплар әзерләнгән. **(24)** Ул Көнне аларның үз телләре, үз куллары, үз аяклары үзләренә каршы чыгып, аларның *(дөньяда)* ни кылганнары турында шаһитлек итәчәк. **(25)** Ул Көнне Аллаһ аларга тиешле җәзаларын тулысы белән бирер. Һәм менә шунда инде алар, Аллаһ—Хакыйкатьнең үзе икәнен, ниһаять, аңлаячак.

**26.** Яман хатыннар—яман ирләргә. Әшәке ирләр—әшәке хатыннарга. Яхшы хатыннар—яхшы ирләргә. Саф ирләр саф хатыннарга тиеш. Алар гайбәтләрдән өстен затлар. Аларга ярлыкау һәм *(җәннәттә)* татлы ризыклар әзерләнгән.

**27.** Әй, иманлы бәндәләр, үз өегездән башка кеше өйләренә, килгәнегезне искәртеп, рөхсәт белән генә керегез. Өйдәгеләргә сәлам бирмичә кермәгез. Бу үзегез өчен хәерле гамәлләр. Һәрхәлдә бу турыда уйлап гыйбрәт алырсыз. **(28)** Өйдә кеше булмаса, рөхсәт бирелгәнче кермәгез. Әгәр сезгә:

—Китегез,—диелсә, шундук китегез. Бу сезнең өчен бик тә мөһим әдәп тәртибе. Аллаһ кылмышларыгызны белеп тора. **(29)** Ташландык өйгә кереп, кирәгегезне аласыз икән, монда сез гаепле түгел. Аллаһ сезнең яшермичә кылганнарыгызны да, яшергәннәрегезне дә белеп тора.

**30.** *(Ий, Мөхәммәд)* мөэмин ирләргә *(харамга)* күз атарга ярамаганны, *(җенси вәсвәсәгә, азгынлыкка бирелмичә)* намус пакьлеген сакларга кирәклеге турында сөйлә. Шулай эшләү аларның үзләре өчен әдәпле бер гамәл булыр. Шик юк ки, Аллаһ алар кылганнарның барысыннан да хәбәрдар.

**31.** Мөэминә хатын-кызларга да сөйлә: *(ярамаганнарга караудан)* тыйлык-

сыннар; намус һәм гыйффәтләрен сакласыннар. Күрсәтергә ярагannardan *(йөз белән куллардан)* башка зиннәтләрен күрсәтмәсеннәр.

*(«Зиннәт» дигән сүзнең эчендә күп мәгънәләр ята. Бизәнү әйберләре дә, сөрмә тарту, тырнакларга кына сөртү дә, муен да, күкрәкләр дә, бармаклардан югары беләкләр дә, итәкләрдән югары балтырлар да һәм, әлбәттә, хатын-кызның табигый гүзәллеге дә—зиннәт. Боларның барысы да ирләрнең дәртен, җенси теләген котырта. Шуңа күрә, хатын-кыз үзенең матурлыгын, зиннәтен ачмаска, ирләрне вәсвәсәгә салмаска тиеш».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.)

Баш яулыклары муеннарын, якаларын, күкрәкләрен каплап торсын. Зиннәт урыннарын үз ирләреннән, үз аталарыннан, үз ирләренең аталарыннан, үз угылларыннан, үз ирләренең *(башка хатыныннан туган)* угылларыннан, үз ир туганнарыннан, үз туганнарының угылларыннан, кыз кардәшләренең угылларыннан, үзенең *(хезмәтче)* асрауларыннан, үзләренең колларыннан, җенси ихтыяҗы булмаган ир хезмәтчеләрдән, хатыннарның яшерен җирләренә дикъкате булмаган балалардан башка кешеләргә хатын-кыз зиннәтле урыннарын күрсәтмәскә, ачмаска тиеш. Яшерелгән зиннәтләре беленсен, күренсен дип, *(ирләрнең игътибарын тартырдай итеп)* каты басмасыннар. Әй, мөэминнәр, барыгыз да Аллаһ алдында тәүбә итегез. Куркынычлардан котылып, морадыгызга *(җәннәткә)* ирешерсез.

**32.** Буйдакларны, колларыгыздан, җарияләрегездән булганнарны өйләндерегез, кияүгә бирегез. Фәкыйрь булганнарны Аллаһ үз нигъмәтләре илә баетыр, иншаэаллаһ. Нигъмәтләре мул булган һәм бар нәрсәне дә белеп торучы—Ул—Аллаһ.

**33.** Өйләнергә мөмкинлекләре булмаганнар исә Аллаһның нигъмәтен көтеп, *(җенси бозыклыклар кылмыйча)* сабыр итсен. Кул астындагы колларыгыз һәм җарияләрегез азатлык язуы сораса, бирегез; әгәр дә аларның итагатьле, намуслы икәненә ышансагыз. Аллаһ сезгә биргән нигъмәтләрдән аларга да өлеш чыгарыгыз. Дөнья рәхәтеннән колак какмыйм әле дип, намусын саклап калырга теләгән җарияләрегезне бозык эш кылырга ирексезләмәгез. Кем дә кем көчләнсә, *(хатын-кыз бу зинасы өчен)* Аллаһ тарафыннан ярлыканыр һәм Аллаһның мәрхәмәтенә ирешер.

**34.** Хактыр ки, Без сезләргә ап-ачык аңлаешлы аятьләребезне *(кисәтүләребезне)* иңдердек. Сездән элек яшәп киткән халыклардан гыйбрәтләр, үрнәкләр китердек, шулардан үгет алып, *(гөнаһ кылудан һәм Аллаһның җәзасыннан куркып)* саф мөселман булсыннар, дип.

**35.** Аллаһ—күкләрнең һәм Җирнең нурыдыр. Эчендә чыраг *(шәм)* яндырылган бер йорт кебек якты нурдыр Ул. Чыраг *(шәм)* исә бер кандил *(шәмдәл)*гә куелган. Ул шәмдәл алмаз кебек балкучы йолдыз кебек җемелди. Ул Кояш чыгышында да, Кояш батышында да тиңе булмаган мөбарәк бер агачтан, зәйтүннән *(алган май)* белән балкый. Аның *(яна торган)* мае үзенә ут төртмәсәләр дә, үзеннән-үзе нур чәчә. Бу яктылык нур өстенә нур булып яна. Аллаһ ихтыяр иткән бәндәсен шул нурга ирештерә. Инсаннар өчен Аллаһ *(гыйбрәтле)* кыйссалар китерә. Аллаһ һәрнәрсәнең асылын белеп тора.

**36.** Бу нурлы кандил байтак кына өйләрнең эчен яктырта. Шундый өйләрнең абруе артсын дип вә анда Үзенең исемен зикер итсеннәр өчен *(Аллаһ)* рөхсәт бирде. Ул өйләрдә иртә-кич Аңа тәсбих әйтәләр *(Аллаһка мәдех укыйлар)*. **(37)** Бар шундый кешеләр, аларны сәүдә һәм алыш-биреш эшләре дә Аллаһны зикер итүдән, *(вакытында)* намаз укудан, зәкят бирүдән аера алмый. Алар дәһшәтле Көн килеп, йөрәкләрне тетрәтә торган, күзләрне шакмакландыра торган Көннән куркалар. **(38)** *(Алар Аллаһның кисәтүләреннән читкә тайпылмыйча яши)* кылган игелекләренә күрә әҗер алыр өчен вә Аллаһ тарафыннан артыгы белән нигъмәт алыр өчен. Аллаһ ихтыяр иткән кешесенә чиксез нигъмәтләр бирер.

**39.** Кяферләр белән эш болайрак тора: аларның гамәлләре тап-такыр һәм чиксез чүлләгә мираж кебек, сусаган кеше су күрдем дип уйлый. Ниһаять, килеп җитәрәк алдавыч су юкка чыга. Ул урында *(юлчы)* бары тик Аллаһны табар. Ул аңа тулысы белән тиешлесен *(җәзасын)* бирер. Аллаһ бик тиз исәп-

хисап өзүчедер. **(40)** *(Кяферләрнең гамәле)* тирән-куркыныч давыллы караңгы дингездәге коточкыч дулкын кебидер, ул дулкын өстенә тагын икенчесе менә, шулар өстендә кара болытлар куера, тагын кара дулкыннар берсе өстенә берсе өелә. Шул мохиткә баткан берәр кеше кулларын сузса *(ярдәм сораса, тавышы да ишетелмәс, хәтта ул)* үз кулларын үзе дә күрмәс. Аллаһ нур бирмәсә, кешенең нуры булмас.

**41.** Күкләрдә һәм Җирдә яшәгәннәр белән очар кошларның, канат кага-кага Аллаһны мактап сайраганнарын ишетмисеңмени, күрмисеңмени? Һәрберсе үз догасын һәм тәсбихен яхшы өйрәнгән. Аллаһ аларның ни кылганнарын белеп тора. **(42)** Күкләрнең һәм Җирнең хуҗасы—Аллаһтыр. *(Кыямәт көнендә)* кайтарылыш та Аңа гына булачак. **(43)** Син шул хакыйкатьне дә күрмисеңмени, Аллаһ болытларны *(теләгән җиренә)* куа, соңыннан аларны куша, бер-берсе белән катнаштырып, *(зур кара)* болытка әверелдерә. Шуннан яңгыр ява башлый, күрәсеңме. Ул Күктән эче тулы боз булган тау кадәр болытлар индерә. Һәм кемне хәвефле итәргә теләсә, шуның өстенә яудыра. Ихтыяр итсә, ул теләгән кешесен бәладән коткара. Аның яшен чаткысы сукырайтыр дәрәҗәдә күзләрне камаштыра.

**44.** Аллаһ төн белән көнне алмаштырып тора. Күрер күзле булганнар өчен, монда, шөбһәсез, гыйбрәтләр бар. **(45)** Аллаһ һәр җанлыны судан *(шәһвәт тамчысыннан)* яралтты. Аларның бәгъзеләре корсагы өстендә шуышып йөри, кайберләре исә ике аякта хәрәкәт итә, кайсылары дүрт аякта тора. Аллаһ ни теләсә, шуны яралтыр. Аллаһның бар нәрсәгә кодрәте җитә. **(46)** Хактыр ки, Без ачык аятьләр индердек. Аллаһ ихтыяр итсә, теләсә кемне тугры юлга бастыра ала. **(47)** *(Монафикълар)*:

—Аллаһка да, аның Пәйгамбәрләренә дә иман китердек, итагать иттек, диләр. Соңыннан аларның байтагы йөз чөерә. Болар мөселман түгел. *(Чөнки алар телләре белән сөйләгәннең киресен эшли.)* **(48)** *(Араларындагы гауганы)* хөкем итәр өчен Аллаһка яки Пәйгамбәр янына чакырылсалар, бер төркеме аркасына борылып, качып китәчәк *(менә күреп торырсың)*. **(49)** Әгәр дә алар хаклы икән, итагать итеп, йөгерә-йөгерә килгән булырлар иде. **(50)** Эчләрендә бер-бер чир бармы соң, әллә аның хак Пәйгамбәр икәнлегенә шикләнәләрме? Яки Аллаһ һәм илчесе аларны хаксызга рәнҗетер, дип куркалармы алар? Юкса, алар үзләре залим.

**51.** Мөэминнәр исә үзара бәхәсләрне хөкем итәргә Аллаһ яки аның илчесе янына чакырылса:

—Тыңладык, итагать иттек,—диләр. Менә шулар морадларына ирешкән булыр. **(52)** Кем Аллаһка, аның илчесенә итагать итә, Аллаһны сөя һәм Аның каршысында *(гөнаһ кылудан)* курка, менә шулар инде Сәгадәткә ирешер.

**53.** Әгәр дә син әмер бирсәң, *(шундук сугышка китәчәкләре турында)* иң олы ант белән ант итәрләр. Әйт:

—Файдасызга *(олы исем белән)* ант итмәгез,—диген.—Бары тик телегез белән генә итагать итәсез бит. Шик юк ки, Аллаһ сезнең ни кылганыгызны *(уйлаганыгызны)* белеп тора.

**54.** Әйт:

—Аллаһка итагать итегез, Пәйгамбәргә итагать итегез,—диген. Әгәр тагын йөз чөереп китсәләр, илченең вазифасы бары тик Аллаһның хөкемнәрен аларга ирештерү генә, аларның бурычы исә илче әйткәннәргә иярү. Шулай гамәл кылсагыз, тугры юлны табачаксыз. Пәйгамбәргә *(Аллаһның әмерләрен)* ирештерүдән башка вазифа йөкләтелмәгән.

**55.** Әүвәл яшәгән *(мөслимнәрне)* ничек итеп җиргә варис һәм хаким иткән шикелле, Аллаһ иман китереп, игелек кылганнарны, һичшиксез, шул җиргә варис һәм хаким итәргә, аларга үзләре ошаткан динне *(Исламны)* тәгаенләп, сакларга, аларның куркыныч мохитен иминлеккә алмаштырырга вәгъдә итте. Бәлки, алар Миңа инаныр, гыйбадәт кылыр. Миңа бернинди дә тиң тотмаслар, дип. Кем дә кем моннан соң да кәферлек кылса, шул кеше нәҗеслекнең үзе булыр.

**56.** Шуңа күрә, намаз укыгыз, зәкят бирегез, Пәйгамбәргә иярегез: һәм сез Аллаһның рәхмәте илә кавышырсыз.

**57.** Инкарь итүчеләр аны *(Аллаһның Жир йөзендәге гамәлләрен)* бичара хәлдә калдырачаклар, дип башыгызга да китермәгез. Аларның барачак урыннары—жәһәннәм. Аһ-һай, хәтәр урындыр ул.

**58.** Әй, иман китергән кешеләр! Һәм арагыздагы балигълыкка ирешмәгәннәр! Әмерегездәге *(колиһәләр, жарияләр)* менә шушы өч вакытта: иртәнге намаздан алда, өйлә эссесендә чишенгәч, ястү намазыннан соң, ихтыяж булганда *(сезнең ятагыгызга керергә)* рөхсәт сорарга тиеш. Бу өч вакыт сезнең өчен *(хатыннарыгыз белән аулакта ялангач килеш)* күрешү форсаты. Моннан соң да бер-берегезне теләсәгез, хатынга да, иргә дә гаеп саналмас. Бер-берегезнең янына кереп чыга аласыз. Аллаһ аятьләрен сезгә шулай ачыклый. Аллаһ бар нәрсәнең асылын белеп тора, Ул—хөкем вә хикмәт иясе.

**59.** Сезнең балаларыгыз балигълыкка ирешкәч, бая телгә алынганнар керергә рөхсәт сораган кебек, алар да рөхсәт сорасын. Аллаһ аятьләрен сезгә шулай ачыклап бирә. Аллаһ бар нәрсәнең дә дөресен белеп тора. Ул—галим һәм хакимдер.

**60.** Кияүгә чыгарга өмете киселгән, бала табудан мәхрүм калган олы яшьтәге хатыннар, зиннәтләрен күрсәтмичә генә, кайбер өске киемнәрен салсалар да гаеп саналмас. Әдәплерәк булсалар, үзләре өчен тагын да яхшырак булыр. Аллаһ ишетеп, күреп тора.

**61.** Сукырга да, аксакка да, авыру кешегә *(көчләре җитмәгән эшләрне эшли алмасалар)* җаваплылык юк. Вә дәхи үзегезгә дә үз өегездә, атагыз йортында яки анагыз өендә, ир туганнарыгыз өендә, кыз туганнарыгыз каралтысында, ата ягыннан булган агаларыгыз табынында, ата ягыннан булган туталарыгыз ризыгын, ана ягыннан булган абзыйларыгыз дәстарханында, ана ягыннан булган түтиләрегез өендә яки ачкычы сезгә ышанып тапшырылган өйдә, дустыгызның өендә ашау гаеп саналмас. Бөтенегез бергә яки аерым ашауда да гөнаһ юк. Өйгә кергәндә Аллаһ тарафыннан килгән мөбарәк сүз белән яхшы яшәү, иминлек теләп сәлам бирегез. Менә, уйлый-уйлый аңласыннар дип, Аллаһ сезгә аятьләрен шулай ачып сала.

***(«Гарәпләр элек сукыр, гарип кешеләр белән бер табын янында ашамаган. Аятьнең икенче яртысы исә, чакырылмаган килеш тә якын кардәшләр өенә кунакка килергә рөхсәт итә.»***

Мөхәммәд Али тәфсиреннән.)

**62.** Бары тик Аллаһка һәм аның Рәсүленә инанганнар гына мөэмин була ала. Алар Пәйгамбәр илә уртак эш башкарганда, аннан рөхсәт сорамыйча, эш ташлап китмиләр. *(Ий, Мөхәммәд)* әнә шул рөхсәт сораганнар, хакыйкатән, Аллаһка вә аның Рәсүленә инанганнар булыр. Шулай булгач, алар кайбер эшләрне эшләргә теләсә, син аларга рөхсәтең бир. Алар өчен Аллаһтан ярлыкау телә. Гафу итүче, тугры юлга бастыручы миһербанлы Аллаһтыр.

**63.** Бер-берегезне чакырган кебек, Пәйгамбәрне дә шулай чакырмагыз *(исеме белән дәшмәгез, итагать һәм йомшак тавыш белән: йа, Нәбиулла, йа, Рәсүлулла, дип эндәшегез)*. Арагыздан бәгъзеләрегез юкны сылтау итеп, мыштым гына *(рөхсәтсез)* качып киткәннәрне Аллаһ белә. Аң булыгыз, Аның әмереннән качып китеп (бу дөньяда) үзегезгә фетнә-бәла чакыра күрмәгез яки *(Ахирәттә)* андыйларга бик хәтәр җәза китереп сугуы бар.

**64.** Аң булыгыз: күкләрдәгеләр дә, Җирдәгеләр дә, хакыйкатән, Аллаһ Тәгаләнекедер *(Аллаһ яралткан милек, Аллаһның коллары)*. Ул сезнең кем (мөэминме, монафикъмы) икәнегезне белеп тора. Үз хозурына кайчан кайтарылачагыгызны да төгәл белүче—Аллаһтыр. Ул көнне аларга ни кылганнары турында хәбәр бирәчәк. Аллаһ бөтен нәрсәнең асылын белүче.

# БЕРЕНЧЕЛӘР

КОМПОЗИТОР МАНСУР МОЗАФФАРОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Кайбер кешеләрнең киләчәктә нинди даирәдә хезмәт итәчәге, әйтерсең лә, язмыш тактасына алдан ук язылып куелган була. Мансур Мозаффаров 1902 елда Казанда туа. Әтисе вафатыннан соң малай әнисе, танылган шагыйрә, кызлар мәктәбендә укытучы Маһруй Мозаффарова тәрбиясендә үсә, бик кечкенәдән үк китап кибетендә йомышчы малай булып эшли башлый. Композиторның истәлекләренә караганда, Казанда Габдулла Тукайны, Салих Сәйдәшевне очратулары аның бала чагының ак шатлыклы хатирәләре булып күңеленә сеңеп калган. Ун-унбер яшьлек Мансур «Болгар» кунакханәсендә яшәгән Тукайга гәзитләр китерә, бөек шагыйрьнең: «Малай, мин бит бүген фәрештәләр белән сөйләштем,—дигән тылсымлы сүзләре, әйтерсең, аның кайчан да булса сәнгатькә хезмәт итәсен алдан белеп әйтелгәләр... Кем белә, бәлки бу "Туган тел" яки «Тәфтиләү», «Зиләйлүк»нең дөньяга килгән чагы булгандыр?

Башлангыч белемне ул мәдрәсәдә ала. 1916 елда учительская школага керә. Әле Октябрь инкыйлабына кадәр үк, татар халкының профессиональ музыка сәнгате яңа оешып, үсеп китә барган бер заманда яшь музыкант «Сәйяр» труппасына килә, ягъни труппа каршындагы ансамбльдә эшли башлый. Әмма ярым һәвәскәр, ярым профессиональ булып йөрү яшь музыкантны канәгатьләндерми. 1919 елда ук Казан музыка училищесенең кларнет классында укый башлый. 1923 елда исә М. Мозаффаров Мәскәү консерваториясенә укырга китә. Тик авыруы сәбәпле, ул консерваториянең композиторлык факультетына караган этнография бүлеген 1931 елда гына тәмамлый.

Шулай ук язмыш эшедер инде, яшь композитор иҗат эшчәнлеген халык җырларын эшкәртүдән башлый. Мисалга М. Мозаффаров эшкәртүендә популярлашып, халыкның гаять зур мәхәббәтен казанган «Сибелә чәчәк», «Галиябану», «Зиләйлүк» һ. б. көйләрне алу да җитә. Халык җырларын композитор фортепианога кушылып җырлау өчен дә, аккомпанемент белән хор яисә хор өчен генә, шулай ук кыллы квартет белән башкару өчен дә эшкәртә. Мәсәлән, ике скрипка, альт һәм виолончельдән торган кыллы квартет өчен татар халык җырлары темаларына ун пьесадан торган цикл төзи.

Музыка белгече К. Тажиева билгеләп үткәнчә, «профессиональ композиторларыбызның беренче буыны өлешенә гаять җаваплы бурыч—татар профессиональ сәнгатенең нигез ташларын салу бурычы төште. Алар халыкның музыка традицияләрен җирлек итеп алып, музыка сәнгатен бик кыска тарихи вакыт эчендә монарчы күрелмәгән биеклекләргә күтәрергә, халык җыручылыгының милли стихиясен классик музыка сәнгате жанрлары һәм формалары белән синтезлаштырырга, идея-эчтәлеге һәм сәнгатьчә кыйммәте, халыкчанлыгы ягыннан киләчәк буын музыкантлары өчен таяныч һәм эталон булырлык әсәрләр язарга, формасы, стиле һәм музыкаль теле белән яңа заманга аһәңдәш, яшь сәнгать алдына куелган максатларга лаек рухи хәзинәләр тудырырга тиеш булдылар». Мансур Мозаффаров бу олуг бурычны лаеклы үтәп чыкты.

Кече жанрдагы вокаль музыка төре булып саналган романска Мансур Мозаффаров әле утызынчы елларда ук мөрәҗәгать итә. Мәскәү консерваториясендә укыган чорында А. С. Пушкин шигырьләренә язылган иң яхшы җырга конкурс игълан ителә. Яшь татар композиторлары да бу конкурста яңа әсәрләре белән катнашалар. М. Мозаффаровның «Җырлама син, иркәм» романсы арада иң уңышлылардан берсе

дип таныла. Музыка белгечләре бәяләвенчә, бу әсәр Пушкин мирасына тирән үтеп керүе һәм аны милли музыка стилендә гәүдәләндерүе белән аерылып тора, эмоциональ эзлеклелеге, тонда бөтенлеге, көйнең табигый агышы, интонацияләрнең нечкәлеге белән сокландыра. М. Мозаффаровның әлеге романсын кайбер музыка белгечләренең Балакирев, Римский-Корсаков кебек рус композиторларының Пушкин шигърияте белән рухланып язган әсәрләре янәшәсенә куеп бәяләве бик күп нәрсә турында сөйли булса кирәк. Шунсы да әһәмиятле, М. Мозаффаров Пушкин шигырьләренә романслар язуын кырыгынчы елларның ахырында да дәвам иттерә. Бу чорда классик поэзия әсәрләренә мөрәҗәгать итү профессиональ музыкабызның сурәтләү чараларын баету, речитатив стильнең мөмкинлекләрен киңәйтү ягыннан да әһәмиятле булды.

М. Мозаффаровның әле утызынчы елларда ук иҗат ителгән җырларының байтагы бүгенгә көндә дә яшь бирәләр. «Җиләк җыйганда» (М. Җәлил шигыре), «Сайра, сандугач» (М. Садри шигыре), «Яшь егетләр, яшь кызлар» (Ә. Ерикәй шигыре) җырлары интонация төзелешендәге яңалык, якты һәм дәртле аһәңнәре белән халыкның рухына хуш килделәр. Композиторның илленче-алтмышынчы елларда иҗат иткән вокаль әсәрләре исә татар музыка үсешендә үзенә бер сәхифә тәшкил итә. Бу чорда ул утыздан артык җыр яза, аларның иң яхшылары оркестр белән башкару өчен эшкәртелгән. Әлеге җырларда композиторга хас иҗат стиленең иң яхшы сыйфатлары бергә җыелган: тирән эчтәлек тә, ачык аңлаешлы аһәң дә, кеше күңеленә тирән үтеп керә торган ихласлык һәм инсафлык та бар аларда. Композиторның җыр өлкәсендә озак еллар туктаусыз эшләве гүзәл нәтиҗәләргә китерә: җыр иҗатында үзенә аерым яңа бер төр—уйланулар дип атарга мөмкин булган жанр туа. Әйе, татар музыкасында яңа вокаль стиль барлыкка килү дигән сүз иде бу. Яңалык композиторның җыр текстларын сайлавында да ачык күренде: ул югары гражданлык рухы бөркелеп торган, туган ил, аның гүзәл табигате, яшәешнең мәгънәсе хакында тирән уйлануларга корылган шигырьләргә мөрәҗәгать итә. С. Хәкимнең «Кайда да йөрәктә», «Башка берни дә кирәкми», М. Мазуновның «Туган як», Г. Зәйнашеваның «Мин тормышка гашыйк», «Менәргә иде Урал тауларына» әсәрләренә язылган җырлар әнә шундыйлардан. Аларга тирән гражданлык хисе, лирик-философик янарыш, киң һәм салмак хикәяләү интонациясе, акыртын темп, кырыс, сабыр һәм тыенкы хисләр хас.

М. Мозаффаров татар музыка сәнгатенең яңа төре—опера сәнгате өлкәсендә дә сизелерлек эз калдырган композитор. Аның бу әсәре М. Фәйзинең татар тормышында тирән үтеп кергән сәхнә әсәренә нигезләнә. Ул—татар театрына музыкаль драмалар жанрын алып килгән әсәр. Шундый пьеса материалы нигезендә опера иҗат итү гаять четерекле һәм җаваплы бурыч булып тора.



*Сулдан уңга (алгы рәттә): З. Нури, М. Саттаров, З. Хәбибуллин, С. Сабиров, З. Хәйруллина, Г. Ахунов. Арткы рәттә: Е. Соколова, Ә. Ерикәй, М. Рахманкулова, М. Мозаффаров, Ф. Хөсни.*

Опера сәнгатендә беренче адымнарын гына атлаучы башка халыкларда да опера жанрын үзләштерү сүзле музыкаль әсәрләр аша барганлыгы мәгълүм. «Галиябану» операсын иҗат итү дә татар театрындагы шул катлаулы күчеш процессының бер мисалы иде.

1943 елда М. Мозаффаров үзенең икенче операсын—«Зөлхәбирә»не тәмамлый. Бу әсәрен дә ул халык моңнары чыганакларына таянып иҗат итә. Әмма «Галиябану»да халык көйләре әсәрнең тукымасына кертелеп, турыдан-туры файдаланылган булса, икенче операда принципиаль яңалык кулланыла. Монда бер генә халык көе дә юк диярлек, әмма шул ук вакытта ул—чын милли формага корылган әсәр, сурәтләүнең классик чаралары монда халык моңнары рухы белән сугарылган. Операның драматургиясендә симфонияләштерү методларына зур урын бирелә.

М. Мозаффаров симфоник музыка өлкәсендәге беренче тәҗрибәләрен утызынчы елларда ук ясый. Аның бу тәҗрибәсе дә халык җырларын тирәнтен өйрәнүдән башлана. Аерым көйләрне, мотив һәм борылышларны әсәрдә турыдан-туры файдалану этабы аша үтеп, интонация закончалыклары, эчке табигате белән халык көйләренә аваздаш, әмма тулысынча оригиналь булган темалар тудыра. Илленче елларда композитор халкыбызның сөекле уллары Габдулла Тукай һәм Мулланур Вахитов истәлегенә багышланган симфоник поэмаларын яза. Һәр ике поэманың да эчке драматургиясе гаҗәеп киеренке, һәр икесе дә мелодик материалга бай. Автор халык көйләре интонациясеннән кыю файдалана. Мәсәлән, Г. Тукайга багышланган поэмада без шагыйрьнең яраткан җырларыннан берсе «Әнкәм кабере янында» дигән җырның көе мотивларын ачык ишетәбез.

Болардан тыш М. Мозаффаров илленче-алтмышынчы елларда «Туган ягым» исемле симфоник поэма, симфониэтта, скрипка һәм оркестр өчен ике концерт иҗат итә. Шулай итеп, инструменталь музыка иҗатын даими төстә җыр белән бергә бәйләп алып баруы, классик сәнгать тәҗрибәсен милли музыка белән органик рәвештә куша белүе композиторны югары иҗади казанышларга алып килә. Аның исеме татар профессиональ музыкасы тарихында тирән эз калдырган С. Сәйдәшев, С. Габәши, Н. Җиһанов, Җ. Фәйзи, А. Ключеров, З. Хәбибуллин, һ. б. композиторлар белән бергә телгә алына.

Композиторның татар музыкасына керткән өлеше югары бәяләнде. Ул—Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык артисты.

Татар музыкасының классигы Мансур Әхмәт улы Мозаффаров 1966 елда вафат була.

**Наис ГАМБӘР**

## «Казан утлары» елъязмасы

(март)




65 ел элек (1937) «Совет әдәбияты» журналында (2-5 саннарында) **Гомәр Бәшировның «Сиваш»** повесте,

60 ел элек (1942 ел) «Совет әдәбияты» журналында (3 сан) **Фатих Хөсниненң «Йөзек кашы»** повесте,

55 ел элек (1947 ел) «Совет әдәбияты» журналында (2-3 саннарында) **Габдрахман Әпсәләмовның «Ак төннәр»** повесте дөнья күрде.

*Әдәбият тарихына*

# ХАЛЫК ИҖАТЫННАН КӨЧ АЛЫП...

Зур тормыш тәҗрибәсе туплаган һәм әдәби осталыкның иң югары үрләрен яулаган могтәбәр әдипләр берәм-берәм безнең белән хушлашалар... Әмма алар ирешкән иҗади осталык серләре онытылмаска тиеш, чөнки ул хәзинә хәзерге буын әдипләр өчен менә дигән остаханә, мәктәп булып тора!

Әнә шундый уйлар безне халкыбызның олуг әдибе Гомәр Бәширов иҗади дөньясына күп мәртәбәләр алып килер әле. Ә бу юлы без язучының халык авыз иҗаты әсәрләренә булган мәхәббәтен, алардан ничек итеп үзенә илһам һәм көч алуын ачыкларга тырышыйк.

Әдәби җәмәгатьчелек алдында ясаган чыгышларында да, матбугат битләрендә дөнья күргән мәкаләләрендә дә Гомәр Бәширов халык иҗаты турында бик еш сүз кузгатты, аның иң җитди уйлары әлеге чыганакка гел-гел әйләнеп кайтты. Мисал өчен, «Татарстан яшьләре» газетасында 1987 елның 21 гыйнварында басылган бер язмасында ул: «...галимнәр телне фәнни яктан өйрәнәләр, ә миңа тел халыкның тормышын бирү ягыннан әһәмиятле»,— дип язды. Әнә шуңа басым ясавы белән өлкән әдип телнең кайберәүләр уйлаганча һич тә үзмаксат түгел, ә яшәешне, чынбарлыкны чагылдыруның көчле бер чарасы, ысулы булуын ассызыклады. Ә инде соңрак дөнья күргән икенче бер мәкаләсендә Гомәр Бәширов үзенең фикерен тагын да ачыклый, тирәнәйтә төшә: «Яшь буын, киләчәк буын балачактан ук үз халкының кем икәнен белеп үссен иде. Укытучы-остазлар шәкертләрендә әлеге сыйфатларны халкыбызның борын-борыннан килгән гореф-гадәтләре аша тәрбияләсеннәр иде» *(«Шәһри Казан», 1996 ел, 1 гыйнвар саны).*

Үзенең әдәби иҗатында да Г. Бәширов халык авыз иҗатына, фольклор жанрларына һәм мотивларына еш мөрәҗәгать итә. Бу яктан шагыйрь Роберт Миңнуллин тарафыннан «...татар халкының этнографиясен, фольклорын, йолаларын бергә туплаган энциклопедик повесть» дип *(«Казан утлары». 1981 ел, № 1.)* бәяләнгән «Туган ягым—яшел бишек» повесте аеруча игътибарга лаек.

Биредә әдип халык яшәешенең һәм рухының әхлакый чыганакларын ачыклый, революциягә кадәрге татар авылының тормыш-көнкүрешен, аның борынгыдан килә торган гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен, йолаларын киң яктырта. Аерым алганда, татарның бәйрәме Сабан туен, аңа әзерлекне, аның барышын тасвирлау юлы белән автор халкыбызның рухи матурлыгын, күңел җорлыгын, тапкырлыгын, әдәп-әхлагын ача. Әсәрдә аксакал карт Сабан туеның мәгънәсен һәм кадерен бер җөмләгә сыйдырып менә нәрсә ди: «Сабан туена кагылу—ул халыкның җан җирен авырттыру дигән сүз». Чыннан да, Сабан туе—татар халкының көтеп алына торган милли бәйрәме. Әлеге бәйрәм күренешләрен, аның күнелле борчуларын сурәтләүгә Г. Бәширов «Туган ягым—яшел бишек» повестенда тулы бер бүлекне багышлый, укучы күз алдына бәйрәмнең җанлы картинасын тудыра. Хәзерге буын өчен шунысы кызыклы: Элек авылда Сабан туена әзерлек эшләре көннәр язга авышу белән үк башланган, һәр кеше бүләкләр, көчтәнәчләр әзерләгән, планнар корган, көрәш, ярышка әзерләнгән. Иртә таннан торып, бүләк һәм көчтәнәчләр җыю, «уникешәр бала итәкле зәңгәр, яшел, алсу күлмәк кигән купшы кызлар», «кәләпүшләрен кыңгыр салган мут егетләр», бәйрәмчә

киенгән карт һәм карчыклар, гармун тавышы, җыр-музыка—әсәрдә һәр детальне белеп, бәйрәмнең күнелле ыгы-зыгысын шул рәвешле бөртекләп тасвир итү, авыл дөньясын җанлы, образлы күз алдына китерә. Бу хәл бер үк вакытта авторның тормышны, гореф-гадәтләрне яхшы белүен, сәнгатьнең төрле алымнарыннан, фольклордан уңышлы файдалана алуын ассызыклый, иҗат үзенчәлекләрен ача.

Г. Бәшировның икенче бер күләмле әсәре «Җидегән чишмә» романында исә Сабан туена фәнтехника заманының карашы чагылдырыла. Бирелә инде, теге әсәрдә күренгән бизәлгән атларга, чуклычаклы киемнәргә, тальян гармунга, милли гореф-гадәтләргә урын юк дәрәҗәсендә. Төп игътибар хәзерге «техника парадын» сурәтләүгә юнәлтелгән. Бәйрәмне бу рәвешле тасвирлау фәнтехника казанышларына мөкиббән киткән колхоз рәисе Чурмантаев образын тулырак ачу өчен кирәк. Уңышлар, казанышлар артыннан гына куучы бу җитәкчегә табигать, чишмәләр, изгелекләр һәм милли яшәеш ят бер нәрсәгә әверелгән. Ул милли яшәештән, рухтан аерылган. Бу хәл авторны татар дөньясының киләчәге турында борчулы уйларга этәрә.

Ә инде кабат «Туган ягым—яшел бишек»кә әйләнеп кайтсак, аның «Кунак кызлар килде утырмага» исемле бүлегендә әдип татар халкының тагын бер йоласына—каз өмәсен тасвирлауга зур игътибар биреп безне тагын бер мәртәбә ныклык, яшәү чыганагы белән тоташтырып, ялгап ала.

Казлар, элек-электән татар халкы өчен муллык, байлык билгесе булып исәпләнгән. Кыз алу, туй мәҗлесләре дә казсыз узмаган. Киленгә пар каз бирү, каз мамыгыннан яшьләр өчен ястык-түшәк әзерләү мәҗбүри исәпләнгән. Шунлыктан көз көне яше-карты каз өмәләрен күтәп алган, аңа бәйрәмгә әзерләнгән кебек әзерләнгән. Яшьләр өчен әлеге йола сынау булып та әверелгән: өмә вакытында аларның осталыгы, җитезлеге, чисталыгы һәм башка сыйфатлары сыналган. Менә шуларны тасвирлап автор әлеге бәйрәмнәрнең тәрбияви әһәмияте зур булганлыгын ача. Бер үк вакытта мондый йолаларны сурәтләгәндә автор ата-бабаларыбызның бер-берсенә дустанә мөнәсәбәтен,

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ

## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Әхмәт Галиев,**

*техник фәннәр докторы*

## МИЛЛӘТЕБЕЗ ГОРУРЛЫГЫ



*Мин «Казан утлары»н узган гасырның алтмышынчы елларыннан башлап бер санын да калдырмыйча даими рәвештә укып барам. Журнал битләрендә дөнья күргән хикәяләр, бәяннәр, романнар, поэмалар һәм шигырьләр авторларына, милләтебезнең язмышын, тарихын, көнкүрешен тасвирлап баручы, аңа җан бирүче, аның учак утын саклап килүче язучыларга, редакция хезмәткәрләренә ихтирамым беркайчан да кимемәде.*

*Минем үземә татар мәктәбендә уку бәхете фәкать өч класс кына тәтеде. «Казан утлары»н эзлекле рәвештә укып баруым аркасында туган телемнән аерылмадым, аның тәмен югалтмадым дип саныйм. Әле исән вакытларында ук классикка әйләнгән Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур, Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах кебек язучыларның әсәрләрен әле китап булып чыкканчы ук укып бару үзе бер бәхет иде.*

*Соңгы елларда язучыларыбызның һәм шагыйрьләребезнең матди*

эчкерсезлеген, эшчәнлеген, жорлыгын һәм шаянлыгын да калку итеп гәүдәләндерә. Бу хәл бигрәк тә кунак кызга мөнәсәбәттә ачыла. Халкыбызда кунак кызы килүнең дә үз вакыты, тәртибе булган икән. Алар, гадәттә, көзге эш вакытында, мисал өчен, каз өмәләре башлангач килгәннәр. Кунак кызлары килү авыл яшьләре тормышына да үзенчә бер жылылык өргән, аны жанландырып жибәргән.

Бәйрәмчә киенеп, көянтә башларына икешәр каз элеп чишмәгә төшү, егетләр белән сүз көрәштерү, жыр әйтешү, өлкән яшьтәге жиңгиләргә, карт-карчыкларга су ташу, кичен каз итеннән бергәләп бәлеш ашау, аулак өй кебек күркәм гореф-гадәтләрне сурәтләү аша автор халкыбызның рухи байлыгын, шигъри күңеллелеген дә ача. Биредә, безнен өчен тагын бер мөһим нәрсә бар. Күп кенә халык авыз ижаты әсәрләре, бигрәк тә лирик жырлар, шаян такмаклар нәкъ әнә шундый бәйрәмнәр вакытында ижат ителгән. Нәкъ менә шушы хакыйкатьне күздә тотып Тукай да: «Халык зур ул, бөек ул, көчле ул, шагыйрь ул, әдип ул» дип язган. Әйе, әдәп-әхлакка, хезмәткә өйрәнү, егет яки кыз сайлау, танышу һәм аңлашу, иң әһәмиятлесе—дуслык һәм бердәмлек халкыбызга менә шундый өмәләрдән һәм бәйрәмнәрдән килгән.

Үзенең образлы фикерләвендә Г. Бәширов мәкаль-әйтемнәргә дә еш мөрәжәгать итә. Ул аларның күп мәгънәлелеген, укучыга тәэсир итү көчен яхшы аңлый. Мәкаль һәм әйтемнәрдә халыкның тирән акылы гына чагылып калмый, образлы сөйләм теле дә ачыла бит. Автор тарафыннан киң кулланылган әлеге рухи ачкыч образларны ачуда да уңышлы файдаланыла. Мәсәлән, «Намус» романында Мәүлиха түти Нәфисә турында: «Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар, кеше булмаган кешедә кешенең ни эше бар!» дип, аның төп сыйфатын төгәл итеп бер жөмләдә ачып бирә. Килене Нәфисә турында төрле гайбәт сүзләр йөри башлагач, каенанасы аңа шикләнеп карый һәм «Кеше күңеле—караңгы төн икән шул» дигән халык әйтемен искә төшерә. Әсәрнең башка образларын (мисалга, Хәсби, Зиннәт һ. б.) тудырганда да автор мәкаль һәм әйтемнәрне еш куллана.

*яктан читенлекләрдә яшәүләренә күңелем әрни. Татарстаныбызда ижат шәхесләренә игътибар житмәгәнгә, аларның ижатларына карата битарафлыкны бетерү юллары табылмау белән һич тә килешәсе килми.*

*«Казан утлары»ның барлык хезмәтләре үз укучысында милли горурлык тәрбияләүгә юнәлдерелгән. Бу журнал татар теленең байлыгына, аның матурлыгына, киң күләмдә аңлаша ала торган тел булганына сокланып яшәргә булышты миңа.*

*Югары уку йортларында татар телендә белем алу киләчәктә табигый күренеш булачагына ышанычым артты.*

*Журналның «Баш мөхәррир сүзе» рубрикасындагы мәкаләләрне аеруча нык игътибар белән күзәтеп барам. «Гасыр йомгагын төенләгәндә» (№1, 1999), «Китап гасыры китәме?» (№1, 2000) исемле мәкаләләр һаман истә. Быелның беренче санында басылган «Яңа елда яңарган уйлар» дигәне дә нык тәэсир итте миңа. Татар милләтенең язмышына битараф булмаган бер генә шәхес тә бу мәкаләдә чагылган мәсьәләләргә һәм сорауларга үзенчә җавап эзләмичә кала алмас кебек.*

*«Казан утлары» инде менә ничәмә еллар латин язмасы үрнәген биреп бара. Укучыларны латин графикасына мөмкин кадәр тизрәк күнектерү максатында эшләнгән бу эш мактауга һәм хуплауга лаек.*

*Бу юнәлештә «Казан утлары» киләчәктә дә эзлекле эш алып барыр дип ышанасы килә.*

*Рус теле халыкара аңлашу теле булса, татар теле милләтебезнең үзен, Татарстанның дәүләтчелеген саклап калу өчен кирәк. Дәүләте булмаган милләт, иртәме-соңмы, барыбер үзенең телен югалтуга дучар ителә. Миңа газиз анам теле малай һәм яшьлек чорларында «ты татарин гололобый, не ходи нашей дорогой» дигән вакытларда кирәкле җавап бирергә ярдәм итте. Күп гасырлар буена яшәгән татар халкының мәдәниятен, әхлакый рухын*

«Җидегән чишмә» романының тискәре персонажы Ризван Чурмантаев образын ачуда да мәкальләр булыша. Аңа карата халык: «Синең бит, кискән дә кырыккан», «Утырган ботагына балта чаба», «Буш башакның башы югары» кебек мәкальләрне куллана. Биредә әйтергә теләгән фикер ачык һәм төгәл. Ризван Чурмантаев үзе дә мәкаль һәм әйтемнәр белән сөйләшергә ярата. Мондый очракларда афористик жанр ике төрле эш башкара: бердән, Чурмантаев рухи яктан үзе дә ачыла, икенчедән, теге яки бу вакыйгага, геройга аның тарафыннан бәя бирелә. Мисал өчен, Минһаҗ картка булган тискәре мөнәсәбәтен ул түбәндәгечә ача: «Ул картның туны тузган, заманы узган инде». Яисә, икенче бер очракта, чишмәләрне саклау турындагы сөйләшүне өзеп, ул менә нәрсә ди: «Чүбек чәйнәп, май чыкмый».

Үзенең табигатькә булган саксыз мөнәсәбәтен аклап Чурмантаев: «Урман кискәндә йомычка чәчрәми булмый» мәкален искә төшерә. Шушы ук мәкаль «Туган ягым—яшел бишек» повестенда революцион вакыйгаларны сурәтләү барышында да кулланыла. Ягъни, инкыйлабның корбансыз гына була алмауы. Әлеге повестьта геройларның эчке кичерешләрен, яшәешкә карашларын ачыклаган мәкаль-әйтемнәр дә очрый. Мисалга, сөйгән кызының башка кешегә кияүгә бирелүен бик авыр кичергән Әхәтне автор: «Аңа хәзер ике чабата—бер кием, ике дөнья—бер тиен» дип характерлый.

Мәкаль һәм әйтемнәрнең кайберләре бердәмлеккә, күмәклеккә омтылу идеясен ача. Күмәк көчнең өстенлеген күрсәтергә алынганда автор: «Ил төкерсә, күл була», «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», «Бары бергә—югы уртак» кебек мәкальләргә мөрәҗәгать итә.

Рифмага салынган афористик җөмләләрдә дә халыкның шигъри җанлы булуы күренә.

«Аксак күп йөрер, сукыр күп күрер», «Борынгыга колак сал, зиһененә кертеп кал», «Бүген бертуган, иртәгә әче суган, берсекөнгә эттән туган» һ. б.

Әнә шулай итеп, образларны, вакыйгаларны җанлы, аңлаешлы итеп күз алдына бастыруда язучыга афористик жанрлар ярдәмгә килә, үткәрергә саклап килүче язучыларыбыз «Казан утлары» ярдәмендә алдагы елларда да үзләренең зыялы хезмәтләрен дәвам итәрләренә ышанам мин.

*«Казан утлары» шәхсән үз тормышымны да иҗади матур вакыйгалар белән урады. Хәләл җефетем Гөлчәчәгемнең шактый күләмле «Тулгак» повесте, эссе һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре шушы журналда басылу аркасында, аны китап итеп чыгару да авыр булмады. Журналда вакытта ук бик күп укучысын үзенә җәлеп иткән «Тулгак», китап булып та чыккач, очрашуларга чакырулар тагы да күбәйде. Арча, Балтач, Сәба районнары, Казандагы төрле китапханәләр, музейлар, мәктәпләр, педуниверситет һәм университет студентлары чакырулары буенча узган очрашулар, менә инде ике елга якын дәвам итә. Нәтиҗәдә, укучылары аны язучы итеп, ә күп язучылар каләмдәшләре итеп таныдылар. Хәзер мин дә яңа иҗади хезмәт белән яңа сулышта яшим. Бәхет түгелмени?!! «Казан утлары»ның киләчәктә дә әдәбиятыбыз өчен яңа талантлы язучылар тууга йогынтысы арта гына барыр дип ышанам. Иманым камил, журнал алдагы елларда да милләтебезнең горурлыгы, аның мәдәниятен, рухи байлыгын үстерүче булып калачак.*

теләгән идеяләр белән алар табигый үрелеп барып, әсәрнең әһәмиятен, тәэсир итү көчен арттыра, телгә мәхәббәт тәрбияли, укучының тапкырлыгын, фикерләү сәләтен үстерә. Бу нисбәттән язучы фольклорның башка жанрлары—легенда, табышмак, җырларны да уңышлы куллана.

Г. Тукай үз вакытында: «Халык җырлары безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә бәһале мирастыр... Халык җырлары—халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс, саф вә раушан көзгеседер», дип язган иде. Г. Бәширов та җырларны «Халыкның музыкаль талантының мәңгелек шаһитләре, онытылмас ядкарьләре» дип атый *(Г. Бәширов «Бүген дә, иртәгә дә». Казан, Тат. кит. нәшр. 1974 ел.)*, бу юнәлештә зур гына хезмәт тә калдыра, ул 1939 елда А. Шамов белән берлектә «Халык җырлары» исемле җыентык төзеп бастыра.

Үз иҗатында халык җырларын әдип төрле максатларда файдалана. Мәсәлән, «Җидегән чишмә»дә әлеге мирас геройларның күңел дөньясын, моң-сагышларын ачуда уңышлы файдаланыла. Тол хатын Язилә җырын китерик:

Бакчаларда ак күбәләк
Серен сөйли гөлләргә.
Ул серен сөйли гөлләргә,
Мин сөйләрмен кемнәргә?

Дим гүзәле Шәүрәгә булган хисләрен, сүз белән әйтеп бирә алмаган мәхәббәтен Гайнан җыр аша җиткерә:

Алларым да син инде,
Гөлләрем дә син инде;
Ялкыннарын үзең бирдең
Суларын да сип инде.

«Туган ягым—яшел бишек» повестенда сөйгәненнән аерылган Әхәт кичерешләрен бирүдә шулай ук халык җырлары ярдәмгә килә:

Йөгереп төштем су буена,
Кереп киттем таллыкка;
Егеттән егет ким түгел,
Кимсетәләр мал юкка.

Егетнең рухи халәтен бирүдә дә җыр уңышлы кулланылган. Фәкыйрь тормыш ачысы, күңел газабы әсәрдәге җырда түбәндәгечә ачыла:

Эчем яна, эчем яна
Беләмен ник янганын,
Сөйгәнемне ятка бирмим,
Күрмим ятка калганын.

Повестьта яшьли ятим калып, күп борчу-хәсрәтләр кичергән Әхмәт образы бар. Әлеге геройның күңеле бай икәнен ачу максатыннан автор шулай ук халык җырларына мөрәҗәгать итә:

Әрәмәгә керсәм, үлән сирәк,
Аланнарга чыксам, җир җиләк.

Эчләремдә генә утлар яна,
Нигә сыкрый икән бу йөрәк?

Иртә генә торам, кырга чыгам
Ак куяннар эзли, тал тапмый.

Өйләргә дә керәм, тышка чыгам,
Ятим башкайларым ямь тапмый.

Югарыда искә алынган «Без кем идек» мәкаләсендә Г. Бәширов үзе дә әлеге герой турында: «Аның җырлары, егет үзе ярлы булса да, күңеле бай икәнен күрсәтергә ярдәм итә» дип язды.

Моңсу лирик җырлар белән беррәттән автор әсәрләрендә шаян җырларга да мөрәҗәгать итә. «Туган ягым—яшел бишек» повестенда, мәсәлән, Сәхипҗамалның шаянлыгы, шуклыгы җырларында да чагыла:

Тук-тук тукран,
Тукылдатып утырам.
Тизрәк яучы жибәрмәсән
Ябьгшып чыгам, чукынган.

Кичке уен барышында, аулак өйләрендә жырланган жырлар тәрбияви яктан да әһәмиятле булганнар. Чөнки, кешесенә карап, мактау, көлү, чеметеп алу рухында башкарылган жырлар әхлак, хезмәт һ. б. яктан тәрбияләү бурычын да үтәгәннәр.

Гомумән, жырлар Г. Бәширов әсәрләренең теленә музыкаль янгыраш бирә, монсулык яки шаян рух өсти.

Әлбәттә, халкыбызның туй мәжлесләре жырсыз гына узмый. Үзара макташу жыры, кыз елату, кыз озату, кызның чәчен үрү, кызга чишмә юлын күрсәтү кебек махсус жырлар, аерым йолаларны сурәтләү аша автор аларны мәңгеләштерү өчен дә зур эш башкарган.

Жырлар турында сөйләгән вакытта «Жидегән чишмә» романының үзәген тәшкил иткән «Жидегән чишмә» жырына аерым тукталмый мөмкин түгел. «Чишмә моны ничек жыр булды?» мәкаләсендә *(«Азат хатын». 1980, 5 сан)* автор әлеге шигыре турында түбәндәгечә язган иде: «Минем уемча, бу жырда халыкның чишмәләргә, шулар аша табигатькә булган кайнар мәхәббәте халык жырларындагыча гади дә, тирән мәгънәле дә, моңлы да булып янгырарга тиеш иде». Автор үз теләгенә ирешә. Сара Садыйкова тарафыннан көй язылгач әлеге әсәр халык жырлары белән бер дәрәжәгә күтәрелде:

Жидегән чишмәләрдә жиде улак, жиде улак,
Чылтыр-чылтыр ага көмеш су.
Көмеш сулар ага, кошлар сайрый,
Шул чакларда бигрәк ямансу.

«Якты талант» дигән мәкаләсендә халык шагыйре Фәнис Яруллин менләгән кешеләрнең фикерен чагылдырып «бу талантка халык кайта-кайта, рәхмәт әйтер әле мең кабат», дип язган иде *(«Якты талант», «Соц. Татарстан». 1991, 18 гыйнвар)*. Чыннан да, ул хаклы. Чөнки Г. Бәширов һәм халык аерылгысыз. Авторның әсәрләре һәм халык ижаты бер-берсен тулыландырып та яши. Фольклор әсәрләре автор ижатына үзенчәлекле төс, халыкчанлык бирсә, әдипнең әсәрләре халык авыз ижатын, аның гореф-гадәтләрен, йолаларын саклап калырга ярдәм итә. Халык мирасын ижади файдалану ахыр чиктә Г. Бәшировны тел остасы һәм талантлы язучы итеп таныткан факторларның берсенә әверелә. Бүгенге яшь әдипләр өчен бу олуг ижат чын мәктәп, якты үрнәк булып тора.

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

---

## «Казан утлары» елъязмасы

(март)




35 ел элек (1967 ел) «Казан утлары» журналында (3 сан) **Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим»** лирик повесте.

30 ел элек (1972 ел) «Казан утлары» журналында (1-3 саннарында **Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар»** романы,

30 ел элек (1972 ел) «Казан утлары» журналында (3 сан) **Фәнис Яруллинның «Жилкәнне жилләр еккач»** повесте дөнья күрде.

# РӘШИТ РӘХМӘТИ АРАТ ҺӘМ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ



Рәшит Рәхмәти Арат (1900—1964)—иҗаты татар халкына әле кайтарылмаган күренекле шәхесләрнең берсе. Ул—галим-тюрколог, профессор.

Күп санлы гыйльми хезмәтләре белән беррәттән, Р. Рәхмәти шигырьләр, хикәяләр дә иҗат иткән. Беренче әсәрләрен Кызылъярда (Петропавловскида) мәктәптә укыганда ук балалар өчен чыгарылган «Берлек», «Яшьлек таңы» журналларында бастырган. Харбинда яшәгәндә «Ерак Шәрекъ» дигән журналны оештыруда катнашкан.

Берлин университетында укып йөргән елларында Р. Рәхмәти Арат бик күп шигырьләрен, нәсерләрен Гаяз Исхакый чыгарган «Милли юл» (соңыннан «Яңа милли юл») мәҗмугасында бастырган. Җитмешенче елларда Төркиядә татарлар чыгарган «Казан» журналында да Р. Аратның кайбер әдәби әсәрләре дөнья күргән.

Чит илгә киткәч, Г. Исхакый берничә мәртәбә татарча матбага оештырырга омтылыш ясап карый. Бу теләгенә ул бары тик 1928 елда гына ирешә. «Милли юл» мәҗмугасының беренче саны 1928 елның 23 декабрендә дөнья күрә. Бу матбага мәйданга чыкканчы, Г. Исхакыйның Аурупаның төрле илләрендә милләттәшләрен барлап, оештырып, «Идел-Урал» комитетлары корып йөрүе билгеле. Әдип аеруча Аурупа университетларында белем алучы яшь милләттәшләренә игътибарын юнәлтә. Мәҗмуганың булачак авторларыннан берсе Рәшит Рәхмәти Арат белән ул Берлинда таныша. Шуннан соң алар хат алыша башлыйлар.

1928 елның 26 июлендә Финляндиядән язган хатында Г. Исхакыйның бу сәләтле студент егеткә зур өметләр баглавы аңлашыла. Шулай ук бу хатта Г. Исхакыйның мәҗмуганы оештыру юлындагы эшчәнлеген күрсәткән кыйммәтле мәгълүматлар да бар. Хатта болай диелә: «Минем төрле җирләрдәге бәйләнешләрем, әлбәттә, әле катгый бер нәтиҗә биргәне юк. Ләкин өметсез түгел. Мәйданда мәҗмуга булганда аз-чук *(азмы-күпме)* дустлык күрсәтерләр кебек тоела. Мөнәсәбәтләрне баглап йөрим. Илемезгә [мәҗмуганы] кертү мәсьәләсе шактый юлга керә, Акса шәрекъ *(Ерак Шәрекъ)* берлә мөнәсәбәттә тәмаслар *(бәйләнешләр)* хис ителә... Кечкенә нигез салдык. Монда да кечкенә-кечкенә оячыклар корамыз. Идел-Урал җөмһүриятенең харитасы бик лазем икән. Һәрбер тәмаста зур ихтыяҗ бар, шуны эшләп куя алсаңыз, шәп булыр иде. Ләкин чикләрне ныгытуда бик саран булмаңыз. Ул йирләр бит барысы да безнең бабайларның йорты булган, көтепханәдә бәгъзе бер материаллар, әлбәттә, бардыр...

Р. S. Нарва шәһәренең музәсендә «Казанны алу» исемендә бер рәсем бар, күчертергә тиеш иде, ләкин бик зур.»

«Милли юл»ның 1929 ел, 6 санында Р. Аратның «Өлешсезләр» исемле нәсере басылып чыккач, Г. Исхакый 1929 елның 14 мартында Варшавадан егеткә болай яза: «Башланган эшнең дәвамына хезмәт итү барымызның да бурычы, хосусән сез яшьләрнең өстенә йөкләнгән фарыздыр. Менә сезнең шул фарызларны үти башлавыгызга сөендем. Моннан соң, әлбәттә, дәвам итәчәксез. Эшләр шактый киңәеп барганга, төрле-төрле эшләр алга басып торалар. Шул эшләрдә сезнең сызганып эшләүчеләр арасында булуыгыз лаземдер. Шул ук харита эшендә, әлбәттә, сезнең хезмәтегез... тагы төплерәк, гыйльмирәк булачак иде. Илемезне тану, таныту юлында сезнең казынырга имкяннарыңыз *(мөмкинлек)* тагын күбрәк, хәзерлегегез тагы тулырак...»

Р. Арат иҗат иткән нәсерләр мәҗмуганың «Әдәби язулар» рубрикасында басылып бара. Ләкин Г. Исхакый моның белән генә канәгать түгел. Ул аңа милли мәсьәләләр хакында гыйльми мәкаләләр язарга киңәшләрен бирә. 1929 елның 28 апрелендә язган хатында ул: «...мәкаләләрегездә ара-сора милли хәлләремезгә кучкәләргә кирәк иде. Мәсәлән, төрек-татар теленең байлыгы, эластичныйлыгы... хакында аурупача карап, Аурупа лисан гамәлләренә таянып, берме, берничәме мәкалә кирәк иде. Бу безнең матур телемезне бозып ята торган ахмак татар малайларына бер гыйбрәт булыр иде. Бу кирәк һәм сезнең кебек лисанчы бер кешенең каләменнән чыгарга кирәк».

Кем белә, Г. Исхакыйның хатларда да һәм әңгәмәләшкәндә дә телләр турындагы фикерләре, бәлки, яшь егетнең күңеленә оетки салгандыр, Р. Арат Рәхмәтинең киләчәктә галим-тюрколог булып китүенә этәргеч ясагандыр.

Шул ук хатта Г. Исхакыйның Идел-Урал иле картасын ничек күз алдына китерүе дә бик кызыклы. Ул болай ди: «...Безнең киләчәк дәүләтемезнең хөдүдләренә *(чикләренә)* мөмкин кадәр иске тарихи җирләремез керү кирәк һәм дә дәүләтемез эчендә рус гонсырының *(өлешенең)* аз булуы кирәк. Шул ике нокта бер-берсенә тискәре килә лә йөдәтә. Минемчә, Казан, Әстерхан, Оренбург, Уфа вилаятьләре, тәмаман Иделнең агуы берлә барганда, Азия ягындагы Сембер, Самара, Сарытау губерналарының өязләре вә аңа Пиремнең татар өязләре керергә тиеш. Шәрекътагы *(көнчыгыштагы)*, хөдүдемез Урал елгасы булса, шәркый-шимали дә *(төньяк-көнчыгышта)* хөдүдемезне ничек теләсәк, шулай киңәйтергә имкян бар. Чөнки анда без үземезнең Себер татарларымызга таба чикләтәбез. Рус гонсыры анда үзе дә бик сыек. Идел буенда, хосусән, Самара, Сарытау губерналарында гына хәлемез авыр. Ләкин Әстерханны читтә калдырып, Каспий диңгезеннән озакта *(еракта)* калып, хәзерге Татарстан, Башкортстан ходүдендә калу, әлбәттә, бернигә дә ярамый. Ул диңгезгә чыкмаган мәмләкәтнең, үзенең кардәшләре берлә контакт ясый алмаган мәмләкәтнең яшәве бик авыр. Шул кулыңыздагы материалларны җыеп, мөмкин кадәр тизрәк бер этнографик харита, бер дәүләт харитасының проҗәсен *(проектын)* хәзерләгез әле. Язга таба, дәресләр беткәч, үзем дә Берлинга барып чыгармын дип торам. Шунда мөзакәрәгә *(тикшерүгә)* куяр идек».

Инде 1930 ел ахырында, 14 ноябрьдә язган хатында Г. Исхакый Р. Аратка: «Харита мәсьәләсе, фәүкыльгадә *(ахыр чиктә)*, минем бер хәлгә керде. Монда хәзер французчага, ләһҗәгә бер пропаганда әсәрне тәрҗемә иттерәмез. Шуның өчен дә харита булу лазем»,—дип хәбәр итә. Бу «пропаганда әсәре»нең 1933 елда Парижда рус һәм француз телләрендә, 1934 елда япон телендә, 1938 елда поляк телендә басылып чыккан «Идел-Урал» исемле брошюра икәнлеге шик калдырмый. Димәк, Г. Исхакый бу әсәрен 1930 елда ук язып тәмамлаган булган. Кызганыч ки, бу очеркның татарча тексты сакланмаган.

«Яңа милли юл» журналында Р. Рәхмәтинең илле әсәре басылып чыккан. Шуларның унбере—шигырь, калганнары—нәсер, публицистик, тәнкыйди мәкаләләр. Журналда авторның үз исеме күренми. Ул псевдоним—тәхәллүс белән яки имзасыз яза. **М. Х.; М. Ф.; М. Х. Ф.; Гали; Гали Биктимер; Шакир Йосыф; Ш. Й.**—менә аның тәхәллүсләре.

Р. Рәхмәти әсәрләре эчтәлекләре белән мәҗмуганың рухына, юнәлешенә туры килә. Туган ил, милләт, бергәлек, азатлык, хөрлек, тартышу-көрәш темалары өстенлек итә. Шулай ук авторның «Хан кызының алмаслары» дигән әкияти бер шигырь-балладасы да бар.

Мәҗмугада иң беренче басылган нәсере, әйткәнебезчә, «Өлешсезләр» дип атала. Идел образы бик матур сурәтләнә. «Тарихы буенча төрек-татар йорты булып килгән, берничә дәүләткә урын биргән Идел суы, шанлы тарихыбызның бик күп борылышына шаһид булып килде. Безнең берлән бергә көлде, бергә җырлады, бергә кайгырды, бергә җылады»,—ди автор. Журналда автор тарафыннан мәгълүматлары азрак булган мөһаҗир укучылар өчен язылган болгар тарихына, илләр тарихына, шулай ук матбугат, татарларның һиҗрәте тарихына караган материаллар да урын алган. Шулай ук, С. Максудиның төрек теленә багышланган китабына, Х. Габдүшнең «Дүрт хикәя» җыентыгына рецензияләр, Казембек, И. Гаспралы, Г. Камалның, Румыниядә яшәп иҗат итүче кырым татарлары язучысы Мөхәммәд Ниязи бәкнең юбилейлары уңае белән язылган мәкаләләр мәгълүматка шактый бай.

Троцкийның «Истинное положение в России» дигән китабына күзәтү ясап, Р. Арат язмасын болай тәмамлый: «Сталинның җинаятьләрен тезеп язган китабында Троцкий Россиядә руслаштыру сәясәте баруын да ачык яза. Ләкин Троцкий шул милләтләрне изә торган оешмаларны үзе дә төзеп йөргән иде»,—ди.

«Бер тарихи драма» исемле мәкаләсендә Р. Арат СССР да Солтангалиевнең «эше» уңае белән кулга алулар турында яза. «Бу хәлләр безгә нәрсә сөйли соң? Мәскәү өчен татарның иҗтимагый хәятеннән үзенең көче һәм тәэсире берлә хөкүмәтнең урыслаштыру сәясәтенә каршы торган бер катлауны алып ташлау кирәк иде»,—ди автор. Шулай ук Г. Рәхимнең кулга алынуы турында мәкалә язып: «Аның бик матур «Идел» исемле повестен большевиклар бер җинаять итеп кабул итте»,—ди. Автор берничә мәкаләсендә яшьләргә көчле оешма булдырырга кирәклеге, бөтен кешенең теләкләрен берләштергән бер программа булдыру зарурлыгы турында яза.

Рәхмәтинең Тукай турында язган мәкаләләрен аеруча билгеләп үтәргә кирәк. «Яңа милли юл»да алар берничә, күбрәк эссе шәкелендә язылганнар. Автор Тукай язмышын милләт язмышы белән бәйләп карый. Ятим калган халыкның ятим калган улы дип атый ул Тукайны.

«Яңа милли юл» журналы унбер ел дәвамында—1939 елның октябренә кадәр чыгып килә. Мәҗмугада Р. Рәхмәтинең соңгы язмалары 1934 елга туры килә. Билгеле булганча, Арат 1933 елда Төркия Мәгариф министрлыгы тарафыннан Төркиягә эшкә чакырыла.

Г. Исхакый исә Төркиягә 1939 елның ахырында килә. Бу илдә яшәгәндә дә олы әдип белән яшь галим үзара аралашып торганнар. Р. Рәхмәти архивындагы материаллардан күренгәнчә, ул Г. Исхакыйның революциягә кадәр чыккан әсәрләрен конспектлап укыган, кыска-кыска фикерләрен дә язып куйган. Галимнең архивында, шулай ук, Г. Исхакыйга кагылышлы материаллар да очрый. Мәсәлән, Г. Исхакыйның «Локман Хәким» исемле хикәясенең татарча тексты нәкъ шул архивтан табылды.

**Лена ГАЙНАНОВА**

# Рәшит Рәхмәти Арат

## Ил көче

Милләтләр тарихында сәяси алмашынулар бик зур роль уйныйлар. Буыннан-буынга күчеп килгән халык ганганәләренә *(сүзнең кешедән кешегә күчүе)* яна бәһаләр куела, яна карашлар чыга, яна идеаллар туа. Халык дулкыны мәйданга яна кешеләр ташлый. Йөрәк сагышын, күңел ялкынын калыпка салучы сүз даһие—шагыйрь туа. Тормышны яна юлларга

боручы, яңа нигезләр салучы көрәшче эшчеләр калка. Халыкның җан аткан, тик ачык билгеләнмәгән, аерым бер формага кермәгән теләген фәлсәфә ягыннан яктырткан, бөтен, тотып карарлык итеп куйган белем ияләре күтәреләләр. Яңа сүзләр, яңа моңнар тормыш күген тутыралар. Өмет күнелләргә сыймый, таша. Халыкта эш тойгысы, ярату көче уяна. Чын даһиның кузгалган халыкның киләчәге өчен сызган юлы йөрәк очкыны берлә сүнмәслек булып яктыртыла. Зур революциядән, халыкның бөтен катлавын кайнаткан тормыш дулкынынннан шул көтелә. Шундый бетми торган, буыннан-буынга калырлык, күнел тудырган мәгънәви куәт өчен матди байлыкны югалту да берни түгел. Ут упкынында күккә очкан җир байлыгы да кызганыч түгел. Алар урынына мәнгелек тормыш өчен рух, җан биргән яңа көч туа. Бу көч, иртәгә үк, ул югалганнарны артыгы берлә тагы кайтарачак. Болар алмашыну үз юлы берлә барганда, халыкның ярату иркенә киртә булып торган бөтен нәрсәләр алынып ташланганда, тормыш юлдашы булган күнел сагышы богавыннан котылганда булалар. Сәяси, иҗтимагый алмашынуның төп сере дә шул табигый барышны буып торган көчләрне юл өстеннән алып ташлауда гына. Рус революциясе булды. Февраль октябрь берлә алмашынды. 3-4 йөздән соң терелгән, калыккан кебек булган татар иле җиде еллык бәйрәмен итте. Тәбрикләдек. Яшь гомернең эшләрен санадык. Шул кыска тормыш өчен искиткеч алга китү таптык. Кайбер бүлемнәрдәге аксауларны да капладык. Киләчәкнең туктаусыз эшен дә, аларның бик тиз барлыкка чыгуын уйлап, бар булган кебек итеп карадык. Болар бу көнге күренеш болыдан бигрәк киләчәктә булуын теләүдән туган бер шәүлә иде. Соң бу күренеш тормышта ничек? Шул дөньяны селкеткән дулкын безгә ни бирде? Дөньяда торырга хак даулаган бер халыкның иркен сакларга бик күп сакчы, тормышының нигезен ныгытырга, көндәлек тормышын бер калыпка салырга бик күп оешма кирәк. Боларның төп нигезе бөтен халыкның һәм халык берлә бергә һәрбер аерым уйлаучы башның тормышын тутырган, ана бер эчке мәгънә биргән, өметен канатландырган нәрсә—халыкның тормыш идеалы. Аерым кешеләр генә түгел, бөтен иҗтимагый тормыш бер идеалсыз бара алмый. Һәрбер чыккан сулыш, һәрбер әйтелгән сүз, һәрбер кыймылдаган кул шул бер нәрсә өчен, бер моң өчен булырга тиеш. Дәүләт, үзенең бөтен оешмалары берлә, шул бер юлга баручы халыкның көтүчесе; аның кирәдәге эшләрен тикшереп торучы, машинаның бөтен чарыклары тигез эшләвен күзәтүче оста гына.

Без шул биргән корбаннар, югалткан байлык, күргән авырлыкларга каршы нәрсә алдык? Хәзерге дәүләт корылышы безне нинди теләккә алып бара? Бу сорауларга каршы бер генә җавап бар. Ул, дошманның безне бетерү юлында тоткан сәясәтенең бер өлешен генә күрсәткән, ике төрле аңларга урын калдырмаслык итеп кыска һәм ачык әйтелгән Мәскәү сүзе: «эчке мәгънә безнеке, тышкы форма сезнеке! Безнең теләгебезне, безнең фикеребезне, безнең, миллә һәм дәүләт уларак тоткан максатыбызны сез үз тормышыгызга кертегез; үзегезнең бөтен мәгънәви барлыгынызны, гомерегез буенча күнелегездә саклап үстергән идеалыгызны ташлагыз, татарча сөйләшә торган урыс булыгыз!» дигән сүз. Бөтен тормышынны, бөтен идеалларынны чыгарып ташлап, аның урынына бөтенләй ят булган, һичбер тарихи барышың берлә, бөтен тормышың берлә сиңа аңлашылуы мөмкин булмаган бер бушлык калгач, бу көнге күнелнең нинди сагыш берлә узганын күз алдына китерүе авыр түгел. Казан алынгач, мәдәни учаклар җимерелгәч, ил терәге булган ирләрнең урманга, караңгылык дөньясына таралып, белемнәреннән файдалана алмый ятканда нинди ачы тойгы тойган булсалар, бу көндә илнең үсүе, бөтенәюе юлында эшләүчеләр шундый авыр бер тойгы эчендә яшиләр. Бөтен халык шул ике ут арасында күнел тудырган идеал берлә, дошман кушкан, аның өчен аңлашылмаган бушлык арасында азаплана. Шул тыелган күнел моңына хезмәт итәр өчен төрле юллар берлә, бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләп килүче бөтен ил уллары, иң зур авырлыкны күтәреп килүче көрәшче батырлар, халык эшчеләре.

Тормыш корылышыбызда шул төп сызык булмаганга, көндәлек эш шул ике тыныш арасында йөрү мәҗбүрияте берлә тулганга, хәзерге дәүләт үзенең бөтен аппараты берлә халык моңына киртә салганга күрә, халык үз теләген

бер формага куя алмый. Илен коручы, идеалын тудыручы оешмалар ярата алмый. Моң һаман шул борынгы килеш, эчтә сүзсез сызлануында дәвам итә. Тормыш корылышы, сәяси, иҗтимагый оешмаларыбыз бөтенләй яңа бер нигезгә куелмый торып, халык үз теләген барлыкка чыгара алмаячак. Моны соңгы елларның тәҗрибәсе бөтен ачысы берлә татытты. Яңа нигездә, үзенең тормыш идеалы нигезенә корылган оешманы ялгыз үз язмышын үз кулына алган, үз киләчәген үзе билгели алырга хаклы булган иректә халык кына тудыра ала. Үзенең киләчәген иректә итеп күрүне, үз идеалы өчен яшәүне изге теләге итеп алган һәрбер кеше алдында бер бурыч бар. Ул—илнең ирегә юлында көрәшкән бөтен ил улларын берләштереп, берләшкән көч берлә, шул кеткән көнгә, якты тормышка юлга чыгу бурычы. Һәрбер аерым янган йөрәкнең утыннан, һәрбер аерым сызланган күңелнең сагышыннан туып берләшкән, бөтен илнең үзенеке булып калыккан көч ямьле киләчәгебезнең иң нык нигез ташы булачак.

**М. Х. Ф.**

*(Берлин, «Милли юл», 1929, 8 сан, 5-6 б.)*

## Галиәсгар Камал

ӘДӘБИЯТЫМЫЗГА УТЫЗ ЕЛЛЫК ХЕЗМӘТЕ УНАЕ БЕРЛӘ: 1899-1929

**20 апрельдә** татар дөньясы үзенең зур язучыларыннан берсе булган Г. Камалның 30 еллык әдәби хезмәт бәйрәмен итте. Г. Камал 1878 нең 23 декабрендә Казанда туган. 1901 елга чаклы Казан мәдрәсәләрендә укыган. Аның каләм көчен сынавы мәдрәсә тормышында ук башлана. Беренче вә мәшһүр әсәрләреннән булган «Бәхетсез егет»нең басылуына 1899 нчы елны рөхсәт алына вә 1901 елда басылып чыга. Шул көннән алып Г. Камал кирәк әдәбиятта, кирәк матбугатта туктаусыз эшләп килә.

Татарның мәдәни тормышында бик зур урын тоткан, тик бу көнгә чаклы кирәгенчә яктыртылып бетмәгән бер хәрәкәт бар. Ул—татар дөньясының бөтен почмакларын тутырган, гомуми тормышка катышкан бөтен көчләрне бергә җыюда бик күп ярдәм иткән «драма түгәрәкләре», тирән тарихи сәбәпләр аркылы йөз еллар буенча гаилә эченә качып яшәргә мәҗбүр булып килгән теләкне берләштереп, гомум каршына куйган бу кирәкле оешмаларның һәр тармакта ачык күренеп тора торган эзләре бар. Мәдәни үсүебезнең тарихы өчен бу түгәрәкләр, бигрәк тә аларның эше булган театр әсәрләре, бик күп материал бирәчәкләр. Моны, әлбәттә, татар театрының 20 еллыгында җыелган материаллар гына дип уйларга ярамый. Шул оешмаларны мәйданга чыгаруда һәм аларның көрәшләрендә кирәк булган коралларны бирүдә иң күрекле урын тотучыларның берсе, шиксез, Г. Камал булды. Әсәрләренең чын татар тормышыннан алынып язылуы, теленең сафлыгы, каһарманнарының бөтенлеге, караучыларга якын, аңлар өчен унай булганга, алар һаман сөелеп уйналган, теләп каралган нәрсәләр булып киләләр. Г. Камалның бөтен тулы эшләнгән әсәрләренең әдәби кыйммәтен билгеләү бу урында безнең бурычыбыз түгел. Татар әдәбияты, бигрәк тә театр әдәбияты тарихы моңар вакыты берлә тиешле урынны бирер. Тик без бу уңай берлә укучыларыбызның карашларын бер тынышка туктатып үтәргә телибез. Татар сәхнәсе безнең үз дөньябызда үз кирәгебез өчен туды. Без анда, халык тормышының көзгесендә, үзебезне үз күңелебез аркылы күрә идек. Сәхнә әсәрләренең кимчелеге булып каралырга тиешле булган, каһарманнарның күбесенең кимчелек ягыннан гына эшләнүләре, күчү дәверенең тартышлары берлә билгеләнгән иде. Тик бу вакытлы иде. Соңгы вакытлар бу юлда яхшы ук уңышлы күренешләр дә яраткан иде. Тик бу көн театрда булган алга китү, театр техникумнары, хәзерлекле уйнаучылар булган бер көндә, үзенең сыеклыгы берлә күзгә ташланган нәрсә, сәхнә әсәрләренең ясалу вә мөндәриҗә ягыннан буш, тормыш берлә нык бәйләнеше булмавы. Бу күренеш карт, уңышлы язучыбызның бәйрәмен иткәндә тагын да ныграк күзгә бәрелә. Һәрбер фикер эшчесенең табигый булган бер теләге бар. Ул—үз урынында үз эшенең алга китүен тәэмин итәрлек яңа яшь

көчләрне күрергә теләве. Татар дөньясының бу юлда сүзләре булган оешмалар, карт язучының картлык тынычлыгын тәэмин итәргә сүз биргәндә аның күнелен шатландырырлык «мәгънәви балаларының» үсенә дә тиешле игътибарны бирергә кирәк. Югыйсә тарих, зур имкяннарны кулларында тотып та, мөндәрижә ягыннан һаман тоткынлыкта калырга һәм калдырырга теләгән уларын мактарга ярарлык сүз таба алмас.

**М. Х.**

*(Берлин, «Милли юл», 1929, 12 сан, 9 б.)*

## Искә алганда

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ҮЛҮЕНӘ 20 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕРЛӘ

Тирән, әлләә нинди зарлы бер моң. Милли татар моңы күп тарихларны агызган Идел агымына кушылып ага. Урал тау итәкләренә тарала.

Ишетте, хәйран булып тыңлап торды бу моңны бөек Кушлавыч ятиме.

Тыңлап торды-торды да, үзенең сынык, ятим күңелендә шул моңны яңдырып, безнең өч йөз ел буенча ничек изелүебезне әйтеп бирде.

Зур-кечкенәләребез, яшь-картларыбызның барысы да аңлардай садә, ләкин искиткеч оста бер телдә аңлатып бирде. Халкыбызның жыры, мәкаль һәм табышмаклары кебек бер ишетү берлә хәтердән чыкмый торган сүзләр—шигырьләр белән телебезнең матурлыгын һәм байлыгын күрсәтте.

Тукай шигырьләрендә беренче кат туган телебезнең матур музыкасы яңгырады, шуңлыктан йорттан-йортка, кулдан-кулга күчеп йөргән авыл малае, кечкенә бер Апуш булып кына калмады—татар халкының онытылмас жырчысы Габдулла Мөхәммәдгариф угылы «зуп-зур Тукай» булды.

Х. ГАБДҮШ. *«Татар шагыйре».*
*Харбин, 1932.*

Шагыйрь—халык баласы. Ул күңеленең бөтен тамырлары берлә халыкның тормышына бәйләнгән. Халык шатлыгы—шагыйрь шатлыгы. Халык кайгысы—шагыйрь кайгысы. Бу сүз башкаларга караганда да тирәнрәк мәгънә берлә, безнең шагыйребез Тукай турында әйтелә ала. Чөнки ул тарихының соңгы елларында ятим калган милләтенең ятимлектә үскән баласы.

Тукай язмышы—халык язмышы. Аның күңелендә ут яна иде. Халык күңелендә дә шул ук ут гөрли иде. Ул татар халкының үз тарихында үстереп дөнья мәдәниятенә бирә килгән төрек милләтенең бер баласы иде.

Без узган көннәребезнең караңгы булганын беләбез. Без бу көнгә тормышыбызның да ачы булганын яшермибез. Шуна күрә дә без киләчәгебезне—халкыбызның язмышын якты һәм ямьле итеп күрергә телибез. Шуның өчен без халкыбызның үзлегеен саклый торган һәм бөтен авырлыкларга каршы нык итеп тота торган бөтен юлларны һәм бөтен терәкләрне эзлибез.

Бу юлның иң кирәклесе—халкыбызның күңеле. Бу терәкнең иң ныгы—халкыбызның теләге. Тукай—безнең халкыбызның һәм шуның берлә бергә бөтен төрек милләтенең күңелен һәм теләген ачкан һәм шуны ачарга тырышкан өчен—безнең жырчыбыз.

Халык язмышы—Тукай язмышы.

Көннәрнең суыклыгы, төннәрнең караңгылыгы шагыйрьгә аның тормыш эзен яктыртырлык, аның учагын жылытырлык бер очкын бирә алмады. Ул яшьлекне татырга да өлгермәстән, үлем тырнагына эләкте. Ашкынган йөрәкнең көчсез канаты сынды. Тик бу сынуда күңелләр берлә бергә безнең дә—иленең дә гөнаһы юк түгел иде. Аның йөрәген кем жылытты? Аның күңелен кем жуатты? Шагыйрь үлде. Үпкәне кимергән үлем корты аның тормышка бәйләнгән соңгы тамырын өзде.

Тик моның берлә генә безнең шагыйребез каршында булган бурычыбыз беттеме? Бетмәде.

Бу бурыч бетмәде. Бу бурыч артты. Ул бер кешегә, бер шагыйрьгә,

бер Тукайга булган бурычтан чыгып, халыкка, милләткә һәм кешелек дөньясына булган бурычка әйләнде. Ул Тукай исеме берлә халык өчен булган бурычка әверелде.

Тукайны кимергән үлем корты бүген халыкны кимерә.

...Илебез соңгы елларда бик күп төрле күренешләр кичерде. Ил йөз елларча көткән теләгенен барлыкка чыга башлавын күрергә өлгермәде, язмыш аны тагын борынгы тартыш сафына чакырды. Алсу-кызыллыктан яңа бер таңның яктылыгын көткән ил икенче бер янгын алдында калды. Аның бик зур авырлыклар берлә генә саклап килә алган бөтен барлыгы да бу янгында янды, көл булды.

Халык язмышы—шагыйрь язмышы.

Халык берлә бергә шагыйрьнең теләге дә, аның эше дә, аның көче дә бергә янды. Шул янгынны еракан карап торучы, илдәге зарны-моңны читтән ишетеп торучы халык уллары—алар нишләделәр? Алар нишләргә телиләр?

Бер халыкның барлыгы һәм шул барлыкның киләчәге өчен кирәк булган билгеле төп нигезләр бар. Шул нигезләр булмыйча торып, бер халык яши алмый. Шул нигезе булмаган, йә шул нигезне югалткан халыклар бетәргә—югалырга мәжбүрләр. Бөтен нигезләрнең барсы да—халык күнел тормышының үз булып калуы, куркынычын-кайгысын үзенчә сөйләве һәм үзенчә көйләве. Бер халык тинсез тартыш эчендә ярлылана ала. Ул үзенең бөтен мадди барлыгын югалта ала—болар бары да вакытлы нәрсәләр. Ә халыкның күнеле, халыкның күнел көрәше—бу меңнәрчә еллардан бирле җыелып килгән. Аның ярату көчен ясаучы нәрсә—ул халыкның язмышы. Ул халыкның үзе.

Бу күренеш бер безнең өчен генә түгел, бүген бөтен төрек милләте үзенең барлыгының, киләчәгенең нигезен бер калыпка суга. Аның бу көнге эше—төрек милләтенең киләчәк төсен һәм аның ярату көченен киләчәктәге чиген билгеләячәк. Милләтнең бу көнге тартышы аның мәдәнияте һәм мәдәниятенен чикләре өчен бара.

Милләтне—илне саклау юлында бирелгән корбаннар, милләтнең сәяси истикъляле *(бәйсезлеге)* өчен бирелгән корбаннар—алар бары да бер нәрсәнен—милли мәдәниятнең саклануы һәм шул мәдәниятнең үсүенә каршы куелган киртәләрне җимерер өчен бирелгән корбаннар.

Бу төп нигезне саклау һәм шуны ныгыту юлында эшләнгән эшнең зурысы-кечкенәсе юк. Ул бер үк төстә зур: ул бер үк изгелекнең юлына бирелгән ярдәм.

Бу тарихи көннәрдә халкыбыз кичергән авыр һәм караңгы төннәрендә халыкның—илнең төп нигезен саклау өчен безгә тагын Тукай ярдәмгә килә. Шул нигезне кору юлында үсеп житкәнче егылган, чәчәк атканчы шиңгән шагыйрь үзенең көчле тойгысы берлә җир астыннан калкып чыгып безгә тагын ярдәмгә килә.

Ул үзенең рухы берлә безнең баш өстебездән очып, безне уйларга, сөйләргә һәм сөйләгәнне эшләргә чакыра!

Үлеп, егерме ел кара-салкын туфрак астында ятса да, ул үзенең янган-көйгән куанычы-кайгысы берлә тагын безгә килеп, «татар халкыниләр сизгәнен» өзелеп-өзелеп әйтеп бирә. Ул үлгәч тә безне шул турыда уйларга һәм шул уйны үзебез өчен кирәкле һәм файдалы юлда барлыкка чыгарырга чакыра.

Ул безнең бөтенебезгә карап, өстебездә торган шул изге эшне, шул мөкатдәс бурычны үтәүдә дә барыбызның да бер үк ан берлә эшкә башлавыбызны көтә.

Ул безнең бөтен әрвахларыбыз өчен, халкыбызның сансыз корбаннары өчен аның туктаусыз аккан күз яше безнең әле торган, яшәгән, сулыш алган илдәшләренең-милләттәшләренең тойгыда, сүздә, эштә берләшүләрен көтә.

**Шакир ЙОСЫФ**

*(Берлин, «Яңа милли юл», 1933, 4 сан, 35-36 б.)*

## Эзләнгәндә

ТУКАЙНЫ ИСКӘ АЛГАНДА

Шагыйрьнең тормышы авыр иде. Ул аны бөтен ачылыгы берлә үзе дә язып калдырды. Аның шигырьләре дә авыр моңга төренгәннәр.

Шагыйрьнең ярату көче турында да әле тәнкыйть коесы капланган юк. Берәү аны шәрекъ тәэсирендә, диде. Берәү аны гарәп тәэсирендә, диде. Берәүләр аның житди шигырьләрен күтәрделәр. Икенчеләр аның һөҗүи шигырьләренә күбрәк әһәмият бирергә тиешлек турында яздылар. Өченчеләр аның балаларга карата язган шигырьләрен беренче урынга куйдылар. Берәүләр өчен ул үзенең ярату көчен халык әдәбияты коесыннан алган оригинал шагыйрь иде. Икенчеләр өчен ул тәрҗемәче һәм тәкълидче *(ияруче)* иде.

Иде!.. Иде!..

Боларның барысы өчен дә аның шигырьләрендә һәм тормышында житәрлек шаһид бар иде... Бу турыда язучылар аның шигыренең тышкы күренешен генә күз алдында тотып фикер йөрттеләр. Алар шул шигырьләрне язарга мәҗбүр иткән шагыйрьнең эчке күңел тормышын карый алмадылар. Шунар күрә бу эчке күңел тормышын дулкынландырган төп сәбәпләр дә капланып калды. Бу уңай берлә халыкның алдына ачылып салынырга тиешле бик күп ачы хакыйкатьләр дә ябылган көе калды.

Тукай ник «болай» иде? Тукай ник «тегеләй» иде?

Моның жавабы:

Тукай үзе «болай» йә «тегеләй» түгел иде: Тукайның күңелен дулкынландырган татарның тормыш шартлары йә «болай», йә «тегеләй» иде. Тукайдагы күренеш, аның шигырендәге төрлелек әнә шул тормышның күренеше һәм шул тормыш шартларының төрлелеге иде. Шагыйрь күңеле шул күренешләргә көзге иде.

Тукайны корбан иткән еллар безнең тормышыбыз өчен өметлерәк еллар иде. Без артка түгел, алга таба бара идек. Безнең соңгы елларда истәлек бәйрәмнәрен иткән көннәребезнең башлангычы ул елларда иде. Шунар күрә без тормышның ул көнге күренешен тәнкыйть күзе берлә карарга теләмәгән идек...

Чынлап та, Тукай еллары безнең өчен—йөз елларча изелгән һәм киләчәге өчен бер нык юл сызылмаган бер халык өчен бер нормаль тормыш идеме? Чынлап та, ул көннәр бер-бер күңелгә ут-ялкын бирерлек, бирә алырлык көннәр идеме? Ул елларда күңел бер генә юлда, бер генә өслүбтә, бер генә төрдә тибрәнә алырлык идеме? Әлбәттә, ул көннәр дә бу көнгесе шикелле үк авыр иде. Бу көнгесе шикелле үк караңгы иде. Ул көннәр дә әле безнең тарихыбыздагы шанлы көннәребезне жанландырырлык түгел иде. Тукайны бер кеше итеп аңлар өчен аның күңел тормышына кереп, аның тойгысы берлә яшәр өчен безнең ул көннәргә чаклы уздырган якын тарихыбызны бөтен авырлыгы, бөтен ачылыгы берлә күз алдыбызга китерергә тиешбез.

Бу тарихта бер уй иясе өчен өмет бирерлек бер күренеш бар идеме? Бер Тукайда гына түгел—аның алдыннан торган дөньядан бизүчеләрне дә карагыз. Берничә буынның үткән тормышы бергә берничә буынның киләчәген уйлый алган һәм үзенең хәрәкәтен шул ике күренешнең мәсъүлиятенә нигезләгән кеше өчен ул көнге тормышта чиксез өмет табу бик жиңел булмас.

Шагыйрьнең күңелендәге сүнмәс очкын—аның идеалы. Шагыйрь идеалы—халык идеалы. Бу идеал шагыйрьгә генә түгел, бөтен халыкка тормыш азыгы бирә. Ул аңар авыр көннәрне өметсезләнмичә уздырырга ярдәм итә. Ул аңар елларның жиленә-суыгына торырга көч бирә. Ул көннән-көн шул идеалга якынлаша: якынлашкан саен аның көче арта бара. Тукай көннәрендә безнең халкыбыз өчен, шулай ук халыкның мәгънәви азыгын әзерләгән әдәбиятыбыз өчен бер идеал юк иде. Тик шуның юклыгын күргән һәм шуның кирәклеген белгән бер даһи аны эзләргә тиеш иде.

Тукай шуны эзләүче иде. Аның шигырьләрендәге тыштан караганда бер-берсенә каршы күк күренгән моң бер үк күңелнең туктаусыз тормышы

иде. Шуңар күрә ул төрле иде. Шуңар күрә ул ачы иде.

1905 елны күргән шагыйрь күңеле ачарга өлгермәде. Аңа аннан соңгы елларның кыравы төште. 1917 нче елны күргән булса иде—без бу күңелнең балаларча куануына шаһид булыр идек. Тик бу шатлык та кыска гомерле булыр иде...

Бер шигырьдә бөтен нәрсә дә шагыйрьнең үз малы гына түгел. Шагыйрьнең андагы хакы—аның бер фикерне халык күңеленә, тойгысына яраулык итеп, һәр яктан үз итеп калыпка салуы. Мондагы осталыгы шагыйрьнең иҗат көчен үлчәргә җитә. Халык биргән материалдан ямьлелек, ярату һәм шул материалдан яңадан-яңа формалар кую—бу шагыйрьнең иҗат көченең тирәнлегенә, чынлыгына бәйләнгән.

Менә монда Тукай бер оста иде һәм башкаларга үрнәк булырлык бер оста иде. Тукайның иҗадиятен аның шигырьләре аркылы тикшерү безнең бу көнге теләгебезнең эченә керми. Уңае берлә бу юлдагы тәҗрибәне икенче урында бирергә мөмкин булыр. Без монда бу көн уңае берлә Тукайдагы төрлелекнең төп сәбәбен генә күрсәтергә теләдек.

Тукай көннәрендә үзенең юклыгы берлә ачылык тудырган бу идеал нәрсә соң? Без үз илебездә яшибез. Тик без дошман кулында яшибез. Дошман безнең тормышыбызның төп нигезләрен җимерә... Ул безне изә, җырыбызны кыса. Халкыбызны мадди һәм мәгънәви ярлыландыра. Әле генә узган дәһшәтле ачлык еллары—алар соңгы тарихыбызның безнең өстебезгә ташлаган югалу куркынычының бер кечкенә шәүләсе генә. Бу куркыныч бүген дә дәвам итә. Ирек ул һичбер вакыт мәгънәви генә була алмый. Ирекнең нигезендә мадди ирек салынган булырга тиеш. Мадди ирек халыкның язмышы үз кулында чакта гына тормышка күчерелә ала.

Коллыкта торган һәм коллыкта яшәргә мәҗбүр ителгән бер халык тулы мәгънәсендә бер мәдәният тудыра алмый. Чөнки мәдәният ул нәрсә икәнлеге билгеле булмыйча һавада очкан бер төтен генә түгел, ул—тормышның, көндәлек тормышның куанычыннан һәм кайгысыннан туган һәм шул куаныч һәм кайгы өчен халыкның үзе корган оешмаларының эшендә генә туа ала. Бу—халыктан бер дәүләт һәм бер үз булган идарә сорый. Бу сорауга җавап бирү халыкның идеалы булырга тиеш. Без халыкның иҗат көченә бер бәһа куйганда һәм аның даһиларының күңел коеларын актарганда әнә шул идеалга хезмәт итүнең дәрәҗәсен үлчәү итәбез.

Тукай безнең шул идеалларыбызны эзләүдә бөек шагыйребез иде. Ул шул юлда туктаусыз һәм тинсез тартышта безнең арабыздан китте. Тик аның юлы калды: аның ачы булса да ямьле, ямьле булса да ачы моңы безгә җуаныч һәм куаныч булып калды.

Аны искә алу көне безне тагын да аның язмышына һәм шуның берлә бергә халыкның язмышына тирәнрәк карарга һәм ул язмыштагы сорауларга тагын да ачыграк җаваплар эзләргә өнди.


**Гали БИКТИМЕР.**

*(Берлин, «Яңа милли юл», 1933, 5 сан, 23-25 б.)*

*Текстларны журналга* **Лена ГАЙНАНОВА** *әзерләде.*

# БЕЗНЕҢ ДӘ ӘНИЛӘР БАР ИДЕ...

Күптән түгел «Мәгариф» нәшриятында шагыйрь Шамил Маннаповның хикәяләр, хатирәләр китабы дөнья күрде. «Мәңгелектән елмаю» исемле әлеге җыентыкка кереш сүзендә язуынча, бу китапны иҗат итү бурычын авторга... мәрхүм әнисе йөкләгән. Ана, инде үзе дә олыгайган улы янына, мәңгелектән төшләр булып бик еш кайта икән. Һәм бер кайтуында ул: «Бурычыңны үтәргә онытмадыңмы, улым?»—дип сорый шагыйрьдән. Улы уйлый: нинди бурыч, кемгә, ничек итеп үтисе? Күңеле белән туган ягына, бала чагына, яшьлек елларына кайта, хатирәләрен яңарта, хәтерендәге авылдашлары, дуслары-танышлары белән кабат очраша... Әйе, гомер юлында очрашкан бик күпләр алдында бурычлы икәнбез бит без, түләп тә бетермәслек бурычлы! Кайсыбыз аңлый да, кайсыбыз юк моны. Гомерлек бурыч, дип бәяли боларны шагыйрь. Гомер бурычы, дип әйтсә дә урынлы булыр иде. Бар булмышыбыз, гомеребез өчен дә кемнәргәдер әҗәтле ич без. Әдип каләменә ия кеше мена шушы китаптагыдай хатирә-хикәятләрне язып чыгару белән булса да үзенең рухи бурычын, бөек вазифасын үтәргә тиеш тә икән бит әле. Китапның эченәрәк кергән саен бер нәрсәгә ныграк ышанасың: әнисе белеп кисәткән ич Шамил замандашны! Чөнки әйтер сүзе дә, хатирәсен җанлы хикәяләп бирерлек тел куәте дә җитәрлек икән аның.



Алай гынамы, язылмыйча әрәм калсалар никадәр үкенеч булыр иде! Беркем язмаганга чорлар тузанына күмелеп калган тарихыбыз азмы инде? Хатирәләрендә автор үз үткәнен гали бер сөйләүчедән әдип югарылыгына күтәрелә алган, шуңа күрә укучы һәркем диярлек үзенең дә гомер юлын кабат кичкәндәй, яшьлек дуслары белән очрашкандай була. Оста каләме белән язылулары ягыннан, «Ачы какылар» яисә «Акмангай» хатирәләре генә дә ни тора!

«Ачы какылар». Никадәр табигыйлек һәм тормыш чынлыгы бу истәлек-хикәядә. Юк-юк, глобаль проблемалар күтәрелми анда. Ләкин шулай булуына әдип түгел, үз әдипләрен һәм шагыйрьләрен «ачы хәсрәт көен көйләргә», какы ачыларын сурәтләргә мәҗбүр иткән җәмгыять күбрәк гаепледер. Бу каләресен читләр аңлый да алмас. Бервакыт «Звезда Поволжья» газетасында безгә ят исемфамилияле берәү, сәхнәдән Туфан Миңнуллинның кайсыдыр әсәрен карагач, моннан да зур примитивлыкны гомеремдә дә күргәнем юк, дип язды һәм Туфан Миңнуллин кебекләргә планетарь талант бирелмәгән, алар безнең кызгануга мохтаҗ, дигән нәтиҗә чыгарды *(З.П., 7-13 декабрь, 2000 ел, «Махровые цветики нации»)*. Кемдер Шекспирны һәм Диккенсны үз телендә уку өчен инглиз телен өйрәнгән кебек, бу хөрмәтле аксакалның иҗатын укып кинәнү өчен генә татарча өйрәнергә теләүче табылмас, ди мәкалә авторы. Әйе, аңлаудан ерак алар безне. Бер үзгәреш көтү дә урынсыздыр, «үзүзен сукырайткан кешегә доктор да ярдәм итә алмый», диелә кытай мәкалендә.

Әйе, татар халкының бөек тарихын оныттырдылар, әдәп-әхлагын,

динен, яшәү рәвешен пыран-заран китереп жимерделәр, үзенчә яшәүгә ireгән алдылар да, шуларны күрсәтеп, югалтуларыбызны халыкка кире кайтару нияте белән Туфаннарыбыз язган әсәрләрне «что-то наподобие латиноамериканского мыльного сериала с некоторыми национальными особенностями деревенского быта» дип кимсетмәкче булалар. Шулай, көчлерәкләр тарафыннан таланган, байлыгы тартып алынган, үз жирендә чит хужага буйсынып яшәргә мәжбүр ителгән Латин Америкасы халыклары белән татар арасында күпмедер охшашлык та бардыр, шуңа күрә әдәбиятлары да бер-берсенә якындыр, бәлки.

Шамил Маннапов хикәясе дә какы ачыларын сабый елларыбыздан татып үскән һәм тәмен әлегәчә онытмаган, аны үзебез белән каберләргә дә алып китәчәк безнең буынга гына шулай көчле тәэсир итәдер, бәлки. Әсәрдәге Гомәрләрнең бәхете һәм бәхетсезлеге безгә генә якын һәм үздер, аны без генә аңлыйбыздыр, бәлки. Әмма ач үлемнән могжиза белән диярлек исән-имин калган безләр дә бик аз түгел әле, шунлыктан безнен өчен дә язарга кирәк. Бераз элегрәк Радик Фәизовның бер хикәясен укыганда кышкы туңы жеби генә башлаган бакчалардан черек бәрәңге жыю истәлегенә юлыгып, ялан аяклар белән тагын бер тапкыр пычрак астындагы бозга басып йөргәндәй өшегән идем. Көчәнеп хәтерлисе түгел бит безгә: өшүләребез дә, ачлык тудырган чирләребез дә, менә-менә янарырга әзер булып, желекләребездә, бар күзәнәгебездә гомеребез буена утырып калган. Ходаем, дим, ятлар аңламас бәләкәй бәхетемә куанып, әле дә исәннәр без. Төзәлмәс чирдән төннәр буе сызлап чыксалар да, шөкер, «бозда тәпиләнгән» аяклар да йөреп тора. Бүгенгенең кадерен тирәнрәк белү өчен ул чактагыларны да хәтерләштергәләп, язгалап тору ярыйдыр— Шамил замандаш әйткәндәй, бу безнең бурычыбыз.

Үзең белгән гыйбрәтләрне сөйләп һәм язып кем каршындагыдыр бурычны үтәү зарурлыгы Шамил Маннапов кына ачкан әдәби алым түгел, билгеле. Әнә Чыңгыз Айтматовның Алтынае да («Беренче укытучы») «Дюшен турында сөйләү—кешеләр алдында минем бурыч», ди. Нәкъ шундый бурыч тойгысы бу яна заманда Айдар Хәлимне моңа кадәрге публицистик әсәрләреннән бик нык үзгә, яктылык-жылылык һәм миһербанлык бөркеп торучы «Минем Түгәрәк Имәнем» китабын язарга этәргеч һәм аңа биниһая олы хезмәтне унышлы башкарып чыгарлык көч-куәт биргән. Автор аны хәтта «васыять» дип атаган.

Әмма Шамил Маннапов үз китабында бурычлыкның мәгънәсен чиксезлеккә кадәр киңәйткән. Әтиәнидән һәм остазларыбыздан тыш, бергә уйнап үскән, укыган, холкыбыз формалашуга ярдәм иткән сабый чак дусларына, гөнаһсыз беренче мәхәббәтләребезгә дә әжәтле без. Безне аңламаган, ни сәбәп беләндер кире каккан мәхәббәтебез дә нәрсәгәдер өйрәткән, сабак биргән, сынаулар аша чыныктырган бит. Шундый сынауны кичә алмыйча яшьтән үз-үзенә кул салучылар да очрый бүген. Яшьлектәге әрнүләребез дә күңелләребезне каралтып, түбәнлеккә төшереп, егып калдырмаган, еллар узган саен сагынып хәтерләрлек монлы сагышка гына әверелгән. Һәрхәлдә, шагыйрь Шамил шулай сурәтли.

Менә «Акмангай» хатирәсе. Акмаңгай—өстенә сыер басып, йөри алмаслык гарипләнгән кәжә бәтие ул. Үсмер малайга артык мәшәкать: ул аны һәркөн күтәреп авыл читендәге чирәмлеккә илтергә, уен арасында да килгәләп, үләнлерәк урынга күчереп куярга тиеш. Әйе, тиеш, чөнки «ул инде тирә-юнендәге үләнне такырайткан була, ак маңгае белән яктырып мине көтә. Мөлдерәп торган зур күзләрендә ялвару-үтенү...» Ә малайның әле уйнар чагы. «Кайвакыт уен белән мавыгып озаграк торыла. Андый вакытларда бәрәнем миңа күтәрелеп карамый. Ак маңгайлы башын озак ятудан изелеп-чәбәләнгән йонлы янбызына салып, күзләрен йомган була. Мөгез төрткән маңгаен сыйпагач кына мәэлдәп куя. Әйтерсең лә шулай соңгарып килүемә үпкәләвен белдерә иде. Куе сусыл үләнгә борыны тигәч кенә үпкәсе басылгандай «керт-керт» итеп ашый башлый. Янә миңа карап-карап ала. Янәсе, бар инде, уйнасаң уйна».

«Бар инде, уйнасаң уйна». Шушы бер жөмләдән дә күренеп

тора: гадәти генә бәти вакыйгасы да әдип өчен эзсез узмаган. Югыйсә, моның кадәр матур һәм табигый итеп сурәтли, укучы күз алдында жанландыра алыр идемени! Бу сөйкемле бәти—хужасының иптәшләре белән уйнарга теләвен дә аңлый торган гарип жан иясе—«кәжә көтүчесе» белән аның күз атып йөргән Мәүлиясе арасына киртә булып ята, аларның бер-берсеннән ерагаюына сәбәпче була. Әмма, язмыш «шуклыгы» түгел диген: күп еллар үткәч, шушы Мәүлия үзе каты чирли һәм аңа кәжә сөте эчеп дәваланырга киңәш бирәләр.

Юк, «Акмаңгай»дагы кызның бәхетсезлегенә куанмый автор, киресенчә, кыз белән бергә әрни, үкенә, сагышлы уйга бата. Теге чакта, «кәжә көтүчесе» дип кыз тарафыннан кире кагылгач, өенә йөгереп кайтып, бичара Акмаңгай өстендә балта уйнатып алган иде бит ул. Ярый үз-үзен мәрхәмәтсез адымнан тыеп кала алган. Жан сыкравын гомере буена баса алмас иде, мөгаен. «Үземә төбәп караган зур моңсу күзләрдән генә кинәт айнып киткәндәй булдым. Акмаңгай яткан салам өстеннән миңа... әни күзләре карап тора иде! Сугарга дип күтәрелгән балтам кулымны аска сөйрәп төшеп китте... Үзем дә Акмаңгайның нечкә муеныннан кочып, елап жибәрүдән чак кына тыелып калдым».

«Әни күзләре» очраклы катнашмый бу вакыйгада. Гарип бәтине «чалып ташлаудан» баштарак та әнисе алып калган, шулай итеп, балаларына миһербанлык сабагы биргән иде бит.

Билгеле, чынлыкта вакыйга төптөгәл «Акмаңгай»да сурәтләнгәнчә булмагандыр. Китап авторы хикәяистәлекләрендә төрле хәлләрне бер каһарманының гомер юлына салып берләштергән, кеше язмышларын да мәгълүм дәрәжәдә гомумиләштергән, әмма берсен дә чынбарлыктан аерып илаһилаштырмаган. Нәтижәдә «Мәңгелектән елмаю» каһарманнары бездән, безне урап алган, көндәлек аралашып яшәгән кешеләрдән яхшырак күңелле, мәрхәмәтле булулары, ихласлыклары, тормыштан тәм-ямь табып яши белүләре, рухи байлыклары, табигыйлекләре белән шактый аерылып торсалар да, тормышчаннар, укучыны ышандыралар. Әдип үзе бурычлы кешеләрнең бөтенесен әнә шундый итеп күрә, алар турындагы китаптан да укучы күңеленә аклык сирпелә. Ирексездән, китап тараткан жылы дулкыннарга көйләнәсең. Чөнки, әнисе Сәрмәдия Зариф кызының якты рухына багышланган «Әгәр, балам, син кайтмасаң» исемле хикәят-хатирәсендә Шамил Маннапов бик урынлы язганча: «изгелек—изгелекне, явызлык—явызлыкны, ышанмау—ышанмауны, ышаныч—ышанычны, мәхәббәт—мәхәббәтне, шигърият—шигърияпне тудыра». Күрсәнә, шушы гапгади дөреслекне дә онытттык бит без. Онытып бетермә-сәк тә, көндәлек яшәү кагыйдәсе итмәдек аны. Уйларыбызның гел авырая, чырайла-рыбызның һаман караңгылана баруын да шуның белән аңлату урынлыдыр: без тирә-ягыбызга яшьле-зарлы күзләр белән каш астыннан гына карыйбыз һәм ул да безгә нәкъ шулай жавап бирә. Шамил Маннапов исә бөтенесенә миһербанлы якты караш салу биекле-генә күтәрелә, хәтта мәңгелектәгеләрнең дә елмаюын күрә алган, чөнки ул китап каһарманнарын тормыш төбе пычрагыннан шактый өстә итеп сурәтләгән. Һичшиксез, үзе дә шулар арасында. Инде безне дә үз биеклегенә дәшә. Шагыйрьлеге дә Аллаһтан һәм... әнисеннән икән. Сәрмәдия-Ана солдаттагы Шамилгә хат яздырганда һәрвакыт шигырь юллары белән тәмамлый, аннары улы шулай язарга күнегеп китә, туры мәгънәсендә «шигърият—шигъриятне тудыра». Әлбәттә, гади иярү, тутый кош кабатлавы турында сүз бармый монда. Әнисе күңелендәге шигырь уты улына сабый чагында ук күчкән, аның да жаны шигъри дулкынга күптән көйләнгән инде. Ә шигъри хатка шигырь белән жавап бирүе—шул утның, шул дулкынның тышкы чагылышы гына. Әтисе дә буш күңелле түгел Шамилнең. Әнә ул, бәрәңге бакчасында эшләгән вакытта, су типкән урынга тап була, шул урынны казып чишмә итә дә үзләре тапкан «чишмә суын дөньядагы бернинди су белән буташтырмый да, алыштырмый да» («Су тәме»). Инде улы да «су тәменә сизгерләнә бара» һәм «Туган жир суы башка сулардан аермалы була икән шул» дип нәтижә ясый.

Шамил замандашның әтисенә бәйле хатирә-хикәятләре дә туган туфрак, туган жир, хәләл ризык һәм аның кадере төшенчәләре белән тыгыз

үрелеп язылган. Менә «Кибән башы» истәлеге. Автор урамдагы чүп савыты янында «тәмәке төпчекләре арасында тилмереп яткан «кибән башы»на карап борчулы уйга талган. Нәрсә бу—инде ачлыкның ни икәнен белмәгән (һәм белергә дә язмасын!) яңа буын кешеләренең мәнсезлегеме, әллә кешелекнең тулаем хәтерсезлегеме? Чүп арасындагы ипи кыерчыгы янышнан гамьсез яшьләр генә түгел, төрлесен күргән өлкәннәр дә илтифатсыз гына үтеп китә ич. Бәлки шагыйрьгә дә шулай гына узаргадыр? Бөтенесенә хәсрәтләнә башласаң, башың кайгыдан чыкмас. Инде чүп савыты янына икмәк кисәге генә түгел, яңа туган бала да ыргытыла башлаган чор бит, бәлки күнегәседер аларга? Юк шул, йөрәге шагыйрьгә ваемсыз булмаска куша. Ваемсызлык болай да чиктән ашкан. Кирәк урында—сызлана, сокланыр күренешкә соклана белми торган хис-тойгысыз «урта» кешеләргә әверелеп барабыз түгелме? Мәшһүр җырчыбыз Вафирә Гыйззәтуллинаның милләтне, аның иреген һәм дәүләтчелеген яклап җаны кыйналуын, көрәшче булып мәйданнарга чыгуын үзе исән чакта күпмебез хуплады. Инде җырчы юк. Әгәр ул бер депутат, дәүләт түрәсе яисә... законлы карак булса, милләткә әллә ни файда эшләмәсә дә, аны бүтән машиналар әйләнеп үтә, юл биреп кала торган «дәрәҗәле» автомобильдә «азау ярган» шоферлар йөртер иде. Бервакыт шул фидакарь җан Татарстан телевидениесенең галимәләр белән үткәреләчәк сөйләшүендә катнашырга теләгәч, гыйльми исеме юклыкны күзенә төртеп әйтеп, «әйдә бар, җырлавыңны бел» дигән кебек сүзләр белән куып чыгаргандай иттеләр. Тик менә аның милләткә әйтер сүзе кайсы фән кандидатыныкыннан кимрәк булды икән? Җырчының көрәш җырларын исә иң элек нәкъ менә шагыйрьләр, шул исәптән Шамил Маннапов ишетеп алды. Чөнки ишетергә «бурычлы» иде алар. Шамил шигыре «Хәвеф килгән чакта» дип исемләнгән.

...Әй, сандугач!
Сина соклансам да,
Шөбһә биләп алды җанымны:
Син бит яклаучыбыз,—
Мәрхәмәтсез язмыш
Каермасмы канатларыңны?...
Син сакларга чакырасың, җырчы,
Халкың оя корган тирәкне...
Әйе,
Хәвеф килгән чакта сандугач та
Була икән бөркет йөрәкле...

Ни көенеч, шагыйрьнең шөбһәләнүе иң начар яктан акланды һәм аңа шигырен «артык моңлы, артык сагышлы» дулкында дәвам иттерергә туры килде:

Болай түгел идем ләса,
Нигә
Күзләремә кайнар яшь килә?
«Хушлашырга безгә иртәрәк бит әле,
Иртәрәк бит әле...» Вафирә!

Строфаның куштырнаклар эченә алынган өлеше—Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның «Аккошлар» шигыреннән. Өч талант—шагыйрь Равил Фәйзуллин, моңчы Фасил Әхмәт һәм Вафирә Гыйззәтуллина иҗат иткән бу җыр җир йөзендә милли рухлы бер генә татар калганда да яңгырар әле. Һәм кемдер бөекләрдән истәлеккә калган ул җырны дөньяга кат-кат ишеттерү өчен үзен бурычлы санар. Шушы хәл үзе генә дә безнең киләчәккә өмет-ышанычыбызны арттыра.

Татар өчен хәтернең ни икәнен аңлап бетерәбез микән без? Ничә гасыр буе дәүләтсез яшәп тә, милләт буларак юкка чыкмаганбыз икән, акыл ияләребез бу могҗизаның сәбәбен нәкъ менә хәтеребез җуелмау белән аңлаталар. Моны читләр дә яхшы белә, шуңа күрә төрле юллар белән безнең тарихыбызны, хәтеребезне оныттырырга омтылалар. Телне кысрыклап, кулланылышын тарайту (бүген дә телебез дәүләт эшләрендә катнашмый, диярлек), әледән-әле әлифба алмаштыру, мәчетләрне җимерү һәм зиратларны сөрү, чын тарихыбызны яшерү һәм милләтара никахларны хуплау әнә шул «бөек» максатка хезмәт итә. Милли һәм тарихи хәтере көчлерәк булган авыл халкы «баш миен селкетү»ләргә аеруча еш тарыды: кумәкләшү һәм бүлгәләнү, авылларны эрешәндерү һәм күчерү, милек формаларын үзгәртеп тору, очыкырые булмаган сүтеп корулар һәм һәр «яңалык» унаеннан искене сүгүләр...

«Мәңгелектән елмаю» авторы да бер көнне дачалары янындагы урманга уйсыз-гамьсез, «җир казып арыгач,

бераз бил яздырып кайтыйк дип» кенә аяк баса. Һәм шунда... кабер өстенә куелган язулы мәрмәр тактага юлыга. Монда инде авыл да юк, зират та, кабер дә беленми, бердәнбер кызганыч истәлек булып шушы такта гына җирдә ята...

Без җир куенындагы якыннарыбызны еш искә алабызмы соң? Каберләрен генә булса да беләбезме? Туры җавап безнең файдага түгел. Һәм әтисез үскән буынның мең фаҗигасе янына мең дә беренчесе килеп өстәлә: менә монысы синең фәлән елда гүр иясе булган кардәшең, менә болары әби-бабаңнар кабере, дип, сабый чагыбыздан җитәкләп күрсәтеп йөрүче, чардуганнарын буярга өйрәтүче, дәвам иттерергә син җаваплы дип, шәҗәрәбезне төзеп бирүче булмады ич безгә. Боларны безнең күңелләргә нәкъ менә сабый елларыбызда салырга кирәк иде. Ул чакта әтиләребез булмады, ә кардәшләребезнең, әби-бабаларыбызның кемнәр булуы турындагы сорауларыбызны әниләрнең ишетергә вакыты булмады. Хәлбуки, бер гаепсезгә иленнән сөрелгән, хөкем ителгән, бәхет эзләп чыгып киткән җирендә хәбәрсез югалган—әниләр моны ничек сөйләсен. Байтагыбыз хәтта әтисенең каберен дә белми, чөнки алар сугышка китеп, чит җирләрдә ятып калганнар.

Әти белән яшәү тәҗрибәсе булмаган, әтисе янында кечкенә көрәге белән чишмә дә казымаган, агач та утырталмаган безнең чордашлар күп очракта үз балаларын да күңелләре уртак дулкынга көйләнми торган, өлкәннәргә һәм тарихыбызга ихтирамсыз итеп үстерделәр—хәтер чылбыры йомшады. Белмим, безнең бу мокытлыгыбызга мәңгелектәгеләр ничек карыйдыр? Елмаялардыр дип уйлый алмыйм. Шамил Маннапов та ташландык кабер ташы яныннан җанына гыйбрәтле авыр уйлар төяп кайтыр сукмакка борыла. «Кайтырга кирәк... Кайтырга...»—дип уйлый ул, әлеге сүзләргә күптөрле мәгънә салып. Туган авылына кайтып, яшьли үлгән кадерле апасы каберен карыйсы, чардуганын төзәтәсе бар аның. Тагын, хәтеребезне ешрак яңарту, күңелебездән үткәннәргә кайтып, кылган гамәлләребез өчен хисап бирү, бик күпләргә вакытында әйтелми калган җылы сүзләребезне әйтү зарурлыгын да искәртә бу сүзләр.

Әйе, үткәннәр каршында—әҗәтле, киләчәк каршында—җаваплы икәнбез. Күңелендә йөрткән гомерлек бурычлы булу хисе шагыйрь Шамил Маннаповка әнисе булып дәшкән һәм изге гамәлгә көч биргән. Бәлки, барлык әниләр шулай дәшәдер дә, ишетергә сизгерлегебез генә җитмидер?!

**Рафыйк ШӘРӘФИЕВ**

*Юмор һәм сатира*

## Фәнис Яруллин

# БӘХЕТЛЕ ПАР

Көннәрдән бер көнне, алмагачлар туй күлмәге кигән кәләштәй балкып утырганда, сандугачлар һәр ботакка кунып мәхәббәт җыры җырлаганда, Минсылу исемле тузганак башлы кыз көзгегә карады. Карады да җилләрдә җилфердәп чияләнеп беткән чәчләрен тарарга тотынды. Тарап җибәргәч чәчләр болыттай кабарды. Аларның йомшак кагылуы муенны, яңакларны иркәләде. Кызга рәхәт булып китте. Ул, булгач булсын инде дигәндәй, кием шкафыннан алып, сылу тәненә сыланып торган ап-ак күлмәген киде. Аякларына яңа туфлиләр дә киеп җибәргәч, Миңсылуыбыз бакчадагы алмагачка охшап китте. Мондый матурлыкны өйдә яшереп яткыру гөнаһ икәнлеген күңеле белән сизенгән кыз, чәч төпләренә тәмле хушбуй тидергәләп урамга атылды. Гаҗәп хәл, бүген һичкайчан булмагандай, ата казлар юаш, хулиган малайлар ягымлы, җилләр йомшак иде. Урамга чыгуга ук кызның тузган чәчләреннән җилләр сыйпады, битләреннән кояш үпте.

Туры килүен әйт әле: нәкъ шул көнне үзенең кәкре аякларын каплар өчен киң балаклы яңа чалбарын киеп юеш танаулы, йомры башлы Минтимер дә урамга чыкты. Чыгу белән күзенә алмагач кебек ак күлмәкле кыз чалынды.

—Һәй,—диде ул,—урамга алмагач үскән дисәм, син икәнсең.

Бу сүзләрдән тузганак чәчле кызның йөзенә ялкын йөгерде.

—Мин шул,—диде ул.—Ә син кем дип белдең?

—Кунак кызыдыр дип уйлаган идем,—диде Минтимер, кояшта янган битенең кызыша башлавын сизеп.

—Нигә?

—Безнең авылда мондый чибәр нәмәрсәләр үсмидер дип йөри идем.

Кыз тузганактай чәчләрен артка җибәреп, башын чөеп куйды. Бу минутта ул үзен җирнең иң гүзәл бер заты итеп тойды. Йөрәк тибеше икеләтә-өчләтә ешайды, тамырларда кан агышы кызуланды, күңеле диңгездәй дулкынланды. Нindидер хисләр пәрдәсе аша карагангамы, каршында басып торучы кәкре аяклы, юеш борынлы малай күршеләрендәге Минтимер булып түгел, җиде диңгез кичеп, биек-биек Каф тауларын үтеп килгән бер баһадир булып күренде. Ул зәп-зәңгәр күзләрен тутырып Минтимергә карады да:

—Һы, безнең авылда да күзле кешеләр бар икән,—диде.

—Күзем әле генә ачылды,—диде Минтимер югалып калмыйча.

Кыз: «Минеке дә!»—дияргә уйлаган иде, үзенең шыксыз үрдәк бәбкәсеннән гүзәл аккошка әверелүен тоеп, әйтмичә калды.

Язның исерткеч һавасы тәэсир иттеме, алар җитәкләшеп су буена төшеп киттеләр. Яр башына басып, бөтерелеп-бөтерелеп аккан суны, бер-берләрен куышып йөгерешкән дулкыннарны карап утырдылар. Шул чагында, һич көтмәгәндә, офыклар артыннан кулъяулык кадәр генә болыт килеп чыкты да чиләкләп яңгыр яварга тотынды.

—Ай күлмәгем, ай туфлиләрем!—диде кыз бик нык хафаланып.

Минсылуның күлмәге һәм туфлиләре өчен борчылуы Минтимер күңеленә хуш килде. «Әйбер кадерен белә!»—дип беркетеп куйды ул. Һәм:

—Туфлиләреңне пычраттырмабыз,—диде ышанычлы итеп, аннары кызны

күтәреп алды.—Ә күлмәгенне үтүкләрсең. Синең күлмәк кенә түгел минем дә чалбар пычрана әле монда.

Өйгә кайтып житкәнче кызны кулыннан төшермәде ул.

Икенче көнне алар кабат очраштылар. Кызның өстендә һәрвакыт киеп йөри торган чуар күлмәк, аякларында резин галошлар иде.

—Нигә ак күлмәгенне кимәдең?—диде Минтимер.—Аягыңда да галошлар...

—Яңгыр явып пычратса?..

—Әйе шул. Менә мин дә иске чалбардан чыктым. Теге көнне балаклары пычранып беткән иде. Чистартып жаным чыкты. Үтүкләп сандыкка салып куйдым әле.

—Дөрес эшләгәнсең. Нигә әйберне кадерсезләргә?

Кесәдәге акча кебек көннәр бер-бер артлы юкка чыга торды. Минсылу белән Минтимернең аралары якынайганнан якынайды.

—Торган саен ныграк ошый барасың син миңа,—диде егет көннәрдән бер көнне.

—Син дә,—дип пышылдады кочактагы кыз.

—Минем кай жирем ошый сиңа?—диде егет бу сүзләрдән эреп.

—Саранлыгың.

—Саранлыгым?

—Әйе, каруным минем.

—Миңа да бит нәкъ менә синең карунлыгың ошый,—диде егет.

—Ә бәлки мин саран түгелдер,—дигән булды Минсылу канәгать калып.

—Ак күлмәктән, яңа туфлиләрдән чыккан көнне яңгырява башлагач куркудан жаның уч төбенә төшеп китә язганны онытма.

—Үзең соң, үзең. Телогрейкаңның бер төймәсен югалткач, капка төбендәге бүрәнәләрне пыран-заран таратып ике көн эзләдең.

—Барыбер таптым.

—Таптың шул! Нигә төймә кадәр төймәне әрәм итәргә? Нәкъ менә шуның өчен яратам да мин сине.—Кыз үз сүзләренең ихласлыгын расларга теләпме, Минтимернең сакчыллыгына сөенепме—тын кичне яңгыратып көлеп жибәрде.

—Бигрәк матур көләсең инде, алтыным,—диде егет сөйгәненә сокланып.—Син көлгәндә авызыңа янчык тотып торсаң—көмеш тәңкәләр белән тулыр иде.

Мондый мактаудан Минсылуның башы әйләнеп китте.

—Хәзинәләр чүлмәгем минем,—диде ул егеткә кысыла төшеп.—Без ул көмешләрне чүлмәккә тутырып барырбыз.

—Чүлмәкне урласалар?

—Урлатмабыз. Без аны жиде кат жир астына күмәрбез.

—Молодец! Нәкъ мин уйлаганча уйлыйсың. Әллә соң, матурым, өйләнешеп жибәрәбезме? Көмеш тәңкәләреңне читкә сибеп йөргәнче, бөтенесе үзебездә калыр.

—Дөрес сөйлисең, батырым. Байлыкны саклап тотарга кирәк. Нигә буш урамга көлеп, көмеш тәңкә сибәргә?!

Алар шулай вәгъдә бирештеләр. Вәгъдә бирешү шатлыгыннан күптәнге вакыйгаларны искә төшерә-төшерә урам урадылар.

—Хәтереңдәме көмеш тәңкәм,—дип башлап китте Минтимер,—бервакыт без урманга чикләвеккә барган идек. Юлыбыз уңды, тубалларыбыз тулды. Әмма кайтканда инеш аркылы чыгарга туры килде дә шунда агымсуга синең кулыңдагы ике чикләвегең төшеп китте. Син тубалыңны минем кулга тоттырып, су өстеннән йөзеп барган чикләвекләренә ташландың. Су агымы сине бөтереп алды, бата башладың. Мин дә сиңа ярдәм итә алмадым, чөнки ике кулымда икебез көне буе жыйган чикләвекләр. Әгәр шунда кәтүче Әхмәт абый очрамаган булса, бүген без синең белән сайрашып утыра алмас идек, көмеш тәңкәм.

Минсылу бу вакыйганы үзе дә онытмаган икән, Минтимер сөйләгәннән соң ул тирән итеп көрсенеп куйды.

—Әйе, шул чикләвекләрне тәки тота алмадым бит, әрәмгә агып киттеләр.

—Әрәм булган нәрсәләрне саный китсәң бик күп инде алар,—диде Минтимер,—минем дә жанны һаман бер нәрсә кимерә.

—Нәрсә ул?

—Сиңа сөйләгән идем бугай инде. Аш исең әйтүем. Пешергән саен әрәм

булып һавага тарала бит. Әгәр шуны жыеп ала торган берәр нәмәкәй уйлап тапсаң, мәйтәм.

—Табарсың әле, жаныем. Синен башың йомры. Ә бәлки бергә тора башлагач икәүләп уйларбыз.

—Карале Минсылу, менә хәзер генә башыма бер уй килде.

—Нинди уй?

—Бигрәк, мәйтәм, кешеләр акча тота белмиләр инде. Теге кыланчык Кирамнар машина алганнар. Беркөн кукраешып хатыны белән районга бараларые.

—Ә-әйе, ишеткәнием,—диде Минсылу.—Аларның кесәсенә акча керсә тавык булып кытакларга гына тора шул.

—Машинага бензины, мае гына күпме кирәк...

—Ватылса, төзәтергә никадәр расхут чыга...

—Барасы жиренә рәхәтләнеп автобус белән барып булганда, ни пычагыма ул машина?!

—Әйтсәм әйтим инде, батырым, мин әле автобусларына да күпвакыт түләми йөрим. Яшьрәк шоферлар булса күз кыскалап алам да урындыкка посам.

—Анысы әйбәт,—диде Минтимер бераз көнләшеп,—буш йөрүеңне хуплыйм. Әмма-ләкин яшь шоферларга күз кыскалавың...

—Әллә көнләшәсең инде?

—Көнләшәм дип... Ни бит, көнләшүдән түгел...

—Ярый, ярый, чуен чүлмәгем, яңадан күз кыскаламам. Буш йөрүнең бүтән юлын табармын.

—Менә ичмасам, акыллы авыздан акыллы сүз.

Егет чупылдатып мәгъшукасының иреннәреннән үбеп алды. Аралар тагын да якынайды.

Теләкләр дә, йөрәкләр дә бер икәне беленгәч кавышуны озакка сузмаска булдылар.

—Туйга кемнәрне чакырабыз?—диде егет.

—Безнең яктан...—Кыз бармакларын бөгә-бөгә туган-тумачаларын саный башлады. Жәмгысы егерме бер кеше булды.

—Хәзер мин саныйм,—диде Минтимер. Ул да нәкъ үзенең жанкисәккәе кебек авыз эченнән бер исем әйткән саен берәр бармагын бөгә барды. Унжидегә житкәч саналасы кешеләр бетте.—Икебезнекен бергә кушсак утыз сигез, шулар янына үзебезне дә өстәгәч кырык кешегә жыелабыз икән,—диде Минтимер һәм бу кадәр саннан куркып калды. Минсылуның күңелен дә: «Кырык кешене сыйларга күпме сый кирәк!»—дигән уй чәнчеп үтте.

—Юк,—диде ул кискен итеп,—нигә моның кадәр кеше жыярга?! Иң-иң якын кешеләрне генә чакырырга кирәк.

Янадан санарга тотындылар. Бу юлы икесенеке бергә егерме өч чыкты.

—Егерме өч тә күп,—диде Минтимер.

—Әйе,—дип килеште аның белән Минсылу.

—Әти-әниләрне генә чакырыйк,—диде кияү.

—Бик дөрес,—дип килеште аның белән кәләш.

—Туй да итеп тормабыз, никах кына укытырбыз, шуның белән вәссәлам,—диде кияү.

—Никах ашына бер тавык суярбыз,—диде кәләш.

—Анысы шулаен шулай,—дип башын кашып алды егет.—Ни бит, ни... Төптәнрәк уйлап карасаң, тавык ул сыер бәясенә төшә икән.

—Ничек?

—Ничекме? Менә, мәсәлән, чутлап карыйк. Бер тавык елына 300 ләп күкәй сала, ди. Өч йөз күкәйдән өч йөз чебеш чыга. Алар үсеп житкәч үзләре күкәй сала башлый. Ә өч йөз тавыкның күкәеннән!—Минтимернең тыны кысылып куйды.

—И-и башлыкаем минем,—дип, Минсылу мәхәббәт тулы күзләрен Минтимергә төбәде.—Бик дөрес сукалыйсың. Ничек күрә торып өч йөз тавыкны бер туйга әрәм итәсен. Барыбер ашап бетерә алмыйлар бит аны. Әнә Гөлчәчәк белән Галимжаннар туйдан калган ризыкларын этләренә ашатканнарые, этләре ай буе маемлап йөрде. Чак үлми калды. Хәзер итле, майлы ризыкларга якын да килми, ди.

—Шулай булмыйча! Туй дип үгез хәтле үгез суй әле. Бигрәк артыгын кыландылар бит. Район ашханәсеннән әллә нинди тортлар, чәкчәкләр пешертеп кайтарттылар. Ул хәтле ризыкны өстәлләре ничек күтәргәндер.

—Кыланышлары кырга сыймады инде,—дип ялгап алып китте сөйгәне Минсылу.—Галимҗан Гөлчәчәгенә җирдән өстерәлерлек күлмәк алган. Итәген арттан ике бала тотып бармаса, абынып адәм көлкесенә калачак иде инде. Ни хаҗәтемә ул бер киеп салыр өчен шундый кыйммәтле күлмәк?!

—Үзен көмеш, сүзләрен алтын, кадерлем. Шаккатам мин: бераз гына алгарак карап яши белмиләр. Алгач-алгач күлмәкнең көн саен киярлеген алырга кирәк.

—Анысын әйтәсен әле син,—дип эләктереп алды Минсылу.—Кочак-кочак чәчәкләр ни пычагыма диген. Җәй көне булса бер хәл: болыннан җыйдын, кайттың.

—Ул розаларның бервакыт бәясен күреп уштан язган идем,—диде Минтимер.

—Аннары видакка төшереп күпме акча түккәннәр.

—Ул фотокарточкаларын әйт тагын. Атлаган саен чарт та чырт.

—Әкәмәт инде, әкәмәт.

—Балдакларына күз салдыңмы? Адәм күтәрмәслек иде бит.

—Әйе, әйе. Әле дә күз алдымда: ярты бармакларын алып тора иде. Син каршы килмәсән, мин туй балдакларын тимерчедән генә ясатып алмакчы булып торам. Урамнан бакыр тәңкәләр дә табып кергән идем. Син каршы түгелсеңдер бит, көмешем?

—Каршы, бик каршы,—диде Минсылу.

Минтимер аптырап үзенең мәгъшукасына карады. Минсылу беренче мәртәбә әле ана каршы төшә иде.

—А-алайса,—дип чигенә башлады Минтимер,—бик теләсән... Тимерчедән ясатырга риза булмасаң...

Минтимернең: «Кибеттән алтын балдаклар алырбыз»,—дияргә теле әйләнмәде. Ул ык-мык килгән арада Минсылу:

—Туй ясамагач балдак ни пычагыма?—дип куйды.—Йә тимерче шуны ясаган өчен бер ярты сорый башлар.

—Ә-ә, әйе шул,—диде Минтимер кәләшенең зирәклегенә сокланып.—Яртының бәясе дә ай-яй-яй бит хәзер. Шаккатам мин бәйрәм дип, туй дип тиктомалдан шампаннар, әллә нинди аракылар алган кешеләргә. Аерткан сөтнең катыгыннан әйрән ясап эчсәң корсакка ук рәхәт.

Сайлаган киявенең тирән акылына торып-торып хәйран калды Минсылу. «Мондый кеше белән тормыш итәргә була. Бу тапканны югалта торганнардан түгел»,—дигән сөенечле уйлар үтте аның башыннан. Һәм үзенең дә төшеп калганнардан түгел икәнлеген күрсәтәсе килеп:

—Әллә никах та укытып маташмыйбызмы?—диде.

—Дө-дөрес сукалыйсың бит син, кәләшем,—диде Минтимер мәгъшукасының фикерен эләктереп алып.—Никах укытсаң муллага хәер бирергә кирәк була. Иң яхшысы, сине җитәклим дә өйгә алып кереп куям.

—Әйбәт, әйбәт,—диде акыллы кәләш.—Юкса мин ат яллап, авыл урап йөрүләр, бала-чагаларга көмеш тәңкә сибүләр күпмегә төшәр икән дип утыра идем. Җитәкләп кенә алып керсәң бөтен мәшәкатьтән берьюлы котылабыз бит.

—Расхутларыннан да,—диде Минтимер.

—Әйе, расхутларыннан да.

Мондый сүзләрдән хисләре йөрәгеннән тулып түгелә башлаган кияү ямаулы куфайкасы белән кадерлесен төрде. Алар күнелләре белән бер-берләренә якынайганнан-якыная бардылар.

—Ничек мин сине элегрәк күрмәгәнмен?—диде егет.

—Мин дә шул сорауга җавап таба алмыйча аптырап утырам әле,—диде кыз.—Бер өй аркылы гына яшәп, шундый сукырлыгыбызга шаккатам.

—Синең теге ак күлмәк ачты минем күзләремне. Шуны киеп чыкмаган булсаң...

—Алгач ике ел кимичә җәлләп сандыкта яткырганыем инде мин аны.

—Ызначит көне килеп җитмәгән булган. Мина яна чалбар алганнарын көткәнсен.

—Шулайдыр инде.

—Беләсенме, көмеш тәңкәм, өйләнешеп жиффәргәч синең ул ак күлмәгенне минем киң балаклы чалбар белән сандыкка салып куярбыз. Ятарлар шунда яшьлек истәлеге булып. Яшьлекне сагынганда: «Әй җүләр чаклар булган бит, шушындый кыйбатлы күлмәкләр киеп акча туздырып йөргәнбез»,—дип үз-үзебездән көләрбез.

—Әйе шул.

Бөтен сүзләр сөйләнеп беткәч юнылмаган бүрәнә өстендә тын гына утырдылар. Бераздан кызның күнеленә бер уй килеп, иңендәге куфайкасын салып атты.

—Беләсенме нәрсә, йомрыбашым?—диде бик зур ачыш ясагандай.—Без бер нәрсәне уйлап җиткермәгәнбез бит.

—Нәрсәне, көмеш тәңкәм?

—Син мине үзегезгә җитәкләп алып чыгам дидең бит.

—Әйе, шулай дидем.

—Җитәкләп алып чыккач ул барыбер өйләнешү була түгелме соң?

—Без өйләнешергә җыенабыз ләбаса.

—Җыенуын җыенабыз,—диде кәләш сүзенең ибен таба алмыйча.—Ни бит, йомрыбашым, җитәкләп алып кергәч, ирекле рәвештә, ягъни үз аякларым белән сезгә барып кергән булам бит мин.

—Соң, болай да...

—Тукта, тукта, йомрыбашым, мин сүземне әйтеп бетермәдем әле.

—Әйтеп бетер алайса.

—Сүзем шул: үз иркем белән сезгә килен булып төшкәч бирнәсе, бүләге кирәк булачак. Иң яхшысы, син мине урла гына.

—Урларга?

—Ә нигә? Элек кызларны урлаганнар бит.

—О-о, акыл чүлмәгем минем. Менә шәп! Куфайка бар. Шуңа төреп, чалбар каешы белән бәйлим дә өйгә апкайтып куям. Иртәгә әниләренә безнекеләр кереп әйтер. Кирәк тапсалар, үзләре коймак пешереп самавыр куярлар әле.

Әйтелгән сүз—атылган ук. Егет үзенең чалбар каешы белән сөеклесен ныклап бәйләде дә өйләренә алып кайтып ташлады.

—Бу сезнең киленегез, минем хатыным булыр,—диде ул аптыраган ата-анага.

Һәм, алар татулыклары белән авылны сокландырып яшәп киттеләр. Кулларына акча керсә, алар аны чүлмәккә салып, чүлмәкнең авызын таба белән томаладылар да кара төндә бәрәңге бакчасындагы өянкеләр ышыгына тирән итеп чокыр казып, җиргә күмә бардылар. Мондый минутларда аларның һәр икесенең йөзләрендә нур балкый, йөрәкләре шатлыктан шашардай булып тибә иде. Күмелгән чүлмәкләр күбәйгән саен уртак сөенечләре дә арта барды. Алар бик-бик бәхетле иде. Бәхет өчен күп кирәкмени?! Кемнәрдер үз байлыгын ташпулатлар итеп күккә күтәрә икән—күтәрсен. Андыйлар шыр дурак. Ә менә йомрыбаш Минтимер белән тузгакчәч Миңсылу бөтен байлыкларын җиргә күмү белән бәхетле. Алар хәтта үзләренең бәхетле икәнлекләрен дә чит-ят күзләрдән яшерергә тырышалар. Акча туздырып машинадыр-чуттыр алучылардан, бәйрәм дип өстәл тутырып кырык төрле сый әзерләүчеләрдән, кеше ишетмәсен өчен базга төшеп көләләр дә, көлеп эчләрен бушаткач кыяфәтләренә юләрлек билгеләре чыгарып, үз эшләренә керешәләр.

Бәлки сез минем бу сүзләремә ышанмыйсыздыр. Ышанмасагыз, әнә, Шыттырдым авылына барып Минтимерләрнең бәрәңге бакчалары артында үсеп утыручы өянкеләрнең төбен казып карагыз. Шунда чүлмәк-чүлмәк акча табарсыз. Дөрес, ул акчалар йөрүдән туктаган, кыйммәтләрен җуйган булыр. Тик анысы өчен аптырамагыз. Аларныкы гына түгел, хөкүмәт банкына салган кешеләрнең дә акчасы юкка чыгып тора. Ин мөһиме, байлыгыңны кассага салудан яки җиргә күмүдән сөенеч табу. Ә калганы пүчтәк. Вәт шулай, дуслар. Сөенеп яшик.

⁂

## *Каләмдәшләребез*

# БЕЗ–БЕР ТӨРКЕМНӘН

*Без әле татар теле һәм әдәбияты бүлегендә уку аеруча престижлы саналган заманнарда – 1964-1969 елларда Казан дәүләт университетында белем алган буын. Әдәбият һәм тел белеменең корифейлары Хатип Госман, Диләрә Тумашева, Мөхәммәт Мәһдиев, Ибраһим Нуруллин кебек галимнәрдән сабак алган төркем. Ул елларда бөтен Казан университетына, татар теле һәм әдәбияты бүлегенә нибары егерме биш егет һәм кыз алына иде. Имтиханнар каты, конкурс зур. Ике ел стажың булмаса, университетка керү турындагы уйларың буш хыял гына булып калырга да бик мөмкин иде. Бер урынга еш кына алты-җиде кеше дәгъва кыла торган иде.*



*Мин үзем университетка армия хезмәтеннән соң, Алабуга désинститутыннан күчеп, икенче курска килеп кердем. Әле дә хәтеремдә, бер-берсеннән яшь аермалары ун-уникешәр ел булган студентлар төркеме беренче карашка бик чуар иде. Араларында инде дистә елга якын колхозда эшләп килгән олпат ир-егетләр дә, редакцияләрдә каләм чарлап, акыл утыртып өлгергән туташлар да, сәхнәдә үз урынын тапкан артисткалар да, әле хәрби киемен дә салмаган солдат егетләр дә бар. Ә инде яңа гына мәктәп тәмамлап килеп кергән яшьләр әле бөтенләй баласымаклар иде. Ләкин аларны бер нәрсә берләштергән икән. Үзенең дәрәҗәсен нык белеп, тирәсендәге яшь егет һәм кызларны сәгатьләр буе авызына каратып тота белүче шагыйрә Клара Булатова дисеңме, артык тыйнак, күзгә-башка артык чалынмыйча гына уйланып йөрергә яратучы Рәшит Әхмәтҗанов дисеңме, барысы да тормышта, әдәбиятта үз урыннарын тәгаенләп, ныклы бер максат белән укып йөрүче шәкертләр булган икән. Хәзер уйлыйм да шаккатам. Бигрәкләр дә кызыклы шәхесләр тупланган төркем булган икән ул! Бер группадан ике фәннәр кандидаты, дистәгә якын Язучылар союзы әгъзасы чыксын әле?! Алда исемнәре телгә алынган Клара белән инде мәрхүм Рәшиттән тыш, шагыйрь Харрас Әюпов, фольклорчы галим һәм шагыйрь Рәшит Ягъфәров, үткен каләмле публицист Равил Вәлиев, Татарстанның халык депутаты, озак еллар "Сөембикә" журналын җитәкләгән журналист Роза Туфитуллова, бүгенге көндә Уфа университетында татар әдәбияты укытучы Сәгыйть Хафизов, "Сөембикә" журналында эшләп ятучы язучы Роза Мулланурова, нәфис сүз остасы Диләрә Ильясова... Әле тагын авыл мәктәпләрендә балаларга туган телебез, әдәбиятыбыздан дәресләр бирүче, район газеталарендә журналистлык йөген тартучы сабакташларыбыз күпме!..*

*Менә шушы чуар төркемдә, әйткәнемчә, балалыклары белән аерылып торучы тагын бер төркемчек бар иде. "Сабантуй" газетенең баш редакторы, балалар язучысы Ләлә Гыймадиева (ул вакыттагы фамилиясе Сабирова) әнә шул төркемчек вәкиле. Без, армиядән кайткан егетләр, аларга ничектер баласытыбрак карарга күнеккән идек, әйтерсең, алар безнең кече сеңелләребез кебек тоела иде. Бәлки әнә шул мөнәсәбәтне тойгангамы, группада иң яше булган Ләлә бик кыю иде, уенда ни булса, телендә дә шул булыр иде. Ул кемне дә булса рәнҗетермен, үпкәләтермен дип уйлап та карамаган кебек, кемдә нинди җитешсезлек күрсә, шуны маңгаена бәреп әйтер иде. Һәм иң кызыгы шунда, башка берәү авызыннан әйтелсә, гомерлек дошманга әйләнәсе кешеләр, дөньяга күзләрен зур ачып сабыйларча караучы Ләләнең әйткәннәрен уенга боралар, яратып үзен үк үртәп куялар да, шуның белән вәссәлам була торган иде.*

*Ләләбез университетка кергәнче үк китап авторы буларак танылган иде инде. 1964 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган "Тылсымлы таяк" исемле күмәк җыентыкта аның – унҗиде яшьлек кыз баланың да балалар өчен язган хикәяләре дөнья күргән иде. Мондый бәхет бик сирәкләргә генә эләгә ул! Шул еллардан бирле үзе дә балалар сыман беркатлырак*

*тоелган, садә күңелле Ләлә Гыймадиева балалар дөньясына мәңгегә тугрылыклы булып калды. Университетны тәмамлаганнан соң Биектау вилаятенең Битаман карьясында унсигез ел буе балаларга тел һәм әдәбият укытты. 1988 елда Казанга күчеп килгәч "Яшь ленинчы" газите редакциясендә корреспондент булып эшли башлады һәм... монда да холкына хыянәт итмәде, бүгенге көнгә кадәр шул урында эшли бирә. Корреспондентлыктан аны җаваплы сәркәтиплеккә күчерделәр, соңра баш редактор урынбасары булды, хәзер исә баш мөхәррирлек йөген җигелеп тарта.*

*Авыл укытучысы булып эшләгән елларында балалар дөньясы белән тагын да якыннанрак танышу, үсеп килүче буында югары әхлакый сыйфатлар, дуслык, ярдәмчеллек, өлкәннәргә ихтирам, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләү теләге аның хикәяләренә, китапларына күчте. 1986 елда Ләләнең "Кызарган алмалар" дигән хикәяләр җыентыгы басылып чыккан иде. 1998 елда икенче китабы — "Мыеклы фәрештә"се дөнья күрде.*

*"Кызарган алмалар" китабына үз заманында рецензияне миңа язарга насыйп булган иде. Анда мондый юллар бар: " Балалар... Әле алар дөнья белән танышып кына килә. Күңел офыклары да әти-әни, туган йорт, туган авыл, коенып үскән күл, җиләк җыйган болыннан ары түгелдер. Әмма яңгыр тамчысында бөтен бер җир шары чагыла алган кебек, шул микродөньяда да бүгенге кешелекне борчыган мәңгелек проблемалар гәүдәләнә. Нәниләрнең чын дуслык һәм иптәшлекне ялганнан аера беләселәре, өлкәннәр тормышын аңлыйсылары килә. Нәрсә ул яхшы һәм нәрсә ул начар? — балалар күңелен шул сорау борчый. Автор нәниләргә дип атап язылган нәни генә хикәяләрендә бу мәсьәләләр турында нәкъ менә балалар күзлегеннән карап фикер йөртә дә инде. Монда ялыктыргыч дидактика да, үгетләү-нәсихәт тә, нәрсәнең чын, нәрсәнең ялган икәнен ярып салып, төртеп күрсәтү дә юк. Болары укучыларның үзләренә калдырылган. Әйтәсе килгәнен язучы ачык буяулар, бала күңеленә тәэсир итәрдәй наян төсмерләр белән җиткерә, уйланырга, фикер йөртергә урын калдыра.*

*Балалар өчен язылган, әмма уйнап түгел, ә алар дөньясына кереп, аны тирәннән аңлап, төчеләнмичә язылган әсәрләр укыйсы килә иде. Ләләнең бу китабы аз булса да әнә шул бушлыкны тутыра кебек, минемчә".*

*Ләлә Гыймадиева иҗаты хакында мин бүген дә шул сүзләрне рәхәтләнеп кабатлыйм. Бер генә теләк бар — күбрәк язсын иде, ешрак каләмгә тотынсын иде. Балаларыбызга яхшы китаплар, алар белән тиң күреп сөйләшкән китаплар кирәк. Хәер, монысы да булыр дип ышаныйк. Халкыбызга горнәдирдәй ике угыл, зыялы, тәрбияле ике егет үстереп бирган Ләлә ханым бүген ике онык сөя. Бу бәхет түгелмени?! Ә ул оныкларга китапны Ләлә язмыйча кем язар икән?! Тормышында түгәрәк бер датаны билгеләп үтәргә җыенып йөрүче группадашым һәм каләмдәшем Ләлә Гыймадиева хакында әнә шундый уйлар килде әле башка.*

**Флүс ЛАТЫЙФИ**

---

# Ләлә Гыймадиева

## КАПКА

ХИКӘЯ

Узган атнада Хәсән пенсиягә чыкты. Ыгы-зыгылы бәрәкәтсез вакытның үткәне сизелми дә калган. Туган авылын кайтып күрмәгәненә дә ун-унбишләп еллап булгандыр инде.

Хәзер менә вакыт аның өчен туктап калгандай булды. Ялга чыкканнан бирле җанына урын табалмагандай йөри, күнеле үткәннәрне барлый. Авылга кайтып килү ниятен әйткәч, хатыны да аның сүзләрен куәтләп җибәрде.

—Бар, бар. Балтаң суга төшкәндәй йөрисен, бераз һава алыштыруын булыр,—диде.

...Авылның исеме генә үзгәрмәгән. Ул белгән, газиз балачагы үткән авыл түгел иде инде бу. Икешәр катлы йортлар калкып чыккан. Эссе җәйләрдә урам

уртасы тоташ тузан иде. Хәзер анда да асфальт түшәгәннәр. Елга да саеккан, кипкән, шаулап утырган камышлары да юкка чыккан.

Хәер... ул үзе дә элеккеге Хәсән түгел бит инде. Балачак дусларыннан да акрынлар ераклашып бетте. Кайберләренең вафатларын да читтән торып кына ишетте. Исәннәре белән әллә нигә бер хәбәрләшеп торсалар да, күптән күрешкәннәре юк. Соңгы елларда бигрәкләр дә ыгы-зыгылы тормыш белән яшәлде шул, артка борылып карарга һичбер әмәл булмады.

Шулчак «дерт» итеп сискәнеп куйды Хәсән, җай гына атлаган җиреннән лып итеп туктап калды. Берсеннән-берсе монсу уйлары да кисәктән таралып бетте: аның каршысына, уйнаклап атлый-атлый, югары очтан Гөлнәзирә төшеп килә иде! Менә аралар бөтенләй якынайды, ул инде аның җылы якты карашын, менә-менә көлеп җибәрер төсле тоелган мөлаем йөзен тагын да әйбәтрәк шәйләде. Каушаудан, аптыраудан кулындагы төенчеген бер куйды, бер алды, үзе бер кулы белән инде сыегая төшкән чәчләрен аралады. «Саташам, ахры», дип уйлады, тик иреннәре аша «Гөлнәзирә-ә» дигән зәгыйфь аваз чыгып өлгергән иде инде.

Кызый кызулап барган җиреннән кисәктән туктап калды, гаҗәпләнүдән кыйгач кашлары өскә сикерде.

—Сез минем әбекәйнең исемен атадыгыз... Сез кем?

Хәсән тирән сулыш алды. Үзен кулга алырга тырышып, елмаерга азапланды.

—Шушы авылныкы мин, әбиең белән бергә укыдык. Соңгы кат мин аны менә синең күк чакта күргәнмендер, мөгаен.

Кызыкай йөзен тутырып елмайды, күрешергә ике кулын берьюлы сузды.

—Кызы-ык! Әбиемнең дә авылга күптән кайтканы юк. Әле менә мин мәктәпне бетергәч беренче тапкыр тәвәккәлләдем. Ул да авылда бит. Менә нинди шәп очрашу булачак!

Хәсәеннең исә күңелендә ургылып-ургылып Гөлнәзирә белән бәйле хатирәләр янарды. Күрше генә яшиләр иде, мәктәпкә дә җитәкләшеп бергә йөрделәр. Югары классларга җиткәч, күрше авылга барып укыдылар. Җилдән-давылдан саклаган, усал малайлардан яклаган өчен аннан «Гөлнәзирәнең тән сакчысы» дип көләләр иде. Үртәлү кая, киресенчә, аның исемен дустыныкы белән бергә атаганда күңеленең ничек ләззәтләнгәнен белсә иде алар! Аннары... аннары институтка керә алмады Хәсән, икенче елны армиягә китте, флотка эләкте, биш елдан кире әйләнеп кайтканда Гөлнәзирә педагогия институтын тәмамлаган, кияүгә чыккан, бер малай үстереп ята, диделәр...

—Үзең генә түгел, тавышың да әбиеннекенә охшаган,—диде Хәсән, үзе дә сизмәстән, кабат хатирәләренә бирелде.—Ул әле дә шулай матур җырлыймы? Сәхнәдән кертмичә, кабат-кабат сорап җырлаталар иде...

—Җырлый. Тик үзе өчен генә. Алай сәхнәләргә чыкканы юк хәзер.

—Күзләре дә әүвәлгечәме, зәңгәргә манган кебекме?—Хәсән кызыкайның җавабын тыңламый да иде, ул инде күңеле белән малай чагына кайткан иде.— Гәүдәсе класстагы башка кызлардан бөтенләй аерылып тора иде, зифа, сыгылмалы иде. Әле дә шулаймы? Бит урталарындагы чокырлары да исәнме? Ә толымнары... Син менә ник кистерден бу чәчләренне, озын чәч килешәрәк төшә бит...

Хәсән абыйсына ияреп кызый да дулкынлана төште, аның инде аларны тизрәк очраштырасы килеп сабырсызлануы иде.

—Әбекәйнең ерак туганнарына кайттык без. Менә, унга борылгач, икенче капка. Яшелгә буялган. Барыгыз, бар. Сез дә юлдан гына кайткан, кереп чәйләп чыгуыгыз да булыр. Мин дә хәзер кайтып җитәм, кибеткә генә барып килам.

Ул аны юл уртасында калдырып, баягыча уйнаклый-уйнаклый китеп барды. Хәсән исә, хисләренә тулышып, төенчеген кулына алды, егетләрчә эре-эре атлап, кыз күрсәткән якка юнәлде. Гәүдәсе тураеп, карашы яктырып киткәндәй булды... Яшел капкага җитәрәк, адымнарын акрынайтты. Һәм... шул талгын адымнар белән аны узып та китте. Күңелендә Гөлнәзирәнең унҗиде яшьлек чагы шәйләнә, оныгы белән сөйләшкәндә ул инде аны тәмам күргән кебек булып беткән иде. Бу—яшел капка артында бөтенләй икенче Гөлнәзирәне очратачагыннан куркумы, әллә яшьлек дустының яңа гына хәтерендә үзе кабат торгызган күркәм образын югалтачагын аңлап шөбһәләнүеме? Һәрхәлдә, арада кырык еллап вакыт ятканын ул яхшы аңлый. Әмма котылгысыз чынбарлыкка капка ачып кына кайтып керәсе килми иде.

# ҮЗБӘК АБЫЙ ҮЗ ИДЕ...

Үзбәк Саттаров, язучы булудан бигрәк, иң әүвәл Татарстан нефть хуҗалыгының зур бер житәкчесе, оештыручысы булып хәтергә килә. Ул озак еллар «Татнефть» берләшмәсенең генераль директор урынбасары булып эшләде. Ул елларда нефть эше башында үзебезнең җирлектә туып үскән зур җитәкче кадрлар аз иде әле. Күбесе килгән, дөресрәге, китерелгән кешеләр иде. Алар, гадәттә, күпмедер эшләгәч, дан-дәрәҗәләр алгач, җиңел килгән кебек җиңел генә китеп тә баралар иде...

Үзбәк Газиз улы - Әлмәт кешесе, нәсел-нәсәбәсе белән шушы җирнеке. Заманында Казан химия-технология институтында укыган, Ватан сугышында катнашкан, нефтьче һөнәренең бөтен нечкәлекләрен үзләштергән, зур һәм катлаулы тормыш юлы үткән кеше иде. Халыкта «башлы кеше» дигән сүз бар. Үзбәк абый чыннан да бик башлы һәм зыялы зат иде. Югары квалификацияле белгеч-инженер, уйлап табучы, техник фәннәр кандидаты, нефть һәм газ эшкәртү буенча күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы. Нефтьне товар рәвешенә кертү өчен беренчел эшкәртү ысулларын эшләүгә зур өлеш керткән кеше дип саный аны белгечләр. Ул биләгән постның рәсми исеме дә «нефтьне эшкәртү буенча генераль директор урынбасары» дип тикмәгә аталмый иде шул.

Югарыда әйтелгәннәр Үзбәк Саттаровның мәшһүр технарь икәнен расласа, якыннан аралашып йөргән кешеләр аның нечкә күңелгә, үткен телгә, образлы күзаллауга, әдәби куәгә ия шәхес итеп тә белә. Ул әдәбият-сәнгатьне үлеп ярата иде. Татарның зур талант ияләрен шәхсән белә, аралаша, хәл кадәри татар рухын күтәрүгә булышлык итәргә тырышты. Хәтердә, Әлмәткә Г. Бәширов, Х. Туфан, Ә. Еники, С. Хәким кебек зур язучылар, шагыйрьләр килсә, алар Үзбәк Газизович белән очрашмый калмыйлар иде. Ә атаклы җырчылар, музыкантлар, артистлар... Андый очрашу-күрешүләр, дустанә мәҗлесләр бихисап булды. Гариф абый Ахунов белән дә дуслыклары көчле иде. Гариф абый аны тыңлый, киңәшләрен тота, кеше буларак бик хөрмәтли иде. Ялгышмасам, Үзбәк Саттаров турында бер әсәр дә яза башлаган иде... Әлмәттә биш елга якын яшәү дәверендә миңа да Үзбәк абый белән еш аралашырга туры килде. Әлмәт язучыларының җитәкчесе идем ул чакларда. Эш дәверендә аның ярдәмен күп тойдым. Яшь кеше өчен вакытында таянычтерәк бик кирәк икән ул! Еш очрашылды. Кабинет өстәлләре арасында да, сәхрәләргә чыгып, табын корып утырулар да булды. Сүз иярә сүз чыгып, көндәлек вак-төяге дә, сәяси хәлләр дә сөйләнелә иде. Әлбәттә, җир мае - нефть турында сүз чыкмый калмый иде. Кая китә бу байлык? Бик үк ачылып бетмәсә дә, тоела, сизелә иде: үз байлыгыбызга үзебез хуҗа булмаганга эчтән сызлана, офтана иде. Минем турыдан төбәбрәк биргән сорауларга, акланырга тырышыпмы яки бүтән максаттанмы, «бүтәнчә була алмый ул!» дөньяда ике төрле системаның көрәше бара, сыйнфый каршылыклар көчәя һ. б. дип әйтеп ала иде. Чынлап, ианып сөйләве булгандырмы, әллә шул чор саклыгымы? Әллә мине тынычландырып үз-үзен юатуы булдымы?

Хәзер нефть якларында беркадәр вәзгыять үзгәрде. Тамчылап булса да, байлыгыбызны үз җиребездә калдырып, әҗерен күрә алдык. Җирле халыктан хуҗа тойгысы булган җитәкчеләр үсеп чыкты. Халыкка кирәк байтак йорт-биналар, сарай-корылмалар төзелде. Язу-сызу өлкәсендәге кешеләргә дә кояш елмаеп алды: «Рухият» дигән фонд ачылды. Бу фонд ярдәме белән менә дигән китаплар чыкты. Бу якның асыл затлары—Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими, Һади Атласыйлар рухы янәдән күңелләргә керә башлады... Болар Үзбәк Саттаров хыялланганды кайбер гамәлләр инде. Гөл чәчәкләрен үзләре күрә алмасалар да, шытымнарын алар—Үзбәк абый кебек ир-егетләр чәчеп калдырды.

Үзбәк абый зур язучы булырга өлгерми вафат булды. Ә телләгә көчле, мөмкинлекләре зур иде. 1980 елда аның балалар өчен «Алма биргәч ни диярга?» дигән китабы дөнья күрде. 1982 елда СССР Язучылар союзына кабул ителде. Бу китап турында «Совет Татарстаны язучылары» исемле биобиблиографик белешмәдә мондый сүзләр бар: «Нәниләр дөньясының сафлыгын, самимилеген, ышанучан, садә беркатлылыгын тормышчан ситуацияләр, оста тотып алынган детальләр аша сурәтләгән бу хикәяләр үзләренен

җыйнаклыгы һәм образлы теле белән аерылып торалар.» Бу бәяләмәгә әлләни өстисе килми, ризалашып баш кына кагасың.

Үткән ел бер төркем язучылар Әлмәткә баргач, татар гимназиясендә очрашу вакытында китаплар бүләк иттеләр. Алар арасында Үзбәк Саттаровның «Молекулалар дөньясына сәяхәт» дигән бик шәп китабы да бар иде. Кызыклы фәнни-популяр бу басма мәктәп укучылары, студентлар, гомумән, табигать байлыклары белән кызыксынган һәр кеше өчен менә дигән кулланма! Китапны Үзбәк абыйның шәкертләре М. Газизов, Р. Фәхретдиновләр төзеп, әзерләп чыгарган. Кеше китә, җыры кала, диләр. Әйе, кешеләр китә, ә сирәгенең генә җыры кала. Бу дөньяда җырың калсын өчен иң әүвәл кеше булуың кирәк, изге гамәл-хезмәтләрең кирәк, дәвамчыларың булуы кирәк!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

*Котлыйбыз!*

## АЗАТ ВЕРГАЗОВКА 70 ЯШЬ

Азат Фатих улы Вергазов 1932 елның мартында хәзерге Пенза өлкәсенең Неверкин районы Карновар авылында укытучы гаиләсендә туган. 1937 елда алар гаиләләре белән Татарстанга Яшел Үзән районының Зур Карауҗа авылына күчеп киләләр.



Азат Вергазов, Зур Карауҗа урта мәктәбен тәмамлап, 1949 елда Казан дәүләт педагогия институтының тарих факультетына укырга керә. Армия сафларында хезмәт итеп кайткач Зур Карауҗа мәктәбендә тарих һәм география укытучысы, Зур Җәке мәктәбе директоры булып эшли. 1970 елда А. Вергазов Яшел Үзән шәһәренә күчә, Казандагы 36 номерлы һөнәр училищесында укыта. 1974 елның көзеннән ул Казан телевидение студиясенең әдәби-драматик тапшырулар редакциясендә өлкән редактор булып эшли. Соңгы елларда Азат Вергазов Яшел Үзән шәһәрендәге 1 нче татар гимназиясендә укыта.

Азат Вергазов гомеренең иң зур өлешен яшь буынга белем-тәрбия бирүгә багышлаган кеше. Әдәбиятка да ул мәктәп дөньясыннан килеп керде, язган әсәрләре дә яшьләр турында. Аның шигырьләре, хикәяләре вакытлы матбугат битләрендә һәм аерым җыентыклар булып та басылып чыкты. Язучының һөнәр училищесы кызлары тормышын чагылдырган «Дулкыннар ни сөйли?» (1976), колхозлашу чорының драматик вакыйгаларын тасвирлаган «Ташу» (1979), яшүсмерләр тормышын сурәтләгән «Уяну» (1984), «Йөрәк җыр сорый», «Без—сезнең балалар» (1996) повестьлары дөнья күрде. Бу әсәрләрдә яшь буынга гаиләдә, уку йортларында һәм көнкүрештә дөрес әхлакый тәрбия бирү, кешелеклелек, саф мәхәббәт һәм ата-аналардан килгән күркәм традицияләрне дәвам иттерү мәсьәләләре дә күтәрелгән. «Без—сезнең балалар» исемле повестьта автор үзен аеруча борчыган проблема—яшүсмерләрне тәрбияли белмәүнең нинди зур рухи югалтулар, фаҗигаләргә китерүенә янадан әйләнеп кайта. Азат Вергазов үз геройларының кичереш-халәтләрен, характерларын, вакыйгаларны тәфсилләп, җентекләп, төгәл сурәтләргә ярата.

Азат Вергазов соңгы елларда Яшел Үзәндә әдәби «Аҗаган» журналын чыгарып килде, «Аҗаган» нәшриятына нигез салды.

Азат Вергазов—1984 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

*«Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлый, аңа сәламәтлек һәм яңа иҗат уңышлары тели.*

# Uqucı süze
# Укучы сүзе

* * *

Егерме ике ел стажлы тел укытучысы буларак, мин ирексездән кешеләрнең сөйләменә, язуына игътибар итәм. Күпме хата сөйләмебездә һәм язуыбызда! Моның сәбәбе без куллана торган кириллица графикасының камил булмавына барып тоташа. Йә, әйтегез, каләм, сәлам, гадәт, кадәр дип язу дөресме инде? Сөйләмдә, нәкъ менә латин графикасында язылганча: ***qələm, sələm, ğədət, qədər*** дип әйтәбез бит. Көн саен кулланыла торган сәгать сүзен генә алыйк. Бу сүзне язарга өйрәнү (ә укытучыга өйрәтү) үзе бер газап: ***г*** авазын калынайту өчен ***а*** хәрефе язабыз, ә аннары иҗекне нечкәртү өчен ***ь*** хәрефе өстибез. Ә сүз латин графикасында бик гади языла: ***səğət,*** ягъни нәкъ әйтелгәнчә. Гомумән, ***ь*** һәм ***ъ*** билгеләрен сүзләрдә урта мәктәп тәмамлаучыларның күпмесе генә дөрес куллана икән? Без хәзер куллана торган урыс графикасы сөйләмебезне гарипләндерә, язуыбызны хаталы итә, ямьсезли. Латин алфавитында уку һәм язу күпкә уңайрак һәм җиңелрәк. Чөнки бу алфавитта һәр авазга туры килә торган хәреф бар. Мәсәлән, ваза һәм вакыт сүзләрендә беренче авазны белдерү өчен бер үк хәреф куллану һич дөрес түгел бит. Шулай итеп, әгәр без камил, дөрес сөйләшергә һәм грамоталы язарга теләсәк, һичшиксез, язуыбызны латин графикасына күчерергә тиешбез. Билгеле, яңалыкны кабул итү һәрвакыт авыр. Латин графикасын өйрәнү дә җиңел булмаячак, бигрәк тә өлкән һәм урта буын кешеләренә. Еш кына: "Нәрсәгә кирәк ул? Без аны барыбер өйрәнә алмыйбыз" дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Урыс графикасына шулкадәр күнеккәнбез, шуңа күрә аның кимчелекләрен күрмибез дә. Латинга күчү дәвамлы процесс. Матбугатта, "Казан утлары" журналындагы кебек, текстлар биреп барылса, гади халык яна графикага ияләнәчәк, әкренләп өйрәнәчәк. Ә мәктәп укучылары өчен латин графикасын өйрәнү бөтенләй авыр түгел. Менә икенче ел инде мин мәктәптә балалар белән "Латин графикасына нигезләнгән татар язуын өйрәнү" түгәрәге алып барам. Укучылар латин язуын бик теләп һәм җиңел үзләштерәләр. Дәресләрне күбрәк уен формасында уздырабыз. Узган уку елында зур әзерлек белән "Йолдыз сәгате" исемле уен-шоу уздырдык. Һәр дәрестә, бөтен кагыйдәләренә туры китереп (барабан да ясадык), "Могҗизалар кыры" уйныйбыз. Укучылар текстларны инде җиңел укыйлар, шигырьләрне дә сәнгатьле укырга өйрәнәбез. Латин графикасына нигезләнеп, иншалар язабыз, иң яхшы иншага конкурслар уздырабыз. Дәресләрдә "Казан утлары"нда басылган шигырьләрдән, язмалардан файдаланабыз. Сезгә үрнәк текстлар биреп баруыгыз өчен зур рәхмәт. Алга таба да бу эшне дәвам итүегезне телибез. Тәкъдимебез—балалар өчен хикәяләр, шигырьләр, әкиятләр күбрәк бастырсагыз иде.

Мин латин графикасы турындагы фикерләремне, барлык журнал укучылар да укый алсын өчен, кириллицада яздым. Барлык журнал укучыларга яңа алфавитны үзләштерүдә уңышлар телим һәм балаларга укыр өчен түгәрәккә йөрүче укучымның үзе иҗат иткән һәм латин графикасында язган әкиятен тәкъдим итәм.

**Зәкия ШӘМСЕТДИНОВА,**
*Саба районы,*
*Юлбат авылы.*

# ALA QARĞALAR

əkiət

Borın-borın zamanda, əle min tumağanda bulğan əlege xəl. Minem ətinen̦ babasının̦-babası yəşəgən çorlarda bulğan bu. Ul waqıtta bøten qarğalar da keşeçə səyləşə belgənnər, cılı yaqlarğa da kitə torğan bulğannar.

Menə cəy axırları citkən. Ala qarğalar cıyılğannar da kin̦əşep alırğa bulğannar. Süz tuğan il belən sawbullaşu turında bulğan. Şul waqıtta ber qarğa balası qıçqırıp cibərgən:

—Minem tuğan ilem belən sawbullaşasım kilmi!

Qalğan qarğalar aptırap:

—Niçek inde alay?—digənnər. Şul waqıt awğan ağaç botağına qanatların əkren genə cilpep qart ala qarğa qunğan həm: "Bala døres əytə, nigə bez hər yılnın̦ kөzendə çit cirlərgə kitərgə tieş əle? Çıpçıqlar da yıraq kitmilər. Əydəgez, bıyılğı qışnı tuğan cirebezdə ütkərəbez. Kemnər minem belən riza—sulğa, riza tügellər un̦ yaqqa tezelep bassın",—digən. Ala qarğa kөtüe ike өleşkə bülenə başlağan. Son̦ınnan ikelənüçe qarğalar ğına qalğan. Şul yaqta ala qarğalar kübrək bulu səbəple, alar da qalırğa bulğannar. Qış citkən, suıqlar başlanğan. Qarğalar tun̦udan:

—Qar suıq,—dip zarlana başlağannar. Annarı, "Qarsu" diep kenə əyterlek køçlәre qalğan. Kөznen̦ son̦ğı atnalarında alar bøtenləy "qar" süzen genə istə qaldırğannar.

Yaz citkən. Ala qarğalarnın̦ xəlləren belergə in̦ berençe bulıp qara qarğalar qaytqan. Qara qarğalarnın̦:

—"Xəllər niçek?"—dip sorawına ala qarğalar:

—Qar, qar,—diep kenə cawap qaytarğannar.

—Qar qurqınıç, qar ala qarğalarnı xarap itkən,—digən qara qarğalar. Annarı üzlәre də başqalarğa iərep "qar" süzen genə əytə başlağannar. Ala qarğalar cəynen̦ cılı yan̦ğır yawıp ütkənnən son̦, cirnen̦ pıçraqlığın kürgən sayın, aq qarnı sağınğannar. Anı qabat küräselәre kilep tağın tuğan üskən cirlərendə qalğannar. Ə son̦ınnan bøtenləy iələşep betkənnər.

**Ruslan MƏCİTOV,**
*7 sıynıf uquçısı.*

## 2002 елда булачак Бөтенрусия халык санын алу уңаеннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының татар халкына мөрәҗәгате

Без, күпмилләтле Татарстан Республикасы халкы тарафыннан сайланган депутатлар, 2002 елда Бөтенрусия халык санын алуны үткәрү өчен әзерләнгән документлар проектлары белән танышканнан соң, бөтен халыкларның язмышы, шул исәптән, татар милләтенең киләчәге өчен борчылып, татар халкына мөрәҗәгать итәбез.

Русия Федерациясе Федераль Җыенының Дәүләт Думасында «Бөтенрусия халык санын алу турында» федераль закон проекты каралды. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы халык санын алганда файдалану өчен Русия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты тарафыннан әзерләнгән «2002 елда Бөтенрусия халык санын алу материалларын эшкәртү өчен милләтләр исемлеге» һәм «Милләтләр һәм телләрнең систематик сүзлеге» дигән документлар проектлары Татарстан Республикасы халык депутатларында һәм җәмәгатьчелегендә ризасызлык тудыра.

Бу документлар проектлары бердәм татар милләтен бернинди фәнни нигезләүләрсез, ясалма рәвештә берничә аерым милләткә ваклауны күздә тота. Шулай итеп, әлеге документ авторлары күп гасырлар дәвамында бер халык булып оешкан татар милләтен примитив кабиләчелек чорына кайтарырга маташалар.

Әлеге документлар тормышка ашырыла калса, бай әдәби телен, үзенчәлекле мәгариф системасын, кабатланмас мәдәниятен, сәнгатен һәм әдәбиятын булдырган татар халкы киләчәктә милли үзенчәлекләрен үстерү мөмкинлеген югалта барачак.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, вакыйгаларның мондый рәвеш алуы татар халкына гына түгел, ә Русия җәмгыятендәге һәм дәүләтендәге милләтара мөнәсәбәтләрнең тотрыклылыгына да куркыныч яный, чөнки бу вәзгыять илдә этник конфликтлар учаклары кабынуга шартлар тудырачак, дип искәртә.

Без, Татарстан Республикасы халык депутатлары, югарыда әйтелгән документлар кирәгеннән артык сәясиләштерелгән, халык санын алганда аларны файдалану татар милләтенең саны турында ялган мәгълүмат туплауга китерәчәк, татар халкының бу өлкәдә хокуклары тупас бозылачак, дип саныйбыз.

Әлеге документлар Русия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган очракта үз бердәмлеген саклап калу юлында татар милләтен авыр сынаулар көтә, бүгенге көндә сан ягыннан Русиядә икенче урындагы татар халкына юкка чыгу куркынычы яный. Бу тарихи сынау көннәрендә һәркем тирән уйлансын, үз милләтенең бөтенлеге өчен җаваплылыгын онытмасын иде. Төрле җәмәгать оешмалары вәкилләре, язучылар, галимнәр, дин әһелләре һәм дәүләт эшлеклеләре халык алдында, киләчәк буыннар алдында үзләренең җаваплылыкларын тоеп, милләтне ваклау сәясәтенә каршы төпле сүзләрен әйтерләр, ватандашларына татар халкының бердәмлеген ныгыту турында чакыру белән мөрәҗәгать итәрләр, дип уйлыйбыз.

Ата-бабаларын, тарихи тамырларын оныткан халыкның киләчәге юк. Язмыш кушуы буенча татарлар, бөтен дөньяга таралып, БДБ илләрендә һәм Русия Федерациясе төбәкләрендә яшиләр. Татар халкы бердәм булганда гына милләтенең көчен, бай мәдәниятен саклап кала алачак.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, татар халкы уяу булыр, тарихи бердәм милләт икәнен һәрвакыт истә тотар, 2002 елда халык санын алу нәтиҗәсендә дә үзенең бүленмәслеген һәм бердәмлеген раслар, дип ышана.

*17 гыйнвар 2002 ел.*

Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ЮБИЛЕЙЛАР ЯКЫНЛАША

6 февральдә Мәскәүдә Казанның 1000 һәм Санкт-Петербургның 300 еллыгын үткәрү буенча ике комиссиянең уртак утырышы булып узды. Утырышны әлеге ике комиссиягә җитәкчелек итүче Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин алып барды.

—Казанның 1000 еллыгы һәм Санкт-Петербургның 300 еллыгы—гомуммилли әһәмияткә ия булган вакыйгалар ул,—диде Владимир Путин. Әлеге чараларны үткәрү комиссияләре, аларны уртак үткәрү турындагы килешүгә кул куеп, бик дөрес эшләде. РФ Президенты әлеге тантаналарга әзерлекне бергә алып барырга кирәк булуын искәртте. Чөнки бу эшләр бер үк ведомстволар тарафыннан тормышка ашырыла. Кешеләр үз тормышында үзгәрешләр сизәргә тиеш, юбилейларга әзерлек программалары тормышны яхшыртуга юнәлдерелгән булырга тиеш. Юбиляр шәһәрләргә, тарихи һәм мәдәни традицияләрдән файдаланып, чын мәгънәсендә төбәкләр, сәүдә башкалалары, туристлык үзәкләре булып әверелүенә ярдәм итү зарур, дип саный ил Президенты.

Тантаналарга әзерлек барышында шәһәрләрнең тормышын тәэмин итү буенча конкрет проблемалар хәл итела башланачак. Әйтик, казанлыларга метроның беренче чираты тәзеләчәк. Кыска гына вакыт эчендә Казанны һәм Санкт-Петербургны тагын да гүзәлрәк һәм унайлырак итеп әвереллерергә ярдәм итәрлек йөздән артыграк инвестиция программасы тормышка ашырылачак.

Казанның 1000 еллыгына әзерлекнең барышы һәм расланган программаларны тормышка ашыру турында Татарстан башкаласы җитәкчесе Камил Исхаков сөйләде.

Комиссияләрнең уртак утырышында ТР Премьер-министры Рөстәм Миннеханов, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов катнашты.

## ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНӘ 10 ЕЛ

30 гыйнварда «Казан» милли мәдәният үзәгендә республика фәнни җәмәгатьчелегенең Татарстан Фәннәр академиясенә 10 ел тулуга багышланган тантаналы җыелышы булды.

Республика галимнәрен Дәүләт Советы рәисе, фәннәр докторы Фәрит Мөхәммәтшин тәбрикләде. Ул Президент Минтимер Шәймиев котлавын игълан итте. Билгеле булганча, 1991 елның августында, аның Указы нигезендә, Татарстан Фәннәр академиясе оештырылган иде. Республика җитәкчеләре Фәннәр академиясенең Татарстанның социаль-икътисади һәм рухи үсеше мөһим бурычларын хәл итүгә зур өлеш кертүен билгеләп үттеләр һәм дәүләтнең киләчәктә дә фундаменталь фәннәр белән беррәттән, гамәли фәннәр үсешен дә яклаячагына һәм интеллектуаль потенциалына теләктәшлек белдерәчәгенә ышандырдылар. Ф. Мөхәммәтшин Фәннәр академиясенең уңышларында аның беренче президенты, җыелышта доклад белән чыгыш ясаган Мансур Хәсәновның өлеше зур булуын билгеләп үтте.

Докладчы академиянең 10 ел эчендә Россиянең эре фәнни үзәгенә әйләнүен, фәннең өстенлекле юнәлешләре буенча эзләнүләр һәм тикшеренүләрне координацияләүче булуын әйтеп үтте. Хәзерге вакытта Фәннәр академиясе составында 35 хакыйкый әгъза, 68 әгъза-корреспондент һәм 10 почетлы әгъза бар. Аның җиде бүлеге гуманитар, биология, авыл хуҗалыгы, социаль-икътисад һәм хокук фәннәре, математика, механика, химия, физика, энергетика галимнәрен берләштерә. Узган еллар эчендә татар энциклопедиясе, тел, әдәбият һәм сәнгать, социаль-икътисади һәм хокук фәннәре, тарих, «Прометей» экспериментал эстетика институтлары булдырылды, информатика проблемалары институты академия карамагына күчте. Президиумда һәм академия бүлекләре

каршында җәмгыять һәм табигать фәннәренең әһәмиятле мәсьәләләре буенча 38 фәнни совет эшли.

Россия Фәннәр академиясе исеменнән галимнәребезне РФАның Казан фәнни үзәге президиумы рәисе, академик Александр Коновалов тәбрикләде. Казан шәһәре хакимияте башлыгы Камил Исхаков үз чыгышында Татарстан галимнәре белән тыгыз хезмәттәшлек турында сөйләде. Әзәрбайҗанның, Башкортстанның, Чуашиянең Фәннәр академияләре җитәкчеләре, Россия Федерациясе Сәнәгать һәм технология министрлыгыннан җылы котлаулар яңгырады.

Җыелышны Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева алып барды.

### ХАЛЫКАРА ОПЕРА БӘЙРӘМЕ

4 февральдә Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Ф. Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивале В. Моцартның «Фигароның өйләнүе» операсы белән ачылды. Тамаша алдыннан Татарстан мәдәният министры И. Тарханов опера сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Казакъстанның халык артисты **Нуржамал Үсәнбаева** белән театрыбызның баш дирижеры, Украинаның халык артисты **Игорь Лацаничка** Татарстанның халык артисты, опера төркеме җитәкчесе **Гүзәл Хәйбуллинага** Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирү турында Президент Указын игълан итте.

5 февральдә исә М. Мусоргскийның «Борис Годунов» спектаклендә төп партияне башкарырга Санкт-Петербургның Мария театры солисты, Русиянең халык артисты, дөньядагы иң яхшы биш бас тавышлы җырчыларның берсе дип танылган Владимир Ванешевның килүе опера сөючеләр өчен аеруча зур шатлык булгандыр. Дж. Вердиның «Аида» операсында шулай ук Мария театрының яшь җырчысы Младо Худолей җырлады.

8 февральдә фестивальне П. Чайковскийның «Пиковая дама»сы дәвам итте. Герман партиясен Грузиянең халык артисты Теймураз Гугушвили башкарды. Бүтән көннәрдә Дж. Пуччининың «Богема», Дж. Вердиның «Риголетто» спектакльләре куелды.

Ф. Шаляпин исемендәге XXI халыкара опера фестивале 10 көн буе дәвам итте. Бәйрәмдә катнашырга Русиянең иң зур театрларыннан, Һолландия, Австрия, Казакъстаннан 28 җырчы, музыкант чакырылган иде.

Шаляпин исемендәге XXI халыкара фестиваль 13 февраль көнне сәхнә йолдызлары катнашындагы гала-концерт белән тәмамланды.

### ГОСМАН ХӘЗРӘТ–ЯҢАДАН МӨФТИ

2 февральдә Казанда Татарстан мөселманнарының II корылтае булып үтте. Аның эшендә барлыгы 578 делегат катнашты. Көн тәртибендә Диния нәзарәте эшенә хисап ясалды, нәзарәт җитәкчелеге сайланды. Корылтайда катнашучылар Татарстан Диния нәзарәте эшчәнлеген канәгатьләнерлек дип бәяләде. Күпчелек тавыш белән мөфти һәм Диния нәзарәте рәисе итеп янадан **Госман хәзрәт Исхакый** сайланды. Аның беренче урынбасары итеп кабат Вәлиулла хәзрәт Ягъкуб билгеләнде. Баш казый булып Габделхак хәзрәт Саматов сайланды.

### ГАЛИМНӘР БҮЛӘК АЛА

Татарстан Фәннәр академиясенең президиум утырышында исемле премия ияләре игълан ителде.

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры профессор **Н. Хисамов** «XIII—XV гасырлар төркитатар шигъриятендә Йосыф һәм Зөләйха сюжеты» дигән монографиясе өчен—Ш. Мәрҗани исемендәге, ветеринария фәннәре докторлары, профессорлар **Х. Гафаров, А. Иванов** һәм Татарстан Фәннәр академиясе академигы **А. Равилев** К. Боль исемендәге премияләргә лаек булды.

В. Мосолов бүләге «Хәзерге технологияләр һәм нәтиҗәлелекне программалаштыру», «Җир ачкычы» монографияләре өчен авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең мактаулы әгъзасы профессор **А. Җиһаншин**га тапшырылды.

### «АК ЧӘЧӘКЛӘР» ХӘТЕРЕ

11 февральдә К. Тинчурин театрында татар әдәбияты классигы **Г. Әпсәләмовның 90 еллыгына** багышланган «Ак чәчәкләр» дигән әдәби-музыкаль кичә булып узды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин ачып болай диде:

«Габдрахман Әпсәләмов үз әсәрләрендә Ватанга мәхәббәт җырлады, саф, намуслы, рухи яктан чиста герой-образлар тудырды. Ул әсәрләре иң күп укылучы әдип иде, шулай булып кала да».

Кичәдә язучылар В. Нуруллин, М. Хәбибуллин, нәфис сүз остасы А. Арсланов һ. б. язучы турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар. Халык артистлары И. Әхмәтҗанов, И. Баһманов Г. Әпсәләмов

әсәрләреннән өзекләр башкардылар. Кичәдә, шулай ук, З. Сөнгатуллина, М. Галиев, Ф. Сөләйманова, М. Сөнгатуллиннар үзләренең җыр сәнгате белән катнаштылар. Бу тантанада Габдрахман Әпсәләмовның оныкчасы, яшь шагыйрә Альбина Әпсәләмовага язучылар таныклыгы тапшыру үзе бер символик мәгънәгә ия булды.

## ШИШКИН КӨННӘРЕ

Алабугада күренекле рус рәссамы **Иван Шишкинның туууына 170 ел** тулу уңаеннан юбилей чаралары булып үтте. Ул 24 гыйнвар көнне шәһәрнең «Космос» сәламәтләндерү базасында «Йөрәккә якын туган як» исемле региональ конкурс белән башланып китте. Анда Чаллы, Түбән Кама, Мамадыш, Менделеевск һәм Алабуга шәһәрләрендә рәсем сәнгате белән шөгыльләнүче яшь пейзаж ясау осталары катнашты. Юбилей кунакларын И. Шишкинның йорт-музее, һәйкәле һәм Алабуганың башка тарихи урыннары белән таныштыргач, конкурска йомгак ясалды, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды.

Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан, Казаннан, Калининград өлкәсеннән һәм башка төбәкләрдән килгән кунаклар И. Шишкин һәйкәленә чәчәкләр салдылар, региональ конкурста катнашкан яшь пейзаж осталарының һәм җирле рәссамнарның иҗат эшләре белән таныштылар. Ахырдан шәһәр мәдәният сараенда И. Шишкин юбилее хөрмәтенә тантаналы кичә үтте. Анда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин, республика Рәссамнар берлеге рәисе Абрек Абзгильдин, РФ Рәссамнар берлеге рәисе урынбасары Николай Соломин, бөек рәссамның нәсел дәвамчысы Николай Ридингер һ. б. катнаштылар.

## ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

Г. Тукай музеенда язучы **Мирсәй Әмирнең 95 еллыгына** багышланган әдәби кичә үтте. Аны музей директоры Мөжип Низамиев алып барды. Язучылар Мәгъсум Хуҗин, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Мөдәррис Әгъләм, Рафаэль Мостафин, Зәки Зәйнуллин истәлекләре белән урталкаштылар.

Кичәнең икенче өлешендә танылган артист Равил Шәрәфиев әдипнең «Газизҗан» хикәясеннән өзек укыды. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле җырчысы Рәшит Сөләйманов М. Әмирнең «Тормыш җыры» спектакленнән җырлар башкарды. Соңыннан Химиклар мәдәният сарае каршындагы гармунчылар төркеме чыгыш ясады.

Музей залында М. Әмир китапларыннан күргәзмә дә оештырылган иде.

## ЧУАШ ШАГЫЙРЕ МУЗЕЕ

Әлки районының Хузангай авылында зур тантана булып узды. Монда, чуаш халкының күренекле шагыйре **Педер Хузангайның** туган төбәгендә яңа музей ачылды. Музейны ачу тантанасына Чуашстаннан, Мари-Иленнән һәм Татарстаннан күпсанлы кунаклар—дәүләт эшлеклеләре, әдәбият-сәнгать вәкилләре, шагыйрьнең туганнары килгән иде. Тантанада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм Чуашстан Дәүләт Советы Рәисе Михаил Михайловский катнашты.

## БҮЛӘКЛӘР ТАПШЫРЫЛДЫ

15 гыйнварда күренекле татар әдибе Шәйхи Маннурның туган ягы Мамадыш районы Тулбай авылында Хәтер кичәсе үтте. Анда Казан һәм Чаллы калаларыннан бер төркем шагыйрьләр, язучылар килде.

Әдип исемендәге бүләк быел Казан компрессорлар заводының элекке директоры, 20 ел элек язучы истәлегенә чуеннан һәйкәл койдырткан техник фәннәр докторы **Әхмәт Галиевкә** бирелде. Әлеге бүләккә «Уйларымны бүләк итәм» дигән шигырьләр җыентыгы өчен унөч яшьлек **Алсу Мингалимова**, шулай ук хезмәт алдынгыларыннан **Әлфия Гыйльфанова, Мөбил Хәбибуллин, Назилә Хисмәтова** лаек булды.

## НӘФИС СҮЗ БӘЙГЕСЕ

Мәдәният министрлыгы һәм халык иҗаты үзәге халык арасындагы сәнгатьле укучыларны барлау, аларның профессиональ осталыкларын үстерү максаты белән нәфис сүз осталары бәйгесе оештыра. Аның I туры районнарда узса, II туры 26 апрельдә Г. Тукай музеенда үтәчәк.

Чыгыш ясаучыларның башкару осталыгына, сәхнә культурасына игътибар ителәчәк. Теләүчеләр 92-46-37 телефонына мөрәҗәгать итә алалар.

12 февральдә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, А. Алиш премиясе лауреаты, балалар шагыйре **Хәкимҗан Халиков** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# АЙ ШӘҮЛӘСЕ АСТЫНДА

60 еллык юбилее уңаеннан җәмәгатьчелек тарафыннан олылангач, зур мәртәбәләргә ия булгач та, Әхсән Фәтхетдин янадан тынгысыз иҗатка чумды. Бүгенге базар хосусияте, чама югалтып төрлечә кыланулар тулы тормышны да ул йөрәге аша үткәрә, борчыла, газаплана, уйлана. Бөек Аллаһыга сыгынганнар, хезмәт кешеләре, фәкыйрь-фокара аның иҗатында төп тема булып кала бирде. «Тәңре һәм ике уй», «Иярләр төнне көтә», «Чечня трагедиясе» һәм рәссамның бүгенге көннең вөҗдан сискәнүләрен тасвирлаган башка әсәрләре шуны исбатлый. Һәм ниһаять, соңгы еллардагы эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, бөтен «иярләрен», аларның җирләрен, йортларын, суларын, куакларын, өметләрен бергә туплаган олуг гомер кыйссасы—«Ай шәүләсе астында» исемле картинасы туды (1993—99). Бу—аның яшәеш келәме, туган халкының тормыш шәҗәрәсе. Яшел урман киңлеге, кәкре-бөкре кәүсәләр, кошлар, атлар, агачлар, түбәләр, күбәләкләр—һәммәсе дә оча, дулкынлана, чәчәк ата. Рәссамның бөтен өметләрен, хыялларын, иҗат турындагы уйларын, эчендәге иң тирән, яшерен тойгыларын ачып салган «Сюр»—сер.


Монда—суга баручы яшь киленнәр, көлтә тоткан аналар, түбәләрдә канатланып утырган малайлар, күзләренә моң тулган изге атлар, тәрәзәдән карап торучы уйчан фидакарь авыл фәйләсүфләре... Карыйсың, болар «иярләр» генә түгел, ә авторның гомер буе йөрәгендә сакланган, ләкин бүген дә тормышка ашмаган кешелекчелек, бәхет, җәннәт хакындагы өметләре. Анда бу биләмәнең хуҗасы—абориген-рәссамның ярымшашкан йөзе. «Үлемме бу, әллә яңаруның башымы?» Җанындагы айкалган вәхшәтне, аянычлы кичерешләрен яшереп, ул шушы гүзәл калейдоскоп-миражларны ясый: «Минем яшь тулы мөлдерәмә күзем—дингез. Аның кырыйларында өмет кошлары оча». Әхсән Фәтхетдин унга да, сулга да карамый, ансатрак һәм табышлырак кәсеп ягына авышмый, халык рухына тиң бу җирнең туфрагын, көлен, күзяшьле-өметләрен туплаган Зур Иҗатында кала.

Ул—эченә алтын-хәзинә яшерелгән мирас сакчысы, узганнарның эзен һәм халык язмышының бөеклеген укмаштырган туган авылы кырыендагы Өмет тавы төсле. Ана карап, узган һәм киләчәк буыннар Рәссам кылганнарның күләмен һәм мәгънәсен абайлардар, рухи яктан үсеп, тураеп китәрләр. Илендә андый Тау булуы үзе бер бәхет.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрә Нәҗибә Сафина.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Ниһаять, әдәбиятыбыз тарихында беренче буларак, «Татар хикәясе антологиясе» дигән исем белән егерменче гасыр татар хикәяләре тупланмасы дөнья күрде. Аны Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарды. Бу нәшриятның күп авторларның әсәрләрен туплаган җыйнама басмалар, бигрәк тә шигырь антологияләре чыгаруда тәҗрибәсе җитәрлек. Моннан ярты гасыр чамасы элек 1956 елда «Татар поэзиясе антологиясе» (8 мең данә), 1992 елда ике зур том итеп яңадән поэзия антологиясе (бусының тиражы бик аз—нибары 1,5 мең данә) чыкты. 1980 елда шулай ук «Балалар поэзиясе антологиясе» дә (10 мең данә) нәшер ителгән иде. Ниһаять, XXI гасырга аяк баскач, соңлабрак булса да, хикәяләр антологиясе!

Антологиягә Ш. Мөхәммәтовның узган гасыр башында иҗат ителгән «Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай», Ф. Әмирханның «Милләт тәрәккый иттерү», Ш. Камалның «Уяну» кебек әсәрләреннән алып, әле соңгы елларда гына язучы буларак таныла башлаучы Р. Зәйдулла, З. Хөснияр, Н. Акмал, М. Закир кебек яшьләрнең хикәяләре кергән. «Егерменче гасырда хикәяләр язучылар саны инде өч йөзгә якынайды. Антологиягә исә бер йөз унсигез авторның гына (!) әсәрләре кертелде. Димәк, җыелма тулы санала алмый» диелә төзүче искәрмәсендә. Шулай да хикәяләр хәзинәсенең иң төп өлеше урын алган бу басмада. Әсәрләр язылу вакыты тәртибендә тезелгән. Шунысы да мәгълүм булсын: антологиягә кергән байтак хикәяләр соңгы елларда «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» дигән рубрикада «Казан утлары»нда дөнья күргән иде инде.

*Антологияне төзүче, кереш мәкалә язучы, аңлатма һәм искәрмәләрне әзерләүче—**Мәгъсум Хуҗин**. Нәшрият мөхәррире—**Роза Заһидуллина**. Күләме—54 басма табак, 608 бит. Тиражы 5000 данә. Бәясе—123 сум.*

Индекс 73210



Нәҗибә Сафина

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)